# казан утлары

1. 1991



16

# ХИКӘЯЛӘР ЯРЫШЫНА ЙОМГАК

Билгеле булганча, «Казан утлары» 1990 елда иң яхшы хикәяләргә конкурс игълан иткән иде. Әлеге жанрның дәрәҗәсен һәм әдәби-эстетик куәтен үстерү, аңа каләмдәшләребезнең игътибарын тагын да арттыру максатыннан уздырылган бу ярышка илледән артык әсәр килде. Аларның иң яхшы дигәннәре журнал битләрендә басылып чыкты.

Ярышка килгән хикәяләр белән җентекләп танышканнан соң, жюри түбәндәге нәтиҗәгә килде:

— Беренче бүләк (300 сум) — **Миргазиян ЮНЫС**ның «Каравыл йорты» хикәясенә;

— Икенче ике бүләк (200 әр сум) — **Шәриф ХӨСӘЕНОВ**ның «Мәхәббәт һәм нәфрәт» һәм **Зиннур ХӨСНИЯР**ның «Кичү» хикәяләренә;

— Өченче өч бүләк (100 әр сум) — **Мәгъсүм ХУҖИН**ның «Кулаклар колхозы», **Рахмай ХИСМӘТУЛЛИН**ның «Чылбырлар» һәм **Зөлфәт ХӘКИМ**нең «Контра» хикәяләренә.

Жюри шулай ук **Әхәт Гаффар**ның «Утын», **Сафа Сабиров**ның «Яшен суккан имән», **Илдар Низамов**ның «Колаксыз Зариф», **Фәнис Яруллин**ның «Күкертле чишмә», **Дамир Гыйсметдинов**ның «Тамгалы бүрәнә», **Рафис Гыйззәтуллин**ның «Сиртмәле кое» хикәяләрен дә уңай яктан билгеләп үтте.

«Казан утлары» редакциясе җиңүчеләрне кайнар котлый һәм хикәяләр ярышында катнашкан барлык авторларга рәхмәт белдерә, каләмдәшләребезнең киләчәктә дә хикәя жанрына игътибарлы булуын, журнал белән ныклы элемтәдә торуын теләп кала.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИЖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР
БЕРЛЕГЕ
ЖУРНАЛЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

**1991**

**1**

ТАТАРСТАН
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Р. ЗӘЙДУЛЛА. Матәм. *Поэма* . . . . . . . . 3
Г. АХУНОВ. Гомер юлы. *Роман* . . . . . . . 16
Н. НӘҖМИ. Халкым арбасы. *Шигырьләр* . . . 85
М. МӘҺДИЕВ. Ачы тәҗрибә авазы. *Истәлекләр* . 88
Ә. ФАЗЫЛҖ.АНОВ. Сыерчык бураны. *Хикәя* . 121

ӘДӘБИ МИРАС

З. РӘМИЕВ. Гасыр башы шигъриятеннән . . . 127
Ф. АГИЕВ. Татар җыры. *Шигырьләр* . . . . 127
Х. ГАБИДОВ. *Шигырьләр* . . . . . . . . 128
Җ. ЗӘЙНУЛЛИН. Нәсыйхәтләр вә мәслихәтләр 130

ПУБЛИЦИСТИКА

Г. БӘШИРОВ. Гыйбрәт . . . . . . . . . . 134
Н. ДӘҮЛӘТ. Гәрчә анда тумасам да... . . . . 151

ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

С. МАННАПОВ. «Сәлам белән, Николай Иванович...» яки тапшырылмаган хатлар жанрында бер бәян . . . . . . . . . . . . . 159

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

М. ГАЙНЕТДИНОВ. Такташ һәм Такташлык турында . . . . . . . . . . . . . . 167
Ф. БӘШИРОВ. Егерме беренче ел авазы . . . . 171
Л. ИХСАНОВА. Аның сабаклары . . . . . . 174

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ф. САФИН. Зөлфәтнең яңа китабы . . . . . 176

Н. ҖИҺАНОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Ак рояль хуҗасы . . . . . 179

СӘНГАТЬ

Х. ГАБДЕЛКАЮМОВ. Горький өлкәсе җырлары . . . . . . . . . . . . . . . 183

ТАТАР ХАЛКЫ: ТӨРЛЕ ТӨБӘКЛӘРДӘ, ТӨРЛЕ ИЛЛӘРДӘ

Т. СУЫККАН. Швеция татарлары . . . . . 186
Котлыйбыз! . . . . . . . . . . . . . . . . 173, 187
Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре . . . . . . . . . . . . . 188
Мәдәният тормышы көндәлеге . . . . . . . . 190
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . 192

*Баш мөхәррир*

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

*Редколлегия*

ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘЖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛҮС ЛАТЫЙФИ
*(җаваплы сәркәтип)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш мөхәррир урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек мөхәррире)*
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек мөхәррире)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркәтип — 53-07-09,

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: роман Г. АХУНОВА «Дороги судьбы»; повесть-воспоминание М. МАГДЕЕВА «Глас горького опыта». Поэма Р. ЗАЙДУЛЛЫ «Траур»; стихи Н. НАДЖМИ; рассказ А. ФАЗЫЛЗЯНОВА «Метель-метелица».
«Литературное наследие»: статьи З. РАМИЕВА о творчестве поэтов начала XX века; стихи Ф. АГИЕВА и Х. ГАБИДОВА. Дж. ЗАЙНУЛЛИН — «Кладезь мудрости» — образцы восточного нравоучения. «Публицистика»: эссе Г. БАШИРОВА «Слово назидания»; статья ученого из Турции Н. ДАВЛЕТА «Хотя я родом и не оттуда...» «Актуальная проблема»: статья С. МАННАПОВА о проблемах книгоиздательского дела в Татарстане.
«Литературная критика»: статьи М. ГАЙНУТДИНОВА, Ф. БАШИРОВА, Л. ИХСАНОВОЙ.
«Библиография»: рецензия Ф. САФИНА на новую книгу поэта Зульфата.
К 80-летию композитора Н. Жиганова публикуется статья Р. ФАЙЗУЛЛИНА «Хозяин белого рояля».
«Искусство»: Х. АБДУЛКАЮМОВ «Песни Горьковской области».
«Татарский народ: в различных регионах страны и мира»: Т. СУЫККАН «Татары в Швеции».
Отмечается 60-летие Н. Юзеева и А. Тимергалина.
Навыки чтения на основе арабской графики.
Хроника культурной жизни.
На наших обложках — татарские монеты; портрет народного писателя Татарстана Г. Баширова.

*Бүлек мөхәррирләре:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Мөхәррирләр:* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Җәүдәт Миңнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Хезмәткәрләр:* Р. Вафина, Л. Гатауллина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина.

Производствога бирелде 13.11.1990 ел. Басарга кул куелды 31.01.1991 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 ... Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 44796. Заказ Д-557. Бәясе 1 сум 50 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1991 ел

## Ркаил Зәйдулла

# МАТӘМ

ПОЭМА

*Окину взглядом Север и Восток*
*песчаную и ледяную сушу,*
*и не географический восторг,*
*а мысль прожжет мятущуюся душу, —*
*о том, что предки шли не торопясь,*
*осваивая реки и наречья,*
*не для того, чтоб износилась связь*
*полустальная, получеловечья.*
*Землепроходцам — исполать и честь,*
*и полководцам — исполать и память*
*за то, что нефть, и лес, и хлопок есть,*
*и есть простор, где оборону ставить.*

Станислав Куняев

I

Сары торбалардан, җанны кыйнап,
Ниндидер бер ят көй ага... ага...
Зират каеннарын тибрәтә дә
Сузылып чыга ул авылга таба.
Туган җиремдәге шушы кабер
Мәңге төзәлмәс бер яра кебек —
Пуля тиеп егылгандай, авар
Армиядән үлеп кайткан егет.

Ул бабасы белән үскән иде,
Ятим иде — ялгыз куак гүя...
Бөтен афәтләрен — иң беренче —
Нигә язмыш ятимнәргә өя?

Әй син, көяз Мәскәү генералы!
Парижларда теккән мундир киеп,
Син сөйләмә безгә «бурыч»ларны,
Сискәндермә «дошман яный!» — диеп.
Без сизәбез сезнең кем икәнне...

---

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА *(1962) — шагыйрь, «Кояшлы күзләр» һәм «Күрәзә» исемле шигырь китаплары авторы. Казанда яши. Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты.*

Аптырыйбыз: ни Чын, ни соң Ялган? —
Безнең патриотизм хисләренә
Әфган якларында нәрсә калган?

Илбасардан илен саклый икән,
Исем әзер аңа, димәк — дошман!
Баскыннардан җирен яклаганнар —
«Басмачылар», —
Кемдер шулай кушкан.
Нигә һаман чит илләрне яулап
«Саклыйбыз» соң туган илебезне?
Җуя-җуя юлда атыбызны,
Җуя-җуя туган телебезне...

...Ябь-яшь кызый күз яшьләрен коя,
Башын бәрә-бәрә бусагага.
Хатын-кызның бәгыре шулай ката,
Күңелләре шулай усаллана.
Аның бүген шундый кара көне —
Сулыгып-сулыгып елый шул яшендә...
Шигыремнән мең мәртәбә авыр
Бу кызыйның сыңар күз яше дә...

Зират уртасында кан табыдай
Кала кабер, кала кәгазь гөлләр.
Онытыла ниндидер бер ят көй,
Комиссардан ишетелгән телмәр.

Контингентлар кайтыр туган илгә,
Континентлар җиңел сулап куяр.
Айшә исемле кыз ләкин мәңге
Шигыремә күз яшьләрен куяр...

2

Өстәл үзенә тарта аксакалны,
Ният тарта, ният — зурайды:
Телдән телгә күчсен, илдән илгә,
Набат булып суксын бу кайгы.
Язылганны балта юна алмый,
Төрмә көчсез аның янында.
Бәет яза шуңа төн ката карт,
Онытыгның манып канына:
«Тарих мең дә тугыз йөз дә
Сиксән бернең язында,
Күз яшьләренә чыланып
Бу хикәят языла».
Әюп картның тәүге бәете бу,
Соңгы бәет инде, төшенә.
Бик зур кайгы этәрде шул аны
Беренче кат иҗат эшенә.
Ә күзләре — бизмән чокырлары.
Мөлдерәмә тигез кайгысы.
Чайпала да тама ак кәгазьгә —
Ярап тора әле анысы...
Шылт итсә дә бәет чыгарганнар.
Чоры шундый булган. Ә монда
Онытын бер цинк табутка салып

Кайтарганнар туган ягына.
Батырларча үлгән, диләр менә...
Шулайдыр, ул — Әюп каныннан!
Ләкин нигә, нигә? Башка сыймый:
Ник әҗәл нәкъ аңа кагылган?

Узган сугыш каһарманы бу карт.
Булмый әле һаман онытып.
Кырык елга якын тынычлыкта —
Нигә табут? Нигә — оныгы?
Кызлар кулын тотмаган да иде.
Дошман әнә тоткан да утка,
Туган ягына ул юлга чыккан,
Юлга чыккан цинк табутта.

Яз, бәетең, әйдә, Әюп бабай,
Кемдер аны укып елар да
Искә алыр ерактагы улын
Һәм мәрхәмәт сорар еллардан.

3

«Нинди сугыш? Нинди Әфганистан?
Тукта тизрәк дөнья болгатудан! —
Сәвит Миннәт миңа төкрек чәчә:
— Сезнең нәсел болгатырга туган».

Көрмәкләнә бераз гына теле,
Чырай — кызыл, гәүдә шактый авыш.
«Онытма, ди, бабаң Зәйдулланы,
Шул көн көтә сине, пынимаеш!
Кычкырдылар теге вакытта да,
Ирек, диеп, хөрлек, фәлән-төгән...
Ну, без инде, ниттек, канишныжы,
Матрац тектек кызыл әләменнән.
Чүпрәк җитә — сәвит өстендә дә
Җилфердәде исерек тукымалар.
Контрларның оныклары хәзер,
Хаклык эзләп, җанда тукыналар.
Син дә артык сикеренмә, туган,
Дилбегәне бераз бушатудан
Ни үзгәрә? Тәртәсе бит имән!
Дуласаң да тәртәсенә тимә...
Яшәп булмый җир йөзендә ансыз:
Тәртә — тәртип, алар бер тамырдан.
Сталинның корыч кулы кирәк,
Сталинны
сагынып
мин каңгырам...»

Миннәт үлгән, беләм.
Ләкин бүген
Рух, сүз ирке, имеш.
Шуңа әнә
Йөзен әләм кебек җилфердәтеп
Ул дөньяга калкып чыга янә.
Даһиларның күләгәсе кебек,

Елмаюын төреп мыегына,
Безнең арттан килә.
Форсат житкәч
Иңсәбезгә сугар кыю гына.

Ә мине ул таный.
Карый шүрләп
Корбанының нәсел-нәсәбенә:
Бабаң кем? — дип анкеталар суза,
Шикле караш ташлый мәсләгемә.
Төкрек чәчә менә:
«Пыр-паганда!
Ни сүлисең анда, нинди афәт?
Һәлак булмаган бит мескен солдат,
Үлгән бары,
вафат булган, вафат!»

Цинк табут жиргә иңә бүген,
Мөхәммәтне алып үзе белән...
Алып батыр түгел,
Япь-яшь малай...
Чит...
жирләрдә...
гомере...
өзелгән...

4

Өч нокталар кәгазь өстенә
Күз яшьләре кебек түгелде...
Иртәгәге, кичәге түгел,
Кайгы шул ул — мәңге бүгенге.
Ярага тоз салма, дисезме?
Сугыш инде хәзер узган эш?..
Анысы шулай.
Тик яшь гомергә
Нокта кую менә кызганыч.
Шуңа ахры өч нокталар күп
Бүген минем кәгазь өстендә:
Сөрлегәм дә тагын кузгалам —
Яшьтәшләрем төшә исемә.
Күтәрелә һөҗүмгә алар.
Командирның кырыс авазы
Алга куа. Йөрәк урынында
Тибә бугай приказ кәгазе.
Экран буйлап чаба шәүләләр...
Нигә минем күзгә чалына соң
Кыядагы бер чалмалы баш?
Болытларга тигән чалмасы.
Мең биш йөз дә илле икенче
Елның шыксыз кара көзендә
Саклаган күк Казан каласын,
Гажизлек бар аның йөзендә.
Кулын суза ярдәм сорап ул
Мөхәммәттән, күктән, алладан.
Туганнарын сугыш үтергән,
Калаларын ялкын ялмаган.

Ә Мөхәммәт автомат алып
Төби аңа: сугыш — шобага...
Аккорд булып яңгырый залп
Төгәлләнми калган догага.

## 5

Хәрби советтан соң патша аңа тоткарланырга боерды.

— Без сиңа зур ышаныч күрсәттек, Шегали, — диде Иван, мыскыллы елмаеп. — Син канәгатьме?

Шаһгали, карашын идәнгә төбәп, түбәнчелек белән башын иде.

— Сезне Алла рәхим-шәфкатеннән ташламасын, галиҗәнаб...

Иван ашыкмыйча гына сүзен дәвам итте:

— Син Казанга иң башта һөҗүм итүче яуның башында булачаксың, чирүең ышанычлымы, шыр җибәрмәсме?

— Һич юк, галиҗәнаб, яугирләремнең барысы да кыю, аларны берни туктаталмас! — Шаһгали янә башын иде. — Безгә күнегәсе түгел, без һәрвакыт алгы сафта сугышабыз. — Аның тавышында горурлык төсмерләре сизелеп алды. — Казанда нинди ганимәт кулга төшәсен барыбыз да яхшы белә бит... Алып булса...

Иван тәхетеннән сикереп торды, арлы-бирле тыз-быз йөренә башлады.

— Алырбыз! — дип акырды. — Күрәзәчеләр әйтте: Казанның көне санаулы.

Шаһгалинең ирен читләре тартышып куйды. Шайтанымамы күрәзә? Шундый көч белән дә янә алып булмаса ул каһәр төшкән шәһәрне, хатын-кыз күлмәге генә киясе кала инде. Ә казанлыларның булыр-булмас илле мең гаскәре бардыр. Соңгы тапкыр хан булып торганда дарыларына да су салып китте ич ул. Казанның көчсезләнүе өчен турыдан-туры Шаһгалигә бурычлы Иван. Хәер, нәрсә белә соң сугыш эшендә бу маңка? — Казан халкына булган нәфрәте Шаһгалинең йөрәген кысып куйды. Өч тапкыр куып җибәрделәр бит... Югыйсә, куркак Мамай каны катнашкан шушы малай каршында баш иеп торыр идемени ул... Ул — бөек Чыңгыз нәселеннән булган Шаһгали бине Аллаһияр!

Ә бәлки... дүртенче кат урнашып калып булыр?

Иван тынычланган иде, кире тәхетенә барып утырды.

— Ханбикәнең хәле ничек? — дип сорады ул карлыккан тавыш белән.

— Аллага шөкер, галиҗәнаб, — диде Шаһгали. Үзенең күз алдына Сөембикәнең кара янган йөзе килеп басты. Кирмәнгә алып кайта алса да, йөрәген яулый алмады ул аның.

— Казанның диварлары биек, — дип тагын иске эзгә төште патша. — Яугирләрең сынатмасмы, Шегали? Ни әйтсәң дә, дин бер тел бер, кан бер дигәндәй... Укларның юнәлеше үзгәрмәсме?

Шаһгали акрын гына көлеп куйды. «Безнең кавемне белми икән әле бу...» — дип уйлады ул.

— Малның нәселе юк... — Аның күзләреннән идәнгә зәңгәр чаткылар чәчрәде. — Этләрең мал исен сизделәр инде, галиҗәнаб...

Шаһгалинең сүзләре Иванның күңеленә хуш килде.

— Син минем иң яхшы этем, Шегали, — диде ул, кулын өскә күтәреп. Бу — китәргә мөмкин дигән сүз иде.

— Алла сезне рәхим-шәфкатеннән ташламасын, галиҗәнаб, — дип тагын кабатлады Шаһгали һәм башын иеп ишеккә таба юнәлде.

Иван күз карашын аның шәлперәйгән колакларыннан ат яурыны кочакларга күнеккән кәкре аякларына күчерде. Авыр ишекләр акрын гына ябылгач, йөзен чытып идәнгә төкерде. Гүзәл Сөембикә пармы соң инде бу хайванга, дип уйлады ул...

6

«Көннәр озын... Гомер озын
кебек биредә.
Исә җилләр — истәлекләр
җанда терелә». —
Бер хатында шундый сүзләр
иде шикелле.
Бүген алар күңелемә
тиде шикелле.
Исте җилләр, истәлекләр
килде, чорнады.
Айкап чыкты шигырь уты
еллар-чорларны.
Ләкин бер көн күз алдында
тора да тора.
Керфекләр күләгәли дә
тагын яктыра.
Аның соңгы киче иде
туган өендә,
иясез уйнады гармун
авыл көенә.
Иптәшләре ашый-эчте,
иркен табыны.
Сагыныр ул бу кичәне,
бик тә сагыныр.
Әюп картка моңсу иде,
сизә, ахыры...
Ни язгандыр... Инде яхшы
бетсен ахыры.
Намаз саен юкса һәркөн
син теләк телә:
Хезмәт итәсе урыны
булсын дип илдә.
Кайтты да менә оныгы
бераз елмайды:
— Миңа — Кабул. Синең теләк
кабул булмады...
«Без китәбез, сез каласыз» —
җырлар җырланды.

Әюп бабай да авызын
йомып тормады.
Кыстап алды: «Сөйләшегез
берсәк салып сез...
Яуда, агай-эне, булмый
безнең халыксыз:
Түгел беренче мәртәбә,
үзем мин менә
үлми-нитми генә барып
җиттем Берлинга.
Минем бабайның бабасы
Парижны алган,
Бонапартның яңагында
уч эзе калган».
«Гололобый» малайларга
бу сүз хуш килде.
Ант иттеләр, без дә, диеп,
сакларбыз илне!

Озата чыкты Мөхәммәт
дусларын тышка...
Хушлашты.
Күз яшен егет
агызмас бушка.
Кем ул әнә тып-тын гына
почмакка поскан?
Бу — бергә китәсе дусты...
Күңелен коскан.
Авыртыр башы. Төзәтмәс.
Болай да төзек.
Мазар-и-Шәрифтә аны
алырлар өзеп.
Талпыныр җәеп кулларын,
гүя очар кош
омтыла туган җиренә!
Һәм иңри:
Хуш!
Хуш...

7

Йолдызлар монда ничектер эрерәк
өрәкләр озынрак һәм нәзек
көн саен алар ничектер буйга үсә
беләзекләрендә җирнең орбитасы
аларга бу якта күңелсез түгел
шуңамы шаркылдап көләләр кайчакта
сискәнәләр дә сәясәт кемсәләре
һәм таш төшеп китә тау башына җиткәч
һәркем үз илен сагына
үлем күргән күңел нечкә була гаҗәп
дөнья яулый
урыс малае владимир
мөхәммәт
таҗик турсун

кырым татары әмәт
курыкмыйлар чалмалылар чалуыннан
өрәкләрдән өрекмиләр диеп булмый
тик кайвакыт моңсу булып китә
каен яфрагын куясы килә йөрәк турына
уяу алар уянырга кирәк түгел
тегеләр бит төбәлгән ди бу төбәккә
океан аша дәгъва итәләр икән
бу ил безнең
тормыш интересларының сферасы диеп
дошман һөҗүмгә ташлана
телләрендә алла
мөхәммәт өммәте
мөхәммәтнең автоматы кыза
өммәте юк өмете генә исән
россия ул һәрчак тынычлык тели
һәм «саклана» алга бара-бара
соңгы сугыш
шәһит киткәннәргә соңгы
соңгы сугыш башланмаска тиеш
йолдызлар монда ничектер эрерәк
өрәкләр озынрак һәм нәзек
лепкәләре эләгә дә гөмбәзгә
йолдызлар җиргә коела гүли-гүли
күтәрелә мәңгелек тузан

8

## Мөхәммәтнең көндәлегендәге сөйгән кызына атап язылган юллар

Сезнең турда басып тордык...
Ни турында сөйләштек без?
Истә дә юк. Сезнең тур ул
Мәхәббәттә безнең «ликбез».

Иң кирәк сүз иреннәрдә
Кипшенгәндер, дым коткәндер...
Безнең өчен җир йөзендә
Соңгы дошман дөмеккәндер...

Җилләр исте арабыздан,
Орынды кошлар канаты.
Дәррәү яфрак ярды каен,
Һәрбер яфрак — сәлам хаты...

Күтәрсеңме мине, дидем.
Карашым белән кагылдым.
Моңсуланып синең күзләр
Керфекләреңне ябынды.

Кем китмәгән, кем кайтмаган?! —
Безгә бит ул уен гына...
Син кулъяулык суздың шул чак
Кыенсына-кыенсына.

Тиз генә алып яшердем.
Бөркелде күңелем эченә
Хушбуй исе белән бергә
Синең тәнеңнең исе дә...

Күтәрсеңме мине, дидем.
Кабатладым ахмак сыман.
Дәррәү яфраклар коелды —
Пышылдадың: Вәгъдә — иман...

9

Мөхәммәтнең автоматы тынды.
Тау кымшанып куйды:
«Дөмекте!»
Кояш — шул ук. Җир дә...

Татар ята —
Өммәте юк... Сүнгән өмете.
Тор син, батыр, тор, яшьтәшем минем!
Әнә дошман, әнә, үрмәли.
Ә Мөхәммәт берни ишетмәде!
Ә Мөхәммәт берни күрмәде!

Дерелдиләр бераз керфекләре.
Исән икән, шөкер.
Тор инде!
Туган якның дымлы болытлары
Юешләсен канлы иренне.
Ерагая туплар гөрелтесе,
Тынлык били якын-тирәне.
Ә Мөхәммәт берни ишетмәде,
Ә Мөхәммәт берни күрмәде.

Күкне терә керфекләрең белән!
Ава...
Авыр, гүя кургашын.
Күк астында, чит-ят күк астында
Сытылдың син, дустым-чордашым!
Тор, син, батыр, тор, яшьтәшем минем.
Исән килеш җырга кер әле?
Ә Мөхәммәт берни ишетмәде...
Ә Мөхәммәт берни күрмәде...

## 10

Озын-озак гыйбадәттән соң, князь Всеволод кятибен чакырып алды. Кятиб ишектән ничектер яны белән керде, тиз генә килеп өстәлгә каурый каләмен куйды, суларга да куркып хуҗасының йөзенә текәлде. Князьнең кәефе юк икәнен ул ишеткән иде инде. Соңгы арада аның кәефе юк шул. Халык хәерче — эшләмәгәч ничек бай булсын? — дружинага түләргә акча юк...

Димәк, яу, яу, яу!

Ганимәт мал Владимир иленең эшләрен җайга салыр, шөһрәтен тагын да өскә күтәрер.

Князь майланган озын чәчләрен артка сыпырып куйды, шешенке күз кабакларын иренеп кенә күтәреп кятибенә карап алды, алдындагы сыра чүлмәген читкә этәрде. Мәгәр сүз башларга ашыкмады.

Болгарларны җиңү җиңел булмас.

Җиңәрбез.

Ач бүренең ачуы яман...

Болгарлар сугыш белән бик мавыкмый, алар сәүдә итә, монда да туар-ишләре күп... Князь үз сәүдәгәрләренең дә сугышка каршы булуын искә төшерде, җирән төкләр баскан дәү йодрыгын йомарлады. Урыс сәүдә итә беләмени?! Урыс — сугышчы! Яугир! Сугыш булмый торса, эчкегә бирелә ул. Менә болгарларның умырткасын сындырыйк әле. Кан кирәк, яңа кан кирәк урыска! Югыйсә тамырлардан аракы ага башлады. Добрыня баһадир кебек борылып китмәбез, итекләрен салдырырбыз, җирләрен воеводаларга өләшербез, чабатага калыр болгар!

Тик кыпчаклар килмәде, каһәр. Алар да булышса, болгарларның көлен бөтенләй күккә очыра идек...

Князь кипшенгән иреннәрен сыра белән чылатып алды.

Ә бит төркиләр мәңге бер-берсе белән алышырга яратты. Аларның бит һәрберсе үзе генә өстен калырга тырыша. Бу юлы Хан нигәдер киреләнде: «Без бер халык, бер-беребезнең канын кою — язык», — дигән була

мөртәт. Басурманнар! Димәк, кыпчаклар да Магометка табына башлаган.

А-а, хәйләкәр Хан, бер халык, язык-фәлән дип маташа, князьнең казнасы бушаганын сизгән ул. Җиткергәннәр...

— Яз! — дип боерды князь. — Хөрмәтле туганым — Бөек князь Святослав!

Тик нәрсә язарга? Болгарларга каршы барырга кыпчак ханы риза булмады, дипме? Үтенечемә төкерде, дип акланыргамы? Святослав миннән кычкырып көләчәк бит, бөтен Киев көләчәк...

— Кыпчакларны чакырырга теләмим, — дип хатын дәвам итте ул. — Аларның нәселләре дә, телләре дә бер үк.

Төркиләрнең бер-берсенә
кылыч күтәрергә баш тартуын
тарих шулай хәтерли.
Шуңа күрә бу гайре табигый вакыйганың
төгәл елы да билгеле —
милади белән 1183 сәнә.

## 11

Цинк табут инә... Кем соң анда?
Бу турыда сүзне башламам.
Мәшриктән мәгърибкәчә җирләр
Безнең халык белән ашланган.

Ыргылганнар яуга җайдагатлар,
Татар аты — затлы,
ашәке...
Тараткannар сөңге очларында
«Урыс коралы»ның дәһшәтен.
Үз атына мәхәббәтле халык
Ят дан хакына яуга атылган.
Көенә белгән Сөембикә өчен,
Һәм Шаһгали кебек сатылган.

Эзләр белән чуарланган дөнья.
Тузан сарган. Әмма ап-анык —
Бу эзләрне бабаларым салган,
Таныйм бабаларым табанын.
Мәшриктән мәгърибкәчә җирдә
Шул ук эзләр, шул ук — охшаган.
Ул эзләрне мин Польшада күрдем,
Яңа хисләр кайтты Польшадан.

Ят төбәккә алып китте «Фиат».
Ят ук түгел бугай бу юлы.
Чатта торган такта юл күрсәтте
Алга...
Анда — «Татар авылы».

Магистрның калын муенына
Туган морза аткан аркандай
Суырып алды чорлар.
Кан, кан тартты —
Ниндидер бер магнит бар канда.

Җиде-сигез татар калган, имеш.
Даны белән миңа ят алар —
Тевтоннарның тимер когортасын
Ботарлап юк иткән татарлар.

Яхшы беләм: су үзгәрсә әгәр,
Тел үзгәрә, холык үзгәрә...
Нидер кала икән: таныш төсмер
Киң тупсалы йөздә, күзләрдә...
Талпынды уй —
Галиҗәнаб Тарих
Туктамышта туктап калгандыр.
Бу хыяллар чындыр әле, баксаң,
Ә чынбарлык үзе ялгандыр?

— Исәнмесез! — дидем бер бабайга.
Карашында өркү, шик иде.
Җиргә килеп төште минем сәлам
Ук эләккән шоңкар шикелле.
СССРны уйлап чыгып киттем
Манарасы биек мәчеттән.
Күзләремне дым элпәсе япты,
Иренемдә калды әче тәм.
«Мөхәммәде...» — диеп суздьı мәзин,
Бу исемнең көче әле бар...
Каравылчы Али дога кылды,
Монда да күп икән Алилар.
Үзебезчә бер сүз әйт әле син! —
Тәкрарлап бер җырлар язарлык.
Онытылган,
үлгән,
корыган тел...
Бер сүз калган — мазар.
Мазарлык...

Үз атына мәхәббәтле халык
Ят дан хакына яуга ялланган.
Идел кичкән үчен кылыч итеп,
Тик чорларны кичә алмаган.

## Мөхәммәтнең көндәлегендәге үзе өчен язылган юллар

«Олтанында туган җир җылысы!
Юнәлсәң дә кайсы якларга,
Син баскан төш, димәк, татар җире,
Туры килер аны якларга».

Минем сүзләр түгел, бабайныкы.
Бабасыннан күчкән аңа да...
Ахры алар мондый сәфәрләрне
Егетлеккә, данга санаган.

Урта гасырлардан килгән сүзгә
Мөнәсәбәт анык, билгеле...
Ләкин көрәш — һәр чорда да көрәш,
Син мәйданда — бирмә биленне!

Дөнья монда — мөлдерәмә касә.
Мөлдерәмә... Вакыт аңларга:
Кем язмышы канга әверелер —
Соңгы тамчы булып тамарга?

Сәер сугыш бара, соңгы сугыш...
Син солдат тик — гамәл аклана.
Ут яңгыры.
Аеру да кыен —
Кем яу чаба, ә кем саклана.

«Йөрәгеңдә туган җир җылысы!
Юнәлсәң дә кайсы якларга,
Син ауган төш, димәк, татар җире,
Туры килер шунда йокларга».

Тик җир килешмәсә кеше белән?
Таш шикелле монда җир — каты.
Безнең җир ул бары — без күчәсе
Тыйнак, моңсу татар зираты...

Бу яклар ят безгә.
Кояшы да
Мунча миче булып торырлык.
Тауларында безнең күңелләргә
Аңлашылмый торган горурлык.

Шуңа миндә нәфрәт.
Һәм курку да...
Яшеренгән анда дошманым.
Кем әмерен, белмим, үтидер ул,
Ә мин командирым кушканны.

Ә кушканны үти беләбез без!
Шуңа күрә БАСКАН җиремнән
Мин чигенмәм!
Һәрбер ташы аның
Безнең җаныбызга төренгән.

*Кем килде исә җиһанга, шик юк ки, китәр...*

Сәйф Сараи

Үзгәрмәс хакыйкать белән кеше килешергә мәҗбүр. Алтын Урда дәүләте заманында яшәгән борынгы шагыйребезнең бу юллары дөнья беткәнче мәңгелек турында уйларга этәрер...

Җиһанга һәркем бертөсле килә. Ләкин һәрберсе үзенчә яши, үзенчә китә. Ни рәвешле китә? — юкка гына шушы сорау меңнәрчә шагыйрьләрнең күңелен бимазаламагандыр...

Солдат чит дәүләттә батырлача һәлак булды. Тик ни өчен? Ни хакына?

Йөзләрчә татар егете әфган туфрагына башын салды.

Кем җибәрде аларны анда?

Һәр халыкның язмышы үз кулында булырга тиеш.

Язмыш атының йөгәне кем кулында, атның язмышы да шуның кулында.

Бер иярдә ике җайдак була алмый. Иртәме-соңмы аның берсе егылып калырга тиеш. Чәрдәкләнгән башын акрын гына тарих тузаны күмәр...

Асылда, бу дөньяда бар нәрсә дә вакытлы. Яралар төзәлә, кайгылар басыла.

Әюп бабай, онытының үлеменнән соң тагын да бөкрәя төшсә дә, саусәламәт кенә йөри әле. Дөрес, ул хәзер үзалдына нидер сөйләнеп йөри, күзләре дә моңсурак, әллә еллар элпәсе каплаганга гына шулай моңсу тоеламы? Еш кына ул эшләпәсен алдын артка кия, кайчакта ыштанын төймәләргә оныта. Сәер гадәте дә бар: тик торганда «идрит-кудрит!» — дип кычкыра да, офыкка карап кемгәдер йодрык болгый.

Ә офыклар һаман алсу...

Айшә исемле кыз шәһәргә эшкә киткәннән соң озак тормады — урыс егетенә кияүгә чыкты. Инде малае йөгереп йөри, диләр. Аңа Володя дип исем кушканнар, имеш. Владимир Ильич Ленин исталегенә...

Сулар ага, ага... Күкләр авырлыгыннан каберләр иңә. Җир бирә, җир ала. Гомер — бер уемнан бер уема уй тизлегендә сикерү генә...

Мөхәммәтнең дә исемен сирәк телгә алалар хәзер. Хәер, Павлик Морозов исемендәге дружинаның яшь пионерлары үз отрядларына Мөхәммәт исемен алу өчен ярыш башлаганнар дип, район газетасында пионервожатыйның хәбәре басылып чыккан иде, ни белән беткәндер, авторга мәгълүм түгел.

Мин шуны беләм: кәҗәсенә печән сорап баргач, авыл советы рәисе Әюп бабайдан Мөхәммәтнең Әфганстанда һәлак булуы хакында белешмә китерүен таләп иткән: «Бәлки ул малай анда үпкәсенә салкын тиеп кәнкәйгәндер?..»

«Бездә шундый закун! —
Галстугын
Төзәткәләп куйды Миннәтев. —
Безнең алда юньле кәгазь булсын,
Справка китер юнәтеп...»

Бу соң әллә сәвит Миннәтенең
Оныгымы? — бигрәк охшаган.
Күзне шүрләтерлек шәрә җанын
Яхшы кәчтүн белән тышлаган.

Алар барсы бер нәселдән ласа! —
Мәңге-мәңге бетмәс бер токым
Илне киләчәккә әнди һаман,
Каплаштырып бераз ертыгын.

Утыра менә иркен бүлмәсендә,
Белә кулның кулны юганны...
Тагын кая юллар авылдашын —
Кайсы яуга? — «өлкән туганы».

Миннәтевме, әллә Шаһгалиев? —
Йөзе бер үк аның асылда:
Үгез үлсә — аңа калҗа бары,
Утын була — арба ватылса.

Мөхәммәтең-ниең аңа нәрсә?
Ул матдәгә бары ышанган.
Рух ят аңа...
Ул Рух — безнең аңда
Котылырга тели тышаудан.

*Ни газизрәк — бу ватанмы?*
*Аһ, туган каумем газиз!*

Дәрдемәнд

Минем сүзем үләннән дә түбән.
Мин пышылдыйм, алар шыбырдаша.
Тамырлары буйлап аска саркыйм —
Аралашам гади шигырь аша
Чорлар белән...
Чорнап ала мине
Әллә кайчан онытылган зарлар —
Калкулыклар тауга әверелә,
Бер-береннән ерагая ярлар.
Пәрдә кебек күтәрелә офык —
Сәхнәләргә безне дәшә мәллә?
Белмиме ул — ат уйнатып булмый
Үләннәрдән түбән яшәгәндә.

Буразнада күзе алашаның,
Кемнәрнеңдер нигә талашканын
Ишетми дә... Уе аның олы:
Ул камчыдан өркә, көтә солы...

Тик җыенмыйм гаепләргә аны:
Кымшандым да бераз буразнадан,
Казна эше кире җиргә кысты,
Калкынырга, ахры — юк, язмаган...

Хәтерләтә җирем язгы таңда
Ашъяулыкны... Матур чигелеше.
Буразналар сала безнең халык,
Межа салмый дәүләт чиге өчен.
Чиктә түгел һич тә илнең көче,
Чиксезлектә — кодрәт.
Чикләнмибез.
Галәм ирене тигән туфрактан без —
Шуңа күктән йолдыз чүпләмибез.

Минем сүзем тын сулардан да тын.
Бу күз яше, гүя соңгы балык,
Мәрхәмәтме көтеп читкә чәчри? —
Сеңдерәлмәс аны чиккән яулык.
И син, сүзем, — тын сулардан да тын, —
Ник җанымда табалмыйсың урын? —
Оран булып түгел, бер гамь булып
Колаклардан колакларга орын.

... Кидергән чак булды җырга зынҗыр,
Чигәләрдән үткәрделәр чикне.
Тик Иманны җанда саклап,
Барыбер
Илтәчәкбез киләчәккә тикле.

Иләмәннең биләмәсе бүген —
Туган тел ул!
Менә минем Ватан.

Соңгы көне булып сүреләм дә,
Өр-яңадан таңы булып атам.

Әй тегермән исән...
Таш әйләнә...
Кемгә тагын, кемгә, кемгә матәм?
Бичаралык...
Мин дә менә хәзер
Дон Кихотны бәлки хәтерләтәм.

Кайда соң юл?
Кем юлбашчы бүген?
Йөрәкләргә сукмак кайдан уза?
Бармак яный һаман, уяна да,
Колымада кол биләгән Хужа.

Үз язмышын башка халыкларга
Тапшырган да татар — мескен кавем, —
Тыңлап ята хәзер хужаларның
Үз исеменә матәм уйнауларын.

Җилләр исә. Диләр: Үзгәрешкә!
Һәр җил арттыра тик канат көчен...
Коммунизм язар бу тегермән,
Безнең канга манып канат очын.

Кайда соң юл?
Эзлим юлбашчыны...
Исән-имин ярга чыгарырлык.
Көчләп җиккән имән тәртәләрдән
Мескен алашаны тугарырлык.

Без кем белән бүген ярашабыз?
Без кем белән тагын талашабыз?
Кайчан сикерер җиргә толпар булып
Йөрәктәге мәхлук алашабыз?

Кидерсә дә дошман җырга зынҗыр,
Чигәләрдән үткәрсә дә чикне,
Безгә тигән өлеш — бу Иманны
Илтешергә киләчәккә тикле.

Шигырь юлым — бал кортының юлы.
Мин бал эзлим җаны хәстәләргә.
Әгәр чаксам — ул да дәва өчен,
Соңгы юлга сезне хәстәрләргә.

Кыяматка кадәр эзлим мин юл!
Сездә әллә кайчан җуелганны...
Җуелса да фани чырайларда,
Язмыш тактасына уелганны.

Эзлим мин юл.
Йөрәкләрдән эзлим —
Табарбызмы кыяматкә хәтле
Мөхәммәтне — димәк, мәхәббәтне,
Мөхәммәтне — димәк, мәрхәмәтне?!

*1987 — 1990*

**Гариф Ахунов**

# ГОМЕР ЮЛЫ

РОМАН

*Авыл кешесенең язмышын җиңеләйтү өчен армый-талмый көрәшкән, шул изге ният хакына күп төрле авырлыкларга, мыскыллауларга түзгән олы җанлы кешеләргә — колхоз рәисләренә тирән ихтирам белән багышлыйм бу әсәремне.*

Автор

## Беренче бүлек

### I



Сорочьи Горы» кичүенә җитәргә ун чакрымнар кала яңгыр яварга тотынды. Тимергалиев, ян тәрәзәдән башын тыгып, күккә, якындагы урманга күз салды. Күктә болытлар куера, урман буендагы каеннар куәтле җилдән чайкала иде.

— Оho! — дип куйды Тимергалиев, үз алдына сөйләнгәндәй,— эшләр начар бит болай булгач...

Аның белән янәшә, машинаның арткы утыргычында тыныч кына утырып килгән Фәһим абзый, плащ якасы эченә муенын яшереп, сүзсез бара: әллә йоклый, әллә уйга талган иде,— башын күтәрде:

— Ә? Нәрсә?..

— Яңгыр килә, иптәш председатель. Бик көчле булырга охшаган.

— Яңгыр? Ә нигә? Беренче явуы түгел бит,— диде Фәһим абзый, кесәсеннән дүрткә бөкләнгән чиста кулъяулыгын сабыр гына чыгарып, черем итеп алган чакта шешмәкләнебрәк киткән күз кабакларын сөртте, биек маңгае өстендәге пеләшенә кагылып алды.— Тоз түгел, эремәбез, иптәш секретарь, яңгыр кирәк иде әле.

— Анысы шулай,— дип килеште аның белән караңгы чырайлы Тимергалиев,— тик менә паромга җиткәндә башлануы начар яңгырның: биредә кунып калырга туры килмәгәе, машина эчендә...

---

**Гариф АХУНОВ** *(1925) — әдип, татар һәм рус телләрендә утыздан артык китап авторы, Татарстанның Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре. 1981—1984 елларда Г. Ахуновның дүрт томлык әсәрләр җыелмасы басылып чыкты.*

«Сорочьи Горы» га килеп җиткәч, эшләрнең тагын да мөшкелрәк икәне билгеле булды: тау астыннан башлап биек үргә менеп җиткәнче — бер чакрым арада — машиналар чираты тезелеп киткән. Казан ягыннан төзү материаллары алып кайтучы авыр йөк машиналары — КамАЗлар, БелАЗлар, тагынниндидер маркалы, биек кузовлы, өсте бөркәүле йөзләгән машина, бер-берсенә терәлеп диярлек, тынып калган; инде чиләкләп коя башлаган яңгыр йөкләр өстенә япкан брезентларны дөпелдәтә, кабина тәрәзәләреннән елга булып ага; яңгырның күпмегә сузыласы билгесез, аяз булып килгән җәйдә аны көтмәгәннәр дә иде, синоптиклар да аны кичтән хәбәр итмәде,— бәлки шуңа күрәдер кожан башлыкларын маңгайларына ук төшереп куйган шоферлар, йөк бушатучылар, кирза итекләре белән юл кырыендагы үзле балчыктан таятая, бер-берсе янына йөгерәләр, сүгенеп җаннарын бушатып аласылары килә бугай.

Тимергалиевнең шоферы Бәдриев, машиналар чиратыннан уңгарак каерып, «Волга»сын кичүгә таба алып китте: райком секретаре Тимергалиевнең дә, Югары Совет депутаты Айтугановның да өстенлекләре бар — алар паромга чиратсыз керә алалар.

Бәдриев, кабина ишеген ачып, арттагы «Газик»ка ишарә ясады: минем арттан калма, янәсе, теге аңлады. Ике машина бер-бер артлы әкрен генә кичүгә таба шуыштылар. Ашыгырга ярамый, юл тайгак, машиналар чиратына терәлеп диярлек барырга туры килә, аз гына читкә тайпылдыңмы, дамбадан аска очасыңны көт тә тор. Болай бару юл кагыйдәләре ягыннан хәвефсез булса да, нервыны бик талкый: чират торучы шоферлар әрсез, кабина ишекләрен ачып, сине берәр «ягымлы» сүз белән озатып калуны изге бурычлары саныйлар:

— Түрәләрдер инде — чиратсыз.

— Сволочной халык, кара, ничек киерелеп утырганнар!

— Кайчан төшәр шул килмешәкләр халык җилкәсеннән!

— Кабер тактасын!.. Безнең илдә тәртипнең буласы бармыни аның?!

— Карале, Хәтмулла, революция чыкканга җитмеш ел, ә бит һич нәрсәнең ата-анасы юк. Халыкны җитмеш ел буе күперсез тилмертәләр. Ыстырам! Ә бит Чистай — йолкыш кала түгел. Сугыш елларында дөньяның нинди зур язучылары яшәгән анда, галимнәре...

Ике машина әкрен генә алга үрмәли, еракка китеп күк күкрәгәне ишетелә, тәбәнәк соры күкне балкытып, яшен аксыл-сары ялыгын җилфердәтеп ала.

Җәйге яңгыр күкрәү-гөлдерәүләре белән офык артына китеп югалгач, Тимергалиевнең шоферы пристань башлыкларыннан белешеп килде: паром берәү генә, анысы да бәләкәй, олы паром ремонтка туктаган. Бер рейсны ике сәгатьсез дә башкарып чыга алмыйлар икән...

Ай-һай-һай! Бу исәптән бер чакрымга сузылган машиналарны тәүлек буена да ташып бетерә алмый бит ул. Ике сәгатьтән әйләнеп киләчәк паромга ничек тә әләгергә иде бит.

Тимергалиев шоферына алгарак узарга әмер бирде, ә Фәһим абзыйга паромга кергәнче үз машинасына күчеп утырырга кушты.

Пристань буена пассажирлар тулы өч автобус, чиратсыз кереп килгән унлап «Жигули» белән «Москвич» барыр юлны тәмам томалап куйган иде.

— Сигнал бир,— диде Тимергалиев.— Юл ачсыннар.

Бәдриев сигнал бирде, Айтуганов машинасының да шоферы сигнал бирде, тик берәү дә аларга юл ачарга ашыкмады.

Алар машинасыннан алдарак ике «Жигули» тора иде, әнә шулардан җиде-сигез кеше берьюлы килеп чыкты. Көньяк кояшында янган Кавказ кешеләре. Каралар, тазалар, буйчаннар. Машинадан чыгулары булды, Тимергалиев машинасы янына килеп туктаулары булды.

Арадан берсе, лапас түбәсе чаклы кепканы маңгаена батырып ки-

гәне, «Волга» ишеген каерып ачты да, русчаны ватып-җимереп:
— Вихади, панимаеш, чава тут сигналишь? — диде.
Тимергалиев машинадан чыкты, ишекне каерып ачкан егет каршысына килеп басты. Ул да биек, ул да таза, әрсезләнеп килгән егеткә бирешерлек түгел.
— В чем дело? — диде, каш астыннан усал карап.
— Нимидленно ухади, панимаеш.
— А если не уйду?
— Пинай на сиба. Машину твою опракинем.
Боларның шабашниклар икәнен, карышсаң, «Волга»ны чыннан да аударып җибәрәчәкләрен аңлады Тимергалиев, сүзсез генә машина эченә керде, Бәдриевкә:
— Машинаны читкәрәк чыгарып куй,— диде.
— Безнең бит хакыбыз...
— Син әйткәнне тыңла.
Тимергалиев машинасы да, Айтуганов машинасы да юл кырыена чыктылар.
Председатель Айтуганов секретарь машинасына керде.
— Ни булды, Морат Баянович?
— Әнә теге Кавказ шабашниклары яныйлар, чиратсыз керсәгез, машинагызны аударабыз, диләр.
— Вәйт нахаллар! Нишлибез соң?
— Утырыгыз,— диде Тимергалиев, әмер итеп.— Күрерсез нишләгәнне!
Секретарь рация кнопкасына басып, Чистайны сорады, горкомны. Бәхете, кирәкле кеше туры килде бугай.
— Таулы Төбәктән әле бу, Тимергалиев. Зур үтенеч: пристаньга милиция отряды җибәрә алмассызмы? Шабашниклар әрсезләнә. Әйе. Акылга утыртасы бар. Безме? Сорочьи Горыда. Әйе. Бер генә паром. Шуңа өлгерсен иде отряд.
Айтуганов рациядә көр тавыш ишетте.
— Булыр. Көтегез.
Райком секретаре кнопкага басып рацияне сүндерде, үтә дә канәгать чырай белән:
— Менә хәзер көтик инде. Бу якка чыгачак паромга өлгерсәләр, шабашникларга шабаш! — диде.
Машинада беркавым тын булып торды.
Тынлыкны Айтуганов бозды:
— Чистайга хәбәр итү ничек башыгызга килде, Морат Баянович? Аю чаклы сигез егетнең берьюлы ташлануыннан каушап калырга да мөмкин иң?
— Мин бит юрист. Райком секретаре булганчы прокуратурада эшләгән кеше. Хулиганнарның мондыен гына күргәнмени?!
— Ә милиция паромга өлгермәсә?
— Без, иптәш председатель, эшләгән эшнең нәтиҗәсен көтик башта. Алда ни була — анда күз күрер.
— Тамак ялгап алмыйбызмы? — диде Айтуганов аптырап.— Мин бик иртә торам.. Дүрттә үк ашаган идем.
— Юктыр. Чистайга җитик әле. Ресторанга керербез.
— Мәйле,— диде Фәһим абзый.— Ресторанда җылы аш ашау яхшырак, әлбәттә.
Пристань ягында ул-бу сизелми иде әле. Шофер Бәдриев курткасын җилкәсенә салып, машинадан чыкты, ул унҗиде ел буена Ханзафаровны йөрткән кеше, секретарь янына берәрсе керәме, машина туктап торган чак булса, һавага чыгарга ашыга,— җитәкчеләрнең икәүдән икәү генә сөйләшер сүзе булуы мөмкин.
Райком секретаре белән колхоз председателенең сөйләшер сүзе бар иде, әлбәттә, ләкин алар Айтуганов җитәкләгән «Сабанчы» колхозы-

ның хәле хакында сөйләшә генә башлаганнар иде, пристань буенда җанлану сизелде, паром якынлашадыр, мөгаен.

Чыннан да шулай икән.

Бәдриев, машинага кереп, шул хәбәрне җиткезде. Айтуганов белән Тимергалиев урамга чыктылар.

Паром, саңгырау гына кычкыртып, пристаньга килеп туктады. Җиңел машиналар әкрен, әмма үҗәт бер ныклык белән, тыгызлана, алгарак үрмәли башладылар. Тик аларның тырышулары бушка булып чыкты.

Паромнан милиция машинасын чыгардылар да башкасын туктатып калдырдылар. Түбәсенә җемелдәвек ут куелган милиция машинасы, кычкырта-кычкырта, «Жигули» һәм «Москвич»ларны ике якка аралап, буш урынга килеп чыкты һәм шундук Тимергалиев машинасына таба юнәлде. Машинадан әзмәвердәй дүрт милиционер чыкты.

— Иптәш Тимергалиев сез буласызмы?

— Мин.

— Шабашниклар кайда?

Тимергалиев, машина янынnан кузгалмыйча гына, зәңгәр төстәге ике «Жигули»ны күрсәтте.

Милиционерлар, барысы берьюлы, күз ачып йомганчы «Жигули»лар янына килеп җиттеләр, кече лейтенант, честь биреп:

— А ну чыгыгыз! — диде.

Кавказ шабашниклары машиналардан бүселеп чыкты.

— Документ?

— Какой-такой дукамент?

— Паспорт! — диде отряд башлыгы.

Милиционерлар, сигез кавказлының сигезенең дә паспортларын җыеп алып, үз машиналарына таба юнәлделәр.

— Пастуй-пагади, дарагой...

— Ждите,— диде кече лейтенант өзеп кенә.

Ул Тимергалиев белән Айтуганов машинасына үз артыннан барырга әмер итте.

Милиция машинасының түбәсендәге җемелдәвек ут бер кабынып, бер сүнеп пристань буена тыгызланган машиналарны читкә чәчте, паромның бушаганын көтеп алгач, башта пассажирлар белән тулы өч автобусны, аннары Тимергалиев белән Айтуганов машиналарын алып керде.

Лапас түбәсе чаклы кепкасын кулында йомарлаган кавказлы йөгереп килеп:

— Пастуй-пагади, дарагой...— дип тотынган иде, кече лейтенант аңа баягы сүзне кабатлады:

— Ждите.

...Паром Каманы ярты сәгать чыккандырмы, бер сәгатьме, — Айтугановка бик озак булып тоелды. Тимергалиев аны сөйләшүгә кат-кат тартып карады, тик моңардан берни дә барып чыкмады.

Яңгыр туктаса да, җил әле басылмаган, күктә кургаш болытлар чаба, Кама өстендә каракучкыл дулкыннар йөгерешә, машинадан чыгып, палубада торырлык түгел, җил җелеккә үтә, ә машина эчендә бөркү иде.

— Бирегә күперне кайчан салырлар икән, белмисезме? — дип сорады Тимергалиев.— Сезгә инде бу якларда күп булырга туры килгәндер, ишетмәдегезме?

— Мин бу елганы соңгы биш елда гына да кимендә унбиш тапкыр кичеп чыктым инде. Әлмәткә мин ел саен ике-өч мәртәбә газ торбасы эзләп барып кайтам. Вәгъдә күп, торба юк. Ниһаять, Мәскәүдә, Госпланга — Байбаковның үзенә кереп, хат тапшырдым. Ниһаять, миңа җавап килде, Әлмәттән алырга, диелгән. Уренгой магистраленнән Балдамарга тикле кырык километр озынлыктагы торбаны үткәрү җиңел-

рәк булды, авылларга унбиш километрны үткәрә алмый чәчем коелып бетә инде. Кама аша күпер булса, ике дә уйламый, җырлап кына барып кайтыр идең кана, утыз ел буена газеталар күпер салуны кузгата, утыз ел буена шоферлар Каманы, паромны, түрәләрне каргап яши...

Каманың теге ягына чыгып, паромнан котылгач, машиналар, бәйге көтеп зарыккан чабыш атлары сыман, элдертеп кенә китеп бардылар.

Чистай ресторанында тамак ялгап чыккач, аларның юлы аерылды.

Тимергалиев Чистайга, республикада икмәкне иң күп бирә торган районга тәҗрибә алырга, иген басуларын карарга килгән, бер уңайдан Тугайлы Төбәк өчен Чистайдан тәҗрибәле милиция хезмәткәрләре белешеп кайтырга, үзе эшләгән районда тулы тәртип урнаштырырга тели иде.

Ул, председатель Айтуганов белән саубуллашып, шәһәр комитетына китте, ә Фәһим абзый газ торбалары артыннан Әлмәт ягына юл алды.

...«Сорочьи Горы»га Айтуганов төнге сәгать уннарда әйләнеп кайтты. Бәхете — паромның икенчесе дә эшли башлаган икән. Чакрым ярымга сузылган чират беткән, Каманың бу ягында унлап кына йөк машинасы тора иде.

Беренче килгән паромга төянеп, Кама аркылы чыкты. Куәтле зур паром аны аргы якка егерме минутта чыгарып җиткезде. Бу якта да машиналар беткән, тик ике «Жигули» гына бер читтә тора, Кавказ егетләре машина янында шаулап сөйләшәләр иде. Айтугановның «Газиг»ын күргәч, барысы берьюлы йөгереп килделәр.

— Начальник, ярдәм ит.

— Ә нигә, сез китмәдегезмени әле?

— Милиционерлар безне бүген теге якка чыгармаска боерык биргәннәр.

Айтуганов башын кашып торгач, сорады:

— Сез кемнәр соң?

— Без, начальник, төзүчеләр.

— Шабашниклармы?

— Әйдә, шулай булсын.

— Нинди һөнәрләрегез бар? Нәрсә төзи аласыз?

— Теләсә нәрсә! Торак йорт, завод, культура сарае... Җаның ни тели?

— Нинди һөнәр ияләре сез?

— Ташчы, түбә ябучы, прораб, инженер...— дип, егетләр берәм-берәм алга чыга башлады, күрәсең, «начальник»ның кызыксынуы аларда өмет уятты.

— Мин колхоз председателе. Миңа пекарьни кирәк,— диде Айтуганов.— Булдырырсызмы?

— Начальник, дарагой...

— Булдырырсызмы дип сорыйм?

— Давай кирпеч, цемент, такта, калай, шифер, типовой мич — пекарни булачак.

— Ал безне, начальник, үкенмәссең.

— Алам.

— Ә паспортлар?

— Анысы сезнең кайгы түгел. Киттек.

Егетләр шаулашып машиналарына кереп утырдылар.

Беренче булып Айтугановның «Газигы», аның артыннан ике «Жигули» бер-бер артлы тезелеп, юлга чыкты: фаралар белән яктыртылган асфальт йөгереп артта кала башлады.

Таулы Төбәк сугышка кадәрле, ни авыл, ни шәһәр дигәндәй, шыксыз бер поселок иде. Агач заты юк та юк инде, урамнары чокыр-чакыр булып казылып беткән — ул чокырларга язын-көзен болганчык су тула, кешеләр тездән пычрак ерып көч-хәл белән базар мәйданына килеп җитәләр иде.

Үзәк урамына сугыштан соң таш түшәп чыктылар. Ул ташлар өстеннән атлы олаулар дөбердәп узган чакта колаклар тона, корырак елларны олаулар артыннан күтәрелгән тузан урамның бер башыннан икенче башына чаклы сузыла, ямь-яшел үләнле урамнарда йөреп өйрәнгән авыл кешеләре, базарга килгән саен Таулы Төбәкне каргап: гомерем булса — тәүбә-тәүбә — бу шыксыз калага аяк та басмам, дип китәләр. Басмый кая барасың — ел саен налог түләүләрдән кара җаяүгә калган халык, «вербаушик» дип аталган елгыр кешеләр сүзенә ышанып, Сахалинга, Читага, Донбасс яки Кузбасс шахталарына киткән чакта Таулы Төбәк аша узарга мәҗбүр була; яшәү өчен кирәкле белешмәне, (паспортны, бәлагә тарыганда страховой акчасын) Таулы Төбәктән алалар. Яшьләр көзен армиягә Таулы Төбәктән китә, тирәяктагы авыллар өчен больница да Таулы Төбәктә генә...

Халык теленә «Думсәвит» дип кергән ике катлы ак ташпулат — райүзәктәге иң матур йорт, сине, патша заманнарындагы губернатор йорты кебек, үзенә тартып та, куркытып та тора. Страховой идарәләре, налог җыю бүлекләре, бәхетсезлек килсә яки аңлы рәвештә җинаять кылсаң — прокуроры, милиция идарәсе, халык суды да шушында...

Килгән-киткәннең һәм шушы төбәктә яшәгәннәрнең күңеленә ятышмаган тузанлы поселокның гаҗәеп бер хасияте бар. Сугышка чаклы Таулы Төбәк үз тирәсендәге авылларны тимерчеләр белән тәэмин итеп торды. Тарихны белгәннәр моңа гаҗәпләнми, моның сере аңлый иде. Иван патша, дөньяда тиңе булмаган бер вәхшилек белән Казан каласын канга батыргач, татар башларын Идел буйлап дар агачларында агызган чагында, Казан тирәли йөз чакрымга русларны утыртып чыккан. Таулы Төбәктән Казанга барганда сугышка хәтле рус авылларын күпләп очратып була иде әле, сугыштан соң алар никтер кимеделәр — кайберләре бөтенләй юкка чыкты, кайберләрендә тәрәзә-ишегенә аркылы такта каккан йортлар күбәйде; кайчандыр авылның урта бер җирендә, калкулыкта кукраеп утырган алтын тәреле чиркәүләр, гөмбәзле түбәләрен югалткан хәлдә, күгәргән тимер ишекләрен юрамалый алгарак чыгарып куйган кебек, менә безне нинди мескен хәлгә куйдылар дигәндәй, боегып кына утыралар. Бу — совет чорында татарлар эшләгән эш түгел, бу — балта осталары, иген үстерүчеләр булган русларның үзләре эшләгән эш тә түгел, бу — түрә булып чабатасын түргә элгән әхлаксыз кешеләр, власть башлыклары эше...

Таулы Төбәкнең татар авыллары өчен тимерчеләр җитештерүе дә очраклы хәл түгел. Иван патша, Казанны алгач, татарга тимер тотарга, тимерчелектә эшләргә рөхсәт итмәгән. Тыйган бу эшне. Тимер осталары патшага каршы корал әзерләрләр дип курыккан. Менә каян килеп чыккан рус тимерчеләре, менә ничек таралганнар алар татар авылларына.

Ходай тәгалә шаһит: татар авылларында гомер кичергән рус тимерчеләре башка милләт халкына өстән торып карамады. Халык — кая куйсаң да халык инде ул: дошманлыкны белми, бер-берсенә ярдәм итәргә әзер тора. Күпме авылда рус тимерчеләре татар күршеләре белән дуслашып, кунакка йөрештеләр, татарчаны су кебек эчеп, мәйдан-сабантуйларында татар гармунына җырлап йөрделәр, рус кызлары татар егетләренә кияүгә чыкты...

Сугыштан соң Таулы Төбәккә кот керә башлады. Райбашкармага рәис булып килгән Суфиян Габдуллин урманлы яклардан иде. Поселокны яшелләндерүне ул беренче эше итеп куйды. Ике урта мәктәпнең дә директорларын үз янына чакырды, вәгазь-мазар сөйләп, озаклап аңлатып тормады ул аларга, кулларына Таулы Төбәкнең планын тоттырды. Планда кайсы мәктәпнең (райүзәктә татар һәм рус урта мәктәпләре бар иде) кайсы урамнарга агач утыртырга тиешлеге төгәл язып куелган иде.

Район Советы рәисе мәктәпләрне генә эшкә тартып калмады. Һәр колхоздан ул мәҗбүри рәвештә бер атлы олау, бишәр кеше китертте, урман хуҗалыгыннан белгечләр чакыртып алды. Башлап җибәрергә генә кирәк икән, мәктәп балалары һәм авыл агайлары янына Таулы төбәкнең һәр урамыннан, һәр йортыннан кешеләр чыкты: чокыр казыдылар, су ташыдылар, урманнардан йөге-йөге белән китерелгән үсентеләрне пөхтәләп утырттылар, кәҗә-мазар кимермәсен, малай-шалай сындырмасын өчен, рәшәткә яки юкә кабыгы белән уратып куйдылар.

Агачлар икенче елны ук үзләрен сиздерде — яшь каеннар, юкәләр җилдә лепердәште, тупыллар бик тиз үрләп китте, өрәңгеләр, кешеләрне сөендереп, яшәреп утырдылар.

Тагын бер ун ел торса,ниләр генә эшләмәс иде Суфиян Габдуллин Таулы Төбәктә. Тора алмады — аны күрделәр, Казанга күчерделәр, ул анда печән кибәне эченә төшкән энә кебек югалды.

Аңардан соң Таулы Төбәктә әллә ничә райбашкарма рәисе, әллә ничә райком секретаре алмашынды, ләкин берсе дә райүзәккә Габдуллин китергән хәтле файда китерә алмадылар.

Ә Суфиян Габдуллин утыртып калдырган агачлар шаулый...

1986 елның язында Таулы Төбәккә килгән яңа секретарь Морат Тимергалиевнең күңелен тау башында саф-саф булып үскән каеннар биләп алды. Үзенә вакытлыча бирелгән ике бүлмәле квартирада төн үткәргәннән соң, ул иртән иртүк поселок белән танышырга чыккан иде — йөри торгач, тау буена килеп җитте.

Кояш яңа гына күтәрелгән, офык алтын-сары төсләргә кереп балкый, иртәнге тынлыкта каеннар ак кәүсәләре, яшел ябалдашлары белән аеруча гүзәл булып күренәләр, еpактан килгән поездның гүләвен тыңлыйлар төсле иде.

Кулларын каш өстенә куеп, икеме-өчме чакрым арырак урнашкан тимер юл станцасының башняларын, поселок белән станца арасындагы болыннарны, кайчандыр су тегермәне булып та, инде хәрабәләре генә калган урынны, суы бөтенләй бетә язган инешне күздән кичерде Тимергалиев. Инешне хыялында тергезде, аңа су тегермәнен кайтарып утыртты, болынга сыер-сарык көтүләре сипте.

Дөнья аның өчен ямьлерәк, мәгънәлерәк булып китте.

Таулы Төбәкнең урамнары асфальтсыз, станца буйлары чокыр-чакыр, халык тездән пычрак ерып йөри, дигәннәр иде аңа. Яңгыр берәр атна яумый торса, агачларны бер илле тузан каплый, дип куркыткannар иде. Баксаң әнә каеннары да бар, болыннары да күз күреме җирдә җәелеп ята, инеше дә исән икән. Шуларның барысын тергезергә, халыкка хезмәткә куярга кирәк.

Дөрес, күз иләнә төшкәч, райүзәкнең тузаннары да, авыр йөк машиналары ермачлап бетергән урамнары да килеп чыкты. Төрле учреждениеләрнең ишегаллары бик шыксыз, коймалары иске, җимерек; райком белән райбашкарма биналары каршысындагы бәләкәй бакчаны һәм соңгы елларда салынган таш кибетләрне исәпкә алмаганда, райүзәктә җанны җылытырлык нәрсә юк иде.

Ләкин ни генә димә, беренче тойгы дөресрәк була.

Шоферы Бәдриев бер көнне хуҗасының каеннар арасында кулын артка куеп йөренүен, адымлап җир үлчәвен күргәч:

— Матур урын бу, Морат Баянович, матур...— диде.
— Син нәрсә?..— диде секретарь гаҗәпләнеп.
— Болай гына...— диде Бәдриев.
Җәй күңелгә ятышлы булып килде: вакытында яңгырлары явып, вакытында кояшы карап торды, игеннәр матур булып өлгерделәр. Шунлыктан район халкының, бигрәк тә колхоз председательләренең күңеле көр, Морат Баяновичның урак өсте якынлашуы турындагы үгет-нәсихәтләрен каш җыермыйча, теләп тыңлыйлар, уракка техниканы ничек әзерләүләрен бик теләп сөйлиләр иде.
Көлсу туфрагы, уңдырышсыз ташлы басулары белән еллар буе артка калып, газета мәгълүматларында исемлекнең иң азагына диярлек куелып килгән район, урып-җыю башлануга, кинәт күзгә күренеп алга килеп чыкты, дәүләткә икмәкне дә тизрәк һәм күбрәк тапшыра, игеннәрен дә тизрәк җыя башлады. Моны обком секретаре Зөфәр Дулатов, Таулы Төбәккә яңа секретарь килгәнгә юрап, телевидениедә ясаган бер чыгышында Морат Баянович исеменә берничә җылы сүз әйтүне кирәк тапты.
Күңеле тагын да үсебрәк китте Тимергалиевнең.
Эшләре аеруча уңышлы барган бер мәлне, басуларда арыш урагы бетеп, сабан ашлыкка төшкәндә, Дулатов Таулы Төбәккә үзе дә килеп чыгасы итте. Бик нык әзерләнеп, әрмән коньяклары таптырып көткән иде аны Тимергалиев, әмма Дулатов тар бүлмәдә бикләнеп утыруны өнәмичә, тизрәк кырларга чыгарга теләде.
Башта Таулы Төбәкнең борын төбендәге бер колхозына, аннары урта полосадагы бер совхозына кереп чыкканнан соң «Сабанчы»га барып җиттеләр. Дулатов баштагы хуҗалыклардагы эш барышыннан да канәгать калган иде, әмма Фәһим Айтуганов басуларына килеп кергәч, ул бөтенләй үзгәрде. Бирердәге тәртип, басуларның чисталыгы, сугылган саламның җирдә аунап ятмавы, эскерт-эскерт булып бер турыга тезелеп баруы аңарда уңай тойгы калдырды. Дулатовка аеруча ошаганы — председатель Айтугановның кунакларны аерым бүлмәгә алып кермичә, механизаторлар өчен әзерләнгән табынга, кыр станына алып килеп ашатуы булды. Ризык мулдан иде: беренчегә — кулдан җәйгән токмачлы аш, икенчегә — сөткә изеп пешергән бәрәңге боламыгы белән сыер ите, өченчегә — өректән кайнаткан салкын компот иде. Теләгән кешегә ике чиләк сыешлы зур самавырда чәй дә кайнап тора иде.
— Әйтегез әле, Фәһим абзый, сез  уракчыларга көн саен шулай пешерәсезме ризыкны, әллә без махсус пешерелгән көнгә туры килдекме? — диде Дулатов.
— Нигә, әллә ошадымы әбәт? — дип сабыр гына елмайды Айтуганов.
— Ә сез сораганга җавап бирегез: көн дәме?
— Моннан да әйбәтрәк көннәре була, иптәш секретарь,— диде Айтуганов, бу юлы җитди итеп.
— Рәхмәт, алай булгач.
— Баш өсте, тагын килегез.
— Киләсе булыр. Сезнең тәҗрибә кирәк безгә, Фәһим абзый. Шулай түгелме, иптәш Тимергалиев?
Морат Баянович, бик әллә ни яктырып китмичә генә:
— Әлбәттә,— диде.
Обком секретаре аның нәрсәдәндер канәгать түгеллеген сизде, әмма нәрсәдән икәнен аңлап җиткерә алмады, аңа калса — эшләрен көйле итеп алып бара торган председателен ул үз күрергә, башкаларны аның янына тартырга тиеш иде.
Мәсьәләгә ачыклык кертмичә китәргә теләмәде Дулатов.
— Уртача күпмерәк уңыш алырга ниятлисез инде, Фәһим абзый, сер булмаса, әйтегез әле?

— Арыш безнең, түгәрәкләп алганда, утызны бирде. Борчак бераз кай — орлыгы бик әллә ни булмады. Солы — егерме ике, бодай егерме җиделәр тирәсе... арпа — егерме өч... Уртача исәбе — егерме биш булыр, дибез. Ләкин бит әле игеннең яртысы кырда, алдагысын алла белә дигәндәй...

Обком секретарена председатель Айтугановның иген уңышы да, шул уңыш хакында тыйнак кына итеп әйтеп торуы да ошады.

— Ә район буенча? — диде ул, Тимергалиевкә таба борылып.

Райком секретареның йөзенә күләгә төште.

— Район буенча кистереп кенә әйтүе кыен, иптәш Дулатов. Фәһим Сабирҗанович дөрес әйтә: кырдагы әле ул кырыкка төрләнә, алдагыны алла белә...— дип туры җаваптан качарга ниятләде Тимергалиев, чөнки район буенча уртача уңыш унбиш центнердан артмаячак иде.

— Шулай да ничә центнер? — дип кабат сорады Дулатов. Аның бүген кояшта алсулана төшкән түгәрәк йөзендә, дугаланып өскә күтәрелгән кашларында зур кызыксыну, ихласлык бар иде.

— Унбиштән ким булмаска тиеш, Зөфәр Зәбирович.

Дулатов бармакларын өстәл тактасында биетеп алды:

— Ун центнерга аерма. Нилектән дип уйлыйсыз, иптәш Тимергалиев?

Райком секретаре бу хакта баш ватмаган. Таулы Төбәктә беренче генә җәйне үткәрүе булгангадыр, ул елларның шулай матур килүенә күңеленнән шыпырт кына куанып йөри, шундый елны обком секретареның ул җитәкли башлаган районга килергә уйлавын иртәнге якта хуплап та куйган иде.

Өзеп кенә җавап бирә алмады,— секретарь канәгатьсез калды. Моңа, әлбәттә, Айтуганов гаепле. Белә бит инде районның күп өлеш кимрәк алачагын, нигә инде шул аерманы бүлтәйтеп, алга чыгарып куярга иде?

Дулатов председательнең кулын каты итеп кысты:

— Мин канәгать, Фәһим абзый. Беренчегә дә шулай дип хәбәр итәрмен,— диде. Азактан: — Йомышыгыз чыкса, туп-туры үземә, мин булмасам, авыл хуҗалыгы бүлегенә шалтыратыгыз,— диде.

Тимергалиев председатель белән салкынрак күреште, обком секретаре ишетсен диптер, ахрысы:

— Иртәгә минем янга, төп-төгәл сигезгә килеп чыгыгыз, Фәһим Сабирҗанович, киңәшәсе бар,— дип рәсми-корырак тавыш белән әйтте.

Таулы Төбәккә кайткач, Дулатов райкомга кереп тормады, Тимергалиевнең җиңенә җиңелчә генә кагылып:

— Уңыш телим сезгә, Морат Баянович. Районның быелгы эшләре хакында мин беркадәр мәгълүмат алдым, халыкның кәефе начар булмаска охшый. Айтугановны күздән ычкындырмагыз, акыллы хуҗа икәне әллә каян күренеп тора,— диде.

Тимергалиев тынып калды.

Дулатов моңа игътибар итте.

— Шәхси тормышлар, квартир якларыгыз ничек? — дип, аерылышуны кешечәрәк очларга уйлады.

— Берничек тә түгел,— диде Тимергалиев.— Эш белән күмелеп, әле ул хакта уйларга вакыт та тимәде, Зөфәр Зәбирович. Коммуналкадан ике бүлмәле квартир биргәннәр иде, шунда торып торам, хатын белән кече улым Казанда әле,— диде.

— Ә олы улыгыз?

— Артурым Әфганстанда бит минем.

— Хәбәре бармы соң?

— Тауларда йөрибез. Бик эссе, дигән.

— Исән-сау кайта күрсен инде.

— Шулай гына булсын иде, юкса ут йотып торабыз.

Дулатов яңа райком секретарена кайтып китәр алдыннан, улының Әфганстанда икәнен дә белгәч, ямьлерәк, күңеленә ятышлырак сүз әйтергә булды:

— Сезгә, минемчә, йорт булдыру ягын карарга вакыттыр, Морат Баянович. Коммуналка — коммуналка инде ул.

— Килү белән үз ягыңны кайгырта башлау — әллә ничек... Халыктан уңайсыз, Зөфәр Зәбирович.

— Халыктан яшереп бер эш тә эшләмәскә кирәк, анысы — хак. Әмма райком секретаре, кулында власть була торып, үзенә җүнле бер йорт та салып керә алмый икән, андый секретарьдан да халыкның күңеле бизәчәк. Үзенә булып үзенә булдыра алмагач, безгә юк та юк инде ул, диярләр.

— Һм, һм...— диде Тимергалиев, тамак кыргалады. Обком секретареннан мондый сүзләр ишетүгә әзер түгел иде ул.

Дулатовны озатып җибәргәч, ул өенә кайтмады, кафе тагын да ныграк кырылыр дип уйлап, ашханәгә генә кереп ашады.

Район хуҗасына, әлбәттә, ашның тәмлерәген китерергә тырышканнар, тамчы да көттермичә, сәгате-минуты белән китереп җиткергәннәр иде. Тик Тимергалиев күңеле белән моңардан риза булмады. Айтугановның кыр станында ашаткан ашы — Дулатов дөрес бәяләде — моңардан күп өлеш тәмлерәк һәм җимлерәк иде. Кул җитми, каһәр суккырысы, барысына берьюлы җитешеп булмый. Ике алтын тешен елтыратып чыккан, битенең пәрәмәче килгән йомры бичә үзенең өендә ашны шулай «мылтык мае» белән пешерми торгандыр, чәе дә аның болганчык су төсле булмыйдыр. Ә монда нәрсә бирсәң дә ярый дип уйлый. Тәмам этләшеп беткәннәр, оятсызлар...

— Тагын нәрсә китерик, Морат Баянович? — дип алтын тешләрен балкытып, төче итеп елмайган бичәгә ул:

— Бүтән берни дә кирәкми. Рәхмәт әйтмим, ашыгыз тәмсез, ризык пешерергә авылларга чыгып өйрәнегез,— дип, яртылаш кына ашаган ризыкларын тәлинкәсендә калдырып чыгып китте.

Ул гына нервыланып йөрмәсен әле, пәрәмәч битле бу хатын да төнлә йоклый алмасын, юкса тәмам эт каешына әйләнделәр.

Ул үзәк урам буйлап китте. Бераз баргач, аптырап туктады: аяклары аны коммуналь квартирына таба түгел, никтер тау буена таба илтә иде.

Кояш инде баеган, шәфәкъ балкышы тоныклана бара, ләкин якты иде әле. Тик җир өстендәге әйберләр: йортлар, агачлар, күк йөзе зәңгәр пыяла аркылы караган төсле серле-күгелҗем булып күренә иде.

Каеннар янына килгәч, ул беренче мәртәбә күргәндәй, әсәрләнеп туктады: алар инде балкымыйлар, офыктагы кучкылланып торган болытлар белән сүз берләшкәндәй, үтә серле булып күренәләр иде.

Обком секретаре әйткән сүзләр исенә төште: «Сезгә, минемчә, йорт булдыру ягын карарга вакыттыр...»

Менә шушында булыр аның йорты. Каеннар арасында. Көнә буе кырлар буйлап чапканнан соң ул биредә ял итәр, гасабилы җанына сихәт табар...

### 3

Фәһим Айтуганов райком секретаре кабинетына төп-төгәл сигездә килеп керде. Тимергалиев аның өс-башына игътибар итте: ул өр-яңа күксел костюмнан, биек ак фуражкадан, көннәр кызу торуга карамастан, чытыр ак күлмәктән һәм галстуктан иде.

Аның белән махсус очрашасы булганга Тимергалиев тә пөхтә киенергә тырышты, тик ул кыска җиңле зәңгәр күлмәктән, пинжәксез һәм галстуксыз иде. Ул оттыра иде кием ягыннан. Шиксез!

— Рәхим итегез, Фәһим Сабирҗанович. Яратам төгәл кешеләрне,— дип, үзенә калса, якты йөз белән, кичәге кәефе китүләрен бер якка куеп, ихлас каршылады аны райком секретаре, утырыгыз дип, өстәл янындагы йомшак кәнәфигә күрсәтте.

Айтуганов, фуражкасын чөйгә элеп, өстәл янына тәкәллефсез генә килеп утырды. Тимергалиев аның кояшта алсуланган озынча битен, биек матур маңгаен, талчыгу-мазар чыкмаган чиста күзләрен күрде. Бу сау-сәламәт йөзгә председательнең киемнәре килешеп тора, председатель дәрәҗәсе өчен аны артыграк затлы итеп күрсәтә иде.

«Гап-гади бер председатель ничек инде райком секретареннан зәвыклырак киенә ала? Каян килә аңа затлылык һәм зәвык?»— дип, кичә иген уңышы турында сөйләшкән чактагы төсле, тагын никтер кәефсезләнә башлаганын сизде Тимергалиев. Үз кабинетында беренче мәртәбә күзгә-күз очрашкан алдынгы председатель белән вакланырга, тар күңелле булып күренергә ярамый иде. Председательләр — аның уң кулы. Югары оешмалар синнән көне-төне икмәк таләп иткәндә, ит белән сөт таләп иткәндә, председательләрдән башка син кем, Тимергалиев? Таяксыз нуль!

Моны яхшы аңлый Тимергалиев. Дөньяда ул кырык ике ел яши. Казан университетының юридик факультетын тәмамлагач, Идел аръягындагы рус районында прокурор ярдәмчесе булып эшләде. Райбашкарма рәисе булды. Ләкин Таулы Төбәккә ул райбашкармадан түгел, югары партия мәктәбеннән килде. Әйе, этеп-төртеп куелган очраклы кеше түгел ул. Совет законнарын да, тормыш законнарын да белә. Тик аның күңелен бер нәрсә борчый: ул үзендә прокурорлык шаукымы калмаганмы дип шикләнә иде. Әнә шуны ачыклау өчен ул бүген Фәһим Айтугановны үз кабинетына чакырды. Икәүдән-икәү генә, күзгә карап, бернәрсәне дә яшермичә сөйләшергә кирәк иде.

Югары партия мәктәбендә, кадрлар — партиянең автономиясе, дип өйрәттеләр. Бу өстенлекне ычкындырган, бу өстенлектән файдалана белмәгән секретарьны җимерелү, урыныннан алып ташлану көтә, диделәр. Таулы Төбәктә аның алдына кешеләрне тану, алар белән эшләү, алар аркылы үз максатларын, дөресрәге партия максатларын гамәлгә ашыру практик рәвештә килеп басты.

Менә хәзер аның каршысында председательләрнең берсе утыра.

— Килдегезме, Фәһим Сабирҗанович? — диде секретарь сүз башлау өчен.

— Сез чакырдыгыз, мин килдем. Уттай урак өстендә юк-барга чакырмагансыздыр дип беләм.

Секретарь сүзне ерактан башлады.

— Мин, Фәһим Сабирҗанович, сезнең учет карточкагызны бик җентекләп карап чыктым. Әтиегез авыл Советы рәисе. Нибары 42 яшендә вафат булган. Үзегез фронтовик. «Сабанчы» колхозын инде кырык ел буена җитәклисез. Орден-медальләрегез байтак. Татарстанның гына түгел, Россия Федерациясенең атказанган агрономы, өстәвенә СССР Верховный Советы депутаты...

— Моның белән нәрсә әйтмәкче буласыз? — диде Айтуганов сабыр гына елмаеп. Ә үзе: «Мактап башланган эш юньлеккә илтми»,— дип уйлады.

Ул арада Тимергалиев тә нәтиҗә чыгарып өлгерде: «Бу сиңа күлмәк якасын чишеп җибәргән тәртә муенлы мужик түгел. Үзе-

нең өстенлеген, башкалардан югары торуын өстәл төю белән аңлатмаячак. Моның белән саграк булганың хәерле. Әнә бит кичә обком секретаре алдында ниндирәк тотты үзен. Дулатовны аулак бүлмәгә алып кереп сыйламады, аны мактап сайрап утырмады, ул аңа механизаторлар ашый торган ашны ашатты, шуның белән кешеләрне кайгыртуын гамәлдә күрсәтеп бирде. Ә Тимергалиевне обком секретаре алдында авыр хәлгә китереп куйды. Син, янәсе, барлык колхозларда да хезмәт кешеләренә мөнәсәбәтне менә шулай, минемчә куйдырта аласыңмы?»

— Мин килдем,— диде Айтуганов, бераз тын утыргач.— Тыңлыйм мин сезне, Морат Баянович.

— Икәүдән икәү генә сөйләшәсе, аңлашасы килгәнгә чакырдым мин сезне, Фәһим Сабирҗанович. Кичә Дулатов алдында үз колхозыгыз «Сабанчы»ны бик хәтәр күтәреп, районның башка хуҗалыкларын түбәнсетүегез миңа ошамады.

— Мин булганны әйттем.

— Анысы дөрес. Булганны әйттегез. Ләкин бит кайчагында такт дигән нәрсә булганны да әйтми торырга куша. Минем аңлавымча, сезнең өчен «Сабанчы» мәнфәгате бөтен бер район интересыннан өстенрәк булып чыга. Шулаймы?

— Алай ук түгел шул...— дип Айтуганов, һич кенә дә сабырлыгын җуймыйча, баягы төсле үк матур итеп елмайды.— Без бит инде бик озак дөресен әйтми килдек, Морат Баянович.— Безнең авызлар бик озак йозаклы булып торды бит.

— Ярый. Бу хактагы сүзне туктатыйк. Уртак тел таба алмадык, димәк. Ә «Сорочьи Горы»да булган хәлгә сез ни диярсез? Мин азынуның аргы ягына чыккан шабашникларны акылга утыртырга теләп, милиция чакырдым, паспортларын җыйдырып алдырдым, ә сез аларны үзегезгә алып китәсез, паспортларын юллап алып бирәсез. Димәк, үзегезне тагын райкомнан өстен куясыз?..

— И аллам, кем инде өстен дип, астын дип уйлап тора аны. Миңа пекарьни салырга эшче куллар кирәк. Ә бу әрмән егетләре — беренче кул осталар булып чыкты. Араларында инженер да, прораб та, башкасы да бар.

— Ә бит алар безне аударырга килделәр.

— Алар хаклы, минемчә.

— Ничек хаклы? — диде Тимергалиев, кыза башлап.— Хулиганнар хаклы, ә без дәүләт кешеләре хаклы түгел. Сәер, бик сәер. Мин сездән моны көтмәгән идем, депутат иптәш.

Айтуганов гомер буена килгән гадәтен — сабырлыгын саклады.

— Әгәр дә мәгәр Кама аша күпер салынган булса, һич югы ике паромның икесе дә эшләп торса, алар безгә бәйләнер идеме? Һич юк. Иң әүвәле явызлыкның нәрсәдән башлануын тикшереп, төбенә-тамырына төшәргә кирәктер безгә, Морат Баянович. Ярый, ул чакта әрмән егетләре бәйләнмәде ди, шоферларның башкасы, үзебезнең татарлар яки руслар бәйләнмәс дип кем кистереп әйтә ала? Чүлмәк тулгач түгелә, диләр. Гомер буе гаделсезлеккә тешен кысып түзгән кешеләр, менә хәзер, перестройка дигән заман килгәч тә түзеп торсыннармы? Алар бит безнең чиратсыз керүебезне коточкыч гаделсезлек дип саныйлар...

Тимергалиев бу сүзләрдән үзенчә нәтиҗә ясады. Күрәсең, алдынгылар арасында алма булып йөрергә ярата Айтуганов. Табылган монда гаделлек сакчысы! Ике тәкә башы бер казанга сыймый дигәнне шушыдыр инде. Элекке секретарь Ханзафаров белән дә борчаклары пешмәде диләннәр иде, мөгаен, дөрестер. Эшләр алайга китсә, без иптәшләрчә сөйләшүдән дә баш тарта алабыз...

Айтуганов тамак кырып куйды, көрсенде һәм, пинжәк җиңен тартып, сәгатенә күз салды.

— Нәрсә, Фәһим Сабирҗанович, ашыгасыз мәллә? — диде секретарь, аннары маңгаена таралып төшкән каты чәчләрен кулы белән артка сыпырырга азапланды.

— Ашыгам шул, Морат Баянович. Заготзерно белән сүз куешкан идем. Казаннан кешеләр киләсе иде. Безнең сөйләшү озакка барырмы әле?

Райком секретаре аның дулкынына күчте:

— Нәрсә, конфликт килеп чыктымы әллә? Заготзерно сезне тыңларга теләмиме?

— Конфликт түгел бу, иптәш секретарь. Башбаштаклык. Заготзерно колхозларны кычкыртып талый — без китергән ашлыкның утыз процентын чүпкә һәм дымлылыкка чыгарып бара. «Сабанчы»ны таласыннар да ди, безнең колхоз нык, алай гына аяктан егылмас, әле бит Таулы Төбәкнең башка хуҗалыклары бар, аларның бит быелгысы кебек көннәр матур килгән елны аякка басасылары, тернәкләнәселәре килә. Ә болар колхозларны талап премия алмакчы...

— Казаннан кемнәр килә?

— Икмәк продуктлары әзерләүнең республика башлыгын чакырттым. Болай гына килми әле ул сиңа. Совмин аркылы эш йөртергә туры килде. Депутатлык запросы биреп.

Тимергалиев уйлап өлгерде: менә ни өчен затлы киемнәрен киеп алган икән ул — минем өчен түгел, эш өчен икән...

— Йә, ничек? Мине җибәрәсезме, Морат Баянович? Сүзне, бәлкем, мин Заготзернодан әйләнеп кайткач дәвам итәрбез.

— Юк, хәзер үк, хәзер үк дәвам итәбез,— дип секретарь «хәзер үк» сүзен кабатлап әйтте.— Киттек, иптәш Айтуганов. Сез бик зур, бик кирәкле мәсьәлә күтәргәнсез. Ә нигә депутат значогын такмадыгыз?

— Уттай урак өстендә депутат значогы тагып фартовать итеп йөрү килешмиме, Морат Баянович. Борчылмагыз, ул минем үзем белән, кирәге чыкса, тагабыз аны,— дип Айтуганов пинжәк якасын кайтарып күрсәтте. «СССР Верховный Советы» дигән кызыл флаг рәвешендәге значок яканың эчке ягына беркетеп куелган иде.

«Таш астыннан чыккан бу. Кайда ничек сөйләшергә икәнен дә, үзен ничек тотарга икәнен дә белә, колхоз авылында кырык ел буена, иң авыр елларда да юкка гына утырып кала алмагандыр»,— дип уйлады аның турында райком секретаре.

Заготзерного чакыртылган кеше — икмәк продуктлары әзерләүнең республика башлыгы Хөснияров, костюмы чандыр гәүдәсендә капчык кебек асылынып торган авыру чырайлы, сары мыеклы кеше, үзе белән ике белгеч — юан гына ике хатын алып килгән иде. Хәлләрне белергә дип элеватор ишегалдына керүләре булды, әлеге ике хатын председательнең ике ягына бастылар да тотындылар кычкырырга, тотындылар элеватор лаборантларының хаклы икәнлекләрен исбат итәргә. Кем сезгә, имеш, утыз процент бозык төяп килергә куша? Нишләп сез дәүләтне алдарга, күз буярга, түбән кондицияле ашлыкны югары сыйфатлы итеп тапшырырга азапланасыз?

Тимергалиевнең мондый хәлне райбашкарма председателе булганда да күргәне юк иде. Ул аптырап калды, җилкәсен җыерып, Айтугановка карады: нигә, сез шулай борчакның начарын китерәсезмени?

Хатыннар әле һаман авызларыннан ут чәчәләр, ә киеме капчык кебек эленеп торган Хөснияров: «Менә шулай бит, егетләр, мин нишли алам, мин берни дә эшли алмыйм, бигайбә»,— дигән төсле бер читтәрәк басып тора иде.

Шул чагында председатель Айтуганов телгә килде:

— Без алай тәмсезләнмик, бер-беребезгә кычкырып, ямьле көн-

нең ямен җибәрмик, сезне мин чакырттым. Совмин аркылы, депутатлык запросы җибәреп,— диде ул. Тимергалиев аның күкрәгенә күз төшерде, депутатлык значогы ипле генә булып аның пинжәк якасында ятып тора иде инде.— Безнең колхоз машиналары да, башка колхозныкылар да әнә чиратта торалар, сез аларның теләсә кайсысыннан, үзегез кирәк дип тапканыннан, проба ала аласыз. Нәтиҗәсен безгә хәбәр итәрсез. Әгәр дөрес бәя чыгармасагыз, депутатлык намусым белән ант итеп әйтәм, мин аларны Казанга, экспертизага алып барачакмын,— диде.

Хатыннар тынып калдылар.

Ниһаять, Хөснияровка җан керде:

— Лабораториядәге белгечләрне дә чакырырга кирәк, пробаны бергәләп алу дөрес булыр,— диде ул.

— Элеватор директорын да чакырыгыз,— диде райком секретаре.— Биредә аның булуы мәҗбүри.

Чирек сәгатьтән пробаның нәтиҗәләрен әйттеләр. Китергән борчакның чүплелеген һәм дымлылыгын 10-12 процент дип тапканнар.

— Инде хәзер директор бүлмәсенә кереп сөйләшик,— диде райком секретаре.

Керделәр. Кабинетта утыргычлар күп түгел, аларга утырырлык та түгел — тузан баскан иде. Бер тирәгәрәк тупланып, аяк өсте баскан килеш кенә сөйләштеләр.

Райком секретаре, дилбегәне үз кулына алып, сүзне Айтугановка бирде.

— Тикшерү нәтиҗәләре кул астында: элеватор лабораториясе безне ике көн буена алдап килгән, безнең борчакны 10-12 процент урынына 30 процент чүпле дип чыгарган. Шофер егетләр колхозга кайткач, риза түгеллекләрен, элеваторда безне алдап утыруларын әйттеләр. Аларның сүзе расланды. Сез менә, солидный ханымнар, колхоз кешеләренең күкрәк көче белән үстергән иген ашлыгын үзләштерергә, шуның бәрабәренә мул гына премия алырга җыенучыларны якларга килгәнсез.

— Яхшы, депутат иптәш, бүгенге проба яраксыз ашлыкны уннан башлап унике процентка хәтле күрсәтте. Ә сез бу борчакның кичәге үк борчак икәнен ничек исбат итә аласыз? Бәлки, сез аны бүген киптереп һәм җилгәреп алып килгәнсездер?

— Урынлы сорау. Ә менә сез кичәге борчакның утыз процентын киметергә кирәклеген нәрсә белән исбатлый аласыз? Пробаның үрнәкләре сакланамы сездә? — диде Айтуганов аңа каршы.

Моңа элеватор лаборанты, башына сары косынка бәйләгән яшь кенә кыз җавап бирде:

— Әкәмәт сәер кеше икәнсез, абый! Ничек инде без көн дә саен агылып торган биш йөз олауның пробасын саклап асрый алыйк ди?

— Менә шул шул. Әзегез калмый сезнең. Чөнки моңарчы сездән гаделлек таләп иткәннәре булмаган. Ә менә без исбат итә алабыз.— Айтуганов кесәсеннән бер бит кәгазь чыгарды.— Күрәсезме, бу кәгазьгә колхозның печате сугылган, ун кешенең имзасы куелган. Депутат Айтуганов, ул мин булам, колхозның парторгы Сираҗиев, амбарчы Локманов, шофер Әбҗәлилов һәм башкалар. Без кулыбызны куеп, шуны мөһер суккан хәлдә раслап әйтәбез: борчак кичә дә, бүген дә бер үк көшелдән алынды. Борчакны быел киптерәсе юк, көннәр унбиш көн инде коры тора, безнең колхозда эшләгән эшен ике мәртәбә эшләүче юк, борчак триердан ике-өч кабат үткәрелгән. Димәк, аның утыз процент дәрәҗәсендә юкка чыгуы мөмкин түгел. Каралганы, ярылганы исәбенә без ун процент киметелүгә каршы килмибез. Безнең колхозда һәммә нәрсәнең катгый, төгәл исәбе бар, бер генә бөртек ашлыкны да җилгә очырырга

ниятебез юк. Моны аңлавыгызны, беркайчан да онытмавыгызны үтенәм, хөрмәтле иптәшләр.

— Йәгез, бүгенге тикшерүдән нинди нәтиҗә ясыйбыз? — диде райком секретаре.

Хөснияров алгарак чыкты.

— Үзем белән алып килгән белгечләрнең дорфалыклары өчен гафу үтенәм. Депутат иптәш Айтуганов, сездән дә, секретарь иптәш Тимергалиев, сездән дә. Белгечләрнең эше дәгъва куптару түгел, вазифаларын үтәү. Ә инде Заготзерно коллективының ямьсез эшләре турындагы мәсьәләне без үзебезнең идарәдә, Казанда тикшерербез, нәтиҗәсен депутат Айтугановка хәбәр итәрбез.

— Райкомга да,— диде Тимергалиев.

— Әлбәттә, әлбәттә! — диде Хөснияров.

4

Бер карлыгач яз ясый алмаган кебек, бер колхоз — нинди генә алдынгы булмасын! — районның гомуми хәлен үзгәртә алмый. Шунлыктан райком өчен кемнеңдер ыргылып алга чыгуы түгел, барлык колхоз һәм совхозларның тигез ритмда баруы кадерлерәк. Чәчүлек җире генә дә бер йөз мең гектардан артып киткән Таулы Төбәкнең гомуми күтәрелешенә ирешү — менә нәрсә тынгылык бирми Тимергалиевкә. Яңа урында эшли башлаганнан соң ул республика районнарының экономикасын, эш стильләрен өйрәнеп чыкты. Нык куллы җитәкчеләр эшли райкомнарда. Сөтне киметкән өчен, председательләрне «келәмгә бастыралар». Бөтен бюро алдында ярты сәгатьләр чамасы ыкы-мыкы килеп, акланып торган председатель кара тиргә бата, икенче килүендә инде ул ничек итсә итә, йөз грамм сөтне кимету ягын түгел, арттыру ягын карый.

Тимергалиев, кулына кәгазь-каләм алып, исәпләп чыгарды: Таулы Төбәкнең утыз биш колхозында утыз мең баштан артыграк савым сыеры бар. Әгәр тәүлегенә һәр сыердан берәр йөз грамм гына артык сөт саусалар да көнгә өч мең, айга тугыз мең, бер елга бер йөз мең килограмм артык сөт савылачак. Бер йөз тонна! Менә кайда математика, менә кайда стратегия, менә нәрсәгә тотынырга кирәк.

Бердәм агым белән баруны Тимергалиев районга җитәкчелек итүнең җитди бер принцибы дип таныды. Баштарак аны мондый принцип канәгатьләндерде, чөнки район сөт савуны киметми, Таулы Төбәк газеталарда, радио тапшыруларында уңай яктан телгә алына — андый чакта кемнең күңеле үсмәс! Өстәвенә ул эшли башлаган елны ук табигать шартларының да туры килүе дәүләткә ашлык сату заданиесен дә төгәл башкарып чыгарга мөмкинлек бирде.

Аны күрделәр, өлкә күләмендәге киңәшмәләрдән соң ресторанмазарда күңел бушаткан чакларында коллегалары аны мактыйлар, Таулы Төбәкне — ничәмә еллар урталыкта, хәтта артта барган районны, алдынгылар сафына алып чыгардай секретарь килде, дип бәялиләр иде.

Татарның, хәтта бик акыллы татарның да, алама бер гадәте бар: әгәр аңа, син даһи, дисәң, шундук ышана.

Тимергалиев шактый соң төшенгән бер нәрсә булды: ул ерак ара белән якын араны аерып җиткерми, еракка йөгерүчеләр өчен бер сулыш, якынга йөгерүчеләр өчен икенче сулыш кирәк икәнен белми иде.

Ә менә Айтуганов белеп эш итә, итә генә түгел, ерак дистанциягә ул өстенлек бирә. Бүген бер йөз грамм сөт арттырырга чәрәшеп, райком боерыкларын үтәп яткан председательләрне ул сөт

томаны аша офыкны күрә белмәүчеләр дип бәяли, кайчан да булса аларның үкенечле хәлгә калачакларын ачыктан-ачык әйтә. Председательнең максаты — бүген, иртәгә, берсе көнгә йөз грамм сөтне, бер кило итне, бер центнер икмәкне арттыру түгел. Председательнең максаты — кешене күздән ычкындырмау. Колхозчы крестьянның әйбәт урнашкан булуын, йорт-җирле булуын, төзек һәм уңайлы техника белән эшләвен тәэмин итү. Менә ул чакта сөт үзеннән-үзе артачак, ит үзеннән-үзе ишәячәк, икмәк үстерү кебек борынгы һөнәргә кешеләр теләбрәк тотыначаклар. Ник? Нилектән шулай? Чөнки — крестьянны, күмәк хуҗалыкларга берләшкән көннән башлап, сарык көтүе дип карадылар. Әнә шул көтү өстеннән кемнәрдер еллар буе чыбыркы шартлатты.

Инде менә үзгәртеп кору дигән заман килгәч, андый чыбыркы шартлатулар бетәр дип көтте Фәһим абзый. Юк икән, бетми икән. Җитмеш ел буена бозылган тәртипне бер-ике елда гына ничек төзәтеп бетерәсең, ди.

Көз яңгырсыз килде. Арыш чәчәргә тиешле август аенда тамчы бөртек яңгыр төшмәде. Таулы Төбәк райкомына обкомнан һәм Совминнан килгән боерыкны җиткерделәр: арыш чәчмәскә!

Фәһим Айтуганов белән Фатыйх Айтуганов кырга чыгып, туфракны актарып, учларына алып карадылар — чәчәрлек. Сентябрь урталарында яңгыр да яварга тиеш: сынамышлар шуны әйтә.

«Сабанчы» кырга берьюлы җиде трактор чыгарды һәм өч көн дигәндә алар өч йөз илле гектар арышны чәчеп тә кайттылар.

Тимергалиевнең, моны ишетеп, чәчләре үрә торды. Бу нинди башбаштаклык? Бу нинди акылга сыймаган эш? Райком бит аларга аңлатып әйтте: арыш чәчмәскә.

Фәһим Айтуганов белән аңлашырга өлгермәделәр, «Яңа көч» колхозы председателе Галинур Айтугановның чәчү агрегатларын кырга чыгаруын хәбәр иттеләр. Монысына инде Тимергалиевнең сабырлыгы төкәнде, ул председательне сәгате-минуты белән райком бюросына китереп җиткерергә боерды.

Бюро уздырыла торган кабинетка, беренче секретарь бүлмәсенә Галинур Айтугановны туп-туры кырдан алып кайттылар, ул чәчүчеләр белән бергә, тузанга батып, басуда йөри — кирза итектән, юка курткадан, өс-башына һәм ямьшәйгән иске кепкасына бер карыш тузан утырган иде.

Бюродагылар эш киемнәреннән, ишекне каерып ачып кергән тап-таза егетне сынаулы караш белән каршыладылар. Алар һәммәсе ак күлмәктән, галстуктан, өф иткән костюмнан һәм күзеңне чагылдырырлык итеп ялтыраткан импорт туфлиләрдән иде.

Тимергалиев председательгә урын-мазар тәкъдим итмәде, аны «келәмгә бастырып», тып-тын калган бүлмәдә игәүли башлады.

Галинур баштарак: бәлкем, минем аңлатмамны да тыңларлар, дип өмет иткән иде. Кая ул! Башта беренче секретарь, аннары агропром башлыгы Сәүбәнов, аннары райбашкарма председателе Әсфәндияров, бер-берсен уздырырга теләгәндәй, «Яңа көч» председателенә ярсып ташландылар.

Болар аңардан аңлатма алырга түгел, аны тыңларга һәм нәтиҗә чыгарырга түгел, аны изәргә, сытарга, ниһаять, үз арбаларына җигеп, камчылап куарга чакырганнар икән. Күрдең — алар балкып торган затлы киемнән, ә ул тузанга баткан килеш...

Ләкин эш киеме Галинурны беркайчан да кимсетми, түбәнсетми, эш киеме киеп алуга ул үзен җир йөзендәге иң көчле һәм иң кирәкле кеше итеп сизә иде.

Бүген дә ул, тузанга баткан кирза итекле аякларын аера төшеп, кунадай арка-җилкәсен уйнаткалап, кабинет уртасында басып тора, бюродагылар аның чибәр кара мыегы астыннан мәсхәрәле елмаеп,

үткен карашлы күзләрен кыса төшеп сабыр гына торуында көчсезлек түгел, киресенчә, үз-үзенә ышанган бер ныклык күрәләр, мондыйларны үгетләү түгел, дегетләсәң дә берни барып чыкмаслыгын аңлыйлар; ачулары аның саен кабара, әйткән сүзләре тәмсезләнә, җанга ятышсыз була бара иде.

Үзсүзле председательне акылга утыртырга бөтен көчләре белән тырышып та берни дә барып чыкмаслыгын аңлаганнан соң, Тимергалиев, ниһаять, гаепләнең үзенә мөрәҗәгать итәргә булды.

— Йәгез, коммунист Айтуганов, сез үзегезнең райкомга каршы, хәтта, мин әйтер идем, үч итеп эшләгән эшегезне ни белән аңлата аласыз?

Галинур беркавым тын торды.

Бюродагылар да тын калды.

— Көтәбез,— диде Тимергалиев бераздан.

Галинур әкрен генә сүз башлады:

— Безгә, Морат Баянович, узган елны, райком кушуы буенча, Казаннан профессор килде. Лекция сөйләргә. Ислам дине, христиан дине, индуизм турында. Барлык төр аллаларны аңлатты. Мәчетне, чиркәүне, синагоганы тетеп салды. Бу ничектер лекция тыңлаучы картларга ошамады. Шундый лекцияләр вакытында көтелмәгән сораулар бирүе белән танылган Гаделҗан бабай түзмәде:

— Иптәш-тавариш прафисор, сез диннәрне бик озак аңлаттыгыз. Җир йөзендә Аллаһы тәгалә яраткан җан ияләре бар бит әле. Менә шулардан сыер, ат, кәҗә ничегрәк тизәк салалар? — диде.

Профессор аптырап югалып калды: «Белмим»,— дип мыгырданды.

Шуннан соң Гаделҗан бабай әйтте:

— Сыер коймак сала, ат алма төшерә, кәҗә чикләвек коя. Ә сез шул тизәкләрне дә аера белмәгәч, ничек соң Аллалар хакында сөйләргә батырчылык итәсез? — диде.

— Соң шуннан? — диде ачуы кабарган Тимергалиев.— Моның белән нәрсә әйтмәкче буласыз?

— Арыш чәчү минем эш. Мин җиргә күмгән арыш тишелми икән, җәза бирү — сезнең эш.

5

Язны Таулы Төбәк райкомында зарыгып көтеп алдылар. Былтыргы ямьсез бәхәсне яз үзе хәл итәчәк иде.

Әмма яз Тимергалиев файдасына булып чыкмады. Айтугановлар чәчкән арыш яшел хәтфә булып, бөтен район басуын балкытып, күзләрне иркәләп утыра, арыш чәчми калганнар үкенеп бетә алмыйлар иде.

Тимергалиев синоптиклардан сорашып белде, ел яңгырлы киләчәк, кояшлы көннәр аз булыр. Таулы Төбәк, көньяк районнар белән чагыштырганда, болай да чәчүгә бер атна соң чыга, инде яңгырлар да буласы булгач, игеннәр үсеп җитеп өлгерерме?..

Шуңа күрә Тимергалиев язгы чәчүне бу эш белән турыдан-туры шөгыльләнүче Гайниевкә генә тапшырып калмады, үзе дә тотынды.

— Алло, «Коминтерн»! Христофоров, сезме? Чәчүгә чыктыгызмы, ниһаять? Нәрсә? «Сабанчы» председателе Айтуганов чыкмыйдисезме? Кем сезнең җитәкчегез — Айтугановмы, әллә райкоммы?..

— Алло! «Егерменче партсъезд». Гафуров, хәлләр ничек: график үтәләме? Нәрсә? Чыкмадыгыздамы әле? Күпме әйтергә була? Причем монда Айтуганов малае? Кем ул сезгә — райкоммы, парткоммы, райбашкармамы? Айтуганов Галинур чәчү срогын өзгәне

өчен үзе җавап бирер, сез үзегез. Карагыз әле, Гафуров, соңгы мәртәбә кисәтәм, кичкә миңа шалтыратып хәбәр итегез: техника кырда булсын! Ул ниткән Айтугановлар, понимаешь! Аталы-уллы Айтугановлар, тапканнар монда үрнәк алыр кеше. Чәчү срогын өзеп кенә карагыз...

Телефоннан районны аркылыга-буйга актарып чыкты Тимергалиев — яртыдан артыгы кырга чыкмаган, шуларның иң зур сылтау итеп куйганы — Айтугановлар.

Бу хәл райком секретарен үзе өчен нәтиҗә ясарга мәҗбүр итте. аталы-уллы Айтугановлар райком белән бер аяктан атламый, ул гына да түгел, район белән җитәкчелек итәргә комачаулый. Әнә бит ярты район Айтугановларга багына. Аталы-уллы Айтугановлар үзләре генә булса бер хәл иде. «Сабанчы»дан үсеп чыккан өч председатель үзләре тирәсендәге колхоз җитәкчеләренә йогынты ясап яталар. Моннан нинди нәтиҗә ясап була? Димәк, Таулы Төбәктә райкомның бер бюросы эшли, аргы очта — Балдамар ягында Айтугановлар бюросы хасил булган. Юк, моңа юл куярга ярамый! Өлкән Айтугановка кагылып булмый — анысы депутат, аның белән күрәшү, әлбәттә, тиңең белән тибешү булыр иде, тик ул тибештән кемнең башы ярыласы билгеле түгел. Юк, өлкән Айтуганов белән тибешү җүнлелеккә илтмәячәк, моны гына белә юрист Тимергалиев. Өлкән Айтуганов халыкка таяна. Халык аны бирмәячәк. Ә менә улы, Галинур Айтуганов, Авыл хуҗалыгы институтыннан алып чыккан экономистлык белеме булса да, тәҗрибә ягыннан сайрак. Анысын акылга утырту ул хәтле үк авыр булмастыр.

Халык битараф. Гамьсез. Аңа кем килсә дә барыбер, ул бит күрә — килгән бер председатель беренче башлап үзенә йорт сала, агачның кәттәсен, наратын, шаулап утырганын кистереп сала, үзе өчен генә тырышты дип әйтмәсеннәр өчен, колхозның ферма каралтыларын яңарткан булып кылана, культура сарае салырга тотына — башта моңа, әлеге кармакка кабалар, соңыннан күңелләре сүрелә, гайрәтләре чигә, чөнки бу председатель дә тегесеннән артык түгел, дәүләттән мул гына ссуда алып, колхозны тагын бурычка батырган икән. Китәр, киткәндә йортын сатып китәр, сатмаса, сүтеп, башка урынга күчереп куяр. Үзе киткәч, ник ямый, ник көл булмый колхозың! Әнә шундый караш туйдырган крестьянны, председатель алмаштыруга ул битараф карый. Әйе, Галинур Айтугановны алмаштыру да әллә ни мәшәкатьле булмас, анда аның үзенә барып йөрү дә кирәкмәстер, икенче секретарь Гайниев тә бик әйбәт кенә башкарып чыгар аны...

Монысына ул икеләнми, үз көченә ышана, тик әле аның икенче бер зур мәшәкате бар — шәхси тормышы көйле түгел. Үзе теләгәнчә, райком секретарена лаек рәвештә яшәрлек йорты юк аның. Дөрес, язга чыгу белән агропром җитәкчесе Сәүбәновны ияртеп, тагын бер мәртәбә тау буендагы каенлыкка барып килде.

Җир кипшергән. Ямь-яшел булып үлән чыгып килә, каеннар яфрак җибәрә башлаган. Аста, күз күреме җирдә, әллә кайларга тикле биек зәңгәр күк җәелә, аның офыкка барып тоташкан урынында күгелҗем урманнар шәүләләнә, станца ягыннан, рельсларга кага-кага, товарнякның тукылдап килгәне тоныкк кына булып ишетелә, әнә шул ритмлы тукылдау язгы дәртле авазларга, кошлар чыр-чуына килеп кушыла, җаннарны рәхәтләндереп, күкрәккә саф һава тула иде.

Тимергалиев белән Сәүбәнов янәшә байтак вакыт басып тордылар. Язгы чәчү турында, кайсы колхозның графикны ничек үтәве турында сөйләштеләр. Ләкин бу чынлап сөйләшү түгел, сүз җилеме өчен генә башланган әңгәмә иде.

Сәүбәнов Беренченең бирегә ник килгәнен чамалый булса кирәк.

Сизгер кеше Даут Кодрәтович. Таулы Төбәкнең «Дала» совхозында ун ел буе эшләве бушка китмәгән, районның агропром җитәкчесе итеп аны шуңа күтәргәннәр.

Сүзне Тимергалиев үзе башласа да булыр иде. Ләкин ул сүз кузгатырга ашыкмый, аңа Сәүбановның үзенә никадәр турылыклы, никадәр бирелгән булуын белү кирәк.

— Карагыз әле, Морат Баянович, матур бит бу каенлы тау. Һава тау башында һәрвакыт чистарак була...— диде Сәүбанов.

— Нәрсә әйтергә телисез, Даут Кодрәтович?

— Сез бит инде гомер буе коммуналкада яши алмассыз. Үзегез — бирелә, семьягыз — Казанда. Йортны сала башлыйк мәллә?

— Кайда?

— Кайда дип? Менә шушында.

— Рәхмәт. Җанга ятышлы сүз әйттегез. Таулы Төбәккә килгәннән башлап күңел төште минем бу тауга. Тик, иптәшләрчә үтенәм: каеннарны мөмкин чаклы имгәтмәскә иде...

Сәүбанов ифрат булдыклы кеше булып чыкты. Унбиш көн эчендә ул леспромхозда бура буратып, автоколонна машиналары белән булачак йортны ташытып та куйды. Шифер, кирпеч, цемент ише нәрсәләр райүзәк базаларында бар, халык исенә килеп өлгергәнче йортны өеп куярга кирәк.

Зурдан купты Сәүбанов: институттан махсус проект алып, йөз илле квадрат метр зурлыгындагы алты почмаклы йортны, верандалы, чарлаклы, мансардалы итеп, барлык каралты-куралары белән салырга тотынды. Әлбәттә, хуҗаның рөхсәте белән! Морат Баяновичның саф һавалы иркен йортта күптән инде яшисе килә, күптән инде ул шул хакта хыяллана иде. Әфганстанда хезмәт итә торган улы Артур да исән-имин котылып, быел җәен кайтып җитсә, аны бит әле башлы-күзле дә итәсе булыр, аның өчен махсус йорт җиткезеп булмас, ә бу дәү һәм иркен йорт аларның барысын да үзенә сыйдырыр...

## 6

Язгы чәчүгә Айтугановлар биш көнгә соңгарак калып чыксалар да, игеннәре башкаларныкына караганда тизрәк үсте, тизрәк ныгыды. Өстәвенә, көзен чәчеп калдырган арышлары кырларны балкытып, тулышып утыра.

Узган елны күз явыңны алырлык итеп киенгән бюро члennарының туп-туры кырдан, тузан баскан эш киемнәреннән китерелгән Галинур Айтугановка ташланулары, әллә ниткән җәзалар белән куркытулары исенә төшкәч, Тимергалиев үзен ничектер уңайсыз сизә башлады.

— Әйт әле, Шәрифулла, ничек соң Айтугановларның игене тизрәк үсә? Җире дә шул ук, кешеләре дә шул ук бит,— диде ул райкомда авыл хуҗалыгына җитәкчелек итүче Гайниевкә.

— Белмим,— диде Гайниев. Белә иде, юри әйтмәде. Чөнки Тимергалиев моңарчы аның белән түгел, агропром башлыгы Сәүбанов белән күбрәк киңәш тотты.

— Даут Кодрәтович та белмиме?

— Ул да белми.

— Ничек инде ул алай?! — дип кызып китте Тимергалиев.— Икегез дә авыл хуҗалыгына җитәкчелек итүчеләр, ә үзегез бер колхозда игеннәрнең ни өчен тиз һәм яхшы, ә икенчесендә озак һәм кәй үсүен дә аңлата алмыйсыз. Оят! Позор! Барыгыз «Сабанчы»га, өйрәнегез, белегез, кайткач, бюрога хәбәр итәрсез.

— Бүген үк китикме, Морат Баянович?

— Бүген үк. Сәгате-минуты белән! Табыгыз агрономын, сорашыгыз, кырларын карагыз.

Гайниев «Сабанчы»га бармыйча да игеннәрнең анда ни өчен тиз үскәнен һәм мул уңыш биргәнен аермачык белә. Сәүбановны «Сабанчы»га алып барып, Айтугановларның акыллы эшләрен күрсәтергә һәм агропром башлыгы аша үрнәк председательне һәм аның улын Тимергалиевкә якынайтырга, дөресрәге. Беренчене дөньяга заманчарак каратырга тели иде.

Игеннәрнең сере гади: агроном Фатыйх Айтуганов беркайчан да озак еллар яткан орлыкны чәчәргә рөхсәт итми, симәнәгә ул яңа уңыштан иң югары сортлы орлыкны салдырып куя. Калибрлата. Сортлы орлыкларны Украинадан, Белоруссиядән, тагын әллә кайлардан кайтарта.

«Сабанчы»га килгән кунакларга Фатыйх Айтуганов әнә шул хакыйкатьне тагын бер кат сөйләп бирде. Дөресрәге, ул аны Сәүбановка сөйләде, ә Шәрифулла Гайниевкә күз кысты: син беләсең, янәсе.

— Ә яңа орлыкның хикмәте нәрсәдә соң? — диде Сәүбанов.

— Яңа орлыкта көч күп була. Буынга тиз утыра, тиз баш җибәрә, димәк, игеннәр тизрәк өлгерә дигән сүз. Ә менә бураларда озак яткан орлык, кеше кебек үк картая, авыруларга бирешә, әкрен үсә, гомумән дә уңышны аз бирә.

— Монысы аңлашылды. Яңа уңышны җыеп алып, симәнә салган чорда район агрономнарына шушыларны сөйли аласызмы?

— Рәхәтләнеп. Мин ачкан яңалык түгел бит. Агрономия белән азмы-күпме таныш булган һәркем моны белә.

— Әйт әле, Фатыйх... Менә сез, «Сабанчы»лар, узган елны өермәләнеп тузан очкан басуга арыш чәчтегез. Сездән күрмәкче Галинур Айтуганов та чәчте. Ә бит обком да, Совмин да колхозларга арыш чәчмәскә команда биргән иде. Сез моны, ни булса шул булыр дип, йөрәгегезгә таянып эшләдегезме, әллә монысының да берәр хикмәте бармы?

— Безнең колхозда йөрәккә таянып кына бер нәрсә дә эшләнми, иптәш Сәүбанов. Без бар эштә дә халыкка һәм үзебезнең тәҗрибәгә таянабыз. Ел килешен өйрәнәбез, сынамышларны... Туфракны кулга алып, учта уып карау җитә: аның чәчүгә яраклымы-юкмы икәнен шундук әйтеп бирергә була.

— Моңа сезне кем өйрәтте?

— Башта моны Фәһим абый белә иде, аңардан мин өйрәндем, миннән — Галинур...

Шәрифулла Гайниев «Сабанчы»да ишеткәннәрне Тимергалиевкә үзе сөйләмәде. Сәүбановка тапшырды.

— Син сөйлә, экономиканы сиңа алып барасы,— диде.

— Ә ул «Сабанчы»дагы акыллы агроном кем ул? — диде Тимергалиев, РАПО башлыгын тыңлагач.

— Фатыйх Айтуганов.

— Ул тагын ниткән Айтуганов?

— Фатыйх — председатель Фәһим Айтугановның бертуган энесе. Унбиш ел инде «Сабанчы»да баш агроном, белемле, эзләнүчән, тынгысыз. Председатель иген уңышын уйлап та бакмый, аның барлык ул эшен энесе Фатыйх алып бара,— дип, бу юлы Гайниев үзе дә сүзгә кушылды.

Тимергалиевнең калын кашлары җимерелде.

— Тәмам тулган икән безнең район Айтугановлар белән. Башка чакта семьячылык дип кычкырабыз. Айтугановларныкы ничек соң ул семьячылык булмый?

Шәрифулла Гайниев аеруча бер ихласлык һәм ярату белән:

— Семьячылык бит ул бер гаилә кешеләре җыелуда гына түгел, Морат Баянович,— диде.
— Нәрсәдә соң?
— Үз мәнфәгатьләрен генә кайгырткан кешеләрнең бер өергә җыелуларында.
— Ә болар үз мәнфәгатьләрен кайгыртмыймы?
— Болар, Морат Баянович, кайчагында тиешлене, законда каралганны да алмыйлар.
— Мәсәлән?
— Мәсәлән, киләсе елның орлык ашлыгын саклап чыгуга, чиста итеп әзерләүгә барлык көчен сала агроном Фатыйх Айтуганов, ә председатель Фәһим Айтуганов яхшы орлык әзерләгән өчен рядовой колхозчыларга бүләк бирә, энесенә — юк. Председательнең үзенә дә бу эш өчен өстәмә түләү каралган, ләкин аны Айтуганов беркайчан да алмый.
— Ә энесе шуңа үпкәләмиме дәме?
— Нинди үпкәләү! Ул аны шулай тиеш дип саный. Шуңа күрә дә колхозчылар Фатыйх Айтугановның озак еллар баш агроном булып торганын күпсенмиләр, алар аның Фәһим Айтуганов энесе икәнен онытканнар да инде.
Тимергалиев авыр итеп бер көрсенде.
— Ә нишләп соң без аларның ул сыйфатларын башкаларга җиткермибез? Нишләп алайса агроном Айтугановны районга күчермибез?
Шәрифулла Гайниевнең йөзенә күләгә төште.
— Нәрсә әйтмәкче буласың? Нигә чыраең бозылды? — диде Тимергалиев.
— Их, Морат Баянович, Фатыйх Айтуганов районга күчмәячәк. Ул чамадан тыш мөстәкыйль кеше. Ул районны бер генә агроном да күтәрә алыр дип ышанмый. Утыз елдан артык бит инде колхозларны текә күтәрү хакында сүз алып барыла. Ике Пленумның берсен Үзәк Комитет авыл хуҗалыгына багышлый. Җитәкчеләр сөйләгән сүзнең барысын бергә өйсәң, Урал таулары килеп чыгар иде. Ә авыл һаман күтәрелми, авыл һаман шыгырдавык арба төсле ыңгыраша-ыңгыраша бара.
— Сәер. Бик сәер...— диде Тимергалиев, үз алдына сөйләнгәндәй.— Мин райком секретареннан мондый сүз көтмәгән идем.
— Зерә, Морат Баянович. Безгә сүзнең бик ачыларын да ишетергә туры киләчәк әле. Хәбәрдарлык чоры, ачыктан-ачык итеп, акны — ак, караны кара дип әйтү чоры килде. Без һаман белмәмешкә, күрмәмешкә салышабыз. Эшне һаман әүвәлгечә алып бармакчы булабыз. Айтугановларны үзебезнең арбага җигәсе урында, аларга каш астыннан карыйбыз, борын җыерып! Бу безгә кыйбатка төшмәгәе...— диде Шәрифулла Гайниев.
— Ярар. Бүгенгә җитеп торыр. Игеннәрне урып-җыюга әзерлек эшләрен башлагыз. Киләсе атнада дүшәмбе көнне иртәнге тугызга председательләрне, совхоз директорларын, барлык парторгларны чакырыгыз. Сәүбанов, син урындагы хәлләрне өйрән, сөйләшүне син алып барырсың, без тыңлап утырырбыз, кирәк булса, йомгак ясарбыз,— диде.
Сәүбанов Беренче белән сөйләшә калды.
Гайниев сүзсез генә чыгып китте.

«Яшь әле. Умыртка сөяге ныгып җитмәгән. Партия солдаты икәнен онытып, Айтугановлар җырын җырлап йөри. Зыян юк, өйрәнер. Бер-ике тапкыр обкомнан каты шелтә чәпәсәләр, башкачарак сайрый башлар»,— дип үзен юатты Тимергалиев. Шулай да күңеленең бер почмагында Шәрифулла Гайниев әйткән сүзләрнең хак

икәнен тану аны «Сабанчы» колхозына, парторг Сиражиевка шалтыратырга мәҗбүр итте.

— Карале, Мөхәммәт, печән өсте якынлашты, озакламый урак та башланыр. Сезнең әзерлекләр ничек анда? — диде ул.— Вакыт табып, килеп чык әле. Планнарың белән уртаклашыр идең.

— Игътибарыгыз өчен рәхмәт, Морат Баянович. Әгәр бик тә кирәк дип әйтмәсәгез, килми торыр идем. Илле чакрымга машина куу үзе бер начар, икенчедән, колхоздагы сабантуйны әзерләүне үз өстемә алган идем.

— Тукта, ә нигә... сабантуй әзерләү — парторг эшемени? Авыл советы, профсоюз, комсомол, конца концов, авыл картлары, аксакаллар юкмыни сездә?

— Алар барысы да бар, алар барысы да катнаша, быел сабантуйларын башкачарак уздырырга уйлап торабыз, иптәш Тимергалиев.

— Төгәлрәк әйтә алмассыңмы?

— Урып-җыюда катнашасы техниканы сабантуй аланына куябыз — смотрга. Кемнеке иң яхшы, кем иң алдан ремонтлап бетергән комбайнын, тагылма машиналарын, грузовикларын, шуларга бүләк бирергә исәп. Язгы чәчүдә үрнәк күрсәткәннәрне дә билгеләп узмакчы булабыз.

— Аңламыйм, сабан туе халык уеннары түгелмени ул?

— Халык уеннары, Морат Баянович. Ул хакта сүз дә була алмый, чабышкы атларны да, көрәшче егетләрне дә әзерлидек. Әмма сабантуеның мәгънәсе дә сабаннан алынган бит, иген үстерүчеләрнең бәйрәме бит ул. Халыкка стимул ясап, намуслы хезмәтен билгеләп узсак, начар булмас, минемчә. Рәхим итеп, килегез, Морат Баянович. Печәнгә һәм уракка дәрт алып китәрсез.

— Яхшы. Уйлармын. Рәхмәт,— дип өзеп-өзеп кенә әйтте секретарь.

## 7

Тимергалиевнең «Сабанчы»га сабантуй көннәрендә барып килергә нияте юк түгел иде, ул Балдамар һәм башка алты авыл халкы белән якыннанрак танышмакчы да иде, тик авылларда сабантуйлары булган дәвердә Таулы Төбәк райкомына бер хат килеп төште. Хат күңелле хәбәр китерми, өстәвенә ул шәхсән беренче секретарьның үзенә кагыла.

Хатны аңа Сәүбанов кертеп бирде.

— Эшләр, минемчә, бик күңелледән түгел, Морат Баянович. Таулы Төбәк кешеләре «Советская Россия» газетасына хат язганнар, 32 кеше кул куйган,— диде Сәүбанов.

Тимергалиев хатны ашыкмыйча, озаклап укыды. Укып бетергәндә кашлары җыерылды, кинәт урыныннан күтәрелеп, зур таза гәүдәсе белән иркен кабинетны тутырып, ишекле-түрле чаба башлады.

Ниһаять, ул туктады, кыл кебек каты, туры чәчләрен учы белән алга сыпырып төшерде.

— Нишлибез? — дип, Сәүбановка карады.

— Ә мин бит хатны укымадым, белмим, Морат Баянович. Нәрсә язганнар соң анда?

— Тимергалиев Таулы Төбәк халкы үстергән каеннарны кыра. Сугыш инвалидлары фатирсыз тилмергән чакта патша сарае чаклы йорт салдыра,— дип язганнар.

— Нәрсә таләп итә инде алар?

— Гарип-горабага тапшырырга кушалар йортны.

— Тапшырабызмыни инде?

— Беләсезме, Даут Кодрәтович, мин бит сезгә әйттем, каеннарга кагылмасагыз иде, дидем... Аннары, нигә кирәк иде аны 150 квадрат метр итеп, чарлаклы итеп салырга?..

— Булгач булгач булсын инде, булдырыйк бер булмаса, дип тотындык бит, Морат Баянович. Сез каршы килмәдегез. Аннары нигә әле без юк белән үз-үзебезне битәрләп утырабыз? 150 квадрат метрда түгел хикмәт, әгәр сезгә кадәр эшләгән секретарь сугыш инвалидларын кайгырткан булса, бу йорт аларның күзенә дә чалынмас иде. Әле күптән генәме — колхоз председательләре моңардан зуррак итеп салалар иде йортны. «Перестройка» дигән хикмәт чыкмаса, берәүнең дә райком секретаре хәтле райком секретарена каршы буза куптару башына килмәс иде.

— Нишлибез? — диде Тимергалиев, гасабилана башлап.

— Бер генә юл кала, Морат Баянович, йортны салып бетерергә дә ветераннарга тапшырырга. Тантаналы рәвештә! Ул чагында без җәза алучы түгел, дан алучы булып калабыз, ветераннарны кайгыртучы.

— Шушы аләк язган картларга бирергәме?

— Ә кемгә бирергә соң?

— Бирмибез кляузникларга. Балалар бакчасына тапшырабыз. Каеннарны рәшәткә белән уратып аласың. Район комбинатына заказ бирергә кирәк. Атынгычлар, әлмәндерекләр, таганнар ясасыннар. Ясап бетергәч кенә алырбыз да бер көн эчендә корып та куярбыз.

— Менә бу акыл! Жалучылар жалуларын тотып калалар. Райүзәктә өр-яңа балалар бакчасы үсеп чыга...

— Яхшы, димәк, килештек. Әйдә, йортны карап, саубуллашып кайтыйк инде алайса.

— Әйдәгез,— диде Сәүбанов күңелсез генә. Барлык көчен, сәләтен җигеп, көннәрен-төннәрен борчылып, җиренә җиткереп салган йорттан аның берничек тә аерыласы килми иде.

Райүзәктә кешеләрнең аяк шиле тынгач, алар каенлыкка бардылар.

Күгәрми торган калай белән түбәсе ябылган, элекке авылларның клубы чаклы, нарат бүрәнәле йорт биек сары коймасы, ак мунчасы, каралты-куралары белән ерактан ук күзгә ташланды.

«Әзер иде бит инде, әзер!..» — дип өзгәләнде Тимергалиев күңеленнән.

Йорт яны бакчасы булачак урын инде коймалар белән уратып алынган, дөрес, әле ул челтәрле койма түгел — имән баганалар да аратлар гына. Әмма алар бик нык, баганалар хәтта төбенә цемент коеп утыртылган, икеме-өчме җиргә, каен башларына хәтта сыерчык оялары да беркетеп куялган иде.

Түбәләре шифер белән ябылган утын-күмер сарайларын, ак мунчаны, гаражны, лапасларны, амбар-келәтләрне озаклап карагач, йортка керделәр.

Өй зур, ифрат зур. Дүрткә бүлгәннән соң да әле бүлмәләр дәүләт оешмаларының заллары хәтле булып калган, сап-сары түбә сайгаклары, сап-сары идән сайгаклары, бик пөхтә итеп мүкләнгән, ап-ак итеп шомартылган тигез нарат бүрәнәләр йорт эчен нарат сагызы исе белән тутырган иде.

«Иех!»..— дип җан бәгыреннән чыккан бер генә сүз әйтте Тимергалиев. Үзалдына көрсенеп әйтте.

Аннары алар кайтып киттеләр.

...Инде менә шыксыз «коммуналка»сында утырганда, секретарь уйга калды. Халыкны ул битараф дигән иде, син ни генә эшләсәң дә алар өчен барыбер, алар гамьсез яшәргә өйрәнгәннәр, дип фикер

йөрткән иде. Юк икән. Битарафлык беткән, исемсез итеп түгел, имза куеп хат язарга, райкомнан курыкмаска өйрәнеп килаләр икән ич. Ә бу нәрсә соң — партиянең авторитетын аяк астына салып таптау түгелме? Моның кайчан булганы бар иде?..

Җитәкчелек авырая, димәк. Халыкка ирек кенә бир — муенына менеп атланачаклар. Айтугановларның азынуы юккамыни? Ирек килгәнне, авызлык бушаганны сизәләр. Аларның берсеннән котылмый булмастыр ахырысы...

Төшенке уйлары белән утырган чакта аның күңелендә Галинур Айтуганов калыкты. Таза булып, көнҗәлә чәченә, мыегына тузан кунган булып! Менә ул кирза итекле аякларын аерып, келәм өстендә басып тора, күзләрендә — тәвәккәллек, ирен читендә мәсхәрәле елмаю... Моны үгетләп җиңеп булмый, моны хәтта көч кулланып та җиңеп булмый.

«Ә йорт әрәм. Нинди буласы иде бит. Тау башында. Ерак офыклар күренеп тора. Каеннар яшел толымнарын җилфердәтеп утыралар...»

Иртәгесен ул үз кабинетына Гайниевны чакырып алды.

— Йә, Шәрифулла, нишлибез? Ничек үз арбабызга җигәбез кече Айтугановны? — дип, якын дусты белән киңәшкәндәй, сорау бирде. Гайниев Таулы Төбәк районында туып үскән, ул якларның халкын, халыкның кәефен белә, райкомга нәкъ менә «Яңа көч» колхозында биш ел парторг булып эшләгәннән соң күчерелгән иде. Икенче секретарь итеп сайланганчы әле ул авыл хуҗалыгы бүлегендә эшләде, кайсы колхозның нәрсәгә сәләтле икәнен күзен йомып та әйтеп бирә ала иде.

— Бу — бик авыр мәсьәлә, Морат Баянович. Чукмарлы халкы бик усал. Өстәвенә «Яңа көч» колхозы, башка хуҗалыклар төсле, алтыҗиде авылны берләштерми, сигез йөз йортлы бер авылга, бер-берсенә бик нык берекән, берсе өчен берсе утка керергә әзер торган авылга урнашкан. Беләм ич инде, биш ел парторг камытын киеп, йөк тарттым бит. Чукмарлы дигән исеме дә аның юктан гына түгел. Кала юлларында йөргән чакта чукмарлылар юлбасарларны тимер кистән — чукмар белән генә тончыктыра торган булганнар.

— Бу минем өчен яңалык,— диде Тимергалиев.— Халыкның усаллыгы һәм бердәмлеге эшне катлауландыра, әлбәттә. Неужели Чукмарлы халкын җиңә алмабыз? Әгәр үзеңә генә авырга туры килә дисәң, Шәрифулла, мин сиңа Сәүбановны бирәм. Даут Кодратовичны, аңарда ныклык та, хәйләкәрлек тә, логика да җитәрлек.

— Юк, Морат Баянович, хикмәт анда түгел. Капитально тотынсам, эшне партия исеменнән алып барсам, Чукмарлы халкын мин үзем дә җиңәр идем. Тик бит менә нәрсә...

— Нәрсә?! — диде Тимергалиев, сагаеп.

— Чукмарлыдан Айтугановны көч белән тартып алуыбыз хәерлегә булырмы? Менә нәрсә борчый мине. Райкомның авторитеты кинәт түбән тәгәрәмәсме? Беләсезме, Галинур каршы килеп бер сүз дә әйтмәс. Әтисеннән килгән сабырлык бар ул егеттә, әтисендә булмаган җор теллелек, шагыйрьлек тә бар. Шул кадәрле дә ягымлы мөнәсәбәттә ул Чукмарлы халкы белән, яшь булуына карамастан, халык аны ярата. Ник? Әлеге дә баягы, үзләрен ихтирам иткәне өчен. Мин бит аның белән янәшә биш ел йөрдем, беркайчан да Галинур бер генә кешегә дә кычкырмас, бугаз ертмас, хәтта берәрсе ялгыш эшләгән сурәттә дә, ул әйтер: фәлән абзый, син, күреп торам, моны бик ихлас, бик чын күңелдән эшләгәнсең инде, иллә дә мәгәр тагын бер уйлап карале, ялгыш булмады микән бу, дияр.

Гомер буена акыру-бакыру ишетеп, гел дә таланып, ач калып килгән крестьянга күпме кирәк,— яраталар Галинурны, ни дә булса эшләргә карар кылсалар, председатель белән киңәшеп алыйк, аның башы йомры, диләр.

— Бу чаклысы аңлашылды. Синең сүз?

— Ел бик авыр килергә тора. Без кышка тикле тими торыйк аңа. Карыйк-сыныйк, таякны тоткан җиреннән сындырмыйк.

— Ярый. Почти ышандырдың, хәзергә кагылмый тордык, ди. Әмма, мин синнән үтенәм, Гайниев, Айтугановларны күздән ычкындырма. Райком күрсәтмәләренә каршы килеп, башка председательләрне дә котырта башласалар, мин ул чагында аларга үзем тотынам. Ничек кече Айтугановның сөт тапшыруы?

— Башкалардан артта бара.

— Менә, менә! Без монда йөз грамм сөтне арттыру өчен тиредән чыгабыз, ә ул!

— Ул бит, Морат Баянович, сыерларын нәселлегә алыштыра.

— Беләсеңме, Гайниев, обком миннән нәселлеме сыерың, түгелме дип сорамый, сөт сорый, ай саен, көн саен сорый. Бугазга басып сорый. Менә кайда утыра ул синең Айтугановың! — дип, Тимергалиев муенына сызып күрсәтте.— Тәмам туйдырды ул мине. Кирелеге белән туйдырды. Караны, әгәр Галинур Айтуганов тагын бер генә мәртәбә этлек эшләсә дә, мин берни белән дә исәпләшмим, урак өстендә булса да алып ташлыйм аны.

## 8

Печәнгә төшүгә яңгырлар башланды. Бер көн кояш — бер көн яңгыр. Кибеп кенә өлгерә печән, җыеп алганчы яңгыр чылатып та китә. Бер атнадан тулаем бетәсе эш ике атнага сузылды, анда да, башка еллардагы төсле, хуш исле печән түгел, күгәрек исе кергән печән җыеп алдылар. «Сабанчы» кебек көчле колхозлар ул печәннең чапкан берсен зур-зур ындыр табакларына, атлар абзарының түбәсенә, мөмкин булган барлык урынга куеп, таратып, җиллэтеп өлгерделәр, эленке-салынкы эшләргә өйрәнгән колхозларның ярты печәне череп-мурып әрәм булды.

Яңгырлар уракка килеп тоташты.

Радио урып-җыюның барышын көн саен иртәнге алтыларда бөтен республикага хәбәр итә. Яңгыр сирәк яуган төбәкләрдә урып-җыю тулы көченә бара. Таулы Төбәк — артта.

Тимергалиев моның сәбәпләрен аңлый башлады. Таулы Төбәк — төньяк район. Бирегә яз көньяк районнарга караганда соңрак килә. Чәчү соңрак булгач, өлгерү дә соңрак, уракка да иң азактан төшәләр. Башка районнар, яңгыр яумый торган биш-алты көн эчендә арышның яртыдан артыгын урып өлгерделәр, сугып дәүләткә дә тапшырдылар. Ә Таулы Төбәкне яңгыр ике кулсыз итте.

Игеннәр узган елгыга караганда да әйбәтрәк уңды, тик аяныч: юеш килеш сугарга мәҗбүрләр, киптерергә урын юк. Сушилкалар аз, куәтләре юк, киптерә алмау сәбәпле, ашлыкны элеваторга китерү бик авыр.

Бу хәл бер Таулы Төбәктә генә түгел, тагын берничә районда шулай. Хөкүмәт ашлык уңган районнардан ничек тә күбрәк алып калырга тырыша. Шунлыктан өлкә җитәкчеләре белән сөйләшеп-киңәшеп, ашлыкны элеваторга юеш килеш китерергә рөхсәт алдылар.

Менә шунда Айтугановлар янә дә калкып чыкты. Өлкән Айтуганов кына түгел, кече Айтуганов та ашлыкны юеш килеш тапшырудан кискен рәвештә баш тартты, берниндн кисәтү, шелтә дә аларны юеш ашлык тапшырырга мәҗбүр итә алмады.

Фәһим Айтугановның сүзе кыска:

— Халыкның тир түгеп үстергән ашлыгын мин черетергә тапшыра алмыйм. Күпме сушилкабыз бар, тулы көченә куям, йокламабезне ничек тә үтәрбез, үтәми калмабыз.

Галинур Айтуганов:

— Хет бүгеннән алып ташлагыз мине, юеш ашлык тапшырмыйм.

— Ник? — ди Тимергалиев, аның күзенә туры карап.

— Тапшырмыйм. Юеш ашлыкның яртысын киметәләр. Алар хакы — элеваторда киптергән кешеләргә түләүгә китә, димәк, без 25 процент ашлыгыбызны башкаларга бирәбез, ә колхозчыны, игенне үстергән төп кешене хезмәт хакының чирегеннән мәхрүм итәбез булып чыга.

Менә монда инде Тимергалиев аталы-уллы Айтугановларга чынчынлап үпкәләде. Бу бит райком тәгәрмәченә таяк тыгу, бу бит күрәләтә районны артка сөйрәү. Айтугановлардан үрнәк алып, тагын биш колхоз элеваторга юеш ашлык китерүдән баш тартты. Айтугановлар җитәкләгән колхозлар да, әлеге биш колхоз да игеннәре әйбәт уңган хуҗалыклар иде, алар көн саен йөз иллешәр тоннадан артык ашлык ким тапшырганга күрә, Таулы Төбәк икмәк тапшыру көндәлегендә тагын арткы рәтләрнең берсенә күчте.

Монысына да түзәргә булыр иде әле. Берьюлы ике колхозның гына түгел, җиде колхозның юеш ашлык тапшырудан баш тартуы кичләрен Тимергалиевне авыр уйларга сала, әллә мин ялгышам микән, алга чыгарга омтылмыйча, ашлыкны кыен булса да сушилкаларда киптереп тапшырырга кирәк микән, дигән фикергә китерә иде.

Шулар янына йорт мәшәкате өстәлде.

Беренче йорт белән уңышсызлыкка очрагач, Тимергалиев агропром башлыгына бик кисәтеп әйтте:

— Шундый бер урын табыгыз, эт тә бәйләнерлек булмасын. Йорт казнаныкы. Капитальный итеп салырга кирәк булыр. Акчаны да, төзелеш материалын да кызганмагыз. Миннән һәм синнән соң киләчәк кешеләр, Даут Кодрәтович, безне сүгеп йөрерлек булмасын. Үзеңә мәгълүм: замана хәзер бик тиз үзгәрә, гомер буе райкомда утырмабыз, кешеләр безне сагынып сөйләрлек булсын...

— Эшлибез аны, Морат Баянович!

Агропром җитәкчесе йорт салыр өчен бу юлы урынның уңайлысын, чыннан да, беркем тел-теш тидермәслеген тапты. Бөек Ватан сугышы инвалиды, ике күзе дә сукырайган бер абзыйның йорты бик искергән, ул үзенә казна йортыннан бер бүлмә сорап поселок Советына мөрәҗәгать иткән. Абзыйның йорты югарыда, аулак урында, аңа казна йортыннан квартир бирелгән сурәттә, аның иске йортын сүтеп таптап — урыны зур, бәрәңге бакчасы гына да унбиш сутыйлык! — менә дигән яхшы йорт салып була, үзе тагын үзәк урамнан да ерак түгел, райком секретаре йортына хәтле генә таш җәйдертү, хәтта асфальт җәю дә кыен булмас, мөгаен.

Болар барысы дөрес. Ә яңгырлар тота кулны, ни бүрәнә китертеп булмый, ни балта осталарын эшләтеп!

Бердән, яңгырларның урып-җыюны тоткарлавы, икенчедән, йортны салып булмау, өченчедән, күмәк эшкә Айтугановларның, аларга ияргән тагын биш колхозның матавык китереп кертүләре аның нервысын шактый ук какшатып, җанын гасабиландыра башлады...

Мең төрле мәшәкать белән, алны-ялны белмичә, тоташ яңгырлар астында йөргән механизаторлар ничек кирәк алай уракны бетерделәр, яңгырлардан каралган саламны эскертләргә өйделәр; эш бәрәңге басуларына, кукуруз һәм чөгендер басуларына күчте.

Октябрь башында, ниһаять, яңгырлар туктады, әнә шул вакытка Айтугановлар да дәүләткә киптерелгән, тулы кондицияле ашлык тапшырып бетереп, амбарларына киләсе ел өчен кирәкле симәнәне салып куйдылар.

Көчле сушилкалары булмаганнарның орлык ашлыгына яраклы икмәкләре дә чамалы иде.

Тимергалиев райкомның киңәйтелгән бюро утырышын киләсе

елның орлык фондын булдыруга багышлап җыйды. Анда ул Фәһим Айтугановны да, аның улы Галинур Айтугановны да чакыртты. Дөрес, киңәйтелгән бюрода башка председательләр дә бар иде, тик беренче секретарь үзенең кереш сүзендә орлык фондын әзерләүне барысы өчен бер таләп белән генә куйды, утыз өч хуҗалыкның җитәкчеләрен атамады. Айтугановларны атап, урыннарыннан торгызды.

— Фәһим Сабирҗанович, минем белүемчә, сездә киләсе ел өчен кирәкле кондицияле, яхшы киптерелгән орлык ашлыгы үзегездән арта. Бодай белән арпаны колхозчыларга өләшмәссез, башка хуҗалыкларга сатып бирерсез,— диде.— Без бюро членнары белән бу хакта киңәштек.

— Мин моны үзем генә хәл итә алмыйм, бездә халык сайлап куйган идарә бар, мәсьәләне идарәдә куеп тикшергәч, фикеребезне әйтермен,— диде өлкән Айтуганов.

Тимергалиевнең мондый сабыр-салмак җаваптан янә бер мәртәбә кәефе кырылды. Шулай да ул тынычлыгын җуймыйча:

— Ярар. Тик бер генә үтенеч — тизрәк хәл итегез,— диде.

Аннары Тимергалиев, кече Айтугановның исемен дәшеп, аны аяк өсте басарга мәҗбүр итте:

— Сездә хәлләр ничек, Галинур Фәһимович? Сез орлыкка күпме бодай бирә аласыз?

— Мин, то-есть, безнең колхоз, бирә алмас, Морат Баянович. Бодай безнең үзебезгә генә җитәрдер,— диде Галинур. Ул бу юлы кырдан килмәгән, кешелеккә кия торган куе зәңгәр костюмнан, ак яканы балкытып бизәкле галстук таккан, кара бөдрә чәч, ыспай кара мыек, саусәламәт алсу чырай һәм атлетларча таза гәүдә аңа дәрәҗәсен белеп сөйләшергә мөмкинлек бирә иде.

— Ә барып тикшерсәк? Мин «Яңа көч»кә халык контроле председателе Вафинны җибәрсәм? — диде Тимергалиев, иренен кысып.

— Ә нигә ул тамаша зурдан кубарга, Морат Баянович? Халык контроле, минем белүемчә, урланган яки законсыз үзләштерелгән әйберне генә тикшерә түгелме соң ул? Бездә урланган икмәк юк.

Киңәшмәдә утыручы председательләр көлеп җибәрделәр. Тимергалиев, кыңгырау шалтыратып, аларны тыйды.

Фикер алышуда беренче булып Сәубанов сөйләде. Ул Айтугановларның, районның аеруча күренекле кешесе, алдынгы председателе булган Фәһим Сабирҗановичның мәсьәләгә җитди карамавын, булган байлыгын күршеләре белән уртаклашасы килмәвен тәнкыйть итеп сөйләде. Бу — коммунистларча түгел, диде.

Моңарчы башкалар исәбенә туенып, дәүләттән миллион сумлык ссуда алып, унар ел буе шуны түләмәгән өч председатель Сәубанов тегермәненә су койдылар. Фәһим Айтугановка шактый ук ямьсез сүзләр әйттеләр.

Фәһим абзый аларның берсенә дә каршы күтәрелмәде, эшләгән эшенең хак икәнен белгәнгә, аларның сүзен колак яныннан гына уздырып җибәрде.

Ләкин хаксызлыкка каршы авыз йомып утырмый торган, җанында сулкылдаганны тышка чыгарып аудармаса, үзен кая куярга белми торган кешеләр була. Шуларның берсе — «Сабанчы»да үсеп чыгып, күрше «Ярыш» колхозына председатель булып киткән Исламшин иде.

Әнә шул председатель кул күтәреп сүз сорады.

— Нәрсә, иптәш Исламшин, сездә дә артык ашлык бар мәллә? — диде Тимергалиев.

Исламшинның җыелыш-киңәшмәләрдә бик сирәк чыгуын, әмма чыкса инде җанында җыелганны көлтәсе-көлтәсе белән бәреп торуын белгәнгә күрә, кешеләр тынды, башларын Исламшин ягына бордылар.

Кырык бишләр тирәсендә, кашлары куе һәм кара, чыраенда нык-лык һәм тәвәккәллек сизелеп торган Фаяз Исламшин, иданнән калку-

рак итеп ясалган сәхнәгә чыгып, трибуна янына баскач, гадәттә башкалар кебек чәчен артка сыпырмады, киресенчә, дуамал бер хәрәкәт белән алга сыпырып төшерде һәм аның кылдай каты чәчләре тырпаеп калдылар, ә үзе ул сугышырга җыенган әтәчне хәтерләтә иде.

— Миндә яхшы бодай бар, арпа да бар миндә, солы да, хәтта ки борчак та. Ләкин мин аны бирмим, бирергә бер дә исәбем юк, Морат Баянович. Юк, үземә җитмәгәннән түгел. Артта сөйрәлгән колхозларны асраудан туйганга! Бездән ашлыкның центнерын бер бәягә алалар, артта барган председательләрдән бер ярым, хәтта ике бәягә! Кайда гаделлек? Кайчанга кадәрле без әрәмтамаклар үрчетербез? Урамда саф җилләр исә башлаган бер чорда, барлык гәзитләр перестройка дип кычкырып торган бер дәвердә без нишлибез — тагын булдыклыны ботарларга тотынабызмы? Бу ниткән әкәмәт — алтмыш яшен тутырып узган, кырык ел буена колхозны җилкәсендә тарткан фронтовик Айтугановны таларга җыенабызмы? Ник әле ул колхозчыларының салкын яңгырлар астында эшләп, көчен кызганмыйча амбарларына китереп керткән бодаен башкаларга, хөрәсән ялкауларына бирергә тиеш?

Тимергалиев кыңгырау шалтыратып Исламшинны туктатмакчы иде, залдан: «Сөйләсен! Брежнев заманы түгел!» — дип кычкырдылар, секретарь тыелып калырга мәҗбүр булды.

Исламшин үзен туктатырга азапланган Тимергалиевкә ачуы килүдән кинәт һөҗүмгә күчте:

— Сез, иптәш Тимергалиев, мине туктатырга телисез теләвен, ләкин мин трибунага чыкканмын икән инде, сөйлим. Чөнки мин трибунага сирәк чыгам. Аппаратчикларны халык хәленә куясы бар. Телевидениедән кайсы гына министрны күрсәтмәсеннәр — табак чаклы бит. Просто карарга уңайсыз. Менә безнең кебек яңгырларда-җилләрдә, лычма су булып басуда йөрсә, куллары берни тоймас дәрәҗәгә җитеп салкын балчык эченнән бәрәңге чүпләсә, бите дә табак чаклы булмас, корсагы да шиңә төшәр иде.

Әйтергә оят — намус дигән нәрсә бетте бит. Укытучы укытучы булудан, врач врач булудан туктады. Галимнәрен әйткән дә юк инде, безнең кырларга яраклы бер комбайн уйлап чыгара алмыйлар. Дөнья тулы карак, аферист, бушбугаз. Кая бара бу дөнья? Элекке заманда халыкны дин куркытып торган, хәзер нәрсә куркыта? Ыстырам, бөтен кеше бозык, бөтенесе үз корсагын кайгырта, аңа каршы чыкканны изәргә, сытарга, юк итәргә азаплана. Гәзитләрне укыгач, чәчләр үрә тора, валлаһи! Җан сатып, үзеннән олы түрәләргә ярашып, взятка биреп, тук яшәргә тырыша. Костырырга вакыт андыйларны! Әйе, әйе, әлбит, шулай. Ул сүз боткасы, ул сүз боткасы! Су туглап май төшмәгән төсле сүз туглап икмәк тә үсми бит. Кайдадыр безнең күршедә генә, Иделме, Агыйделме аша гына бер түрә үзенә каршы әйткәннәрне, яла ягып, сигезәр елга яптырган. Прокурор сатылган аңа, судьясы сатылган. Бер гөнаһсыз кешеләр аның ялгышына ләббәйкә дип тормаганнары өчен генә төрмәгә кереп утырганнар. Ярый әле, журналист дигән куркусыз кешеләр, гадел кешеләр пәйда булды дөньяга, моның барлык әтлеген казып чыгарганнар да гәзит аркылы фаш иткәннәр. Ярый әле перестройка чыкты, тегеләр өчәр ел гына утырып калганнар, югыйсә сигезәр елны түтелке-түтелке утырып чыгасылары икән, месекенкәйләр. Ә теге затсыз бик ансат кына пенсиягә китеп барган. Персональныйга! А как же, алланың кашка тәкәсе бит ул, депутат, делегат, коммунист.

Көч-хәл белән түзеп утырган Сәүбанов аяк өсте басып, кыңгырау шалтыратырга тотынды:

— Җитте! Булды! Райкомда икәнегезне онытмагыз, Исламшин!

Тимергалиев күрде — урынсыз килеп кысылды Сәүбанов. Киңәшмәдәгеләр дәррәү кузгалып, аңа төрле яктан кычкыра, ямьсез сүзләр

әйтә башладылар, аларны Морат Баянович, аяк өсте торып, озаклап кул күтәреп торгач кына туктата алды.

Кичен, өенә кайтып, йокларга яткач та әле гасабилы тавышлар аның колагында чыңлап торды, сугышырга җыенган төсле чәчләре тырпайган Исламшин күз алдыннан китмәде.

Үзгәрә дөньялар... Моннан берничә ел элек кенә шулай кыланып карасын иде Исламшин, белер иде, күрер иде. Бугаз киерергә ирек бирмәс иде аңа райком...

## 9

Яңа йортка декабрь башларында күченделәр.

Әминә ханым, бәхетле тигез тормыштан түгәрәкләнә төшкән йомры гәүдәле врач, йорттан канәгать булып калды. Хуҗа үзе дә канәгатьлек кичерде. Чөнки монысы беренче сала башлаган йортка караганда да җанга ятышлырак: чарлагы, мансардасы, верандалары, җайлы каралты-куралары гына түгел, эчке як стеналары кирпеч белән ныгытылган бик зур подвалы да бар. Таулы Төбәк — Казан түгел, базарга чыгып атна саен килолап алма алып кайта алмыйсың, Мораты машина белән Казанга барган чакта алмасын-фәләнен дигәндәй базадан берничә яшьнек алып кайтып куйса, бозылмый-нитми ай буена торасы. Бәрәңгене дә көзен председательләр китереп аудара ала, яшелчәмазарын да.

Җайлы иркен квартирда торачагына ышанган Әминә ханым җиденче класста укучы төпчек улы Азат белән бик әйбәтләп яңа йортка кайтып урнашты һәм үз зәвыгы белән йортны бизәргә кереште.

Шөкер, Тимергалиевнең бу яктан хәсрәте кимеде. Тик әле аның җанын ашап торган бер нәрсә бар — элеваторга дымлы килеш китереп аударган ашлык. Вакыт табып, андагы хәлләрне белешәсе булыр.

Белешү райком файдасына булып чыкмады.

Юеш килеш элеваторның ярым ачык бер мәйданына китереп аударган ашлыкның яртысыннан артыгын гына җилләтеп, киптереп, тиешле кондициясенә китереп, келәтләргә сала алганнар, калган өлеше көшелдә ята һәм аңардан күгәрек исе борыннарны ярып керә иде.

Бу хәл язга тикле Тимергалиевнең күңеленнән китмәде.

Моның райкомга зур күңелсезлек алып киләсен ул сизенә, тик бу эшнең обком рөхсәте белән эшләнгән булуы гына бераз күңелен юатып тора иде.

Менә ул шунда янә дә Айтугановларны исенә төшерде.

Төшерде һәм ярсуы кайнап чыкты. Әгәр алар да ашлыкны юеш килеш тапшырсалар, аларга ияргән биш хуҗалык та башкалар төсле эшләсә, ихтимал, Тимергалиев кайгырмас та иде, барыбыз да ялгыштык: обком да, райком да, председательләр дә, дияр иде. Ә болай, җиде колхоз ашлыкны коры килеш, сушилкаларда киптереп тапшырган булгач, Морат Баяновичка бәйләнү өчен сәбәп чыгып тора. Әнә бит акыллы кешеләр эшлисе эшләрен җиренә җиткереп эшләгәннәр, сез нәрсә, аларның намуслы эшен башкаларга үрнәк итеп куя алмый идегезмени?

Менә шунда ул теге чактагы киңәйтелгән бюро утырышын, Айтугановларның үз-үзләрен тотуларын, бигрәк тә кече Айтугановның райком секретаре булып райком секретарен санга сукмый сөйләшүен исенә төшерде. Йөрәгенең ачулы гайрәт белән дөпелди башлавын тойды. Алып ташларга кирәк ул мәгънәсез егетне председательлектән, белер ул аннары үзеннән олылар белән, райком белән ничек сөйләшергә икәнен...

Галинур Айтугановны урыныннан алу бик артык күзгә бәрелмәсен өчен, эшләре начар барган ике председательне урыныннан алырга булды Тимергалиев. Кадрлар сайлау — партия автономиясендә, әле бу язылмаган законның үзгәргәне юк, шунлыктан председательләрне булдыклырак иптәшләр белән алыштырырга райкомның тулы хакы бар. Моның отчет-сайлаулар вакытында үткәрелүе берәүдә дә шик тудырмас.

Шәрифулла Гайниев ике колхоздан ике председательне әллә ни мәшәкать күрмичә генә алыштырып кайтты. Моны колхозчылар үзләре теләделәр.

Ә менә Галинур Айтугановны алу мәсьәләсе белән ул принципиаль рәвештә килешмәде, шунлыктан бюро членнарының фикере икегә бүленде. Галинурны алдырырга теләүчеләр Тимергалиев ягында, алдырмаска теләүчеләр — Гайниев ягында торып калдылар. Күпчелек тавыш белән җиңеп булмады, бизмәннең ике тәлинкәсе дә тигез тарта иде.

Калган ягы ничегрәк бетәр, анысын җыелыш күрсәтергә тиеш иде.

Җыелышка Гайниев барырга теләмәгәч, Сәубановны җибәрергә булды беренче секретарь һәм аңа озаклап, иренмичә, үзен ничек тотарга икәнен өйрәтте.

— Иң мөһиме — сөйлисе килгәннәрнең сүзләрен әйттереп бетер, азактан ипләп, килешле итеп, Галинур Айтугановның эшләгән әйбәт эшләрен санап чык, әмма тормышларның үзгәрүен, үзгәртеп кору заманы килүен, Яңа көч» колхозын кызурак темплар белән алга алып бара алырдай яңа бер җитәкче кирәклеген төшендерергә онытма. Комсомол райкомында җиде ел эшләгән уттай җитез егетне бирәбез, диген.

Соңгы киңәшләрен, яшерен сер кебек итеп, шыпырт тавыш белән әйтте:

— Райком исеменнән вәгъдәне кызганма. Комбайннар, яңа автомобиль, комбикорма, төзү материаллары. Сине өйрәтәсе юк. Даут Кодратович, эшеңне җиренә җиткереп кайт. Миңа йорт салып биргәнеңнән ким булмасын.

— Аңлыйм мин, Морат Баянович. Тик без Айтугановларның мөмкинлекләрен киметеп карамыйбызмы икән? Алар ягында халык булуын истән чыгармыйбызмы? Сез әллә Фәһим Сабирҗанович бу эштән читтә калыр дип беләсезме? Мин совхозда эшләгән дәвердә, аның бер мәртәбә серен ачканы бар иде, улын ул үзе кырык ел буена җитәкләгән колхозда калдырырга, династия булдырырга тели бит.

— Соң шуннан? Калдырырга теләү әле ул калдыру дигән сүз түгел...

— Анысы шулай. Тик белеп торыгыз, өлкән Айтуганов никадәрле генә тыйнак кеше булса да, улының язмышына битараф карамаячак, ул аны яклап бөркет кебек ташланачак.

Сәубановның сүзе дөрескә чыкты.

Таулы Төбәккә гыйнвар азакларында өлкән Айтуганов үзе килде. Районның хуҗасы аны бик әллә ни якты чырай белән каршыламады: без синең улыңны урыныннан алабыз, дип елмаеп тормас бит инде... Ләкин ул аны кабул итми дә булдыра алмый, СССР Югары Советы депутатын кабул итмәскә аның хакы юк иде.

Сөйләшү кыска булды.

— Галинурны председательлектән алырга булгансыз, диләр, дөресме шул хәбәр?

— Дөрес,— диде Тимергалиев, бу сүзне әйткәч, аның иреннәре кысылды, зур соры күзләрендә тәвәккәллек очкыны көйри, кылган чәчләре маңгаена таралып төшкән иде. Чәчен кулы белән артка китәрергә тырышып та, китәрә алмагач, ул гамәленнән туктады, калку ия-

ген кулы белән учлап, Фәһим абзыйга төбәлде. Үз дигәнен итә торган җитәкче икәнен күрсәтергә теләп:

— Миңа яшь Айтуганов түгел, өлкән Айтуганов кирәк. Чукмарлы кешеләре усал, хәтта ки — явыз. Өйрәндем мин ул авылның тарихын, Галинурны да сынадым. Улыгыз юаш, Фәһим Сабирҗанович. Чамадан тыш ягымлы. Алай булмый. Чукмарлылар Галинурны гына түгел, аның әтисе Фәһим абзыйны да төпсез көймәгә утыртырлык кешеләр. Куйсам, мин анда тешләгән җиреннән өзә торган усал кешене куям.

— Ала-а-ааай...— диде өлкән Айтуганов сузып кына.— Ә Галинурга нинди рәк эш бирмәкче буласыз инде?..

— Кирәк микән аңа эш табу, Фәһим Сабирҗанович? Белеме бар, экономист дигән һөнәре бар, главное — яшьлеге бар. Миңа калса, аны теләсә кайда ике куллап каршы алырлар.

— Отчет-сайлауга кем бара, үзегезме?

— Күз күрер, бәлки үзем дә барырмын.

Райком секретаре торып басты, ул озын буйлы, нык карашлы, зур каты куллы иде. Кул кысышканда алар бер-берсен тагын бер мәртәбә сынадылар.

«Моның әле районда утын ватасы көннәре алда икән. Демократия дигәннәренә барып җиткәнче әле байтак көтәсе бар икән»,— дип уйлады Айтуганов саубуллашкан чакта.

Аның гомер юлы, сугыштан соң күргән михнәт-җәфалары күз алдына килде. Кирәк булдымы икән аңа, сугыштан яраланып кайткан унтугыз яшьлек солдатка «Сабанчы» колхозын үз өстенә алу? Кирәк булдымы икән аңа кырык ел буе шул чамасыз авыр йөкне тартып бару?

Тиздән аның үз отчеты. Хисапны бирергә дә, ышанганнары өчен халыкка рәхмәт әйтеп, лаеклы ялга китәргә кирәк.

Председательлек вазифасыннан бушатуны сораган гаризаны ул бүген үк кесәсенә салып барган иде. Әмма Тимергалиевнең шулчаклы да үз-үзенә ышанып, кискен итеп сөйләшүе аны гариза бирү кебек җитди гамәлдән туктатып калды.

Өйдә аны Сөембикә ханым көтә иде.

Энесе Фатыйх шалтыратты, хәл белеште.

— Эшләр уңай якка үзгәрмәдеме?— дип сорады.

— Үзгәрмәде. Секретарь бик каты тора. Сайлау нәтиҗәләрен көтик инде,— диде абый кеше, тыныч булырга тырышып.

Идарәгә бармады ул бүген.

Анда, әвене янган кеше кебек, йомыш белән килүчеләрнең ямьле көннәрен ямьсезләндереп утырырга теләмәде.

Тышта буран кузгалган.

Үр өстендәге терлекчеләр каласы күренми, Дәүрән үзәнендә дә кар бураны бөтерелә, юлларны көрт басар, улы Галинур кичен килеп тә чыга алмас әле, болай булса...

Ә ул аның килүен тели, аңа киңәшләрен бирәсе килә. Урыныннан төшергән чакта үзен ничегрәк тотарга — мескенләнмәскә, акланмаска, күп сөйләнмәскә өйрәтмәкче иде. Ул аның председательлектән китүе белән әченнән килешкән иде инде.

Тик менә шушы буранлы көндә, Дәүрән үзәнендә һәм үр өстендә җирне-күкне каплап алган кар буранын карап торган чакта аның янында райком секретаре Тимергалиевкә карата үпкә-рәнҗү күтәрелә башлады. Ярар, аның улы нәрсәнедер эшләп тә бетермәгән ди,— бәйләнергә теләсәң, азмы бәйләнерлек сәбәпләр председательгә!— Ләкин ул аның ихласлыгын, шушы эш өчен яратылганлыгын күрергә, үз канаты астына алырга тиеш иде. Ул, ахыр килеп, былтыр, яңгырлы елда, улы Галинур белән әтисе Фәһимнең киптергән, кондициясенә китереп җиткергән ашлык тапшыруларын райкомга каршы килү дип

түгел, киресенчә, ярдәм итү дип кабул кылырга тиеш иде.

Кышкы көн кыска, сәгать өчләрдә күз бәйләнә, бик тиз караңгы төшә. Өйдә ут кабынган. Галинурдан хәбәр юкмы икәнен Фатыйх икенче мәртәбә шалтыратып сорады, абыйсы бүген телефонга килми, шалтыратучылар белән Сөембикә ханым гына сөйләшә, сөйләшеп бетергәч, авыр итеп көрсенә иде.

Фәһим әле бик ягымлы һәм мөлаем булып йөргән хатыны Сөембикәнең бер көн эчендә кинәт олыгаеп, күз төбенә күгелҗем күләгәләр утыруын күрде.

«Ниткән таш бәгырьле кеше бу Тимергалиев, ниткән прокурорлык замашкалары аңарда? Ул бит, һич югы, минем хакыма, кырык ел буена колхоз камытын киеп, чамасыз авыр йөкне тарткан кеше хакына булса да, мин пенсиягә китканче Галинурга кагылмый торырга тиеш иде...»— дип күңелсез уйларын уйлады Айтуганов.

Кичке сигезләрдә Фатыйх үзе килде. Ул килгәч, бераз гына булса да күңеле тынычлана төште Фәһим абзыйның.

— Минемчә, Мамай курганында сугыш булачак. Көчләр зур, көчләр тигез, берәү дә бирешергә теләми. Минемчә, Чукмарлы халкы, чукмарын тотып, сугыш башлаучылардан үз председателен яклар,— дип көлдерергә теләде Фатыйх.— Күңеле аның изге, күңелендә аның ышаныч бик зур, чөнки ул Галинурны әтисе Фәһимнән күбрәк белә, егет тиктомалдан чоңгылга барып төшмәячәк.

Күңелендәге шушы уйларны әйткәч, абыйсы Фәһим:

— Тукта, мин бер акбашлыны чыгарыйм әле, йөрәкне яндырып утырмыйк әле,— диде.

— Юк, абый, сабыр итик, Галинурдан хәбәр килгәнне көтик инде, акбашлыга өлгерербез,— диде Фатыйх.

Энесенең кышкы җилләр кискән сау-сәламәт йөзенә, ут кебек кызыл җирән чәченең чигәләрендә күпереп торган бөдрәләренә һәм биек такыр маңгаена карап, күңеленнән рәхмәтле булды Фәһим абзый. Рәхмәтле булды — туганнар бит хәсрәт килгәндә, дуслар шатлык уртаклашканда кирәк.

Сәгать төнге уннар тирәсендә, Фатыйх инде кайтып китәргә, абыйлары йокларга җыенганда, ишектән зур толып кигән, өстен кар баскан берәү үзе артыннан олавы белән салкын ияртеп килеп керде.

Аны беренче булып күреп алган Сөембикә ханым:

— И улым, бәгърем, килдеңмени?!— дип Галинурга ташланды, аның толыбын салдырырга өтәләнә башлады.

Ишек янында купкан шау-шуга Фәһим абзый белән Фатыйх та килеп кушылгач, өй эче төрле тавыш, хәл-әхвәл сорашулар белән тулды.

— Туктагыз, минем шофер да бар бит әле. Ул машинада туңып утырмасын, алып керим әле мин аны,— дип Галинур, кулларын угалап, урамга ашыга башлады.

— Торып тор,— диде әтисе.— Нәрсә белән бетте эшең? Председательлектән алмадылармы?

— Алып җиткерә алмадылар бит, әти. Чукмарлы халкы мине бик хәтәр яклады. Уникe сәгать буена азапланды Сәубанов, халыкны ризалаштыра алмады. Кичке сигездә генә таралдык, бер атнадан Тимергалиев үзе киләчәк, анысы нәрсә белән бетәр, әйтүе кыен, әмма җиңү безнең якта бүген, әти.

— Ярар, бар алып кер шоферыңны, калганын табын янында сөйләшербез,— диде Фәһим абзый.— Кил, энем Фатыйх, утыр. Әнисе, Сөембикә, әзерлә табыныңны.

Төнге буранда исән-имин кайтып кергән улы Галинурга барысыннан да күбрәк Сөембикә ханым сөенгән иде. Көндездән күп итеп пешергән өчпочмакны, кәбестә бәлешләрен җылытып китерим дип җәтҗәт кухня арасында йөренә башлады, әле суынырга өлгермәгән доге

өйрәсен тирән эчле тәлинкәләр белән табынга чыгарып куйды. Сулышы кабар дәрәҗәдә ашыга иде ул — аш-су китереп йөргән арада улы Галинур бүгенге хәлләрне сөйли башлар да, иң кирәклесен ишетми калырмын, дип курка иде.

Тик аның ире — тумыштан ашыкмый торган сабыр холыклы Фәһиме — әңгәмәне куертып җибәрү ягында түгел иде әле. Башта ул табынга Галинурның шоферын — егерме биш яшьлек буйдак егет Шәкүрне китереп утыртты: аның руль тотасы бар, тамагы тук, йокысы туйган булырга тиеш.

Эчкәрге бүлмәдән, кулларын алъяпкычы астына яшереп, кыштыр-кыштыр сиксән ике яшьлек Гөлйөзем әби чыгып килә иде.

— Галинур бәбкәм, Галинур бәбкәм...— дип сөйләнә иде ул.

— Әйе, шулай, дөрес: Галинур бәбкәң кайтты, әни, аңа берни дә булмаган, ул бездә куна, иртәгә сөйләшерсең, яме, бик иркенләп сөйләшерсең,— дип Фәһим абзый әнисен җайлап-көйләп кире үз бүлмәсенә кертеп җибәрде. Аннары, урын җәеп, шофер Шәкүрне йокларга яткыздылар.

Тик шуннан соң гына өч ир-ат табынга утырдылар.

Өлкән Айтуганов шкафтан бер шешә аракы, өч стакан алып килде, тик шешәнең бөкесен ачарга ашыкмады, яшькелт төстәге кыска шешәне кулында тоткан хәлдә әйтте:

— Моны мин сез үпкәләмәсен дип чыгарам. Үземнең эчәргә исәбем юк. Бара торган юлыбызның бик текә бормасына килеп җиттек без. Әгәр сез уйлый белә торган кеше булсагыз... Мин моны, энем Фатыйх, сиңа да, улым Галинур, сиңа да әйтәм... Әгәр сез чыннан да уйлый һәм борчыла торган кеше булсагыз, бүген, шушы урында, төптөгәл бер фикергә килергә тиешсез: Айтугановлар өчен сынау сәгате сукты! Игенче Айтугановлар династиясе быел йә исән кала, йә бетә...

— Әйе, дөрес әйттең, абый: сөйләшәсе сүз зур. Син үзең эчмим дисең икән, эчмә. Галинурга йөз илле граммны сал. Аның ничә көн инде нервысын талкыйлар, без дә талкымыйк. Дөрес әйттемме, энем?

— Мин аракы эчәргә дип килмәдем килүен. Ләкин мин болай гына йоклап китә алырмын микән?

— Ярар,— диде өлкән Айтуганов, шешәнең бөкесен ачып, кырлы стаканга тутырып аракы салды, хатыны Сөембикәгә күз сирпеп алгач, стаканны улы Галинур алдына куйды, шешәне яба башлады.

— Йә инде, кыланма. Галинур бер ялгызы сезнең алда оялмыйча эчеп утырмас, үзегезгә дә сал!— диде Сөембикә ханым.

Өлкән Айтуганов шешәнең бөкесен кабат ачты, кырлы стаканны тутырып энесе Фатыйхка һәм үзенә салды.

Сүзсез генә күтәрделәр дә сүзсез генә эчтеләр. Суынып өлгергән дөге өйрәсенә иелделәр. Эш эшләп ямьсәгән кешеләрчә берәр тәлинкә ашны ялтыратып та куйдылар. Берәр чәшке кайнар чәй эчтеләр. Дөнья ямьлерәк булып китте.

— Йә, сөйлә,— диде Фәһим Айтуганов, улы Галинурга карап.

— Нәрсә сөйлим?

— Отчетыңны халык ничек кабул итте? Сәүбанов ничек?

Галинур, таза ак тешләрен балкытып, көлеп куйды:

— Бөтен хикмәт тә нәкъ шул отчеттан башланды инде, әти. Гадәттәгечә, бер сәгатьлек итеп түгел, ике сәгатьлек итеп яздым мин аны. Бер еллык эшемә түгел, сигез еллык эшебезгә хисап бирдем. Соңгы мәртәбә бит. Әйтер сүзне авыз тутырып, халык аңына барып җитәрлек итеп әйтергә кирәк иде. Докладның яртысын үзебез, ягъни идарә башкарган эшләрне барлауга, яртысын райкомны, бигрәк тә агропромны тәнкыйтьләүгә кордым.

— Менә анысы зерә. Нигә алай эшләдең? Үзеңә карата дошманлык артасын белеп торасың бит! Дипломат булырга дип мин сине күпме өйрәтәм, балакаем...

Галинур өчен Фатыйх җавап бирде:

— Энекәш дөрес эшләгән. Мин дә нәкъ шулай иткән булыр идем. Рас синә каныга райком, син аның алдында тәлинкә тотарга тиеш түгел! Үлсәң дә, егылсаң да! Борыныңны канатсаң да! Тәлинкә тоту — түбәнлек, коллык, мескенлек. Оборонаның иң дөресе — һөҗүм.

Кызып китә башлаган Фатыйхны абыйсы туктатты:

— Аңлашылды,— диде ул өзеп кенә.— Мәсьәләдән читкә китмик әле, Фатыйх.— Беләм мин сине, тиздән син яшелле-күкле тавышларга күчеп, түрәләрне сүгә башлыйсың. Ә бүген безгә булган хәлне белү кирәк. Дәвам ит, Галинур.

Галинурны туган-үскән йортына кайту, әти-әнисе һәм яраткан Фатыйх абыйсы янында булу тынычландырган һәм ул дөнья кайгыларын онытып җибәргән иде. Үзе белән булып узган хәлләргә ничектер читтән карап, башка берәү белән булган хәлне бәян иткән кебек гади итеп сөйләде:

— Докладның беренче яртысын тыныч кына тыңладылар. Шауламыйча. Ә менә икенче яртысында мәхшәр купты, әйткән бер сүзгә кул чабалар, «Бетсен агропром!»— дип кычкыралар.

— Ә Сәүбанов?— дип Сөембикә ханым да бу юлы сүзгә кушылды.— Сәүбанов нишләде? Үч алдымы синнән? Агропром бит аның өлкәсе.

— Теләге бар иде бугай үч алырга. Тик ул ашыкты — доклад бетүгә сүз алып ялгышты. Кирәк иде аңа иң әүвәл чыгышларны тыңларга, үз бизмәненә салып үлчәргә, әти әйтмешли. Барысын уйлап, үлчәп, сабыр гына итеп азактан йомгаклау сүзе белән чыкса, кем белә, бәлки, откан да булыр иде. Ә ул доклад бетүгә миңа ябырылды. Коммунист Айтуганов райкомга каршы бара, председатель Айтуганов колхоз коммунистларын партиягә каршы котырта. И китте, и китте, үз сүзләреннән үзе ярсып! Бераздан кайда басып торганын да белештермичә, онытылып китеп, трибунаны йодрыгы белән төя башлады.

— Чи надан икән!— дип нәтиҗә ясады Фатыйх.— Нәрсә ул Брежневлар, Сусловлар, Муратовлар заманы дип белгән мәллә?! Вәйт мөртәт!

— Сүгенмәскә,— диде Фәһим абзый, аның үзенең дә яңак сеңерләре тартыша башлаган иде.

— Ахыры ни белән бетте инде, улым?— диде Сөембикә ханым.

— Бик шәп бетте, әни. Сәүбановны, сөйләтеп бетермичә, трибунадан куып төшерделәр. Шуннан соң кая бара аласың? Халык сөйләгәнне тыңларга мәҗбүр булды Сәүбанов. Ә халык әйтсә, усал әйтә инде ул. Агропром ел саен бездән туксан-туксан мең тәңкә акчабызны талап ала, ни машинасын, ни төзелеш материалын вакытында бирми, агропромнан чыгабыз, аның беркемгә дә кирәге юк, диделәр. Беренче бригада шулай чыкты, икенче бригада, өченче... Карар кабул иттек — агропромнан чыгарга. Акчаны түләмәскә!

— Ай-һай!— дип гаҗәпләнде өлкән Айтуганов.— Каты тотынгансыз. Тирәнгә киткән эшләр. Болай булгач, Тимергалиев сине «Яңа көч»тә калдырмас инде, урыныңнан алдырганчы тырышыр.

— Тырышуын тырышыр, алдыра алыр микән? Беләсеңме, әти, фикер алышу алты сәгатькә сузылды, кырык ике кеше чыгып сөйләде. Утлар чәчелә клубта! Кузгалды халык. Рәнҗешен йөге белән китереп аударды клубта. Сәгать икедә көндезге ашка туктадык. Килерме төштән соң халык, юкмы, дим. Кая килмәгән! Басып торыр урын юк. Карыйм — төштән соң Гайниев килеп җиткән, Сәүбанов, күрәсең, райкомга шалтыраткан. Килде, ярар. Нишләр бу? Заманында биш ел минем белән парторг булып эшләгән кеше бит, райкомга күчкәч бозылмаганмы, дип уйлыйм. Юк, бозылмаган. Сәүбановның капма-каршысы. Җайлы шундый, сабыр, сүзләре йөрәккә ятышлы. Халыкны да екмый, мине дә. Белеп торам — райком аны задание белән җибәргән,

мине алдырып, башканы куярга. Ул, әлбәттә, шул мәсьәләне җыелышка чыгармый булдыра алмый. Чыгарды, ярсымады, иплəп әйтте, фикер тыңлады, тавышка куйды — икеме-өчме кеше каршы кул күтәрде, калганнары минем яклы.

— Тәки урнында калдыңмы, улым?— диде әнисе.

— Бер атнага, әни. Бер атнадан Тимергалиев үзе киләчәк.

— Ə нигә бер атнадан, нигә иртәгә түгел?

— Күрәсең, бер атна эчендә Тимергалиев нәрсәдер оештыра алуына ышана. Ярар, күрербез. Бер атна райкомга гына түгел, безгә дә бирелгән бит әле ул.

## Икенче бүлек

### 1

...Кышкы салкын иртәләрдә, авыл әле йокысыннан уянып та өлгермәгән бер вакытта, Фәһим абзый үзләренең кар баскан алма бакчаларына чыгарга ярата. Кышын умарталар саклый торган тәбәнәк өйне, су буе өянкеләрен күздән кичереп, үр ягына озак кына карап тора ул — аннан ишетеләчәк гөрелдене көтә. Гөрелде бар икән, димәк, авыл яши, авыл исән. Иртәнге гөрелде аның күңеленә тынычлык иңдерә, көне буена җитәрлек кәеф алып килә.

Дәүрән үзәненнән югарыда, җиләс җилләр искән үр өстендә, Терлекчеләр каласы яши. Сигез йөз дә туксан җиде баш савым сыер, өч йөздән артык тана, бозаулар. Савымчы җиңгиләрне, таңнарда кияү кадерен белеп кенә назланырга тиешле яшь киленчәкләрне, элеграк кенә мәктәп тәмамлаган кыз-кыркынны колхоз автобусы, Дәүрән үзәне буйлап сузылган ике чакрымлы Балдамар авылының һәрбер йортыннан диярлек берәм-берәм җыеп, Терлекчеләр каласына китереп куя. Терлекчеләр каласының үз тәртибе — ул аерым бер дәүләт кебек. Аңа көн дә саен салам төялгән, печән төялгән йөкләр килә. Үзләре зур бер завод чаклы цехларда терлекләргә азык әзерләнә. Җылы пар бөркеп торган тирес тораклар артына чыгарыла, эскертләп өелә. Көн дә саен сөт цистерналары Таулы Төбәккә иртән һәм кичен сөт алып китәләр. Терлекчеләр каласының Күчәртауда, Акчуртанда, Каңгырашта — «Сабанчы» колхозына караган бәләкәйрәк авылларда — филиаллары бар. Алар Терлекчеләр каласының үзәктәге тормышыннан үзгәрәк, борынгырак тормыш белән яшиләр: анда ферма каралтыларына саламны машиналар китерми, атлы олаулар ташый, мал-туарга кирәкле җылымса су да тагаракларга автомат җайланмалар ярдәмендә китерелми, колонкалардан алына. Боларның барысын да белә председатель Айтуганов, күреп йөри: бәләкәй авылларда акчаны Балдамар терлекчеләренә караганда тир түгебрәк, азап беләнрәк табалар, тик берәү дә зарланмый, туган-үскән авылын ташлап, колхозның үзәк утарына күчәргә җыенмый. Бу хәл сәер тоела Айтугановка, бик сәер. Зур авылларда тормыш җайлырак бит. Торгынлык дәвере дип яманаты чыккан җитмешенче елларда, күмәк шаукымга ияреп, Фәһим Айтуганов бәләкәй (перспективасыз!) авылларны Балдамарга күчереп куярга ымсынып караган иде, башбаштаклык булмасын өчен идарәнең карарын да чыгартып алып килгән иде. Кая ул! Бәләкәй авылларның таякка таянган картлары, бөкрәеп беткән карчыклары, аларга ияреп, ир уртасы абзыйлары аяк терәп карыштылар да калдылар. Бушлайга, колхоз исәбенә өр-яңа, алты почмаклы, шыңгырдап торган нарат бүрәнәле йортлар салып бирәбез, колхоздан акчалата ярдәм итәбез, ул гына җитмәсә, күченү чыгымнарын колхоздан түләтербез,

дип тә кызыктырып карады Фәһим абзый.

— Юк!— диделәр кече авыл кешеләре.— Бу җиргә безнең кендек каныбыз тамган. Бу зиратларда безнең ата-бабаларыбыз, туганнарыбыз ята. Без аларны ташлап китмибез. Алар безгә рәнҗеп калачак. Әгәр инде көчләп күчерергә ният кылып килгәнсең икән, туп-туры әйт, персидәтел, ул чагында без калага китәбез. И белеп тор, ахыры хәерле булмаячак: кече авыллар күченә башладымы, олы авыллар да калага таба юл тотмас дип кем әйтә ала?! Мисаллар күп, мисаллар үкенечле!

Нишләргә? Кече авылларны ничек ризалаштырырга?

Айтуганов, идарә белән киңәшеп, кече авылларга кибет салдыртты — тоз-шырпыга, сабын-мазарга биш-алты чакрымга йөреп интекмәсеннәр; кино карар өчен биналар әмәлләтте, шунда ук телевизорын да кайтарып куйды, симертелергә дигән мал-туарны кече авылларга күчерде.

«Куллары буш булмаса, күңелләре юкка алгысымас»,— дип фикер йөртте Айтуганов. Озак та тормый, кылган гамәленең дөрес икәнен үз күзе белән күрде. Эшкә җаптәшлек дисеңме, тәртипне әйтәсеңме — кече авыллар олыларына үрнәк була башлады. Авыллар төзекләнде, зиратларның коймасы тотылган, урамнары — яшел, чишмәләре улаклы, чылтырап агып тора! Шәһәрдән кайткан егет-кызлар, чишмә суларына, болын тугайларына, авылдагы шундый тиз үзгәрешкә аптырап йөриләр. Шуның өстәвенә Айтугановның күңеленә хуш килгән тагын бер хәл булды: Күчәртауда, Акчуртанда, Каңгыраушта йорт салу һөнәренә бик тиз төшенеп алдылар: балта осталары, ташчылар, түбә ябучылар, рам ясаучылар, тагын әллә ниткән затлы һөнәр ияләре үсеп чыкты. Һәммә нәрсәкәйне тотып-тикшереп, үз бизмәненә салып үлчәп карарга гадәтләнгән Фәһим абзыйга шул гына кирәк тә иде. Ничәмә еллар күңелендә хыял асрый иде ул — «Сабанчы»да Терлекчеләр каласы булдырырга!

Моның сәбәпләре бик тә нигезле, җитди иде.

Фәһим Айтугановны председатель итеп 1944 елны сайладылар. Унтугыз яшендә иде. Фронттан яраланып кайткан иде. Менә шуннан бирле инде күпме вакыт узган. Ул һаман председатель, аның һаман бер нәрсәгә эче поша. Үзе колхозны җитәкләгән дәвердә нiләр генә күрмәде ул, нинди генә куркынычлар янамады аңа, әмма ул шул дәвердә колхоз авылында хатын-кызлардан да күбрәк җәфа чиккән, кимсетелгән затны күрмәде. Бәләкәй һәм караңгы фермаларда еллар буена, билләре сызлый башлаганчы саз ера алар, гомер буе резин итек киеп йөргәнлектән, дөньясын каргый-каргый яшиләр дә теге дөньяга китеп баралар. Аз гына җаны бар кеше савымчыларны, бозау караучыларны, мал-туар симертүчеләрне резин итек киеп, саз ерып йөрүдән коткарырга тиеш! Моның өчен нәрсә кирәк? Автомат җайланмаларга корылган фермалар. Терлекчеләр каласы. Комплекс! Бер мең баш сыер асрап була торган уңайлы, заманча салынган торак. Яше алтмышка таба барганда әнә шул гигант каралтыны салдырып чыгарга ниятләнде Фәһим абзый. Озакламый аның пенсия яше җитә. Зирәк акыллы бер адәм әйткән: «Ишек ачыла да ябыла. Вакытында ачып керә белгәнсең икән, вакыты җиткәч, ябып чыгып китә дә бел!» Соңгы елларда шушы акыллы сүз аның күңеленнән китми. Комплексны салып бетергән көннәрен күз алдына китерә Айтуганов. Әлеге гигант торакның капкаларын киң итеп ачып, хәтта ки каерып ачып куяр да бөтен гомерен багышлаган колхоз кәнсәләренең ишекләрен ябып чыгып китәр. Лаеклы ялга! Ул чагында инде бер генә савымчы да үпкәләмәс. Тәки сүзендә торды бит, вәгъдәсен үтәде бит Айтуганов, диярләр. Терлекчеләр каласында сыерларны электр белән саварлар, сөт торбалар буйлап агып, цистерналарга җыелыр, бер генә хатын-кыз да сөтне чиләк

белән ташып интекмәс. Күз явыңны алырдай чытыр ак халат кигән киленнәр, кызлар, эшкә барган-кайткан саен, күңелләреннән Фәһим абзыйга рәхмәт укырлар...

— Тукта, туган, бик өметләнмә!— дип әйтте ди дөньяның акыллы диванасы Хуҗа Насретдин.

Проект эзләп Казан каласына килде Айтуганов, институтка. Аңа күз дә йоммый әйттеләр: ике елдан килегез, чиратка куярбыз, хәзергә без баш түбәсеннән заказга күмелгән! Фәһим абзаң баш түбәсен кашып торды: ай-һай-һай! Димәк, ике елдан? Бары тик ике елдан гына?! Монысы бит әле чиратка язылу гына. Ә проект? Айтугановның төшләренә кереп йөдәткән комплексның проекты кайчан өлгерәчәк? Анысына тагын ике ел вакыт кирәкме? Юу-уук, болай булмый, җәмәгать. Таулы Төбәккә сугылып, район түрәләренең кылын тартып карарга кирәк. Әгәр проект әзер булса, төзелеш идарәләре Балдамарга кайчан килеп, кайчан комплексны сала башлар?

Айтуганов ул көнне авылга сөмсере коелып кайтты.

Сөембикә ханым, укытучы-педагогларга хас сабырлык белән ирен күзәтеп, табын әзерләде, аның нигә борчулы икәнен сораштырып-нитеп тормастан, каршысына килеп утырды.

Башка чакта бер тәлинкә пилмәнне ялтыратып кына куя торган ире бу юлы тәлинкәне этеп кенә куйды.

— Ни булды, этисе?— диде Сөембикә ханым борчылып.

— Хыяллар җимерелде әле. Чиновникларның таш маңгаена бәрелеп чәлпәрәмә килде, сыер абзарын салырга биш елдан да алдарак керешмәячәкләр.

— Комплексны әйтәсеңме?

— Шул инде. Төшләргә кереп йөдәтә бит.

— Нигә шул тамаша үз-үзеңне ватасың? Эшләмәдең түгел, эшләдең бит инде. Калганын, бәлкем, башкалар эшләр...

— Алай түгел ул, Сөембикә. Пенсиягә хәтле ул эшне эшләп бетереп, комплексны тапшырып китәрмен дигән идем. Тыныч күңел белән...

Беркавым икесе дә тын гына утырдылар. Һәркайсы үзенчә исәп тота, килеп туган мәшәкатьтән ничек чыгу юлын эзли иде.

Сөембикә Җантаһирова заманында пединститут тәмамлаган иде. Фәһимгә кияүгә чыгып, Айтугановлар фамилиясен алгач һәм Балдамар урта мәктәбендә балалар укыта башлагач, директор аңа математика укытуны тапшырды. Яшь укытучы математиканы яхшы белүе белән мәктәптә генә түгел, авылда да танылды. Кызлары Фаягөл дә, әниләре юлыннан китеп, физика-математика факультетын тәмамлады һәм Балдамарга математика укытырга кайтып урнашты. Болар сөендерә иде Фәһимне: исәп-хисапны биш бармагы кебек белгән ике кеше — гомер юлдашы Сөембикә һәм кызы Фаягөл колхоз башлыгына, ягъни председатель агайга, кирәк чагында әллә ниткән четерекле мәсьәләләрне чишеп, аның эшенә җиңеллек китерәләр иде.

Бүген беркавым уйга калып утыргач, Сөембикә ханым, ире өстенә нинди борчу килгәнне аңлап, гадәтенчә, җайлы-ипле генә итеп әйтте:

— И этисе! Без синең белән мондый гына мәсьәләләрне чиштекмени? Беләсеңме, синең өчен хәзер бердәнбер дөрес юл нәрсә? Югарыдан ярдәм көтеп ятмау. Колхозның үз белгечләрен эшкә җигү. Бик ныклап! Тик бер ягы бар...

— Нинди ягы?

— Мәсьәләне идарә утырышына чыгарганчы туганнарың белән киңәш-табыш итеп алу кирәк түгелме икән?

— Кем белән?

— Минемчә, иң кулае — Фатыйх.
— Чыннан да, карале, идея бу!
— Ләкин син Фатыйхны кәнсәләргә, кәҗүнни сүз сөйләшергә чакырма.
— Кая чакырыйм?
— Үзебезгә чакыр. Кунакка. Бүген үк. Ярты-мазар кирәк булырмы?
— Кирәкми. Дәүләт эшен дәүләтчә хәл итәргә кирәк. Аек баштан.
Фәһим шундук энесенә шалтыратты.
Ярты сәгать уздымы икән, Фатыйх килеп тә җитте.
Айтугановларның берсенә дә охшамаган Фатыйх. Тегеләр һәммәсе кара, бу — җирән. Җемелдәп торган бакыр чәч, елмаюдан бушамый торган җәенке ирennәр, битен сипкел баскан. Гәүдәгә уртача гына булса да, төп кебек таза, бодай капчыгы кебек тыгыз тәнле. Шаянлык-тапкырлыкның чамасы юк.
Фатыйх йортка бу юлы да гадәтенчә, балкып килеп керде:
— Бирәхмәтикә ярхәм икәлла! Исән-сау гына торасызмы? Бала-чагаларыгыз, карчык-корчыкларыгыз һәммәкәйсе дә сау-сәламәтме? Мәйтәм, председатель агаем юкка-барга, урык-сурыкка чакыра торган кеше түгел, моның акыллы башында, мин әйтәм, затлы бер фикер тугандыр, шул затлы фикерен ул үзенең сүз тыңлаучан энесе Фатыйх белән ирләрчә икәүдән-икәү генә бизмән тәлинкәсендә үлчәп карарга ният кыладыр...
Фәһим абзый энесенең сау-сәламәт йөзенә, таза нык муенын ачып җибәргән аппак күлмәгенә, чаткыланып кабынган коңгырт күзләренә карап алып, үзенә хас тыенкы елмаюы белән, сабыр гына әйтте:
— Әйе, энекәш, дөрес сизенәсең. Синеңчә әйтсәк, фикер кузгалды. Зур фикер. Четерекле бер эшкә тотыныр алдыннан синең белән киңәшеп алуны кирәк таптым. Әйдә, сал бу туныңны, кил табын янына, пилмән белән сыйлыйм үзеңне.
— Мин, абый, пилмән ашап тормам, табын яныннан гына кузгалдым,— дип Фатыйх мәтрүшкәле чәйгә үрелде.— Тыңлап карыйк, председатель агаемны нәрсәләр борчый икән?
Фәһим абзый Казанда, проектчылар институтында булуын, аннары Таулы Төбәк райкомында сөйләшүен энесенә ике-өч сүз белән генә әйтеп бирде. Аннары:
— Йә, нишлибез, Фатыйх?— диде.
— Башта хуҗаны тыңлап карыйк,— диде Фатыйх.— Аннары үз фикеребезне әйтербез.

Фәһим абзый энесенә текәлеп карап торды. Әтиләре Сабирҗан гүр иясе булганда җиде яшендә калган иде бу малай. Вакыты җиткәч, ул минем арка таянычым булыр дип башына да китермәгән иде Фәһим. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң Фатыйх Казанга китте. Авыл хуҗалыгы институтына укырга керде. Аңа кадәр дә китүчеләр бар иде,— авылга кайтмадылар. Фатыйх Балдамарга кайтып төпләнде. Фәһимнең күңеле канат какты. Аның гомерлек теләге — туганнарын, балаларын авылда калдыру иде. Ләкин ул чагында колхоз башлыгының күңелендә бер шик тә посып тора иде: ник ул нәкъ менә «Сабанчы»га агроном булып кайтты? Ник бүтән берәр колхозга түгел? Халык бик усалланды: Айтуганов туган-тумачалык белән шөгыльләнә, дип кырын карый башласалар? Районга җиткерсәләр? Әллә Фәһимнең сак кеше булуы, туганнарын башкалар белән тигез күрүе, кирәкмәгәнне эшләп, кешеләр күзенә кылчык булып кадалмавы ярдәм итте. Фатыйхның «Сабанчы» колхозында агроном булуын берәү дә күпсенмәде. Алай гына да түгел, дуртме-

бишме елдан аны баш агроном итеп кую мәсьәләсен күтәрделәр. Менә шунда башны кашырга туры килде председательгә. Китте бу районга, хәлләрне бәйнә-бәйнә сөйләп, нишлим дип киңәш сорады. Райбашкармада да, райкомда да Фәһим Айтугановның уйламый эш итми торган кеше икәнен белгәнгә, гади генә хәл иттеләр: үзеңә кара, син җавап бирәсе.

Революция чыкканнан бирле рәнҗетелгән, бил сынганчы эшләп тә тамагы ипигә туймаган, эшләгәнен тулаем илгә биреп, үзе бакча бәрәңгесе бәрабәренә җан асраган крестьян агай үзен крепостное право заманнарындагы кебек хис итә, аның бернинди хокукы юк, ул авылдан китә алмый,— аңа паспорт та бирмиләр, аны кешегә дә санамыйлар иде. Шулай булгач, табигый: җылы сүзгә, гаделлеккә, әйбәт мөгамәләгә мохтаҗ иде авыл кешесе! Фәһим Айтуганов күреп, белеп торды: энесе Фатыйхта — акыл бер кибән, җылы сүз — бер олау, көлке-мәзәк дисәң — җиде авылга җитәрлек. Табигать бит ул — хикмәтле нәрсәкәй, берәүгә булдыклылыкны йөге-йөге белән бирә, икенче берәүдән гап-гади ягымлылыкны да кызгана. Фатыйх бик яшьли ятим үскәнгәдер, җылы сүзен берәүдән дә кызганмады. Кешеләрне ул тигез күрә, якын итә, кызгана белә иде. Эшләгәне дә күз алдында: алтмыш бишенче елның Март пленумында бирелгән хокуклардан файдаланып, Фатыйх Айтуганов басуларга ашлама кертә башлады. Чамалап. Җаен белеп кенә. Орлыкны калибрлау, тирәнгә чәчү техникасын үзләштерде. Бәрәңгенең мул уңыш бирә торган «Лорх» дигән сортын гына үстерүгә юл тотты. Ул сортта башка төр бәрәңгеләргә караганда крахмал бермә-бер артык, димәк, ул сыерларның сөтен дә арттырачак, сугымга симертә торган малны да көрәйтәчәк.

Бертуган энесенең үз-үзен тотышы да, эш-гамәлләре дә Фәһимне канәгатьләндерде. Белеп эшли, яратып! Ун ел эчендә иген уңышы сигез центнердан унтугызга сикерде. Район буенча уникедән артмаган чагында «19» рекорд саны һәм ул «Сабанчы»ны алгы сафка китереп чыгарды.

Эшләгән өчен акчаны чагыштырмача мул түли башлагач, председатель Фәһимнең җанына җылы керде: гаделлек заманы килә бугай. Моннан файдалана белү кирәк. Бик кирәк! Авыл кешесенең йоклап яткан аңы уянсын. Ләкин гомер буе йокларга дучар ителгән аңны аерым җитәкчеләр генә уята аламы? Белгечләр кирәк — сине аңлардай, сине екмастай, сиңа таяныч булырдайлары. Төп белгечләр, тармак җитәкчеләре. Менә аларның берсе өлгерде — баш агроном Фатыйх Айтуганов. Аклады Фатыйх ышанычны. Абыйсына тап төшермәс өчен ул хәтта үзенә тиешле өстенлекләрдән дә баш тарта белде. Балдамар кешеләре дә, «Сабанчы»га караган башка зуррак авыллар да каралты-кураны, йорт-җирне мулдан өлгертергә тотындылар. Фатыйх та, алар белән бергә, яшьләр урамына күчә ала иде. Йортны кара-каршы, алты почмаклы итеп, капка-коймаларын бизәкләп, нәкышлап эшли ала иде, аңа гына хыялы да, булдыклылыгы да җитә иде аның, юк — яңа урамга күчмәде Фатыйх, төп йортта торып калды. Саклап калды төп нигезне. Сабирҗан нигезе аңар кадерлерәк булды. Айтугановлар исеменә тап төшермәде Фатыйх. Инде менә шул хәлләрдән соң аның белән ничек киңәшмисең дә, ничек аңардан акыл сорамыйсың ди?!

Абыйсы Фәһимнең озак кына уйга калып, аңа төбәлеп утыруын күргән Фатыйх баягы соравын кабатларга мәҗбүр булды:

— Комплекс салуга карата хуҗаның фикере ничек соң, дигән идем мин, абый?

— Фикерем минем, Фатыйх, бер генә: комплексны салырга кирәк. Ләкин ничек салырга? Хикмәт — менә кайда. Берәү дә безгә

булышырга теләми: проектчылар да, райком белән райбашкарма да. Нишлибез?

— Минемчә, абый, менә нишләргә кирәк. Илдә йөри торган барлык типовой проектларны җыярга. Бер булдымы? Аларны чагыштырып карап, үзебезгә уңайлысын сайлап алырга. Ике булдымы? Сайлап кына калмаска, безнең шартларга яраклы итеп төзәтергә, өстәргә, киметергә,— гел үзебезчә итәргә, һәммәкәй төзәтү, камилләштерү — терлекчеләрне истә тотып эшләнгән булырга тиеш. Комплексны без үз гомеребездә бер салабыз. Салгач-салгач берәгәйле итеп салырга кирәк.

— Төзүчеләр каян алабыз?

— Ә бездә кырык кешелек төзүчеләр бригадасы ник яши соң?

— Әйттең сүз! Алар бура бурый белә, кирпеч стена өя, урыс капка, ак мунча ясый. Бу бит — гигант корылма! Ким дигәндә ике миллион сум торырлык. Монда бит тимер-бетон каркаслар, атланмалар, түбә аслары... Безнең ише авыл мокыты күргән каралтымыни бу?!

— И абыкаем, син бит аны чертежларда күреп әйтәсең. Син ул гигант корылманы кисәкләргә бүлеп кара. Иң элек түбәсен ал. Шифер булачакмы ул, күгәрми торган калаймы? Ничә кеше безнең бригадада шифер түбә яба белүче? Бишәүме? Хуп! Инде шулар янына ярдәмче бишне өстик, ди — калай түбә яба торганнарын. Димәк, унау була. Нәрсә, без аңа кеше таба алмыйбызмы?

Өлкән Айтугановның хыяллары уйнап китсен өчен шунысы да җиткән иде. Тимер-бетон блокларны ялгый белүчеләрне дә, балкалардан һәм кирпечтән фундамент салучыларны да табабыз. Балта осталары турында сүз дә куертып торырга кирәкми. Алар Кучәртауда, Каңгыраштa, Акчуртанда буа буарлык. Бүген сызгыр — әртилләре белән киләчәкләр. Чистайданмы, Түбән Камаданмы, әллә Чаллыдан укмы төзүче бер инженер алып кайтсак, типовой проектыңны гына түгел, әллә нәрсәләреңне аңлатып бирер. Яңа суйган ит, бал-май, сөт ише ризыклар теләсә кемне кызыктыра. Читтән китерелгән инженер ярдәмендә төзүчеләр бригадасы өчен берәр айлык курслар да ачып җибәрербез, зиһенлерәк яшьләрне катлаулы конфигурацияләр белән эш итәргә өйрәтербез...

Яз борын төбендә иде — баш агроном үз эшенә, чәчү орлыгы саклана торган амбарларга, аннан ашлама чыгарыла торган басукырларга юнәлде — ашламаның бер генә мыскалын да әрәм итмәскә, су белән юдырып, инешләргә төшермәскә, басуларга саклап калырга кирәк. Контроль, туганкаем, контроль!

Кырларда язның әрсез кояшы астында йөри торгач, Фатыйхның сипкелләре ясмак-ясмак булып тибеп чыктылар, борыны кубалакланды, коңгырт күзләре елтырый, күз тирәләрендә җилпәзә җыерчыклар нурлана иде. Ул язгы чәчү үткәреләчәк мәйданнардан әйләнеп кайтып, абыйсы белән икенче мәртәбә очрашкан чакта, председатель Фәһим Айтуганов, көне-төне китапханәдә ятып, егермедән артык китап укып чыккан, кирпеч, цемент, калай, шифер кебек төзү материалларының хасиятен өйрәнгән иде. Материал бар, шөкер, төзүчеләр дә кул астында. Ә менә Чаллыдан килгән инженер белән типовой проектларны чагыштырып, чаманы чамага китерү мәшәкатьле булып чыкты. Иң әүвәл проекттагы койма белән килешмәделәр. Тимер-бетон рәшәткә куярга куша проект. Ә андый рәшәткәләр берәр елдан ватыла, тимер чыбыклары гына тырпаеп кала. Койманы кирпеч баганалардан коеп, калын агач рәшәткәле итеп ясарга, койма буендагы яшь агачларны эчке якка түгел, урам якка утыртырга кирәк. Койма буендагы агачлар,— әгәр эчке якта булсалар — комплекс салуга киткән биш ел вакыт эчендә тапталып, сынып, кырылып бетәчәкләр. Утыртмый торырга да була, әлбәттә,

эмма утыртмаган сурәттә алар үсмәячәк. Агачларны койманың тышкы ягына утыртып чыксаң һәм моны беренче эш итеп башкарсаң, терлекчеләр каласы аякка басканда койман да, койманың тышкы ягындагы агачлар да күзгә күренеп, ямь-яшел булып утырачаклар. Фәһимнең моңа гына башы җитте. Бригадада, төзү эшләре белән җитәкчелек итүче Нури Батыркаев та моны хупладылар. Ләкин моның өчен проектта утыз мең сумнан артыграк өстәмә чыгым тотарга кирәк булды. Тотты председатель, өстәмә чыгым документларына ике дә уйламый кул куйды. Проектта терлекчеләр өчен бер генә уңайлылык та каралмаган,— күрәсең, проект авторлары савымчыларның да, башка терлекләрнең дә хәлен бөтенләй белмиләр, мөгаен, күңел өчен генә булса да колхоз фермаларына килеп карамаганнар. Ә Министрлар Советында, үзәктә шуны раслап, кулланышка чыгарганнар. Комплекс мәйданында асфальт юллар аз, дамбалар тәбәнәк, арзан итеп сметага салынган. Димәк, савымчы кызлар тагын, әүвәлгечә үк, су ерып, язын-көзен резин итекләрдән интегергә мәҗбүр булачаклар. Ә нигә алайса, зурдан кубып, Терлекчеләр каласы дип авыз суыңны корытырга?!

Асфальтка акча кызганмадылар. Юлларны озайттылар, биегәйттеләр, киңәйттеләр, гадәти асфальттан бетон юллар итеп үзгәрттеләр. Бу хәл үзе генә дә проектның кыйммәтен ике йөз илле мең сумга арттырды. Моңарчы яшәп килгән закон проектта каралганнан бер генә тиен дә артык тотмаска боерса да, терлекчеләрнең сәламәтлеге хакына, артыгын тотты Айтуганов. Бу хакта инженер Нури Батыркаев, болай рөхсәт итмәсләр бит, җавап бирергә туры килер бит, дип өзлексез колагына тукып торса да, үз дигәнен эшләде. Проектта терлекчеләр өчен ял бүлмәсе дә, ашханә дә, аптека да юк; җыелып сөйләшү, киңәш-табыш итү өчен аерым бүлмә дә каралмаган, душ бүлмәсе дә юк, мунча турында инде авыз ачып сөйләп торасы да түгел; савылган сөтне чиләкләп ташуны күз алдында тота проектчылар — сөт үткәргечләр, лабораторияләр, зоотехник, ветеринар кабинетлары авторларның күңелләренә дә килмәгән. Проектка барысын да керттерде Фәһим абзый. Барысын бергә исәпләп карагач, 400 мең сумнан артык өстәмә тотым кирәк булып чыкты. Эшне үз вакытында, югары сыйфатлы итеп башкарган өчен бирелеп барган бүләкләр, өстәмә түләүләр дә кушылгач, проектта каралганнан артык тотым 550 мең сумга җыелды.

Менә кайчан конфликтлы хәлгә килеп эләкте председатель. Проект сметасын бозганы, башбаштаклык күрсәткәне өчен, «Сабанчы» колхоз председателе Фәһим Айтугановка 5 мең, ә колхозга 55 мең сум штраф китереп салдылар.

## 2

...Фәһим Айтуганов штраф мәсьәләсен ачыклар өчен шундук Казанга чыгып чапмады. Мәскәүдә гаделлек табачагына ышанып ятудан гына түгел иде бу. Түрәләр барысы да бер чыбыктан сөрелгән. Казанныкы ни, Мәскәүнеке ни — алар үзләренә җайлы якны каералар. Аларның берсенә дә ышанмый Айтуганов, хәтта ки хәзер дә — илгә үзгәрешләр килгән, кысрыклаулар бетеп барган заманда да. Һич! Аның Казанга яки Мәскәүгә китмәвенең сәбәбе бар. Нәкъ шул кисәтү хаты алган көннәрдә аның председательлек вазифасы белән бәйле зур гына бер мәшәкать чыгып куйды. Терлекчелек комплексына баш ветеринар куярга кирәк иде. Моннан ике ел элек ветеринария институтын тәмамлап, «Сабанчы» колхозына эшкә билгеләнгән Максуд Каюмовны шушы эшкә кулай булыр дип исәпли иде

председатель. Егет төпле. Күп сөйләшми, ишеткәнен чәчми. Эшкә җаптәшлеген дә, савымчы кызларга, терлекчеләргә ягымлы булуын да яратып сөйлиләр. Балдамарда аның авыру әнисе, урта мәктәпне тәмамларга торган сеңлесе бар — шулар хакына Каюмов Балдамарга кайтты. Югыйсә аны институтта калырга, аспирантурага укырга да чакырган булганнар. Әнисе күзен йомса, сеңлесен урта мәктәптән соң үзе теләгән институтына урнаштырып куйса, кала ягына китеп баруы да ихтимал бит әле аның. Институт галимнәре белән хат алышып торуын да белә аның Фәһим абзый, белә, тик менә «Сабанчы»дан һич кенә дә җибәрергә теләми иде. Авылдан читкә китүчеләргә карата Фәһим Айтугановның үз принцибы бар: галим булырга, язучы яки артист булырга омтылганнарны ул тотмый, аларга ак юл тели, чөнки алар авыл өчен яратылмаган, аларны авылда аркан белән дә бәйләп асрый алмыйсың. Була авыл өчен яратылганнар: баштарак алар, аны белмичә, шәһәргә китеп баралар, заводка урнашалар, башлы-күзле, балалы-чагалы булалар, ә бераздан өзелеп-өзелеп авылны сагына башлыйлар, җаннары әрнеп, моңаеп, гармунчылар белән бергә җырлап йөриләр, бәйрәм мәҗлесләрендә нечкәреп китеп, үкенүләрен әйтеп елап та җибәрәләр — тик инде кайта алмыйлар, алмыйлар, каһәр суккыры! Койрыклары бозга каткан: улы мәктәптә, кызы ясле дә, хатыны җайлы гына эшкә урнашкан, өстәвенә, ул әле кала кызы, авылны бар дип тә белми, авылга кайткан чакларда да тизрәк шәһәргә таю ягын карый. Башлана күңелсезлекләр. Хатыны — калага, ире салага тарта. Менә шундыйларны кулдан ычкындырмаска, менә шундый җирси белүчеләрне тотып калырга кирәк. Максуд Каюмовны председатель әнә шундый авыл җанлы кешеләрдән саный. Авылның тармак җитәкчеләре «Москвич»та яки мотоциклда чапкан чакта да Максуд һаман атка утырып йөрер. Үзе хуҗалык кибетләреннән эзләп алган ат дирбияләрен ул тәңкәләр белән бизәп чыкты. «Сабанчы»ның ат җене кагылган «главный конюхы» Сөләйман карт белән дуслашып, җәй өчен тарантас, кыш өчен кашевой чана булдырды. Колхозның йөз илле баш аты арасыннан үзе сайлап алган өч яшьлек кырыкмышны чанага җигәргә һәм атланып йөрергә өйрәтте.

Ничек беркетергә Максуд Каюмовны Балдамарга? Нинди җепләр белән бәйләп куярга? Әлбәттә, аның иң ышанычлы юлы — Максудның кара бөдрә чәчләрен берәр савымчы кызның озын толымнары белән бәйләп кую. Тик Максуд дәрәҗәсендә торырлык, аның уйтойгыларын аңларлык, аның белән гомер кичерерлек савымчысы бармы соң? Ни хәл итмәк кирәк, җай чыкканны көтәргә туры килә.

Ә җай чыга ул, чыкмый калмый.

Көннәрдән бер көнне идарә йорты алдына Максудның тәрәкле матур чанага җигелгән чаптар кырыкмышы килеп туктады. Чанадан өстенә аксыл каракүл якалы пальто, башына аксыл каракүл бүрек кигән егет җиңел генә сикереп төште дә, атны дилбегәсеннән койма баганасына бәйләп, идарә йортына юнәлде.

Йомыш белән килүчеләрне Фәһим абзый, председатель урындыгында утырган хәлендә, бик артык җәелеп китмичә генә каршылый иде. Бу юлы Максудны аяк өсте каршылады:

— Рәхим итегез, Максуд. Ни йомышлар?

— Миңа, Фәһим абый, төзү материаллары кирәк буласы иде.

— Әллә тагын берәр кечерәк авылга бозаулар каралтысы салырга йөрисезме?

— Юк, Фәһим абый, ферма каралтылары хәзергә җитеп торыр. Үземә кирәк иде төзү материалы. Бер мәлне сез миңа, тартынып тормагыз, йомышыгыз чыкса, туп-туры үземә керегез, диган идегез. Онытмагансыздыр бит?..

Айтугановның күңеленә матур уй йөгерде:
— Әллә, Максуд, авылда төпләнеп калыргамы исәбегез?
Озын буйлы, тыныч-сабыр чырайлы, яңа матур пальтодан, ачык изүе аша кызыл түштәге махер шарфы күренеп торган егет, башыннан каракүл бүреген салып, аны кулында әвәли-әвәли, бер кавым сүзсез торгач:
— Пожалуй, калырмындыр, Фәһим абый. Ияләндем. Безнең Балдамар — матур авыл бит,— диде.
Бердән, Максудның шул ягымлы сүзне, председатель күптән ишетергә теләгән, хәттаки зарыгып көткән сүзне колхоз идарәсенә килеп, үз теле белән әйтеп бирүе Фәһим абзаңның йөрәгенә сары май булып ятса, икенчедән, Балдамарга карата җылы сүз әйтүе, кыеклап булса да, председательнең эшен хуплауга кайтып кала иде.
— Алайса, без болай итик, Максуд: йортны без колхоз исәбенә салып бирик. Кереп урнашкач, сез аңа, шәһәр җирендәге кебек, ай саен әҗерен түләп барырсыз. Озаклап яшәргә теләсәгез, әйбәт эшләсәгез, без ул йортның бәясен биш елдан соң идарәдә килешеп, яртылаш киметербез. Башкаларга гел шулай эшләп киләбез ич. Мин куркам, әгәр сез үзегез йорт әмәлләргә тотынсагыз, муеннан шул эшкә чумарсыз да мал-туарны, комплексны онытырсыз. Безнең бит әнә терлекчеләр каласы үзе генә дә... ай-яй-яй! Бик шәп хуҗа кирәк бит аңа. Мал җанлы кеше. Өстәвенә Акчуртандагы, Күкчәртаудагы, Каңгыраштагы фермаларда күпме терлек бар. Шулар янына — атлар... Барысын күрергә, күз-колак булырга, үз малларың кебек итеп кайгыртырга кирәк. Шулай, Максуд, йортны сезгә үзебез салып бирәбез. Сезнең эш — малларны кайгырту.
Каюм Максудов, рәхмәт әйтеп ишектән чыгып киткән чагында: «Менә моны ике дә уйламый баш ветеринар итеп әзерләргә кирәк»,— дигән уй Айтугановның җанын җылытып узды.
Төзүчеләр бригадасының балта осталары сагыз исләре аңкытып торган нарат бүрәнәдән бура бурады. Аны Яшьләр урамы дип тә, халык телендә Буйдаклар урамы дип тә йөртелә торган бик иркен һәм киң урамга күтәртеп тә куйгач, түз лапасларга, ак мунчага, урыс капкага да чират җитте. Председательнең ике көннең берендә төзелешне карарга килүе яшьләрдә кызыксыну уятты. Кемгә булыр икән бу председатель абзыйның контрольлегендә корыла торган йорт? Кайсы бәхетлесенә?

Колхозга төп-төгәл,— артык та түгел, ким дә түгел,— уникe мең сумга төшкән шушы яңа йортның ачкычын хуҗа буласы кешегә тапшырыр алдыннан Айтуганов идарәне җыйды:
— Җәмагать, киңәшсез булмый. Әлерәк кенә салынып беткән йортны кемгә бирергә икәнне ачыкларга, идарәнең ризалыгын алырга дип чакырдым мин сезне. Бүгенге көндә ветврач вазифаларын үтәүче Максуд Каюмов бар. Яшерен-батырын түгел, йортны аңар диебрәк атап салдырдык. Әтисеннән калган йорты тузды инде, әнисе авыру, үзенең йорт җиткезеп йөрергә вакыты юк. Сез аны барыгыз да беләсезме? Тукта, бигүк дөрес әйтмәдем фикеремне. Сезнең аны белмәвегез мөмкин түгел, авылдашыбыз бит, яхшы беләсезме димәкче идем.
— Беләбез. Акыллы җегет!
— Акыл кемдә дә бар хәзер, Максуд — намуслы бала.
— Рәхмәт. Безнең фикерләр туры килә икән,— диде Айтуганов, алдында яткан кәгазьгә «Каюмов» дип язды да шуның турысына «+» билгесе куйды.— Әйе, туры килә икән, килмәсә кыен булыр иде. Минем күңелдә бер уй туып тора бит әле... Максуд бездә ике ел эшләде инде. Үзен ямьсез яктан күрсәтмәде. Эчеп-исереп, азыптузып йөрмәде. Сөйләштек: тагын да эшләргә исәбе бар. Шуны бел-

гәченнән, мена без аңар йорт салдык. Ягъни мәсәлән, колхоз исәбенә салган йортка аны кертергә торабыз. Кем белә, бөтенләйгә торып калуы да ихтимал. Башлы-күзле булса, авылда тамыр җәеп җибәрсә дигәндәй...

— Бәрәкалла, бирсен ходай!— диде арткы рәттән кемдер.

Балдамардагы беренче бригада бригадиры Шәйми аны күтәреп алды:

— Максуд кебек егетләрне кулдан ычкындыру — гөнаһ. Тамыр җәйдерергә кирәк. Вәйт имынны — тамыр җәйдерергә! Төпләнеп утырсын Балдамарда, җил-давылларга бирешмәстәй имән булып.

— Алайса, җәмәгать, бүгенгесе көнне күңелдә туган уй-фикеремне әйтеп бирим инде. Каюмов Максудны, бездә ике ел буенча бик әйбәт эшләгәнен искә алып, «Сабанчы»ның баш ветеринары итеп куйсак? Сез моңа ни диярсез?

Авыл кешесе — салмак, ашыкмаучан.

Идарәдә тынлык урнашты.

— Яшьрәк түгелме?— диде баш механик.

Аңа җавапны шул ук бригадир Шәйми әйтте:

— Карт кеше белән нишлисең? Терлекләр белән ул-бу була калса, карт кеше мыштырдап кузгалганчы, киенеп, кыбыр-кыбыр барып җиткәнче... Җанлы мал — ярты мал. «Ат дуктырының» бер аягы өендә булса, икенчесе терлекләр торагында булсын. И булачак та, яшь кешене куйсак! Барып та җитәчәк и сабражайт итеп тә өлгерәчәк. Әгәр шуны эшләү Каюмовның кулыннан килә икән, куйыйк. Эшлисе килсә эшләсен, эшлисе килмәсә — эшләмәсен. Малтуарыбыз ишәйде, мәшәкатьләр күбәйде. Куйыйк, Фәһим абый, Максудны мал-туарга духтыр итеп. Сынамадык түгел, сынадык бит инде без аны.

Ризалашып кул күтәрделәр.

Күтәрүен күтәрделәр, ләкин Фәһим абзаңның күңеле шул көнне кичен үк пошаманга төште.

«Ярый, монысы да булды»,— дип ул, гадәтенчә, бик аллә ни кычкырып куанмый гына өенә кайткан иде. Кайтып керсә, күрә — аны бик матур табын көтә. Хатыны Сөембикә дә, кызы Фаягел дә сабантуйларында гына кия торган затлы күлмәкләрен киеп алганнар, иңнәрендә — Фәһим Югары Совет кибетеннән, депутатлар өчен генә эшли торган кибеттән, алып кайткан аппак өрфия шәл, хикмәти хода — ел буе сандыкта бикләнеп ята торган биек үкчәле ак туфлиләр дә килеп чыккан. Чырайлары якты, нурлы; тукта, чү, бераз моңсурак та түгелме? Ни булган боларга? Йорт хуҗасына анилекызлы нинди сюрприз әзерләп куйган болар? Икесе дә педагог, башка чакта бик тыйнак һәм тыенкы була белгән кешеләргә бүген ни булган соң?

«Ни булганы» табын янында итле өйрә ашап, авыл өендә сирәк пешерелә торган үзбәк пылавына урелгәч ачыкланды.

Фаягөл кинәт ашавыннан туктады, җиң очыннан бәләкәй кульяулык чыгарып, авыз тирәләрен сак кына сөртергә тотынды, бит алмаларына күзгә күренеп ялкын кабынды. Дулкынлануы, ниндидер бик тә мөһим сүз әйтергә җыенганлыгы күренеп тора иде.

— Әти... әни, син дә...— диде, озак итеп сулыш алды.— Сез миңа үз гомеремдә күп төрле яхшылыклар эшләдегез. Таптыгыз, бактыгыз, кеше иттегез. Алары өчен бик зур рәхмәт. Инде тагын бер яхшылык эшләсәгез икән...

— Йәле, әйтеп кара, кызым, нинди яхшылык икән ул?

— Миңа... Максудка...

Фәһим абзый ашавыннан туктады, кызының сүзен көтеп бетерә алмыйча:

— Нәрсә Максудка?— диде.

— Рөхсәт итегез... кияүгә чыгарга...

Эти кешенең коелып бетә язган чәчләре үрә торды.

— Максудка?— диде ул, урынында кыбырсып.— Максуд Каюмовкамы?

— Әйе, нәкъ шуңа — Максуд Каюмовка.

— Ни сөйлисең син, кызым? Акылыңа кил!

— Ә нигә? Максудка ни булган? Эчәме, тәртип бозамы? Сүгенәме, әллә кеше әйберенә тияме? Буй дисәң буе, акылы дисәң акылы, кешегә күрсәтим дисәң — чырае бар.

— Хикмәт анда түгел, буе-сыны да, акылы-фигыле дә үз урынында аның. Бүген, шушы минутта, ун кызны чакыр, ун кыз да аңа кияүгә чыгарга риза булыр иде...

— Соң, шулай булгач?..

— Без бит әле бүген генә аны колхозның баш ветеринары итеп күтәрдек. Әле бер атна элек кенә: без аңа колхоз чутыннан унике меңгә төшереп йорт салып бирдек.

— Бик әйбәт. Без әнә шул яңа йортта парлашып яши башларбыз.

Фәһим абзый, кызы Фаягөлнең сабырлык ягыннан үзен дә уздырып җибәргәнен күреп, телсез калды. Бераздан гына аңына килеп:

— Туктагыз әле, нишләвегез бу?— дип күңел түреннән килгән әкрен, әмма рәнҗешле тавыш белән сүз башлады:— Халык минем хакта ни әйтер? Ә-һә-әә, дияр, алты почмаклы нарат йортны булачак кияве өчен тырыштырган икән. Ә-һә-әә, баш ветеринар урынын да киявенә саклап тоткан, дияр.

— Ләкин бит алай түгел, Фәһим. Монда бит синең бер генә дә гаебең юк,— диде Сөембикә ханым да, урыныннан торып. Ул карты янына килеп, аның җилкәсенә кулын салды, тирләп чыккан маңгаен тастымал белән сөртте.— Син юкка борчыласың, әтисе, минемчә. Аларны син кавыштырмаган, аларга бер-берсен яратырга син әйтеп бирмәгән. Табышканнар, кавышсыннар. Гаебең юк икәнен син бит бик яхшы беләсең...

— Мин беләм. Ярар, беләм ди мин! Ә халык беләме?

Фаягөлнең бу сөйләшүдән ризасызлыгы чыраена бәреп чыкты: бите, әлерәк кенә алсуга кабынган бит алмалары сулды, агарып китте, иреннәреннән, алсу матур иреннәреннән кан качты, алар сизелер-сизелмәс дерелдиләр иде.

— Ярар, эти, борчылма. Без сиңа авырлык китермәбез. Максуд белән бергәләп Казанга китәрбез. Максудны аспирантурага чакырганнар иде былтыр ук. Миңа да Казан мәктәпләренең берсендә эш табылмый калмас. Яңа йортка яңа килгән ветеринарны урнаштырырсыз. Изге урын буш тормас...

Сөембикә ханым, иренен тешләп, елап җибәрде.

## 3

... Кызы Фаягөл әйткән сүзләр Фәһим абзыйның йөрәгенә пычак булып кадалды. Калага китәләр, имеш, галим булалар. Малтуар үстерү, авыл тормышын ямьле итү өчен яратылган Максуд Каюмов институт аудиторияләрендә студентларга лекция сөйләп йөрүче, инде ничәмә еллар авыл өчен берни дә бирә алмаган кысыр галимнәр дәрәҗәсендә торып калачак. Аннары үкенәчәк. Гомер буе үкенәчәк. Фаягөл калага китә. Кияве белән бергә. Димәк, Фәһим гомер буе хыялланган игенчеләр династиясенең бер почмагы кителә, бер чылбыры өзелә. Болары артыннан Фатыйхы китмәс дип кем

ышандыра ала? Фатыйх җирне белә, авылны белә, әмма авыл кешеләреннән аермалы буларак, каралты-курасы белән генә яшәми Фатыйх, әдәбият-сәнгать белән яши. Ул татар культурасын гына түгел, дөнья культурасын белә, аңлы рәвештә өйрәнә, татарның мең еллык мәдәниятын шулар белән чагыштырып карый. Философ Фатыйх, авыл философы. Тарих турында, тарихтагы гаделсезлекләр турында сүз кузгалдымы, Казаннан килгән берәр зыялысы яки үзәк газеталарның корреспонденты шул хакта гәп оештырамы, Фатыйх дөньяда авыл барын, игеннәр барын оныта, кич буе, төн буе бәхәсләшеп чыга. Халыкның рухи хәзинәсен саклар өчен ул җанын фида кылырга әзер. Кече авыллар кала ягына кузгалганнан соң олы авыллар да дәррәү кузгалган күк. Фаягөл белән Максуд кына калага китсеннәр, Фатыйх әсәрләнәчәк, күзенә ак-кара күренми башлаячак. Казанда ул үзенә бәхәсчеләр табачак, театрларга, концертларга йөрүдән, сәнгать кешеләре белән очрашудан җанына азык алачак. Ә эш урыны? Җайланыр анысы да. Авылда ничәмә еллар иген үстергән агроном егетне үзе укып чыккан Авыл хуҗалыгы институтына биш куллап алырлар. Практик килде, тәҗрибәле кеше, дип сөенерләр әле. Менә шулай, Сабирҗан малае Фәһим Айтуганов, син иягеңне сыпырып, картлык көнеңдә авылда Сөембикәң белән икәү генә утырып калырсың. Әнә бит бөтең өметең — күрше «Яңа көч» колхозында председатель булып эшләгән олы улың Галинурда иде. Аны да Тимергалиев эшеннән алырга ашкына. Бер тотынгач, алыр инде ул аны, алмый калмас. Әгәр Фаягөлләр, Фатыйхлар артыннан Галинур да кузгалырга уйласа, ни диярсең? Күрми дә калырсың — анысы да китеп барыр. Ул бит аны үз урынына «Сабанчы»да председатель итеп калдырмакчы иде. Шикләнми иде ул райкомның аны әтисе урынына күчереп куячагына. Әнә бит эшләр нинди борылыш алырга тора... Кече улы Таһир бик яшь әле, өстәвенә, анысы игенчелеккә бик әллә ни егылып та бармый, бар белгәне — техника.

Кем беләндер киңәшергә, мәсьәләне уртага салып сөйләшергә кирәк иде. Андый кеше итеп ул партоешма секретаре Мөхәммәт Сираҗиевны тапты.

Мөхәммәт — ятим үскән егет. Әтисе сугышта үлгәннән соң әнисе кулында калып, лаеш шулпасын туйганчы чөмерде. Ярашуны, ялагайлыкны белми. Туры сүзле Мөхәммәт: бер әйтә, берәгәйле әйтә.

Фәһим абзый аны, киңәшәсе бар иде, дип идарәгә чакырып алды. Буйга озын, гәүдәгә ыспай-җыйнак, өстендә чия төсендәге свитер, свитер изүеннән шакмаклы бумази күлмәге күренеп тора. Зур таза кулын Фәһим абыйсына күрешергә дип сузды, күрешкәч, каты итеп кул кысышкач, Айтуганов янына урындыкка килеп утырды.

Ләм-мим бер сүз дәшмәстән, Мөхәммәт үзеннән унбиш яшькә олы, ихтирамлы кешенең сүзен көтә башлады: иртә баштан чакырып алган икән (ә ул нәрәт вакытында парторгның катнашуын көтеп тә ала ала иде!), димәк, аның әйтер сүзе, икәүдән-икәү генә хәл итәсе мәсьәләсе бар.

Айтуганов кичә гаиләләрендә килеп чыккан аңлашмауны, күңеленә җыелган шикләрен сөйләп бирде Сираҗиевка.

— Йа алла!— Парторгның игътибар белән сабыр гына тыңлап утырганнан соң әйткән беренче сүзе шул булды.

— Йа алла! Сез, Фәһим Сабирҗанович, олыгая-олыгая куркаклана барасыз мәллә? Кем инде сез әйткәнчә уйласын! Кем инде Айтуганов кызын җылы урынга урнаштырырга җыена дип сезне гаепләсен? Килешмәгәнне? Сезнең бит туганнарыгызга, гаиләгезгә карата нинди таләпләр куйганыгызны да, борчыла торган кеше икәнегезне бөел гына белмибез бит инде. Балдамар халкы да, калган алты авылның

кешеләре дә, шөкер, сезне үтәдән-үтә күреп торалар ич. Ярый, сезнеңчә булсын, болай дип фараз кылыйк: Фаягөл белән Максудны өйләндермәдек, ди. Бу соң үзе үк әхлаксызлык булып чыга түгелме? Безнең ни хакыбыз бар бер-берсен яраткан ике йөрәкне аерырга, аларның саф хисләрен җиргә салып таптарга? Фаягөл Айтуганова сезнең кызыгыз булган өчен генә, Максуд Каюмов сезнең кызыгызга өйләнгән өчен генә аларны ник аерыйк ди әле без? Башкаларга салып биргән йортны ник аларга салып бирмик ди? Сез нәрсә, аны башбаштакланып, берүзегез хәл итмәдегез бит, мин карап утырдым кичә, аны бит идарә хәл итте, идарә яклап чыкты. Ярый, хуш, без аларга идарә бирергә кушкан йортны бирмәдек ди, алар безгә рәнҗеп, шәһәргә китеп бардылар, ди. Бердән, без белгечсез калабыз, икенчедән, колхозыбыз җитәкчесез калмас дип кем мине ышандыра ала? Йә, әйтегез, кем ышандыра ала? Балагызның калага китеп баруы сезнең бәгырь итегезне ашаячак. Бу — сезнең мәңгелек үкенечегез, үз гомерегездә эшләгән иң зур ялгышыгыз булачак. Каты шелтәне сез кырык ел буена колхозны җитәкләгән дәвердә аз алмагансыздыр, орденнарыгыз да җитәрлек. Дәрәҗәгез — баш түбәсеннән. Элекке җәзаларны да, дәрәҗәләрне дә сезгә властьтагы кешеләр бирде, сез аларны үзегезгә үзегез алмадыгыз. Ә менә балаларыгыз берәм-берәм калага китеп барса, монысы инде үз кулыгыз белән, үзегез тырышып алган җәза булачак. Үзе егылган — еламый, дип әйтәләр әйтүен дә, белмим, сезгә бу җәза кыйбатка төшмәгәе, Фәһим Сабирҗанович...

— Минем бит инде болай да китәр көнем җитте. Җәй житкәнне сабырсызланып көтәм бит инде...

— Кая китмәкче буласыз?

— Кая дип... Ялга. Пенсиягә...

Мөхәммәт аның тавышында сизелер-сизелмәс рәнҗү ишетте. Мондый рәнҗү аңа таныш: еллар буена файдалы зур эш эшләп тә, тиешенчә рәхмәт ишетмәгән кешеләр шулай әкрен генә кешегә сиздермичә, күңелләреннән генә рәнҗи торган булалар.

— Болай сөйләшмик әле без, Фәһим Сабирҗанович, — дип Мөхәммәт зур кара күзләре белән төбәлеп, үз итеп Айтугановка карады.— Сез бит, Фәһим абзый, китәм-китмим капризыннан өстенрәк кеше бит. Минемчә, сезнең әле китәргә хакыгыз да юк. Халык моңа каршы киләчәк. Колхозчылар сездән өйләренә газ кертүне көтеп утыралар. Чөнки вәгъдәгез шулай. Монысы, әйтик, бер хәл. Газны анысы сез китсәгез дә кертерләр. Изге урын буш булмый, дигәндәй, сезнең урынга яңа кеше килер, кем белә, бәлкем, ул сездән дә акыллырак, сездән дә булдыклырак булып чыгар. Минем әйтергә теләгән сүзем менә нәрсә: нигәдер минем күңелдә, сез үзегез киткән чакта колхоздан иң шәп егетләрне читкә таратып китмәкче буласыз, дигән фикер уянды. Сез нәрсә, Фәһим Сабирҗанович? «Мин эшләгәндә барысы да ал да гөл иде, мин киткәч, һәммә нәрсә көл булыр», — дип әйтмәкче буласызмы?

Айтуганов бөтенләй югалып калды. Аның парторглардан беркайчан да мондый сүз ишеткәне юк иде әле. Юк иде, чөнки колхозга баш — председатель, власть аның кулында, мал-мөлкәт, һәммә байлык аның кулында, парторг кулында — вәгазь, гамәлгә ашмаган буш сүз. Күпме еллар шулай булып килде, райком аларны, сәхнәдә курчакларны йөрткән төсле, ел саен алыштырып торды. Партком секретарьлары гынамы?! Райком секретарьларының үзләре дә Айтуганов председательлек иткән кырык ел эчендә тугызмы-унмы тапкыр алышындылар. Аларны обкомнан мактый-мактый китереп куялар, колхозчылар алардан алтын таулары вәгъдә иткәнне ишетә, колхоз рәисләре аларга ялагайлана, тегеләр озакламый «алтын таулар»ын оныта, урамга йомычка таулары өеп, Таулы Төбәккә үзләре өчен «патша сарае» салып куялар, моны күреп халыкның күңеле сүрелә,

гайрәте чигә; секретарь дигәнебез, эшләре алга бармагач, Казаннан җылырак урын һәм квартир эзли башлый. Алар киткәч, район халкы алар эшләгән ямьсез эшләр, этлекләрне сөйләп яши, обкомның җәза биргәнен көтә, көтә-көтә арый; хикмәти хода, көннәрдән бер көнне киткән, чамасыз тәнкыйтьләнгән секретарьның Казанда янә дә номенклатурный эшкә урнашып, казна машинасында җилләр уйнатып йөри башлавын, һаман да балда-майда йөзүен ишетеп, күңелендә аппаратчыларга карата ямьсез уй кузгала: карга карганың күзен чукымый икән...

Боларны яхшы белгәнгә, әле «перестройка» дигән сүз дөньяда пәйда булганчы ук халыкның шушы хәлләргә биргән бәясен үз колагы белән ишеткәнгә, Мөхәммәт Сираҗиев үҗәт бер ныклык белән авыл халкы арасында партоешманың абруен күтәрергә керешә. Моның өчен үзең гадел булу гына, җаныңны аямый эшләү генә җитми, колхоз рәисе белән кулга кул тотынып эшләргә, ул башлаган эшләрне райкомда яклый белергә дә кирәк әле. Ә яклау өчен син председательнең кем икәнлеген төшенеп җитәргә, аны үзеңне белгән кебек белергә тиеш. Ун ел буена Фәһим Айтуганов белән кулга-кул тотынып эшләү дәверендә ул күреп торды: Айтуганов райкомның «үз кешесе» булырга тырышмый, ара саклауны кулай күрә, ягъни «дистанция тота», шул сәбәпле аны бер генә секретарь белән дә бәйләп телгә алмыйлар, тегеләргә таккан гаепне аңардан эзләмиләр; «Сабанчы» халкы ихтирам иткәнлектән, председатель Айтуганов ел саен үз урынында кала бирә, халыкны эш белән, төзү материаллары, мал азыгы һәм икмәк белән вакытында тәэмин итә, — ел саен уздырыла торган исәп-хисап җыелышларыннан ул тагын да ныгыбрак чыга һәм, яңа көч белән, җиң сызганып, җиде авылны берләштергән «Сабанчы»ны тагын бер адым алгарак алып китү өчен тырыша башлый.

Айтугановның колхозда беренче кул белгечләр, тармак җитәкчеләре булдырырга барлык көчен салуын күргәч, Мөхәммәт аны яклады һәм андый җитәкчеләрне табышты. Колхозның үзендә картлар йорты булдыру кирәклеген башлап ул күтәрде һәм моның әти-әниләрен багарга теләмәгән әхлаксыз яшьләрне тәрбияләүдә төп чара икәнлеген исбат итә алды. Фәһим Айтуганов кайчандыр мең мәшәкать белән ачтырган Балдамардагы участок больницасын сәламәтлек министрлыгы ябарга теләгәч, Сираҗиев моңа теше-тырнагы белән каршы чыкты. Больницаны ябарга бер түрәнең имзасы җитә, кабат ачуны ун түрәнең дә имзасы хәл итмәячәк. Ә больницаны ябарга юл кую — идарәнең дә, партоешманың да, авыл Советының да абруена китереп сугачак, халыкта җитәкчеләргә карата ышаныч какшауның башы әнә шул булачак инде...

Халык язмышына бармак аша карамавы — Мөхәммәтне үз итәргә, аның белән күңелендәге шик-шөбһәләрне уртаклашырга өндәде Айтугановны. Ул аңа партоешма секретаре итеп түгел, барыннан да элек кешелекле кеше итеп карый, ә партия тормышында — райкомда да, обкомда да, хәтта үзәктә дә кешелексез, таш бәгырьле чиновникларны, шөкер, үз гомерендә күп очратты ул.

Бүген Айтуганов алдында Мөхәммәт ничектер зуррак, мәгънәлерәк булып ачылды бит әле. Фәһим абзый, аны ничектер үзеннән, ягъни председатель биләгән урыннан түбәнрәк итеп күрә, аеруча кискен эшләрне, райкомга каршы да чыгып эшли алырдай эшләрне булдыра алырдай кеше итеп санамый, безнең колхозда парторгның абруе минем аркада югары, артта сөйрәлгән колхозда ул пычагымны да кыра алмас, дип уйлый иде. Бүгенге сөйләшүдән соң аның ул фикере чәлпәрәмә килде. Шуңа күрә ул озак кына уйга калып утырганнан соң

— Мөхәммәт Хәйдәрович... Без өйләргә кайтып, тамак ялгап килик. Сөйләшү әле бетмәде. Башланды гына әле. Нәрәттән соң икәүдән-икәү генә калып, тагын бер сөйләшик әле без, — диде. — Бу безнең икебезгә дә кирәк. Бик кирәк.

Мөхәммәт нәрәттән соң гына да килә ала иде. Әмма үзе партоешма секретаре булып эшләгән колхозның бүгенге сулышын аның бригадирлары, баш белгечләре авызыннан ишетү нияте белән төп-төгәл кичке алтыга идарә бүлмәсенә килде. Шундук игътибар итте: биек түшәмле, стеналары аксыл-сары төстәге обой белән ябыштырылган иркен зур бүлмәдә, стена буйларына тезеп куйган венский урындыкларда кешеләр тезелеп утырган. Алар эш киеме булган кожаннарын, каеры туннарын, мамык сырмаларын каракүл якалы пальтоларга, кубанка яки җөнтәс мех бүрекләргә алмаштырганнар, тик аякларында гына ялт итеп торган мехлы сапожки яки җылы эчле ботинкалар урынына чүчинкә-галошларын коридорда калдырып кергәннәр: урамда эшләп өйрәнгән гадәт буенча шакмаклы бумази күлмәкләренең изүләре ачык, ачык изүдән таза кызыл муеннары күренеп тора. Алар арасында үтүкләнгән кара костюмлы, ак күлмәкле һәм галстуклы бер генә кеше аерылып тора: төзүчеләр бригадасының инженеры Нури Батыркаев. Ул киеме белән генә түгел, шаулап сөйләшкән тармак җитәкчеләре арасында сүзсез булуы, алардан шактый ук читтә утыруы белән дә күзгә ташлана иде.

Мөхәммәт, өстәл янында бик бирелеп нәрсәдер язган Айтугановка дәшеп (ул да бүген кешелеккә кия торган костюмнан, ал күлмәктән, галстуктан!), аннары барлык кешегә берьюлы сәлам биреп, инженер Батыркаев янындагы буш урындыкка килеп утырды. Инженер тәбәнәк буйлы, ак чырайлы, ябык, Мөхәммәт Сираҗиев аңардан бер баш биегрәк булып чыкты.

Нәрәтне тиз тоттылар.

— Йәгез, иптәшләр, кайсыгызда нәрсә бар? — дип Айтуганов кәгазьдән башын күтәрде.

«Сабанчы»да ун ел инде яңа тәртип: нәрәтне председатель бирми; иртәгәсе көнгә нинди эшләр башкару, кайсы эшкә ничә машина бүлеп бирү, төзелешкә күпме материал кирәклеген ачыклау, кайсы колхозчыга өмә ясап йорт җиткезүнең чиратын билгеләүне тармак җитәкчеләре үзләре уйлап кыйләләр. Айтуганов аларны кәгазьгә теркәп кенә бара.

— Пекарьни төзелешенә өч машина, — диде Батыркаев.

Моны председатель Айтуганов һәм баш механик Әмирханов блокнотларына теркәделәр.

— Кар тотуга өч трактор, — диде беренче бригада бригадиры Шәйми.

Аңа өч «ДТ-70»не язып куйдылар.

— Газ балоннарына...

— Казаннан ипи алып кайтырга...

— Урманчыларга азык илтергә...

Болары көн дә саен үтәлә торган гадәти эшләр иде.

Сираҗиев көтелмәгәнрәк тәкъдим кертте:

— Картлар йортына бер машина, йөк машинасы түгел, җиңел машина кирәк булыр.

— Кем күчә картлар йортына? — диде Айтуганов, башын күтәреп.

— Әүхәди бабай.

— Ә малае?

— Малае Рөстәм, хатыны Гөлсинәнең коткысына бирелеп, башка чыкты бит. Карт хәзер япа-ялгызы. Көннәр буе капка төбендә утыра... Күчерергә кирәк булыр аны.

Бүлмә эче тынып калды.

— Булдым мин аның янында. Сөйләштем, — диде Айтуганов, тынлыкны бозып. — Тик әле картның өеннән китәргә нияте юк. Мөхәммәт Хәйдәрович. Мин, әлбәттә, сезнең белән килешәм. Хәле кыен

картның. Шулай да аны ирексезләп картлар йортына күчерү килешер микән? Авыл безгә рәнҗемәсме?

— Алайса, малаена аңлатырга, аңламаса, исемен алдынгылар тактасыннан алып ташларга кирәк.

— Аннан да шәбрәк механизатор юк бит безнең, ул әле бүген дә кар тотудан кайтып керми, — дип ризасызлыгын белдерде өлкән яшьтәге бригадир Шәйми.

— Бәлки, картның үзендәдер гаеп. Бәлки, ул бик вакчылдыр, мыжыктыр? — дип сүзгә кайнарланып кушылды баш механик. Бер якны гына гаепләп утыру — гаделлек булырмы?

— Әлбәттә. Чистый... — дип аны куәтләде яшь бригадир Сәләхетдинов.— Менә мин дә картлар белән торам. Бик рәхәт дип беләсезме әллә? Тегесен болай итмә, монысын тегеләй ит. «Ризыкны бисмилла әйтеп пешер, ишекне шапылдатып япма!» — вакчыллык картларда әле поты белән. Гаепне Рөстәмнең Гөлсинәсенә генә кайтарып калдырмыйк. Укучы балалар аның өчен җанын фида кылырга әзер. «Гөлсинә апай, Гөлсинә апай!» — дип авыз сулары корый.

Мөхәммәт сүз көрәштерүчеләргә байтак вакыт тын гына карап торгач, Айтуганов ягына күз сирпеп алды. Председатель чәче коелган баш түбәсен, чаларган чигә чәчләрен сыпыра-сыпыра, урыныннан торды:

— Иптәшләр, булмаса, бүгенгә шушының белән тутәрәклик. Әүхәди бабай мәсьәләсен Мөхәммәт Хәйдәрович белән икебез ачыклап бетерербез, — диде.

Нәрәт алганнар, дәррәү кузгалып, бик тиз чыгып киткәч, председатель белән партком секретаре тын бүлмәдә икәү генә торып калдылар.

— Менә шулай, Мөхәммәт... Тырышабыз, тырышабыз, яшьләребез тәрбияле дигән булып тынычланып йөрибез. Ә аларның эштә иң алдынгысы, әтисен япа-ялгыз йортта калдырып чыга да китә. Шушы да булдымы тәрбиялелек?

— Фәһим абзый, бу — бик җитди мәсьәлә. Әгәр без алга таба да андый ямьсез күренеш кабатланмасын диеәк, яшь механизаторлар арасында, хәтта бөтен Балдамарда Рөстәм Тукрановка карата түзеп тора алмаслык атмосфера тудырырга тиешбез.

— Ягъни?

— Халык аның күзен ачырмасын. Бармак белән төртеп күрсәтә торган булсын.

— Алайса, сез, Мөхәммәт Хәйдәрович, чын хәлне белмисез. Беркөн пожар каланчасы янында яшьләр белән сөйләшеп торам. Рөстәм — хатыны Гөлсинә белән узып бара. Халыкны күргәч, Гөлсинәсе — бик үткен, бик җитез нәмәстәкәй бит, — ирен култыклап ук алды.

— Ә егетләр?

— Егетләр нәрсә?.. Егетләр безнең Гөлсинә кебекләрне генә күргәнме? Авызларына бармакларын кабып, шундый ачы итеп сызгырып җибәрделәр, аннары: «Кол Гали! Кол Гали!» дип кычкыра башладылар. Янәсе, хатынының колы...

— Алайса, эшләре начар Тукрановларның, егетләр аларны авылдан чыгарып җибәргәнче тырышачак. Ләкин китереп җиткермәскә иде бит аңа тикле?

— Мин Әүхәди бабай белән сөйләштем. Җылый. Утыны юк. Кайгыртучысы юк. Иртәгә мин утын китерергә машина бирермен, ә сез, Мөхәммәт, Рөстәмнең үзен, хатыныннан башка, партоешмага чакырып сөйләшмәссезме? Сезгә килешә ул.

Мөхәммәт урыныннан торып, ишекле-түрле йөренеп килде.

— Беләсезме, Фәһим Сабирҗанович... күңелдә ниндидер авыр бер таш ята. Колхозда 200 кешелек партия оешмасы бар. Ә без гап-гади бер механизатор егеткә йогынты ясый алмыйбыз. Заманында

авылда бер мулла булган, туганны, үлгәнне, өйләнгәнне теркәгән, балаларга исем кушкан, вәгазь сөйләгән, бөтен бер авылның әхлагын саклап тора алган. Минемчә, дәүләтне диннән аеру шушы хәлләргә китереп җиткерде...

— Әйтмәгез инде... — диде Айтуганов.

Алар беркавым тын гына утырдылар. Аннары Айтуганов, бик якын бер кешесенә күңелендә озак йөрткән шик-шөбһәләрен ачарга теләгәндәй, серлерәк тавыш белән сүз башлады:

— Мөхәммәт... үзгәртеп кору дигән сүзне хәзер кем генә сөйләми. Ә бит әлегә файдасы ташка үлчим. Үзгәртеп кору партаппаратта бер дә сизелми бит. Узган елны көзен обком райкомга, райком безгә утызар пункттан торган инструкция җибәрде.

— Ачыклый төшик: инструкцияне райком җибәрдеме, агропроммы?

— Агропром шул ук райком кубызына бии бит инде. Үзбаш, мөстәкыйль рәвештә нәрсә эшли ала соң ул? Көзен обком белән Совмин арыш чәчмәскә әмер бирде. 32 колхоз безнең районда чәчмәде арышны. Коры җиргә ярамый, диде. Без чәчтек. Минем улым Галинур җитәкләгән «Яңа көч» колхозы да чәчте. Шуның өчен Галинурны келәмгә бастырып, райком бюросы мыскыллы сүзләр әйткән.

— Мин булдым ул бюрода, Фәһим Сабирҗанович. Сезнең улыгыз Галинур егетләрчә тотты анда үзен, бюроның тәкәбберлеген шундый итеп җимерде, Тимергалиев ул бюроны әле бүген дә оныта алмыйдыр.

— Менә шул шул. Тимергалиев хәзер Галинурның исемен киңәшмә саен булдыксыз җитәкчеләр арасында телгә ала. Бу нәрсә дигән сүз?

— Бу, Фәһим Сабирҗанович, гади генә итеп әйткәндә, каныгу дип атала.

— Ә соң ул каныгу райком секретарен бизи торган сыйфатмы?

— Беләсезме, Фәһим Сабирҗанович... Чир китә, гадәт китми, дигән халык, ул моны, күрәсең, юкка гына әйтмәгән. Сталин канцеляриесе урнаштырган күсәк белән тондыру алымы, алтмыш елдан артык дәвам итеп килгән шул алым, — хәзер аңа әмер-административ методы дип рәсми исем дә куштылар бит инде, — аны икеөч ел эчендә генә юкка чыгарып буламыни?..

Әңгәмәнең шул юнәлештә баруы Айтугановның күңеленә ятышлы иде, аның күңелендә йөрткәннәренә туры килә иде, шуңадыр бәлки, ул мәсьәләне «кабыргасы белән куярга» кирәк дип тапты.

— Сезнеңчә ничек, Мөхәммәт Хәйдәрович... Таулы Төбәк райкомының беренче секретаре үз урынындагы кешеме?

— Тимергалиевме?.. — дип, Мөхәммәт уйлар өчен үзенә вакыт калдырды. Ләкин аңа озак уйлап утырырга ярамый, Айтуганов, үтә дә җитди кыяфәт белән, кашларын җыера төшеп, аңарга төбәлгән: әйтерсең, аның алдагы язмышы шул сорауга җавап алуга бәйле иде.

— Беләсезме, Фәһим Сабирҗанович, бу бик авыр мәсьәлә. Бүген Тимергалиев китә икән, иртәгә Миңнегалиевне, Сәфәргалиевне, Шөкергалиевне, тагын әллә ниткән Галиевләрне китерәчәкләр. Безнең республика җитәкчеләр мәсьәләсендә гел дә бәхетсез булды. Ниндидер компетентсыз, Мәскәүгә ярашучы кешеләр урындык били. Партиянең үз эчендә кискен бер үзгәреш булмый торып, яхшылык көтәргә ярамый...

Алар тагын бик күп нәрсәләр турында: былтыр коры туфракка чәчкән ике йөз гектар арыш турында, язгы чәчүгә техниканы әзерләү, елларның килеше нинди булачагы, колхоз авылларына килеп кергән аренда подряды турында сөйләштеләр. Тик бу инде Айтугановка кирәкле сөйләшү түгел, аның җанын җылыта торган

әңгәмә түгел, председательнең күңелендә кадак булып Сиражиев әйткән сүзләр кереп утырган: партиянең үз эчендә кискен үзгәреш булмый торып, яхшылык көтәргә ярамый...

Төнге уннар тирәсендә генә кайтырга чыктылар. Иртәгәме, берсекөнгәме комплекс буенча салынган штрафны ачыклар өчен Казанга барасы булганга, Айтуганов, Терлекчеләр каласын тагын бер мәртәбә күздән кичерергә теләп, машина чакыртты.

Айтугановның үзен генә ташлап китү ничектер уңайсыз иде, Сиражиев та аңа иярде.

Машинага чыгып утырдылар.

Авыл инде утларын сүндереп бетерә язган, урамнар аулак, кайбер йортлардан ара-тирә генә этләр өреп куйганы ишетелә иде.

Терлекчеләр каласына илтә торган куперне чыккач, алар «Волга»сы яныннан йөк машинасы узып китте. Айтуганов игътибар итмәде, бик арыган иде. Сиражиев игътибар итте: машина авылныкы, фара яктысында ул аның номерын да күреп калды. Сиражиев, әхлак кагыйдәсе итеп, колхоз җитәкчеләре яныннан узганда, теләсә кайсы машинаның туктавын, бик ашыгыч эше булган сурәттә дә сәлам биреп, нинди йомыш белән юлга чыгуларын әйтеп китүне язылмаган закон буенча гамәлгә керткән иде. Председатель түгел, нәкъ менә партком, авылның әхлагын сакларга тиешле оешма керткән иде бу тәртипне. Бу, партком уенча, халыкның бер-берсенә карата бик борынгыдан килә торган ихтирамлылык билгесен сакларга тиеш иде. Моңа бик тиз күнектеләр, сәламләшүне, хәл-әхвәл белешүне зарури бер нәрсә итеп саный башладылар.

Ә менә бүген йөк машинасы сәлам бирмичә, туктамыйча узып китте. Димәк, биредә эшнең арты чиста түгел, биредә нидер бар.

Сиражиев «Волга»ны борырга, сәлам бирми киткән машинаны куа чыгарга боерды.

— Ни булды? — диде йокымсырый башлаган Айтуганов, башын күтәреп.

— Ни булганын хәзер беләбез, Фәһим Сабирҗанович, — диде парторг.

Артларыннан машина куа чыкканны сизеп булса кирәк, йөк машинасы караңгы бер чатка борылды, әмма ачы итеп сигнал биргән тавышка туктарга мәҗбүр булды.

Кабинадан шоферны һәм аның янында утырган кешене чакырып чыгардылар.

— Нишләп туктамадыгыз? Нигә хәлләрне әйтми киттегез?

— Гафу итегез, Мөхәммәт Хәйдәрович, шәйләп өлгермәгәнбез.

— Ярый, шулай да булсын. Кая барасыз?

— Ферма мөдиренә.

— Нәрсә алып барасыз?

— Цемент.

— Ничә капчык?

— Җиде.

— Каян алдыгыз?

— Төзелештән.

— Ник алдыгыз? Колхоз бит хуҗалыкларга кирәк чагында цемент бүлеп бирә...

Егетләр тынып калды. Сиражиев аларның битен кесә фонаре белән яктыртты. Егетләрнең берсе битен кулы белән каплады, ә шофер:

— Әй, ахмак булганга алганбыз инде. Ферма мөдиренә бит. Аның кул астында эшләгәч, сүзен тыңламасаң да әллә ничек... Үзебезгә түгел бит, — диде.

— Нишләтәбез, Фәһим Сабирҗанович? — диде Сиражиев, председательнең колагына иелеп.

Айтуганов алгарак чыкты, бер дә ачуланмыйча, иплэп кенә әйтте:

— Ярый, егетләр, цементны каян алган булсагыз, шунда илтеп куегыз. Кайтышлый ферма мөдире Хәлимгәраевкә әйтергә онытмагыз, иртәгә, иртән сәгать тугызга, идарә утырышына килсен, аның белән бергә сез дә килегез.

Идарә утырышын төштән соң җыя торганнар иде, иртәнге тугызда идарәне җыю гадәттән тыш хәл килеп чыкса гына була, һәм ул хәбәр сәгате-минуты белән Балдамарга, Балдамардан чыбыксыз телефон буенча башка авылларга таралып өлгерә иде.

Бу юлы да шулай булды.

Иртән идарә йортына таба атлаган чакта Хәлимгәраевне кызганып, шыпырт кына сөйләшеп калдылар, кыюраклары, уңайсызланудан курыкмаганнары:

— Әй, Мөбәрәкҗан абзый, нигә үрелдең инде син ул цементка? Персидәтел бераүдән бер нәрсә җалләми, менә бөтен тормышыңны боздың инде... Идарә сиңа моны гафу итмәс бит, — диделәр.

— И туганкайларым, күрәсене күрми гүргә кереп булмый шул. Үгез сөзгәнне төшемдә күрдем мин. Кичә берьюлы ике үгез сөзгәнне күргәнием. Шушыңа икән. Усал ният белән дә алмадым инде кана мин аны. Үземнеке булгач та илтеп куярмын, берәү дә сизми калыр, дип уйлаганыем. Күрәчәк күмер ашата, и алла...

Идарә бүлмәсен тутырып утырган авылдашлары янына Мөбәрәкҗан Хәлимгәраев бик мескен хәлдә килеп керде: күрәсең, төне буе йоклый алмаган, чырае юк, өстәвенә сакал-мыегы да кырылмаган, киемнәре дә эленке-салынкы иде. Авылдашларының кызганулы да, шелтәле дә карашларына түзә алмыйча, башын түбән иеп, ишек буендагы урындыкка чүмәште. Эшләгән эше өчен үкенү җанын айкап алды. Ә бит ул Балдамарда күкрәк киереп йөрерлек кеше. Сугыш вакытында унике яшеннән тырма тырмалады, аннары колхоз малларын көтте, соңыннан ферма мөдире булып кына да егерме ел эшләде. Инде менә, дөньяның адәм актыгы булып, башыңны түбән иеп утыр...

Кеше җанында казынуны яратмый Айтуганов.

— Менә, җәмәгать, колхозыбызда кичәгенәк төнлә бик хурлыклы эш булды, төзелештән җиде капчык цемент урланды, — дип председатель булган хәлне сөйләп бирде.

Өлкән яшьтәге бригадир Шәйми:

— Мөбәрәкҗан, авылдаш, яшермичә әйт әле, цементны апкайтырга үз телең белән куштыңмы? Яшьләрне этлеккә үзең өйрәттеңме? — диде.

Мөбәрәкҗан авырдан гына торып басты.

— Кичерегез, авылдашлар. Алдырыр көн яздырыр, ди. Гаепле. Нинди җәза бирсәгез дә күтәрермен, өтермәгә генә утыртып куймагыз, биш балам кала бит.

Яшь бригадир Сәләхетдинов беренче булып сикереп торды.

— Җәлләү — түбәнлек. Кулы белән эшләгән икән, иңе белән күтәрсен.

— Әлбәттә!

— Туктагыз егетләр, — дип, баш агроном Фатыйх күтәрелде. — Менә син, Мөбәрәкҗан абзый, әйтәле, үкенәсеңме?

— Инде әби үкенә, баласы килгән к... нә, — дип кычкырып җибәрде Сәләхетдинов.

— Азмыйк, яшьләр. Кеше язмышы.

Айтуганов, кул күтәреп, тавышларны туктатты.

— Нинди җәза бирәбез?

— Колхоздан чыгарырга!

— Вәйт әйтте, син нәрсә, кеше җаны бит ул.

Партком секретаре Мөхәммәт Сиражиев сүз сорады.

— Иптәшләр, Мөбәрәкҗан абзый, сүз дә юк, колхозыбыз йөзенә кызыллык китерә торган бик оят эш эшләде. Гөнаһысы аның гафу ителә торган түгел. Әмма төптәнрәк уйлап карыйк әле. Ул бит инде егерме ел фермада гына чиләнә. Әгәренки без ул рөхсәтсез алган җиде капчык цементның колхозга китергән зыяны белән фермада иң авыр елларда мал-туар караудан китергән файдасын үлчәү тәлинкәсенә салып карасак, фермадагы эше, әлбәттә, күбрәк тарта. Әйдәгез, без Мөбәрәкҗан абзыйның цемент алып китүен явыз ният белән эшләгән эше дип түгел, үз гомерендә беренче мәртәбә ялгышуы дип карыйк. Авылга таралган хурлыгын, өстәвенә, биредә бик мескен хәлдә үкенеп утыруын да истә тотып, аны мал-туар караудан мәхрүм итмик, фермада терлекче итеп калдырыйк. Ягъни мөдир итеп түгел, кара эшче итеп. Ялгышу була торган хәл: дүрт аяклы ат та абына...

Хәлимгәрәев башын күтәрде. Халыкның тып-тын калганын һәм аны фермада калдырырга дип берәм-берәм кул күтәргәннәрен күргәч, кулында әвәләгән бүреге белән күз яшьләрен сөртә-сөртә:

— Рәхмәт, авылдашлар. Миңа китәргә ярыймы инде? — диде.

Аның ишектән бөкрәя төшеп чыгып киткәнен идарә әгъзалары тып-тын озатып калдылар...

— Иптәшләр, безнең әле тагын бер мәсьәлә бар. Анысы да бик җитди мәсьәлә. Җыелган-җыелган, анысын да хәл итәрбез. Ә хәзергә тәнәфес ясап алыйк, — диде Айтуганов.

Идарә әгъзаларының күбесе тәмәке тартырга, тәмәке тартмаганнары һава сулап керергә дип урамга чыгып киткәч, Мөхәммәт Сиражиевка Казан төзелеш банкысыннан килгән штраф телеграммасын күрсәтте.

— Моны сузарга ярамый. Мин аны, бәлки, Мәскәүдә, Финанс министрлыгында хәл итеп кайтырмын дигән идем. Казанның төзелеш банкысы түзми: бик хәтәр яный, инкасса аркылы 50 меңне тотып калабыз, ди. Бүген шушы мәсьәләне идарәдә хәл итмәсәк, авыз ачып калуыбыз мөмкин, — диде Айтуганов.

Идарәдә шау-шу купты.

— Бирмибез!

— Табылган талаучылар!

— Без комплексны дәүләт акчасына салмадык, үз кул көчебез белән тапкан хәләл акчага салдык.

— Чистый!

— Безгә шул хакта карар кабул итәргә кирәк, карарны мин Казанга Финанс Министрлыгына алып барырмын, — диде Айтуганов.

## 6

Дөньяда күп төрле һөнәрләр бар. Ташчы, игенче, балта остасы — болары дөньяның тоткасы. Балаларга белем бирүче педагог, авыруларны дәвалаучы врач, җилдән җитез корабларны галәм киңлекләренә очыртучы галим — һөнәрнең кәттәләре. Ә идән юучылар, урам себерүчеләр, бала караучылар? Меңләгән һөнәр! Аларны санап бетермәле түгел. Аларны көн саен газитләргә язалар, зәңгәр экраннан күрсәтәләр, эфирга чыгаралар. Тик дөньяда әле беркем дә күрергә теләмәгән, беркем дә санга сукмаган тагын бер һөнәр бар — председатель хатыны булу.

Кайдадыр басу-кырларда йөри синең ирең. Кайдадыр Мәскәүдә, Кремль сараенда, депутатлар арасында утыра синең ирең. Ха-лык белән шыгрым тулы авыл клубында хисап бирә синең ирең. Ул синнән гел читтә, ул синнән еракта, ләкин ул һаман да синең

йөрәктә. Синең белән янәшә. Син аны илчеләр төсле чиста йөртергә, игенче кебек тамагын тук тотарга тиешсең. Ул ниндидер мөһим сәбәпләр аркасында соңгарып, төн урталарында гына кайтса, син, йокламыйча, аны көтеп утырасың. Хәтта тамагыңа да капмый көтәсең. Югыйсә синең дә эшең бар. Син инде укучыларыңның дәфтәрен карап чыгарга өлгердең, көне буена мәктәптә дәрес аңлатудан, өстәвенә өйгә кайткач, аш-су пешерүдән арыдың, синең инде күзләрең йомыла, тик әле син йокларга ятмыйсың, син аны — кырдан кайтасы, райком бюросыннан кайтасы, депутатлар сессиясеннән кайтасы иреңне көтәсең. Көтәсең дә көтәсең. Көтми ярамый — син председатель хатыны, көтмәскә хакың юк.

Тракторчы Тәхәүнең хатыны ире белән урамнан бара, дөнья яңгыратып көлә. Больницада эшләүче врачның хатыны Луиза, иренең беләгенә асылынып, импортный пальтосының чабуларын җилфердәтеп, кыланчыкланып атлый. Синең дә ирең Мәскәүдән алып кайткан затлы киемнәрең бар. Юк, дисең, ярамас, дисең, председатель хатынына гади-простой булырга кирәк, сине күрәләр, сине ефәк иләктән үткәрәләр, син — председатель хатыны.

Ә гомер дигәнең уза, озын толымнар кыскара, сирәкләнә, аларга мул булып замана кыраулары төшә...

Төшми хәле юк. Айтугановлар йортында, еллар буе урнашкан ныклы бер гадәт буенча, җәен-кышын, язын-көзен, беренче булып Сөембикә ханым уяна. Сыерлары Түгәнәй хуҗабикәне мөгрәп каршы ала, аның кулындагы апаралы чиләккә үрелә, җилемен җылымса су белән юганны, Түгәнәем, Түгәнәем, дип йомшак кына дәшкәнне көтеп тора. Сөембикә ханым чиләкне Түгәнәйнең аяклары янына куеп, үзе тәбәнәк урындыкка утырып, аның җилененә орына — массаж ясый, аннары гөҗелдәтеп сава башлый. Рәхәтләнеп тора Түгәнәй: сөттән арына барган җиленеңең җиңеләюен тоя бугай, җәйләрен көтүче быргысының болыннарга чакырып, моңлы итеп уйнаганын исенә төшерә шикелле...

Башка көнне сыерлар абзарын тазартырга аягына тирән эчле калош киеп Фәһим чыга торган иде, бүген ул Казанга китте, аны алмаштырырга әнә кече уллары Таһир чыккан. Ә бит аңа этисенең иртән иртүк Казанга китәчәген беркем дә әйтмәде — чыккан балакай. Күңеле сизгән, күрәсең. Аңа, җырчы кыз Саниягә өйләнеп, эти-әнисе янында торып калган төпчеккә, беркемнең беркайчан эш кушканы юк. Ләкин Таһир бер генә минутын да эшсез үткәрми. Балдамардан дүрт чакрым ары Таулы Төбәкнең төзү-монтаж идарәсе бар. Инженер-экономист Таһир Айтуганов көн саен иртүк шунда китә, эшкә җәяү йөри, кичен кайткач, тамак ялгап ала да өйдәге эшләргә тотына. Такта белән тышлаган бүрәнә йортны, биек урыс капканы сары буяуга ул буяды: лапаста әрдәнәләп өелгән утынны «Дружба» пычкысы белән ул кисте; ишегалдын, капка төпләрен ул чиста-пөхтә итеп тота; ел саен колхоз бүлеп бирә торган болын кишәрлегендәге печәнне ул чаба, ул киптерә. Бигрәкләр дә өй җанлы булып чыкты шул Таһиры: язын бәрәңге бакчасын бер тәрәнле сабан белән ул сукалый, хатыны Сания белән бергәләп, бәрәңгене утырта; әнисе белән этисен бакча бәрәңгесенә якын да китерми, алар тирәсенә, өмәгә дип, әллә ни арада кыз-кыркын, егет-җилән җыелып өлгерә. Сөембикә ханымга тәмле ризыклар пешереп, әчесен-төчесен әмәлләп куярга гына кала...

— Улым, артыгын тырышып, эшеңә соңга калып куя күрмәтагын, дүрт чакрымны җәяү атлыйсың бар бит әле, — ди Сөембикә.

— Борчылма, әни, мине бүген Түбәночның Фәтхеш малае матай белән кереп алачак, — ди Таһир.

Сөембикә ханым өйгә кергәндә, килене Сания дә уянып килә. Ай-һай, бар иде заманалар — кайнана килене өчен албасты иде.

— Килен, сыер сау!
— Килен, мунча як!
— Килен, су китер!
— Килен... Килен... Килен...

Сөембикә ханымның албасты буласы килмәде. Килен белән кайнана арасында беренче көннәрдән үк әни белән кызы арасында була торган җылы мөнәсәбәт урнашты.

Килененең ир-ат игътибар итәрдәй чибәр булуы, өстәвенә, чамасыз чаялыгы кайнананы шик-шөбһәгә дә салып куйгалый: Таһир клубка чыгарга яратмый, хатынын үзен генә җибәрә, берәр мут егет моның башын әйләндереп куя күрмәсен тагын! Таһир урнында Сөембикә булса, Санияне үзеннән башка клубларга җибәрер идеме? Кыз чагы түгел бит инде, ике бала анасы...

Шулай вәсвәсәләнә кайнана, әмма килененә Балдамар халкы гөрләтеп кул чапканда, «Вәйт, ичмасам, Фәһим абзыйның килене, авызыннан энҗе сибә!» — дип мактап та җибәргәндә җаны канат кага.

Өйгә кайткач, ул клубта күңеленә килгән шик-шөбһәләрен оныта. Чөнки Сания килен өйдәге эштән дә баш тартмый, шимбә көннәрне мунча яга, кер уа, өйне җыештыра, аш-су әзерли. Ә Сөембикә ханым ял итә — шимбәдә ул Айтугановлар йортында кунак. Ул көннәрне кайнана оныклары — берсеннән-берсе матур, курчак кебек киенгән ике кыз белән мәш килә. Алсу белән Айгөлнең чәчләрен тарый, шигырьләрен, җырларын тыңлый...

Сөембикә ханым бүген ире Фәһимне Казанга, улы Таһир белән килене Санияне эшкә озатып җибәргәч, ике яшьлек оныгы Айгөл белән япа-ялгызы торып калды. Гөлйөзем әби ахирәтләрендә куна калган, Алсуны әнисе үзе эшли торган бакчага алып киткән иде.

Әнә Айгөл, лапы-лопы басып, ава-түнә идәндә йөри, кулына тоткан курчакның битенә зәңгәр карандаш белән сызыклар сыза, өстәл тутырып чәйне түгә, кычкыра; дөньяда барлыгын исбат итәр өчен, кием шкафы янына, идәнгә «күл» ясап куйган.

Тамчы бөртек тә ачуланмый аны дәү әнисе — ачуланыр заманнар узган. Үзенең балаларына эләккәли иде, боларга — юк. «Баламның баласы балдан татлы...» Җир йөзендәге барлык-барлык нәрсәдән дә кадерле, барлык нәрсәдән дә матур, гөнаһсыз сабый белән чүкердәшеп болын чаклы өйдә ялгыз утырудан да рәхәтрәк тагын нәрсә бар!

— Кара инде син моны, ни арада чәемне түгеп өлгердең әле син минем, и рәхмәт яугырысы... — дип сөйләнә дәү әнисе ачусыз гына.

Сабый сизә олыларның күңел җылысын. Валлаһи, сизә. Карасана, тарак алып килә, тарак. Йә инде, мә инде, алайса, тара инде дәү әниеңнең ала-кола чәчләрен...

Айгөл тарый, күзләренә ишеп төшерә дәү әнисенең чәчләрен. Үзе һаман лыкы-лыкы килә, үз телендә әллә ниләр сөйләнә...

Сөембикә ханым сабыйның кыланышларына мәлҗерәп утыраутыра да, көтмәгәндә керфек төпләре җылынып китүен, күзләреннән яшь тәгәри башлавын тоя. Бәракалла, монысы ни булды тагын? Сөрт күзеңне, дәү әни, сөрт, юньсез, диген, кызым. Көпә-көндез, уйламаган-көтмәгән җирдән, кем инде бер сәбәпсез күз яше коеп утыра?! Тиктомалга...

Тиктомалга түгел. Сәбәпсез түгел.

Бүген аның ире — «Сабанчы» колхозын кырык ел буена җилкәсендә тартып барган Фәһим Айтуганов Казанга китте. Дәүләт банкысына. Штраф түләргә. Җәза биреләр, димәк. Ни өчен? Ул нинди ярамаган эш эшләде? Дәүләткә каршы бардымы? Кеше коныйрттымы? Биш ел буена җан-фәрманга чабып, йоклыйсы йокы-

ларын йоклап бетермичә, иркәлисе оныкларын иркәләргә вакыт тапмыйча терлек каралтылары салдырды. Инде менә шуның өчен аны җавапка тарталар. Мал-туар карауачыларның эшләрен җиңеләйтте ул, җәен-кышын сөйри торган резин итекләрдән коткарды. Аларга мунчалар, ял бүлмәләре ясатты, ашханәләр булдырды, биек дамбалар җәйдерде. Ул алар янына врачлар китерде. Менә шулар өчен дәү әтиебезне җәзага тарталар, штраф түләтәләр...

Төне буе янып-көеп чыкты дәү әтиебез. Йокысыз төн үткәрде. Үзе өчен түгелдер, мөгаен. Үзенә салган биш мең сумны күзен дә йоммый түләп кайта ала торган кеше ул синең дәү әтиең. Әмма колхозга китереп салган илле меңне ул җаны чыкса да түләмәячәк. Кырык ел буена ул халык байлыгын күз карасы кебек саклады. Халык малына кул сузарга ул ирек куймаячак. Йа ходаем, сабырлык бир дәү әтиебезгә, үзләрен әллә кем итеп санаган түрәләргә бик каты бәрелмәсә генә ярар иде. Сабырлыкка бик сабыр да, балам, дәү әтиең, әмма да ләкин сабырлыкның да бер чиге бар бит. Күз алдында, күрәләтә торып, гаделсезлек эшләсеннәр әле алтмыш яшең тулган көннәрдә, әйбәт кенә, хөрмәт ишетеп, лаеклы ялга китәм дип торганда...

Сөембикә ханым ашыгып кына урыныннан тормакчы булды. Ләкин, картлык шатлык түгел, дип юкка гына әйтмәгәннәр инде аны. Ул биленә таянып, оеп киткән аякларын язгалап торып киткәнче бәләкәй Айгөл инде тагын кием шкафы янына барып җиткән, курчагын кулына алып, тагын аның битенә зәңгәр карандаш белән сызыклар сыза башлаган иде.

— И балакаем, без синең белән икәү җәелеп утырдык та утырдык. Безнең бит әле бер генә нәрсәбез дә әзер түгел. Чөгендер пешерелмәгән, токмач җәелмәгән, винегретка дигән бәрәңгене дә пешерергә куймадык бит әле без. Кичен балалар җыелыр, туганнар. Мөгаен, килми калмаслар алар, килеп җитәрләр. Шимбә бит, кызым, тагын шимбә килеп җиткән...

Сөембикә ханым авырдан гына кузгалып, биленә таянгалап йөри-йөри, Айгөл түккән чәйне сөртеп алды. Кулын юды, елаудан кызарган күзләрен сөртте. Аш куярга кирәк — зур кәстрүл белән. Балалары ярата торган ит бөккәне пешерәсе булыр. Алдан аяк киенмәсәң, үкенергә туры килмәгәе...

Шуларны гына уйлап бетерүе булды, ишектән, шакымыйнитми хат ташучы Исламия килеп керде. Ишек төбендә карлы итекләре белән таптанып:

— Сөембикә апай, монда кил әле, түргә үк узып тора алмыйм, аягымдагы карым эри, әйтәсе бик җитди сүзем бар, — диде.

— Ай аллам, ниткән сүз ул тагын? — диде Сөембикә ханым, ире турында хәвефле уйлар уйлап.

— Чукмарлыдан Галинур шалтыратты. Почтага. Өйне алып карадым, алып булмый, ди. Исламия, әнигә генә кереп әйт әле, зинһар, Тимергалиев җыелышны дүшәмбе көнне түгел, бүген үткәрә, үзе килә, диде. Әтигә дә әйтеп куйсын әни, диде. Мин якшәмбе көнне хатыным, балаларым белән килеп җитәрмен, әти Казангамазарга китми торсын әле, диде.

Сөембикә ханымның кинәт башы әйләнеп китте, лып итеп урындыкка утырды. Аның шулхәтле дә үзгәргәнен беркайчан да күрмәгән, сабыр табигатьле, ягымлы педагог итеп кенә белгән Исламия элекке укытучысына кызганып карап торды да, юатыр әмәлне таба алмагач, ишек төбендә таптанудан мәгънә юклыгын аңлап, чыгып китте.

Кулларын кушырып озак утырды Сөембикә ханым. Күңелсез уйларын уйлады. Әле гөл кебек эшләп килгән улына райкомның көтмәгәндә каныгуын, ел башында инде ике мәртәбә җыелыш җыю-

ларын ул берничек тә башына сыйдыра алмады. Ә нигә бәла дигәнең ялгыз йөрми, ишләре белән йөри икән? Әтисен кайгыга салулары җитмәгән, инде улына каныгалар булып чыгамыни? Райком секретаре Тимергалиев белән сүзгә килде микән әллә? Алай дисәң, тота-каба кузгала торган егет түгел инде ул. Әллә, ходаем, гаиләсендә җанҗал чыкканмы, чит-ят хатыннарга күзе төшкәнме?

Озак утырды Сөембикә ханым, уйларына батып.

Менә шунда ул үзенең председатель хатыны гына түгел, председатель анасы да булуын исенә төшерде.

Аның чигәләре шаулый, зиһене томаланган иде.

## Өченче бүлек

### 1

Фәһим Айтугановны ай буе газаплап, җанына тынгы бирми асраган көн, ниһаять, килде. Ул бүген халык алдында хисап бирер һәм, күп еллык эшенә йомгак ясап, пенсиягә чыгар...

Син көчеңдә чакта, урындык биләп утырганда, яныңда бөтерелеп йөрүчеләр күп була. Ә менә син эшеңнән киткәч булырмы алар?

«Сабанчы» колхозына берләшкән җиде авылның кешесе сиңа нинди мөнәсәбәттә — бүген билгеле булачак.

Кыр-басуларда, терлекләр янында, урман юлларында, төзелеш мәйданында, атлы эшләрдә эшләгән, машина-трактор паркын аякка бастырган кешеләр — җыйнап кына әйткәндә, әле үз кул көче белән көн күрә, шатлыктан шатлана, кайгыдан кайгыра белә торган сау-сәламәт кешеләр сине борчымый. Аларның мөнәсәбәте ачык. Кыска итеп бер генә сүз белән әйткәндә, ул и х т и р а м дип атала. Яшьләр дә сиңа кырын күз белән карамый, туганыдай якын итә. Әнә армиядән кайткан Мортаза Хәнәвиен КамАЗ машинасына утыртасың икән, аның өчен председательдән дә яхшы кеше юк. Сыер савучы җиңгиләрнең, әле генә тормыш корып җибәргән яшь киленнәрнең дә мөнәсәбәте ачык, син алар өчен өч миллион ярымга төшереп Терлек комплексы салдырдың, аларның һәркайсы анда илле сыер сава, әмма элекке заманнардагы кебек, бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр эшләми, сигез сәгатен белә; сөтне чиләкләп ташымый, чөнки син алар өчен сөт үткәргеч ясаттың, син алар өчен мунча, душ, аптека, ял бүлмәләре булдырдың; алар да синең хакта, табигыйдер ки, начар уйламаслар, уйласалар — рәхмәтсез бәндә булырлар...

Әле бит авылда тагын бер иш халык бар — ветераннар. Алар синең белән бергә буразнада бил бөкте, синең белән бергә күтәрәмгә калган атларны күтәрде, Таулы Төбәк станциясыннан бәләкәй чана белән симәнә ташыды; сугыш елларында ачлыктан шешенгәннәре булды аларның, сабан сөргән чакта буразнада егылып калганнары булды. Хәтереңдә бит, Сәми абзый кырда, кара җир өстенә ятып, кырга чәчкән борчакны чүпләп ашаган чагында уполномоченный Вәлиәхмәтов аңа: «Син, нишлисең, корткыч? Колхоз милкенә кул сузасыңмы?» — дип нәфрәтләнеп кычкырган иде. Сәми абзый хәлсез тавыш белән: «Хет аркама афтаматтан атып, чардаклап бетер, ачтан үлгәнче, ичмасам, борчак ашап, күбенеп үлим»,— дигән иде.

Менә бүген клубка шул кешеләр — ветераннар да киләчәк. Аларның күбесе элеккерәк елларны «тишекле сутый»га эшләгәнгә күрә, кырык тәңкә акча белән утырып калды. Баштарак әле ул кырык

түгел, егерме сигез тәңкә генә иде. Менә алар нәрсә уйлый, аларның сиңа мөнәсәбәте ничегрәк икән?

Син белеп торасың: алар хәзер колхозга бер тиенлек тә файда китермиләр. Әмма... зыяннары булуы мөмкин. Чөнки алар авылның әхлакый атмосферасын тудыручылар. Алар капка төпләренә чыгалар, авылның һәр көнен энә күзеннән үткәреп, яхшысын яхшыга, яманын яманга аерып баралар. Пичәт сугып! Алар Балдамарның картлар йорты һәм зур калаларда укып яткан балалары хакында сөйләшәләр. Алар колхоз рәисен, аның хатынын, балаларын, туган-тумачасын җиз иләктән үткәрәләр. Менә бит хикмәт кайда! Син аларның күңелләрендә нәрсә ятканны, җаннарын нәрсә кимергәнне белергә тиеш. Алар — акыл иясләре, аларның гаять тормышчан үз бизмәннәре бар, син эшләгән эшләр алар бизмәнендә күпме тарта — белергә тиеш син...

Бүгенге җыелышта председательлектән китәргә уйлаган Айтугановны менә шундый уйлар биләп алды. Ә уйлар парторг Сираҗиев шалтыратканнан соң аеруча көчәеп китте. Чөнки ул Казанда, авыл йортларын газлы итү өчен махсус проектлар булдырып, газовиклар белән килешү төзеп йөргән арада, партоешма һәм авыл Советы, авыл активын яңа культура сараена җыеп, Ветераннар Советы төзергә карар кылган икән.

— Ә отчет? — диде Айтуганов.— Мин колхозчылар алдында кайчан хисап бирәм соң? Минем эштән китүем кайчан хәл ителә?

— Ветераннар сезне эштән җибәрмәскә булды, Фәһим Сабирҗанович. Бүген алар үз сүзен әйтәчәк.

— Ә отчет? — диде Айтуганов үҗәт бер ныклык белән.— Мин ясамыйммыни отчетны?

— Ясамассыз. Эшләнгән эшегез күз алдында. Планнарыгызны колхозчылар белән уртаклашсагыз, шул җитеп торыр. Халыкны бер генә нәрсә кызыксындыра — авылга газ кертү буенча нинди яңалык әйтә аласыз?

— Ала-аа-аааай...— диде Айтуганов сузып кына. Аңа хәтта күңелсез булып китте. Кырык еллык эшеннән лаеклы ялга кучу көнен дүрт күз белән көтеп торганда,— менә сиңа мә! — ветераннар сине җибәрмиләр. Пенсия яше җиткән кешене көчләп тотарга аларның ни хакы бар?

— Карагыз әле, Фәһим Сабирҗанович, ветераннар җыелышында сезгә, мөгаен, сөйләргә туры килер. Ил картлары сезгә ихтимал үпкә-сапкаларын да җиткезерләр. Әзерләнебрәк килегез, яме.

Улы Галинур Айтуганов белән Чукмарлыда булып узган күңелсез хәлләрдән соң Фәһим абзыйның күңел кыллары скрипка кылы кебек тартылган, аз гына кагылдыңмы,— чыңлап китәргә торалар иде.

Ул аягыннан киез итеген салып, мич буена куйды. Кешелеккә кия торган затлы зәңгәрсу күлмәген, кара йон костюмын киде, чия төсендәге өр-яңа галстугын такты. Костюм якасына депутат значогын беркетте. Баш түбәсеннән коелып бетә язган, чигә турыларына мул булып кырау төшкән чәчен озаклап рәтләде, тәртипкә китереп азапланды. Тик шуннан соң гына кыйммәтле мех якалы драп пальтосын, ондатр бүреген киеп, алгы бүлмәдәге зур көзгедән кыяфәтен карап алгач, хатынына дәште:

— Әй, сиңа әйтәм, Сөембикә, әзерме син? Китәбезме инде?

Яше инде илле бишләрдән узса да, әле һаман буй-сынын саклаган, гомер буе эшләп яшәгән кешеләргә хас ыспай гәүдәле, ап-ак кеш якалы кышкы пальтодан Сөембикә ханым килеп чыкты, чырае якты, битенә иннек-кершән якмаган, тавышы җайлы-салмак:

— Әтисе, син үзең бара тор. Мин Фаягөлгә кереп чыгам, икебез бергә килербез. Кайгырма, соңга калмабыз...

Фәһим абзый, капка келәсен күтәреп, урамга чыкты. Көн тымы-

зык: күкне юка гына болыт пәрдәсе каплаган һәм шул юка пәрдә аша февраль кояшы, тоныкк бөҗра ясап, беленеп тора, сирәк кенә кар төшкәли иде.

Инеш күперен узган чакта Фәһим абзый зур урамны тутырып үз җайларына гына атлаган өлкәннәрне күрде. Ул үзе дә алар җаена күчте: ил картлары кебек, кулны артка куеп, җай гына, салмак кына атлап бара башлады. Моның күңел тойгылары белән дә, җитәкчелек тактикасы белән дә бәйле сәбәпләре бар иде. Әгәр ул аларны куып җитеп, араларына барып керсә, аның шундук хәл-әхвәлен сораша башлаячаклар, аннан да бигрәк, йомышларын, гозерләрен әйтеп, булачак җыелышның олылыгын юкка чыгарачаклар.

Зират турысыннан меңләгән карга күтәрелеп, Каңгыраш ягына таба китеп барды. Карга — акыллы кош, кайчан ялгыз, кайчан көтүкөтү йөрергә икәнен белә. Табигатьне саклау хакындагы законнар гамәлгә аша башлагач, иң нык үрчегәне карга булды. Халык тук яши. Азык-төлек калдыкларын урамга аудара. Шәһәрне инде әйткән дә юк, авыл булып авыл ипи кадерен белми башлады. Балаларыбыз җан иярәренә миһербанлы булсын дип карга үрчетәбез. Ә ул нәгъләтләр борчак җирен борчаксыз калдыра, язга чыксаң, зираттагы каргалар тавышыннан колак тона...

Кышкы юл иңкүлектән үргә күтәрелгән урында бер көчак силос төшеп калган иде. Фәһим абзый түзмәде, иелеп силосны учына алды да, борын турысына ук китереп, иснәп карады. Силосның әчкелтемтатлы исе борынны ярып керде. Шөкер, күгәрмәгән, язын терлекләргә азык мул булачак. Сыерларның күпләп бозаулаган чагы, тамаклары тук, азыклары колорияле булсын...

Тәрәкле кашавай чанага җигелгән күк айгыр гөрселдәп, йөрәк кагып килеп җитте,— председатель белән тигезләшкәч, ярсынып туктады, чанада, дилбегәне ике кулына чорнап, ак мыеклы бабай утыра, кышкы салкынынанмы, ат җиленнәнме, алсуланып киткән бите аның мыегын аеруча ак итеп, көмешләндереп күрсәтә иде.

— Фәһимулла! Саумы-сәламәтме? Әйдәле, утыр әле, урам буйлатып җилләр уйнатып бер әйләндереп килим әле үзеңне! Яшьлекләреңисеңә төшәр! — дип дәртләнеп кычкырып җибәрде ул.

Акчуртан авылында өлкән ат караучы Сөләйман карт, инде җитмеш бишне узып китсә дә, әле җен кебек таза, аңа сугыш зәхмәте дә, замана җилләре дә зыян китерә алмаган иде. Ат җене кагылган бу кеше машиналарның күз явыңны алырлыкларына да төкереп кенә карый: шул да булдымы адәм баласын кызыктыра торган затлы нәмәкәй? Ат, менә ичмасам, дөньяның могҗизасы! Ник шунда галим-голәмә мең төрле рәкитә уйлап чыгармый, ник шунда касманахлар Алла бабайның үзе янына ун тапкыр менеп төшми — Сөләйман бабайның кылы да селкенми. Яшәсен Тимеркүге, яшәсен кашавай чанасы!

Айтуганов аны үз итә. Акчуртанга барган чакта, атлар абзарына кереп, Сөләйман картны күрмичә кайтмый. Ул аны колхозның горурлыгы, дәртсез күңелләрне дәртләндереп, борыны салынганнарның күңелен табып, шаян сүзе һәм ат яратуы белән «Сабанчы»ның данын күтәргән мәзәк бер кешесе дип саный иде.

Бу юлы да Фәһим абзый, кешелеккә кия торган пальтосына печән чүбе ябышыр дип тә тормастан, Сөләйман карт чанасына ауды. Дилбегәне үз кулына алып, атны салмак кына, үз җаена гына атлатмакчы иде, Сөләйман карт шундый итеп бер чөңгереп җибәрде, ярсулы Тимеркүк аларны җан-фәрманга алып китте.

Кисәк талпынудан чак кына егылмый калган Айтуганов, айгырны көч-хәл белән тыеп, көлә-көлә:

— Син әллә тилергән сыер сөте каптыңмы, Сөләйман абзый?.. Ашкынуыңның бер дә чамасы юк,— диде.

Сөләйман карт аның шаяртуын шундук эләктереп алды, чәнти бармагының очын гына күрсәтеп, рәхәтләнеп көлде, янәсе, ул уймак белән генә авыз чылаткан.

Айтуганов аның соң дәрәҗәдә чиста-җыйнак кеше икәнлеген белә, аның аракы-мазар белән шаярмаганын, хәтта бәйрәмнәрдә дә тилергән сыер сөтеннән ерак торуын башкаларга үрнәк итеп сөйли иде. Бу юлы картның мутланып, аның шаян сүзен шундук эләктереп алуына күңеле булды, аның елкылдап торган аксыл каракүл бүрегенә карап әйтте:

— Алай да мут инде үзең, Сөләйман абзый! Бер дә харап! Мондый кәттә бүрекне минем хәтта райком секретаре башында да күргәнем юк.

— И тиеш тә түгел күрергә. Мондый бүрек теләсә кемгә тәтеми, Фәһимулла. Бөтен районга бер бүрек ул. Аны миңа Каракалпакстандагы олы баҗай тектереп җибәрде. Ком сахраларында кылган ашап үскән куй сарыкларының тиресеннән тегәләр икән моны, беләсең килсә! Анда да әле сарыкның үзеннән түгел, бәрәненнән. Сарыкның эченнән ярып алган бәрәннән. Шуңа күрә ул көмеш кебек ялтырап тора. Телисеңме, сиңа да тектереп бирәм?

Председатель хәйләкәр генә елмайды:

— Акчагамы? Әллә берәр этлек хакынамы?

— Ниткән этлек? Ничек оят түгел, персидәтел, укымышлы аграмун, дипутат. Әйттерерсең әллә ни! Нәрсә сорыйм соң мин синнән? Закунга тарттыра торган берәр нәмәрсә сорыйм штули?! Мин бит синнән гап-гади бер нәрсәне гозерләнеп сорыйм: рөхсәт ит син миңа, минем белән бергә кулалмаш ат караучы ике улыма пар атлар җигеп, бизәкле дугаларына кыңгырау-шөлдерләр тагып, атларга җиз таңкәле, шлия-чуклы дирбияләр киертеп, җыен-сабантуйлар вакытында урам әйләнеп йөрергә. Кырантас башына Акчуртанның иң җилле гармунчылары утырган булыр, кырантас артына улларым белән мин арка терәп утырган булырмын, барып кайтыйк әле быел шул рәвешле Казан каласына. Гармуннар уйнасыные, егет-кызлар җырласыные, без үскән чактагы борынгы заманнар кайтсыные...

Фәһим абзыйның чырае сытылды. Очрашкан саен бер балык башы! Очрашкан саен — укалы-чуклы атлар, кыңгырау-шөлдерләр, кала тау җыены. Нигә күзгә төтен җибәрергә, нигә җилбезәкләнергә? Эшлисе эш муеннан, җиде авылның җидесенә дә газ кертәсе бар. Сыерларның нәселен яхшыртасы, күп итеп сөт аласы, райкомның адым саен сөткә, сыерларга бәйләнеп торуыннан котыласы бар. Тузга язмаган мәзәкләр уйлап чыгарып, халыкның башын катырырга кирәкми.

— Юк, анысы булмас,— диде Айтуганов, җитди итеп.

— Ни өчен, ягъни-мәсәлән?..

— Үзең дә беләсең бит ни өчен икәнне.

— Ә менә синең энең Фатыйх булса, һич югы Чукмарлыда эшләгән улың Галинур булса, миңа Калатау җыенына барырга ике дә уйламый рөхсәт итәрләрие. Аларда йөрәк бар, аларда хыял бар — персидәтел Фәһимулла, белдеңме?

— Бу хакта бүтән сөйләшмибез, Сөләйман абзый. Син минем авырткан җиргә кагылма, яме.

— Юк, кагылам. Минем бит сугыштан җанвалит булып кайтканнан соң кырык ел буена ат караганыма нинди дә булса бүләк булырга тиештер бит?

— Без сиңа, Сөләйман абзый, ел саен йөз илле таңкә акчалата бүләк биреп барабыз лабаса! Син аңардан канәгать түгелмени? Тагын нинди бүләк турында сүз кузгатасың син?

— Әй, төкерим лә мин ул акчага! Әнә машинага акча җыйганнар-

га бирегез сез аны, белдеңме, персидәтел? Син миңа пар ат белән, йә булмаса урыслар шикелле тройка атлар белән олы юлдан, авыллар аркылы, урман-кырларны кичеп, Казан каласына шае барып кайтырга рөхсәт ит. Төшерсеннәр ул пар атларны теливизыр кинасына. Ул пар атлар, Тукай бабабызның пар аты кебек, истуриягә кереп калсын. Мәңгелеккә! Менә шул чагында һәммәкәй егетләр әйтерләр: «Кирәкми безгә аллы-зәңгәрле тасма таккан луфкәвәйләр, кирәкми безгә шытыр-пытыр килә торган матайлар, бирегез безгә Сөләйман карт җигә торган пар атларны! Без гармуннар уйнатып туйга барырбыз, кунаклар апкайтырбыз, дияр яшь-җилкенчәк. Белдеңме, персидәтел? — диде Сөләйман карт рәнҗешле карашын яшермичә.

— Юк, белмәдем,— диде Айтуганов.

— Алайса, төш аттан!

— Туктале, син нәрсә, үзсүзләнәм дигәч тә... Сине бит, хөрмәтле ил карты, ветераннар җыелышына чакырдылар. Син бит шуңа килгәнсеңдер?

— Төкерәм мин синең җыелышыңа! Витиран исемен күтәреп йөрүем хәрам булсын! Әйдә, төш аттан, яхшы чакта.

Алар клубка килеп җиткәннәр иде инде. Мәзәкчел Сөләйман белән көрешеп һәм көлешеп алырга дип кашавай чана янына картлар җыела башлады, әмма күңеле тулып түгелгән Сөләйман карт алар белән сүз куертып тормады, атын кинәт кенә кайту юлына борды.

Фәһим Айтуганов аны үгетләргә дә өлгерә алмый калды, өлкән ат караучы Тимеркүккә чөңгереп, дилбегә кагып җибәрде. Тук ат уйнаклап, баскан төшендә бер биеп алды да, тояклары астыннан каты кар кисәкләрен ветераннар өстенә чәчеп, җилләр уйнатып китеп барды...

## 2

Акчуртанның хөрмәтле картын шулай котмагәндә үпкәләтеп куюы Айтугановның кәефен алды.

Культура йорты эшеге төбендә председательне каршылаган Мөхәммәт Сираҗиев моны беренче булып сизде:

— Нәрсә, Фәһим Сабирҗанович, авырмый торгансыздыр бит?

— Каян килде әле андый уй, Мөхәммәт?

— Чыраегыз үзгәребрәк киткән...

— Дөнья булгач, үзгәрер дә... Зиннур кайда?! Авыл Советы рәисен әйтәм? Ул соң ветераннар хакында сөйләргә тиеш түгелме?

— Ул белә вазифасын, Фәһим абый,— дип иплән кенә әйтте партком секретаре, җыелыш башланганчы аның председательне әйбәт кәефтә тотасы килә иде.

Мөхәммәт шуңа күрә аны президиум өстәле янына алып менәргә ашыкмады. Картларның кәефе ниндирәк, бүген бирегә җыелуны хуплыйлармы-юкмы — шуларны мыегына урап йөрсен.

Тик алар теләкләренә ирешә алмадылар. Культура сарае мөдире бинаны җылытырга оныткан, тамаша залы суык, картлар бүрекләрен салмыйча, карчыклар мамык шәлләренә уранып утыралар иде.

Бу исә Айтугановның тагын бер мәртәбә кәефен кырды.

Җыелышны әзерләүче авыл Советы нәрсә караган? Алдан тикшерсә булмыймыни? Моңарчы ул үз тирәмә намуслы һәм җаваплы кешеләрне җыйдым дип йөри иде, аларга күшып торуны да, аларның эшләрен тикшерүне дә кирәкмәс бер нәрсәгә саный иде. Баксаң — әнә клубны да җылытып куймаганнар. Ә бит мичләрне утын белән ягасы түгел, күмер белән ягасы, аның өчен хезмәт хакы алып торучы кочегарлар бар. Алардан таләп итәргә генә кирәк.

Башка чакта холкының сабырлыгы белән аерылып торган председатель бүген сабырсызлана: иң җаваплы көнне, шушы колхозга көчләрен түккән, сугыш юлларын узган ветераннарны колакчын бүректән, әбиләрне мамык шәлләрдән боектырып утырту бер дә килешкән эш түгел... Залда җылы булмау әле быел гына өлгерткән Культура сараен да, гәрчә утлары балкып янса да, котсыз итеп күрсәтә иде.

Ил картларының күзенә чалынмас өчен, Айтуганов башта сәхнә артындагы бүлмәгә, шул бүлмәдән клуб мөдире кабинетына чыкты.

Бер ел элек кенә Казанның Культура институтын тәмамлап кайткан япь-яшь кызга — Алмазия Шәяхмәтовага әйтте:

— Сеңлем, нишләп зал суык? Әллә бүген зур җыелыш буласын әйтмәделәрме сезгә?

— Әйткәннәр иде дә, и абый...

— Ә сез клуб үзеннән-үзе җылыныр дип уйладыгыз мәллә?

— И абый... уйламадым да... Бәләкәй сеңлемне детсадка урнаштырып йөргән идем, клубны җылытасы барлыгы бөтенләй дә башымнан чыгып киткән...

— Сез сеңлем, болай итегез: хәтерегез начар булса, атналык кенәгә булдырыгыз, көн саен эшлисе эшләрегезне шунда язып барыгыз. Эшләнгән берсе янына плюс билгесе куегыз. Шуннан хәтерегез кабат кайтыр.

— И абый... гафу итегез инде бер юлга,— дип, Алмазия комач кебек кызарды.

— Мин анысы гафу итәрмен, тик менә картлар-карчыклар гафу итәрме, алар бит суыктан бөкшәеп утыралар, барыгыз, кочегарларны эзләп табыгыз, хәзер үк ягып җибәрсеннәр, без сөйләшкәли торганчы җылынып та җитәр, бәлкем.

Сөрмәле зәңгәр күзләре мөлдерәп тула башлаган Алмазия:

— И абый...— дип каршы сүз әйтә башлаган иде, Айтуганов аны ярты сүздән өзде:

— Беләм, үзешчәннәргә кием әзерлим, димәкче буласыз. Концертка чаклы әле бер сәгать вакыт бар, йөгерегез кочегарлар янына, кайтып җитәсез әле, өлгермим дисәгез, кием шкафының ачкычларын миңа калдырыгыз, ансамбль җитәкчесенә үзем тапшырырмын,— диде.

Айтуганов зал ягына чыкканда, авыл Советы рәисе Зиннур Мәгъсүмов килгән иде инде. Өстендә каеры тун, башында бүре бүрек, аның йөнтәслеге йөзенең ябыклыгын бераз каплап, киметеп тора иде.

Айтуганов сәгатенә карап алды,— көндезге бер җиткән, башлап җибәрергә кирәктер. Мәгъсүмов беренче булып доклад ясарга тиеш булганга, Айтуганов аңа бинаның суыклыгы турында әйтеп тормады, егетне каушату кирәкмәс, дип уйлады.

Партком секретаре сәхнәгә, кызыл постау япкан өстәл янына чыгып баскач, Айтуганов тынычлангандай булды. Мөхәммәт, клуб суык булса да, өстеннән пальтосын салган, башы да яланбаш, куе зәңгәр төстәге костюмы, пинжәк якасыннан күренгән йон свитеры — барысы да аңа килешә, ул хәтта кырык яшендә түгел, утыз яшьләрендә генә булып күренә иде.

Башта ул җиде кешедән президиум сайлатты. Тавышы калын, әмма дорфа түгел, йомшак иде.

— Ил буйлап сугыш һәм хезмәт ветераннарының Советлары төзелә. Без дә калышмыйк, дидек. Көн тәртибенең беренчесе шул булыр. Ветераннар Советының уставы белән танышырбыз. Икенчесе — үзебезнең Советны төзербез. Аннары ветераннардан район слетына делегатлар сайларбыз. Дүртенчесе — сугыш ветераннарына орденнар тапшырырбыз. Ә азактан — өлкәннәргә ихтирам бу-

лыр — җырчыларыбызның, биючеләребезнең концертын күрсәтербез. Кем дә кем шушы көн тәртибе белән риза, рәхим итеп кулларыгызны күтәрегез...

Арткы эскәмияләрдән:

— Торып тор, Мөхәммәт, торып тор! — дип кычкырган көчле тавыш ишетелде.

— Кем ул? Чыгып әйтегез сүзегезне,— диде партком секретаре.

— Әйтербез дә, әйтербез дә! — дип, башына колакчыннарын төшереп иске бүрек кигән, кәҗә сакаллы бер абзый рәт араларыннан уза башлады. Сәхнәгә таба кулын сузып:

— Карале, энем, Мөхәммәт. Мин бит персидәтелебезгә сорау бирермен дип килгәнием, аның бит атчуты була дигәннәрие, ә нигә, бүген атчут булмыймыни инде?

— Юк, Зөлкәрнәй бабай, бүген отчет булмый. Ул хакта бригадаларга әйтелде, отчетны тагын бер айдан ясыйбыз. Әле уйланып җитмәгән яклары килеп чыкты,— диде Мөхәммәт, Зөлкәрнәй картка ихтирам белән карап.

Карт җилкәсен җыерды:

— Ә мин сорауны кемгә бирәм инде, алайса?

— Соравыңны онытма, Зөлкәрнәй бабай, әзерләп тор, председатель монда, вакыты җиткәч, бирерсең.

Карт никтер иске колакчын бүреген башыннан салып, җилкәләрен асылындырып, арттагы урынына китеп барды.

Мөхәммәт көн тәртибен раслатты. Әкрен генә, иренеп кенә куллар күтәрелде. Бу хәл сәеррәк тоелды Айтугановка, ник дигәндә, исәп-хисап җыелышында халык бик җанлы була торган иде. Куллар күтәрелеп, алардан урман хасил булгач кына, нигә кулларның әкрен күтәрелүен аңлады, хәтта баштагы уй-тойгысыннан уңайсызланып та куйды. Мылтык тотып, көрәк сабы тотып бирчәйгән куллар. Агач тармаклары төсле чатлы-ботлы куллар. Боларга игътибар итми мөмкин түгел иде.

Авыл Советы рәисе Мәгъсүмовның беренче җөмләсе аны гына түгел, залны да сискәндерде. Илдә 50 миллион ветеран бар. Шуларның 520 се Балдамар авыл Советына карый. Сугышка безнең колхозның җиде авылыннан 803 кеше киткән, 120 кеше әйләнеп кайткан. 683 кеше сугыш кырында ятып калган. Шушы корбаннарны истән чыгармас өчен, сугыштан исән кайткан фронтовикларны һәм хезмәт ветераннарын бүгенгесе көнне иҗтимагый тормыштан аермас өчен, Ветераннар Советы төзелә.

Ветераннар Советының үз эмблемасы һәм печате булырга тиеш.

— Доклад бетте. Кемнәрдә сорау бар,— диде партком секретаре, урыныннан торып.

— Карале, пичәте бар дидеме? Нишлик без ул пичәт белән? Сугыш вакытында да барые пичәт, аңа карап тамак туймады, тишекле сутыйларга эшләп, ач утырдык.

Моны шәл өстеннән мескен бүрек киеп куйган ачы тавышлы тол хатын кычкырды.

— Әйтмә дә, сөйләмә дә! Пичәт, имеш. Булмасын аның пичәте, җиме булсын! Әнә Казанда җанвалитларга, витиралларга аерым кибете бар ди, бишәр кила ит, индинский чәй, чүпер-мазар бирәләр, ди. Ай саен. Белдегезме, катыллар? Ә бездә нәрсә: шымытыр! Әнәтерәк ике йөз дә илле гырам май биргәлләрие, кибеттән кайтканчы эреп агып бетте. Әдәм ыстрамы! Кем моңа әтбит тота? Тотамы, жукмы?

Аңа төрле яктан кычкырган тавышлар кушылды, зал тавышлана башлады. Мөхәммәт ат дугасына тага торган җиз кыңгырауны бик озак кагып, халыкны тынычландырды. Кыңгырау кагудан тыш

ул залны буе белән, калын тавышы белән буйсындырды. Айтуганов аның хакында үз уйларын да уйлап алырга өлгерде.

Мөхәммәт — Балдамарныкы. Түбәннән күтәрелде, халык арасыннан. Йөк төяүче булды, шофер. Тырышлыгы, җәптәшлеге халыкка ошады. Идарәдә дә күрделәр. Авылга баллоннар белән газ кайта башлагач, Сиражиевны Казанга җибәреп, укыттылар. Ул эшне дә җиренә җиткереп башкарды Сиражиев. Аннары аны Балдамар авыл Советы рәисе итеп сайладылар. Фәһим абыйсы үзе тәкъдим итте егетне. Тотынган бер эшенең төбенә төшә, җелеген таба белә икәнен аңлап тәкъдим итте. Мөхәммәт авылның тәртибе өчен җанын-тәнен аямыйча, көнне төнгә, төнне көнгә ялгап эшләде, утызынчы еллардагы «силсәвит» кодрәтенең беткәнлеген, кулаклар дип урта хәлле крестьянга каршы көрәшкән этәч заманнар узганлыгын белеп һәм аңлап эшләде. «Сабанчы» колхозы биләмәсенә урнашкан больницаны, аптеканы, картлар йортын, китапханәне, урта мәктәпне, күперләрне, елга-суларны күз уңыннан ычкындырмады. Үлемҗитем булса, иң беренче ул килеп җитә, клубтамы, кыр станындамы берәр акылсызы эчеп, тәртип боза башласа, Мөхәммәт аны үзенең «тимер кулыннан» уздыра иде. Юк, закон капчыгы түгел Мөхәммәт, статья белән, өстәл сугулар белән дә эш итми, әгәр алай эшли торган булса, Айтугановның әдәпле, итагатьле гамәлләре алдында ул шундук күсәк җитәкче булып калыр иде, Балдамар кешеләре аны бер көн дә тотмыйча, яңа бер кешене сайлап куйган булырлар иде.

Табигать биргән сәламәт акылы, уйлый һәм уйлана белүе, барыннан да бигрәк, еллар буе күреп килгән үрнәк-өлгесе — Фәһим Айтугановның тәҗрибәсе аны олы юлга алып чыкты. Ул үзе халыкны ихтирам итәргә, халык аны санга сугарга өйрәнде.

Айтуганов аның күзгә күренеп үсүен югары бәяли, аңа авыл Советыннан парторглыкка күчәргә кирәк дип, лаеклы дип саный иде. Һәм ул аның партоешмага сайлануына ирешә алды.

Озын буйлы, затлы нәселдән килә торган нәфис битле, дулкынланган чагында ярсуы тышка бәреп чыкмый, битенә алсулык булып кына җәелә торган ир уртасы бу кеше белән алар инде менә ничә еллар бергә, кулга-кул тотынып эшләп киләләр, әмма Мөхәммәт остазының һәр сүзенә ләббәйкә дип торганга түгел, үзе инанган иманга турылыклы булганга янәшә эшли алалар. Теге чакта булачак кияве Максуд Каюмов мәсьәләсендә икеләнә башлагач, Мөхәммәт председательне җиңде. Бүген менә кара инде — председательлектән китәргә тәмам күңелен беркетеп бетергән Фәһим абзыйсын бит ул нинди хәйләкәр юл белән башка юнәлешкә борып җибәрде: син, янәсе, башта кордашларыңны, синнән дә өлкәнрәк ветераннарны тыңла, алар сүзенә колак сал, шуннан соң китү-китмәү мәсьәләсен уйлашырбыз.

Мөхәммәт залда тынычлык урнашуга ирешкәч, ветераннарны активрак булырга чакырды, тагын кемдә сораулар бар, тик төрлегез төрле яктан кычкырмагыз, кул күтәреп кенә әйтегез, диде.

Бераз тын утырдылар — уйлыйлар иде бугай.

Озак еллар «Чапай бүрек» киеп йөргән Әхмәдиша карт торып басты:

— Энем, Мөхәммәт, син әйтәсеңме, персидәтелебез әйтәме, аңнатып бирегез әле миңа, пажалысты, ветераннарга газ ише нәмәстәләр керткән чагында өлгүтә булыр дигәннәрие. Дөресме шул сүз, түгелме?

Ни Сиражиев, ни Айтуганов җавап бирергә өлгермәде, шәл өстеннән бүрек киеп куйган ачы тавышлы тол хатын тагын калыкты:

— Әхмәдиша бабайлар, Сәмигуллалар, ярый, сугышта булгал-

лар, аларга өлгүтәсе дә, бүтәне дә булыр, ә безгә, катылларга нәрсә? Без дә сугыш вакытында арт санны киптереп ятмадык. Үләрне-калырны белми эшләдек. Витиралларга җал җорты буламы? Әгәренки булса, без, катыллар да, шунда беррәттән җал итеп кайта алабызмы?

Берсе утырып җитмәде, җыелыш саен әллә ничә мәртәбә чыкмый калмый торган Зөлкарнәй карт тагын күтәрелде:

— Минем сорау силсәвиткә. Мин кәнсәләргә менеп багана сораганыем. Капка баганасы. Бирмәдең, Зиннур энем, иптәш Мәгъсүмов. Ә бит багана күп кайтканые. Син әйттең, үзебезгә дә җитми әле, дидең. Ә менә бу карт-корыны кайгырту булып чыгамы соң? Әллә чыкмыймы? Белмим инде мин, җәмагать. Рас минем гозерем үтәлми икән, ветеран буламмы мин, юкмы?

Авыл Советы рәисе яшь иде әле. Дәшмичәрәк калса да булыр иде дә бит. Тик ул үзен ветераннарны кайгыртмый торган итеп калдырырга теләмәде. Моның бик җитди тагын бер сәбәбе бар, җыелыш башлангач, өстенә күн тужурка, башына җөнтәс фуражка кигән, җилкә аша кыеклап сумка аскан таныш булмаган бер кеше килеп керде. Җитез хәрәкәтләренә, бер дә тартынып-нитеп тормастан иң алдагы эскәмиягә килеп утыруына караганда, юк-бар, тегендимондый гына кеше булырга охшамаган, йә ул Казаннан килгән инструктор, йә газета хәбәрчесе булырга тиеш. Ихтимал, соңгысыдыр. Юкса ул сумкасыннан блокнот чыгарып, Зөлкарнәй карт сүзләрен яза башламас иде. Күр дә тор: Казан газеталарының берсендә бастырып та чыгарыр. Мәскәүдә үк булмаса әле. Йөр син шуннан соң дөя түгеллегеңне исбатлап!

— Юк, Зөлкарнәй бабай, мин алай ук димәгәнмендер. Сез булган хәлне дөрес хәбәр итмисез... Хәтерегез саеккан!

— Аллаһы тәгалә шаһит, якты көннең чыраен күрмим, шулай дидең, энем Зиннур, билләһи газим, шулай дидең!

Мөхәммәт, эшләрнең тирәнгә китә баруын, азагы талаш белән бетәчәген аңлап, килеп чыккан хәлне, кызып бара торган бәхәсне йомшарту өчен, дилбегәне тиз генә үз кулына алды. Микрофон аның җай гына әйткән сүзләрен шактый ук көчәйтеп халыкка җиткерде:

— Хөрмәтле ил картлары, әбекәйләр! Булмаса, без болай итик әле: безнең Балдамар авыл Советына караган ветераннарның Советын сайлыйк. Аннары менә шул Советка гозерләребезне әйтербез. Килештекме шуңа?

— Килештек!

— Давай сайлат!

— Бик яхшы. Колхоз идарәсе, авыл Советы, партком — өчебез берьюлы киңәшкәннән соң шундый карарга килдек: Ветераннар Советын тугыз кешедән сайларга. Каршылар юкмы, барыгыз да шушы карар белән килешәсезме? Рәхим итеп кулларыгызны күтәрегез. Каршылар? Юк. Битарафлар? Юк. Бертавыштан дип язып куй, Сәрбиназ.

Партком секретаре тугыз кешенең һәрберсе хакында җылы сүз әйтеп, сөйләп-бәяләп чыкканчы халык тынычланып бетте. Берәмберәм тавышка куйды.

— Ярар. Инде менә без ветераннарның үз Советларын да сайладык. Аның бит, үзегезгә мәгълүм, башлыгы да булырга тиешләр бит.

— Дөрес! Көтү көтүчесез булмый! — дип, Зөлкарнәй карт янә дөньяда барлыгын белдерде.

Кеткелдәп бер көлешеп алдылар.

— Безнең авыл Советы территориясендә җиде авыл бар. Балдамар, Түбән Камышлы, Югары Камышлы, Акчуртан, Каңгыраш,

Кучәртау, Мүк авылы кешеләреннән сорашып чыктым мин — Ветераннар Советының башлыгы, ягъни председателе итеп Кәтиев Хәбибрахманны сайлыйк, диләр. Сугыш һәм хезмәт ветераны. Фронттан яраланып кайткач, авыл Советы рәисе, Акчуртан әле безгә кушылмаган чакта, анда колхоз председателе булып эшләде. Хәзергесе көндә «Сабанчы»ның сыйфат комиссиясе председателе, ягъни, бүгенгечә итеп әйткәндә, госприемка кебегрәк була.

Сабырсыз Зөлкарнәй карт аваз салды. Торды, таянып тора торган артыш таягын алга сузды:

— Озак үгетләмә, кем, партионный сиклитар, Хәйберинең кем икәнен, мичкә керсә, катасыннан таныйбыз. Ату күп итеп үгетли башласаң, күңелгә коткы керә башлый. Әнә бит Сталинны бөек тә бөек дип кычкырдылар. Ә ул, бактың исә, бөек түгел, кыек икән. Давай, булмаса, кул күтәрт, энем.

Кул күтәртте Мөхәммәт: ризалар.

Шуны халыкка әйтеп тә бетермәде Сиражиев, шәлле бүрек тагын чырыйлап кычкырып җибәрде:

— Син, Исмәгыйль Мөхәммәте, әммәкәй кеше дә бертавыштан риза дип, тота-каба гына әйтеп ташлама әле, җәме. Менә мин риза түгел. Хәйбери — Акчурталлыкы. Акчурталлар — явыз халык, яман да үчлекле. Хәтереңдәме, ун җыллар моннан элгәре алар, сүз берләшеп, безнең персидәтелебез Фәһимулланы урыныннан алып ташларга дип килгәлләрие. Менә мин сезгә туп-турыдан туп пашул дип шуны әйтәм: Кәти Хәйберие минем хәлемә керәчәкме, җукмы? Әллә башила киресен киртекләп, таякка тамга салып утырачакмы? Син, энем, Исмәгыйль Мөхәммәте,үзең үк әйттең, Хәйбери түрә булган кеше, диден. Хәзер түрәләрнең гамәлен җиз иләктән үткәзеп, ривәзия ясый торган замана. Без аны күз алдында анадан тума чишендереп, тикшереп карыйк, кем белә, әллә бәлкем, аның чирле-чиңке җире бардыр, күңелне кайтара торган бүсерләре бардыр?..

Төрле җирдән төрле тавышлар кычкырды:

— Туктатыгыз инде шул пырдымсызны!

— Чистый! Теленә ни килсә шуны...

Мөхәммәт, кыңгырау кагып халыкны тынычландырды да, шәл өстеннән мескен бүрек киеп куйган тол хатынга дәште:

— Сез моның белән нәрсә әйтергә телисез, Пәтихәттәй?

Партком секретаре көтелмәгән шушы соравы белән кортканы ык-мык итеп торырлык хәлгә куймакчы иде. Тик ул бер нәрсәне исеннән чыгарган: Пәтихәттәйне рупор итеп әзерләгән Майпәрвәз утыра иде әле аның янында. Пәтихәттәй «тишекле сутый» заманында эшләгәннәре өчен 40 сум гына пенсия ала, ә Майпәрвәз аңа өзлексез: «Сиңа алай гына тиеш түгел. Син Мәскәүгә язып җибәр, анда гаделлекне тапмый калмаслар»,— дип гел котыртып тора, Пәтихәттәй Мәскәүгә ничек язарга икәнен белми, күңелендә җыелганнарны җыелыш саен бер чыгарып аудара иде.

Майпәрвәз, Пәтихәттәйне санга сукмаска теләүләрен күреп, үзе дә дөрли башлаган учакка бер пүлән ыргытмакчы булды:

— И түрәләр, түрәләр, берсен-берсе күрәләр, безнең ише мескеннәрдән авыз җырып көләләр! — дип кычкырды да урынына утырды.

Халык гөр килеп көлде.

Майпәрвәзнең теләсә кайчан такмак чыгара алганлыгын беләләр, аңардан бераз шүрлиләр дә иде. Бу юлы да шулайрак булды. Мөхәммәт Сиражиев беренче рәттә утырган корреспондентның иелеп, кызу-кызу язганын күрде, үзенчә шундук нәтиҗә ясады: ә бит аның, халык белән исәпләшмәделәр, хезмәт ветераны Маһипәрвәз әбинең сүзләрен кибәккә чыгардылар, дип язып җибәрүе мөмкин.

— Тагын кемдә нинди уй бар, иптәшләр? Әйдәгез, гел җые-

лып тормыйбыз, очрашкан чакта әйтәсе сүзебезне әйтеп калыйк,— диде партком секретаре һәм шул чакны алгы рәттә йокымсырап утырган түгәрәк кама бүрекле, ап-ак сакаллы бер картның урыныннан кузгала башлавын күрде.

— Син сүз әйтәсеңме, Миңлебай бабай?

Бик сузып кына, бик әкрен генә сөйли Миңлебай карт. Моны белә кордашлары. Әмма заманында аның иң оста тугымчы булуын, иң матур кашавай чаналары ясап, тирә-юньгә дан казануын да беләләр, ихтимал, шуңадыр, аны тыңлыйлар, ашыктырмыйлар.

— Син... энем... Хәммәт... Исмәгыйль кордашның... әә... ийе... Исмәгыйль кордашның... олы улы бит әле син. Әйеме? Син бит, энем... Хәйберахманны тавышка куйдың бит ийе...— дип, бөтенләй тормозланган төсле, чамадан тыш сузып, сүз саен пауза ясап сөйләргә кереште бабай.— Монда утырган карт-коры, ягъни минем кордашларым, әммәкәе дә Кәтиев Хәйберине сайлыйбыз, дип әйтте бит. Пәтихә кортка сайларга теләми икән, сайламасын. Ийе. Сайламасын. Йомышы чыкса, гозере төшсә, Пәтихә кортка, әйе, ни... Хәйбери янына килә алмас. Хәзер син, Исмәгыйль кордаш улы Хәммәт, дилбегәне Хәйберинең үзенә тоттыр, булмаса. Үз җаен үзе карасын, үзенә кирәкле замнарын, пумнарын үзе сайлатсын.

«Менә бу акыл»,— дип нәтиҗә ясады партком секретаре һәм шундук үзе белән янәшә утырган Кәтиевкә дәште:

— Әйдә, Хәбибрахман абзый, башкарып чык шул эшне. Ил агалары сиңа ышаналар.

Арба чәкүшкәсе хәтле генә бәләкәй бер карт, урыныннан торып, пальтосын салды, аны буш бер урындыкның аркасына элгәч, сул күзенә кыеклап бәйләгән ак марляны төзәткәләп, аннары чокыраеп әчкә баткан битен учы белән сыпыргалап:

— Клуп эче җылынып китте, миңкә яктылар, ахырысы, пәлтәне салып сөйләмичә булмас,— диде. Миңлебай картның капма-каршысы буларак, ул бик кызу һәм бер генә сүзне дә йотмыйча, төгәл сөйли иде.— Кая, алдан ала әзерләп куйган исемлек бардыр ич, бир әле, энем, миңа шуны,— дип Сиражиевка таба кулын сузды.— Әһә! Монда Фәррах дип язылган. Элекке тегермәнчедер бит инде ул. Барыгыз да беләсезме?

— Беләбез!

— Сузма, тавышка куй!

— Гадел кеше. Намусын сатмас, иншалла!

— Сайладык, җәмәгать. Кем дә кем Фәррах тегермәнче и шулай ук ветеран минем урынбасар булсын ди, шулар рәхим итеп газиз кулларын күтәрә. Сана булмаса, Мөхәммәт.

Аннары ул шулай ук ашыкмый гына җеген-җеккә китереп, әмма әйтер сүзен төртелеп тормастан, бик кызу сөйләп, Советның секретарен сайлатты.

— Булгандыр бит инде, шуның белән бүгенге минем вазифа беткәндер бит, иптәш партком? — дип ихлас сорады.

— Булды! Булды! Әйбәт итеп сайлаттың! — дип кычкырды бүрекле Пәтихәттәй.

Такмакчы Майпәрвәз аңа кушылып:

— Озак тор, тозак кор, каракларны аула, ялкауларны каула, әммәдәгеп витиралларга кирәген даула,— дип халыкны тагын көлдерде.

Фәһим Айтуганов җыелышның кызыклы һәм кирәкле сукмактан баруына күңеле булып тыңлап утырды. Аның да сөйләр вакыты җитә торгандыр инде. Юк икән әле, аңа түгел икән әле, район слетына делегатлар сайлыйсы бар икән әле. Анысы озак булмады, каршы чыгып торучы да күренмәде. Сәбәбе гади — слетка беренче делегат итеп Хәбибрахман Кәтиев, икенчесенә Зөлкарнәй карт, өченче-

сенә Акчуртанның өлкән ат карауичысы Сөләйман абзый күрсәтелде.
Хәбибрахман Кәтиевне дә, Зөлкарнәй картны да хупладылар, Сөләйман абзый исеме әйтелгәч, залдагылар үзара гөжләшеп алдылар.
— Нишләп үзе юк?
— Булырга тиеш. Әле генә Тимеркүген кашавайга җигеп килде!
— Әллә авырып киттеме, ходаем?!
Залның гүләве бераздан тынды. Фәһим Айтугановның күңелендәге гүләү генә тынмады. Юкка үпкәләтте ул аны. Кирәкмәс иде мондый көнне турыдан-туры каршы килергә, карарбыз, киңәшербез, дип әйтергә иде.
Партком секретаре аңа, фронтовикларга орден тапшыруны йөкләгәч, күңелендәге борчылу арта төшкәндәй булды. Картлар Ватан сугышы орденын алырга дәртләнеп килерләр, дип уйлап, моңа нык ышанып утыра иде ул, ни дисәң дә әлеге орден аларның иң кадерле, иң газиз истәлекләрен яңарта торган, аларны олылый торган бүләк бит.
Беренче өч кешенең исеме әйтелде. Алары килмәгән булып чыкты. Орден тартмаларын читкәрәк алып куйдылар. Шулай итеп, бәйрәм тантанасы бетте. Бүләк алучылар үзләре биредә булмагач, халык кул чабарга да, чапмаска да белмичә аптырап калды.
Дүртенче кешенең исем-фамилиясен әйттеләр. Килүче күренми. Мөхәммәт, микрофонга иелеп, фронтовикның исемен тагын бер кат, бу юлы кычкырыбрак әйткәч кенә арткы рәтләрдән кемдер кыймылдап, йөрү юлына чыкты, бик әкрен генә килә башлады. Юк, ул килми, ул үрмәли, чын мәгънәсендә үрмәли иде.
Айтуганов үзләренең уң як күршесе Баһави картны таныды, аның сәхнәгә менеп җитә алмаячагын абайлап, үзе аска, халык янына төште. Халык әле Айтугановка, әле Баһави картка карап, килүчене көтә, ә тегесе кызуларга уйламый да, кыштыр-кыштыр үрмәләвен белә иде.

*Ахыры киләсе санда.*

## ШИГЪРИЯТ

# Нажар Нәҗми

## Халкым арбасы

*«Дружба — дружбой, а служба — службой».*
Рус халык мәкале.

Хезмәт кешене бар иткән,
Хезмәт — кешегә тормыш.
Хезмәт — җирдәге гүзәллек,
Кешегә һава, сулыш.

«Хезмәткә дан!» дибез һәрчак,
Кайчан ул булган дансыз?
Хезмәт — канда! Ә тере җан
Кайчан соң булган кансыз?

Мактану юк — гомер буе
Мин хезмәт юлы үттем.
Җиремә һәм милләтемә,
Халкыма хезмәт иттем.

Әйе, тормышта дус кирәк,
Дуслыкка дусча шатмын.
Тик мин башта үз халкымның
Арбасын тарткан атмын.

## Үз кояшы белән

Үтеп барам басу юлы буйлап,
Сөзәк кенә яшел үр аша.
Миңа таныш күз күреме җирләр
Офыкларга барып тоташа.
Күз күреме җирләр... Күз күреме дөнья —
Туган-үскән ягым киңлеге.
Шул кырларга, урман, таулыкларга
Береккән лә минем кендегем.
Күз күреме җирләр... Күктә кояш
Шушы кырлар, таулар өстендә.
Кояш бирәү, Җир шарына бирәү,
Ә ул бирәү бу як өчен дә.
Көн дә чыга ул үз урынына,
Үз урынына барып бата ул.
Бу як, гүя, аның туган ягы —
Кичен китсә, иртән кайта ул.
Үз кояшлы, димәк, һәрбер сукмак,
Һәрбер үзән, һәр юл, һәр төбәк.
Үз кояшлы, димәк, шушы җирдә

---

Нажар НӘҖМИ */1918/ — күренекле шагыйрь, РСФСР һәм Башкортстан Дәүләт премияләре лауреаты, башкорт, татар, рус телләрендә дөнья күргән күпсанлы китаплар авторы. Шигырьләре журналыбызда күптәннән басылып килә. Уфада яши.*

Туып-үскән һәркем — һәр йөрәк.
Шушы җирдән минем йөрәгем дә,
Шушы җирләр белән җан ашлы.
Кеше җаны, туган җире кебек,
Үз кояшы белән кояшлы.

*

Шулдыр инде, шулдыр инде үзе
Үкенечле гомер азагы.
Авыр икән (ничектер ул үлем?)
Әкренләп сүнү газабы.
Алга бардык... Якты киләчәкләр
Юк ул, юк ул — артка чигүдә.
Алга барам, димәк, яктылык бар.
Киләчәк бар минем сүнүдә.
Мин дә әле акыл сатам кебек,
Фәлсәфәле төсле язганнар.
Бер уйласаң, азмы дан казанды
Шигырьләрдә акыл сатканнар.
Чыкма, җырым, йөрәк юлыннан син,
Ни булса да булыр азагы.
Йөрәк яна, диләр (акыл янмый!),
Мең яшә син, яну газабы.

*

Урамда ул күреп, туктатты да:
«Җырың белән елатасың...» — диде.
(Исемен дә аның белмимен мин)
Минем исә түбәм күккә тиде.

Елату да, көлдерү дә безгә
Җинел түгел — шуны белсә иде.
Бу җыр елатса, ах, икенчесе
Күз яшьләрен аның сөртсә иде.

## Тукта син, гүзәллек!

*О күз ачып йомган ара.*
*Син гүзәлсең — туктасана!*
*Гете*

Киң күңелгә фани дөнья иркен —
Һәр кешегә җирдә урын бар.
Әдәбият! Сәнгать! Ә тик синең
Урының һәм күңелең булды тар.

Гомер бакый шулай... Хәзер инде
Бу тарлылык иске — безгә ят.
Күңеле киң — адым саен талант,
Даһилыкка күпме кандидат.

Күтәрелдек биек түбәләргә,
Ирешмәгәннәргә ирештек.
Гүзәллекнең алтын түбәсендә
Балкый бара ялган дөреслек.

Тукта син, гүзәллек! Ялганлыклар
Кунмаганмыни соң, чамасыз!
Тукталып бер кагынып алсаң иде...
Юк! Туктарга син бит чарасыз.

*

Чүп үләнен чәчеп үстермиләр...
Чүпле кырын хуҗа утаган.
Җинаятьләр утап бетергесез —
Чәчеп үстергәнгә охшаган.

Ни чәчәбез җиргә, йөрәкләргә?
Без кылганнар хакмы, хатамы.
Ни чәчсәң бит шуны урырсың, дип
Халык әйткән... Безнең хактамы?

## Көнгә чыксам...

«Юлга чыксаң, төнгә калма
Юл яхшысы — якты күздә...»
Көнгә чыксаң, шушы сүзне
Әйтә иде әни безгә.

Юлга чыгу, төнгә калу —
Гадәти хәл миңа һаман.
О дөньяның үзгәрүе! —
Көнгә чыксам, төнгә калам.

*

*«Өмет белән яшәү күңелле...»*

Өмет һәрчак әйдәп торды мине,—
Шайтан гына, диләр, өметсез.
Тик гомерем хаталардан торган —
Хаталануларым өзлексез.

Кем гомере бер хатасыз икән?
Шундый уй да гөнаһ шикелле.
Бу дөньяда, димен, бер гөнаһсыз
Яшәве дә гөнаһ түгелме?

## Көймәдә

Дәрьяның да, гомернең дә
Ярлары бар — ике яры.
Чыгып киләбез бер ярдан
Без икенче ярга бары.

Без көймәдә... Утырганбыз
Ал белән дә, арт белән дә.
Һәркемнең үз урыны бар —
Шулай кирәк тә гамәлдә.

Беребез бүген койрыкчы.
Ә койрыкчы бага алга.
Су ярып килгән көймәне
Алып бара ерак ярга.

Мин ишкәкче — барыр ярга
Утырганмын арка куеп.
Үзем ишәм, вакыт-вакыт
Карап куям башны борып.

«Боргалама башыңны! — дип,
Койрыкчыбыз әйтә яман —
Ишүеңне генә бел, — ди, —
Көймәне мин алып барам».

## Мөхәммәт Мәһдиев

# АЧЫ ТӘҖРИБӘ АВАЗЫ

ИСТӘЛЕКЛӘР

### Сүз башы

*Халык хәтле халыкка хезмәт итүнең төрле юллары бар, әмма явызлыкны, ялганны, бозыклыкны күрсәтә белү дә шулай ук файдасыз нәрсә түгел дип уйлыйм, чөнки бу эш игелеклелеккә һәм хакыйкатькә тулысынча теләктәш булуны күздә тота.*

М. С. Салтыков-Щедрин



Хәзер, мин яшем буенча, мемуар язарга үземне хаклы дип исәплим. Хәзер дә язмасаң — кайчан? Бу әсәрдә — чынлыкта булган шәхесләр, минем баштан узган хәлләр. «Техницизм» тарафдарларын кисәтеп куйыйм: монда буровой да, торбалар да, насослар, агрегатлар да юк. Әле шул буровойлар сытып, имгәтеп бетергән Татарстан табигатенең сыкрануын ишетеп яшибез бит. Әдәбият — ирек эше, вөҗдан эше. «Технарь»лар да язсын, без дә языйк. Укучы үзе теләгәнне укыр, уку да ирекле. Узган ел бер иптәш мине матбугатта тәнкыйтьләп чыккан иде. Имеш, мин гел авыл турында язам. Ул автор калын-калын әсәрләр язгалаган иде бугай. Топонимия буенча акыллы гына мәкаләләре дә чыккалады булса кирәк. Менә бит иптәшкә кайсы өлкәдә эшләргә! Хәер, ул да ирекле.

Шулай, истәлек-повесть тәкъдим итәм укучыларга. Тик бер искәрмә белән: кайбер типларның исем-фамилияләрен үзгәрттем. Укысалар, үзләрен танымый калмый инде алар. Шулай итеп, сезне сәяхәткә чакырам. Бу юлы инде — шәһәр тормышына...

*1989, сентябрь.*

---

Мөхәммәт МӘҺДИЕВ *(1930) — язучы, әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче, Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе, «Фронтовиклар», «Торналар төшкән җирдә», «Кеше китә — җыры кала», «Бәхилләшү» һәм башка роман, повестьлар авторы. Казанда яши.*

# Яңа Чуриле.

«Аваз,— дим,— ишетеләсең, әйтче, кайдан?
Фәрештә кычкырамы, яки шәйтан?
Җавабында аваз: «Син рәнҗемә,— ди,—
Минем исмем — ачы карт тәҗрибә»,— ди.

Г. Тукай.

## I. Кара еллардан бер ләүхә...

1948 елның март ае. Дүрт ай элек кенә акча реформасы булды, кибетләргә чәй-шикәр, ипи, ситсы, галош кайта башлады. Авыл халкына тагын ни кирәк? Авыл халкына ни җитми? Авылда буфет ачтылар (сельполы, авыл), керсәң — йа дөнья, болай да яшәп була икән, ярты телем ипи өстенә ярты йомырка куелган, исеме — бутерброд, анысын ошатмасаң — шундый ук телем өстенә бер кисәк селедка куелган, анысының да исеме шундый. Бер стакан кызыл аракы. Керәләр, шуны әйләндереп куялар да тормышның рәтләнә баруы турында гәп коралар, кан җылына.

Мин мәшһүр Сеҗе мәктәбендә өлкән пионервожатый булып эшлим, тырышып эшлим. Өс-баш бөтен: башта — киҗе-мамык тутырып сукно белән тышланган бүрек, өстә — сырма, реформага кадәр эшли башлаган көннәрне генә РОНОдан талон белән бирелгән киҗе-мамыктан тегелгән юллы чалбар. Мин бу язмаларымда бик күп кешенең исем-фамилияләрен, авылларны үзгәртмичә язам. Менә шулай: Югары Курса авылы егете, фронтовик Хәбиб Зарипов дигән кеше РОНО мөдире иде, район үзәгендә очратып, минем хәлне күргәч, болай диде:

— Син РОНОга кереп чык әле, мин сиңа бер талон бирермен, чалбарыңның бер дә рәвеше юк,— диде.

Раймагтан мин талон белән чалбар алдым.

Аякта шома ягын эчтә калдырып тегелгән күн ботинкалар (аны «рабочие ботинки» дип йөртәләр иде), уң аяктагысының бер кырые ярык, аннан су керә; әмма бераздан, икенче кырые да ярылгач, кергән су чыга торган булды, минем эш начар түгел иде.

Мәктәп — әйткәнемчә, мәшһүр. Директоры — географ Госман Бикташев, яшел френчтан, шахмат уйнарга ярата. Сугыш узган кешедер, дип уйлыйм, каешлар, итекләр шыгырдап тора иде. Эшкә килгән көнне үк миңа бер кәгазь тоттырды. «Завхоз иптәш... (фамилиясен онытканмын, Газиз абый иде; Бикташев Саба районы кешесеме, әллә шунда эшләгәнме, завхозы, техничкалары — барысы да Саба районыннан китерелгән кешеләр, «үзенекеләр» дип йөртәләр иде); өлкән пионервожатый М. Мәһдиевкә өч кило он, сигез кило бәрәңге, ике кило кишер бирегез. Директор: Г. Бикташев».

Госман агай! Син дөньяда юк инде... Синең төрле сыйфатларың уңай һәм тискәре якларың байтак иде. Хаталарың да аз булмады шикелле. Ләкин мин сиңа дога белмәгән көе дога кылам: авыр туфрагың җиңел булсын! Нәрсә өченме? Завхоз Газиз абыйга биргән әнә шул кәгазең өчен...

Мин эшләп киттем, гармунда уйный белмим, бии белмим, хәтта... (әйтергә оят!) быргыда кычкырта белмим. Ләкин шахмат уйныйм. Моңа мине Арча педучилищесында сабакташым Яхъя Халитов өйрәтте. Бар бит әле шундый бер усал редактор нәшриятта... Шахмат турнирында, Арчада, хәтта Яхъяны да җиңгәләп, мин училищеда икенче урынга чыктым. Яхъя беренче инде!

Бикташев белән мөнәсәбәттә миңа шул ярдәм итте. Госман аганың

шахматка мөнәсәбәтендә сабыйлык бар иде: отылса — кәефе кырыла, отса — балаларча шатлана, эш мәсьәләләрен оныта. Мин, бик күп җитешсезлекләре булган сугыш еллары баласы, үземчә хәйләкәр, директорның шул сыйфатын белеп алдым һәм шуннан байтак файдаландым. Эшкә соңга калам (туган авылым алты чакрым ераклыкта) — директорга мәгълүм була, аңлатма кәгазе сорыйлар. Директор йөнтәс кашларын җыерып йөри, дәрестән соң укытучылар бүлмәсенә керә, шахмат уйнарга кеше эзли. Мин, тиз генә шахмат тартмасы күтәреп, каршысына утырам һәм шактый «азаплангач», юри оттырам. Директор канәгать. Бернинди аңлатма кирәкми...

Мәктәптә, традиция буенча, чын педагоглар эшли. Сеҗе авылы Татарстанда иң беренче ТБУМ, иң беренче урта мәктәп ачкан авыл иде, иң беренче быргы, барабан, тынлы оркестр да шул мәктәпкә кайтты. Без яланаяк, ярымыштанлы малай вакытта Сеҗе мәктәбе укучыларын хәтерлим: йөк машинасының кузовына утырган кыска чәчле, ак кофталы, пионер галстугы таккан кызлар, егетләр көмеш торбалар, зур барабан белән акрын гына урамнан уздылар.

— Ярабби, ахырзаман шушыдыр инде,— дип, карчык-коры укына-укына капкасын ябып, өенә кереп китте ул көнне. Сәйдәш маршын гына уйнаганнар, югыйсә: мин моны берничә елдан соң хәтерләп таныдым.

Сеҗе мәктәбе зур традицияле иде. Педагоглардан фронтовик Мәгъсүм Рафиков — тарихчы. Хәтәр елларда ук университетта укыган, авыр ситуациядән хатыны Әминә апа коткарган, Сталинның үзенә хат язган, дип сөйлиләр иде. Математика укытучысы — Разия Башкирова, элеккеге нарком хатыны, Казаннан сөрелгән. Чын мәгънәсендә интеллигент. Малае Казаннан кайтып йөри (Мөндеш разъезды алты гына чакрым), үзе белән тагын бер чибәр егетне алып кайта. Боларның бүгенге көндә зур шәхесләр булачагын ул чакта кем белгән, кем уйлаган? Разия апаның улы — университетның математика профессоры Шамил Башкиров, аның белән бергә кайтып йөргәне — Гази Кашшафның улы, тарихчы, университет парткомы секретаре булып озак еллар эшләгән Ренат Кашафетдинов. Ул чакта кем уйлаган? Әдәпле, зыялы, чибәр...

Тагын кемнәр? Бәдыйгов Газиз. Рус теле укытучысы, иске интеллигент. Белүемчә, шәһәрдән сөрелгән. Искиткеч тәрбияле, русчасы гаҗәп,гарәпчәсе, төрекчәсе бар, балалары кайдадыр, Фатыйма апа белән теркелдәп кенә сөйләшеп яшиләр; Газиз абый, шәпләп, газета кәгазенә чорнап, тәмләп тәмәке тарта, сөйләшми, гел елмая гына. Аягында метрлы киез итек, мәзәк сүз тыңларга ярата, рәхәтләнеп көлә. Сөйләшми. Егерме елдан соң гыйльми китапханәдә утырганда иске журналда рәсемен күрәм — иске, егерменче еллар интеллигенты икән, Казаннан аны сөрмичә кемне сөрәсең утыз җиденчекырыгынчы елларда? Шәп абзый иде, мине ярата иде, бер сүз әйтмәсә дә, миңа җылы мөнәсәбәтен тоя идем.

Газиз Сафич — интеллигент иде.

Тагын менә Ләбибә апа Зарипова. Ыспай, әдәпле, тәрбияле, югары белемле кыз. Татар теле һәм әдәбияты укыта. Кияүгә чыгарга вакыт. Әмма яшьтәшләрен сугыш кырып бетергән. Миңа «егет-малай» дип иң беренче шул кушамат такты. Коеп куйган педагог, бер генә артык сүз әйтмәс, һәр сүзе үлчәнгән булыр. Яше җитеп узып бара торган тагын өч-дүрт кыз бар. Классик укытучылар — болар гел кеше баласын тәрбияләү турында гына сөйләшәләр, болар үз бәхетләре турында уйламыйлар да. Математика укытучысы — таза, мөлаем кыз, алты чакрым ераклыктагы Поник авылыннан килеп йөри. Салкын кыш көннәрендә мәктәпкә ул килеп кергәч, сыңар куллы завуч Мәгъсүм абый әйтә:

— Миңлегөл, син бәхетле, көн саен саф һава күрәсең бит, шуңа күрә бик чибәр син,— ди. Тагын коеп куйган педагоглар: Гарифә Нигъмәтуллина — классыннан башка бер кайгысы да юк. Буйлы, яше чыгып барган кыз, әдәп-әхлакның үрнәге инде. Аннары Гөлниса Фәһмиева. Мәктәпнең китапханәсе аның кулында. Мине шунда кертеп өстән бикли дә, төн буланчы мин шунда утырам. Гөлниса апа үзе районга-фәлән гә киткәндә классын гел миңа биреп калдыра, мин укытып карыйм. Укыта белмим; хәзер, кырык ел элеккеге тормышка кайтам да, уйлап, куркып калам: мин кулланган антипедагогик ысуллар! Боларны мин яза да алмыйм. Бер малайны, тәртипсез иде, аеруча каты җәзаладым. Гомерләр узды, Татарстан өлкә партия комитетының командировкасы белән лекция укырга Сеҗе авылына барып чыктым. Төнлә, лекция бетеп, күрше йортта ашап-эчеп утырганда колхоз председателе сорап куйды:

— Шушы йортта кунарга ризамы сез? — диде.

Йортта хуҗа хатын — педучилище буенча сабакташым Нәкыя Абдуллина иде, нигә инде кунмаска; ире Вәкил ике дә уйламаслык итеп рюмка күтәрде һәм түрдә җәелгән йомшак караватка ишарә ясады. Ләкин биш-алты чакрым ераклыкта гына минем туган авылым Гөберчәк һәм анда авыру карт әнием көтеп ята иде. Өлкә комитетыннан командировка алганда да мин үзебезнең Арча районын, ә анда кайткач райкомнан үзебезнең Кесмәс буе авылларын сайлап алган идем, командировканы файдаланып, әни янында өч-дүрт кенә көн булса да торасым килгән иде.

Мин, кыен булмаса дип, үземне озатып куюларын үтендем. Председатель мондый үтенечкә әзер икән, ярты сәгать үттеме-юкмы, йортка толып, тире бияләй, олтанлы итекләр кигән таза бер егет килеп керде.

— Ат әзер,— диде.

Ул еллардагы гадәт буенча аңа мөлдерәтеп кенә бер касә тоттырдылар. Егет каушап калмады, минем каршыга ук килеп, башта кулын бирде, аннан:

— Сезнең исәнлеккә, абый,— дип әйләндереп тә куйды. Шул вакытта минем йөрәгем «жу» итеп алды: таза егет — мин моннан егерме еллар элек, дүртенче класста, антипедагогик алымнар белән җәзалаган ташбаш Сәүбән иде...

Хуш, Әмирхан Еники әйтмешли. Шушы Сәүбән белән төнге юлга чыктык бит инде без. Нәкыя белән Вәкил мине дә җылы толыпка төрделәр, ботинкаларымны салдырып киез итек кигерттеләр, чана башына «Авыл күчтәнәче булыр, Казанга алып китәрсең»,— дип, каз түшкәсе дә тыктылар. Без юлда, чана шыгырдый, төн бераз буранлы. Мин, куркуымны басар өчен, чит-ят темаларга сөйләшергә телим, уйлыйм. Каз үстерү, каз симертү буенча иң оста булган ике хатынны беләм мин Кесмәс буенда. Аның берсе минем әни, икенчесе Нәкыя.

Мин шуларны уйлыйм да, сөйлим дә булса кирәк юлда. Үзем һаман шикләнәм: кайсы үзәннәрдә генә чанадан төртеп төшереп калдырыр икән бу егет теге, 47—48 еллар өчен? Ничә кабырганы сындырып, ничә тешне кар өстенә сибәчәк икән бу Сәүбән?

Инде хәтәр холыклы кешеләр яшәгән Мөрәлене дә чыктык, алда әле ике үзән бар, буран да кыюланды. Минем нервлар актык чигенә кадәр киерелде һәм мин шул чакта мәшһүр Гюго сүзләрен исемә төшердем: «Үлемгә каршы барып, еш кына үлемнән котылып калып була. Ул вакытта табут капкачының сине коткаручы тактага әйләнүе мөмкин». Буран эчендәге үзәнлеккә килеп кергәч, түзмәдем, сүз каттым:

— Сәүбән, мин сине бик каты тоттым бит теге елларда, синең эчеңдә миңа карата ниләр бар? — дидем. Кыйналып, изелеп, бил-

гесез күтеп барудан котыласым килгән иде — әйттем дә бетердем.

Сәүбән толыпларын чиште дә тәмәкесен чыгарды һәм, атын акрынайтып, тәмле әңгәмә башлады.

— Һи-и, абый. Барысы да онытылган инде аның. Тик бер генә нәрсә, күңелдә калган: сез, Сталин туган көн дип, пионер сборы уздырдыгыз безнең отрядта. Без лозунглар кычкырдык, барабан кактык. Ә мин быргы кычкыртырга ярата идем. Шул сборда сез очыпкунып сөйләдегез: безнең илдән дә бәхетле ил юк, бу бәхетне безгә иптәш Сталин бирде, дидегез. Ә мин... Мин ул көнне иртән ашамыйча килгән идем. Әни әйтте ул көнне: «Көненә өч ашатырга минем хәлемнән килми сезне, сез бишәү, әтиегез сугыштан кайткан булса, биш тә, алты да ашатыр идем»,— дип елады. Ә сез «каты тоттым» дисез...

Миңа гадәттән тыш авыр иде, чана газаплы шыгырдады. Хәтерлим, бер педсоветта Бикташев мине эт итеп сүккән иде:

— Хватит сиңа авылыңа кайтып йөрергә, синең квартираң бар, хуҗаларыңа дүрт кубометр утын бирелгән,— дип кычкырынды.— Нигә гел авыл юлында син?

Шунда мин, урынымнан юаш кына торып:

— Монда ашарыма җитми, шуңа күрә әни янына кайтып йөрим,— дидем.— Менә ике көн инде ипи бирмиләр...

Педсовет ахырында Бикташев агай мине кабинетына чакырды. Хәтердә шунысы гына калган, кабинетта агач кисмәктә зур фикус гөле утыра иде.

— Тәк,— диде Госман ага, болай да киң булган борын тишекләрен киңәйтеп.— Знаешь что? Синең «ашарга юк» дигәнеңне менә хәзер ЭМГЭБЭгә хәбәр итсәм, нәрсә булачак? Сине бит бүген үк атаң янына озатачаклар. Син шул турыда уйладыңмы?

Мин шул вакытта Яңа Чуриле районының ЭМГЭБЭ начальнигы Шамилне күз алдыма китердем: биек маңгайлы фуражка киеп йөри торган, буйлы, чибәр мишәр егете иде. Мәктәп коллективында әсирлекне күргән ике егет бар иде, алар сөйли иде, начальник әсирлектә булган ирләрне чиратлап көн саен чакырта һәм «үз теләгем белән фашистларга хезмәткә күчтем» дигән протоколга кул куярга кыстый, юашракларны кыйный (бүлмә такталары чытыр-чытыр килә икән), сүгенә, пистолет белән яный, ди.

Күрше авыл Зөфәр исемле егеттән сорау алганнарын бүлмә тактасы аркылы тыңлап торганнар. Зөфәр дөнья бәясе, юньле, юаш егет иде, сугыш башланган җәйдә үк, унсигез яшендә әсирлеккә эләккән, аннан котылган, әле сугышта йөргән, менә тыныч хезмәткә кайткач, тугыз класс белемле булса да, бер җиргә дә эшкә алмаганнар, җитмәсә, мулла малае! — аның кебек белемлеләр, биографияләре чиста булганда, ул елларда директор да министр иде инде, югыйсә... Менә шул Зөфәрне измәкче була икән. Коридорда дер калтырап тыңлап торган чират көтеп утыручы егетләр.

— Куясыңмы кулыңны юкмы, фашист ялчысы, мулла калдыгы, фәлән-фәлән итәм бит! — дигән тавышка урындык шуыша, өстәл кыймылдый, нәрсәдер нәрсәгәдер чыдырдап бәрелә, ди.

— Куясыңмы, юкмы, атып үтерәм бит (пистолетын чыкылдатып взводка куя), котлет ясыйм бит, ЦРУ агенты! Син бит... Интелледженс сервис...ка язылып кайткансың! Беләм бит мин синең ни өчен шыпырт кына леспромхозга урнашып, трелевщик булып агач тарттырып йөргәнеңне...

Тагын чыдырдау, тагын тавыш.

Тыңлап торган егетләрдән берсе сөйли:

— Ну, малай, булса да була икән йөрәк кешедә. Туп-туры әйтә бит тегеңә Зөфәр:

— Менә якын кил, тырнак белән чиртеп кара,— ди.— Миңа, ди.

нечего терять, шушы урындыкны алам да башыңны янчим, но только кәгазенә кул куймыйм,— ди.

Начальник әле яшь иде, күрәсең, кабинетын әзерләп бетермәгән: сорау ала торган бүлмәдә, гадәттә, урындык идәнгә беркетелгән була, өстәл өсте дә тап-такыр булырга тиеш. Пистолет та, нигездә, өстәл тартмасындарак ятарга тиеш.

— Ну, гад, мин сине нишләтәсен белермен алдагы дүшәмбедә, йөрәгемне боздың,— дип, арган, тирләгән начальник такта ишегеп ачып Зөфәрне чыгарып җибәргән. Коридордагы ике ирне чакырып керткән дә, арган кыяфәт белән әйткән:

— Йөрәгем начарланды, кул куясызмы теге кәгазьгә, юкмы, куймасагыз... иләп йөрмәгез, алдагы дүшәмбедә барыбер сытам мин сезне, идите к... матери,— дип чыгарып җибәргән.

Ул явыз оешманың бинасы башта Чуриле чиркәвенә инеш аша гына карап тора иде, агач йорт, такта бүлмәләр. Сорау алганда ул такталарның шыгырдавы, шәт, чиркәүгә ишетелгәндер. Кышкы томанлы, томан арасыннан яшькелт ай караган моңсу тын кичләрдә без малайлар чиркәү чаңын тыңларга чыга идек. Кышкы юлда, еракта, ат чанасы шыгырдаган тавышлар ишетелә, кышкы тын кичтә бу тавыш 6—7 чакрымнан килә, дип сөйлиләр. Чуриледән әтиләр кайтканны без чана тавышыннан сизә идек. Ләкин шул вакытта тонык кына бер моң колакка бәреп керә. Без әсәренәбез. Чиркәү чаңының ритмы менә болай иде кебек:

Даң-доң-доң,
Доң-доң-дың,
Тең-гель, тең-гель —
Пил-лер, даң-даң,
Тиль-тиль-тиль.

Базар йөргән, урыс белән аралашкан ирләр, Чуриледән кайтышлый, ат чанасында килеш моңа кушылып, шаярып, болай дип җырлыйлар иде:

Нов-вый год —
Годовой счет;
Кил-дең, кит-тең
Бер ти(е)н акча бирмә-дең...

Без малайлар моны рәхәтләнеп тыңлыйбыз, ә әниләр каш җыера.

— Азан әйткәндә шау итеп чана шудыгыз бит, ник анысын тыңламадыгыз,— дип орышалар.

Ялгышалар. Азанны да тыңладык. Анысы эңгер-меңгер алдыннан булды. Тау башында, чана-чаңгыларны куеп торып тыңладык. Тыптын калган, кичкә иңрәгән татар авылының өстенә манарадан кичке азан тавышы иңгәндә карчыклар иңнәренә бишмәтләрен салып чоланга, ишек алдына, капка төбенә чыгалар. Салкында манара такталары чарт-чорт килә, мөәзин басар урынын җайлый, бу тавыш бөтен авылга ишетелеп тора. Менә бервакыт күктән фәрештәләр авазы килгәндәй була. Мөәзин яки аның вазифасын үтәүче мәдрәсә белемле ил карты борын авазлары белән генә авыл өстенә сихри моң сибә:

Сөбханәзил вәл-кил вәл-мәләкү-ү-ү-т
Сөбханәзил вәл-кил-вәл-мәләкү-ү-ү-т!
Сөббухән, котдусән
Вәл-кил вәла икәти вәр-рух!
Сөббухән, котдусән...

Карчыклар моңаеп елый. Үләселәре искә төшә. Теге дөньяга барасы, анда баргач бу дөньяда эшләгән явызлыкларың өчен җавап бирәсе бар бит. Йә, хода, гөнаһларыбызны ярлыка...

Тау башыннан без дә кайтабыз: кичке аш инде казаннан табакка бүленгән, сәкегә кижә ашъяулык җәелеп тәлинкәләр тезелгән, өрәңге кашыклар таратылган.

Кич утырырга дип, куенына «Йосыф — Зөләйха» йә «Таһир — Зөһрә», йә «Мәликә китабы»н кыстырып, Гыйльменисатти килеп җитә. Чишенә, түргә уза, догасын кыла, йортка, илгә иминлек теләп битен сыпыра һәм гел әйтә торган сүзен әйтә:

— И ходаем, диннәр куәтләнергә булсын, бүген бик әйбәт төш күрдем,— ди.— Ак патшаның (Сталинны әйтә) күңеленә аллаһе тәгалә миһербанлык салсын, амин...

Кичке аш тәмамланганда Чуриле чиркәвенең чыңы ишетелә.

...Менә еллар узган — Чуриле чиркәвенә каршы агач йортта бүлмә такталары шытырдый.

— Син кул куясыңмы, юкмы бу кәгазьгә... Майть! Изәм, бетерәм бит сине, гестапо агенты! Шпион бит син... майть! Б... буду, сине атып үтермәсәм!..

Чиркәү гөмбәзе тирәсендә төнгә кунаклаган чәукәләр чырылдашып ала.

Укучы! Мин Сәүбәнне оныттым инде, ә? Гафу итегез. Әйе, Бикташев шулай куркыткач (Сәүбән, атын борып, хушлашып кайтып китте, минем күземне ачты да, юк булды инде), кинәт кенә минем тамак туеп китте. Шул сүздән соң мин мәңгегә туйдым. Минем белән аралашкан кешеләр беләләр, мин — дөньяда иң аз ашаучы кеше. Чөнки теге көнне Бикташев агай минем ашау юлын Колыма, Соловки, Норильск дигән ризыклар белән томалап куйды. Бичара, Сәүбән дә ач булган икән бит ул көннәрдә.

Ә теге начальник?

Утыз еллар узган. Казан аэропортында кунак озатам. Шунда агарган чәчле бер чибәр ир «һай-һу» килеп безгә якынлаша, минем кунакны таныган икән, аның белән күрешә һәм миңа да исемемне әйтеп кул суза:

— Әллә танымыйсыңмы? Мин бит Яңа Чуриледә эшләгән Шамил абыең булам,— ди. Мин шактый аптырап:

— Ул вакытта бит мин унҗиде яшьлек бер малай идем, каян хәтерләп калдыгыз? Сезгә эшем төшмәгән иде кебек,— дим.

Ул рәхәтләнеп көлде:

— Ә соң биография? Аны кая куясың? Аннан соң бит син гел телевизордан чыгасың. Мин бит фамилия буенча танып утырам.

Җылы булмаган гына сөйләшү, кыска гына истәлекләр. Иртәгәсен бу көтелмәгән очрашу турында эш урынымда сөйләп утырам. Арадан бер иптәш әйтә куйды:

— Ну бетә инде бу Шамил абый, аракыны ящигы белән генә алдырта, өенә кайтырга куркып, кайчак бездә куна, без бит якташлар,— диде.

Берничә айдан әйтте:

— Син белгән Шамил абыйны җирләдек,— диде.— Соңгы көнендә караватт астыннан ярты ящик ак аракы тартып чыгардык. Йөрәге начар булган,— диде.

Теге юаш, юньле Зөфәр дә йөрәк чиреннән моннан утыз биш еллар элек үлгән иде инде, бичара.

## II. Пәке йөзенә яланаяк басып...

*Максим Горькийны укыганда — шуларга нәфрәтем,*
*Кнут Гамсунны укыганда — шуларга ләгънәтем.*

Г. Тукай

Март ае, кырык сигезенче ел марты. Мул карлы кырлар өстендә кояш уйный, быел март бик кояшлы килде. Йортларның сәлам

нигезләрендә иртә туган кәҗә бәтиләре сикерә-сикерә уйнады, абзар артларында күксел-зәңгәр кар таулары өстенә казлар чыгып басты, ата казлар озын муеннарын мартның зәп-зәңгәр күгенә таба сузып гоңгылдады. Тышта озак йөрсәң, кояшлы кардан күз чагыла, күз кабаклары авырта башлый, йортка килеп кергәч, берни күреп булмый. Карт-коры моны «күз тышта калган» дип әйтә.

Быел март шулай гел кояштан гына торды.

Ял көне, зәңгәр күктән яз шавы ишетелгән ниндидер шатлыклы да, сагышлы да, борчулы да якшәмбе иде.

Бикташев агай кичтән һәр кешегә аерым әйтеп чыкты: ял көне сәгать унда педсовет башлана, ике аягы исән булган кешегә килү мәҗбүри, килмәгән өчен берниндиди сәбәп гафу ителмәячәк, диде.

Ял көне мәктәп бинасы моңсу, коридорлар, класслар ятим була. Бүген дә шулай: утызлаган укытучы килеп тулуга карамастан, мәктәп ятим иде. Укытучылар бүлмәсенең зур-зур тәрәзәләреннән кояш кереп тулган, бүлмәдә утырасы килми, шушы тәрәзә рамын ук алып ташлап, туп-туры кар диңгезе өстенә чыгасы да, кояшка, көньякка карап кырдан берүзең барасы килә.

Педсовет башланганчы ук, шахмат тактасы күтәргән директор белән бергәләп, ике каешлы күн портфель тоткан, гимнастеркалы, ап-ак фетр итекләре кызыл күн белән читләнгән ир уртасы кеше керде, елмаеп исәнләште, директор аның исем-фамилиясен әйткәч, әлеге иптәш, әдәп саклап кына, киңәшмәләр вакытында директор утыра торган өстәл почмагына, «Т»нең аркылы өстәле янына җайлап килеп утырды.

Укытучылар арасында моның «И»гә башланган фамилиясен ишеткәч чышын-шашын китте. Берсе, кыюрагы, шәһәр кызы, үрелеп аңа бер язу сузды. Портфельле кеше моны укыды һәм елмаеп җавап бирде:

— Юк, түгел.

Аннан педсовет башланды. Мәктәп коллективыннан Өлкә комитетына зур жалоба килгән. Мәктәп директоры тәҗрибә участогыннан алынган бәрәңгене, кишерне, суганны ашый икән. Директорның биографиясе дә чиста түгел икән. Гомумән, мәктәп коллективында укытучы булып эшләргә хакы шикле булган кешеләр юк түгел икән.

Китте чыгышлар, бәхәс. Директор белән завуч әләгешеп алды. Март кояшы инде горизонтка төшеп бара, инде хатын-кыз ачлыктан бөгелеп төште, ике тапкыр тәнәфес ясады, ирләр тәмәке төтененә батып алды.

Педсовет тәмамланганда кояш нуры күренми иде инде — нәкъ сигез сәгать утырылган.

Өлкә комитеты вәкиленең фамилиясе бер язучы фамилиясе белән бер үк хәрефтән башлана икән, әдәбият укытучысы «Сез шуның туганы түгелме?»— дип язу биргән икән.

Вәкил өч көн, өч төн мәктәптә ятты. Көндезләрен дәресләргә керә, беркетмәләр укый, планнар тикшерә, ә төнге уникеләрдә директор кабинетына аерым-аерым чакыртып, укытучылар белән әңгәмә уздыра иде.

Дүртенче көнне тикшерү нәтиҗәләре буенча тагын җыелыш уздырылды, монысы кыскарак булды, ләкин сизделәр, төп нәтиҗәләрне вәкил әйтеп бетермәде. Берәр атнадан РОНО, райком тирәсеннән авыр хәбәр кайтып төште: нәтиҗә акты бик яман язылган икән. Чөнки: директор утыз бишенче елларда ук хатын аерган кеше; завуч — керәшен побы малае булган, татар кызына өйләнеп исем-фамилиясен алмаштырган, дөрес, Ватан сугышында катнашып, кулын өздереп кайткан; математика укытучысы, рус теле укытучысы —

шәһәр пропискасыннан мәхрүм ителгән кешеләр, берсенең ире утыз җиденче елда атылган; башлангычта укытучы ике кызның берсе — элеккеге сәүдәгәрләр нәселеннән, икенчесенең этисе мулла малае булган; пионервожатыйның (иң әһәмиятле идеология фронты!) этисе, халык дошманы буларак, утыз җиденче елда атылган; куст берләшмәсендә (ягъни шушы урта мәктәпкә буйсындырылган башлангыч мәктәпләрдә) әсирлектә булган ике егет эшли. Һәм башкалар...

Мәктәп, корбаннар сорап, тынсыз калды.

Җәйгә бу коллектив таратылды, әсирлектә булганнар эшеннән чыгарылды, калганнарын районның төрле мәктәпләренә күчергәләделәр.

Портфельле агай әнә шулай «җәза экспедициясе» белән узды ул елның кояшлы мартында.

...Күп еллар үтте. Мин — үземнән, пионервожатыйдан, төнге кабинетта эшәке, мәкерле сорау алган гимнастеркалы абзыйны егерме биш еллардан соң кафедрада очратып тынсыз калдым. Елмаю шул ук күзләр, чәчләр шул ук, тик бераз чигенгән, утыра төшкән. Бераз басынкы. Каяндыр, кемдер аңа бер кыйммәтле әйбер биргән. Имеш, Казан Кремле янында казынулар вакытында табылган. Ул әлеге әйбердәге нәкыш белән язылган текст буенча кандидатлык диссертациясе якларга йөри икән. Пенсиягә зуррак акча белән чыгу өчен.

Ул кешедән утыз җиденче ел исе килә иде.

Хәер, утыз җиденче, кырык сигезенче еллар истәлеге миңа адым саен очрап тора. Күрәсең, бу йөз елларга җитәр. Югары уку йортларында бигрәк тә еш очрый ул. Минем үземне 1947 елда институтка чак-чак алдылар. Фамилияне күрүгә үк сорау бирәләр иде:

— Сез элеккеге финанс наркомы Мәһдиевнең нәселеннән түгелме?

— Син, егет, сәнгать белгече Мәкәрим Мәһдиевнең туганы түгелме?

Керү имтиханнарын биргәндә, билге куйганчы, башта шундый сорау бирәләр иде.

Ә бер олы ир әйтте (географиядән имтихан алучы):

— Иллә дә начар фамилия инде, моны алыштырырга кирәк,— диде.

Бары тик илле алтынчы елдан соң гына аңладым: финанс наркомы да, сәнгать белгече дә утыз җиденче елның корбаннары — «халык дошманнары» булган икән.

Хәер, бу мәсьәләдә минем күз гел ачылып тора. Тарих шулай булырга тиеш, кешенең күзен ачканга күрә тарих дип атала да инде ул. Тарих ул — кешелек җәмгыятенең ачы тәҗрибәсе.

1946 елның көзендә безнең училищега тарих фәненнән яңа укытучы килде. Без өченче курста, өйрәнә торган тарихыбыз — «Кыскача курс». Бар иде бит әле шундый китап — ВКП(б) тарихы, Сталин үзе әйтеп яздырган китап. Моны һәр көзнең башында бөтен актив — райком, райпо, мәктәп, райздрав, колхоз идарәсе, тимер юл парткомы һ. б. оешмалар, политик уку планына кертеп, конспектлап өйрәнә башлыйлар да, яз җиткәндә дүртенче бүлегенә кереп чумалар һәм... дәресләр шуның белән туктала иде. Ярым-йорты укый-яза белгән активистлар, дүртенче бүлеккә килеп җиткәч, Гегель, диалектик материализм, монизм, идеализм, метафизика сүзләренә килеп кереп шаккатып калалар иде; ну баш та икән бу Сталинның үзендә! Кара син аны, бер дә белмәгән нәрсәсе юк бит! Сталин кешеләрне нәкъ үзенчә бер төрле генә итеп уйларга өйрәтә. Ләкин Гегельнең бер фикерен телгә алмый ул анда. Гегель абый исә болай дигән: «Бөтен кеше дә бер төрле уйлый икән, димәк, беркем дә уйламый».

Әйе, безгә дә яңа укытучы шуларны өйрәтә, Троцкийны, Зиновьевны, Рыковны, Каменевны сүгәбез. Партияне халык дошман-

нарыннан чистартуда ОГПУ, НКВД органнарының батырлыгын мактыйбыз, бер дәрескә кырык-илле тапкыр «Иосиф Виссарионович Сталин» сүзен телгә алабыз. Бер үткен малай бер дәрестә санап барган: кырык җиде тапкыр искә алынган әлеге өч катлы исем. Ул бик ач иде, ач кеше ни әйтмәс, ни язмас. Шуны исәпләп барган кәгазенең ахырына ул болай дип тә язган: «Чишеп җибәрәмович ыштаның». Әлек авылда картлар, чыннан да, баулы ыштан кияләр иде.

Тарих укытучысы — зәңгәр күзле, тәбәнәк буйлы (үкчәсе өстәлгән ботинка кия), кызылга каккан яхшы, кыйммәтле тунлы. «Шулай бит инде» дигәндә «шулай биг инде», ди; «өч солдатлар килеп кергәннәр», дип тә сөйли.

Шулай кыш буе троцкийчыларны сүктек. Шуларны сүгеп, Сталинның шәхесен Антей белән чагыштырып («Кыскача курс»ның соңгы битендә), тәмам алҗыгач, җәй башында имтихан бирдек.

Кырык бер ел узгач, Ибраһим Салахов романында укыйм. Казан ОГПУ — НКВДсында гаепсез корбаннарның канын эчүче аждаһа, коточкыч рәхимсез палач Бикчәнтәев Гәрәйша эшләгән теге елларда. Аның исемен ишеткәндә тоткыннар тораташ булып катып калганнар. Ә инде эзләрне югалтырга кирәк булгач, бу палачны каядыр озатканнар.

...Теге тарихчы шул үзе булган икән.

Менә безне кемнәр укыткан! Бездән кем чыксын!

Без «Кыскача курс»тан имтихан биргәндә училище өстендә «халыклар атасы»ның кылычы нык уйнап алды. Училищега очраклы килеп эләккән тупас, тәрбиясез бер укытучы, НКВД органнарына донос җибәргән, дигән хәбәр таралды. Җәй эчендә өч ирне юк иттеләр. Бу бит инде 1947 ел җәе. Тыныч тормыш җәе. Кемнәрне алдылар соң? Педагогика укытучысы, чын зыялы остаз, керәшен Константин Афанасьевич Ибаевны. Имеш, элек кадет булган. Рус теле, әдәбияты укытучысы, карт журналист, тәнкыйтьче, дәреслекләр авторы Хәлим Фәттәхович Искәндәревне. Имеш, мулла малае икән, Галимҗан Ибраһимов белән дус булган. Физика укытучысы, фронтта утны-суны кичкән Әхәт Кариевны. Монысы шагыйрь Әнәс Кариевның абыйсы, Әнәс Кариев исә безгә татар әдәбияты укыта иде. Әхәт абый, имеш, әсирлектә булган.

Менә шундый егетләр кинәт юкка чыктылар. Без училищены тәмамлап киткән идек инде, үзара очрашканда гел теге явыз доносчыны сүктек. Мин аның монда исемен әйтә алмыйм, чөнки документым юк, бары тик иптәшләремнән ишеткәнемне генә язам. Шулай да шартлы бер исем куймый хәлем юк. Чөнки бер малайның дәфтәреннән (немец теле өйрәнеп йөргән көннәрме икән?) аңа багышлап язылган бер җыр табылып, кулдан-кулга күчереп язып йөрткән идек. Ул җыр болайрак иде шикелле:

Аллер шюлер һабен дас
Гыйльмуш абзый — башы таз;
Аллер гейен һинаус —
Гыйльмуш абзый — зур авыз

Бу җырның тексты теге явызның үзенә дә эләгеп, күрше класста (үзе җитәкче булган) бөтен китап-дәфтәрләрне җыеп алып тентү ясаганы хәтердә. Андагы халык иҗаты! Әйтеп кара син халыкны гел куркып яшәгән дип! Ишетүебезгә караганда, ул дәфтәрләр арасыннан менәниләр килеп чыккан:

Рәхмәтләр яусын Ленинга —
Ике сыер саудырды;
Ләгънәт төшсен Сталинга —
Кәҗәсез дә калдырды.

Яки: «Сталинская влачь — көненә бер умач». Тагын: «Кәҗә асрамаган кеше — кулак; төрмәгә кермәгән кеше — дурак». Тагын:

Безнең авыл мәчетенең
Таш аның манарасы;
Алабута чумарасы —
Ысталин заманасы.

Теге явыз әлеге корбаннарына боларның барысын ябыштырган, имеш. Күрәсең, 1947 елда алынганнарны инде атмаганнар. 1954 елдамы икән, болар исән-сау кайтканнар. К. А. Ибаевка пенсиягә чыгу өчен белешмәләр кирәк икән. Ул Арчага кайткан. Училищега кергәч, имеш, болай дигән:

— Станциядән Арчага менгәндә бик ерак сукмаклардан уратып йөрдем. Теге кабәхәт очрар да, шуны буып үтереп, яңадан төрмәгә керермен дип курыктым.

Ишетүемчә, алар өчесе дә ирекка чыккач озак яшәмәгәннәр. Яшь тә бар, аннан соң Сталин лагере Артек лагере түгел икәнен кем белми. Мин, кызганыч ки, бу остазларымның берсе белән дә күрешә алмадым. Әмма теге явызны күрдем. Алтмышынчы еллар уртасы иде. Станциядән Арчага менә торган автобусны көтәбез. Ул заманда әле автобуслар кечкенә, алдан гына ачыла торган. Автобус Арчадан кеше төяп төште, туктады, ишек ачылды, ишек янына балалы хатыннар, карчыклар бөялгән иде, алар төшешкә утырырга дип чиратка баскан халык та байтак. Этеш-төртеш башланды. Шулвакыт мин үз күзләремә үзем ышанмадым. Алтмышларны узган теге явыз үзенең олы корсагы белән кинәт кенә чиратны бәреп таратты да тар ишеккә ыргылды. Әле автобустан беркем дә чыкмаган иде, әмма капкорсак, ишек янында чыгарга торган бөтен хатын-кыз, бала-чаганы изеп-сытып, эчкә ыргылды. Астан аның якасына ябыштылар, чалбарыннан өстерәделәр, яман, ятсыз сүзләр әйттеләр, ләкин теге үзенекен эшләде: сабыйлар, хатыннарны сытып эчкә узды һәм тәрәзә янындагы урынга «лык» итеп утырды. Автобус иңеп алды.

Мин Арчага җәяүле сукмактан гына мендем. Әйе, педагог Ибаев дөрес эшләгән. Мондый шәхес белән очрашмавың яхшы. Арча, аның училищесы миңа кызганыч тоелды. Нинди асыл затлар эшли иде анда элек...

Кәлабе җәһлә калдый
Гиздекең назендә сахралар...[1]

... Югары уку йортларында шәхес культы корбаннарының балалары очрый: галимнәр. Безнең ун кешелек кафедрада алар өчәү, ә факультетта — унлап. Ләкин ара-тирә башкасы да очрый. Мәсәлән, болай:

Кыш. Кичкә таба. Университет коридоры тулы студентлар. Кышкы сессия бара. Баскычлар тулы — ташланган дәфтәр, китап, брошюралар. Коридорлар гөж килә. Мин арган, йончыган. Группада егерме дүрт студент. Ведомостька әле нибары унбер билге куелган. Студентның җавабын рухсыз гына тыңлыйсың. Йөзенә күтәрелеп карамыйсың (күтәрелеп карап аласың), фәлән фәннән «биш»ле алган, димәк, сәләтле. Теге «фәлән фән»нең экзаменаторы — кырыс хатынкыз. Кырыс хатын-кыз — доцентмы ул, профессормы — чибәр кызларга бик нык таләпчән була. Чибәр кызның иң гадел билгесе — бары тик хатын-кыз укытучы куйганы гына.

---

[1] Син күңел ачып йөргән матур
Сахралар надан этләргә калды.
Төрек шагыйре Кәмал-бәк

Менә бер кыз килеп утырды, каушый-каушый сөйли башлады. Белгәнгә охшый. Зачетканың катыргысын ачам, фотосына карыйм. Унынчыны бетергәндә төшкән инде, күзләрендә әле сабыйлык бетмәгән. Авыл кызы. Икенче курста инде төскә-биткә байтак үзгәргән. Каян икән, әллә Башкортстаннанмы? Аннан килгәннәр шулай тиз үзгәрә. Ә, юк үзебездән икән. Бәрәч, үзебезнең Арча районыннан. Әйдә, якташ, әйдә, әйбәт сөйлә. «Бишле»лек итеп. Кайсы мәктәптән икән? Әһә, анысы да язылган. Мин бу авылны яхшы беләм. Ул мәктәптә танышларым бар. Фамилиясе? Да-а, шундый фамилияле бер егет эшләгән иде безнең авылда. Нәселеннән түгелме? Бәрәч, әтисенең исеме дә таныш сыман... Стоп! Стоп! Уф-ф-ф... Мин ыңгырашып куйдым. Кызый исә, мине аңламыйча, сөйли дә сөйли: «1910 еллар тирәсендә Тукайның иҗатында оптимистик авазлар көчәя башлый. Илдә барган вакыйгалар...» Минем башым шаулый, колакларым начар ишетә. Чөнки алдымда җавап бирүче —1937 елда минем әти өстеннән донос язып, әтине аттырган кешенең кызы. Йә хода, мәдәт бир. Йә хода, шушы балага карата гадел булыйм. Сөйлә, сеңлем, сөйлә, «биш»ле алырлык итеп сөйлә. Башым чатный, тыным кысыла. «Тукайның дусты Хөсәен Ямашев үлгәч...» Кара, нәкъ әниеңә охшагансың бит син. Әниең ул елда синең кебек үк чибәр, кыйгач кашлы, калын толымлы яшь хатын иде. Көләч йөзле иде. Әмма әтиең кабахәт кеше булып чыкты да инде. Ул бит әле аннан соң да берничә кешенең башын ашаган. Сөйлә, сеңлем. Миңа гадел булырга ярдәм ит. Югыйсә, мин гомер буе газапланырмын...

Мин аңа бернинди өстәмә сорау бирмәдем, «биш»ле куйдым. Бер сорау да бирмәгәнгә гаҗәпләнеп, чыгып китте ул. Миңа бик авыр иде.

Чибәр туташ! Мин синең турыда ишеттем: кияүгә чыгып бик тату гаилә коргансыз икән, үзең кайсыдыр мәктәптә кем булыптыр эшлисең икән. Мин монда синең исемеңне атамадым — сәбәбе билгеле. Балалар әти-әниләрен сайлап ала алмыйлар. Үзеңне танысаң, миңа хат яз әле. Мин сиңа һич тә рәнҗемим.

Ә менә икенче бер сеңелнең фамилиясен тулысы белән атыйм. Мине бервакыт «почасовик» итеп эшләргә пединститутка чакырганнар иде. Почасовикның акчасы ноль бөтен фәлән... икәнен белсәм дә, шатланып риза булдым. Элек үзең укыган институт аудиториясендә лекция уку нинди горурлык, нинди зур бәхет! Мин беренче лекциямә бик горур кердем. Университеттан киләм бит — университетның абруен белмим түгел. Университет лекторлары бераз гына борнай була, һавалы була; алар, студентлар алдына кереп, пединституттагы кебек исемлек тикшермиләр, «Гөлсинә ник килмәгән бүген?»— дип вакланмыйлар, лекцияне гадәти авыл мәктәбе дәресенә әйләндермиләр. Алар, аудиториягә бик эшлекле кыяфәт белән кереп, кафедра янына басалар да студентка бөтенләй игътибар итмичә, академик стильдә сөйли дә башлыйлар.

«Карл Маркс «Политик экономияне тәнкыйтьләүгә карата» дигән гениаль хезмәтенә кереш сүзендә...». Һи-и, бөеклек, әлләкемлек, пафос, бравада...

Мин дә шулайрак башлармын дип барган идем — шаккаттым. Пединститут аудиториясендә, лекторны тыңламыйча, чыш-пыш сөйләшеп утыралар икән. Университетта чирек гасыр лекция укып мин мондый хәлне күргәнем булмады. Нишләдең, кая барып чыктың син, туган йортым? Безме? Без лекция тыңлагандамы? Профессор Рифгать Таһиров, ул вакыттагы доцентлар (хәзер исәннәрдән кайберсе профессор инде) М. Ременников, Евгений Иванович Устюжанин, Николай Петрович Муньков, Юзеф Геннадиевич Трунский, Григорий Наумович Вульфсон, Аркадий Семенович Шофман лекцияләре... Ә Бушмакин? Карт, элеккеге интеллигент. Бөтен рәвешендә, холкында

Париж, Санкт-Петербург, Сорбонна тәрбиясе сизелеп тора. Анысы безгә урта гасырлар тарихын укытты. Без, суга тилмергән караком сахрасы кебек, алар сөйләгән сүзне миебезгә генә түгел, тәнебезнең күзәнәкләренә шифалы яңгырдай сеңдерә идек.

Күрәм, мине тыңлаучы юк. Сизәм, нәрсәдер эшләргә кирәк. Шунда минем башка бер фикер килде. Башны, мине без тиешенчә файдаланмыйбыз: ныклы «нагрузка» биргәндә ул һәрчак уңайга эшли. Мин әйтәм:

— Әйдәгез, танышып чыгыйк әле. Сез мине ишетеп беләсездер. Мин шундый-шундый кеше булам. Сез исә хәзер, рәттән басып, миңа өч төрле информация бирегез. Район, мәктәп, исем-фамилиягез. Мин нинди контингент белән эшлим икән, беләсем килә. Студентлар моңа бик тиз күнделәр.

— Саба районы Икшермә мәктәбе...

— Саба районы Завод Нырты мәктәбе...

— Саба районы Олы Шыңар мәктәбе...

— Пермь өлкәсе Сараш мәктәбе...

— Арча районы Сеҗе урта мәктәбе...

Тукта, тукта! Стоп! Монысы мин эшләгән мәктәп. Фамилия? Хәсәнова. Исемегез? (Инде оныткан мын). Кайсы авылдан? Сикертәннән. Ай-й... Минем әти туган авыл. Галиәсгар Камал авылы. Мин укыган, ахырдан ярты ел буе рус теле һәм әдәбияты укыткан авылым. Әтиеңнең исеме?

— Зөфәровна...

Һәм минем күз алдыма текә фуражкалы ЭМГЭБЭ начальнигы, аның такта стеналы кабинеты килеп басты. Бу дөньяда бер генә сәгать тә рәхәт-шатлык күрә алмыйча, гаделсезлектән изелгән, акыллы, юаш егет, куллары сыткый сагыздан каралган, тормыш тарафыннан каһәрләнгән егет — Зөфәр абый, укымышлы мишәр мулласы Хәсән хәзрәтнең улы күз алдыма килеп басты. ЭМГЭБЭ корбанының чибәр, буйлы-сынлы кызы минем алда басып тора иде. Мин аңыма килдем һәм бөтен аудиториягә әйттем:

— Мин бу студентканың әтисен белә идем, дөнья бәясе егет иде,— дидем. Аннан тамагыма төер утырды, күземә яшь килде.

Сөйләшеп утыра торган бу аудиториядә бер атна «эшләп» карадым да ташлап качтым. Әй, чуртым! Белемне аны белергә теләгән кешеләргә генә бирәсе. Әлеге сеңел Зөфәровна! Син кайда хәзер, өеңдә әтиеңнең зурайтылган рәсеме бармы, әгәр кияүгә чыгып балаларың булган икән, аларга дәү әтиләре турында сөйлисеңме? Без бит синең белән «братья». Белмим, син бәлки «Язгы җылылык» елларында үскәнсеңдер, фамилияңне алыштырырга сиңа тәкъдим итмәгәннәрдер.

Ә миңа тәкъдим иттеләр. Укучыларны алдарга теләмим, мин — егеттә шундый омтылыш та булып алды. Күңелдә. Ә нәрсә? Фамилияне үзгәртсәң, бәлки, башка кешеләр шикелле тигез хокуклар белән яшәп булыр. Мәсәлән, Гайнетдинов. Яки Хисаметдинов. Яки Минсабиров. Яки Колгалиев. Ә нәрсә? Бәлки, шулай тынычрак булыр?

1953 елда Балтыйк буенда кече офицерлар курсын бетергәндә мине фамилия китереп кысты. Хәер, аңарчы ук. Халыклар атасы үлүгә, газеталарда яңа президент Ворошилов имзасы белән амнистия турында указ чыкты. Ләкин анда 58 нче статья турында бернинди сүз дә юк иде әле. Мин Ворошиловка шул хакта сорап хат яздым. Җавап көттем. Әле ЭМГЭБЭ системасы үз көчендә, Лаврентий Павлович Берия дә үз урынында иде. Җавап көтеп йөргәндә мине кинәт кенә Аерым бүлеккә чакырдылар, стенага ак җәймә

элеп, яннан да, алдан да фотога төшерделәр. Берни дә әйтмәделәр. Берничә көннән үзебезнең хәрби часть бүлегенең комсомол җыелышын җыйдылар. Әмер белән. Мин комсомол секретаре идем. Карыйм — часть командирының төсе качкан. Ниндидер хезмәттәге кимчелекләремне казып чыгарып, мине секретарьлыктан азат иттеләр. Аннан редколлегиядән чыгардылар. Часть командиры минем «Шәхси эш» белән таныш булмаган икән. Замполитына әйткән:

— Менә кемне куенга елыштыргандыз,— дигән.— Ә син,— дигән,— эшләпә. Бу — синең өлкә. Менә хәзер икебез дә очсак? Иптәш бит яшерен документлар, серле аппаратура белән эш итә иде...

Берничә көннән мине тагын Аерым бүлеккә чакырдылар. Фәлән сәгать фәлән минутта фәлән аллеяда каштан төбендә басып торырсың, диделәр. Килдем, бастым. Юл аркылы икеме-өчме катлы гүзәл бер ак бина калкып тора — урта гасырлар стилендә салынган. Хәрбиләр бу бинаны кайсы «Ак йорт» дип, кайсы «Смерш» («Смерть шпионам»), кайсы «контрразведка» дип кенә йөртәләр һәм бу сүзләрне әйткәндә калтыранып, як-якка каранып алалар иде.

Каштан төбендә торам. Урамда эт тә юк. Менә ак йортның җиз тоткалы мәһабәт ишеге шыпырт кына ачылды, аннан ак чырайлы, тәбәнәк гәүдәле бер мичман чыкты. Як-ягына каранды да сак кына миңа ияк какты. Мин аңа таба атладым. Ул мине эчкә уздырды. Анда тагын бер мичман каршылады. Алар мине, аллы-артлы уртага алып, мәрмәр баскычлардан икенче катка алып менеп киттеләр. Паркет шыгырдаганы, коридор диварларының шыр ялангачлыгы истә калган. Шундый ук шыр ялангач зур бүлмәгә алып керделәр. Полировкалы, «Т» рәвешендәге өстәл. Түрдә зур дәрәҗәле офицер утыра. Миңа яннан урын күрсәттеләр, мичманнарның берсе чыгып китте, икенчесе каршыма утырды. Безнең авылда шундый гадәт бар: кунак-фәлән яки күрше кешесе кергәндә аңа тиз генә урындык куясың, аның өстенә иң яхшы көрпә (бездә — киез) җәясең. Әнә шуңа утырганда теге кеше, һичшиксез, урындыкны бераз гына ишек катына таба шудыра, өч-дүрт кенә сөям булса да шудыра. Бу — ихтирамга ихтирам билгесе.

Контрразведка бүлмәсендә мин дә шулай урындык шудырып маташам икән. Бик кырыс кына искәртү ясадылар. Урындыкны тиешле хәлгә китереп тынсыз калдым. Күрәм: буп-буш өстәл. Дүрт диварның өчесе шыр ялангач, миңа каршы ягында — Дзержинский портреты. Авыр тынлык урнашты. Зур түрә өстәл тартмасын үзенә таба тартты, аска карады, ләкин бер кәгазь дә чыгармады. Бераздан карлыккан тавыш белән сорады:

— Синме әле Ворошиловка хат яздың?
— Так точно.
— Әтиеңнең язмышын беләсең киләме?
— Так точно.
— Әтиең 1938 елның башында атылган.
— Сорау бирергә мөмкинме?
— Әйе, мөмкин.
— Белергә рөхсәт итегез: ни өчен атылган?
— Контрреволюцион эш алып барганы өчен.

Авыр тынлык. Башны аска идем. Өстәл тартмасы ябылды. Мин, күтәрелеп, начальникның йөзенә карадым.

— Мин кече офицерлар курсында укыйм. Звание бирелачәкме?— дидем.

— Вряд ли сезгә флот офицеры званиесе бирелер.

— Миңа берәр киңәш бирсәгез иде. Минем ул дәрәҗәне аласым килә. Аны алсам, мине запаска чыгаралар. Кайтасым, институтны тәмамлыйсым килә.

— Сез фамилиягезне алыштыра аласыз...

Мин шатланып киттем: менә иртәгә үк фамилиямне алмаштырам. Аннан мине имтиханга кертәләр. Бер айдан буласы диләр. Аннан, запастагы кече лейтенант званиесен бирәләр дә, институтыма кайтарып җибәрәләр. Менә бәхет. Тик нинди фамилия алырга? Хәйруллин? Галимуллин? Заһидуллин?

Ике мичман мине каштан аллеясенә күмелгән урамга кадәр озата төштеләр.

Хәтәр йорттан чыгып куе яфраклар астындагы тротуардан атлаганда кинәт кенә күз алдыма әти килеп басты. Аның тавышын ишеттем сыман. Бераз бөкрәя төшкән нужалы гәүдәсен, камыт аякларын күрдем сыман. Шунда әтинең тонык тавышы ишетелде кебек:

— И улым, улым, син дә саттыңмыни инде мине?..

Мин айнып киттем. Күңелем җиңеләйде. Кычкырасым килде:

— Юк, әти, юк! Синең исемеңне-фамилияңне сатсам, җирдә яшәү миңа хәрам булсын!

Берничә ел үткәч, КГБ чиновниклары миңа ялган белешмә бирделәр: әтиегез 1942 елда йөрәк параличыннан үлгән. Ә университетта эшли башлагач, үзем кебек кыерсытылганнар белән танышып сөйләшкәндә, бер нәрсәне белдем: бөтенебезнең дә әтиләре 1942 елда йөрәк параличыннан үлгән икән. Нигә алай?.. Моны без, кыерсытылганнар, исәпләп чыгардык. Статистика өчен. Үзебезне һәм чит илләрне алдар өчен. 1942 ел — сугыш вакыты ул. Димәк, Колыма, Магадан, Якутия, Караганда лагерьларының корбаннарын да сугыш чутына керткәннәр.

Үлемнәр, каберләр, кеше сөякләреннән ясалган статистика. Кабахәт, җирәнгеч статистика...

Ачы тәҗрибә мине шулай уйларга мәҗбүр итә. Һәм минем моңа хакым бардыр кебек.

# Ялта

*«Россиядәге кебек мемуарлар файдалы булган бүтән ил хәзерге вакытта юк. Без, цензура аркасында, ачыктан-ачык сөйләшүгә бик аз өйрәнгәнбез. Андый сөйләшү безне гаҗәпкә калдыра һәм масхара итә».*

А. И. Герцен, 1855 ел

## Гомернең кадерен белеп кенә...

1963 елның сентябрендә беренче тапкыр Кара диңгезгә бардым. Минем өчен бик күп нәрсә беренче: Кара диңгез дә, ял итү дә, язучыларның иҗат йорты да, чит шәһәр язучыларын күрү дә.

Һәр көнне иртәнге аштан соң пляжга автобус алып китә. Шәһәрдә кымызның ярты литры илле тиен, виноградның килосы шулай ук илле тиен. Без, акча азлыктан, виноградның арзанрагын эзлибез һәм табабыз. Кырым шәрабы стаканлап сатыла — ике йөз граммы унҗиде тиен. Анысын да эчәбез, байлар әрмән коньягы эчә (шешәсе дүрт сум унике тиен), боржоми алалар.

Иҗат йортында Ялтаның «завсегдатае» — Хәмит Ярми. Юньле кеше, күңелле кеше.

Хәмит абый мине Ялтаның яр буе урамыннан акрын йөрергә өйрәтә. Ә мин гел торып йөгерәм икән, үзем сизмим. Бу өйрәнү бер атнага кадәр барды. Аннан ул безне кич белән диңгез буенда йод сулап утырырга өйрәтте. Анда яр буенда амфитеатр сыман урын бар, кичен шунда чыгып утырасы да, дәшми-сөйләшми генә йод сулыйсы. Борынның әле бер тишегеннән, әле икенчесеннән. Монысына өйрәнә алмадым.

...Хәмит агай шәп киенә, затлы ризыкларның, мәҗлеснең рәтен белә иде. Банкет-фәләнгә калькуляция төзисе булганда илленче-алтмышынчы елларның шау-шулы, мәҗлесле, тостлы заманында ресторааннарның диварлары тышка таба этелеп киеренке бер мәҗлеси тормыш белән яшәп ятканда, тәҗрибәсез, чабатадан, кычыткан ашыннан, черек бәрәңге кумәченнән ясалган безнең буын кандидат, ә кайбер уртакулраклары хәтта доктор да булып яткан заманда ресторааннарда калькуляция төзү, тамада булу өчен әдәплерәк, тәрбиялерәк кешеләр, егерменче еллар рухында тәрбияләнгән кешеләр кирәк иде. Һәр кандидат, һәр доктор андый мәҗлесләрне оештыру мәсьәләсендә йә Ә. Еники, йә Х. Ярми янына торды да йөгерде, торды да йөгерде. Беләләр: «Ә. Еники — «череп таркалган дәүрән»— морзалар нәселеннән, сизәләр — Х. Ярми дә ниндидер әдәплелек мәктәбен үткән гаиләдән.

— Әмирхан абый, зинһар, калькуляция төзеш!

— Хәмит агай, зинһар, тамада бул!

Сугыш елында үгез җигеп көлтә ташыган, бәясе ноль-ноль тиен булган «хезмәт көне»нә эшләп шуңа инде иялэнгән, ләкин фән-гыйлем өлкәсендә конкрет ике йөз сиксән, өч йөз егерме, дүрт йөз илле сумнар түләнгән «үрләр» барын аңлаган агай-эне ул елларда банкетларны бәрде инде. Ул банкетларның даими әгъзалары бар-лыкка килде, ул мәҗлесләрдә инде кем хатынының нинди күлмәк киеп киләсен, кемнең нинди тост әйтәсен, кемнең, кызып алгач, ризык тулы өстәл өстеннән кинәт сикереп уртага төшеп шашып бии башласын алдан белеп торалар иде. Банкетны тәмамлаганда агай-эне үзенең бушка ашау-эчү тәмен белгән хатынының җилкәсенә тунын киерткән вакытта да алга карап аерылыша иде:

— Тагын бер атнадан фәлән иптәш кандидатлык яклый. Шунда очрашканга кадәр.

Тун кигертүчеләрнең икенчесе кызган, һөҗүм ясый:

— Ти шту? Читвирыг көнне фәләнев докторлык яклый бит! Ник, әле сез чакыру алмадыгызмыни?

Хатынына тун кигертүчеләрнең өченчесе, үз-үзеннән канәгать «банкетчы» редактор бар: фән китаплары аның кулыннан уза, аннан башка беркем дә кандидат та, доктор да була алмый, моны инде ул үзе генә түгел; аның хатыны да, фәннән бик ерак торса да, аңлап бетергән. Һәм редактор иптәш әйтә куя:

— Алдагы читвирыг нәрсә ул? Ә менә сез егерме алтынчы апрельгә әзерләнегез. Ул көнне иптәш Фәләнский докторлык яклый һәм нәкъ шул көнне — Тукай туган көнне — аңа Тукай премиясе бирәчәкләр. Менә банкетларның банкеты кайда ул! Сез әле лауреат-ка бүләк алмадыгызмыни? Бәр-рәч...

Шундый заманнар иде...

Колхоз председательләрен Казанга җыеп шәп җыелышлар уздырыла, көтелмәгән шәп «пассаж»лар ясап заллар шаккаттырыла иде, дәрәҗәле җыелышлар тәмамлангач, җитәкче агай-эне «Татарстан» кунакханәсендә уналты катлы тартманы талгын җилдә чайкалдыра, мәҗлес ясый иде: Сарманнан, Минзәләдән килгән таза тәнле, ышанычлы чырайлы колхоз-совхоз җитәкчеләре урнашкан бүлмәләрдә ике тәрәзә уртасына тутырылган ит, паштет, балык,

шашлык, пирог-шпиг күсәбәләреннән рамнар каерылган, мокытрак яклардан килгән җитәкчеләр бүлмә саен кереп әҗәткә «бер кабарлык ипи» яки бер ике килька сорап йөргән, гөж иткән көннәр иде.

Банкетлы, шәп заман иде.

Күпмедер еллар узгач, илдә бер акыллы кеше табылды. Яшь икән, бездән дә яшь икән. Ул кеше халыкның күзен ачты. Теге тамадалы, кандидатлы, докторлы, лауреатлы шәп мәҗлесләрдә, беләсезме, без нишләгәнбез икән?

...Мин бала вакытта ук гарәп хәрефле бик күп китап укыдым. Уку китаплары, төрле-төрле җыентыклар байтак иде безнең өйдә. Эти гел әйтә килде: менә боларны укы, менә боларны. Тукай шигырен гел тукыды:

«Өч наданга алмашынмас бер язу белгән кеше».

Шул китапларның берсендәге мәсәл-хикәят хәтердә калган. Бер мачы, диелә анда, майлы игәү тапкан да, шуны бик тәмләп ялый башлаган. Ул шулкадәр тәмләп ялаган ки, бервакыт үз теленең канын ялаганны да тоймас булган. Үз теленең канын ялый-ялый, ул шулай телсез калган.

Шәп! Шәп! Дан! Яшәсен!— дип егерме ел банкетларда йөзгәннең соңында аек кеше идарәгә килеп күзебезне ачтырса... ачтырса... теге мачы кебек икәнбез бит без!

Ул елларда без күч белән, пачка белән, көтүебез белән галимлеккә омтылдык. Сиздек: крестьян хезмәте белән көн итеп шәп ашап, шәп киенеп тә булмаячак, иң матур кызлар белән дә танышып булмаячак, иң затлы, бай, акчалы ханымнар арасында (безнең буын иң акчалы халык — артисткалар, дип уйлый иде, шуннан инде безнең кем икәнне белегез) игътибар казанып та булмаячак. Һәм җөмһүрият галимнәр чүкеде. Кандидат, кандидат, кандидат, доктор. Кандидат, кандидат, тагын бер доктор. Кемнәрнедер яклатмадылар, аларга аяк чалдылар, аларның бер төрлесе шәһәрен алмаштырды, икенче төрлесе инфаркт, инсульт алды, өченче төрлесе: «И, төкердем мин сезнең галимлегегезгә»,— дип, башка юлдан китте. Әмма тырышлар бәреп алга чыкты. Арада шундыйлары күренде ки, профессор-фәлән дигән зур исемнәрне алгач, шул дәрәҗәләренә күрә урыннар, вазифалар билгеләнгәч, боларны рус, яһүд, чуаш галимнәре алдында күрсәтергә оят була башлады. «Профессор Фәләневкә сүз бирелә»,— дип әйтелүгә, ояты булган укымышлы агай-эне бөгелеп төшеп, үзенең татар булганына кыенсынып, оялып, ыңгырашып утыра торган булды...

«Моның әлеге темага ни катнашы бар?»— диярсез. Бар шул. Хәмит Ярми дидекме? Әнә шул банкет заманындагы иң әдәпле, оста телле тамада искә төшә.

Әмирхан Еники — «хитри». «Төнке тамчылар»да ул шундый банкетларның берсен телгә ала. Беләм мин бу сюжетның каян алынганын...

1964 елның 12 марты иде, бернинди төнге тамчылар юк иде, мин бик шома итеп, шәп итеп сөйләп (бөтен җөмләләрем язылган иде, тексттан башка бер сүз дә әйтмәдем), кандидатлык якладым. Банкет — «Казан» ресторанының кече залында. Минем белән кафедрада эшләүче берничә галим бар, үзләрен эре тотканнардан берикесе килмәде: кем ул — Мәһдиев? Шул булдымы диссертант?

Мәҗлес шәп башланды, шәп барды. Ләкин беренче тәнәфестә үк тар залга таба узганда Г. Бәширов зур залда утыручы ике тере классикны күреп алган: Ә. Еники һәм Ф. Хөсни, ди. Болар белән мин таныш түгел, болар — ул вакытта әдәбият күгендәге ике йолдыз, болардагы кебек шәп мехлы пальтолар, шәп драп, шәп бүрек тагын кемдә икән. Г. Бәширов борчыла гына бит:

— Карале, уйлап кара әле, боларны монда алып керәсе иде бит...— ди.

Ярлы, авылдан килгән, авызын ачса үпкәсе күренергә торган аспирантның диссертация язу дәвамында эшләргә өйрәнгән башы тиз генә әллә ничаклы мәсьәләләр чишә. Дәшмичә генә, күзләрен йомып.

Тәк. «Бер кешегә уртача уникe сум чыгар,— дигән иде шеф-повар, кичтән без Х. Ярми белән калькуляция төзегәндә. Дөрес, өстәл янына тезелеп утырган туган апалар, абыйларның сумкалары тыгыз, ул сумкалар аяк арасында гына: рестораннан җан башына йөз грамм заказ биреп, калганын сумка белән алып килеп, банкет ясаучы туганның хәлен җиңеләйтү ул елларда туганчылыкның иң изге сыйфатларыннан берсе булып санала иде.

Ә, әйе, теге аспирант башы эшли бит әле. Ә ул баш-компьютер боларны бирә: туган апаларның, абыйларның шешәләрен чыгара башларга вакыт. Ул вакытта, бәлки, борын башына ун сум белән дә котылып булыр. Алай булганда, кесәдәге акча җитәр дә.

Һәм бераздан аспирант башы йомгак ясый: чакырырга кирәк. Тегеләр? Һи, тегеләрме? Шундук, теге залдагы официантка белән исәп-хисапны өзделәр дә, түргә үк кереп утырдылар.

Банкет шәп узды, ләкин аның шәплеге минем артык тырышлыгым, кесә тулы акча (!?) һәм туганнарымның аяк арасында кысып утырган сумкаларында гына түгел иде. Нәтиҗәсе озак көттермәде: Ә. Еникинең «Төнге тамчылар»ы дөнья күрде. Анда инде мин дә бар (гел шома димәкче, мондый хәлләрне алдан өйрәнеп, әзерләнеп куйган димәкче); анда инде, әлбәттә, Хәмит Ярми бар. «Тамада итеп мондый мәҗлесләрнең берсеннән дә калмый торган бик борынгы кандидат Кәли иптәшне сайладылар. Кәли иптәш аягүрә басты, тамагын кырды, көлдерергә теләп нидер әйтте, көлүче булмагач, пычак сырты белән шешә муенына сукты һәм коньякларны, столичныйларны рюмкаларга салырга кушты... Монда инде яңа кандидат, яшь килендәй, баштан ук алдына карап, тыйнак кына утырды, чөнки хәзер аның исеменә мактау сүзләре китәчәк. Һәм, чынлап та, рюмкалар күтәрелгән саен, мактау сүзләре егетнең бик дөрес уйлый белә торган өметле башына ява гына торды».

Х. Ярми белән минем адреска никадәр сатира!

Ай-йәй, хитри син, Әмирхан ага! Мин кесәдәге акча запасын исәпли-исәпли иза чигеп утырам, ә син хикәя язып утыргансың икән шул чакта. Авыл халкы әйтмешли, акча эшләп. Алай-й-й...

Еники 12 мартның ябалак карлы йомшак төнен апрельнең тамчылы төненә әйләндергән. Бауман урамының урта бер җиреннән троллейбусларны туктатып, әле пальтосын, әле бүреген кар өстенә ыргытып дулап-җырлап кайткан бер галимебезне Хәлил Ишмаевка әйләндергән. Гайбәтме? Ялгышаммы? Юк, юк. Егерме биш еллар узгач, Пицунда иҗат йортының пляжы буйлап сузылган бетон юлда һәр кичне Ә. Еники белән бергә йөрибез, ике сезон шулай. Йокы алдыннан шулай озак йөрибез.

Еники — «дәүрән калдыгы» — әдәп, ип белән мөсахәбә кылырга ярата, кызмый, ак аракы эчми, затлы эчемлек булганда гына тамак чылатып, «тонус күтәреп» кенә әңгәмә кора белүче, безнең тәрбиясез буын арасында «соңгы могикан».

— Бар әле, бар, нимаешь, бар әле, телевизорны кабызып бирәр фильм карый тор әле, ы-ы, ийе,— дип, ул бүлмә ачкычын Мөршидә апага бирә.— Бар әле, нимаешь, минем бераз гына киңәш-табыш итәсе бар иде, безнең мөсахәбә сиңа бик күңелсез булыр, нимаешь-ли...

Мөршидә апа белеп тора инде, фильм юк, бүген ЦСКА белән

«Спартак» уйный, ләкин ни хәл итәсең — язучы хатыны булуның үз кыенлыклары бар. Кемгә кияүгә чыкканыңны алдан белергә кирәк иде.

...Тыгыз, җылы диңгез һавасы, авызыңны ачсаң, үпкәңә бәреп керә. Рәхәт, моңсу. Август аенда үзебездә дә шәптер, кырдан билчән чәчәге, арыш башагы исе киләдер, бакчаларда түтәлдә кыяр тәгәрәп ятадыр, бәрәңге алмалары купшы кызның алкасы кебек кичке һава дулкынында тибрәнәдер, авылда сөт исе, чыклы бәрәңге бакчаларының исе дулкын-дулкын булып йөридер, ә без — ике төбәк, ике буын кешесе — төнге Рица янындагы алсу ут булып янган тау башларына карап, безгә чит телдә сөйләшкән диңгез дулкыннарының чупылдавын тыңлап бетон юлда йөрибез. Юк шул, дөнья Әмирханын — үзенең кымызлы Дәүләкәненнән, мине — фәкыйрь, тыйнак Казан артыннан, бәрәңге бакчаларыннан, чикерткәләр моңыннан аерган. Юк инде, бер өзелгәч, юк инде. Җырдагыча:

Бер айрылгач, күңелләрең
Сүрелсен инде әйдә...

Әйе, Еники сөйли.

— Ул бит, хикәя, алай гына язылмый. Син инде үзең әдәбият укытасың, боларны гына белергә тиеш. Хикәядәге тамада да Хәмит Ярми генә түгел, пнимаетели. Алай бер кешедән генә язу — минем өчен мөхаль бер эш. Ләкин бит мәсьәләнең шул ягы бар: әсәр «Казан утлары»нда басылып чыккан көннәрдә ничектер татар театрына барып чыккан идем, хәтерләмим инде, берәр юбилей-мазармы, әллә, пнимаетели, берәр яңа спектакль, һәрхәлдә, шунысын тәгаен генә хәтерлим, минем белән кул биреп күрешкән агай-эненең һәркайсы авызын ера иде, бер генә фикер әйтә:

— Әмирхан ага, иллә дә төп башына утырткансыз теге абзыйны,— ди.

Әмма арадан берсе әйтеп куйды:

— Ник син алай галим кешене рисвай итәсең? Без бит аны таныдык,— ди.— Ул бит, ди, как-никак, безнең бүгенге көндә бердәнбер галимебез.

Менә шулай, пнимаетели, мине чорнап алдылар. Бөтенесенең авызында бер генә сүз: «Сезнең героегызны таныдык, бик шәп чыккан»,— диләр. Мин нәрсә әйтим инде?

...Ул төнне без озак йөрдек, «Төнге тамчылар»ны аркылыга-буйга сүттек, Хәмит Ярмине — «мәңгелек тамада»ны сагынып искә алдык. Диңгез буеннан кайтып килгәндә таш-бетон сукмакта безне шатлыклы кыяфәттә Мөршидә апа каршы алды.

— Әмирхан! Әле сез ишетмәдегезме? «Спартак» ЦСКАны өч тә ике белән отты бит! Ну, уйнадылар да инде...

— Һы, шулаймыни? Кара син аны, ә? Өч тә ике, диген. Бу — бик зур хәл инде. Кем уйлаган, ә? Өч тә ике. Ә без менә үткәннәрне сөйләшеп йөри торгач, соңга да калганбыз. Карарга кирәк иде, әлбәттә. Өч тә ике диген...

Без хәерле төн теләшеп хушлаштык. Тагын Хәмит ага искә төште. Юморлы, ләкин сатирасыз кеше иде ул. Әмирхан ага исә әлеге матч турында сөйләгәндә сатирик булып алды, анысы — факт.

...Хөрмәтле укучы! Мин сине ялыктырмадыммы? Хәзер түгәрәклим. Мин моны өйдә грипп белән авырып ятканда язам. Аягымда йон оекбаш, тун бөркәнеп ятам. Юкә чәчәге, кура яфрагы, мәтрүшкә кайнатып эчәм. Кырынмаганыма бер атна. Идән тулы газета-журналлар. Укылып бетмәгән кульязмалар. Эзләсәң, кирәкле даруны да табып булмый. Без шул бөтен җирдә мужик инде: ашаганда да,

эчкәндә дә (анысында бигрәк тә), эшләгәндә дә, йоклаганда да, авырганда да...

Авыру дигәннән. Дөньяда иң матур итеп, авыруны сәнгать дәрәҗәсенә менгереп авыручы бер кеше белә идем мин. Ул авырганда бер-ике тапкыр өенә хәл белергә бардым. Кая ул безнең яту! Безнеке — аунау ул, белдегезме шуны?

Ә теге танышым...

Полировкалы бер кешелек агач карават. Аның янында шундый ук төстә (куе чия) тумбочка. Аның өстендә ике стакан. Аларның эченә градусник, бал калагы бастырып куелган. Шунда ук бер-ике шешә сыек дару. Бер-ике тасма төймәле дарулар. Рецептлар һәм зәңгәр кәгазь — бюллетень. Аяк очындарак терәкле урындык. Анда бүген килгән газеталар, «Казан утлары», «Азат хатын», бер-ике русча журнал, Тур Хейердал китабы, академик Конрадның монографиясе һ. б. Тагын... түрек телендә «Казан» журналы.

Авыру үзе бөтен буена сузылып яткан, чәчләр чиста, ияк-яңак шома итеп кырылган, йомшак юка дөя юрган ияк астына кадәр килеп, гәүдәне каплаган да, ак җәймә белән каймаланып кул яссуы кадәр кирегә кайтарылып куелган.

Авыру елмаеп миңа дәшә, утырырга урын күрсәтә.

— Нихәл, балакай, нигә вакытыңны әрәм итеп йөрисең?— ди.— Без картлар ятарбыз да, торырбыз да, ә сиңа тиздән докторлыкны якларга кирәк,— ди. «Доктор» сүзен ул үзенчә каты «к» белән әйтә иде, аеруча зур басым ясап әйтә иде.

Бу «матур авыру» — Хәмит ага Ярми.

Мин бу авыруның башын да беләм. Яшьлегемдә миңа Шәйхи Маннур, Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Хәмит Ярмидән торган «дүртлек» иттифакының бик күп мәҗлесләрендә катнашырга туры килде. Бу картларның бер дә ялгыштырмыйча үтәп бара торган изге бер йолалары бар иде, ул — туган көн. Моңа алар берәр атна алдан әзерлек башлыйлар, телефоннан сөйләшүләр, ярым-йорты ымлыклар белән аңлатулар китә.

— Абзыйның теге көне җитә бит, онытмагансыңдыр?

— Ие шул, үзем дә әйтермен дип тора идем. Берәр ызнак ясыйсы булыр инде.

— Ансыз ярамас инде. Нишлибез, аерым-аерыммы, әллә бергәләпме? Бер колхоз булыйкмы әллә?

Шулай, исем-фәләнне әйтмичә генә сөйләшүләр. Менә Хәмит аганы чакыру вакытындагы диалог...

— Ни хәлләр? Кәефләр ничек? Вакытлар бик тыгызмы?

— Ярыйсы әле, абзый. Муеннан эш. Күптомлыкны әзерләп ятабыз. Баштан пар чыга.

— Ник, барысына да үзең йөгермә инде. Син бит анда — бердәнбер доктор. Шәкертләреңне эшләт.

— Һай, абзый, җиңел уйлыйсың да инде. Шәкерт бит ул — күзколак булсаң гына шәкерт. Эш күп, авырырга да вакыт юк. Әле менә бер-ике срокка Ялтага барып эшләп кайтмакчы булам. Билет кесәдә инде. Авырып китмәсәм...

— Алай икән... Ниме, син алай бик каты эшләгәч, онытып та җибәргәнсеңдер инде. Иртәгә бит Шиһап солдатның (Ш. Маннурны дуслары ихтирам белән үзара шулай йөртәләр иде)... Беләсеңдер.

— Ай, абзый, әле эш белән барысы да онытылган иде бит. Иртәгә дисеңме? Юк, бара алмам.

— Нәрсә булды, берәр көтелмәгән мәшәкать чыктымыни?

— Юк, эш анда түгел. Ну бит, абзый, үзең беләсең: моторчик шәптән түгел бит минем. Шаяра бит. Бу докторлык бушка гына бирелмәде инде ул. Мин бара алмам. Мәҗлес бик хәтәр нәрсә минем өчен.

— Соң инде, анда коры-фәлән генә була. Шиһап солдатны беләсең инде: дүрт борынга бер шешә «Рислинг»ы була инде аның. Йә бер шешә «Ркацители».

— Ай-һай, абзый, мине егып куймагай идегез. Белмим, белмим...

Көне буе Ярми агай белән шундыйрак сөйләшү бара. Бераздан Х. Туфан, аннан Г. Бәшировларның туган көне җитә. Һәрберсендә шулай. Ләкин Хәмит агай ул мәҗлесләргә килмичә калмый. Затлы костюмнан, өр-яңа күлмәк-галстуктан (татар зыялылары арасында иң шәп киенүче кешеләрнең берсе шул иде), ялтыр штиблетлардан...

Мәҗлеснең үзәге — Ярми. Мәзәк — аннан. Кызык хәлләр — аннан. Әлбәттә, тамада.

Тамада — грузин сүзе. Россиягә бу сүз егерменче гасыр башында кергән (мәҗлестәге өлкән ага мәгънәсендә), алтмышынчы елларда «капитально» эчә башлагач, безнең сөйләмгә дә килеп керде. Ләкин без аның, тамаданың эшен «әйдә, күтәреп, эчеп җибәр» дип команда бирүгә генә кайтарып калдырдык. Мәҗлеснең өлкән агасы исә (грузинча — тамадоба) — мәҗлесне оештыручы, алып баручы, кытыршы якларны шомартучы режиссер булган һәм кавказ халыкларында бу кеше мәҗлестәге һәр кешенең күңелен бөтен итеп, һәркем канәгать булырлык итеп эш оештырган. Безгә, чабатадан чыккан малайларга, тегендә-монда Рәсүл Гамзатов, Кайсын Кулиев катнашкан мәҗлес читләрен күргәләгән татар язучыларына җитә калды: һәркем тамада булырга омтылды, ярыш башланды. Ләкин бит традиция юк: төрки бабайлар мәҗлестә эчмәгәннәр. Тамадалык — шәраблы Кавказ халыкларына хас. Дөрес, безнең бабаларның мәҗлесләрендә дә хуҗа булган: аш бүлгән, каз тураган, бәлеш ачкан, касәләргә ширбәт салган. Өлкән кешедән башка мәҗлес булмаган. Без исә тиз генә грузин булмакчы булдык. Юк, бер милләтнең буявы икенче милләткә күчергәндә төссезләнә. Без «тамада» сүзен дә үзебезчә аңлатмакчы булдык. Тамада, имеш, тәгам атасы дигән сүздән икән. Кайбер иптәшләр мәҗлес саен баш миләребезгә шуны тукыды. Әй бездә наданлык, кадерен белеп тотсаң — гомерлек.

Грузинның нәрсә? Аның максаты — мәҗлесне күңелле итеп алып бару. Һәркемнең күңеле бөтен булсын.

Безнең нәрсә? Тамада дигән безнең буын кешесе мәҗлескә «чинопочитание», ялагайлык, мәкер алып килде. Безнең буын тамадасына карагыз, тыңлагыз: мәҗлестә иң беренче башлап үзенә файда тидерерлек кешегә сүз бирә ул. Безнең тамадалар алып барган мәҗлес — шәхесне сыту, имгәтүдән, мыскыл итүдән тора. Безнең тамада җәмгыять иерархиясендә синең урыныңны билгели. Йә, ир кешенең хәлен аңлагыз инде: син — гадәти бер язучы, хатыныңны култыклап алып кеше төсле банкетка килдең, урын алдың, утырдың. Мәҗлес башланды. Тамада сүз бирә: директорга, редакторга, председательгә, бүлек мөдиренә, тагын чуртымнарга. Ә сиңа — юк, бирми. Син көтеп утырасың, хатының да көтеп утыра. Мәҗлес бетә, сиңа сүз бирмәделәр. Шуның белән тамада сине үтерде: син — бу җәмгыятьтә ноль, диде.

Алар эчүчеләр түгел иде, тик Хәсән Туфан белән Шәйхи Маннур төтенне «чигәләр» иде инде...

Иртән картлар телефоннан хәл белешәләр.

— Ни хәлләр, башлар бик авыртмыймы?

Баксаң, иртүк уянып, Гомәр Бәширов инде бер табак корректура укыган, Хәсән Туфан таң атканчы утырып ике строфа шигырь язган, Мөдәррис Әгъләмов дигән бер малайның зур бер поэмасын редакцияләгән, Шәйхи Маннур исә үзенең мең ике йөз битле романының кулъязмасында редактор искәрмәләрен карап чыккан да, иртәнге тугыз тулганны көтә, Матбугат йортына барып редакторның

җиде кат тиресен тунап кайтырга әзерләнә, читлектәге арыслан-дай йөренә, сигарет тарта.

Ә Ярми? Ә Хәмит Ярми?

— Ни хәлләр, Хәмит туган? Кәефләр ничек?

Телефоннан авыр тавыш ишетелә:

— Аһ, ыһ... Ие, мин. И-и абзый... Беләсез бит инде. Әйттем бит инде. Ну да сакламыйсыз инде энекәшегезне. Менә мине бәреп салды инде бу. Ялта путевкалары яна инде. Белеп торасыз инде минем моторчикны...

Әнә шундый сөйләшүләрдән соң аның янына берәм-берәм әле-ге «дүртлек» иттифакы әгъзалары барып кайта, алда әйткәнемчә, бер-ике тапкыр миңа да туры килде. Тик... Ялта — янмый. Тора ул, тора Хәмит Ярми урыныннан, дус-ишләре бер кат рәвешен күреп чыккач, тагын өч-дүрт кеше килеп киткәч, Ярми агай тора һәм эшкә чыга.

Үз гомеремдә шифаханәләргә пакет, сумка тотып мин күп йөр-дем. Дөресен әйтим — туганнар, дуслар янына. Нәшрият директоры янына да кергәләдем, ләкин ул — акыллы кеше — аңлый иде, һәм икебез дә ояла идек. Минем китап чыгарасым бар бит, шуңа күрә генә кергәнмен бит аның янына. Ул директорлыктан төшкәч, алай йөрмәячәкмен-бит мин. Ул моны белә, аңлый иде.

Ә дуслар янына... Микстура салынган шешәгә даруын түгеп хәмер саласың. Шешәдә язылган: «Перед употреблением взбал-тывать». Шаян бер иптәш аскарак төшереп язып куя: «После упот-ребления не болтать». Ха-ха-ха! Гөлдерәп көләбез, яшь чакта авыру да, шифаханәгә кереп яту да бер мәзәк кенә.

Ләкин Хәмит ага чынлап, җитди итеп авырый. Аның янында бу вакытта юмор була алмый.

Ярми агай тора һәм эшкә чыга.

Килә, кабинетына уза, өстен салып ялтыравыклы кара сатин халатын киеп куя, кәгазьләренә чума, телефоннан берәр сүз булса, өстәлдән тиз генә картотека кәгазен ачып нидер яза да, күкрәк ке-сәсенә тыгып куя, берәр сәгатьтән чәй китерттерә, аннан урамга чыгып йөреп керә, бераздан тагын эшкә чума. Филиалның фольк-лор секторына ямь биреп утыра, йөри.

...Аның докторлык диссертациясе «астына» чыгарылган моно-графиясенә, үзенең үтенүе буенча, мин рецензия язган идем. «Казан утлары» журналының җаваплы сәркатибе Ләбибә Ихсанова белән сөйләшеп, Ярми ага ул рецензияне журналда бастыруны кайгыртты. Бик шат йөрде, бичара, балаларча беркатлы иде, туктале, бу малай нәрсә язды икән, дип барып укып та карамаган. Журнал материалы бит, иң аз дигәндә дә, ярты ел гына ята редакциядә. Ә мин беләм, яңа буын яшьләре бар, аларга берәр рецензия язгач, редакциягә ба-рып, аны укып, хәтта үз адресларына мактау сүзләре өстәп йөрүче-ләр бар. Ә Хәмит ага ышанган: рас мин «балакай» язгач — шәп булачак. Ә минем анда ачы-ачы гына тәнкыйть сүзләрем бар иде. Рецензия шулай була бит инде. Дөресрәге, шулай булырга тиеш.

Рецензия чыкты, зур гына, саллы гына мәкалә иде. Нигездә уңай, ләкин тешле иде.

Хәмит ага миңа чын күңелдән рәнҗегән. Каргаган. Сүгенгән.

— Дөмексен, башы бетсен, мин аны юньле малай дип йөреп бик зур хата эшләгәнмен,— дигән.

«Дүртлек» иттифакы әгъзаларының барысына да шулай сөй-ләгән.

Хәмит аганың каргышы миңа төште. Изге җан булгандыр ул. Күпмедер еллар узгач, минем «докторский астына» язылган моно-графиямне, әләкләр язып, әйләндереп-түгландырып туктатып кал-

дылар. Бу монография нибары өч экземпляр булып дөньяда яши. Моны туктатуда филиал галимнәре, КПСС өлкә комитетының торгынлык елларында тарихыбызны, культурабызны изеп, пычратып яткан җаваплы түрәләре, главлитның надан, ялагай хатыннары, үзем эшләгән кафедраның радиодан яңа хәбәр булган саен иманнарын алыштыра торган иске галимнәре, филиалдагы яңа бюрократлар актив эшчәнлек алып бардылар.

Хәмит агайның каргышы төште миңа...

Ләкин ВАК та аның докторлык диссертациясенең язмышын хәл иткәндә минем рецензиянең русчага тәрҗемәсен укыганнар (аны Ил Саттаров юлга-юл тәрҗемә иткән иде, дип хәтерлим) һәм, имеш, зур кешеләрнең берсе әйткән:

— Менә бу рецензия әлеге диссертациянең язмышын хәл итә дә инде. Гел мактаган гына булса, әлбәттә, ышанмыйдыр идек. Чөнки, диссертациягә килгән отзывларның төрлесе бар. Кемнәр «за»? Кемнәр «против»? Юк? Димәк, бертавыштан...

«Доктор» Хәмит агай минем белән гел якын итеп сөйләште шуннан соң. Ләкин элеккеге җылылыклар юк иде инде — ул да олаеп китте, минем дә чәчләргә ак йөгерде, элеккеге «балакайлык»-тан чыктым.

...Фәннәр Академиясенең Казан филиалына мин әле дә кереп йөрим. Анда мине өнәп бетермәгән галимнәр бар, үземнең элеккеге укучыларым да байтак. Ул укучыларымның бик күбесе инде фән кандидатлары. Гыйлем йортын бик яратам мин, шундагы тар коридорларда кыштыр-кыштыр килеп профсоюз эше эшләп йөргән мәҗнүн яшь кызларны, дөньяда миннән дә акыллы кеше юк дип ышанып, үз фәненнән башка бөтен нәрсәгә пүчтәк дип карап йөргән тел, әдәбият, тарих галимнәрен — үземнең кичәге укучыларымны яратам.

Тик... тик... гаеп итмәгез инде: филиалда кара сатин халат кигән, себерчә киң елмайган, әдәпле, балаларча самими күңелле, үпкәчән агай — зыялы Хәмит Ярми юк. Шул җитми. Тар коридорлардан ул узганда, ничектер, коридорлар киңәеп кала иде...

# Пицунда

*Не знаю, что стало со мною,*
*Душа моя грустью полна...*

Һ. Һейне

## Зәй артисты

Пицунда — грекча нарат дигән сүз, имеш. Гомеремнең байтак җәйләре шул оҗмахта узды.

...Бу эш моннан унбиш еллар чамасы элек булды: язучыларның Пицундадагы иҗат йортында Роберт Батуллин белән бергә ял иттек, дөресрәге — һәркем үзенә бирелгән аерым бүлмәдә иҗат эше белән шөгыльләнде, калганын үзең кара — җылы диңгез, кояш, комлы пляж, кичен кино-мазар... Кыскасы — рәхәт... Ә рәхәт чиккәндә кеше беркайчан да гадәти итеп яшәүгә риза булмый. Мөгез чыгарасы килә. Бу сыйфат минем үземдә дә, ихтимал, юк түгелдер, әмма Зәй ягында туып үскән Робертта ул байтак ук көчле иде. Ул үзе миңа берничә мәртәбә әйтте:

— Без, Зәй яклары, гадәти түгел. Без тормышта — гел артист. Без — маска киеп яшибез. Без кешеләрне, тормышны өйрәнәбез, кешеләрнең кайвакыт бөек, кайвакыт беркатлы — наив, кайвакыт бик түбән булганнарын күзәтәбез. Бөтен хикмәт шунда, кешеләр безнең чын йөзебезне аңлап бетермиләр. Зәй яклары — без шулай. Алып кара син — танылган язучы... Алып кара син — танылган сәхнә эшлеклесе...

Һәм ул берничә фамилия саный. Ахырдан гел бер сүз:

— Без кыланырга, рольдә уйнарга яратабыз. Без — маска киеп яшәүчеләр.

Баштарак мин моны аңлап бетерми идем, әмма, берәр атна бергәләп яшәгәннән соң, аңлый башладым кебек. Ничекме? Роберт үзе моны эш-гамәле белән күрсәтеп аңларга ярдәм итте.

...Пляж. Якты, җете кояш. Мәскәүле ханымнар ярым чишенүнең, кояш астында кызынуның, дулкында йөзүнең иксез-чиксез рәхәтлегенә генә риза булмыйча, каядыр, камышлар төбенә барып анадан тума чишенеп кызыналар. Кемдер акваланг белән чума, кайсыдыр берсе гарпун белән су астында балык чәнчеп үтереп йөри. Ә Роберт?

Ул һәр ходай бирмеш иртәне душ астына кереп чәчен бритва белән кыра. Үз башыңнан үз чәчеңне кыру гадәттән тыш авыр бер хәл инде ул, әйтик башыңның артын ничек кырырга? Ә бу — кыра. Көн саен. Канатып бетерә. Канаган урыннарына кәгазь ябыштыра. Күз алдына китерегез: камыт бөяте шикелле яңаклар, иякне чорнап алган куе кара сакал һәм... ялтырап, зәңгәрен чыгарып кырган ямаулы сөяк баш. Иртәгәсен пляжда бөтен кеше моның яныннан бер узып китмичә булдыра алмый. Кем бу? Нәрсә бу? Җитмәсә, Роберт баш очына транзисторын куя да һичшиксез Төркия радиостанциясен тота. Аның янында гел төрек моңнары гына агылып тора. Ә нинди еллар! Тыңлар өчен бит башка җырлар бар: БАМ турында, «Кече җир» турында. «Партия наш рулевой», «Товарищ генеральный секретарь» дигән җыр тыңларга тиеш бит нормаль кеше. Бу юк, бу — төрек музыкасын тыңлый. Көннәрдән бер көнне Роберт яңа мөгез чыгарды. Эре чуерташларны өч җиргә өеп, шулар өстенә сузылып ятып кызына. Аяклар бер өемдә, баш икенчесендә, арка тагын бер өем белән терәтелгән. Шулай сәгатьләр буе, бер-ике көннән, ахырысы, бу да туйдырды. Ләкин уен тузы әле чыгарылып салынмаган иде. Ялның соңгы көннәре иде. Кояшлы рәхәт бер көн, комда аркаң пешәрлек. Ханымнар иртәнге аштан соң тулы рәхәт күңел белән диңгез буена ашыктылар. Тиз-тиз чишенделәр, зәңгәр фирәзә дулкыннар эчендә шоколад төсенә кергән тәннәрен ялтыратып дельфиннар булып йөзәселәре килә иде. Кинәт бер ханым шыгыйлап кычкырып җибәрде. Аннан тагын берсе. Тагын берничәсе. Халык шул тавыш килгән якка карады. Карасалар. Комда бер баш ята. Адәм башы. Зәңгәрләтеп кырылган, яннан, ияктән куе сакал белән уратылган. Батуллин башы. Кешеләрне курку алды, тик мин генә елмаеп бер читтә басып тордым. Теге сүзләрен исемә төшердем:

— Без, Зәй яклары маска киеп кыланып яшәргә яратабыз.

Әлбәттә инде ул пляжга алданрак төшеп гәүдәсен комга күмеп теге такыр башын гына калдырган. Күзләр йомык иде.

Шул көнне лифтта миңа бер ир дәште.

— Слушай, теге ямьсез синең якташыңмы ул, сезнең сөйләшкәнегезне ишетеп йөрим мин,— диде. Бүген пляжда иң беренче булып куркып, кычкырган ханым — аның хатыны икән.— Әйт әле шуңа, кыланмасын иде, зинһар,— дип күзләрен мөлдерәтеп карап куйды теге ир.

Мин аңа Зәй ягы фәлсәфәсен ничек аңлатыйм инде, алар Көнбатыш Украинадан. Зәеңне түгел Казаныңны да ишеткәннәре юк.

Бер-ике көннән без Казанга кайтып кердек.

Роберт юлга чыгасы көнне дә чәчен шулай алды, дөресе — башын тунады.

Бер-беребезгәияләнеп, үзара ихтирамыбыз артып кайттык. Казанда бер кич кунуыма иртән сатучы бер танышым чылтыратты.

— Син сораган гарнитур килде, сәгать унбергә акча белән кил,— диде.

Мин ашыгып кына җыена башладым, саклык кассасындагы таныш хезмәткәргә чылтыраттым (безнең кассабыз бик тыныч, кечкенә, кайвакытта аларда акча да булмый, зур сумма аласы булганда алдан әйтүне үтенәләр).

— Миңа ике мең ике йөз сум акча әзерләп куегыз, пожалуйста,— дидем.— Мин нәкъ сәгать унда сездә булам.

Әзерләп куярга вәгъдә иттеләр.

Мин киенеп өйдән чыгып китим дигәндә генә тагын телефон. Батуллин икән. Сагынышканбыз да.

— Сине күрәсе бар иде бит, планнарың ничек?

Мин мәсьәләне тиз хәл иттем:

—Әйдә нәкъ сәгать унда сберкассада очрашабыз, мин акча алырга барам,— дидем һәм адрес өйрәттем. Ул риза булды.

Трамвай, автобус көтеп, әлбәттә, инде соңа калдым. Нәкъ ярты сәгатькә соңарып, Роберттан гафу үтенергә җыенып кассага керсәм... Керсәм... Бүлмә тулы валериан исе. Ярым караңгы. Бер клиент та юк. Барьер артына күз салам — өч урындыкны бергә тезгәннәр. Шунда контролер кызны сузып салганнар. Кассир ханым аның пульсын тоткан. Каушап калган. Мине күргәч тиз генә тәрәзәчек янына килде. Беравык берни дә әйтә алмыйча торды. Аннан, тыны бераз җибәргәч, тотлыга-буыла сөйләп бирде. Сөйләүдән шул аңлашылды: ун тулып нәкъ ун минутта кара бөят сакаллы, кырган ямаулы башлы берәү кассага килеп керә дә:

— Мәһдиев акчасын алдымы әле? — дип сорый. Контролер кыз шундук егыла. Кассир ханым сигнал кнопкасына басарга җыена, әмма кулы калтырый, кнопкага туры китерә алмый. Роберт берни аңламыйча чыгып китә, кассир ханым исә валерианкага ябыша.

Контролер кызны аңына китергәнче, эшне аңлатып биргәнче ярты сәгатьләр вакыт узды. Роберт белән без урамда очраштык. Акча да алган булган идем, тик мин барып җиткәндә, срогы узу сәбәпле, теге гарнитур сатылган иде инде.

Без әнә шулай мебельсез калдык. Хәзергесе инде кирәк тә түгел, хәзер мебельне йомычкадан, кләйдән ясыйлар.

## Шиһап солдат

Шәйхи Маннур белән болай таныш-белеш идек. Өстән генә. Ул бик ачы телле кеше, төртмә сүзле, үзенчә кире, үзенчә гадел, үзенчә кырыс һәм таләпчән язучы иде.

Минем беренче хикәяләрем журналда чыккач, бер очраганда күреште дә, күзгә «ехидно» карап:

— Һай, һай, һай,— дип телен шартлатты да китеп барды. Тагын бер елдан шул ук «Казан утлары»нда беренче повестем басылды. Анысында Шәйхи абзый, күрешкәч, юка иреннәрен ялаштырды да:

— Инде поэма язасың гына калды,— дип, ачы елмаеп китеп барды.

Мин аңладым. Безнеңчәгә тәрҗемә иткәндә:

— Синең дә безнең арага керәсең килеп йөримени инде? — дигән сүз иде бу.

Ләкин, Пицундада бергә туры килеп, без аның белән уртак тел таптык, дуслаштык. Ул, өлкән яшьтә булуына карамастан, үзен егетләрчә тота, иртән бик озаклап йөзә иде. Пляжга бергә чыгабыз, суга бергә керәбез. Ул, яр буеннан егерме метрлар чамасы эчкә кергәч, су өстенә кулларын җәеп чалкан ята да, тын кала. Күккә карап шулай озак-озак ята.

Яшь ханымнар өлкән яшьтәге бу кешенең шулай кыю булуына гаҗәпләнәләр. «Аңа ничә яшь?» — дип сорыйлар. Минем җавап бер генә:

— Ул элеккеге шахтер,— дим.

Яр буенда һава сулап йөргәндә Шәйхи абзый сөйли:

— Менә син инде татар халык иҗатын укытасың. Бу турыда мәкаләләрең дә чыккалап тора. Менә син бер сорауга җавап бир: безнең татарда шахтерлар фольклоры дигән бер өлкә бар. «Шахта көе» дә бар. Башка милләтләрдә андый фольклор юк. Шуның сәбәбе нәрсәдә? Ә? Белмисең?

Билләһи, үзем шул фәннән лекцияләр укыйм, үземнең бу турыда уйлап та караганым булмаган. Әйе, Шәйхи абый, белмим. Билләһи, белмим. Шунда ул, безнең чорның диссертацияләре, монографияләр, аспирантуралар турында берничә тозлы сүз әйтә дә, сөйләп китә.

— Татарның тимер юлда, станокта, элемтә системасында эшләрлек техник хәзерлеге юк. Бәхет эзләргә чыгып киткән татар егетенә бер генә юл бар — шахта. Чөнки анда техник әзерлек кирәк түгел ул заманда, тачка, кәйлә, көрәк белән эш итү өчен нибары физик көч кенә кирәк. Ә татар егетендә ул бар. Шуңа күрә шахтерлык ул — безнең милли сыйфат. Әнә шулай аның үз фольклоры да туган.

Бу — әлбәттә, минем өчен ачыш иде. Бераздан мин моны, үз белгәнем итеп, лекцияләрдә файдалана башладым.

...Шәйхи Маннур (дуслары Г. Бәширов һәм Х. Ярми аны, ни сәбәптәндер, «Шиһап солдат» дип йөртәләр иде) минем өчен күптән «башланган» шәхес. 1937 елларда дәреслекләрдән Тинчурин, Ибраһимов, Ш. Усмановларны алып ташлаган чор. Әдәбият кансыз, егәрсез калды. Ләкин ул чор — лидерлар чоры иде. Тракторда мы? — Паша Ангелина. Тимер юлдамы? — Бусыгин. Күмер чабудамы? — Алексей Стаханов. Мамык җыюдамы? — Мәмләкәт һәм башкалар. Бәс, шулай булгач, әдәбиятта нигә әле лидер булмасын. Татар әдәбиятында бармы андый лидер булырлык кешеләр? Булмаса, табарга кирәк. Кави Нәҗми лидерлыкка ярамый, төрмәгә кереп чыкты (ничек чыгарганнардыр!) Боларны мин хәзер шулай, чигереп уйлыйм инде, ләкин теге, сабый вакытымда да лидерлыкка бераз шигем бар иде, ни әйтсәң дә Тукайны укып үстем. Шулай кырыгынчы елларга таба татар әдәбиятында өч жанрда өч лидер барлыкка килде. Боларның исемен әйткәндә «орденлы» дип әйтәсе иде — безгә гаҗәп — язучының ордены буламыни? Аның бит әсәре генә була. Шулай, орденлы шагыйрь Ш. Маннур, орденлы драматург Т. Гыйззәт, һәм орденлы язучы Ш. Камал барлыкка килде. Шәйхи абыйның шакмаклы пиджак якасына орден тагып төшкән рәсеме дәреслекләргә урнашты. Рәсемнән соң «Гайҗан бабай» поэмасы килә иде. Бу поэманы без яттан бикләдек. Анда бит безне кызыктырган бик хикмәтле бер вакыйга бар: Гайҗан бабайны колхозда алдынгы булганы өчен ике канатлы самолетка утыртып колхоз басулары өстеннән әйләндерәләр. «Әйдә, карчык, син дә тырышып эшлә, бергә очарлык булсын ыштубы»,— ди Гайҗан карт. Ике канатлы самолетлар безнең басу өстеннән очалар иде ул заманда. Һәм без, малайлар, күзләрдән яшь чыгарып, җирдә мескен булып карап кала идек.

Ә бер көнне безнең басуга да «трети әвеслеге» янына (ягъни, өченче бригада әвеслеге янына: колхозлашу белән бергә авылда милли сүзләр кысрыклана башлаган иде инде — бригада, плуг, сеялка, триер, ударник, стахановчы, молотилка, звено, ефремовчы һ. б.) ике канатлы самолет килеп утырды. Авылда бер генә кеше калдымы икән? Шунда агылдык. Нәкъ Гайҗан бабай поэмасындагыча булды: кара күн тужурка, зур пыялалы күзлекләр киеп, тез астына кадәр салындырып күп сумкалар аскан таза ике ир халык уртасында басып тора иде. Алдынгы колхозчылар арасыннан берәү дә Гайҗан бабай кебек күккә менәсе итмәде, курыктылар, ә минем яшьтәшләрдән ташбаш бер малай риза булды. Самолетның күтәрелгәнен, авыл өстеннән әйләнгәнен тын алмыйча карап тордык. Ул көнне авылда бер әтәч тә кычкырмады. кош-корт, эт-мәче куркудан барысы да лапас астына, бәрәңге сабагы арасында, иске мунча артына посып беткәннәр иде. Ә без ул көнне дәреслекне эзләп табып тагын Гайҗан бабайны укыдык.

...Без Шәйхи абый белән кичке аш сеңдереп аллеяда йөрибез, мин аңа болар турында сөйлим. Ул кырыс кына тыңлый, аның нәрсә уйлаганын белеп булмый. Ул — драматик шәхес. Менә ничә еллар буе инде ялгыз яши, кибеттән ашау-эчү әйберләрен үзе ташый. Аның көндезге ашы — Татар ашлары йортында. Ул йортның кайчан, ничек ачылуы турында бу урында сөйләп узарга кирәк дип уйлыйм. «Язгы җылылык» еллары иде ул. Казанда 1937 елда кулга алынган кешеләрне реабилитацияләү комиссиясе эшли, анда-санда исән калган «сәясиләр»нең кайтуы турында сөйлиләр, элеккеге кайбер милли журналлар кабат чыга башлый. Һәм, «Менә сиңа мә!» — дигәндәй, Бауман урамында Татар ашлары йорты ачыла. Бу — 1957 ел булса кирәк. Ул бина бер ярым катлы, бер генә заллы, иске — тарихи бик гүзәл бер йорт иде. Менә инде йорт ачылу Казан татарларының күзен ачып җибәрде: бәрәч, татар дигән сүзне эш-гамәлгә мөнәсәбәтле итеп тә кулланып була икән бит! Укымышлы халыкның телендә бер генә шәхес булды: обком секретаре. Әйе, Семен Денисович Игнатьев — әнә шул рус кешесе ул елларда өлкә комитетының башында тора иде. Имеш, шул әйткән: ачыгыз шундый йорт, дигән, анда милли ашлар пешерегез, әмма хәмер кертмәгез, дигән. Карагыз ул алфавитыгызны, рәтләгез, дигән. Укытучылар съезды булганы бармы? Юк. Уздырыгыз. Хәбәрчеләр съезды булганы бармы? Уздырыгыз. (Мактанып әйтәм: һәр икесендә делегат булып катнаштым). Ул шәхес, безнең кайсы милләт кешеләре икәнлегебезне аңлата язып, бераздан Мәскәүгә эшкә китте. Элек-электәннән килә инде ул, юньле җитәкче дә, юньсезе дә Казанда озак тора алмый...

Ашханә. Татар ашханәсе. Төш вакыты. Зәңгәр атлас күлмәк кигән, ак алъяпкыч япкан, башларына энҗеле калфак кадаган чибәр яшь хатыннар, кызлар көмеш подносларр күтәреп өстәлләр арасында балык кебек йөзеп кенә йөриләр. Ризык менә болай: токмачлы аш, сыер итеннән, катык — шул йортта оетылган; өчпочмак — бик һәйбәт сарык итеннән; хәер, өчпочмак белән шашлык бары тик сарык итеннән генә була, хәзер генә ул, милләтләрне бутап бетергән кебек, ризыкны да бутап, милли төсен югалтып ләззәтен алдылар. Чын фарфор чынаяклларда хуш исле чәй, шикәре, өреге-мазары да аерым касә белән бирелә. Җиңелчә генә музыка: Рәшит Ваһапов, Зөләйха Хисмәтуллина, Җәваһирә Сәлахова, Шәфыйка Котдусовалар җырлый. Бервакыт боларга яшь Илһам белән яшь Әлфия моңы да өстәлә.

Һәр ходай бирмеш көннең нәкъ көндезге бер сәгать утыз минутында Татар ашлары йортына Шәйхи абый килеп керә. Ашыкмыйча гына чишенә, үзе иялләнгән өстәл янына зал буйлап шерт-шерт атлап (өс-аяк киемнәре бик затлы була иде) килеп утыра, кулына меню ала. Официанткалар болай да белеп тора инде нәрсә китерәсен: бер чынаяк чокыры катык, токмачлы аш, өчпочмак, өрек җимеше белән чәй. Лә-

кин официанткалар башкасын да белә: бу абзый бик таләпчән, ә... биргәндә бу бик күп сорау бирәчәк. Мәсәлән, болай: катыгыгыз монда оетканмы, әллә хөкүмәт кибетендәге шешәле катыкмы? Катык урынына «мә, тагын» бирергә уйламыйсызмы? Токмачыгыз кулдан кисәнме? Заводта станок белән кырдырып ясаган макарон түгелме? Аштагы ит үгез ите түгелме? Йомшакмы? Өчпочмакның камырына сары май кушылганмы? Чәй нинди? Сәйлүн-фәлән юкмы? Һәм башкалар.

Шуңа күрә Шәйхи абый ашханәгә килеп кергәндә бөтен официанткалар корпусы дерт итеп куркып кала. Шулай, еллар буе. Картайгач та...

— Әнә теге бабай тагын килде инде!

Бу — хәвефле сигнал, бу — кибеткә көтмәгәндә ревизия килеп төшү, сәркәсе белән өендә утырган ирнең хатыны һич тә көтмәгәндә кайтып төшү кебегрәк халәттә калу иде.

Бу турыда мин нигә бик озын язам? Сәбәбе бар: ашханәдәге бер хәлне искә алуым аркасында Шәйхи абый миңа мәңгегә рәнжеде. Шул көе дөньядан китте һәм мине гомер буе үкенергә дучар итеп китеп барды. Мин наданга шул кирәк тә...

...Таләпчәнлек. «Кеше китә — җыры кала» дигән повестымны Шәйхи Маннурга әчке рецензиягә биргәннәр иде. Нәшрияттан. Ул бик бәхәсле әсәр иде, аны Ә. Еники, А. Расих, Я. Халитов укыды, журнал редакторы тунады — ахырдан, хак сүз әйтер өчен, Шәйхи абыйга бирделәр. Бер экземплярда алтылап кешенең искәрмәләре. Ул кулъязма миндә тарих өчен саклана. Шәйхи абый ахырга «Моны басарга кирәк» дип имзасын куйган. Әмма әчендәге искәрмәләре инде! Күпме горчица, борыч, үт сыекчасы була икән кешенең телендә.

Мин язам: «атны төз лапас астында кертеп туардылар». Безнең Арча ягында крестьян кыш керер алдыннан төз лапас ясый. Аның түбәсе туры булып, андагы киштәләргә бәрәңге сабагы, салам өяләр. Яннарын да шулай авыш киштәләргә салам, бәрәңге сабагы өеп каплыйлар. Бәбкә-киштәле, кыек түбәле абзар-кура белән арасында шулай ышык коридор ясала, мал карарга яки башка йомыш белән чыкканда буранга-карга эләкмисең. Төз лапасны язын сүтеп алалар, ишек аллары яктырып китә. Минем җөмлә янында рецензент искәрмәсе: «Һе, лапасның кәкресе дә була икән. Ш. М.» Мин язганмын: «Сабантуй мәйданына ат сбруяларының куе исе таралган иде». Рецензент: «Һә, шулай диген. Дирбия, ат дирбиясе дигән сүзне белмибез, диген». Беткәнче шулай. Мин кулъязмамны укыганда Шәйхи абыйның усаллыктан кысылган юка ирennәрен күз алдыма китердем. Бу кеше белән шаярырга ярамас. Ярамас. Бер редакторның сөйләгәнен хәтерлим. Шәйхи абый үзенең «Муса» романын китерде, ди. Укып чыккан редактор. Искәрмәләрен кәгазь кырына яза барган. Редактор сөйли — нинди каты күңелле, таләпчән, имансыз редактор инде — ул да югалып калган. Дөньяда аны да сындырлык авторлар бар. Әйе, ул сөйли. Шәйхи абый кулъязманы укып кире китергән. Редакторның һәр искәрмәсенә кәгазь кырыенда Шәйхи Маннур үз реакциясен-мөнәсәбәтен белдереп барган. Тик сүз белән түгел, ә ни бары ике хәреф белән. Һәр хәрефтән соң нокталар куеп. Боларны редактор әле аңламаган. Аның бер генә искәрмәсен дә автор кабул итмәгән, һәр очракта теге ике хәрефне куеп барган. Мең битлек (әллә мең ике йөзме?) кулъязмадагы бик еш кабатланган теге ике хәрефне аңламыйча, редактор авторны чакырткан.

— Мин моны аңламадым, Шәйхи ага, нәрсә соң бу? — дигән.

Шиһап солдат шунда пиджагының уң кесәсеннән фольгага төрелгән мөштеген алган, шуңа бик пөхтәләп сигарет киерткән, хәер, сигарет киерткәнче ул әле икенче бер фольгага төрелгән тимерчыбык кисәге белән мөштегенең каналын чистартып ала иде — анысын да эшләгән, иреннәрен югартып, тәмләп бер төтен суырган һәм, зәһәр-

хәйләкәр елмаеп, болай җавап биргән:

— Аңламадыңмы? Аңламассың шул. Сезнең буын шулай бик күп нәрсәне аңламыйча үсте инде. Әнә шуңа күрә татар әдәбиятына күпме чүп-чар тулды хәзер. Председатель Ахунов бит җыелыш саен «бездә башлап язучыларның саны җиде йөздән артып китте» дип шәрран яра. Җиде йөз язучы буламыни әдәбиятта, ахмаклар...

Редакторны исә теге ике хәреф кенә кызыксындырган.

— Улмы? — дигән Шәйхи абзый.— Улмы? Ул — менә нәрсә дигән сүз...— Һәм әйтеп күрсәткән. Аны инде кәгазь битендә язып булмый, ләкин мәгънәсен аңлап була: берәр кеше үзенә тиешле, лаек булмаган әйберне сораганда татар извозчигы да, рус ломовое, половое да әйтә торган ике сүзнең баш хәрефләре икән тегеләр. Шахтер Шәйхи аның русча вариантын файдаланган.

Редактор, шулай итеп, әсәрне нәкъ автор теләгән рәвештә чыгарырга мәҗбүр булган.

Шәйхи Маннур кайбер язучыларны (бигрәк тә, җитәкчелектә торганнарын) яратмый һәм яратмаганын демонстратив рәвештә белдерергә тырыша иде. Мәсәлән, бер вакыт ул «Казан утлары» баш редакторы белән арасын өзде. Баш редактор трибунага чыгып сөйли башлауга Тукай клубының алгы рәтләрендә утырган Шәйхи абый кинәт кенә кузгалып күтәрелә дә, пиджагының уң як кесәсеннән фольгага төргән мөштеген чыгарып, башын үҗәт түбән иеп, ясалма-явыз адымнар белән шерт-шерт атлап, залны ярып, тәмәке тартырга чыгып китә. Шундый чыгып китүләренең берсендә ул урта бер җирдән кире борылып, иреннәрен әчкә җыеп трибунага кычкырды:

— «Кеше китә — җыры кала» повестен ник басмыйсың? Ничә ел ята бит инде! Азрак намус кирәк! — диде.

Мин, башымны иеп, артта утырдым.

Шәйхи Маннур бу повестьның трагик язмышын һәм моңарчы басылмавының төп сәбәбен белми иде. Баш редакторның монда гаебе юк, булса да, үз журналында басылып яткан, инде корректурасы килгән әсәрне югарыдан «звонок» буенча төшереп калдырырга кушкач, шуны яклап кала алмавында иде. Кая инде безгә Твардовскийлар! Югыйсә, баш редактор — егет кеше, фашистлар белән, полицайлар белән күзгә-күз карап сугышкан.

Ә повесть болай төшеп калды: корректура килде, рәхәтләнеп укыдым, дөрес, байтак туналган иде, аз гына тәнкыйть сүзе — җәмгыятебез, строебызга карата,— алла сакласын,— баш редактор тарафыннан каты басып, кәгазьнең канын чыгарырлык итеп сызылган иде. Шулай да мин шат. Корректураны укып, әлләкем кыяфәтендә журналга киттем. Секретарь Ләбибә Ихсанова иде. Кердем, исәнләштем. Ул, гадәттәгечә елмаеп, корректураны актарды. Бик вакытлы китергәнсез, журналны «төшереп җибәрәсе» бар, диде (ягъни, типографиягә тапшырасы). Мин бик бәхетле идем. Шулвакыт өстәлдә телефон чылтырады. Ләбибә апа бүленде. Берьяклы сөйләшү, бу яктан — «ыһыммыһым». Ләбибә апа миңа карап-карап ала, үзенең чырае һаман караңгылана бара. Утыз җиденче ел шиге-шөбһәсе белән тәрбияләнеп үскән егет буларак, мин барысын да дөрес аңладым.

— Ләбибә апа! — дидем, ул авыр сулап телефоннан арынгач.— Төшереп калдырырга кушалармы? Обкомнанмы?

— Әйе шул, туганкай,— диде ул.— Мин нишлим инде?

— Ә сезгә дөресен әйткәнегез өчен рәхмәт.

Мин саубуллашып чыгып киттем. Баш редактор, әлек мине яратып, ятратканлыгыннан хәтта исемемне дә бутап «Мөдәррис» дип аркадан сөеп йөргән фронтовик куркып калды: күңеленнән мине кара исемлеккә кертте. Моңарчы ул исемлектә әле С. Баттал, А. Гыйләҗев, Н. Фәттах, Ә. Еники генә иде. Хәер, Р. Батулла да инде бу исемлеккә кандидат иде.

Бу абруйлы исемлеккә мин дә кердем. Ә теге звонокның кемнән икәнен белә идем, ул шәхес белән урамда очрашканда, берни дә булмагандай, исәнләшеп йөрибез. Мин, дин тотмасам да, рәсүлебезнең бер фикерен гел хәтеремдә саклыйм: таш белән атканга аш белән ат. Мин тарихны, диалектик материализмны ихтирам итәм. Тарих һәр әйберне, һәр шәхесне еллар узу белән үз урынына куя. Тарих каберләрне күчерә. Вольтерны, бичараны, әллә ничә тапкыр күмгәннәр. Лермонтовны үтергән майор Мартыновны детдом балалары совет чорында, кабереннән казып алып, чергән гробын агач ботагына асып куйганнар. «Бу сиңа, Лермонтов өчен, гад», дип язып та куйганнар. Залим Сталинга да үлгәч тынычлык бирмәделәр. Тарих шулай, елый-елый, кан түгә-түгә, хаталарын төзәтә. Төзәткәндә дә хаталар китми калмый.

«Кеше китә — җыры кала» повесте турында сүз бара бит әле. Шәйхи абыйның бер-ике җыелышта баш редакторга бик нык әйтүенә карамастан, повесть ятты да ятты. Менә бервакыт...

Шәйхи абый белән Пицундада тагын бер очраштык. Ул «Агымсуларга карап» дигән исемдә моңсу гына, сагышлы гына бер әсәр язып ята икән.

Диңгез буендагы таныш аллея. Сүзне Шәйхи абый алып бара. Без — биш-алты кеше, татарлар. Кайсы — Өфедән, кайсы — Ташкенттан. Уен-көлкегә кереп киттек, бер-ике мәзәк тә сөйләп алдык. Шунда мин, күрәчәгемә булгандыр, Шәйхи абыйга бер сорау бирдем. Дөресме, булдымы шул хәл? — дидем.

...Сүз менә нәрсә турында бара иде. Шәйхи абый гадәттәгечә, көндезге ашын ашарга Татар ашлары йортына кергән. Официанткалар да гадәттәгечә йөгерешкәннәр, каушаганнар.

— Үләм-бетәм, тагын килгән бит теге карт,— дигән, үзе карый торган өстәл янына килеп утырганын күреп, бер официантка. Һәм пычак, чәнечке, кашык китереп куйган. Бераздан меню да китергән. Китерсә — күрә, «абзый» пычак белән кашыкны әйләндергәләп бик җентекләп карап утыра икән. Билгеле инде, ак металлда бернičә вак тамчы май калган. Ваннага тутырып бөтенесен берьюлы өйкәләгәндә була торган хәл. Булмаска тиеш инде ул, әлбәттә, ләкин була...

Официантка баскан урынында торараш булып каткан, ә «абзый», явыз елмаеп, иреннәрен бөтенләй югартып бетереп әйткән:

— Сеңлем, менә шушыларны юучы абыстайны монда чакыр әле,— дигән. Савыт-саба юучы булгач, пенсионерка-фәлән, майлы алъяпкычлы, тирләгән бер юантык хатын булыр дип уйлаган инде ул. Ләкин күп тә үтми, ялт иткән чиста киемле, дөньяның гүзәле, егерме-егерме ике яшьләр чамасы бер кыз моның каршына килеп баскан.

— Сеңлем, син,— дигән юка ирен,— эчке киемнәреңне дә шулай юасыңмы? (Имеш, ул эчке киемнең конкрет берсен әйткән).

Кызый шундук, кычкырып елап, кухня ягына кереп киткән.

Бу чыннан да шулай булгандырмы, юктырмы, ләкин шулай мәзәк итеп сөйлиләр иде. Ә мин, юләр, шул хәлне Өфе, Ташкент татарлары барында сора да куй! Дөресме, янәсе.

Шәйхи абыйны ай күрде, кояш алды. Ул шундук кырт борылды да, мыгырдап, минем адреска бер-ике яман сүз әйтте дә, кире китеп тә барды. Без кыен хәлдә калдык, ә иртәгесен ул минем сәламемне алмады. Күрәсең, теге хәл бөтенләй уйдырма булган һәм кеше алдында сөйләп мин аны рәнҗеткәнмен. Ахырдан ничә тапкыр гафу үтенергә омтылып карадым — «Шиһап солдат» моңа мөмкинлек бирмәде. Бик горур кеше иде шул, мәрхүм.

Калганын миңа «Казан утлары» журналы хезмәткәре сөйли. Алдагы өч санның планын тикшерәбез, ди. Редколлегия утырышы икән. Шунда Шәйхи абый яратмый торган баш редактор минем әлеге бәхет-

сез повестемның алдагы саннарның берсенә кертеләчәген әйткән. Редколлегия әгъзасы Шәйхи Маннур шунда сорау биргән:

— Редакция портфелендә тагын проза әсәрләре бармы?

Ник булмасын инде, бик күп була ул проза әсәрләре редакция портфелендә. Баш редактор санап чыккан. Шунда Шәйхи Маннур котчыккыч усал чыгыш ясаган, минекен чигереп торырга кушкан, минеке урынына икенче бер әсәрне тәкъдим иткән. Бәхәс кызган. Бәхәс инде минем әсәрдән узган һәм бер-берсен өнәмәгән редактор белән редколлегия әгъзасы мөнәсәбәтләренә кайтып калган. Баш редактор исә, мине яклаудан түгел, ә тегеңә юл бирмәс өчен генә минем әсәрне номерга тәкъдим итеп кул күтәрткән. Бер каршы тавыш белән план расланган.

Гарәпләрдә бер мәкаль бар: Мөгайидине яратуымнан түгел, Галине дошман күрүемнән.

Унбиш ел буе редакцияләрдә, нәшриятта әвәләнеп йөргән, аптыраганнан ике-өч тапкыр исеме үзгәртелгән повесть журналда әнә шулай басылып чыкты. Уйлавымча, аның шул номерга керүенә минем теге «ашханә вакыйгасы» ярдәм итте. Ахырдан ул повестьны гел мактадылар тагын.

Шулай берәр ел узды. Ул арада Шәйхи абыйның 70 еллыгы да килеп җитте. Ул чорда алтмыш, җитмеш еллык юбилейлар бик еш була иде.

Һәм, һич тә көтмәгәндә, миңа Шәйхи абыйдан чакыру кәгазе килде. Парлап, дигән, Татар ашлары йортында, кичке сәгать алтыда дигән. Рәхим итегез, ихтирам белән Һ. б.

Бу — миңа чын, туп-тулы реабилитация иде.

Әлеге мәҗлес бик нык хәтеремдә. Өстәлләр гадәттән тыш мул, кунаклар да бер йөздә генә бетмәгәндер. Чират торып, сүз алып Шәйхи абыйны мактадык. Ул, иреннәрен кысып, усал елмаеп, дәшми генә утырды, туган-тумачасын, кызы Миләүшәне берөзлексез йөгертте: кунакларның алды буш тора күрмәсен, эчемлек, ризык вакытында килеп торсын һәм башкалар. Мәҗлес күркәм иде.

Банкетның нәкъ кызган вакытында залда югы-загы булып алды. Кемнәрдер йөгереште. Мәгънәдән аңлашылды: юбилярның мәҗлесенә югарыдан секретарь килгән. Бу — бик сирәк була торган хәл. Юбилярның дәрәҗәсе бит мәҗлескә нинди дәрәҗәдәге кеше килүенә карап билгеләнә. Берәүгә инспектор, икенчегә инструктор килә. Димәк синең дәрәҗәң шулай. Дәрәҗәң бик тә, бик тә зур булса, мәҗлесеңә Үзе дә килүе мөмкин. Ләкин бу да уен-муен түгел инде, секретарь иптәш теләсә кемгә йөрми. Зур иптәш, килеп утыруга, үзен хуҗаларча хис итеп, сүз башлады. Ул рус телендә сөйли иде, ул елларда җитәкче иптәшләргә үз телләрендә сөйләргә ярамый һәм, мин уйлыйм ки, аларга татарча сөйләшергә рөхсәт тә булмагандыр. Гаҗәпмени, әле моннан берничә ел элек дәрәҗәле бер сәнгать әһеленең юбилей кичәсенә Үзе килгән иде һәм җыелыш барышында берничә тапкыр саф «татар» телендә шаян җөмләләр әйтеп куйгач, зал тынсыз калды. Карале, шундый зур кеше дә татарча сүз әйтер икән!

Шулай, Шәйхи Маннур юбилеенда секретарь иптәш сүз алды.

— Менә без соң гына Бюро утырышын тәмамладык. Беләсезме, бездә шундый гадәт бар: бюро утырышыннан соң без үзара сөйләшеп утырабыз, республикадагы хәлләр турында фикер алышабыз. Менә мин шунда Үзенә әйттем: бүген дидем Шайхи (ул шулай диде) Маннурның 70 еллыгы. Шунда синең биографияңне сөйләдем. Ул, дидем, шахтер булган. Шунда Үзе гаҗәпкә калды. Һо-о, диде ул, Шайхи Маннур рабочий булганмыни? Так, алайса син аның мәҗлесенә бар, рабочий класс безнең илдә ведущий класс, диде. Вот так.

Шахтер Шәйхи бу вакытта да иренен кысып елмаеп утырды. Ничектер, аның шагыйрьлеге, «Ана җыры», «Бәлки әле син дә сөярсең» кебек моңлы лирикасы, калын «Муса» романы һәм «Агым-суларга

карап» дигән искиткеч җылы әсәре онытылыбрак калган сыман иде.

Ә мәҗлес кызды. Биюләр булды. Вальс, танго биедек. Фокстрот булмады, булса, Шәйхи абый, һичшиксез, авызын кысып «язвить» итмичә калмас иде.

— Фәхештрот!

«Муса» романында аның шундый сүзе бар.

Бераз гына чигеним: бу секретарь иптәш бик егет кеше, вак түгел, «бала»ланмый. Дөнья күргән, сугыш узган. Әмма аңа безнең татар әдәбиятының язмышы тапшырылган, имеш. Юктыр инде, әдәбиятның язмышын берәүгә дә тапшырып булмый, әдәбият, хәтта, синең хәлеңә бәйле түгел, ул алай мескен була алмый, әдәбият карарларга, указларга буйсына алмый, ул хөкүмәтләр, президентлардан өстен. Юньле патшалар, президентлар әдәбият әһелләре белән гел дус булганнар. Шуңа күрә бу әйбәт егетнең әдәбият барышына бернинди тәэсир ясамаганын беләм, аңлый идем. Дөрес, андый егетләр әдәбият өстендәге бюрократик аппаратны, язучыларга бирелә торган орденнар, лауреатлыклар һәм башка төрле дәрәҗәләр мәсьәләсен хәл итәләр, бу Зур иптәш тә, кайсы язучының әдәбиятта киләчәк өченниләр калдырачагын бөтенләй белмәгән көе (чөнки, минем белүемчә, безнең әдәбиятны бөтенләй укымый; ә ул хаклы: республиканың бөтен җиренсуын бетереп яткан нефтьчеләр турындагы калын романнарны укып күзен бетерергә аның башына тай типкәнмени?), теге орденнар, лауреатлыклар, бюрократик әдәби постлар мәсьәләсен төп хәл итүче иде.

Дөресен әйтим, бу егетне бик күп сыйфатлары өчен мин ихтирам иттем, мәсәлән, вак булмавы һәм... Йә, ярар мин чит шәхестә казына башладым бугай, ә бу сыйфат һич тә автор өчен мөрәүвәт сыйфат түгел.

— Шайхи,— дип кычкырды секретарь,— иди-ка сюда. Давай, с тобой чокнемся. Я специально пришел на твой праздник. Подойди ко мне! Ну, давай, подойди!

Шиһап солдат түрдәге урыныннан күчеп үзенең җан дусы булган бер карт язучы янына утырган, тәмләп сигарет суыра, сөйләшә иде.

Элеккеге шахтер, утызынчы еллар башында ук танылган әдип, күп әсәрләр авторы. Ватан сугышы ветераны, туры-ачы сүзле, үзенчәлекле характерлы һәм зур абруйлы кешегә секретарьның (юбилярдан 15 яшьләр чамасы яшьрәк) аңа «син» дип дәшүе күңелне бераз рәнҗетте. Без аңа күнгән инде, нишлисең. Ул елларда шулай иде: Язучылар берлеге рәисе, СССР Югары Советы депутаты, күп китаплар авторы югары оешмада эшләүче бик тә «рядовой» инструктор яки татар әдәбиятында солыдан кибәкне аера алмаган бүлек мөдиренә (шулай ук әдәбият мәсьәләләре белән шөгыльләнүче) «Сез» дип дәшә, ә тегесе, орыплар да бирмичә, аңа «син» ди, командалык итә. Татар язучылары ул елларда әнә шундый хәлгә куелган иде. Галимҗан Ибраһимов, Фәтхи Бурнашлар белән, шәт, алай сөйләшмәгәннәрдер югарыдагы иптәшләр.

— Шайхи! Иди сюда, сядь! Я хочу предложить тост. Иди, говорю...

Мин, башымны иеп, уйланып утырдым. Берничә секундмы, минутмы узды. Шахтер Шәйхи, фронтовик Шәйхи, горур Шәйхи нишләр? Нишләр? Малай хәлендә бит бу...

Шәйхи абый, акрын гына урыныннан торды да, энекәше янына «Сез, фәлән фәләнич» дип сөйләшеп утырырга китеп барды.

Ничектер, күңелгә авыр булып китте. Фатих Кәрими, Дәрдемәнд, Фатих Әмирхан, Мәхмүт Галәү кебек шәхесләр күз алдына килде. Кандалый, Заһир Бигиев, Риза Фәхретдиновлар, Гаяз Исхакыйлар күз алдына килде...

Һай, безнең мөнәсәбәтләр...

Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре көндезге аштан соң ял итеп ята икән. Хадимәсе кереп «Сезне күрергә губернатор җәнабләре килгән, шәһәр буйлап сәйран кылып йөрүе икән»,— дип хәзрәтне уяткан.

— Кабул итә алмыйм,— дигән Мәрҗани хәзрәт,— минем ял вакытым.

Губернатор үпкәләмәгән, чөнки Мәрҗанине ихтирам иткән. Мәрҗани аның кабинетында еш булган, бервакытта да «приемный»да чират көтеп утырмаган. Гарәп мәкале бар, әллә инде Коръәннән: «Галимнәрнең юньлесе патшаларга ялагайланмас, патшаларның юньлесе галимнәр белән танышлык итәр».

...1986 елның июнендә Татарстанда зур бәйрәм — Чуаш әдәбиятысәнгате атналыгы булды. Кунакларны өч-дүрт төркемгә бүлделәр. Алар белән татар язучылары да бергә йөрергә тиеш иде. Мин Мамадыш — Алабуга «төркеме»нә эләктем. Беренче көнебездә Мамадыш мәдәният йортына барабыз, карасак — куаклар, чәчәкләр арасында бер һәйкәл. Мин тынсыз калдым. Шәйхи Маннурга һәйкәл. Бюст. Туктале, туктале, Татарстанда безнең чорда яшәгән кайсы язучының туган ягына һәйкәл куелганы бар? Һәйкәлгә чәчәкләр куябыз. Әйбәт эшләнгән. Шул ук киңчә бит, шул ук кечкенә күзләр, шул ук кысык иреннәр! Гипстыр инде ул, көмешсыман буяуга буялгандыр инде — ләкин һәйкәл! Шул ук көнне аның туган авылы Тулбайга барабыз. Бөтен авыл аның истәлеге белән тулы. Клубта чыгыш ясыйбыз. Халык — шыгрым.

— Бездә Шәйхи Маннур туган! Ул — безнең авылдаш!

Халык шулай гөжли. Без шат. Үз төбәгеннән чыккан галимнең, язучының сәнгать кешесенең кадерен белгән авыл — өметле, игелекле авыл.

Шәйхи абыйны, үзенең васыяте буенча, туган туфрагына күмделәр. Табут юлга чыкканда яңгыр явып тора иде. Озатучы халык сөйләде: Шәйхи Маннур гаҗәп тә тыйнак тормыш алып барган, кием-салымы да бер катлык кына.

Берничә көннән билгеле була: саклык кассасына җыелган йөзләрчә мең акчасын туган авылының мәдәният хаҗәтләренә васыять итеп калдырган.

Моны Татарстанда бары тик Шәйхи Маннур гына эшли ала. Андый кешегә һәйкәлне Мамадышта гына түгел, Казанда да куярга кирәк. Аның исемен шәһәрнең берәр урамына бирергә кирәк.

Мин бу истәлекне язучыларның Пицундадагы иҗат йортында язам. Кичләрен диңгез буендагы камышлы аллеяга чыгып йөрим. Каршыма килүче тәмәке уты күренсә, сискәнеп китәм: менә, җай гына атлап килүче Шәйхи абый очрар да:

— Нихәл, абзый, ял итәргә чыктыңмы? — дип иреннәрен кысып елмаер кебек.

Ләкин бу аллеяда мине танучы, миңа сәлам бирүче юк.

Пицунда хәзер минем күңелдә гел сагыш кына уята. Нәрсә булды миңа?

*Ахыры киләсе санда.*

# Әхәт Фазылҗанов

# СЫЕРЧЫК БУРАНЫ

хикәя



Иртән килеп, клуб ишеген ачып керергә өлгермәдем, сине партоешма секретаре чакыра, диделәр. Озаклamaска кушкан. Ашыктырганда гына түгел, мондый чакта да көттергәнне яратмый Сәхип абый, төгәл кеше. Иөгердем.

Кабинетның ян стенасы буйлап тезелешкән урындыкларның берсендә баш яулыгы чите белән йөзен яртылаш каплаган Зөлхәбирә апай утыра. Аны күрүгә юрап куйдым: ашыгыч чакыртып алулары, мөгаен, үз хезмәтем буенча түгелдер.

— Гамил энекәш, сиңа бер зур үтенеч чыгып тора бит әле. Җәһәт кенә больницага барып кайтырга кирәк. Калабашка. Нәбирәнең кайтасы көне икән бүген.

Әйтәм ич.

Кешесен дә тапканнар икән.

Сәхип абый, сүзен бик ипле генә башласа да, җәһәтләргә ашыкмадым әле. Гарьлегем кузгалды.

— Тудыру йортыннан балалы хатыннарны ташу вазифасы кайчаннан бирле клуб мөдиренә йөкләнде әле? — дидем, бераз кыза төшеп. Ярый әле, җилдән туган балалы хатыннарны, дип ычкындырмадым. Югыйсә, анысы да тел очында гына эленеп тора иде.

— Тукта, керпе шикелле энәләреңне тырпайтырга ашыкма, юньләп әйткәнне тыңлап бетер. Синең вазифаңда булса, менә болай сөйләшеп тә тормас идек, булмаганга күрә үтенеп, гозерләп сорыйбыз бит.

Миңа күтәрелеп карамастан гына, Зөлхәбирә апай телгә килде:

— Әтиләре дә өйдә юк көн туры килде ичмаса. Калага киткәние. Ул гына барырие кана. Озаккарак китте, зарыккандыр инде, балакаем. Температурасы төшми интектерде. Нәбирәнең дим.

Зөлхәбирә — Нәбирә. Карале, исемнәренең аваздашлыгын әле менә хәзер генә колакларым тотып алды. Әллә, ходаем, исемнәре үк юмартлыкларына ишарә инде. Яшь чагында Зөлхәбирә апай кимен куймаган бугай үзе. Рамазан абыйга көмәнле килеш килгән дип ишетеп беләм. Инде менә кызлары килеп абынды. Шәһәр егетенә кияүгә чыкмакчы, янәсе. Тоттырды койрыгын. Ай күрде, кояш алды кияү дигәннәрен! Эзе дә юк бу тирәдә. Ирләрнең бөтенесе Рамазан абый шикелле булмыйдыр шул.

Туктале, егет башым белән нишләп мин әллә кем баласы артыннан Калабашка хәтле чабарга тиеш? Авылда миннән башка кеше бетмәгәндер ич.

Әйтерсең, Сәхип абый минем уйларымны укып торган, нәкъ менә әчке сорауларыма җавап биргәндәй итте:

— Безне дөрес аңла. Чәчү вакыты, үзең күреп торасың, хәзер генә кемне тотып җибәрәсең, йә? Кем буш? Син дә трай тибеп йөрмисең анысы...

Чәчү дигәннән, басудагылар өчен концерт әзерләп йөрүебез искә төште һәм кичкенә генә ялганга бардым:

— Тугызынчы яртыга агитбригада членнарын репетициягә җыймакчы идем.

Бу аклануымны да колагына эләргә теләмәде секретарь, каныкты тәмам:

— Бераз гына көтеп торыр артистларың. Күп булса ике сәгать вакытың китәр. Карышып торма инде, яшьлегең, җитезлегең бар, көне матур. Әнә

---

Әхәт ФАЗЫЛҖАНОВ *(1927) — «Тормыш җиңә», «Күкчәчәк бөресе», «Үрдәкләр нәрсәдән көләләр?» дигән китаплар һәм вакытлы матбугатта басылган күп санлы хикәяләр авторы. Балтачта яши.*

минем «Москвич»ка гына утыр да элдерт. Бер яхшылыгың күп булмас Нәбирәгә. Моңарчы бер концертыңнан да калмады бит үзеңнең. Клуб советы члены да түгелме соң әле ул? Кул селтәп бетермә.

Болардан котылу әмәле юк, ахры.

Әйтсәм әйтим инде, мин бит үзем дә моннан элек Нәбирәгә кармак салып караган егет. Тик йөрәктә ничектер капылт кына кабынган мәхәббәт уты дөрләп ук китәргә өлгермәде, тиз сүнде.

Белмим, үзе белән байтак аралашып та, Нәбирәнең шушы кадәр чибәрлегенә, зифалыгына ничек күз төшмәгән, игътибар ителмәгәндер. Былтыр Беренче май бәйрәменә багышлап куелган концертта очынып-очынып биюенә, үтә күренмәле юка күлмәге ятышып торган җиңелчә сылу гәүдәсенә, таза һәм төз аякларына сокланып, мөкиббән китеп утырдым. Кинәт кенә зиһенем, фикерләрем чуалгандай булды. Ошбу минутта игътибарымны, карашымны җәлеп итәрдәй Нәбирәдән башка берни дә юк иде. Әйтерсең, бүген аны беренче тапкыр күрүем. Бөтен барлыгы белән сихерләде дә куйды күңелемне. Картлар әйтмешли, көне-сәгате җитүе шушы булды микәнни? Моңарчы андый сәер халәтне беркайчан да кичергән юк иде әле.

Әнә шул көннән соң әчтән генә янып-көеп йөрер чамам озакка бармады. Авыл урамнары шомырт чәчәге исе белән тулы, һавасын сулап туймаслык язгы аяз кичләрнең берсендә, аллага тапшырып, өенә хәтле озата кайттым мин моны. Әле уй-хисләремне туры гына әйтеп салырга телем әйләнмәсә дә, кыюсыз кайтуымның тикмәгә генә түгеллеген чамалады Нәбирәм. Тиз аңлаштык.

— Син дә яратмаслык егет түгел анысы,— диде бу икеләнеп-боргаланып тормастан.— Гафу ит, Гамил, мин башка берәү белән вәгъдәләштем бит инде. Үпкәләмә. Әйдә синең белән элеккечә дуслар булып кына калыйк. Бар, кайт инде.

Шушы сүзләреннән соң шомырт чәчәкләре исен тоймас, күк йөзендә җемелдәшкән йолдызларны күрмәс булдым. Күңелдәге татлы хисләр ташкынын кинәт кенә әллә нинди рәнҗүле-үпкәле тойгылар басып китте.

Әлегә хәтле Нәбирәнең үз авызыннан ишеткәнем булмаса да, бераз гына сизенеп-абайлап йөри идем инде үзем дә — «башка берәү» дигәне Казан егете Мәсхүт булып чыкты. Медицина институтында укыган Сәми Равиленә ияреп авылга кайткалаган иде, шуның белән иснәнеп өлгергән, имеш.

Мине алмасарлап йөртмичә, шул чагында ук дөресен әйтеп ташлавы әйбәт булган әле. Әрсезләнеп, кадеремне югалтып бөтән озата кайтмадым. Кешене көчләп яраттырып буламыни. Шундый чибәрлеге белән тиздән кулына диплом аласы егетне ун класслы авыл клубы мөдиренә алмаштырмас шул. Буй җитмәслеккә үрелгәнмен бугай.

Тиздән авылда, Нәбирә Мәсхүттән алданган икән, дигән ямьсез хәбәр таралды. Анысы да минем файдага гына булды, мине артык гасабиланып йөрүдән саклап калды. Нәбирәне күңелемнән алдын-артын уйлап бетерми торган бер җилбәзәк кызга чыгарып, үземне тынычландырдым. Андыйлардан ерак торуың хәерле, дидем...

Зөлхәбирә апай, миңа рәхмәтләр укый-укый, балага чүпрәк-чапрак әзерли торырга булып, өенә йөгерде. Үземә дә өс-башны алмаштырып чыкмый булмас. Болай гына килешмәс. Теге зәңгәр күлмәкне киим.

Бервакыт Нәбирә ничектер:

— Бигрәк килешеп тора бу күлмәгең үзеңә, күзләрең белән пар,— дигән иде. Шул искә төште. Үзем дә бер мәми авыз инде, ачуым килмәгәе. Тел тибрәтеп бер юньле сүз әйтә белмәдем бит шуңа каршы. «Комплиментың өчен рәхмәт»,— диясе генә инде, югыйсә. Татар акылы — тау менгәч шул. Мәсхүтне әйтәм әле, ул минем шикелле Нәбирә алдында авызына су капкандай тормагандыр, сайрый белгәндер.

Өйгә кайттым да әнине ашыктырам:

— Минем зәңгәр күлмәкне табып бирче. Районга китеш. Тиз кирәк.

Ни йомыш белән йөргәнне әйткән юк инде үзенә. Дөресен әйтсәм, олы тавыш куптарасын белеп торам. Коты алыныр.

— Кичтән сыгып куйган идем шул анысын. Күрмәдеңмени, ишегалдында эленеп тора. Ник бүтәне ярамасмыни?

— Ярамый. Ул гомердән бирле кипкәндер инде, көн җылы бит. Мин үтүкне кыздыра торам, зинһар, тизрәк кыймылда әле.

Күлмәккә дип чыгып киткән әнинең тышта кемгәдер бик каты җикерен-

гәне ишетелде. Тәрәзәдән барып карарга өлгермәдем, ул арада үзе кереп җитте. Еларга җитешкән.

— Каһәр суккан нәрсә!.. Кичтән өйгә кертеп элим дип талпындым шуны, тәки кул-аяк җитмәде. Менә, киярлеге калмаган инде.

Өстәлгә сыңар җиңе төптән дип әйтерлек умырылган күлмәкне җәеп салды.

— Монысы нәрсә тагы? Бер җиңе кайда?

— Бозау корсагында. Чүпрәк күрер хәле юк, бөтәрли дә тыга. Нинди хайван булды соң бу!

Бозау буе җитәрлек итеп күлмәк элгән әнине әйтер идем. Әмма озак уйлап-аптырап торырга вакыт юк.

— Ярар, юк өчен йөрәгеңне бозма. Якасы бөтен булгач, шул җиткән. Сойдет! — дим.

— Шашма! Шул таланган күлмәк белән кеше янына бармассың ич инде. Кияреңә беткән мәллә?

— Пиджак эченнән шайтаным да күрми аны. Мәҗлескә бармыйм, өсне салып утырасы түгел.

Мин Нәбирәгә илтеп тапшырасы төенчекне кочаклап, Зөлхәбирә апай капка төпләренә үк чыгып баскан иде инде.

— Энем-җаным, исән-сау гына алып кайта күр инде үзләрен. Юлда хәвеф-хәтәрдән саклана күр. Юл хәлен белеп булмый.

— Борчылма, Зөлхәбирә апай. Көн матур, юл такыр, машинасы сәгать кебек эшләп тора — җәһәт тотабыз аны.

Быел яз гадәттәгедән күп иртәләде. Апрель башында ук кар китеп, җир тәмам кипшереп өлгерде. Үзәнлекләргә ташып чыккан Шушма суы да бер атна элек үз ярларына төште. Әнә, колхоз механизаторлары, чәчүне Май бәйрәменә хәтле төгәллибез, дип йөриләр.

Олы юл читеннән башланган арыш уҗымнарын кара: күзгә күренеп күтәрелде. Җылы кояш шушы бер атна эчендә колакларыннан тартып үстергәндәй итте. Табигать кышкы йокыдан уяна. Кыр ышыклау полосасындагы яшь каеннар бәләкәй генә яфрак чыгарып маташалар. Полосага, ерактан чак кына шәйләрлек булып, яшел төс иңеп килә.

Мин авылдан чыгып киткәндә чалт иткән аяз, җылы көн иде. Сокланып бара торгач, күз тидердемме шунда. Әнә инде елга аръягындагы текә тау тезмәләре түбәсеннән чит-читләренә көмешсыман кояш нурлары йөгертелгән кара-кучкылт болытлар сырт күрсәтә башлады. Алары сабын күбегедәй күпереп, бу якка таба шуыштылар. Мин чама белән юлның яртысына җиткәндә тоташ болытлар җәймәсе, күзгә күренеп, күк гөмбәзен томалап алырга өлгерде. Дуамал җил купты. Тузгыта гына болытларны. Озаклamaстан кыйгачлап эре һәм юеш кар яварга тотынды.

Әйдә, хәере белән яусын. Мондый җылысы булып торганда язгы карның зыяны юк, авыл кешесе аны күктән төшкән ашлама дип кенә кабул итә.

Саранча өере шикелле мул булып төшкән кар алай гына эреп өлгерми, ун-унбиш минут эчендә җир өсте ап-ак булып калды. Машина артыннан юлда, ике кара тасма булып, тәгәрмәч эзләре төшеп кала. Куәтле тыгыз җилнең каршылыгын машинада утырган килеш гәүдәм белән тоеп барам. Тоташ-тоташ булып машина тәрәзәләренә сырышкан лычкылдык карны сыпырып төшерергә «дворниклар»ның да көче җитми хәтта. Үземә төшеп чистарткаларга туры килә. Бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, уңышсыз юлга чыктым, ахры. Аякларым тартып бетермәгән иде шул башта ук. Зөлхәбирә апайга бик җәһәт кенә барып кайтырга ышандырдым ышандыруын. Кайтыр юлга чыкканчы юлны изрәтеп бетермәсә ярый инде. Кутәртелмәгән юлда «Москвич»ка утырып калырга күп кирәкмени?

Минем бәхеттән, больницада тоткарлык-мазар килеп чыкмады. Көне дә ачылып китәргә исәпләгән шикелле.

Авызын-борынын марля белән каплаган шактый өлкән яшьтәге ханым:

— Зарыгып көтәбез инде сезне,— дип каршы алды.— Хәзер чыгарлар. Китерегез киемнәрен.

Мине коридорда калдырып, үзе эчке бүлмәгә кереп китте, ә мин аның сүзләренең мәгънәсен эзләп-юрый калдым. Сезне көтәбез, дию болай гына булдымы, әллә менә нәкъ мин киләсен белеп үк торганнармы? Авылдан шалтыратып куйдылар микәнни?

Әнә үзе дә чыгып килә. Артыннан бала төреп тоткан теге акушерка

хатын (акушеркадыр дип беләм) атлый. Больницаларда гына була торган әллә нинди дару исләрен басып, борынга кыйммәтле, хушбуй исе килеп керде. Анысы Нәбирәдән килә. Агарып, чистарып калган үзе. Хәтта элеккедән дә сөйкемлеләнеп киткән димме. Гәүдәсе нәфисләнеп калган. Бала табу килешкән, ахры. Йөзендәге кара-кучкыл тапларның эзе дә калмаган. Коңгырт шома чәчләрен тарап, артка өеп салган. Косынкасы кулында иде, монда чыккач бөркәнеп куйды. Карашларыбыз очрашкач, бит урталарына сизелер-сизелмәс кенә алсулык йөгерде. Саран гына көлемсерәгәндәй итте.

— Исәнме, Гамил!

— Исәнме, Нәбирә! Кызың белән котлыйм!

— Рәхмәт.

Күлмәк җиңе очына кыстырылган кулъяулыгын алып, дымланган күзләрен сөртте. Минем дә күңел бераз йомшагандай булды.

— Әтисеме? — диде акушерка.

Мин монысын үземә адресланган сорау дип кабул итмәдем, дөресрәге, ишетеп бетермәгәнгә салыштым. Нәбирә исә, җавап бирәсе урынга, соры күзләрен мөлдерәтеп, миңа төбәлде. Карашында уңайсызлану катыш ниндидер үтенеч, ялвару шәйләдем. Баланың атасы юклыгын әйтмәгән, димәк. Кем белгән, бәлкем, әлегә хәтле Мәсхүтнең килеп чыгасына да өмет белән яшәгәндер. Өметсез — шайтан, диләр. Ә, бәлкем, анысына ук исәп тотмыйча гына чын дөресен әйтергә базмагандыр. Ходай белсен, миңа караңгы.

— Әтисе,— дидем, ниһаять, Нәбирәнең хәленә кереп.

— Моңарчы килгәнегез булмады шикелле. Мин генә күрми калдыммы әллә?

— Командировкада идем.

Ирексездән тагын ялган әвәләдем инде. Гөнаһысын кая куеп бетерермен.

— Тотыгыз алайса кызыгызны.

Тоттым. Нәкъ урта бер җиреннән ефәк тасма белән буып бәйләнгән ап-ак юрган эчендә бала түгел, әйтерсең, тыгызлап тутырылган мамык кына иде. Шундый җиңел тоелды.

Чыгып китәбез генә дигәндә акушерка юлыма аркылы төште.

— Бала тотарга өйрәтәсе бар икән әле үзегезне. Менә болай, башын өскәрәк каратыгыз. Утын агачы түгел ич ул сезгә.

— Беренчесе генә бит әле, күнегелмәгән. Ничава, өйрәнербез,— дип, үземчә акланган булдым.

Ходаем, кеше баласы аркасында шундый шелтә ишетәсе генә калган иде миңа. Юк, моның белән генә дә бетмәгән икән әле.

— Синең өстеңдә бик юка түгелме соң, бу килеш салкын алдырмагаең, җиле бар,— дип, бу юлы акушерка Нәбирәнең юлын бүлде.

— Көннәр бик җылы торгач, тышкы киемнәремне алмаган идем шул. Туңмам әле, хафаланмагыз.

— Машинада җылы, мунчадан ким түгел,— дидем мин дә, моннан тизрәк чыгып сызу ягын карап.

— Алай димәгез, җиле бик усал, анда чыгып утырганчы да электерүе бар.— Ул арада акушерка бер кулы белән минем иңемә кагылды.— Сез ир кеше, туңмассыз әле, пиджәгегезне хатыныгызга салып бирер идегез.

Бар икән күрәселәр! Адәм көлкесенә калырга дип кенә килгәнмен икән монда. Ник ризалык бирдем? Пиджакне салып, җиңсез күлмәк белән калыйммыни?!

Барысы да шул имансыз Мәсхүт аркасында. Башы беткере! Гарьләнеп үләрсең. Хәзер менә үзен китереп бастырасы иде шушында. Пиджәген генә түгел, ыштанын салдырып алыр идем әле, кулга эләксә. Шарлатан, мир үгезе! Тагын әллә ниләр әйттерә бугай инде.

«Минем балам, минем хатыным түгел, бәйләнмәгез!» — дип кычкырырга җитештем. Андый ук этлеккә бармадым инде. Нәбирә кызганыч.

— Ярар, баскыч төбенә чыккач киертермен,— дип тышкы ишеккә ашыктым.

Бераз шелтәсен ишетсәм дә, монысыннан котылдым бугай. Алда тагын ниләр күрергә, ниләр ишетергә язгандыр. Яхшы чакта тизрәк ычкынырга кирәк.

— Бала тоткан килеш минем янда тыгызрак булыр. Син, Нәбирә, артка утырырсың. Иркенләп, җәелеп кайт. Әле юлда таратып имезәсең дә булыр. Бик якын ара түгел.

Нәбирә үзе машинага кереп утырган арада, әнисенә тоттырганчы, кулымдагы баланы таратып карыйсым килеп китте.

— Баласы бармы соң моның, бик җиңел тоела,— дигән булдым.— Яратам шул нәниләрне. Кызыңны бер карап алырга ярыйдыр бит?

— Күз тидерә күрмә.

— Курыкма, зәңгәр күз каты булмый ул.

Бик саклык белән генә юрганның алга кайтарылып төшкән почмагын күтәрдем. Шактый түрдә уч төбе хәтле генә бәләкәй, алсу йөз күренде. Күз төпләрендә, борын тирәсендә тары бөртекләре хәтле генә ак бөрчекләр бар. Битемә җылы һава һәм яшь бала исе (балалы гаиләдә үскәч, миңа анысы да таныш) килеп бәрелде. Юрган кырыен ачкач төшкән яктылыктан йоклап яткан бәбәйнең күз керфекләре калтыранып куйды. Ул арада, иреннәрен йомган килеш кенә, авызы белән ими ашагандагы шикелле хәрәкәт ясады.

— Исеме бармы соң әле?

— Инде сайладык шикелле. Гөлфирә булыр, ахры. Минем үземә шунысы ошый.

— Матур ич,— мин әйтәм.— Үзеңнекеңә килешеп кенә тора... Гөлфирә Мәсхүтовна, ызначыт?

Мәңә «Мәсхүтовна»сы ифрат урынсыз ычкынды инде.. Анысы шайтаныма кирәк идеме? Сөйләшә белмәгән авыздан нәрсә яхшырак дилэр әле? Нәбирәне тиктомалга чын-чынлап үпкәләттем, әй. Миңа рәнҗүле, җимерек караш ташлады.

— Гамиловна димим бит.

Болай ук хәтерен калдырырга теләмәгән идем, ипидер.

Уптым-илаһи сөйләшеп күңелен төшердеңме, хәзер менә теләсәң ничек күтәр инде үзең. Телең тик тормаса...

Бераз сүзсез бардык.

Көн чын-чынлап рәтләнергә чамалый. Анысы икебезнең дә әле генә кителгән кәефне күтәреп җибәрде. Мин килгәндә купкан җил тынып калды, баш очында гына йөзгән кар болытларын ары куа китте бугай. Инде өзелеп калган сүзне ялгап җибәрергә дә ярыйдыр.

— Беләсеңме, больницада нишләп пиджәгемне салып бирмәдем мин сиңа?

— Нишләп?

— Бер җиңсез күлмәк белән бит мин бүген, ышанасыңмы? Әйтергә дә оят. Берсен кибәргә элеп куйган җирдән бозау чәйнәгән.

Нәбирәдән оялып торган юк әле, пиджәкне салып ук күрсәттем. Менә тотынды көләргә.

— Мескен! Бүтән күлмәгең юк идемени соң? — диде, буыла-буыла көлеп.

— Бар иде анысы. Кидем инде шунда ашыгычлык белән.

— Харап иткән икән шундый матур күлмәкне.

Тагын нидер әйтергә талпынган идем талпынуын, дәшми калдым. Ул хакта бүтәнчә озайтмадым сүзне.

Без тынышка, бәбәй аваз салды.

— Тынычландыра күр, зинһар. Балалар елаганны ишетсәм, әллә ничек, йөрәгемә ярамый.

— Мин елак түгел, Гамил абый, диген, кызым. Ачуланма инде, ашарга сорап кына кычкырам, диген... Үз вакытын белеп шаулый ул.

Нәбирә баласын имезгән арада әле яши башламас борын якты доньядан китеп барган төпчек сеңелем турында сөйләп алдым. Инде гүр иясе булганына унике ел үтсә дә, шул бичара кыз һаман күз алдыннан китми. Бигрәк үкенечле булды шул үлеме. Ике яшен тутырып, матур гына теле ачылып килгәндә кинәт сырхаулап китте. Нәкъ бер атна күз алдыбызда уттай кызышып, хәл эчендә ятты. Аны кызганудан сырхауга сабыша яздык.

Соңыннан әни авыл буйлап: «Бездән китәсен күңеле сизенде, һәркайсыбыз белән, кулдан-кулга күчеп, хушлашып, бәхилләшеп чыкты»,— дип сөйләп йөрде. Анысы әни юрап чыгарган нәрсә генәдер инде, югыйсә, ике яшьлек сабый үлем дигәнне кайдан белсен икән? Әнә шуннан бирле бала елаганны тыныч кына тыңлый алмыйм.

— Кызганыч,— диде Нәбирә, минем кайгылы хисләремне уртаклашырга теләгәндәй.— Юк, мин үзем андый кайгыны күтәрә алмас идем. Үз балам үлеп китсә, дип әйтәм. Ходай күрсәтмәсен... Үлем турында сөйләшмик әле бүген, Гамил. Куркам мин.

Машинаның алгы пыяласы өстендәге бәләкәй көзгене Нәбирә күренерлек итеп җайлап куйдым да, әледән-әле күз ташлап алам үзенә. Ул гына мин күзәткәнне сизми. Миңа мөлаем йөзе, озынча ак муены, чишеп җибәргән күлмәк изүеннән калку чиста күкрәгенең бер өлеше күренә. Ике як чигәсеннән, артка җыеп салган бәйләмнән ычкынып, берәр тотым чәче косынка астыннан тугайланып бөселеп чыккан. Косметика-фәлән тимәгән ай шикелле йөзе әйтеп бетергесез нәфис, нәзакәтле. Юк, аның чибәрлеген, камиллеген бөтен нечкәлекләре белән телдән генә әйтеп-сурәтләп бирү минем көчтән килми. Кулымнан килсә, мин аның рәсемен нәкъ менә бүгенге халәтендә ясап куяр идем. Юк бит андый сәләтем, сокланып утырырга гына кала.

Мәсхүтне әйтәм әле, кеше таный-аера белмәгән сукыр бер ахмактыр ул. Врачлыкка укып йөргән була икән тагы үзе. Врачлыгына төкерәсе.

— Бала тотып утыру галәмәт килешә икән сиңа, Нәбирә.

— Чынлап әйтәсеңме, шаяртасың гынамы?

— Нишләп шаяртыйм.

— Рәхмәт инде... Исән-сау алып кайтып җиткерүең өчен дә бик зур рәхмәт.

Авыл урамына килеп кергәнбез икән. Юл озынлыгы сизелми дә калды тагы үземә. Әле яңадан йөз чакрым барасы булса да авырыксынмам, зарыкмас идем шикелле. Машинаны капка төпләренә китереп туктатышка, Нәбирә:

— Бабәй аягын «юмыйча» ярамас инде синең белән,— диде, шаян елмаеп.— Өйгә рәхим ит, әйдә.

— Юк, ярамый, мин, рульдә бит,— дидем һәм, бүген ничәнче тапкырдыр, тагын ялганга бардым:— Аннан ни... эшем дә күп. Концерт бригадасын репетициягә җыясы бар. Синнән башка юньлерәк биючесе дә калмады...

Дөресен әйткәндә, аягым бик тартса да, әтисенең күтәрмәдә басып торган итекләрен күреп, тартынып калдым. Олы кешене уңайсыз хәлдә калдырасым килмәде.

Нәбирә баласын күтәреп өйгә кереп китүгә, үземә ничектер ямансу булып китте, күңелдә ниндидер бушлык барлыкка килде. Якын туганымны озаткандагы шикелле.

Кайчандыр мине кире каккан Нәбирәгә саклап йөрткән бераз үпкәле хисләрем, аны җилбәзәклектә, тотнаксызлыкта гаепләүләрем, мине көчләп юмалап дигәндәй, тиктомалга больницага чыгарып җибәргән Сәхип абыйга иртән кузгалган ачуым, мине мәгънәсез бер бәндәгә чыгарып калган акушерка каршында аклана алмавыма үкенү — бөтенесе-бөтенесе, баярак кына явып, ул арада эреп өлгергән язгы кар шикелле юкка чыкты.

Клубта никадәр эш белән мавыккан кебек булсам да, матур итеп баласын имезеп утырган Нәбирә һәм фәрештәләр тамашасыннан көлемсерәп яткан почык борынлы кызы күз алдымнан китмәде...

## ӘДӘБИ МИРАС

# ГАСЫР БАШЫ ШИГЪРИЯТЕННӘН

Халкыбызның бүген дә яшәмәктә булган рухи, мәдәни хәзинәсендә иң зур урынны әдәби мирас биләп тора. Бихисап афәтләргә, фаҗигале язмышларга тарып та, шөкер, юкка чыкмаган ул. Соңгы елларда исә аны күзаллау мөмкинлекләре әдәбиятчы галимнәрнең һәм Татарстан китап нәшрияты хезмәткәрләренең уртак тел табып, максатчан эшләүләре аркасында сизелерлек киңәйде. Шунысы аерата мөһим: күпгасырлы әдәбиятыбызның тарихи үткәнен фәнни-теоретик тикшерү белән бер үк вакытта диярлек әдәби ядкярләрне җыйнау, текстологик өйрәнү һәм нәшер итүгә игътибар арта бара. Милли горурлыгыбыз чыганагы булган классик әдипләребез әсәрләре фәнни һәм фәнни-популяр басмаларда чыга тору — бигрәк тә куанычлы хәл.

Әмма әдәби мирасыбызның байлыгы, сәнгатьчә кыйммәте классиклар эшчәнлеге белән генә чикләнми. Әдәби хәрәкәттә дистәләрчә, хәтта йөзләрчә авторлар каләм тибрәтеп, күңелләрендәге сүз һәм сурәт аша әйтергә омтылып яшәгәннәр. Билгеле ки, әсәрләренең хисси-фикри тирәнлеге һәм байлыгы белән кайсылары классикларга якынайган, кайсылары шактый еракта торган. Ак тапларны бетерү, һәр әдәби күренешкә, һәр әсәргә, һәр авторга үзенә тиешле бәясен бирү — бүген дә әдәбиятчы галимнәр алдында торган иң зур бурыч.

XX гасыр башы әдәби мирасы бу яктан аеруча игътибарга лаек. Татар халкы, мәгълүм булганча, бу вакытларда чын мәгънәсендә рухи уяну хәрәкәте кичерә. Зур тырышлыклар нәтиҗәсендә, ниһаять, вакытлы татар матбугаты да туа, театр, рәсем сәнгате профессиональ төс ала. Уяну, ул чактагыча әйтсәк, уйгану, бигрәк тә матур әдәбиятта тирәнтен чагылды. Тукай һәм Әмирхановлар, Исхакый һәм Ибраһимовлар, Камаллар әдәбиятыбыз алтын хәзинәсенә керган әсәрләрен бирделәр. Алар янәшәсендә исә бик күп затлар әдәби иҗатка һәвәслек күрсәтте. Бу елларда китап-рисалаларен чыгарган, татар газета һәм журналларында, төрле дәреслек һәм хрестоматияләрдә шигырь, хикәя, нәсер, мәкалә, рецензия, фельетоннарын урнаштырган авторларның гомуми саны сигез йөзләргә җитә диләр. Әле күпмесенең әсәрләре кульъязмаларда гына калган, югалган!

Кызганычка каршы, ул чор иҗатчыларының тәрҗемәи хәлләреннән без аз хәбәрдар. Кайсыларының туу һәм яшәү урыннары, эш-гамәлләре турында бөртек кадәр дә мәгълүмат килеп җитмәгән безнең көннәргә. Икенчеләрен исә культ чоры репрессияләре «көтеп торган»...

Татар язуын кат-кат алмаштыру, үткәнне сыйнфый күзлек аша гына бәяләү, кызыксынмау, битарафлык аркасында шактый ук «ерагайган» XX гасыр башы татар шигърияттен бүгенге укучыга «якынайту» нияте белән бу санда берничә шагыйрьнең шигырьләре тәкъдим ителә. Аларда чагылган уй-фикерләр, өмет һәм борчылулар бүген дә үзләренең тормышчан яңгырашын югалтмаганнар дип ышанам.

Зөфәр РӘМИЕВ

## Фәхрелисләм Агиев

(1887—1938)

Пенза губернасының Төнеш авылыннан (хәзер Мордва АССР да). Күп санлы хикәяләр, мәкаләләр, шигырьләр авторы. Балалар әдәбиятын үстерүгә, яшь буынны тәрбияләүгә күп көч куйган әдип. Татар балалары өчен чыгарылган «Ак юл» журналының (1913—1916) нашир вә мөхәррире. Ул Тукай, Әмирхан һәм Коләхмәтевләрнең якын дусты булган. Шәхес культы корбаны.

## Татар җыры

Эчем пошканда, күңлемнең сынык минутлары булса,
Ышанмаулык изә башласа, күзләргә дә яшь тулса,—

Бөтенләй онтылып, күзләрне йомып башлыймын җырлый;
Күрәсем килми, күрмим шул минутта күкне һәм җирне!

Сизәм: шул җырлаган чакта изелгән рух үсә башлый:
Һаман җырлыйм, җырым бар хәсрәтемне өзгәләп ташлый!

Болытлар тарала, тормыш күгем дә яктырып ала,
Күз алдымда, кырыйсыз сәхрә төсле, хөрлегем кала!..

Тагы җырлыйм татарның моңлы җырын — уйланам, куймыйм,
Гүя айрыласым килми бу җырдан, гүя мин туймыйм!..

Бөтенләй җиңеләям! Тагын бала төсле көләм, уйныйм...
Рухым төшсә, һаман да моңланып татар җырын җырлыйм...

(«Кояш», 1913 ел, 8 март)

## Югал, караңгылык!

Үтеп җил тик китәләр еллар, айлар,
Ләкин аңлар гына үтми, агайлар!

Үтә җил тик чәчәктәй гомеремез дә,
Үтә яшьлек, гөнаһсыз көнемез дә!

Караңгылык безе бу хәлдә тоткан,
Изеп-сыгып безем канларны йоткан.

Карангылык! Югал күз алдымыздан!
Югал рәхәт-зәвыклы дөньямыздан!

Татарлар ләгънәте төшсен йөзеңә!
Сибәрмез бозлы су киткән эзеңә!

*(«Әхбар», 1907 ел, 19 декабрь.)*

# Хәбибулла Габидов

(1886—1939)

Хәзерге Башкортстан АССРның Баймак районы Габделкәрим авылында туган. Өфедә «Галия» мәдрәсәсендә укыганда шәкертләр хәрәкатенә катнашып китеп, аны ташлап чыга. Төрле җирләрдәге мәктәп-мәдрәсәләрдә мөгаллимлек итә. 1917—1918 елларда башкортларның милли хәрәкәтләренә катнашып, бераздан башкорт гаскәрләре белән совет власте ягына чыга. Соңрак рәсми оешмаларда, газета-журнал редакцияләрендә эшли.

Х. Габидов шигырьләре көндәлек матбугат битләрендә 1913 еллардан соң күренә башлый. 1918 елда Оренбургта «Башкорт моңнары» исемле җыентыгы басылып чыга. Совет власте елларында да актив иҗат иткән.

Әй кара күз, әй каләм каш, әй фәрештә очкыны!
Ул зифа буй... нечкә кальбең чын тамукка төштеме?

Калды артыңда сиңа моңсуланып туган илең.
Калды... җырлап чишмәсендә керләрең юган җирең.

Түктереп күз яшьләреңне, гыйззәтеңне саттылар.
Чын ходайсыз таш йөрәкләр кальбеңә ут яктылар.

Көтмә инде, бел, фәрештәм, һич адәмнән мәрхәмәт!
Кайдан алсын мәрхәмәт соң бозланган салкын йөрәк?

Саф мәхәббәт, мәрхәмәт һичкемдә юк... тик миндә бар!
Күкрәгемдә балкыган иман да бар — «алла»м да бар.

Сызланып, хәлең күреп, эчтән көеп — эчтән янып,
Күз яшемә шигъреме яздым каләмемне манып.

*(1915 нче ел, декабрь, 13.)*

## Нигә бу шәмнәр сүнә?

Куркыныч... җан калтырый... дөньяны золмәт каплаган...
Сизенә рух... әрни йөрәк... мескинне залим таптаган.

Анда мәзлум күкрәгеннән ялкын катыш аһлар чыга,
Монда мескин ике күздән кан катыш яшьләр сыга.

Коточыргыч... бик тирән диңгезгә китте бер кеше —
Юк аңа шәфкать итүче, коткаручы-әрнүче.

Чыкты ут... басты төтен... фәрьяд вә зарлар күккә аша!
Тартты гүрдән ил корабын... сыкрый җаннар, ыңгыраша!..

Мәрхәмәт!.. Шәфкать!.. Ярабби!.. Кызганыч өннәр чыга!
Бу караңгы төн үтеп, безгә качан көннәр чыга?..—

дип мөгаллимнәр горуһы сызлана, җаннан бизә,
«Коткарам!» дип милләтен, михнәт күрә, дөнья гизә.

Җан атып, корбан булып шанлы мөгаллимнәр үлә,
Каршыларга изге җаннарны мәляикләр килә.

Киттеләр ул гали җаннар... һичкем боңа күз салмады,
Шиңде-сулды гөл-чәчәкләр, бакчада ямь калмады.

Әйтегез, әй саф күңелләр, ник мөгаллимнәр үлә?!
Җил өрәме, мае йокмый — нигә бу шәмнәр сүнә?

*(1914 ел, март, 24.)*

---

Гыйззәтеңне — кадереңне.

*«Кабуснамә» әсәре. Аны шәрыкъта да гарәбтә дә яратып укыганнар. Бу әсәргә мөгаллимнәр дә, галимнәр һәм бөек акыл ияләре дә һәрзаман игътибарлы булганнар, аңарга мөрәҗәгать иткәннәр. Үгет-нәсыйхәтләргә вә мәслихәтләргә бай булган бу әсәрне XI гасырда Кайкавус исемле зат иҗат иткән. Галимнәр тарафыннан аның Каспий буенда яшәгән Гилән кабиләсе кешесе икәнлеге ачыкланган.*

*Әсәрнең авторы һиҗри ел исәбе белән 412 елда зур булмаган феодал гаиләсендә дөньяга килә. Үзенең әсәрен ул 63 яшендә иҗат итә. Кайкавус «Кабуснамә»не иҗат иткәнче борынгы бабаларыннан калган әдәби мирасны яхшылап үзләштергәнлеге күренеп тора. Ул яшәгән заманда Сәмәрканд шәһәрендә генә дә уникидән артык мәктәп-мәдрәсәләр була, аларда дин гыйльме белән бергә дөньяви фәннәрнең дә укытылганлыгы мәгълүм.*

*«Кабуснамә»нең эчтәлеге әхлак, кешелеклелек, миһербанлылык, дуслык һәм тәрбия мәсьәләләренә багышлана. Ул 44 бүлектән тора. Һәр бүлек аерым бер мәсьәләне бәян итә. Китапның (1—4) дүрт бүлеге дини эчтәлекле. Бишенче бүлек ата-ананы хөрмәтләү хакында, 6 бүлек белемне күтәрергә һәм тәкәббер булмаска өндәүдән гыйбарәт...*

*«Кабуснамә»не беренче тапкыр татар теленә 1881 елда Каюм Насыйри тәрҗемә иткән. Төрек теленә «Кабуснамә» 1432, 1705 елларда тәрҗемә ителгән. Аның уйгур, үзбәк, француз, немец телләрендәге тәрҗемәләре дә бар. Мәшһүр шәрыкъ телләре белгече Е. Э. Бертельс 1953 елда «Кабуснамә»не рус теленә тәрҗемә итә һәм бастырып та чыгара. Бу әсәрне хәзерге татар телендә бастырып чыгару ихтыяҗы да күптән өлгерде. Түбәндә «Кабуснамә»дән өзекләр тәкъдим ителә.*

## Ата-ананы хөрмәт итү хакында

Әй угылым! Акыл вә инсафлылык — ана-ананың гыйззәтен һәм хөрмәтен үз өстеңә алырга куша. Чөнки баланың нигезе — ата-анадыр. Ни өчен әле мин ата-анамны хөрмәт кылам соң дип күңелеңә дә китермә. Син белеп тор, алар синең өчен үләргә дә әзерләр.

Әгәр бала акыллы вә белемле булса ата-анасының мәхәббәтеннән баш тартмас. Ата-ананың бурычы — сине ризыкландыру вә сине яхшылыкка өйрәтү.

Әй угылым! Ата-ананың күңелен рәнҗетмә... Син ата-анаңның хакын дин күзлегеннән ригая кыла[1] алмыйсың икән акыл вә мөрәвәтлек күзлегеннән чыгып ригая кылырга тырыш. Аңла һәм бел, ата-ана сине чын йөрәктән тәрбия кылырга иҗтиһад[2] итәләр. Әгәр син аларга карата хата, начар эш башкарсаң ул чакта син яхшылыкка лаек бәндә булмыйсың. Адәм баласы үз ата-анасының яхшылыгын аңлап бәяли алмый, аларның кадәренә җитми икән инде — ул башкаларның да яхшылыкларын аңлый алмас. Әгәр син үз балаңның сиңа кадер-гыйззәт күрсәтүен телисең икән, ата-анаңны зурлый, хөрмәтли бел. Аларга син нинди хөрмәт күрсәтсәң, балаң да сиңа шуны күрсәтер. Адәм ул җимешкә, ата-ана исә җимеш бирүче куакка охшыйлар. Җимеш куагын яхшылап тәрбияләсәң аның җимеше дә яхшы һәм татлы була. Шуңа күрә дә ата-анаңа кадер-хөрмәтне күбрәк кылсаң, аларның догалары да сиңа тизрәк ирешер, кабул булыр...

Мирас алу нияте белән, нәфеслелек белән ата-анаңа үлем теләмә. Малсызлыктан ярлы булсаң да, акыл ягыннан бай булырга тырыш. Чөнки мал байлыгына караганда акыл байлыгы күп тапкырга артыграк. Акыл белән мал туплап булса да — байлык белән акылны табып булмас. Җаһил, надан бик тиз ярлылана. Әмма шуны бел — акыл ул шундый кыйммәтле бер нәрсә ки — аны угры да алып китә алмас, ул утта да янмый, суга да акмый.

---

[1] ригая кылу — кайгырту, олылау, игътибар итү.
[2] иҗтиһад итү — тырышлык күрсәтү.

Акыллы бала һөнәр өйрәнер. Чөнки һөнәрсез акыл ялангач тәнгә, оятны белмәгән адәмгә тиң. Менә шуңа күрә әйткәннәр дә инде — белем ул акыл күзгесе дип.

## 9 бүлек. Картлык һәм егетлек хакында

Әй угылым! Син нинди генә шәп егет булсаң да, акылың синең олы булсын. Юк, мин сиңа егетләргә охшама дияргә теләмим. Син егетлегеңне камилләштерүдән туктама, җиңел табигатьле булма, сабыр булырга тырыш. Бөек акыл иясе Аристотель: «Егетлек акылсызлыкның бер күренеше ул», — дип әйткән. Җаһил егетләрдән булма, чөнки җаһиллектән төрле бәлаләр туа. Егетлек вакытыңның кадерен бел, мәгънәсезләргә вакытыңны сарыф итмә. Картайгач елап, зарланып, уфтанып утырудан мәгънә булмас. Беркайчан да үлемне исеңнән чыгарма. Үлем картларны да яшьләрне дә аямый ул...

## 10 бүлек. Нәфесне тыя белүнең күркәмлеге һәм ризыклану (ашау) тәртибе турында (өзек)

... Хикәят

Бер вакыт Сәхиб Исмәгыйль бин Сәхиб Габбад үзенең дуслары һәм кардәшләре белән мәҗлестә утыра иде. Арадан берәү кулына бер кабым ризык алды. Аның ризыгында бер чәч бар иде. Сәхиб Исмәгыйль моны күреп: «Әй фәлән туган, кашыгыңдагы чәчне алып ташла», — диде. Ул кеше ашын куеп торып чыгып китте. Сәхиб исә икенче берәүгә аны кире алып килергә боерды. Күпмедер вакыттан алар икәүләп кайтып та килделәр.

Сәхиб әйтте: «Әй туганкай! Нигә син ашыңны ашап бетермичә торып чыгып киттең», — диде. Теге кеше: «Минем ризыгымдагы чәчне күргән кешенең ашын ашау миңа килешле түгел», — дип җавап кайтаргач Сәхиб бу сүзләрдән бик нык оялды...

Әй угылым! Аш вакытында үзең белән генә мәшгуль бул. Соңыннан гына ризык бүлергә боер. Бу мөнәсәбәт белән шуны да искәртим: Халыкның гадәте ике төрле була: Кайберәүләр ризыкны беренче булып алалар, аннан соң гына башкаларга бүлеп бирәләр, ә бәгъзеләре иң әүвәл ризыкны башкаларга куя, аннан соң гына үзләре алалар. Соңгысы мәртәбәле, зыялы затларның ысулы, ә беренчесе исә сәясәт халкының ысулыдыр.

Әй угылым! Аш вакытында кашыңны салып утырма, аш хуҗасына фәлән ризыгың яхшы, ә фәләне начар димә. Мондый сүзләрне аш өстендә сөйләү һич урынсыз.

Әй угылым! Инде ризыклану тәртибен белдең, хәзер шәраб эчү тәртибен дә бел. Чөнки шәраб эчүнең дә урыны һәм тәртибе вә кагыйдәсе бар...

## Шәраб эчү хакында

Әй фәрзәнд!* Мин сиңа шәраб эч дип тә, эчмә дип тә әйтмим. Чөнки яшь егетләр карт кешенең әйткәнлеге өчен генә үз эшләреннән аерылмыйлар. Егет чагымда миңа да күп үгет-нәсыйхәт бирделәр. Мин дә аларны кабул итмәдем.

---

*Фәрзәнд — угыл.

Әй фәрзәнд! Әгәр шәраб эчмәсәң, ике доньяда да файдасын табарсың, халык гайбәтеннән котылачаксың, мин дә синең иң якын дустың булырмын. Әмма син яшь егет. Белеп торам, синең яшьтәшләрең сиңа эчерми тынычланмаслар. Шуңа күрә яман дуслар белән бергә булганга күрә бер ялгызың утыру хәерлерәк.

Әгәр инде шәраб эчәргә уйласаң, ничек эчәргә кирәклекне бел. Аны белмичә генә эчсәң, ул сиңа зыян булачак, белеп эчсәң, агуга каршы торыр. Хакыйкатьтән дә шулай ич: Әгәр ризыкны, яки эчемлекне чамасын белми ашасаң яки эчсәң, ул зыян китерә.

Әгәр күп эчелмәсә, эчкәндә чамасыннан узылмаса, мондый чакта (кешеләр әйтүенә караганда) агу агуга каршы тора ала диләр. Әгәр ашаганнан соң сусап калсаң, өч тапкыр шәраб эч, әгәр сусамасаң өч сәгатькә кадәр сабыр кылу кирәк. Чөнки ашказаның ни кадәрле таза, исән булмасын, барыбер ашказанына чамасыз ашау һәм эчү авырлык китерә. Ашказаны өч сәгать дәвамында ашалган ризыкны сеңдерә һәм бавырга җиткерә, бавыр кешенең барлык әгъзаларына бүлә, әгәр нәрсәседер артык булса, аны эчәккә җибәрә... Сигез сәгатьтән ашказаны бушап кала. Әгәр инде ашказанының шундый көче булмаса — ул ашказаны түгел, ә кабак корсак кына булып кала.

Шуның өчен мин әйткән дә идем, ризык ашаганнан соң өч сәгать уткәч кенә эчемлек эч дип... Исерек чагында кая да булса чыгып йөрмә. Шәраб эчү өчен сахрага, бакчаларга барып йөрмә. Әгәр барсаң, өеңә кайтып җиткәнче исермә, өеңә кайткач исер... Адәмнәр үз өйләрендә патша булсалар да, сахрада ялгызлары гына...

Эчемлекне эчсәң дә ике-өч кәсә эчмә. Ашны күп ашаудан, эчемлекне күп эчүдән сак бул. Күбенгәнче эчеп исерү мөнасиб эш түгел. Шәрабны бер йотым, ризыкны бер локым азрак эч һәм азрак аша.

Эчкечеләрнең ике нәрсәләре бар: берсе — авыру, икенчесе — диваналык. Чөнки эчкече исерә дә махмырлый. Әгәр исерек булса — диваналарга, махмыр булса авыруларга тиң була. Эчкечелек гадәте ул начар авыру белән бәрабәр. Адәм йә диванага, йә авыруга әйләнгәч мондый эш белән шөгыльләнү нигә кирәк!

## Шаяру, мәзәк сөйләү, шахмат һәм нард уйнау әдәбе турында

Әй фәрзәнд! Шаяру — начарлыкның башлангычы дигәннәр. Шаярып, кимсетә торган сүзләр белән кеше күңеленә тыкшынудан сак бул. Исерек вакытында шаярырга тырышма. Чөнки барлык яманлыклар, начарлыклар шаярудан килеп чыга да инде. Әдәпсез сүз сөйләүдән оял. Андый сүзләрне шахмат яки нард уйнаган чакта сөйли күрмә, юкса икегез арасында ызгыш чыгып калуы бар. Шахматны да, нард уенын да күп уйнама. Әгәр уйнасаң да акча куеп уйнама. Акчасыз уйнасаң гына әдәп кысасына сыяр. Бик яхшы шахматчы булсаң да акчага уйнап, бозылып беткән һәм яман ат казанган адәм белән уйнама. Нард вә шахмат уйнауның да мәгълүм бер тәртибе бар: беренче булып шахмат фигурасын алырга тырышма. Беренче булып аны көндәшең сайласын. Әгәр нард уйнасаң уен сөякчәләрен дә көндәшеңә бир, ул беренче булып сайлап алсын. Исерекләр һәм бозык адәмнәр белән бер кайчан да андый уеннар уйнама, әгәр уйнасаң да акча куеп уйный күрмә. Алар белән бәхәскә кермә... Син дөрес сөйләсәң дә, алар аны барыбер ялганга чыгарачаклар. Шаяру гаеп түгел түгелен, ләкин сакланыбрак шаяр. Шаяруның да чамасын белү кирәк. Яман, начар сүзләрне сөйләү ярашлы эш түгел.

Әй фәрзәнд! Үзеңнән түбәнрәк кеше белән шаяр, яки бөтенләй дә

шаярма. Кадерем китмәсен дисәң, үз тиңдәшләрең белән генә шаяр. Алар сиңа шаяру белән җавап кайтарсалар да гаеп булмас. Чамасыз күп шаярма, чөнки кирәгеннән артык шаяру адәмнең кадерен киметә (китерә). Кешеләргә нәрсә әйтсәң шуңа лаек җавап та алырсың, ни кылсаң шуны күрерсең дә. Берәү белән дә сугышма, чөнки сугышу акыллы вә көчле кешеләр эше түгел, яшь балаларга гына хас гадәт. Әгәр кем белән булса сугыша калсаң, телеңә килгән әшәке сүз белән сүгенмә, килешүгә урын калдыр, битсезлек күрсәтмә. Соңгысы бозык, кабахәт кешеләргә генә хас сыйфат. Мөлаем, әдәпле, ихтирамлы булу хәерлерәк. Тәкәбберлек тә начар сыйфатларның берсе. Үзең башкара торган эшләреңдә тәртибен, чамасын онытмасаң гына кешеләр гайбәтеннән азат булырсың.

Уналтынчы бүлектә «Гыйшык һәм аның гадәтләре турында» бәян ителә. Ата үз улына сабырлыкның өстенлеген аңлатырга тырыша. Бер нәрсәгә яки кемгә дә булса мөкиббән китеп гашыйк булуның нәтиҗәләрен гыйбрәтле хикәятләр белән исбатларга тырыша:

«Кеше егетлек вакытында гашыйк булса аның гаебе юк... Гыйшык тотканыңны белеп калсалар да сиңа гаебе юк. Ләкин картлыкта гашыйк булып калсаң... карт кешене кем дә кичермәс... Синең күзеңә барчадан да матур күренгән башкаларның күзенә ямьсез булып күренүе дә бик мөмкин... Шуңа күрә кеше алдында аңа теге яки бу нәрсәне бирмә, аның колагына пышылдап ни дә булса сөйләмә, чөнки халык сиңа шикләнеп караячак...»

## 16 бүлек. Мунчага бару турында (Мунчаның файдасы вә зыяны турында)

Әй фәрзәнд! Мунчага бару ихтыяҗы туса, беркайчан да ашап туйганнан соң барма, чөнки бу бик зарарлы. Һәр көн мунчага барудан да файда юк. Адәмнең сөякләре язылып, йомшарып китә. Шуңа күрә кешенең табигате һәркөн мунча таләп итә башлый, әгәр бармаса барлык әгъзалары аның катып калгандай була. Бәдән тынычлыгы өчен мунчага көн аралаш бару яхшырак.

Җәен яки кышын мунчага барганда иң әүвәл салкынча бүлмәдә утыр. Болай эшләгәндә җисемгә яхшырак була. Аннан соң эссе бүлмәгә кереп берәр сәгать утырып чык, буыннарыңа, тәнеңә рәхәтлек килсен. Шуннан соң аерым бүлмәгә чыгып юынып алырга да була.

Мунчада озак утырма. Кайнар суга кереп утырма. Бик каты кайнар яки салкын суны өстеңә койма. Коена торган суның урта җылылыкта булганы хәерлерәк. Тагын шуны да белеп тор: әгәр мунча буш булса, ул синең бәхеткә булыр. Акыл ияләре дә мунча буш булса бәхет елмайган була дигәннәр. Мунчадан тәнеңне, чәчләреңне яхшылап корытмый торып чыгып китәргә ярамый. Юеш чәч белән өлкәннәр алдына да бару килешле эш түгел. Кыскасы, мунчадан яхшылап кипми торып чыгып китү акыллы кешенең эше түгел.

Мунчаның файдалы ягын да, зыянын да белдең, инде мунчага кергәч су эчүнең ярамаганлыгын да бел. Сары су авыруы нәкъ шуның нәтиҗәсендә барлыкка килә. Әгәр бик каты сусаган булсаң аз гына эчәргә мөмкин.

Акыл ияләренең бер гадәте бар: алар мунчадан соң шунда ук аерым бер бүлмәдә бераз гына йоклап алалар һәм шуннан соң гына кайтып китәләр.

Җәмил ЗӘЙНУЛЛИН,
филология фәннәре кандидаты.

# ПУБЛИЦИСТИКА

*Татар әдәбиятын сөючеләр һәм киң катлам җәмәгатьчелек бу айда күренекле әдибебез Гомәр ага Бәшировка 90 яшь тулуны билгелиләр.*

*Мәгълүм ки, татар совет әдәбиятын Гомәр Бәшировның күпкырлы, киң колачлы иҗатыннан башка күз алдына да китереп булмас иде. Аның тормышны тирәннән аңлап язылган хикәяләре, «Намус», «Җидегән чишмә» кебек романнары күптән инде бер татар халкы байлыгы гына булып калмыйча, илнең башка халыклары һәм кайбер чит ил телләренә дә тәрҗемә ителделәр, кешелекнең гомуми рухи хәзинәсенә әйләнделәр.*

*«Казан утлары» журналы үзенең күпсанлы укучылары исеменнән Гомәр ага Бәшировны күркәм юбилее белән котлый, аңа бәхет, саулык һәм иҗат уңышлары тели.*

*Әдип үзенең 90 яшьлеген яңа публицистик әсәр язып каршылады. Биредә шул язманы тәкъдим итәбез.*

## Гомәр Бәширов

# ГЫЙБРӘТ

### I

Мин хәзер үземне туксан баскычлы биек үр өстендә торам кебегрәк хис кылам. Алдыма карасам, анда баю ягына авыша баручы сары сагышка баткан моңсу кояш күрәм. Узган юлыма борылып карасам, анда һәрберсе озын-озын туксан елга сузылган иксез-чиксез дәрьядай җәелеп яткан бинихая киң җиһан күрәм. Безнең гасырның беренче елларында ук дөньяга килгән ифрат та үзенчәлекле бер буынның бормалы-бормалы тормыш юлы бу, кашкалы (тамгалы, үзенчәлекле) буын юлы. Ни сәбәпле кашкалы дим, чөнки бер буынның да тормыш юлы безнеке шикелле катлаулы, газаплы, четерекле була алмый торгандыр...

Менә шул тиңсез түземле, фидакарь буынның соңгы могиканнарыннан берсе буларак, туксан еллык ераклыкта калган шул зәңгәр офыклар аръягына мин яңадан борылып карыйм. Ни шатлык, шул юлның аргы башында бер бөгелеп, бер тураеп такыр басу ызанында ачы какы җыеп йөрүче яланаяклы чандыр малай күрәм. Каян беләсең: бәлки ул малайга бу кадәр еракларга сузылган гомер юлын узарга туган туфрагының әнә шул ачы какылары, балтырганнары, кыр суганнары, көч биргәндер, шифалы чишмә сулары, яшүсмер чагындагы сабан туе көрәшләре, бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр сузыла торган җир сөрү, тырмалаулары, баш күтәрмичә урак урулары шулай чыныктыргандыр? Бәлки шулайдыр...

Монысы минем җисемем тормышы инде. Адәми зат үзенә бер мөстәкыйль шәхес булып аякка бассын өчен, ул җисемнең эчке дөньясы үз чорына, яшәгән мохитенә хас замана сулышы белән, нииндидер якты омтылышлар, һавада асылынып торган изге теләкләр белән байый барырга тиеш бит әле... Күз җитмәслек шул ерактагы эңгер-меңгергә тагын да текәлебрәк карасам, шул ук киндер ыштанлы яланаяклы малайның каты басуда тырма тырмалап йөрүен күрәм. Кояш шулкадәр аяусыз кыздыра, чыдар хәлләр юк.

Көн уртасы бит. Җиргә басканда аяк табаны пешә, тамак чатнап кибә, тел аңкауга ябыша. Атның бар җиреннән бөрчек-бөрчек тир бәреп чыга, аны кигәвеннәр талый, ул түзә алмыйча пошкырына, тибенә, коерыгын селки, хәтта ыңгырашып куя...

Нишләргә? Ничек түзәргә? Тырмалыйсы җир әнә бит әле нихәтле?

Шәкерт малай җиргә тезләнеп кулларын дога кылырга күтәрә, күз яше белән күккә гозерен әйтә:

— Иланһи раббым, кодрәтең чиксез, мәрхәмәтеңнән ташлама! Кызган безне, кызган үзең бар иткән хайванны, коткар бу афәттән, яудыр яңгырыңны, күрсәт могҗиза! Илаһи раббым, күз яшем белән согынам!..

Малай, күңеле йомшап, битен каплады. Җиңе белән күзен сөрткәндә күтәрелеп караса... йа, кодрәт, йа хода! Бишна урманы өстендә мендәр тикле генә ак болыт калкып чыкмасынмы?!

Малай шатлыгыннан атының муенын кочаклады, күңеленнән ниндидер бик изге теләкләр теләде. Ул да түгел, кечкенә болыт күз алдында үсә, күперә торгач, болайга таба авышты, килеп кояшны каплады, болыт астыннан искән дымлы җил эре-эре яңгыр тамчылары коя башлады.

Салкынча яңгырга аркасын куеп ат, мескен, күзләрен йомды, рәхәткә чумды.

Малай кәләпүшен салып, борынгы кыргый бабалары сыман яңгыр астында кәлә-кәлә сикергәләргә тотынды. Китапларда укыган могҗиза иде бу, могҗиза, ул үтенеп, дога кылып яудырган могҗиза!

Кинәт аңа үзе олыгаеп, дөнья тагын да матурланыбрак киткәндәй тоела башлады. Хәзер инде аның иң бөек кодрәтле зат белән икәве генә белә торган, Хәкимҗан да, Миңҗан да, бүтән малайлар да ышанмаслык тирән сере бар. Аның күңеле шатланып җырлый, күңеле түрендәге мәгъ-нәле сере йөзендә, күзләрендә елмаю булып балкый иде.

Хәзер инде аңа авыл кызларының сузып кына, моңсу гына Иосыф китабын көйләүләре дә ниндидер башкалар белмәгән тылсымлы дөньядан булып ишетелде. Кулларында зырылдаган орчык Иосыф белән Зөләйха мәхәббәтенә аларның үз мәхәббәтләрен дә үреп бара, әллә кайчангы ул гыйбрәтле кыйсса безнең белән бергә яши, хәзер дә дәвам итә кебек тоела башлады.

Рамазан ае кичләрендә ул малай, мәчет манарасына менеп, яшь егетләр белән сузып-сузып «Әлвидаг» көйләде, мәдрәсәдә кичләрен, хәлфә абзый кайтып киткәч, «Сак-Сок» бәетен әйтте:

Мәдрәсәләрдә китап киштәсе,
Сак белән Сокның бәетен иштәсе...

Әнкәй каргагач, Сак-Сок булдык без,
Бу дөньялардан гыйбрәт алдык без...

Болар искә төшкәндә, карт йөрәкнең кай төшедер татлы гына кысылып-кысылып килә. Күрәсең, юкка гына хәтердә яңгырамыйдыр алар, яшүсмернең яңа яуган ак кар төсле керсез саф күңеленә болар һәммәсе дә иң кирәкле җан азыгы булып иңгәндер, Сак белән Сок арасында калкып чыга торган тылсымлы текә тау да гомер юлының хәтәр борылышларында синең вөҗданың сагында торгандыр...

Күз алдына китерәм дә хәйран калам: кадерен белсәң, нинди бай, нинди акыллы һәм гыйбрәтле бу тормыш! Әнә ул, кинәт кенә калкып, яуган ак болытны «чакырып» китермәгән булсам, ул мине беренче илһам җиле булып канатландырмаса, ул дастаннар, бәетләр, җырлар яшь егетнең рухын баетып, күңелен җилкендермәсә, ул яланаяклы малайдан кем чыгар иде икән?.. Белмим, әйтә алмыйм. Һәрхәлдә, ул «мин» булмас идем инде...

Ниләр генә булып алмады бу гасыр башында, тын гына йокымсырап яткан авылны нинди генә шомлы хәбәрләр борчуга салмады?! Бик еракլардан, кояш чыгышы якларыннан солдатларга «Япон сугышы бәете» ияреп кайтты.

Японнар туп аталар,
Порт-Артурны ваталар.
Кайсы аяксыз, кайсы кулсыз
Тилмерешеп яталар... —

диелә иде анда. Ничәмә-ничә мәдрәсәләрдә укылмады, күпме генә аулак өйләрдә әйтелмәде, тол хатыннарның күпме кайнар күз яшьләре түгелүгә сәбәп булмады бу бәетләр!

Ул да түгел, яңа хәбәр таралды. Имештер, Петербурда студентлар патшага каршы күтәрелгәннәр. Шулар патшаны тәхетеннән бәреп төшерә калса, үзенең Вятка ягындагы биләмәсенә качар өчен, Николай патша Казаннан Себергә таба тимер юл салдыра, имеш... Бар, ышанмый кара! Шул елларда Казан елгасы буйлап чыннан да тимер юл суза башладылар. Кичке тынлыкта ул яктан паровоз тавышлары да ишетелә иде инде...

Еллар уза, җилләр исә торды, яңадан-яңа сәер хәбәрләр авыл тәрәзәсен чиертә торды. Ниндидер җил белән мәдрәсәләргә «Беренче сада» килеп керде.

Кояш чыкты, нур балкыты,
Тәрәзәдән өйгә аркылды.
Ятма йоклап, уян, шәкерт,
Кузгалырга вакыт җитте!

Бәет белән мөнәҗәтләргә, «Тәкый гаҗәп» белән «Бакырган»га күнеккән колакларыбызга бу шигырь сәеррәк ишетелде. Без ул «уянуның» чын мәгънәсен аңлап та җиткермидер идек әле. Әмма нишләптер ул безгә ошый башлады. Бу шигырьдән ниндидер яңа, кыю сулыш бәреп тора, ул нидер вәгъдә итә иде. Дәрестән соң, өйгә таралыр алдыннан, бигрәк тә тәгътыйль (каникул) кичәләрендә без ул шигырьне, якын-тирәне шаулатып, бик рәхәтләнеп җырлый идек.

Шундый җилкенгән күңелләрнең кайнарлыгын бастырып, моңсу җилләр дә искәли иде. Теләче, Әтнә, Арча базарчылары ашамы, Казаклар, Кышкар, Курса мәдрәсәсенең шәкертләренә иярепме, башка төрле моңнар безнең авылга да килеп ирешә:

Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы,
Шат яратса да, җиһанга ят яраткан раббысы...

Бу шигырьдә моңа кадәр укыганнарга һич охшамаган, бик тирәндә яткан, әммә күңелләрдә беләсе килү омтылышы тудыра торган, йөрәкләрне чеметеп-чеметеп алучан әчке куәт, тирән моң бар иде. Яисә менә бу шигырь:

Күз яшең дә кипмичә, еглап вафат булган әни!
Гаиләсенә җиһанның ник китердең ят кеше?..

Боларны безгә яттан өйрәнергә куштылар. Ял көне иде. Урамда челтерәп, шатланышып саргылт сулы гөрләвекләр ага, оялары каршысында бөтерелә-бөтерелә сыерчыклар сайрый. Күңел түрендә исә — моң, җиһанга ят кеше... Шагыйрьнең без яшәгән бу дөньяны ят күрүе бик үк ошап бетми, күңелгә ятмый иде. Икенче яктан... шундый якты, шатлыклы дөньядан да канәгать булмас өчен, бу җиһанны башкача күрә белергә кирәктер. Нинди күзлектән күрә белергә?!

Габдулла Тукай исеме ул вакытта безгә Мөхәммәт пәйгамбәр кебек үк бөек зат исеме булып ишетелә иде. Күпмедер вакыттан соң, уночченче елның язында бөтен дөньяга кайгылы хәбәр таралды. Габдулла Тукайның бездән 20-25 чакрымдагы Кушлавыч авылында туып үскән авыл егете икәнен белгәч, башта без моңа бик гаҗәпләндек. Ничек була инде бу? Ул да безнең шикелле авыл чирәмендә, яланаяк килеш каз-үрдәк көткәнме? Авыл мәдрәсәсендә «әлиф, би, ти, си»дән башлаган да, тора-бара шундый биеккә күтәрелгәнме? Инде бала чагында аның да «Апуш» кына булуына тәмам ышанып җиткәч, ул исем бездә чиксез горурлык тудырды, шагыйрьгә карата якташлык, туганлык хисләре уятты. Без аның байтак шигырен яттан белә идек инде.

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең каберең ташы, —
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!

Шагыйрь анасы Мәмдүдә остабикә каберенә тамган күз яшенең «иң ачы һәм татлысы» ул айларда бик күпләрнең йөрәкләренә тамды.

II

Бармы икән тарихта безнең кебек үк газап чиккән башка бер буын?! Үз гомерендә башыннан элек беркайчан да тарихта булмаган, миллионнарның җанын тетрәткән, береннән-бере хәтәррәк, дәһшәтлерәк вакыйгалар кичергән бүтән шундый бер буын?! Юк тарихта андый, юк! Мең шәкертләр булсын, җир шарының башка кыйтгаларында яшәүчеләр Россия халыклары башыннан узган коточкыч дәһшәтләрне беркайчан да, берничек тә кичермәде. Ул заманнар кәрван-кәрван булып күз алдымнан уза. Тәннәр чымырдап китә, көйдергеч ялкыннарыннан тыннар буыла. Менә алар:

— Россия хуҗалыгының җелеген суырып, халыкны тәмам аяктан еккан өчъеллык Герман сугышы;

— Җир шарының алтыдан бер өлешендә бөтен тормышның астын өстенә китергән Октябрь революциясе;

— Күпме кан коелган гражданнар сугышы;

— Идел буендагы коточкыч ачлык;

— Миллионнарның башына җиткән Сталин репрессияләре;

— Бөек Ватан сугышы...

Чү! Сабыр, тукта, каләм, як-ягыңа каран! Хәзер бит әнә нинди хәтәр чаклар, һәйкәлләр җимерелеп, кыйблалар үзгәргән заман! Ил өстендә яңадан дәһшәтле давыллар уйный. Мин хәтта революция елларында да, тормышның болай ук буталуын, халыкларның бу кадәр үк тынычсызлануын хәтерләмим.

> Чыкты җилләр
> купты дулкын —
> Ил корабын җил сөрә!..

Әйе, заманалар тагын үзгәрде. Тормыш мәйданында төрле милли оешмалар, социалистлар, демократлар, радикаллар һ. б. пәйда булды. Аларны табигый бер хәлдәй хуп күреп каршы алдык. Сталинның икейөзле рәхимсез диктатурасы елларында кызыл кикрикле, әмма туң йөрәкле кызыл әтәчләр мәчет манараларын кисеп бетергән булсалар да, шул ук авылларда, җомга кич саен, хәзрәтләрнең телевизорда акыллы вәгазен тыңлау хәзер күңелләр түренә күптән көтелгән тансык, шифалы бәлзәм булып иңә башлады. Ю-ыйсә бит, беркемгә дә сер түгел, безнең җәмгыять каты бәгырьле, кырыс холыклы җансыз бәндәләр тәрбияләүгә йөз тоткан иде. Күз алдында бит, соңгы кырык-илле ел дәвамында иртәсенкичен-көнозын кабатланып торган берүк командалар, берүк боерыклар, бөтен система — кеше рухындагы шәфкать, мәрхәмәт, туганлык кебек табигый хисләрне корыта барды, кеше рухы ифрат саекты, ярлыланды. Тирәнрәк уйлап карасаң, халыкның түземлегенә хәйран каласың. Әйтерсең, кеше дигән бу бөек зат зур бер механизмның кечкенә бер шөребе генә, әйтерсең, ул үзе теләгәнчә, үз иркендә яшәү өчен түгел, бәлки өстән кушылган эш планы үтәү өчен генә, авыл халкы исә ит, сөт, йомырка, йон... җитештерү өчен генә дөньяга килгән!.. Нинди мәгънәсезлек, нинди башбаштаклык!

Шөкер, ул заманнар, бик авырлык белән булса да, акрынлап үтеп бара кебек инде. Дөньяга «хөррият» дигән күптәнге өметле вәгъдә яңадан калкып чыкты. Ләкин менә шул чын хөрлеккә өндәүче дәртле авазлар арасында, шулар күләгәсенә посып, тарих караңгысыннан шомлы кара күләгәләр, элекке кара груһларның өрәкләре дә калкып чыкты бит әле. Алар, күзләрен дә йоммыйча, митингларга Николай патша рәсемен күтәреп чыгалар. Аларның иярченнәре, кан кардәшләре-демократлар, радикаллар, тагын әллә кемнәр байрагын бөркәнеп, шушы буталчыктан файдаланырга, элекке империяне ныгытып калырга, татар халкын элеккечә басып ятарга омтылалар.

— Ай-һай, изге патша тәхетенә кул салу ялгыш булмадымы икән? — диләр алар.— Хәзер ничек кенә яманласалар да, заманында патша Россиясе зур дәүләтләрдән санала иде бит! Изге патша тәхете нинди зур, таркау илне оркетеп торды, шәүкәтле, даны бөтен дөньяга таралды...

«Изге» идеме соң ул халыклар сөяге өстенә корылган тәхет?! Сагынырлык ягы бармы соң ул «халыклар төрмәсе» дип, «балчык аяклы ги-

гант» дип аталган ул көпшәк империянең? Мин — яшьлек елларымда шул империя коллыгы астында яшәп калган кеше. Кара груһларның монархияне сагынып сүз кузгатулары башыма сыймый. Ул нинди кыргыйлык? «Патша режимы» диюгә, минем колагым төбендә каторжаннар аягындагы богаулар тавышы чыңлый башлый. Мин урядник каршысында бүреген салмаган өчен авыл агаеның аркасына чыжылдап камчы төшкәнне үз күзем белән күргән, «Татарин гололобый» — дип акырганны үз колагым белән ишеткән кеше. Октябрь революциясе көннәрендә без шул хурлыктан азат булып, хөр халыклар булып яшәү өчен көрәшмәдекмени?! Моны онытырга һич тә хакыбыз юк!

Безнең буынның бөтен гомере «халык бәхете өчен көрәштә» узды. Әйе, без чын күңелдән халыкка хезмәт итәбез дип, актык көчебезне салып тырыштык. Ләкин соңыннан гына аңладык: матур сүзләргә, гамәлгә ашмастай буш вәгъдәләргә ышанып хурлыклы рәвештә ялгышканбыз икән. Хәзер йөрәкне авырттырып күңелләр рәнҗи, халыкка хыянәт иткән эреле-ваклы тираннарга ләгънәтләр ява.

Ничек без шушы көнгә калдык? Нигә, ни сәбәп? Бөтен дөнья халкы диярлек адәм рәтле тормыш корып үзен бәхетле хис иткәндә, нигә без — Россия — Советлар Союзы халыклары гына шундый кыенлыкка дучар булдык? Без кемнән ким?! Әле безнең буын гынамы?! Безнең бит ата-бабаларыбыз да ничә гасырлар буена хәерчелек чигендә, коллык хәлендә яшәгән. Моңа коммунистлар гына җаваплымы соң? Әллә бу Россиянең борынгыдан ук килгән төзәлмәс чиреме?! Башыма төрле уйлар килә. Нигә?

Мин, төбем-тамырым белән — шушы ил кешесе, яшәешнең ачысын да, төчесен дә җитәрлек татыган халык вәкиле. Тормышның туксанынчы баскычына аяк басканда минем элек булып узган хөкемдарлардан да җавап сорарга хакым бар! Чөнки теге яки бу халык өстеннән хакимлек итү — аны басып яткыру гына түгел! Юк! Хөкемдар булу — ул халык язмышына җаваплылыкны үз өстеңә алу, аның хәзерге тормышын да, киләчәген дә кайгырту дигән сүз! Моңа бөтен кешелек тарихы дәлил!

Тарихчылар, экономистлар безнең илнең артталыгына бик җитди сәбәпләр табалар, төрле дәлилләр китерәләр. Шулай да нигә, ни сәбәпле? дигән сорауга җавап эзләгәндә иң беренче булып әлеге шул Россия хөкемдарларының деспотлыгы, замана таләбен аңлаучылар биеклегендә тормаулары төп сәбәп булып алга килеп баса. Моңа мисалларны күпләп китерергә мөмкин. Мәсәлән, Европа илләре белән чагыштырып карыйк.* Алар үзләренең табигый байлыкларына, халыкның борынгыдан ук килгән тормыш-көнкүреш шартларына таянып, илнең экономик һәм сәяси-иҗтимагый моделен моннан берничә йөз ел элек үк ачыклыйлар (фермер хуҗалыгы, хутор системасы һ. б. юнәлешләр). Россия дәүләте исә бу вакытта үзеннән көчсезрәк күршеләрен басып алып империяне тагын да киңәйтү, гигант дәүләтнең хуҗасы булу комсызлыгы белән шөгыльләнгән. Моңа Россия империясенең чигендәге «Влади...» сүз кушымчасы белән башланып киткән шәһәр исемнәре дә шаһит: Владивосток, Владикавказ... Европа илләре, прогрессның тагын да югарырак баскычына күтәрелеп, университетлар, музейлар, шифаханәләр ачканнар, бөтен дөньяга танылган сәнгать шедеврлары иҗат иткәннәр, халыкның тормышын яхшыртканнар. Ә Россия хөкемдарлары нишләгән? Бәлки тора-бара, күрше дәүләтләрдән күрмәкче, халыкның мондый бөлгенлектә яшәргә тиеш түгеллегенә Россия хөкемдарлары да игътибар итә башлагандыр? Юк шул, Европа фән яктысына омтылганда, Россия императорлары адәм рәтле тормыш өчен, азатлык өчен көрәшүчеләрне рәхимсез асу-кисү белән мәшгуль булган. Россия интеллигенциясенең иң алдынгы вәкилләре — декабристлар каны, гади халык җитәкчеләре Болотников, С. Разин, Е. Пугачев, Салават Юлаев, Бәхтияр Канкаев һәм меңнәрчә бүтән фидакарьләр фаҗигасе Россия монархлары тарихында мәңге онытылмый торган кара тап булып калды.

Фәндә бик тә катлаулы итеп, бутап, башкача аңлатсалар да, без хәзер тарихи шәхеснең халыклар тормышына, хәтта аларның киләчәгенә ифрат көчле тәэсир итүенә ышанмыйча булдыра алмыйбыз. Аның үрнәге тиз генә онытыла торганнардан түгел. Беренче бөтендөнья сугышыннан соңгы чорда башка милләтләр һәм дәүләтләр, сәламәт акыл кушканча гамәл кылып, фән кушканча алга атлаганда, Сталин «Джугашвилиның дөньяда тиңе булмаган канлы хакимияте безне, чабуыбыздан тартып, артка сөйрәде. Без хәзер бу фаҗиганең сәбәпләрен ачарга тырышып үзебезгә

үзебез газаплы сөаль бирәбез: «Әгәр Ленин бу дөньядан вакытсыз китмәгән булса... Әгәр ил белән идарә итү тәхетенә Сталин менеп утырмаган булса?» — дибез һәм авыр сулап куябыз. Тик бер нәрсә бик ачык: ничек кенә булганда да бу — безнең Россия чире! Алдынгы Европа илләрендә аерым шәхес бөтен халыкка карата мондый коточкыч, тетрәндергеч җинаятьләр эшли алмас, аңа мөмкинлек бирмәсләр иде. Россиядә исә андый хәлләр булып торган, тираннарның кансызлыгы электән үк дәвам итеп килгән. Тик масштабы, заманы гына башка булган.

Явыз Иван (Грозный) кем? Бөтен илне канга батырган, үз улына үзе кул салган ярым мәҗнүн кансыз тиран. «Әби патша» дигәннәре дә — бөтен җиһанга иренең канлы мәете аша тәхеткә күтәрелгән комсыз, бозык хатын булып танылган кеше.

Император булып Россияне төрле вакытта төрлечә басып яткан Александрларның берсе дә яхшы истәлек калдырмаган. Александрларның беренчесе, халык җилкәсенә Аракчеевны атландырып, аның кулы белән буып яткан. Ирләрне җиләк кебек чагында туган җиреннән, тормышыннан аерып 25 ел буена казарма режимында яшәргә мәҗбүр иткән. Безнең бабайлар аның турында рәнҗүле җыр чыгарганнар:

Егермебиш ел хезмәт иттем
Әләксандр патшага...

Икенче Александрның кансызлыгы, халык язмышы белән уйнавы шул дәрәҗәгә җиткән ки, ул заманның революционерлары, үзләрен корбан итү бәрабәренә булса да, халыкны аннан азат итәргә хәл кылганнар...

Кыскасы, элек-электән шулай халыкның бәхете булмаган. Рәсәй халкы хөкемдарлардан уңмаган...

Бик гаҗәп хәл: язмыш монда мәкерле уен уйнаган. Россия императоры итеп ул тәхеткә йә чамадан тыш кансыз, кешелексез явызларны, йә дәүләт белән идарә итәргә сәләтсез, йомшак, гомумән, шәхес дәрәҗәсенә күтәрелеп җитмәгән йә «уртача» гына бәндәләрне утырткан.

Россиянең иң соңгы патшасы Николай язмышы да шул фикерне раслый. Яңа борынлаган «монархистлар» аны бик кызганып, мактап язалар. Янәсе, ул бик тә йомшак күңелле, гадел шәхес булган, аны нахакка җәзалаганнар, диләр. Ә аңа үзе исән чагында ук тагылган «канәчкеч Николай» дигән хурлык кушаматын кая куясың?! (Мәскәүнең элекке шәһәр чите булган Ходынкада 1896 елны Николай тәхеткә утыру уңае белән бүләк өләшкәндә бер меңнән артык кеше тапталып үлгән, 1800 кеше гарипләнеп калган. «Канлы якшәмбе», 1905 елның гыйнварында патша гаскәре Петербург эшчеләренең тыныч демонстрациясенә ату нәтиҗәсендә меңнән артык кеше һәлак булган, аннан да күбрәк яраланган.)

Менә танышып карыйк. Портретларында ул юаш кына кыяфәттә, гөнаһсыз бер бәндә булып кына утыра. Саргылт сакаллы тыйнак кына бу кеше бәлки, чыннан да, йомшак күңелле булгандыр? Ходынкада һәлак булган йөз кырык мең кешенең һәлакәтен авыр кичергәндер, борчылгандыр? Ни әйтсәң дә аның түрәләренең гаебе аркасында тапталган бит ул бичаралар... Николай патша бу хакта тыныч кына «...йөз утыз мең кешенең тапталып үлүе миңа җан биздергеч дәрәҗәдә начар тәэсир итте (?)...» дип язып куя да, Франция илчесе оештырган җиде мең кешелек шаушулы мәҗлескә яшь хатыны белән биергә китә... Бары шул гына! Бу уңайдан кайгы белдереп тантананы туктату да, борчылу да, кайгы мәрасиме дә юк. Әйтерсең, берни дә булмаган, әйтерсең, коточкыч бу фаҗигада аның тузан кадәр дә гаебе юк!

Бәлки император буларак аның җитәкчелек сәләте халыкны кайгырту ягыннан илгә, халыкка зур сынау кичерергә туры килгән кризис көннәрендә ачыграк күренгәндер? Бәлки шундый чакта, акылга килеп, халык өчен берәр яхшылык эшләгәндер? Ни әйтсәң дә, ул да кеше ләбаса!..

Менә 1917 елның февраль көннәре, халык ачыга башлаган, армия таркала, корал ташлый, Россия дәүләтенең хәле кыл өстендә. Министрлар советы рәисе, фронт командующийлары патшага илнең һәлакәт алдында торуын аңлаталар, нинди дә булса чара күрергә, халыкның хәлен җиңеләйтергә киңәш бирәләр. Николай аларның һәркайсын: «Юк! Берни дә үзгәрмәсен!» — дип кисеп кенә салган.

Хәер, Николай үзе генә түгел, аның тирә-юне дә, халыклар аңында зур үзгәрешләр барлыкка килүен белмәмешкә салынган, халык теләге белән исәпләшүне кирәк санамаган. Алар дәүләт белән нәкъ борынгыдан килгәнчә урядник йодрыгы, казак камчысы була диган фикердә торганнар.

1917 елның февралендә Николайның хатыны Мария Федоровна Ставкадагы иренә язган хатында аңа, мәсәлән, шундый киңәш биргән: «Кадерлем, нык тор! Күрсәт русларга йодрыгыңның көчен! Миңа ничә кеше әйтте инде: аларга камчы кирәк, алар моны үзләре сорап торалар. Бу бик сәер; ләкин славянның табигате шундый... Алар хәзергә әле синнән куркалар, ләкин тагын да ныграк куркырга тиешләр! Кайда гына булсаң да, алар синең алдыңда калтырап торсыннар!..»

Иа хода! Кем әйтә диген бу мыскыллау, хурлау сүзләрен? Рус халкының күпчелеге табынып яшәгән рус патшасының хатыны әйтә! «Үз» халкына карата әйтә! Билгеле, руслардан башка халыклар хакында әйтеп тә торасы юк, патша нәселе аларны кешегә дә санамаган! Кем булуларын да белмәгән!..

Гасырлар буена шулай килгән, патша нәселе үзен ходай тарафыннан халыкларның башында утыру өчен яратылган затлы нәсел дип исәпләгән. Минә шушы кәпәренү, патша — теләсә ни эшләргә хаклы, вакыйгаларны үзе теләгән якка борып җибәрергә сәләтле зат, дип ышану Мария Федоровнаның иренә язган икенче бер хатында тагын да катгыйрак итеп, кистереп әйтелгән: «...Кайчан син шуларга, ниһаять, бер өстәл сугып кычкырасың инде?! Син бит — Россиянең хуҗасы, һәммәсенә баш кеше, шуны онытма? Шул бозык бәндәләр һәм республикачылар төркеменә каршы арыслан бул! Үзеңне олы тот! Бөек Петр бул, Явыз Иван, Павел Беренче бул, күрсәт йодрыгыңның көчен, бөгеп сал, ботарлап ыргыт шуларны!..»

Алма агачыннан ерак төшми, диләр бит, Икенче Николай да нәкъ бабалары юлын дәвам иттергән, хәтта патшалык итүенең соңгы көннәрендә дә ул ил язмышы, халык язмышы хакында уйланып борчылмаган, үзен теләсә нишләргә хакы булган «бөек» кеше итеп тоткан!

Бу уңайдан «Бөтен Россия императоры»ның минем кулга 1923-24 елларда ук кергән һәм ваемсызлыгы белән хәйран калдырган көндәлеге искә төште. Вакыт күп узу сәбәпле мин аны сүзгә-сүз китерә алмыйм, әмма эчтәлеген хәтерлим.

«...Бүген түтиләрдә аш мәҗлесендә булдык. Сый-хөрмәт әгъләләрдән иде. Князь (фамилиясе истә калмаган) ифрат үткен һәм кызык анекдотлар сөйләде. Гомумән, мәҗлестән бик канәгать калдык...»

Гаҗәп бит, хәтта башка сыймаслык! 1917 елның февраль айларында язылган бит бу! Россия империясе җимерелергә торганда, фронтның таркала башлаган чагында! Тәхете аварга торган шундый хәтәр һәм фаҗигале көннәрдә император кешенең, баш командующийның анекдотлар тыңлап кәефләнүдән башка бер генә җитди борчуы да булмадымы икәнни?! Шулкадәр фикер сайлыгы, шундый рухи ярлылык! Хәйран каласың!

Хәер, Рәсәй патшасы бит ул!Ниләр генә булмас дисең бу серле, буталчык Рәсәйдә!..

Күрәсең, Романовлар династиясе Европа һәм Америкадагы иҗтимагый сәяси үзгәрешләр, фән-техника яңалыклары тәхеткә куркыныч яный дип шикләнгәннәрдер, алар демократиягә омтылышны, фәнгә, техникага яңалык кертүне рәхимсез рәвештә бастыра килгәннәр. Искелеккә ябышып яту, яңалыкка тискәре караш тора-бара җәмгыятьнең тәмам канына сеңгән. Бу тискәрелек, искегә табыну нәтиҗәсендә яңа, прогрессив фикерләр гамәлгә ашмый калган, проектлар күбесе төрмәдә черегән. Шуны гына искә алу да җитә: патшаның Министрлар советы рәисе Столыпинны хәтта җирдән файдалануга реформа кертергә омтылуы өчен дә атып үтергәннәр!

Шунысы бик гаҗәп, Романовлар династиясенең яңача фикерләүне кысу, демократияне рәхимсез рәвештә сүндерә бару сәясәтен үз заманында Сталин да кулланды. Күренекле совет галимнәре Вавилов, Чаянов һ. б. бик күпләр нәкъ әнә шул тормышка яңалык кертеп халыкның яшәеш шартларын адәм рәтле итәргә тырышулары өчен җәзаландылар. Кибернетика белән компьютер техникасы мәйданга чыкканда, Сталин юк иде инде. Ләкин Россия галимнәре барыбер искелек богавыннан азат була алмадылар. Бу уңайдан «череп таркалучы капитализм сихерчелеккә күчте» дию-

ләре белән дөнья күләмендә күләгәдә калдылар. Бу да монархиянең калган тискәрелек мирасын дәвам иттерү түгелмени?!

Нихәл итмәк кирәк, Рәсәй бит бу! «Балчык аяклы гигант»ның һаман да шул үзен-үзе замана кушканча идарә итәргә сәләтсезлегенең бәласе. Яшермичә генә әйткәндә, без әле хәзер дә менә шул булдыксызлык, деспотлык аркасында җәфа чигәбез!

Артта калган туксан еллык озын юлга борылып караганда үкенүдән йөрәк сызлана. Күпме фаҗига, күпме үлем, күпме вөҗдан газабы! Әмма шулар арасында иң авыры, багырьләргә тия торганы, кимсетүләргә, гаделсезлекләргә түзү мәҗбүрияте иде. Шуларның берсе — Явыз Иван Казан ханлыгын басып алуын тарихта прогрессив күренеш дип аңлатып килүләре. Моннан байтак еллар элек дәүләт музеенда татар әдәбияты бүлеген ачканда өстә утырган татар түрәсе, милләтчелектә гаепләнүдән куркып, бу хакта иң күренекле урынга классиклар фикерен дә язып элдерткән иде.

Мондый фикер белән килешү — хакыйкатькә ачыктан-ачык хыянәт итү ләбаса? Каян килеп, басып алу — прогрессив күренеш булсын икән?! Безнең борынгы бабаларыбыз — болгарлар, Көнчыгыш Европада беренчеләрдән булып үз дәүләтләрен оештырганнар, моннан 1100 ел элек үк, мәҗүсилектән баш тартып, ислам дине кабул иткәннәр. Аларның бай язма әдәбияты, һәртөрле карьханәләре (остаханә), мәчет-мәдрәсәләре яшәп килгән. Болгар дәүләте Көнчыгыш һәм Көнбатыш илләренең сәүдәгәрләрен очраштыручы эре сәүдә үзәге булып хезмәт иткән. Болгар дәүләте һәлак булганнан соң Казанга күчкән халык мөстәкыйль дәүләт булып яшәвен янә дәвам иттергән. Алты йөз илле ел чамасы мөстәкыйль дәүләт булып яшәгән халыкны басып алып, аның матди, мәдәни, әдәби байлыгын җимереп, туздырып ташлау, үзен кол итү ничек уңай вакыйга булсын икән?!

Явыз Иванның Казанны алгандагы кансызлыгы — бәхәссез, авыр фаҗига, бу ышанычлы мәгълүматлар белән раслана. Татар халкы бу һәлакәтне бик тирәннән кичергән, ул хакта күп санлы бәетләр чыгарган. Мин бала чакта мәдрәсәдә әйтелә торган бәетнең берсе болай башлана иде.

Балалар, балалар, таш каланы алалар,
Таш каланы алалар да безне утка салалар...

Патша режимының татарларга булган рәхимсез мөнәсәбәтенең асылын аңлау өчен безнең халыкны көчләп чукындыру кебек кыргыйлыкны искә төшерү дә җитә. Бу көчләүләр вакытында күпме халык тотенле базларга ябып җәзаланды, күпмесе кыйнаудан һәлак булды, күпме кешенең рухы гарипләнеп калды, күпме халык байлыгы таланды. Русларның дин башлыклары «андагы җәннәткә охшашлы җирләрне, хәтта татарлар безгә дус булган суратта да, басып алырга кирәк», дип, бу юлбасарлыкны хуплап торганнар. Хәзер булса, бу вәхшилек — геноцид, дип аталыр һәм халыкара кануннар буенча хөкем ителер иде.

Шушы көчләп чукындыруны, татар халкын көчләп үз мәдәниятеннән, үз теленнән мәхрүм итүне дә прогрессив күренеш дип бәяләп булмый торгандыр бит!? Тарихи фактлар нәкъ шуның киресен сөйли түгелме соң? Мәсәлән, Казан ханлыгын алганда илдә дүрт йөз сиксән чамасы мәчет һәм шулкадәр үк мәдрәсә юкка чыгарылган. Әмма халык китап сүзеннән башка яши алмаган, яндырылганнары урынына, кыенлык белән булса да, яңа мәчет-мәдрәсәләр салган. Миссионерлар һәм патша солдатлары исә 1744-1755 еллар арасында янә дүрт йөз унсигез мәчет һәм мәдрәсә юк иткәннәр.

Бу кимсетүләргә тагын патша хөкүмәтенең татарларга үз телләрендә газета чыгарырга, театр ачарга рөхсәт итмәвен, татар яшьләрен югары уку йортларына укырга кертмәвен, татар халкына карата гомумән дошманлык сәясәте кулланууын да өстәргә кирәк. Патша жандармериясе кемнәрне генә эзәрлекләмәгән, татар зыялыларыннан (Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов кебекләрне дә кертеп) кемнәр генә патша төрмәләрендә утырмаган?!

Озын сүзнең кыскасы шул — хөкемдарлардан уңмадык. Безнең дәүләт башында утыручылар дөнья цивилизациясеннән йөз елларга артта сөйрәлделәр. Күз алдында бит: Америка белән Канада булсын, Голландия белән Бельгия, яки Финляндия белән Швеция булсын, һәркайсының дөнья базарында үзенә лаек мактаулы урыны бар. Россия хөкемдарлары исә гомер-гомергә

чама белмәде, цивилизация агымына ияреpгә сәләтләре җитмәде. «Дөньяда юкны пешер хатын!» — дигәндәй, тарихта булмастай гамәлләр кылып, нинди дә булса «мөгез чыгару» Россия хөкемдарларының канына сеңгән, күрәсең. Чөнки корыч диктатор Сталин да патшалар деспотлыгын кабатлады, ул да, нәкъ алар кебек замана белән, халыкның гореф-гадәте таләпләре белән исәпләшмичә, яңа «мөгез чыгарып» маташты: тундрада болан асраучылар белән кара диңгез буенда йөзем һәм шафталу үстерүчеләрне, балыкчылар белән бодай игүчеләрне көчләп бер арбага җикте. Нәтиҗәсе күз алдында...

Ил башында, Югары Советта утыручылар әле хәзер дә илле ел буена халыкны интектергән, ниһаять, «үзе бара алмый, үзе таралмый», дип, яманаты чыккан әнә шул авыр мирастан ничек котылырга белмичә баш ваталар. Шунысы бик гыйбрәтле, алар алдында башка илләр моннан йөз ел элек үк хәл иткән төп мәсьәләне «киләчәктә ничек яшәргә?» дигән мәсьәләне хәл итү бурычы тора. Димәк, нәрсә килеп чыга? Без бер гасыр буена гел бер урында таптанганбыз!..

Күрергә теләгәннең күз алдында: канлы күз яше бәрабәренә булса да, тормыш акыл бирде бит инде — колачың җитмәгәнне кочакларга көчәнмә! Ун меңнәрчә километргa җәелгән гигант илне бер ноктадан торып идарә итү — чиксез кыен шөгыль. Йөз егерме төрле шартларда, йөз егерме төрле гореф-гадәт белән яшәп, йөз егерме телдә сөйләшүче, мәдәниятнең төрле баскычларында торучы йөзләрчә халык белән Бабил манарасы салу, ай-һай, мөмкинме икән?!

Халыкларның үз язмышларын үзләренә тапшырырга кирәк. Татар халкының үз дәүләтен үзе идарә итәргә хакы да, тәҗрибәсе дә бар. Җәннәткә көчләп кертмиләр. Уңсаң да үзең, туңсаң да үзең. Үз язмышыңны үзең яз, үз тормышыңны үзең көйлә, ни булса да үзең бел, үзең ела, үзең көл, әмма күршелекне һәрдаим изге дип бел! Иленең язмышын кайгыртуны үз өстенә алган халык, ваемсызланып; башкалардан ярдәм көтеп ятмаячак. Мөстәкыйльлек алу халыкның үз эченнән эшлекле, уңган җитәкчеләр, акыллы лидерлар, төрле талант ияләре калкып чыгуга көчле стимул булачак.

Нигә моңа Финляндия үрнәк булмасын икән? Патша кул астында чагында ул нибары колония генә иде. Мөстәкыйльлек алганнан соң иң алдынгы мәмләкәтләр сафына менде.

Мөстәкыйль дәүләт статусы Татарстанда яшәүче башка халыкларга да кирәк. Без бит борынгы заманнардан бирле үк күп милләтле республика булып яшибез. Татар мәдәниятенең башка халыклар казанышы белән кулга-кул тотынып бергә чәчәк атуы нур өстенә нур булачак. Халыклар дуслыгы — кешелек дөньясының мең еллардан бирле сыналып килгән иң гүзәл казанышы.

## III

— Ахырзаман!..

Кая гына барма, карт-карчыклар авызында хәзер һаман шул бер сүз, бер шомлы фал:

— Ахырзаман җитә, ахырзаман! Шуның галәмәтләре! Ахырзаман якынлашмаса, халык бу тикле чыгырыннан чыкмас иде! Юк!

— Мөгаен шулайдыр! Ишеттегезме? Казанның «Куба» дигән бер почмагында беләсезме ниләр булды? Төнлә ике машина белән киләләр дә, өеннән чакырып чыгарып, бер бандитны атып үтерәләр. Беләсезме шуны ничек күмделәр? Халык белән бөтен урам тулды, унлап автобус гына килде. Бәләкәй машинаның чуты да юк! Нинди зур түрә үлгәндә дә, бу хәтле халык җыелганы юк! Искитмәле!..

— Әле ул гынамы? Шул бандитның егылып үлгән урынына көн саен чәчәк куеп тордылар! Ишетәсезме — көн саен! Өч атна буена!

— Әйе. Гаҗәп-хәйран! Кемнәр куя соң ул чәчәкне, кемнәр?

— Ә милиция нәрсә карый? Ник күрми? Ул нишли?

— Нишләсен? Шыпырт кына читтән карап тора!..

— Менә сиңа, мә! Ышан хәзерге милициягә! Китте Казанның яманаты!

— Ахырзаман! Бөтенесе азды, юлдан язды. Хатын-кыз аракы эчә, кызлар сүгенә! Гарип балалар күп туа, коточкыч! Алла сакласын!

— Балалар да азды. Кичен урамга чыксаң, исән кайтырмын димә! Малайлар очраган бер кешене тимер чыбык белән кыйныйлар! Нишләп кыйныйлар? Аларга ни җитми? Алла белсен!..

— Бер дә бүтән түгел, шул инде — ахырзаман, әәҗүҗ-мәәҗүҗ чыгар заманнар җитте! Халыкта иман калмады, намус качты. Вәгъдәдә тору бетте. Коръән күтәрелер* вакыт җитте! Әстәгъфирулла-тәүбә! Ходаем, имансыз китүең бар!

Зират коймасы буенда яулыгын күзләренә үк төшереп бәйләгән бер әби, акрын гына атынгалап, борынгы китаплар укый, мөнаҗәтләр әйтә:

— Ахырзаман җитсә,ниләр булгай,

Галимнәр чагыр эчеп зина кылгай...

Әгәр бу әби моннан җиде-сигез ел элек шулай укынса, аны күптән «карга күтәреп киткән» булыр иде инде. Аның өчен ул көннәр чыннан да ахырзаман булыр иде. Аннары аны, башына капчык кидереп, тимер ишекләрнең берсеннән соңгы юлына алып китәрләр иде. Бәхете бар икән: яңарыш елларына кадәр бәлагә тарымаган. Мин аның янында туктап сораштыра башладым:

— Әбекәй, бигайбә! Син бит бик хәтәр сүзләр сөйлисең! Ахырзаман булгач, ул бит инде дөньяның асты-өскә килә, бөтенләй бетәбез дигән сүз була! Бик хәвефле сүз бит бу! Син аңа үзең дә ышанасыңмы? Бәлки синең китабыңда динне нығыту, халыкны шундыйлар белән өркетеп азып-тузудан саклар өчен генә шулай язылгандыр?

Әби як-ягына төкеренде:

— Әстәгъфирулла-тәүбә! Мөэмин-мөселманмы син? Әллә киртә сикергән бәндәме? Мөэмин булсаң, әстәгъфируллаңны әйтеп, иманыңны яңарт! «Ля иляһа илла аллаһ, Мөхәммәд рәсүлуллаһ!» диген...

Аннары ул, кулын күзләренә куеп, мине башымнан аягыма кадәр тикшереп чыкты. Күрәсең, мин аңа кяфер булып ук күренмәгәнмен, шуннан соң гына мине үзе белән сөйләшергә лаек бәндә дип тапты шикелле.

— Син үзең дә китап тоткан кешегә охшыйсың! Уйлап кара, ничек мин Коръән шәриф сүзләрен бозып әйтергә җөрьәт кылыйм? Гөнаһын кая куярмын? Юк, кордаш, һәммәсе китап сүзе, акка кара белән язылган! Ахырзаман җиткәч, күктә тимер кошлар оча башлар дигәнме? Дигән! Күктә тимер чыбыклардан пәрәвез хасил булыр дип язган. Урамга чыккач күтәрелеп кара! Хакмы? Хак! Ходаның язганы шулай...

Әбигә якын гына утырган агач аяклы саргылт сакаллы гарип солдат та аның сүзен куәтләде.

— Радио тыңлыйсыңдыр, шәт, агайне, тиливизор да карыйсыңдыр, әйеме? Күрәсең-ишетәсеңдер, монда гына түгел бу афәт! Җир шарының вобше тынычлыгы бетте. Кругом зилзилә, су ташкыны, котыра, таулар җимерелә, кешеләрне бөтен авылы-ние белән җир йота, дәрьялар шәһәрләргә ташлана! Зарарга генә димә! Әби дөресен әйтә, көллесе ахырзаман галәмәте! Һәммәсе борынгы китапларда язганга туры килә. Бу фетнәләр һәммәсе ходаның шуңа ишарәсе!

Аңлашыла, монысы сугышта нәзер әйтеп кайткан...

Әби укына калды, мин китеп бардым. Әйе, дөресен укый иде карчык. «Тәкый гаҗәп» китабында, тагын уннарча башкаларында моннан йөз илле, ике йөз илле, мең еллар элек нәкъ шулай язылган. Шәрыкның борынгы зирәк галимнәре тормышның барышын, нинди гамәлнең кая алып чыгасын алдан ук күрә белгәннәр. Халык азар, дөньяны имансызлар басар, ата — улын, ана кызын белми башлар, дип тә язганнар...

Күптән түгел чыбык очы кардәшемнең күз яше белән елавы исемә төште:

— Улым төн уртасында бер марҗа кызы ияртеп кайтты да мин йоклый торган бүлмәгә килеп керде. «Монда без йокларбыз инде, бу кызый минем хатыным булыр»,— диде. Ничек түзәргә бу хурлыкка?!

Кичә генә телевизорда бер ханым сөйләде:

— Казан шәһәрендә узган ел гына да йөзгә якын яшь ана үз баласыннан баш тартты. Хәзер шәһәребездә ата-анасы ташлаган шундый ятим сабыйлар берничә йөз. Коточкыч хәл бу, бозыклыкның актык чиге! Кыргый хайван да үз баласын үзе тәрбияли.

— Ахырзаман җитсә, ниләр булгай, иркәкләр хатыннарга охшап калгай...

Газаплы авыр уйларымнан чыркылдап көлгән яшь тавыш уятты. Янәшәдән ике яшь нәрсә узып бара икән... Икесенең дә кигәннәре берүк төрле,

---

* Коръән күтәрелү — борынгы китапларда ахырзаман җиткәч, Коръәннең сүзләре күккә очар, буш кәгазь генә калыр диелә.

бер төсле: зәңгәр киндердән тегелгән чалбар, җиз төймәле берүк төсле кофта... Бер-берсенең кабыргаларына төртеп чыркылдашалар, әледән-әле пумаладай тузгак башларын селкеп куялар, иреннәренә җыелган көнбагыш кабыгын тротуарга төкерәләр... Иа хода! Кайсы кыз бала боларның, кайсы егет? Ә?

Шулардыр инде. Шушындыйлар балаларын да көнбагыш кабыгын төкергән кебек кенә ташлап китәләрдер. Ничек куллары күтәрелә? Ничек җир күтәреп тора боларны? Ничек яшен сукмый? Кая бара бу баштанаяк ясалмалык белән агуланган кыланчык токым!

Кинокартина алдыннан рок-группа концертын биреп алалар икән. Сәхнәдә күз иярмәслек тизлек белән яшел, кызыл, зәңгәр, сары утлар уйный, барабан дөпелди, ачы итеп сыбызгы чәрелди. Шул какофония эченнән йөзен куе сакал баскан озын чәчле бер зат маймылдай, аякларын ике якка җәеп, сикереп чыкты да, күзләрен акайтып, кинәт кыргый тавыш белән шырыйлап кычкырып җибәрде. Ул кеше миңа борынгы заманнарның ярым кыргый, ярым сихерче шаманнарын хәтерләтте. Нәселдәшләренең котын алу өчен ул да шулай кыргый җанвар тавышы белән кычкырып җибәргәндер...

Ул да түгел, котырынган утлар өермәсе эченнән ярым шәрә бер хатын килеп чыкты да ялангач ботларының ниндилеген төрлечә айкап, арт саннарын оятсыз биетеп күрсәткәннән соң, әлеге йонлач кешене кочагына алды. Ниндидер кыргый тавышлар ритмына кушылып, әлеге йонлач бәндә шәрә хатынны бер күкрәгенә кысып, бер идәнгә ташлап тегеләй дә болай әвәләргә тотынды.

Залны тутырып утырган яшь кызлар, яңа мыек чыга башлаган малайлар котырынып кул чаба, аяклары белән дөберди, чиный, сызгыра иде.

Мин тыннарым буылып, күз алларым әлҗе-мөлҗе килеп саф һавага ыргылдым. Бераз аңыма килә алмыйча тордым. Әллә... Әллә чыннан да ахырзаман җиттеме? Югыйсә бит...

Әйе, югыйсә бит аңлавы кыен! Әйе, кыен! Башка сыймый. Мин 1917—1920 еллардагы үзгәрешне башымнан кичергән кеше. Ул вакытта да ике-өч мәртәбә власть алмашынды, хөррият дип, НЭП дип байтак кешенең башы чуалды. Ләкин шундый ачлы-туклы яшәгән кыен елларда да, шәһәрдә булсын, авылда булсын, халыкның борынгыдан килгән изге гореф-гадәтләрен, әдәп-әхлак кагыйдәләрен хәзерге кебек аяк астына салып таптамаганнар иде. Шул авыр чорда да спектакльләр, концертлар халыкның рухын игелекле, җанга якын нечкә хисләр белән баету урыны булып санала, без сәхнәләрдә гүзәллек алиһәсе, нәфис сүз остасы Фатыйма Ильскаяның соклангыч уенын күреп, Галия Кайбицкая, Сара Садыйкова, Гөлсем Сөләйманова, Салих Сәйдәш кебек онытылмас талантларны тыңлап, күңелебез матурлык, нәфислек, изгелек тойгылары белән илһамланып кайта идек. Ә хәзер? Озын чәчленең акайган күз карашы, шәрә кешеләрнең оятсызлыгы күңелемне рәнҗетте. Тукта, бу бит чыннан да нәкъ борынгы китапларда язылганча:

— Ахырзаман җитсә,ниләр булгай? Хатын-кызда әдәп-оят качкай, бәндәләрдә намус пычрангай. Һәм, ниһаять, адәми зат үз пычрагында үзе гарык булгай...

Шикләнебрәк кенә күтәрелеп карадым. Шөкер, әле актык чиккә барып җитмәгәнбез булса кирәк. Тормыш дәвам итә, шәһәр урамы шаулый, гөрли. Әнә аллеяларда яшел агачлар, әнә генә күптәнге таныш Шамил йорты, андагы Габдулла Тукай музеена кереп баручы пөхтә киенгән әдәпле замандашларыбыз.

Әйе, шөкер, бу күргәннәрем ахырзаманның үзе үк түгел икән әле.

Чыннан да, әгәр әби әйткәннәр дөрескә чыкса, ул бик үкенечле дә, гаделсез дә булыр иде. Чөнки тарихка күз салсак, хәйран каласың! Карасана, моңарчы инсаниятнең бөтен гомере ызгыш-талашта, ачлык-фәкыйрьлектә, бәхетсезлектә узган икән ләбаса! Тоташ сугыш та кырылыш, күз яше, аяныч язмыш! Кеше дигәнең — табигатьнең кадерле баласы, күз өстендә кашы, бөтен яшәеш дөньясының таҗы! Аның дөньяны җәннәт итәргә, гадел тормыш белән яшәргә хакы бар! Мөмкинлеге дә чиксез!

Шулай да тынычланырга хакыбыз юк! Һич! Бер генә сәгатькә дә, бер генә минутка да!

## IV

Шулай, кабатлап әйтәм, тынычланырга һич хакыбыз юк, чөнки безгә ахырзаманны әллә кайлардан көтәсе түгел. Әлегә халыкларга җир шарын

зир-зөбәр китереп җимереп ташларга сәләтле булган атом бомбасы да, дин китапларында тасвир ителгән җирне ашап килүче әәҗүҗ-мәәҗүҗ дә янамый. Юк, безгә бүтән төрле һәлакәт яный. Татар халкының ахырзаманы, аның аерылмас кара күләгәсе үзе белән бергә йөри. Әйе, җәмгыятебез һаман да менә хәзергесе кебек яшәсә, ягъни, Сталин чорында туып, башкалар чорында нытып калган шушы ярым коллык шартларында яшәвен дәвам иттерсә, аны бүтән төрле ахырзаман көтә. Ул — мәшһүр әдип Гаяз Исхакый моннан сиксән алты ел элек үк искәртеп, сискәндереп куйган инкыйраз (юкка чыгу, бетү).

Бөек әдип үзенең публицистик алым белән иҗат ителгән ярым фантастик әсәре «Ике йөз елдан соң инкыйраз»да татар халкының киләчәге өчен ифрат борчылып язган. Аныңча, халыкны «...акыртын гына шәм кебек тик торганда эреп бетәргә» дучар иткән сәбәпләр байтак кына. Мәсәлән, байларның халыкка яшәеш шартларын, мәдәниятләрен алга әйдәргә ярдәм кулы сузмыйча, яхшы уку йортлары салмыйча, байлыкларын «курчак туе» кебек юк-барга исраф кылулары, мәдрәсәләрдә укуларның заман таләбенчә югары дәрәҗәдә куелмавы, шәкертләрнең һич файдасыз сафсата белән башларын әйләндерү, галим-голәманың наданлыгы, юк-бар белән мавыгып халык мәнфәгатен кайгыртмавы, халык арасында төрле йогышлы авырулар таралу...

Автор гөман кылганча, бу сәбәпләр халыкның кырылуын тизләтәчәк, ул ике йөз елдан соң тәмам кырылып бетәчәк.

«Егерменче гасырның ахыры җитә башлады. Бу гасыр белән бик күп нәрсәләремез бетте, гәзитләремез бетте, мөхәррирләремез бетте... Халык һаман тарала бара иде. Сала халыклары заводлар, фабрикаларга күчә баралар, шәһәр халкы да вак-төяк толчок кәсебе белән кара эшкә генә кала баралар иде»...

Бөек әдипнең пәйгамбәрлек сәләте хәйран калырлык. Мондый әсәр язу өчен җәмгыять тормышын, анда өстенлек иткән төрле фикер юнәлешләрен бик тирән белергә, шуның өстенә, философ һәм, барыннан да бигрәк, киң карашлы талант иясе булырга кирәк. Әдипнең үз милләтен, бигрәк тә аның зыялыларын, киләчәктә көтелгән һәлакәттән искәртеп куюы зур игътибарга һәм ихтирамга лаеклы.

Инде шунысын да әйтергә кирәк, Г Исхакыйга ихтирамыбыз никадәр зур булмасын, бу әсәрне укыганда, күңелдә берникадәр канәгатьсезлек тә туа. Эш шунда ки, автор татар халкының шундый аяныч язмышка дучар булачагын нигәдер эчке сәбәпләр белән генә аңлата. Ягъни, үзенең юкка чыгуына татар халкы фәкать үзе генә гаепле. Ул үзен начар тоткан, халык буларак, үзен-үзе кайгыртмаган, талантлы, эшлекле, уңган халыкларның берсе булуына карамастан, үзенең элекке дәрәҗәсен сакламаган булып чыга. Г. Исхакый болай бер яклы караштa торса, ул гайре табигый бер хәл саналыр иде. Чөнки татар халкының гасырлар буена колониаль изү астында газапланып яшәве, миссионерларның халыкны көчләп чукындырулары, татарга балаларын үз телендә укытырга мөмкинлек бирмичә мәктәп-мәдрәсәләрен яндырулары һ. б. шундый кимсетү-җәберләүләр хакында әсәрдә бер сүз дә әйтелми. Бу хәл бик гаҗәпләндерә. Чөнки милли изүне ничек авыр кичерүен без аның күп санлы башка әсәрләрендә бик ачык күрәбез («Зөләйха» пьесасы һ. б.) Шулай булгач, сәбәп нәрсәдә? Рус хөкүмәтенең бу сәясәте нигә бөтенләй телгә дә алынмады икән? Г. Исхакый әсәрләрен дөньяга чыгаруга ифрат күп көч салган профессорыбыз И. Нуруллин аңлатуынча, моның сере әсәрдәге күп нокталар эченә яшеренгән. Ягъни татар халкын җәберләү хакында Г. Исхакый бу әсәрендә, һичшиксез, язган булырга тиешле. Әмма цензор аларның һәммәсен дә сызып ташлаган. Минемчә, бу фикер белән килешмичә мөмкин түгел.

«Инкыйраз» — гыйбрәтле әсәр. Халкыбызның моннан йөз ел элек булып узган тормышына нигезләнеп язылу сәбәпле, билгеле, аның байтак мисаллары безнең заман өчен искергән. Әмма әсәрнең гомуми фикер сөрелеше хәзер дә кыйммәтен җуймаган. Автор татар халкының наданлыгына, башка халыклардан артка калуына чын күңелдән рәнҗеп яза, үзенең «төп чыганагы» булган дин әһелләре мохитының кимчелекләрен гаделлек белән усал тәнкыйтьли, татар халкын аңлы, мәдәни тормышка, кешелек җәмгыятенең алдынгы өлеше ирешкән прогресска өнди. Г. Исхакый, мәсәлән, яшьләрне бөтен милләт мәнфәгатен алга сөрердәй зур эшләргә керешмичә, «кәкре-бөкре черек фикерләрне үзләренең юл күрсәткече итеп санап», вак-төяк эгоистик гамәлләр белән мавыгуда гаепли, аны хәр күңелле булырга, милләтне кай-

гыртырга, бердәм булырга чакыра, мещанлык, ваклык, эгоистлык инкыйразга илтә, ди ул.

Әйе, дөрес әйтә әдип. Аның күзе үткен, зиһене житез, гакылы камил булган. Халыкның тормышын бик тирәнтен белеп, аның киләчәген алдан әйтеп бирергә сәләте җиткән. Моны халкыбызның соңгы бер гасырда башыннан узган вакыйгалар да раслый.

«Язмыштан узмыш юк» дигән тәгъбир дә яшәп килә бит әле. Күрәсең, безнең халык борынгыдан ук шундый авыр сынаулар узарга тиеш булгандыр. Инкыйраз куркынычы безгә күптән үк яный башлаган. Ул безне Батухан белән ушкуйниклар Бөек Болгар дәүләтен харап иткәннән бирле өзлексез сагалап килгән. Халкын һәм җанын, иманын саткан Шаһгали аны тагын да көчәйтеп җибәргән. Бөек әдип бу әсәрен язганнан соң узган бу чуалчык йөз ел эчендә инкыйраз галәмәтләре исә тагын да тармакланып, көчәеп китте. Инкыйраз вирусы, хаким даирәләр тырышлыгы белән, безнең генә түгел, барлык кечерәк милләтләрнең яшәү мохитына, сулый торган һавасына кереп тулды. Бу афәт хәзер, йогышлы авыру кебек, тормышыбызга һава белән дә, су белән дә тәэсир итә, татлы сүз булып күңелләргә керә, мәхәббәт булып куеннарга сыена.

Күпләргә мәгълүм инде, безнең халыкның булмаган җире сирәктер. Туган-үскән җирендә аңа тамагын туйдырырлык шартлар юклыктан, ул бәхет эзләп кайларга гына китеп бармаган? Туган илен, гаиләсен, сөйгән ярын сагынып нинди генә үзәк өзгеч моңлы җырлар чыгармаган... Нихәл итмәк кирәк, язмыш! Ул тешен кысып булса да түзә. Татар кешесе дөнья океанында балык тота, тайгада урман кисә, тундрада болан үрчетә, Төмән якларында нефть чыгара, Урта Азиядә мамык үстерә. Ул — Төрекмәнстан чүлләрендә дә, Сахалин белән Карелиядә дә үз кеше. Америка белән Европаны әйткән дә юк, татар кешесен хәтта иң ерак Австралиядә дә очратырга мөмкин. Әмма кая гына барып чыкмасын, татар халкының вәкилләре читенсенеп, ятсынып маташмый, теләсә кайсы халык белән тиз үк уртак тел таба, барып урнашкан якларын үз итә, яратып, якын итеп, хәтта чит өлкәләргә, шәһәрләргә багышлап җырлар да чыгара. Андый чакта татар кешесе — үзе шагыйрь, үзе композитор, үзе үк җырчы да. «Уфа-Чиләбе» дип җырлап җибәрә ул, «Байкал күл» белән «Шахта»ны да, «Эрбет»не дә искә ала. Ул да түгел, аның Оренбург, Мәскәү, Бохарага багышланган җырын, Ашхабадны искә алган моң-зарын ишетәсең. Татар кешесен, рухының асыл сыйфаты җәһәтеннән, чын мәгънәсендә интернационалист дип атарга мөмкин.

Әмма татарның күзгә бәрелеп торган, үзенең милләт булып тәмам ныгып житүенә зур зыян китерә торган бер кимчелеге дә бар. Ул шулай чамадан тыш интернационалист булып китә дә үзе хакында онытып җибәрә, үз халкының мәнфәгатен бик үк тырышып кайгыртмый. Кыскасы, аңа башка халыкларда ярыйсы ук көчле булган милли горурлык хисе җитми, үз кадерен, үз дәрәҗәсен үзе белеп, үзен мәгърур тоту җитми! Бик аяныч хәл, әмма дөресе шул! Башка халыкларга мөнәсәбәтендә исә ул беркатлы самими, эчкерсез, кинә сакламый, кулыннан килгәнне кызганмый, кирәк икән, машина йөртә, кием тегә, кирәк икән, балалар укыта, нефть чыгара...

Менә шулай башкаларга ярдәм итеп оясыз коштай читтә каңгырап йөри торгач, ватандашыбыз сабантуена кайтып төшсә, ни күзе белән күрсен, аның туган ягына миллионнан арттырып башка тел халыкларын китереп тутырганнар, аның ата-бабасыннан калган кара туфраклы бодай җирләрен, бер шагыйрь әйтмешли, чикылдап, үкереп торган шау-шулы тимерчелек баскан. Читтән кайтучының туганнары:

— Мәскәү түрәләренә шулай кирәк булган,— диделәр.

Читтән кайтучы моңа бик гаҗәпләнеп башын чайкады.

— Карасана, туган җиребездә дә эшче кул бик кирәк икән ләбаса! Ә без эш эзләп читтә каңгырап йөрибез! Нигә безне чакырып кайтармадылар икән?

Хәзер инде аның туганнары гаҗәпләнде:

— Бигрәк тә беркатлы инде син, шуны да шәйләмисеңмени? Мәскәү түрәләренең планы бит бөтенләй башкача!

Аның соравы җавапсыз калды. Чөнки Идел белән Чулман буенда яшәүче татарның киләчәге ничек булып бетәргә тиешлеген Мәскәү түрәләре үзләре генә беләләр...

Шул рәвешчә, татар халкын инкыйраз упкынына сөйрәүче сәбәпләр, берсе өстенә икенчесе өстәлеп, гел арта гына бара. Менә аның тагын бер төре: «Мәктәптә, бигрәк тә рус мәктәбендә укучы татар балаларының күбесе

башлангыч классларда «СССР тарихы» буенча Казан ханлыгының Мәскәү дәүләтенә «кушылу» чорын үткән көннәрдә өйләренә кайгырып, үзгәреп кайталар. Кайталар да «Я не хочу быть татарином (татаркой)...» дип үкси-үкси елыйлар. Сәбәбе — «СССР тарихы» дәресләрендә татарларны кеше үтерүче, талаучы, басып алучы вәхши, явыз халык итеп күрсәтү. Үзен татар дип санаган балага моннан да зур хурлык була аламы икән?» (Ә. Кәримуллин. Хак вә нахак. «Шәһри Казан» газетасы. 17 август, 1990 ел.).

Әле ул гынамы? Русларны шулай әшәке итеп, ата-аналарын кушып сүгенергә кем өйрәткән дип уйлыйсыз? Шул «басурман» татар барында, тагын кем булсын инде? Татар өйрәткән!.. Иң әшәке женси авыруны сез әле Европа якларыннан килеп кергән дип уйлыйсыздыр? Юк шул! Аны да русларга каяндыр табып татарлар йоктырган имеш... (Ә. Кәримуллинның шул ук мәкаләсеннән.). Сез әле китапларда, крепостное правоны да рус патшалары керткән, дип укыгансыз. Хәзер менә, плюрализм заманында, аны да татарларга сылтый башладылар. Ул хурлыклы законны кертүгә дә бөтән беркем дә түгел, шул ук сөйкемсез татарлар гаепле икән ләбаса! Ышанмыйсызмы? Буш хәбәр дисезме? Әнә, «Огонек»ның 1989 елгы 3 нче санында Э. Рязанов мәкаләсен укыгыз!..

Инде шушы хакта бераз фикер йөртеп карыйк. Һәркемгә мәгълүм, тарихи вакыйгаларның берсе икенчесенә үрелеп баруы, борын заманда халыкларның бер урыннан икенчесенә күченүе нәтиҗәсендә, безнең болгар бабаларыбыз тора-бара руслар белән чиктәш булып чыкканнар. Аларның озак еллар тату яшәгән чаклары да аз булмаган. Хәтта, «судагы таш өскә калыкканчы, колмак суга батканчы» дуслыкта яшәргә вәгъдәләр куешып, килешүләр дә төзешкәннәр. Шулай да төрле чак булган, ара-тирә сугышкалап та алганнар. Әле берсе җиңгән, әле икенчесе. Әмма ахыр чиктә руслар Казан ханлыгын тәмам тар-мар итеп үзенә буйсындырган. Шул еллардан бирле татар халкы, кара язмышына буйсынып, элекке дәгъваларны яңадан кузгатмаска, күршеләре белән тату яшәргә, матбугатта булсын, телдән булсын, башка халыкларга тел-теш тидермәскә тырышты. Чөнки безнең халыкның әхлак кагыйдәләрендә, күрше хакы — тәңре хакы, диелә. Шуның өстенә, татар халкы гаделлекне ихтирам итә. Менә бу ике кагыйдә күрше халыклар белән мөнәсәбәттә гомер буена төп шарт булып килде. 438 ел буена Россия империясе итеге астында изелеп яшәү никадәр генә кыен булмасын, без түздек, бу гаделсезлектә рус халкын гаепләмәдек, хәтта зарланмадык та. Чөнки бик яхшы беләбез: рус патшалары, аларның миссионерлары һәм күп санлы түрәләре кылган явызлык өчен бөтен рус халкы гаепле түгел. Шул сәбәпле татарлар, кайда гына яшәмәсеннәр, һәр җирдә рус халкын ихтирам итеп килделәр. Әле хәзер дә шулай. Шундый ук ихтирамны без башкалардан да көтәргә хаклыбыз!

Әмма белеп торабыз, башка халыклардагы кебек, русларның да төрлесе бар. Рус руханиларының кайберләре, язучылары, журналистлары, бүтәннәре әледән-әле татар халкын хурлап телгә алалар икән, татарны халык буларак мыскыллыйлар икән, халык моңа чын күңелдән рәнҗи, ул моны яхшы мөнәсәбәткә яманлык белән кайтару дип карый. Хәзерге мәдәни халыклар арасында андый сүгенү, мыскыллауны гафу итү мөмкин түгел. Чөнки бу — халыкларга шул ук империя тәхетеннән торып җикерену, башка халыкларга карата шул ук элекке азу ярган кара груһлар сәясәтен дәвам иттерү дигән сүз! Империя рухы аларның, күрәсең, каннарына сеңгән.

Без хәзер тарихи вакыйгалар алдында торабыз: татар халкының киләчәк язмышы хәл ителергә тиешле. Инде мөстәкыйльлек турында Декларация кабул ителгәннән соң да Россия империясенең колониясе булып, телсез-авызсыз кол булып калабызмы, әллә һәртөрле аумакайларны, милли йөзен югалткан нигилистларны, шовинист-монархистларны җиңәргә көчебез җитеп, халыкның чын суверенлыгына юл салабызмы? Икенең берсе. Сайлану алдыннан халыкка алтын таулар вәгъдә иткән депутатлар, халыкның киләчәге өчен кискен көрәш барганда, кайсы якка басар? Әгәр дә алар халык мәнфәгатенә хыянәт итеп, Татарстанның мөстәкыйльлегенә каршылар икән, бу — таралырга торган империяне һаман да яшәтергә тырышу булып чыгачак.

Г. Исхакый, талантлы әдип, тирән акыллы фикер иясе буларак, халыкның киләчәген алдан ук күрә белгән, шундый язмышның ихтимал булуын аңыбызга сеңдерергә теләп, моннан тугыз дистә еллар элек үк искәртеп куйган. Без исә, бу дәһшәтле фалны искә алмаска никадәр тырышсак та, һич тә булдыра алмыйбыз. Чөнки инкыйраз — империя шартларында буылып яшәүче аз санлы халыкларның даими афәте. Ул шомлы гыйбарә, Сак-

Сок бәетендәге кара каргыш сыман котылгысыз язмыш булып, әледән-әле каршыбызга килеп баса. Ул әле төрле түрәләр кыяфәтенә кереп татар мәктәпләрен ябып йөри. Ул үз ана теленнән күптән үк ваз кичеп: «Балама чит телләр өйрәтсәм, ул туп-туры бөтендөнья цивилизациясенә менеп басачак!» — дип, алданып яши.

Инкыйраз һәрдаим арабызда бутала. Ул ярым-йорты белеме белән үзен белдеклегә санап, үз ана телен санга сукмыйча, татар авылларында ватып-җимереп русча докладлар сөйли, пивнушкаларда халкының гайбәтен сата. Ул башына кереп утырган туң фикердән бүтән берни дә аңларга теләмичә, үзен замана культурасын үзләштергән прогрессив кешесе санап, татар гимназиясе ачуга каршы чыга, бала атасы булып: «Нәрсәгә ярый ул татар теле?!» — дип, төкрек чәчә.

Инкыйраз — безнең иң зур бәлабез, яшәү-яшәмәү мәсьәләсе. Без аңа битараф караштa була алмыйбыз.

## V

Без хәзер ифрат та чуалчык заманада яшибез. Иҗтимагый тормыш системасы да, хуҗалык итү ысуллары да, фикерләр дә — һәммәсе дә тәмам чуалган чак. Халыкларның үзара мөнәсәбәте дә бик үк әдәплелəрдән түгел. Әле теге тарафта, әле бу тарафта аңлашылмаучылыклар, хәтта җанҗаллар да кабынып киткәли. Менә ничә ел инде шушы буталчыкны тудыруда гаепләрне эзләү, табарга тырышу, үкендерү, үкенү, яңа кыйбла эзләү белән шөгыльләнәбез. Алдыбызда һаман да шул бер үк сөаль: кайчан, ничек, ни сәбәпле, ялгыштык соң без?! Бу сөальгә берәүнең дә күңелне тынычландырырлык җавап биргәне юк әле. Шунлыктан ул сөальне бәлки икенче ягы белән әйләндереп кую мәгъкульдер: кайчан да булса ялгышмаган вакытыбыз, озак еллар буенча туп-туры бер изге максатка омтылган чагыбыз булдымы икән соң безнең?..

Бу сөальгә дөрес һәм аңлаешлы җавап табу өчен иң әүвәл кайсы, ниндирәк илдә яшәвеңне искә төшерергә кирәк. Россия исә бик борынгы заманнардан үк ифрат та үзенчәлекле бер тараф, һич тә истә-оста булмаган, тарихта күренмәгән, искитмәле, гадәттән тыш, шаккаттыргыч вакыйгалар иле булып дан алган. Безнең татар бу ·хадисәне (күренешне) бер сүз белән генә аңлатып бирә: «Дөньяда юкны пешер хатын!»

Менә шул «дөньяда юкны» булдырырга тырышулар нәкъ безнең буынның яшь чагына туры килде. Нилар генә кичермәде безнең газиз башлар?! Кыска гына вакыт эчендә без җилкәбездә ничә төрле иҗтимагый формацияләр күтәрмәдек! Безнең бала чагыбызда Россиядә яңа гына капитализм борынлап килә иде. Бөек революция аны берничә атна эчендә зир-зөбәр китереп аударып ташлады. Истә-оста югында без хәрби коммунизмга килеп кердек. Алай булмый икән дидек тә НЭПка күчтек. Ләкин Сталин-Джугашвили аны ошатмады, ул капитализм ише «искелек калдыгы»на сәлам дә бирмичә, туп-туры социализмның үзенә үк алып китте. Без — Россиянең урыс агае да, дала кешесе калмык та, татарлар, үзбәкләр, әрмәннәр, бүтәннәр дә — һәммәбез бергә укмаштык та шул якка ыргылдык. Без башка юлларны күрә алмадык. Чөнки барасы юлыбызга тезелеп киткән прожекторлар яктылыгыннан күзләребез камаша иде...

Хәзер инде өлкән буынның башыннан узган шушы тарихи гамәлләрне кирегә сүтеп маташалар, «алай кирәк түгел иде, болай кирәк иде» димәкче булалар. Арада бөек революция казанышларын бөтенләй юкка чыгарып, Татарстанны Казан өлкәсе итәргә омтылучылар да бар. Имештер, революциянең кирәге шуның тикле генә иде, гражданнар сугышы тикмәгә кан кою гына булган...

Менә монысы элекке империяне, як-яктан терәтеп булса да, һаман да яшәтергә омтылучы чеп-чи кара груһ монархистлар коткысы! Безнең буын нәкъ әнә шуларга каршы сугышты да инде. Мин ул тарихи көрәшләргә катнашуым белән чын күңелдән горурланам. Чөнки «алай итмичә, болай булмый ул»! Әгәр дә татар халкы шул елларда үзенә хөррият яулап алмаган булса, ул чагында Сөембикә манарасын әле хәзер дә патшаның ике башлы кара кошы басып яткырыр, хәзерге Муса Җәлил һәйкәле урынында, элеккечә албасты сыман бөтен шәһәрне басып, үзенең симез чуен аты өстендә Александр Икенче патша утырган булыр иде. Башка якларын күз алдына

китерү дә куркыныч. Ул чагында хәзерге кебек Татарстанга мөстәкыйльлек алу өчен көрәшүче халык уллары — депутатлар кайсы казематта, кайсы каторгада газап чиккән булып, «Бакыр бабай» бакчасының капкасы өстенә «татарларга керергә рөхсәт ителми!» дип язылган булыр иде.

Юк инде, элекке империя, нинди генә ягымлы кыяфәткә кермәсен, аңа кире кайту юлы киселде. Егерменче гасыр фаҗигаларын кичерү чамадан тыш кыйммәткә төшсә дә, без рухыбызны сүндермәдек, милләт буларак сакланып калдык, хәтта тагын да ныгый төштек. Хәзерге халык, империя каршысында бил бөгеп бүрек салырга әзерләнеп тормый.

Шулай да ул вакыйгалар узылган чор инде, мине исә бүгенге көн борчый, татар гимназиясенә баласын укырга бирүгә каршы торучы уйландыра. Чөнки ул — минемчә, заманыбызның иң хәвефле, инкыйразга алып баручы иң сагайта торган күренеше.

Хәер, элек тә булгалады бит андый хәлләр, дөрес, бүтән рәвештәрәк, әмма аслы шул ук иде.

Мин яшьрәк вакытта бер елны Мәскәү газеталарында бик тә сәер игъланнар басыла башлады. «Мин, Хәйретдин Минһаҗев, исем фамилиямне Харитон Михайловка алмаштырам...» Яисә «Мин, Исхак Нигъмәтуллин, моннан соң үземә Исак Незнамов исем, фамилиясе алам...» — дип язылган була иде аларда.

Бу минем башыма һич сыймый иде: ничек була инде бу? Ярый, кәләпүшне — картузга, бишмәтне зипунга алыштырган сыман, иманны ансат кына башкага алыштырдың, ди. Монда бит дин турында гына сүз бармый! Кәгазьгә язып куйганга карап кына Хәйретдин Харитонга әверелә алмый! Юк, «чын Харитон» булу өчен гасырлар кирәк! Ә җаныңны, бала чактан ук күңелең түренә кереп утырган газиз телеңне, гореф-гадәтне, халык моңнарын кая куясың?

Ни газизрәк — бу ватанмы?
Аһ, туган каумең газиз!
Ул мөкаддәс кан белән ул
Изге сөткә ни җитәр?
Сөт калыр, ватан китәр,
Сөт калыр, ватан китәр.

*(Дәрдемәнд)*

Шуның өстенә, ни генә булып кала ул күчкән кеше бүтән мохиттә? Арбаның бишенче тәгәрмәче яисә агымга кушылып китә алмыйча, чоңгыл өстендә әйләнүче йомычка булып...

Шулай да игълан бирү юлы белән күчүчеләр алай хәвеф тудырырлык күп түгел иде. Сталинчыларга мондый «сүлпән темп» ошамый башлады. Алар монда да Рәсәйгә хас «гигант колач» белән эш итеп татар балаларын «оптом иләйһи» — барысын берьюлы рус теленә күчерергә керештеләр. Моны гамәлгә ашыру һич тә кыен булмады. Ильминскийлар да кирәк булып чыкмады. Чөнки бу вакытта инде халык, төрле матди һәм рухи газаплар, тетрәнүләр кичерү нәтиҗәсендә, тәмам аңгырайтылган, кара язмышына буйсынып, бөтенесенә кул селтәгән иде.

Рус мәктәбен тәмамлап чыгучыларны: «Аһ, бичаракайлар! Үз телләреннән, моңнарыннан, халыкның гореф-гадәтеннән мәхрүм булып ничек яшәмәк кирәк?!» — дип, кызгануның кирәге калмады. Чөнки аларның күбесе туган тел, милли хис, гореф-гадәт кебек «вак-төяк» милли чирдән тәмам «арынып», менә дигән «интернационалистлар» булып чыкканнар иде. Аларны үз чорының тәрбиячеләре, нәкъ үз чорына хас рухи азык белән коралландырды. Югарырак баскычта торган культура җимеше булуын бик яхшы аңлап, аларның күбесе инде үзеннән түбәнрәкләргә өстән генә карый, синең телеңдә дә, милләтеңдә дә аның әллә ни эше юк, баласына да «икенче сорт» тел өйрәтү ягында түгел. Хәзер ата-анасы кушкан исеме аңа бик примитив булып тоела, «культурныйрак» кешеләрнең аңа фәлән-фәләнич дип дәшүләре дәрәҗәсенә лаеграк булып ишетелә. Мондый тәрбия алучылар хәзер йөз генә, мең генә түгел, алар күбәү. Байтагысының урыны — түрдә. Ул министр да, депутат та, башка шундый җаваплы урында да эшләргә мөмкин. Бу — татар зыялыларының бүтәнчә тәрбия алган яңа катлавы. Тукай заманындагы зыялылар, кәсебе нинди булуга карамастан — табибмы ул, землемермы, әдип яки журналистмы — нигездә һәммәсе дә диярлек халык мәнфәгате

идеяләре белән рухланып яшәгән. Сталинның милли сәясәтенә нигезләнгән тәрбия ысулы исә милли интеллигенцияне туган теленнән, милли җирлектән аеруга көйләнгән иде. Шунлыктан бу катлауның милли мәсьәләне бөтенләй башкача аңлавы һич тә гаҗәп түгел. Татарстанга мөстәкыйльлек алу өчен барган көрәшләрдә ул үзен шактый сиздерде.

Зыялыларның бу катлавының байтагысы ана телен белү-белмәүгә битараф. Татарстан Югары Советының соңгы сессиясендә бер депутат: «Татарча белмәвемә мин гаепле түгел!» — диде. Билгеле, ул иптәш, үзенчә хаклы. Шулай да «Теләге булса, чарасы табылыр иде» яисә «теләк булса, беләк карышмый» дигән мәкальләр дә бар бит әле.

Әйе, бу мәсьәләдә ниндидер дәрәҗәдә азмы-күпме без һәммәбез дә гаепле. Менә берничә мисал. Алтмышынчы еллар уртасында Оренбург өлкәсендәге татар мәктәпләрен һәм Чаллыдагы М. Вахитов исемендәге мәктәпне, алдынгы күрсәткечләренең әгъла булуына карамастан, русчага күчерү һәммәбезне дә борчуга салды. Язучыларның, университет галимнәренең бу протестлары, хат рәвешенә кереп, депутат Мирсәй Әмир аша РСФСР Югары Советының президиумына барып ирешә. Без, беркатлы бәндәләр, гаделлекнең һичшиксез өстен чыгачагына инанып, куанычлы хәбәр көттек. Кая ул?! РСФСР Министрлар Советы рәисенең урынбасары В. Кочемасовның катгый җавабы безне тынсыз калдырды. Бу мәктәпләрнең русчага ата-аналар үтенүе буенча күчерелүен белдергән иде ул. Хәлбуки, ата-аналар нәкъ шуның киресен раслаганнар иде...

Җитмешенче елларда булса кирәк, мәгълүм драматург һәм режиссер Батулла Казанның Актерлар йортында гаҗәп күңелле, җанлы уза торган очрашу кичәләре оештыра башлады. Ул кичәләрдә укучы яшьләр әдәбият-сәнгать әһелләре белән очрашалар, шигырьләр укыла, җыр-бию, юмор-сатира гөрләп тора, кыскасы, ул кичәләрне без көтеп ала торган идек. Берзаман бу кичәләр кинәт сүнде, Актерлар йорты бик озакка тынып калды. Ни сәбәп, ни булган, тагын нинди зур «гөнаһ» тапканнар? Моны аңлатучы булмады, әчтән генә тындылар. Имеш-мимештән генә чамаладык: иң югарыда утырган «идеолог»ка бу кичәләрдә гел татарча гына сөйләшеп, татарча гына көлүләр ошамаган. Без бит — интернационалистлар!..

Бу гаделсезлеккә дә без чын күңелдән рәнҗедек, әлеге идеологның башына әчтән генә нәфрәтләр яудырдык, каргадык һәм... мескен бүрегебезне басып, тынып калдык. Чөнки ул елларда әле өстебездән «кара шәл» күтәрелмәгән, «озын теллелек» авыруы белән чирләгәннәрне кайбер шифаханәләрдә ничек «дәвалауларын» онытмаган идек әле.

Нихәл итмәк кирәк, кара сакалың кайда да үзеңнән калмый, диләр бит. Ни әйтсәң дә, без — иң реакцион деспотлык хөкем сөргән империянең иң каһәрләнгән колониясендә гасырлар буена кимсетелеп яшәгән халык ләбаса. Иманнан яздыру, телебезне, мәдәниятыбызны оныттыру өченниләр генә кылмадылар?! Безнең бөек милләткә буйсынырга тиешле «ким кеше» икәнлегебезне өзлексез колагыбызга тукып, әле урядник камчысы белән, әле нечкәләбрәк гасырлар буена каныбызга сеңдерергә тырыштылар. Сталин-Брежнев заманында шул ук сәясәт башка рәвешләргә керде. Шөкер, халыкның сәламәт акыл белән эш итүче көчле шәхесләре «милли мескенлек» чиренә беркайчан да бирелмәде, күңел хөрлегенә зыян китермәде. Шулай да бу «тырышлыкның» тәэсире нәтиҗәсез калмады.

Гыйбрәтле хәлләрне җитәрлек кичердек. Хәзер менә шулардан сабак алыр вакыт җитте. Моңарчы аңыбызга утырган коллык юшкыныннан, җаныбызга тигән җәберләнү хисеннән тәмам азат булып, күңелләрне бәйсезлек, хөрлек хисе белән сафландыру вакыты җитте. Мин ышанам: халыкны халык иткән изге гадәтләрне, кимү юлына баскан асыл сыйфатларны онытыла язган затлы һөнәрләрне яңадан аякка бастыру халкыбызның данын, күршеләре белән дус яшәүче киң күңелле халык, дигән яхшы исемен тагын да югарырак баскычка күтәрер!

Безнең буын гомеренең туксанынчы баскычыннан миңа әнә шундый гыйбрәтләр күренде.

*Сентябрь, 1990 ел.*

## Надир Дәүләт

# ГӘРЧӘ АНДА ТУМАСАМ ДА...

Казан университеты белән Г. Ибраһимов исемендәге Татар тел, әдәбият һәм тарих институты бергәләп уздырачак конференциягә чакыру килеп төшкәч, мин чын мәгънәсендә шатландым. Бу миңа ата-баба йорты, татар мәдәниятының мәркәзе белән танышу мөмкинлеген бирәчәк иде. Тамырларым тоташкан Идел буен моңарчы кайбер фотолардан, китаплардан, анда булып кайтучыларның сөйләгәннәреннән генә белә идем.

Мине үстергән этием Әхтәм Ильяс тумышы белән Актаныштан иде. Ул үзенең нинди матур авылда тууын, үскәч, казакъ далаларына барып, балалар укытуын, беренче бөтендөнья сугышында катнашуын, ул гарасаттан аллага ышануы гына коткаруын кат-кат сөйли иде. Аның сөйләгәннәре миңа әкият кебек тоелса да, ике-өч вакыйгасы бала рухымда аеруча зур тәэсир калдырды. Беренчесе — кызыллардан качып Байкал күлен кичкәндә, бозларның шартлап-шартлап ярылуы, йөзләгән-меңләгән коралдашының шунда батып юкка чыгуы этиемнең могҗиза белән генә котылуы иде. Шул ук фаҗигадан исән калган яшь шагыйрь Шаһвәли Келәүленең «Байкал буенда мылтык кулымда, кылыч билемдә» дигән шигыре дә исемдә. Үстергән этием мәрхүмнең авыр хатирәләреннән миңа янә нык тәэсир иткән икенче сәхифә — аның берничә иптәше белән кызыллар кулына эләгүе турындагысы иде. Тоткыннарны шыр-ялангач чишендерәләр һәм Себер салкынында сафка тезәләр дә йөгерергә кушалар, саф урыныннан кузгалгач, ата башлыйлар. Шулардан бары этием генә исән кала.

Бервакыт этиемнән: «Кардәшләреңә нигә хат язмадың, нигә алар белән бәйләнеш урнаштырмадың соң?» дип соравым хәтердә. Аның күзләреннән шундук мөлдер-мөлдер яшь тибеп чыкты. «Бер мәртәбә хат салган идем — абзый, син безгә бүтән язма! — җавабы гына килде», дигән иде. Боларны искә алуым тикмәгә түгел. Әгәр шушы изге кешенең тәрбиясенә эләкмәсәм, бәлки тарих һәм Идел буйлары белән кызыксынуым, аларга мәхәббәтем дә тумаган булыр иде. Мин аның Коръән укымыйча уздырган бер генә көнен дә хәтерләмим. Балачагымда, шул бер китапны укудан ничек бизми икән, дип уйлаган көннәрем дә исемдә. Ләкин соңрак шушы ислам диненә ышану гына безне саклап калуын аңладым. Әниемнең, аш пешергәндә дә, өйдәге бүтән эшләр белән шөгыльләнгәндә дә, гел татарча җырлавы, гарәфә көннәрдә иртән өйне җыештырып, аш-сулар әзерләве дә әлегә чаклы күз алдымда. Эти белән без бәйрәм намазыннан кайтканда, табын пәрәмәчләр, сумсалар, төрле-төрле бәлеш, чәк-чәкләр белән бизәлгән була иде. Бу ягы белән безнең гореф-гадәтләрнең төрекнекеннән аерымлыгын да сиздем. Төрек өйләрендә, гомумән, бәйрәм табыннары әзерләнми, килгән кунакка кофе яки чәй, конфет тәкъдим ителә.

Балалыктан яшүсмерлеккә адым атлаган көннәрдә безгә ерак Кызылъяр (Казагстан) шәһәреннән бер хат килеп төште, ул мине тудырган әнием Рокыя Дәүләткилдедән булып чыкты. Шуннан соң гына, миңа ике яшь тулганда, без яшәгән Мукден (Кытай) шәһәренә Совет гаскәре килеп керүе һәм мондагы «Идел-Урал төрек татарлары» оешмасының алдынгы әгъзаларын, җөмләдән, «Милли байрак» татар газитенең җаваплы хезмәткәрләре булган газиз эти-әниемне кулга алып, ун елга төрмәгә һәм биш елга сөргенгә хөкем итеп, Себергә алып китүләре мәгълүм булды. Йөкле әниемнең төрмәдә бер кыз бала, ягъни, сеңлем Фәридәне табуы, аның да эти-әнием белән Кызылъярда яшәве беленде. Болар яшүсмер күңеле җиңел генә кабул итә алмаслык хәбәрләр иде. Язмышның шулай борылуы өчен кем гаепле, кемгә рәнҗергә һәм нәфрәтләнергә? Нишләргә белмичә озак тинтерәп йөрүем әле дә хәтеремдә. Шул хаттан минем өчен сәер тоелган кайбер нәрсәләр дә ачыкланды. Беренчедән, мине Кытайда чакта Ильяс фамилиясендә йөреп, Төркиягә килгәч, «Дәүләт»кә әйләнүебез сәерсендерә иде. Моның серен соңрак Гайнижамал әнием аңлатты... Этием: «Минем бер кызым бар, тик ул кияүгә китәчәк, ә Надир — ир бала, үз фамилиясен яшәтсен», дигән. Гәрчә фамилиямнең «килде»се

---

*Надир ДӘҮЛӘТ (1944) — тарихчы галим, Төркиянең Мәрмәрә университеты профессоры, берничә китап авторы. Журналда беренче мәртәбә катнаша.*

төшеп калса да, «Дәүләт»не саклап кала алуым өчен яңа этием Әхтәмнең игелеген, фидакарьлеген үз нәселе исеменнән ваз кичеп, минем исемемне йөртергә риза булуын гомер буе онытасым юк.

Икенчедән исә, урта белемне алман (немец) мәктәбендә үзләштерүем гаҗәпләндерә иде. Гомумән, байлар укый торган шушы хосусый мәктәпкә мине ничек йөртәләр соң? Без — ярлы бер гаилә ич. Апам Рәшидә булышмаса, бәлки фатирга да түли алмас идек. Шунда Төркиядәге татарларның миһербанлылыгы, аларның үзара акча җыеп, мине укытуларын ачыкладым. Ләкин әлегә кадәр берсенең дә: «Без сине укытыр өчен фәлән хәтле акча бирдек», дип ялгыш та битәрләгәне юк. Бу хәл милләттәшләремнең сокланырлык матур сыйфатларга ия булуын раславы белән миндә гаять тирән тәэсирләр калдырды. Кыскасы, шушы кичерешләрдән соң мин берзаман үзем дә татар җәмгыяте эшенә катнашып киттем. Тукай исемендәге яшьләр түгәрәгендә «Тукай бюллетене», соңрак «Казан төрекләре җәмгыяте» эшчәнлегенә кушылып, милләттәшләрем белән «КАЗАН» журналын чыгаруга көчемне салдым. Әкренләп өлкән буын татар галимнәре Әкъдәс Нигъмәт Курат, Габдулла Баттал Таймас, Зәки Вәлиди Туган, Хәмит Зөбәер Кушай, Габделкадыйр Инан һәм Рәшит Рәхмәти Аратлар белән танышу хөрмәтенә дә ирештем. Шулардан Рәшит Рәхмәтинең этием Ибраһим Дәүләткилде белән заманында сабакташ булганлыгы да ачыкланды — алар Кызылъяр гимназиясендә бергә укыган, Кытайга да бергә килеп урнашканнар икән. Шуңадырмы, Р. Рәхмәти мине Истанбул университеты каршындагы «Ислам энциклопедиясе» нә эшкә урнаштырды. Шушы галимнәребезнең татарга багышланган хезмәтләрен укып, мин дә Истанбул университетының тарих бүлеген тәмамладым, шунда ук Русиядәге төрки халыкларның 1905 — 1917 еллардагы мәдәни һәм сәяси хәрәкәтләренә багышланган докторлык диссертациямне якладым. Гомумән алганда, төрки халыклар, хосусан, татар-башкортлар белән кызыксынуым бүгенгәчә дәвам итә. Ләкин туплаган белемем укыганнарым һәм ишеткәннәремнән генә хасил иде. Халыкара фәнни конференцияләрдә чыгыш ясаганнан соң, кайбер чит ил галимнәре миңа: «Сез СССРда ничә мәртәбә булдыгыз?» дип сорау биргәләде. Алар үзләре — америкал, алман, француз, инглиз һ. б. галимнәр СССРны, кимендә, берничә мәртәбә үз күзләре белән күреп кайтучылар. Мин исә, тамырларым шунда тоташса да, тарихи ватаныма аяк басмаган идем. Чит ил белгечләре өчен төрки халыклар бары тик тикшеренү объекты гына, күпчелеге аларның телен дә белми, мәгълүматларны урысча чыганаклардан җыялар, төркиләргә әллә ни мәхәббәтләре дә юк. Идел-Урал буйларына аларны кан да, хис-тойгылар да тартмый. Ә мин җаным-тәнем белән төрки халыклар язмышы белән кызыксынам, аларның катлаулы язмышлары күңелемдә төрле уйлар, хисләр хасыйл итә. Төрек шагыйре Әхмәт Кутсый Тәҗәр әйтмешли, «китмәсәм дә, бармасам да, күрмәсәм дә», ул ил — газиз ата-аналарымның ватаны. Менә шулай тилмереп дигәндәй ятканда, Казаннан рәсми чакыруның килеп төшүе миндә әллә нинди тойгылар давылын кузгатты. Баруын барырсың, ә кайта алырсыңмы? Хатыныңны, балаларыңны, дус-ишләреңне кабат күрә алырсыңмы, язмышың әти-әниеңнекенә охшамасмы? Әмма ахырда, тәвәккәлләп, тәкъдиремне аллага тапшырып, Совет илчелегенә виза сорап мөрәҗәгать иттем, очкыч билетына акчаны исә виза алганчы ук түләп куйдым. Виза бирмәсәләр, ул акчаны (зур гына сумма!) югалтырга туры киләчәк иде. Казанга АКШтагы профессор Рифат Тәби белән бармакчы булган идек. Көн саен диярлек телефон аша булачак сәяхәтебез турында — Казан белән бәйләныш урнаштыруның кыенлыгы, андагы дуслар белән хатлар, телеграммалар алмашуыбыз, яңа калыккан бүтән мәсьәләләр хакында сөйләшә идек. Инде бару өметебез өзелеп беткәндә генә, визаларыбыз килеп төште.

Нью-Йорк белән Мәскәү арасы очкыч белән тугыз сәгатьтә узыла. Унтугызынчы майның иртәсендә без, ниһаять, Мәскәүгә килеп төштек. Казанга кичен очарга тиешбез. Мәскәүдә таныш-белешләребез юк, көнне ничек уздырырга? Киңәш табыш иттек тә мәчеткә шалтыраттык. Равил хәзрәт: «Әле вакытыгыз җитәрлек, туп-туры мәчеткә килегез!» диде.

Такси ялларга булдык. Такси шоферы Шереметьево аэропортыннан шәһәргә илтү өчен бездән йөз доллар, ягъни, рәсми курс буенча 564 сум (базар бәясендә — 1700 тәңгә!) сорап шаккатырды. Туристларны шулай тунауларын ишеткән идек, ләкин нәфеснең дә чиге булырга тиеш ләбаса!..

Мәскәү мәчете бик матур урынга урнашкан икән. Түбәсендәге айлары еракта ук аның мөселман йорты булуын күрсәтә. Равил хәзрәт һәм башкалар безне мәчеттә бик яхшы каршы алды. Зур Мәскәүдә татар утраучыгына килеп әләккән төсле булдык. Тирә-юнебездә гел татар теле генә яңгырагач, үзебезне чын мәгънәдә илгә килгән сыман хис иттек. Икенде намазыннан соң безне бер хәзрәт өенә алып китте. Шул арада кызыклы бер очрашу да булып алды. Австралиядә яшәүче

иптәшем Рөстәм Садри да Мәскәүгә килеп, бер казакъ кардәшебездә кунаклап ята икән. Көтмәгәндә шуның белән күрешеп, күңел ачтык. Тугыз сәгать очып килү арыткан, монда төнебез көнгә әйләнгәнлектән, аңгы-миңге булсак та, һәммә нәрсәне күрергә, һәркем белән очрашырга тырыштык. Ул арада Казанга очар вакыт та килеп җитте.

Ниһаять, Казанга кузгалдык! Арыганлыктан күзебез йомыла, әмма Татарстан башкаласына якынлашуыбыз турында урысча игълан бик тиз йокыбызны качырды. Белдерүне татарча әйтүләрен көтүебез акланмады. Европа мәмләкәтләреннән Төркиягә очканда, очкыч ширкәтләре төрекнеке булмаса да, гадәттә, төрекчә белдерү, аңлатмалар бирә. Инде монда Казанга очучыларның күпчелеге татарлар булырга тиештер, аларга үз телләрендә эндәшү кирәктер, дип уйлаган идек...

Очкыч Казан аэропортына килеп кунгач, тагын бер гаҗәп хәлгә очрадык. Салоннан башта өч пилот, аннары стюардессалар чыгып китте. Акча түләп килгән кунакларны иң соңгы нәүбәткә калдырдылар! Ил генә түгел, гореф-гадәтләр дә бүтән икән ләбаса СССРда!

Казанда безне профессор Зәкиев, Абдуллин, Кәримуллин һәм башкалар каршылады. Алар арасында чәчәк бәйләме тоткан, әлегә кадәр фотосы буенча гына таныш сеңлем Фәридә дә бар иде. Бер үк ата-ананың балалары әнә шулай кырык дүрт елдан соң гына очраштык. Асылда ике ят кеше кебек күренсәк тә, арабызда ниндидер хис-тойгылар җепе бар иде, тел уртаклыгы булмаса да, хис уртаклыгының җимешләре күзләремнән яшь булып бәреп чыкты. Фәриданең туган телне үзара аңлаша алырлык дәрәҗәдә белмәве өчен әти-әниебезнең төрмәләрдә һәм сөргендә тотылуы, сеңлемнең исә балалар йортында ятлар карамагында тәрбияләнүе сәбәп идеме — әйтүе кыен. Аның — татарча, минем урысча бик чамалы белүем арадашчысыз гына аңлашырга мөмкинлек бирмәде. Серләшәсе нәрсәләребез күп булса да, һәммәсе эчебездә йомылып калды. Кату кебек, таш кебек! «Ат кешнәшеп, адәм сөйләшеп аңлаша», диләр. Егерме мең чакрымны узып килдем, әмма сеңлем белән сөйләшер өчен тел киртәсен җиңә алмадым. Татар теленең вазифасы чикләнгәнлектән, сеңлем мәдәни мәркәзебездә укыса һәм ничә еллар шунда яшәсә дә, татарча өйрәнә алмаган. Бу инде Казаным урамнарында туган телемне ишетермен, кибетләрдә кеше ярдәменнән тыш кына татарча алыш-биреш ясармын, урамда юл сорармын, дигән өметләремне өреп очырды.

Казанда беренче төнне бик әз йокладым. Вакыт аермасыннан тыш башка сәбәпләре дә бар иде моның. Казанга килеп төшү безнең өчен хаҗга бару, изге туфракларга аяк басу, аның изге һавасын сулау белән бер дәрәҗәдә. Шул хәтле дулкынланган идек ки, теләсәк тә, күзебез йомылмады.

Иртән без Г. Ибраһимов исемендәге институтка киттек. Анда «Идел буе татарлары» исемле хезмәтнең (бу — татарлар турында инглиз телендә дөнья күргән беренче тарихи тикшеренү) авторы Азадә-Гайшә ханым Рорлих белән дә очрашырга тиешбез икән. Аның белән күптәнге дуслар булсак та, берничә ел күрешкәнебез юк иде. Очрашуыбыз ифрат күңелле булды. Шуннан, бергәләп, Сөембикә манарасын тамаша кылырга алып киттеләр.

Мәшһүр манараның ава башлаганлыгы, хәзер аны төзәтү дәвам иткәнлеге мәгълүм булды. Такта корылмалар белән чорнап алынган, ком-таш, чүп-чар өеме арасында калган Сөембикә күршесендәге алтын гөмбәзле төзек чиркәү янында, халкының язмышына ишарәләгәндәй, башын аска игән, ялгызлыктан һәм мескенлектән моңаеп торгандай тоелды.

Сөембикә манарасы янындагы бинада (анда Татарстан җөмһүрияте рәисе утыра икән) ике истәлек тактасы дикъкатемне җәлеп итте. Аларның беренчесе — урысча, икенчесе — татарча-урысча иде. Соңгысы түбәндәгечә язылган иде: «1917 елның 26 октябрендә (8 ноябрьдә) монда предприятиеләрдәге һәм гаскәри частьлардагы Кызыл Гвардия отрядлары вәкилләренең большевиклар җитәкчелегендәге берләштерелгән утырышы Казанда Совет власте игълан итте. «Минемчә, мондагы сүзләрнең өчтән берсен рәхәтләнеп татарчага тәрҗемә итеп булыр иде!

Шуннан соң татар халкының аеруча әһәмиятле истәлекле урыны — зиратка юнәлдек. Аның капкасына: «Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел!» дип язылган. Безне үткән белән бәйләгән кадерле кабер ташлары арасында йөреп, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г. Тукай, мөфтиебез Г. Баруди, Милләт Мәҗлесебез рәисе С. Максудыйның абыйсы Ә. Максудый һәм тарихыбызның байтак кына бүтән шанлы шәхесләре белән исәнләшеп, аларның рухына бер дога укый алмаганым өчен бәхиллек үтенгән сыман булдым. Исәннәрнең кадерен беләбезме — моны әйтүе кыен, ләкин татар зиратында үлгәннәребезгә хөрмәт күрсәтелгәнлеген күреп шатландым.

Инде шуннан Мәрҗани хәзрәт мәчетенә таба юнәлдек, үткәнебезгә сәяхәтне

дәвам иттек. Юл уңаенда архитектурасы ягыннан иң матур Әҗем мәчетен карарга туктадык. Намаз вакыты булу сәбәпле, имам белән күрешергә насыйп булмады. Тик мәчетнең озак еллар тулай торак рәвешендә файдаланылуы, хәзер инде аны төзекләндерү эшләре алып барылуы аңлашылды. Манараларны торгызу, борынгы мәчетләребезне яңадан ачу буенча кайбер тырышлыкларны күрү безне байтак шатландырды. Ләкин шушы мәчетләрне озак вакыт бүтән максатларга хезмәт кылдыру, хәзер исә тәзәтү чыгымнарын мәхәллә җилкәсенә генә йөкләү бик сәер.

Мәрҗани мәчетендә безне җанлы тарих каршы алды. Туксан ике яшьлек хәзрәтнең күңелдә әллә нинди дулкынландыргыч моңлы хисләр уяткан тирән мәгънәле сүзләре әле дә колакларымда яңгырый: «Без — җир йөзендә кардәшләр. Аллаһы тәгалә: мөэминнәр, ходайга ышанучылар, сез бөтенегез дә үзара кардәш, кардәшләрегезнең арасын төзек, пакь кылыгыз, дип боерган. Без — дөньяда бертуганнар шикелле яшәргә тиешбез. Аллаһы тәгалә моны һәммәбезгә насыйп итсен иде»... Шушы яхшы өндәүгә, теләккә кушылмый мөмкин түгел. Шартлар хасыйл иткәндә, кешеләрнең кардәшләрчә яшәве өчен бертөрле дә киртә була алмый. Чөнки бер халык та тынычсызлык, яман ыгы-зыгы теләми. Изгелеккә омтылганда күмәкләшеп тирә-юньне сәламәт саклау, белемне арттыру мәсьәләләрен тизрәк һәм уңышлырак чишәргә мөмкин.

Казандагы беренче көнебез театр тамашасы карау белән тәмамланды. Дин әһелләребез тормышын бозып күрсәтә торган «Зәңгәр шәл» спектакле иде ул. «Темасы ягыннан искереп беткән, сәнгатьчәлек ягыннан да әллә ни казаныш санала алмаган бу пьесаны нигә бүген дә сәхнәләштерәсез?» дигән сорауга «халык ярата» дигән дәлил китерделәр. Милли башкалабызда уздырган беренче көнемнең эч пошырган сәхифәсе ярый әле шул гына булды.

Иртәгәсен безне шактый ук тыгыз төзелгән программа көткән икән. Башта Казан университеты китапханәсендә татарча кульязмаларның язмышы белән танышттык. Тарихыбыз, мәдәниятыбызның язма һәйкәлләрен монда тик бер кешенең генә тырышып өйрәнүе һәм саклавы гаҗәп. Бөтен гомерен шушы эшкә багышлаган А. Фәтхигә ихлас рәхмәтемне белдерәм. Ул кайгыртмаса, бәлкем анда бүгенге көндә сакланган кадәре кульязмалар да булмас иде.

Моннан соң без Г. Ибраһимов исемендәге институт хезмәткәрләре белән очраштык. Коллегаларыбыз белән танышу киләчәктә хезмәттәшлек итү өчен дә кирәк иде. Институт директоры М. Зәкиев безне зур залга җыйналган галимнәргә тәкъдим иткәч, хуҗалардан бигрәк безгә күп сөйләргә туры килде.

Хуҗалар чит илләрдәге татарларны, без исә илдәгеләрне күрергә, белергә сусаган идек. Ике якның да бер-берсе белән кызыксынуы табигый. Чөнки һәр ике як та бер-берләре әйткәннәрне, язганнарны я ишетмәгәннәр, я укымаганнар. Укыганнар исә бер-берсенең язганнарына ышанмаган, ышанырга теләмәгәннәр иде. Шулай итеп бер-берләреннән ераклашканнар, үзара ят булганнар иде. Инде соңгы берничә елда һәр ике як та бер-берсен танырга тырыша башлады. Ләкин шулай да җитмеш ел буе җимерелгән күперләрне яңадан салу, уртак телдә сөйли башлау өчен мәгълүм вакыт һәм ике якның да түземлек күрсәтүе кирәк булачак. Чит-ят планеталарда яшәүчеләр очрашканда бер-берләренә ни хәтле шикләнеп караса, төрле сәбәпләр аркасында үзара аерылган бер үк халыкның балалары да шундыйрак халәт кичерүе табигый. Әле яңа гына беренче адымнар атланды, яхшы ният белән хәрәкәт иткәндә һәм тиешле сабырлык күрсәткәндә, алар безне, һичшиксез, уртак максатка илтер. Институттагы очрашу шушы юлда бер адым атлануын раслады.

Институттагы очрашудан соң без тагын бер кызыклы мәҗлескә эләктек. Татар иҗтимагый үзәге (ТИҮ) идарәсе атна саен уздыра торган утырышларның берсе иде ул.

Көнбатышта менә инде ничә ел СССРдагы демократик үзгәрешләр, рәсми сәясәттән тыш та фикерләр әйтелә торган хәрәкәтләр пәйда булуын хәбәр итә башладылар. ТИҮ идарәсе утырышы шул хәбәрләрне расларлык, әллә моның күз буяу уены гына икәнлеген фаш итәрме — шуны үз күзебез белән күрү, үз колагыбыз белән ишетү форсаты чыкты.

ТИҮ 1988 елның 28 июнендә борынлый, 1989 елның февралендә исә оештыру корылтаен уздыра. Анда унөч карар кабул ителә, шуларның түбәндәге бишесе аеруча әһәмиятле санала:

1. Татарстан союздаш җөмһүрият статусы алырга тиеш.
2. Республикада татар теле дәүләт теле статусына ия булырга тиеш.
3. Республика табигате сәламәт сакланырга, Татарстан атом электр станциясен төзү туктатылырга тиеш.
4. Республиканың җир өсте һәм җир асты байлыклары шушында яшәүче халыкларныкы булуы фарыз.

5. Республикасыннан читкә таралган татарларны тарихи ватанына кире кайтару, кайтмаганнарының мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә булышу кайгыртылсын.

ТИҮ утырышында хәрәкәтнең төрле-төрле кыенлыклар күрүе мәгълүм булды. Административ-әмер аппараты һәм рухи ассимиляцияләшкән (урыслашкан) татарлар аеруча аяк чала икән. Ләкин алга китеш тә күренә: әүвәл союздашлык статусы таләп итүне гаепләгән түрәләр хәзер инде сабыррак фикер алышырга керешкән!

Татарда хәл кылынмаган мәсьәләләрнең күплеге аңлашыла. 430 меңләп милләттәшебез яшәгән Казанда, интернат мәктәпне хисапламаганда, бер генә чын милли уку йорты юк. СССРда бер миллион йөз меңнән артык татар үз туган телен җуйган. ТИҮ югарыда саналган милли мәсьәләләрне чишүне үтенеп, ике йөз мең имза куеп, президент М. Горбачевка мөрәҗәгать иткән. Ләкин Мәскәү әлегә моңа колак салмаган. ТИҮнең үз матбугаты булмау аңа халыкны агарту, оештыру эшендә комачаулый икән.

Казанда ишеткән бер мәзәк әле дә исемдә. Әзербайҗан, казакъ, кыргыз, татар очрашканнар да һәркайсы үз илен мактый башлаган икән. Кыргыз: «Дөньяда иң зур күл бездә. Энем ат белән Ыссык күл тирәли юлга чыккан иде, бер айдан көчкә әйләнеп кайтты», дигән. Казакъ: «Шул да күл булдымы? Минем абыем ат белән Аралны әйләнеп чыгарга алты айда гына өлгерде»,— дигән. Әзербайҗан да бирешергә теләмәгән: «Мин Каспий диңгезен автомашина белән дә бер елда гына әйләнеп чыга алдым», дип лаф орган. Боларны тыңлап торган татар егете: «Безнең Казанда Черек күл бар, абыемны шунда 1937 елда алып киткәннәр иде, әле дә әйләнеп кайтканы юк»,— дигән...

ТИҮ зур максатлар куеп көрәшкә күтәрелгән. Ләкин күпләрнең кул кушырып, аңа читтән генә карап торуы аңлашылмый. Татарның язмышы ансатлардан түгел, кичекми ТИҮ сафларын ныгыту яхшырак булыр иде, безнеңчә.

Килүебезгә дүрт көн тулганда, вакыт, көн-төн алмашынуларына да ияләшә башладым. Бүген конференция ачыла. Асылда безнең төп максатларыбызның берсе — шунда катнашу иде.

1917 елның 20 ноябрендә Уфада Садри Максуди җитәкчелегендә Идел-Урал-ның төрле төбәкләре сайлаган 120 вәкил катнашында ачылган Милләт Мәҗлесе турында мин бер тикшеренү әзерләгән идем. Ләкин конференция үткәреләчәк бик купшы бинага (мемориаль музей), каршы алучы ханым, берничә тапкыр «Исәнмесез!» дисәм дә, урысча гына җавап биргәч, мин бу мәҗлестә үземнең үги икәнемне аңладым. Гаҗәбе, сөйләргә тәкъдим итүче дә булмады. Конференциянең Татарстан Җөмһүрияте башкаласында тик урысча гына алып барылуы сәер иде. Бу миндә Көнбатыш галимнәренең әлле кайдагы Африка яки Австралия кыйтгасында яңа гына табылган, дөньяга мәгълүм булмаган бер кыргый кабилә яки инде күптән юкка чыккан бер халык турында үткәргән конференцияләрен искә төшерде. Шулай да залга Рифат әфәнде белән кереп утырдык. Азадә-Гайшә ханым исә мөһимрәк эш — Бубый мәдрәсәсен өйрәнү артыннан киткән иде. Билгеле шәхесләр генә кертелгәнгәме, зал яртылаш буш иде. Милли мәсьәләләр тикшереләчәк мәҗлескә кызыксынуның әзлеген бәлкем шушы рәвештә генә аңлатырга буладыр. Татарстанның иң күренекле рәсми шәхесе М. Шәймиев конференцияне ачкан нотыгында безнең исемнәрне дә телгә алып, «хуш килдегез!» диде. Моннан соң берничә чыгышны ярты-йорты гына белгән урысчам белән тырышып тыңласам да, файдасын күрмәгәч, чыгып киттем. Минем өчен конференция маҗарасы шуның белән тәмамланды.

Берничә ел элек Истанбулда бер конференциядә очрашып танышкан галим дустым Фәрит Хәкимҗановтан мине «Идел» журналы редакциясенә алып баруын үтендем. Алдан хәбәр бирмичә генә килеп керсәк тә, баш мөхәррир Римзил Вәлиев безне кунакчыл каршылады. Ул, «Идел»не чыгарырга Мәскәү рөхсәт бирсә дә, матди якны хәл итмәү сәбәпле, байтак авырлыкларга дучар булуларын аңлатты. Шулай да бер ел эчендә 120 мең тираж җыю иң алдынгы илләр өчен дә зур уңыш исәпләнә. Римзил әфәнде моңа журналда яңа фикерләрне кыю әйтеп ирешүләрен белдерде. Шулай да шәһәр яшьләре «Идел» белән кимрәк кызыксыну көенечле бер хәл икән.

«Идел»дән соң без инде «Социалистик Татарстан» журналистлары белән очрашырга бардык. Автоном җөмһүриятләрнең гәзитләре чит илләргә чыгарылмаганлыктан, бүгенгә хәтле берничә санын гына күрә алган шушы гәзитнең мөхәррирләре белән очрашу мине ихлас кызыксындыра иде. Шушы гәзиттә минем белән үткәрелгән бер әңгәмә дә басылырга тиеш иде. Гомумән алганда, совет гәзитләре, кайсы гына телдә чыкмасыннар, бер-берләренә бик охшаш. Көнбатыштагы ишләреннән нык аерылалар. Кайбер саннарның тик сәяси эшлекләләрнең чыгышлары белән тутырылуы миңа бик гаҗәп тоела. Җирле гәзитләрне укып кына ил, халык

тормышы турында дөрес күренешне күзаллау мөмкин түгел шикелле. Дөнья халләре турында инде әйтеп торасы да юк. СССРда матбугат, хәбәр таратудан бигрәк, халыкны эшкә өйрәтү, өндәү белән шөгыльләнә бугай. Шулай да «Социалистик Татарстан» соңгы вакытларда «Әллүки» дигән бер кушымта чыгарып, анда халыкны кызыксындырган нәрсәләргә дә кагыла икән.

Газит редакциясендә безне инде байтак кеше көтә иде. Бер үк телдә сөйләшсәк тә, күңелдә бер үк тойгылар кайный иде, дип әйтергә тартынам. Нигә дисәгез, ярты гасырдан артык чит илләрдәге татарлар турында ил матбугатында бик әз язылу, язылганда да, аларны битәрләү, хәтта «хаин» дип сүгү аркасында бер-беренә шөбһәләнеп карау тамыр җибәргән иде. Шуңадырмы, безгә сорауларны бик саклык белән генә бирделәр. Кунакларга яхшы мөгамәлә күрсәтү, аларның күңелен калдырмау ниятеннән эшләндеме бу — әйтүе кыен. Ләкин без кыюрак, үткенрәк сораулар көткән идек.

23 май иртәсендә без Алабугага табан сәфәр чыктык. Юлда Татарстан табигатенең искиткеч матур булуына сокланып бардык. Дөньяның байтак җирләрендә хозур урманнар, кырлар, болыннар күргәнем бар, ләкин Татарстан урманнары ничектер башкача матур тоелды миңа.

Алабуга пединституты студентлары һәм укытучылары белән күрешкәннән соң, Чаллыга юнәлдек. Безне монда да йөздән артык кеше көтеп тора иде. Язучылар, инженерлар, укытучылар... Аларның байтак сорауларына җавап бирдек, аннары һәвәскәрләр концертын тамаша иттек.

Халыкны теле һәм сәнгате яшәтә. Әгәр дә бер халыктан шушы ике хосусиятен тартып алсагыз, ул милләт булудан ераклаша. Музыка кемгә дә якын һәм аңлаешлы диючеләр бар. Дөрес, мин үзем дә төрле халык моңнарын яратып тыңлыйм, ләкин татар музыкасының күңелемдәге урыны бөтенләй башка, ул биргән ләззәтне башка һичбер бүтән милли музыкадан таба алмыйм, бигрәк тә, безнең борынгы җырларыбыз шикелле күңелемне нечкәрткән нәрсә юк.

«Түбән Камада сезне бик күп кеше көтә!» диделәр. Димәк, гади халыкны да турыдан-туры күрә алачакбыз. Дөрес, без әлегә кадәр дә күп кеше белән очраштык, сөйләштек инде. Ләкин алар төрле фәннәрнең вәкилләре, укымышлыларыбыз, зыялыларыбыз иде. Алда исә без халкыбызның төп өлешен тәшкил иткән гади катлам белән дә очрашырга тиеш идек.

Түбән Камада безне әүвәл мәдәният сарае директоры Николай белән таныштырдылар. Карыйбыз, бик матур итеп татарча сөйли. Бераз гаҗәпләнебрәк төбәлүебезне абайлагач, «ул — керәшен татары», диделәр. Баксаң, без бер милләтнең төрле диндәге балалары икәнбез...

Озакламый безне залга алып керделәр. Ул шыгрым тулы иде — меңнән артык тамашачы җыйналгандыр. Буш урындыклар калмау сәбәпле, күпләр кырый-кымтыкта аягүрә басып тора. Кызыксынуның шундый көчлелеген күреп дулкынландык. Шул кадәр халыкка нәрсә әйтергә инде? Аларны нәрсә кызыксындыра? Туган телебезнең чичәннәре янәшәсендә безнең кытыршы татарчабыз аларның күңелен кырмасмы?

Безне халыкка тәкъдим итүчеләр, чыннан да, гаҗәеп тел осталары булып чыкты. Тыңлаган саен тыңлыйсы гына килә. Әмма залдагы тамашачылар чит ил мөсафирларын тыңларга, күрергә килгән иде. Мин үзем чыгышларымны кәгазьдән укырга ияләшкән бер бәндә булу сәбәпле, сүземне кыюсыз гына: «Әссәламе галәйкем!» дип башладым. Җавап ишетмәгәч, ихтимал, әдәпсезрәк тә тоелганмындыр, болай дип өстәдем:

— Безнең якларда исәнләшүчегә «Вәгаләйкем әссәлам!» диләр.

Күпләр елмайды, байтагы җавап та кайтарды. Димәк, кайбер гореф-гадәтләребез югала башлаган, ләкин хәл бөтенләй үк өметсез түгел!

Рифат әфәнде һәм үзем турында кыскача мәгълүмат бирдем дә тамашачылардан сораулар көтүебезне әйттем.

Кичә бик яхшы оештырылган иде, чыгышлар арасы матур җыр-биюләр белән бизәкләнде. Чыгыш ясаучылар арасында дикъкатемне Роберт Батулла дигән берәү җәлеп итте. Аның һәм сатирик, һәм җитди эчтәлекле чыгышын халык зур ләззәт белән тыңлады.

Татарстанда безгә сәер тоелган Роберт, Марсель, Ренат, Лена, Люция кебек исемнәр шактый еш очрады. Шул исемнәрне йөртүчеләрне төрки халык вәкиле итеп кабул итү ничектер бик кыен. Моннан тыш, исемнәребезгә «ов», «ев», «ин» кебек урысча кушымчалар ялгап фамилия ясау да колакка ятышмый. Исем белән фамилия кешенең милли чыгышын да бик ачык күрсәтә. Татарда бу җәһәттән шактый ук саташу абайлана.

«Җидегән чишмә» һәвәскәрләре оештырган очрашу ифрат күңелле узды, халык бик озак кул чабып, безне озатып калды. Болай алкышлау гадәти тәрбиялелек күрсәтүдән ашып, безгә бирелгән иң матур бүләккә әверелде.

Кичәнең иң матур өлешен бергәләп аягүрә җырланган «Туган тел» җыры тәшкил итте. Берниңди кыскартусыз барлык дүрт куплетының да җырлануы Түбән Камада милли рухның шактый күтәренке булуына ишарә иде.

Элек Казаннан соң Әстерхан, Оренбург, Уфа милли мәркәз ролен үтәсә, хәзер шул вазифа Чаллы белән Түбән Камага күчкән сыман. Әлбәттә, аларда да атлыйсы адымнар күп әле. Ләкин Идел буена ясаган сәяхәтем вакытында Түбән Каманың «Җидегән чишмә» кичәсендә катнашуым күңелемдә мәңгелек тәэсирләр калдырды. Казан матбугатында бу кичә турында бер генә хәбәр дә басылмавы гына кызганыч. Халыкны кызыксындырган нәрсәләргә кул селтәп карау әле дә дәвам итә, күрәсең. Казанның урысча матбугаты безнең хакта бер сүз дә язмавы аеруча сәер. Без әллә кем булудан түгел, чит илдән ике татар галиме килү урыслар өчен кызык булмаса, урысча гына укучы татарларны онытырга ярамыйдыр лабаса?! Хәер, урыслар язмады, дип кайгыга төшмәдек без. Алар матбугатының гасырлар буе татарны күрмәмешкә, белмәмешкә салынуы, язса, каралтып, битәрләп кенә телгә алуын да белгәнлектән, «бәлки, дәшмәүләре хәерлерәктер дә!» диеп уйладык. Дистә еллар буе «халыклар дуслыгы» дип лаф оруларның күбрәк күз буяу өчен генә кирәксенелүен без болай да яхшы белә идек.

Түбән Камада татар урта мәктәбендә, балалар бакчасында, Чаллы пединститутында һәм тагын берничә урында булдык. Байтак кына укытучылар, галимнәр, эшчеләр, балалар белән сөйләштек. Татарча укыту эшләренең бик үк һәйбәт көйләнмәве, хәл итәсе хәтсез мәсьәләләр барлыгы да сизелде.

25 майда Татарстан язучылар берлегендәге очрашуга дистәләп күренекле әдип һәм шагыйрь килгән иде. Күпсанлы сорауларга җавап бирергә, Төркиядәге татарлар хакында белгәнемне уртаклашырга тырыштым. Монда да республиканың союздашлык статусы алуы, татар теленә Дәүләт теле статусы бирү, милләт тарихын объектив яктырту, төрки халыкларның латин нигезендә уртак әлифбасын булдыру мәсьәләләре кузгатылды. Җөмләдән, болгар-татар мәсьәләсе дә телгә керде. Революциядән соң Идел-Урал төркиләренең татар, башкортка бүлгәләнүе безне болай да төрле югалтуларга дучар итте инде. Бәлки кемнәргәдер, халыкны зәгыйфьләндерер өчен «типтәр», «мишәр», «керәшен» һ. б. милләтләрне уйлап чыгару да файдалыдыр? Югыйсә, татарны төрки болгарларга гына бәйләүне фәнни яктан да аклап булмый. Бүтән мөһимрәк мәсьәләләребез көн тәртибендә торганда, татар исеменә каныгуны, «шул исем аркасында кысым, җәбер күрәбез», дип халыкка бүтән «сөйкемлерәк» исем тагарга маташуны милләтнең кирәксезгә башын әйләндерү, беркатлылык яки җавапсызлык күрсәтү дип кенә бәяләргә мөмкин, минемчә. Язучылар белән күрешүдә менә шундый кешеләрнең, игътибарны юри бүтәнгә борып, милләтнең иң хәлиткеч ихтыяҗларын кайгыртуга аяк чалулары сүз ителде.

Казан университетындагы очрашуны атаклы тарихчы, проректор М. Госманов ачты. Монда Төркия белән бүтән чит илләрдәге татарлар, милләтебезнең киләчәге өчен хафалану игътибар үзәгендә торды. Физика-техника институтында Рифат Тәби әфәнде нотык тотты. Бирегә Ш. Мәрҗани исемендәге мәдәният җәмгыятенең эшлекләләре белән танышу мөмкинлегенә ирештек һәм татар халкының техника өлкәсендәге укымышлыларының да милли язмышына битараф карамавын белеп, чын күңелдән шатландык.

Бүген инде беренче мәртәбә Идел өстеннән йөзеп китә алачакбыз — сәфәребез тарихи һәйкәлләр үзәге, Көнчыгыш Европада исламның рәсми рәвештә аяк баскан җире Болгарга. Кораб киткәндә юлчыларга радио аша бер мәртәбә урыс акценты белән татарча мөрәҗәгать ителде. Бу яңа хәл икән. Үзгәртеп кору җимеше.

Ләкин татар исеменә ия бер генә корабка да очрамадык. Гасырлар буе төрки халыклар елгасы булган Идел хәзер Волга дип атала һәм аның өстендә татар көймәләре йөзми, хуҗалар тәмам алышынган.

«Метеор» ике сәгатьтән артыграк вакыт эчендә Болгарга килеп җитте. Тарихыбызның иң данлыклы заманы һәйкәлләренә таба атлыйбыз. Ерактан ук Болгар хәрабәләре күренде. Меңләгән чакрымны узып, Болгар туфрагына аяк басу турында моннан берничә ел элек хыяллана да алмый идем. Нурлы Болгарга якынлашкан саен дулкынлануым арта бара. Ләкин... хәрабәләрнең уртасында әле күптән түгел генә реставрацияләнгән бер чиркәү тора. Аның ике гөмбәзендә исә татарны басып алуның символы — ярты ай өстенә кадалган тәреләр. Алар, тарихыгызга да без ия, дигәндәй ялтырап торалар. Шушы чиркәү 1732 елда салынган була. Җимерелгәч, 1860 елда аны яңадан торгызалар, бу юлы нигезенә бабаларыбызның изге кабер ташларын түшәргә дә онытмыйлар. Бу — татар халкын мәсхәрә итәр өчен махсус эшләнмәгән, диючеләр дә бар. Ихтимал, хөрмәтләү өчен куелгандыр. Әлегә чиркәү музей итеп файдаланыла, әмма иртәгә гыйбадәтчеләргә бирелсә, ни булыр?

Музейда берничә генә хезмәткәр эшләп, араларында Җәмил әфәнде генә татар

икән. Тарихыбызның шушы изге һәйкәлләрен саклауга ул бик күп көч сала. Ләкин ялгыз хезмәткәргә генә зур тарихи байлыкны саклау ансат түгел. Милләтебезнең шундый фидакарь шәхесләре беттеме икәнни соң, дип пошынуыбыз табигый. Ләкин СССРдагы уртача хезмәт хакыннан ике мәртәбә түбәнрәк айлыкка (130 сум) тагын кем эшләсен?! Мәдәниятыбызнең болай да аз калган үрнәкләрен саклау өчен тагын берәз акча табу шул хәтле кыен микәнни? Җәмил әфәнде хәрабәләр, болгарлар тарихы турында безгә бик бай мәгълүматлар бирде.

Татарстан башкаласында очрашуларның бигрәк тә истә калганы «Казан утлары» редакциясендә узды сыман. Милли әдәбиятыбызның, сәнгатебезнең, бөтен мәдәнияты бызның иң алдынгы көче булган шушы журнал хезмәткәрләре белән очраша алу минем өчен гаять истәлекле вакыйга иде. Чөнки бу мәҗмуга ярты гасырдан артык татар әдәбиятының, фәненең, иҗтимагый фикеренең көзгесе булып килде. Мин үзем да озак еллар буе тик шушы журнал аркылы гына ил белән мөнәсәбәт тота алдым. әдәби телебезне үзләштерүдә дә миңа менә шушы журнал юлъкүрсәткеч булды. Хәтта Истанбулда чыгарган «Казан» мәҗмугасының тышлыгын да, эчтәлеген дә аңарга охшатырга тырыша идек. Тормышымда: тикшеренүләремдә һәм илгә мөнәсәбәтемдә, халкыма мәхәббәтем уянуда үтә мактаулы урын тоткан «Казан утлары»ның хадимнәре белән очрашу, күптәнге рухи дустым, остазым белән күрешү шикелле, бөтен барлыгымны биләп алып дулкынландырды.

Мәҗмуганың яңа баш мөхәррире, атаклы шагыйрь Равил Фәйзуллин редакциядәге хезмәттәшләренә мине таныштырганда: «Былбыл кунган җирдә яфрак тибрәнер», диде. СССРның үзгәртеп кору җилләре әллә нинди ерак җирләрдән минем кебек кошларны да татар урманнарына хәтле алып килде. Шундагы агачларның кайберләренә кунарга да өлгердем. Мин анда нинди тәэсир калдырганмындыр, әйтә алмыйм, әмма үзем «Казан утлары»ннан тәэсирләнеп кайттым. Шушы юлларны язганда, очсыз-кырыйсыз кебек күренгән Мәрмәрә диңгезенә карыйм да: «Их, шушы су юлы белән дә барып Казанны янә бер күрергә!» дип хыялланам.

«Казан утлары»нда очрашу якынча ике сәгатькә сузылды. Сүз бигрәк тә татар-төрек әдәби бәйләнешләре, шушы тугандаш ике халыкны бер-берсенә яхшырак таныту, журналны Төркиядә тарату, татар язучылары әсәрләрен чит илләрдә бастыру, чыгышы белән татар булган Төркия галимнәре Йосыф Акчура, Садри Максуди, Габдулла Баттал, Рәшит Рәхмәти, Әкъдәс Нигъмәт, Хәмит Зөбәерләр язмышы, алар эшчәнлеген журналда яктырту хаҗәтлеге, СССР белән Төркия арасындагы мөнәсәбәтләрне тулаем ныгыту хакында барды.

Кешелек дөньясын тәрәккый иттерү өчен хәзер халыклар үзара тәҗрибә уртаклашу юлларын ныграк эзли башлады. Бу эштә исә мәдәни бәйләнешләрнең, бигрәк тә, әдип-шагыйрьләребезнең роле зур. Чөнки алар халыкларның бер-берсен аңлавына күренекле өлеш кертә алачак. «Казан утлары» мәҗлесендә без шушы хакта җентекләп сөйләштек һәм киләчәк уртак эшләребезнең планнарын билгеләдек. Ниятләребезнең гамәлгә ашуы өчен көчемне кызганмаска вәгъдә бирүем әле дә хәтеремдә.

...Ата-баба йорты белән саубуллашу мизгеле дә килеп җитте. Уналты көн күз ачып йомганчы диярлек узып киткән иде. Бу сәяхәт миңа кырык дүрт елдан соң беренче мәртәбә сеңлемне күрү, былтыр вафат булган әниемнең каберендә дога кылу, кайбер дуслар белән очрашу, татар халкының алдынгы вәкилләре белән танышу һәм дә бөек, эшчән, матур татар халкына сыену шатлыгын биргәнлектән, үземне Аллаһның иң бәхетле колларыннан берсе дип исәплим. Миңа карата юмарт кунакчыллык күрсәтелде. Тирә-юнемдәге һәммә кеше иң нәни ихтыяҗымны канәгатьләндерү өчен дә теше-тырнагы белән тырышты. Шундый зур илтифатны һичбер илдә дә татымаган идем.

Бу юлларны чит илдә туып-үскән, ләкин шулай да тарихи ватаны белән кендеген өзмәгән бер әүнең ата-баба җиренә килгәч нинди тәэсирләр алганын белдерү өчен яздым. Шундый кыска вакыт эчендә һәрнәрсәне күрдем, аңладым, дип дәгъвалый алмыйм. Алдарак кайбер тәнкыйть сүзләре дә әйтелде, әмма боларның һичберендә яман ният юк. Шулай да, кайбер милләттәшләремнең күңелен калдырган булсам, гафу итсеннәр. Минем изге теләгем — газиз, сөекле милләтемне бәхетле, тулы хокуклы милләтләр сафында күрү. «Гәрчә анда тумасам да», Татарстан, Идел буйлары һәрвакыт күңелем түрендә.

Килер бер көн, Казан, Алабуга, Чаллы, Әлмәтләргә күршедәге өйгә кергәндәй тагын барып кайтырмын, дигән хыял белән очкычка менеп утырдым. Казан күчкенә бер ноктага әверелгәнче, күзләремне тәрәзәдән алмадым. Шул чак Тукайның «И Казан! дәртле Казан! моңлы Казан! нурлы Казан!» дигән сүзләре исемә төште. Сау булыгыз дуслар, сау-сәламәт яшәгез, рәхмәт сезләргә!

*Истанбул.*
*Август. 1990*

## Салих МАННАПОВ

# «СӘЛАМ БЕЛӘН, НИКОЛАЙ ИВАНОВИЧ...»

## яки тапшырылмаган хатлар жанрында бер бәян

Көннәрнең берендә мин Николай Иванович Рыжков булып уяндым. Соңгы араларда төрле-төрле сурәткә кереп алулар табигый хәлгә әйләнә башлаган иде инде. Табигый дигәч тә... дөнья үзе шуңа мәҗбүр итә икән ул. Әрсезенә, мәнсезенә юлыга торгач, кайчагында бүре булып улардай хәлгә килсәң дә гаҗәп түгел...

Әмма СССР премьер-министры кабыгына кереп карарга туры килгәне юк иде әле.

Барысына да ерак Казагыстан якларында яшәп ятучы бер милләттәшебез сәбәпче булды. Пенсиядәге мөгаллим Мөхәммәтдин агайны татар китабының СССРдагы татар халкы яшәгән төбәкләргә барып җитмәве бик борчыган. Борчылып кына калмаган ул, кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә карар кылган. Тик ничек итеп, нинди юллар белән?..

Аңлашылса кирәк, вакыйга безнең көннәрдә — әле дә булса әкияттәге кебек ак патшага, акыл иясе баш вәзиргә ышаныч бетмәгән шартларда бара... Рәсәй күләмендә мәгариф отличнигы, илле еллык пропагандист, кулына каләм алып, Мәскәүгә хат язган. Әйе, әйе, СССР министрларының башлыгына, Николай Ивановичның үзенә. Хәзерге Татарстан җирендә халкыбызның миллион ярымы гына калды, янә биш миллионы мәмләкәтнең сиксән төбәгендә яши; мең еллык тарихыбыз, телебез вә әдәбиятыбыз бар, басма сүзгә ия булу ягыннан империядә рустан гына калышканбыз, дигән Мөхәммәтдин агай. Бүген исә татар матбагачыларының милләт алдындагы зур бурычларын үтәп җиткерә алмавыннан зарланган, моның төп сәбәпләреннән берсен әйтеп тә биргән: «Казандагы бердәнбер нәшриятыбыз хәлсез, фәкыйрь шул,— дигән.— Күрәсең, Мәркәз аны шул төбәктә яшәгән халык микъдарынча гына кәгазь белән тәэмин итәдер...» Милләттәшебез, Мәскәүнең үзенә сүз катып: Татарстаннан читтә яшәсәк тә, без дә бит хак-хокуктан мәхрүм ителгәннәр түгел, без дә дәреслеккә, сүзлеккә, туган телебездәге бүтән төрле китапка мохтаҗ, дигән. Гаделлекне торгызырга өндәп, илнең башка төбәкләрендә көн итүче милләттәшләр өчен дә китап басарлык кәгазьне Казанга бирүне сораган.

СССР Министрлар Советы рәисенә турыдан-туры мөрәҗәгать иткән икән, Мөхәммәтдин агайның моңа үзенчә сәбәбе-сылтавы да юк түгел. Николай Иванович Рыжков белән якташлар лабаса; шул Пермь якларында утыз җиде ел буена сабыйларны укыткан. Юк, олы яшьтәге мөгаллим, Сугыш ветераны үзенә нindидер майлы калҗа сорап язмый. «Знакум»лыгын да ул халкына китап сүзе басарлык кәгазь алу өчен файдаланып булмасмы дип кенә өметләнә.

Ул заманда әле Татарстаныбыз суверен дәүләт түгел (хат нәкъ бер ел элек — 1990 елга аяк баскан көннәрдә язылган); «Совет халыкларына дан!» дигән кайгыртучан сүзләр урынына «Көчле үзәк — көчле республикалар!» дигән чираттагы канатлы тәгъбирне һавага чөйгән вакытлар... Үзәккә таба суыру инерциясе хәтта Рәсәйнең үзендә дә: «Нинди көчләр,

---

Салих МАННАПОВ (1953) — *әдәби тәнкыйтьче; Татарстан китап нәшриятының баш редакторы; «Сезгә ышанам», «Тамыр тирәнлеген яфрак тоя» дигән китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.*

нинди упкын тарта безне җан сорап?!»— дип әйтерлек тойгы-настроениеләр кузгаткан мәл. Үзәктән этелү көче исә милли аһ-зарларны, элеккечә үк шактый җилле генә итеп, читкә куып-себереп торуын белә... Балтыйк буе, Молдова илләренең хәле: койрыгын алса — башы ябыша, башын алса — койрыгы дигәндәй. Кыргыз, Әрмән, Әзербайҗан, Кырым граждан-нар сугышы чигендә: анда кан түгелә, яшь коела. Ә Мәскәү, күрәсең, гадәтенчә, күз яшьләренә ышанырга ашыкмый. Аның тәрәзәсендәге «дворник»лар уңга-сулга җитез генә селтәнеп, куа-себерә тамчыларны, куа-себерә... Яңадан-яңа хасбулатовларга, эш арткан вакыт...

*«Москва. Совет Министров СССР. Рыжкову Н. И.»* дигән хат минә шундый җилләр белән килеп төште дә инде... минем өстәлгә.

Хатны кулыма алганда дулкынландыммы, әллә аптырадым микән — хәтерләмим. Без бит инде — җитмеш ел буе Мәскәүнең төчкергәненә бәрәкалла кылып, һәртөрле Указны ходайдан килмеш вәхи белән бер күргән халык...

Татар түбәтәен кыңгыр салып, кишер чәе эчкәндә, даһи юлбашчыбыз: «Теге, мулла малае...»— дип, Тукайны искә төшергән, диләр.

Халыклар атасы, «Язгы җилләр»неме, «Намус»нымы укып чыккач, тәэсирләренә чыдаша алмый, җиде төн уртасында Казанга шалтыраткан, имеш, дип тел шартлаталар.

Заманының иң күренекле халыкара эшлеклесе «Кече җир» дигән үлемсез китабында безнең милләт кешесен дә телгә алгач, ничек куанган идек...

Кыскасы, «Әби патша»дан алып «Рәйсә Мәгъсүмовна»га кадәр татарга мөнәсәбәтле әллә ни хәтле риваять иҗат ителгән.

Әлеге хат аркасында Николай Ивановичка да шундый легенда каһарманы булу мөмкинлеге ачылган иде... дип әйтергә теләмим. Ул кадәресе бик яхшы аңлашыла. Республикалар союзы премьер-министры, үзе теләгән җәһәттә дә, һәр хатка җавап язып утыра алмый. Мөгаллим-ветеран да аны гына аңламаслык беркатлы агай түгелдер. Әмма ул, мәсьәләнең никадәр зурлыгын белгәнгә күрә, шул дәрәҗәдән торып — чишелүен үк димим...— өйрәнелүен, куелуын булса да өмет итә ләбаса.

Миңа нишләргә? Хатны озата килгән баскыч-баскыч кәгазь кисәкләрендә «авторга җавап язарга» дигән томанлы гына күрсәтмә бар-барын. Ләкин... нәрсә дип язарга? Кем исеменнән язарга? СССР Министрлар Советы рәисе булыпмы?.. Дөрес, зур-зур түрәләр өчен хат кынамы, әллә нинди җаваплы чыгышлар, китаплар иҗат ителгән мохитта яшибез. Тик андый эшләргә керешкәндә, фикер сөрешенең кайсы якка таба агасы алдан мәгълүм була шул. Ә монда — шактый ук четерекле хәл бит: автор дигәнебез хатка каршы хат түгел, конкрет ярдәм көтә!..

«Хөрмәтле...» дип беренче юлны гына башлаган идем дә, шундый икеләнүләр уртасында тукталып-төртелеп калдым.

Аннары, ни булса шул дип, яңадан кулга каләм алдым,— җанны кыйнаган уйларның бер өлеше чайпалып кәгазьгә түгелде

## Беренче хат

*Хөрмәтле Мөхәммәтдин ага!*

*Милли китапчылык юлындагы кыенлыкларга игътибарны юнәлтеп аваз салгансыз — рәхмәт яусын.*

*Бер карaганда, кәгазьгә кытлык — ил белән. Нәшриятларның тулаем матди хәле кыенлашу, тормышыбызның бүтән яклары кебек үк, үзен көннән-көн ныграк сиздерә башлады. Бай чимал чыганагы сыйфатында кырын ятып яшәүгә җайлашып килгәндә генә СССР дигән мамонтны әле теге, әле бу яктан проблемалар борчасы тешли. Һәм сәяси-политик, һәм икътисади-экономик кыенлыклар уртасында калдык шул. Кинәт кенә илдәге барча сабын заводлары һәм тәмәке фабрикалары берьюлы тузып эштән чыккан, имеш. Кәгазь комбинатларында да «кинәт кенә» чимал җитми, ремонт кирәк булып чыкты. Яңа кануннар кабул ителгән саен куллары ныграк бәйләнә барган дәүләт нәшриятларының хәле тәмам мөшкелләнде. Комбинатлар белән килешү җепләре бушаганнан-бушый, кәгазь һәм бастыру хакы кыйммәтләнә бара. Бәяләр һәм принциплар шактый үк болганган әлеге «базар»да милли нәшриятка икеләтә, өчләтә авыр булачак. Чын мәгънәсендә акча басар өчен мәйданга чыккан кооперативлар кәгазьне генә ту-*

*гел, полиграфия базасын да сатып-тартып алырлык көч алды. «Приватизация» кебек ялтыравыклы төшенчәләр күзне камаштырган, учны кычыткан бер заманда кайберәүләр, җиңел генә кубып, «хосусый матбага», «конкуренция» дип авыз суын корыта башлады. Сөйләве яхшы, күңелле... Ким дигәндә җитмеш елга артта калганыбызны гына онытабыз. Иске гадәт буенча, тагын да тулы бер дәверне «сикереп үтү» өянәге кузгала. Җенси яки сәяси порнография бастырып көн күрүдән башлаган «хосусый» матбагалар милли мәдәниятны үстерү кебек авыр йөкне үз җилкәләренә алырлармы?.. Ә бит безне бу юлы да нәкъ үзебезгә хас, урак-чүкечле хаталар һәм бәлаләр көтеп тора: булганны нигезенә хәтле җимерәбез дә, яңаны күтәрмәгән көе түбә ябарга маташабыз...*

*Менә шундый шартларда милли китап үзенең йөзен саклап кала алырмы, туры мәгънәсендә базары төшмәсме аның?..— Сезнең хатка җавапны әлегә шул сорау билгесе белән төгәлләргә туры килә.*

* * *

Әйе, Николай Иванович «исеменнән» менә шундыйрак хат язылды. Язуын яздым, әмма иңгә басып торган бер эшне, бурычны үтәү тойгысы тумады. Киресенчә, күңелдә ниндидер канәгатьсезлек хисе төенләнде һәм көчәя генә барды. Мөхәммәтдин агай да мондый җавапка, хәтта ул премьер-министрның үзеннән килсә дә, риза булмас иде, мөгаен.

Юк шул, кәгазь хәлләре читен дип, җае чыккан саен зарланудан гына файда юк. «Планнан тыш» кәгазьне рәхим итеп базардан сатып ал, диярләр: хакы дәүләтнекеннән ун мәртәбәгә кыйммәтрәк булса ни, аның каравы тулы хөррият...

Ә дәүләт? Ә Мәскәү?.. «Ходай тәгалә дә сораучыга мохтаҗ»,— диләр анысы. Чынлап торып сорасаң, сукыр бер тиенне дә «конвертлы рубль»гә әйләндереп була, имеш... Әмма безме соң ул — имчәк сорап еламаган? Әнә бервакыт... «Җиде миллионлы халыкка китап чыгарырга тиеш бит без, нигә шуны белмәмешкә салышасыз?»— дип ишекләрне шакый торгач, Мәскәү агай кечелекле мөнәсәбәтен күрсәтеп алды. Көннәрнең берендә «өстәмә фонд» дигән кәгазь килеп төшмәсенме. Кәгазь дип, китап баса торганы ук түгел әле, аны алырга мөмкин дигән язу гына. «2 нче номерлы» дигәннәр (саргылт, тупас инде; булсын!— артыгына өмет иткән дә юк), «милли китап басу өчен» дип аерып күрсәтелгән (һай, рәхмәт төшкерләре!) Җәмгысе 10 (ун) тонна... Күпме бу? Күз алдына китерү өчен шундый чагыштыру: «Казан утлары»ның бер санын басарга 25 ләп тонна кәгазь китә. Ә нәшриятка бер ел эшләү өчен 1800 тонна кәгазь кирәк... «Милли китап» дигәннәре исә безнең полиграфкомбинатта бүтән республикалар өчен басылгалап килгән дәреслекләр булып чыкты...

Мәскәүдән кәгазь сорау эпопеясе менә шулайрак төгәлләнде.

Әйе, «икенче сорт» дигән стереотипны, «тулып җитмәү» комплексын табигый хәл дип кабул иттерү өчен безнең башкайларга шактый озак тукыдылар. Республикадан читтә яшәгән милләттәшләр исәпкә алынса да, санга сугылмады. Халыкның зурлыгын да, илдә сибелеп яшәү шартларын да күрмәмешкә салыштылар. Милли мәдәниятны өстән басып, астан кисеп килделәр.

Чагыштырып карыйсыздыр: Татарстан нәшрияты чыгарган күп кенә басмаларның «авызын ачса — үпкәсе күренеп тора». Кәгазе саргылт, рәсемнәрнең төсе яңгыр юган төсле уңган, тышлыгы кыек-мыек ябыштырылган, җилемгә батып беткән. Нәшрият бер очтан полиграфкомбинат оятын да күтәрә.

Миңа инде Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты хуҗаларының күңеленә май булып ятмаслык сүзләрне еш әйтергә туры килә. Үзара аралашу вакытында да, кайчак хәтта матбугатта да. Хезмәттәш-партнерларның ачуын чыгарасы килми, әмма ни хәл итәсең: заманында хәтта газета, журналлар бастырып килгән комбинат хәзер, тупасрак итеп әйткәндә, «күтәрәмгә калган»: кайбер басмалар икешәр-өчәр ел чыга алмый интегә, аларның сыйфаты да яхшыруга таба бармый. Сыйфатына күз йомган тәкъдирдә дә, полиграфкомбинатка гына ышанып торсаң, татар баласына йөзәр меңләгән данә белән күп төсле, рәсемле китаплар чыгарып булмас иде.

Бу бәлаларнең иң төп сәбәбе — техник җиһазлануда артта калганлык, шуның өстенә әзерлекле белгечләр һәм эшчеләр җитешмәү булса, әлеге сәбәпләрнең (яки нәтиҗәләрнең) чыганагы эшне оештырудагы җитешсезлекләргә һәм озак еллар дәвамында тиешле дәүләт оешмалары тарафыннан игътибар күрмәүгә барып тоташа. Ләкин безне иң борчыганы: хәлне төзәтү юнәлешендә сизелерлек бер генә адым да ясалмавы. Турысын әйткәндә, Татарстанның төп дәүләт типографиясе хәзер татар китабын бастырудан баш тарту дәрәҗәсенә җитеп килә. Нәшрият, ниһаять, яшәвенең җитмеш икенче елында беренче тапкыр, «үзенең» китабын бастыру өчен, район газетасы типографияләренә сүз катып карый. Шулай итеп, үзебез, үз кулыбыз белән милли китап санын кыскартуга мәҗбүр ителәбез...

Хәер, Госкомиздат дигән мәшһүр системада татар халкының китап нәшрияты, русның провинциаль нәшриятларыннан да мескенрәк хәлгә төшерелеп, район газеталары белән бер тактага куелган иде инде. Әле соңгы елларга кадәр тематик пландагы берәр өтерне үзгәртү дә Мәскәү рөхсәте белән генә эшләнде. Теленне белмәгән, әдәбиятыннан хәбәре булмаган чиновниклар кайсы китапны кайчан, ничек чыгарырга икәнен хәл итеп килделәр. Шул чорда дилбегә тотарга өйрәнеп калган кайбер үз түрәләребез бүген дә әле шул иске гадәтне куарга азаплана. Ә нәшриятка ярдәм кирәксә, күзеңә туп-туры карап, авыз ералар: «Үз җаегызны үзегез карагыз, сез бит хәзер мөстәкыйль түгелме соң»,— дигән булалар.

Хәтерлисездер: Союзда да, Россия федерациясендә дә министрларны раслау теге яки бу өлкәдәге авыр бурычларны барлау, искә төшерү рәвешендә барды. Тимер юлчылар яки күмер чабучылар министры буласы килгән кешегә нык кына тирләргә туры килде. Ә менә матбугат министрларының ничек билгеләнгәнен күреп калдыгыз микән? Мин моны махсус күзәттем: депутатларыбыз китап матбагасына кайсы яктан килеп кагылырлар да, министр дигәнебез әлеге проблемага нindирәк мөнәсәбәт белдерер? Көтүем бушка булды: ике Югары Советта да китап язмышы турында җитди сүз кузгатылмады. Ике якның да битарафлык күрсәтүе идеме бу, әллә компетенция җитмәвеме? Һәм инде шуннан соң нәшриятлар белән җитәкчелек итүдә берәр үзгәреш, яңарыш көтәрг мөмкинме?..

Ә бит ул чакта ук илдәге һәр ике китапның берсе «зыянлы» булуы билгеле иде. Инде быел Татарстан китап нәшриятында басыласы китапларның уннан тугызы үзен-үзе аклый алмый. Бу исә парадокска тартым күренеш тудыра: милли китапны саклап калу өчен, аңа дип, мең бәла белән эзләп алынган кәгазьнең күпме өлешен «договор бәясе» белән чыга торган китапларга сарыф итәргә мәҗбүр булабыз. Хуҗалык исәбендәге милли нәшрият хәлләре... Шул шартларда да татар китабының тиражы үсә баруы — гайре табигый хәл. 1987 елда әлеге сан 1,924 миллион данә булса, 1988 елда ул 2,295 миллион, 1989 елда —4,334 миллион, ә 1990 ел планы буенча —5 миллионннан артык. Өч кенә ел элек татарча китапның өлеше 26 процент булса, былтыр, киресенчә, русча китапның саны шул чамага калырга тиеш иде. «План буенча», «тиеш иде» дип икеле-микеле әйтүем шуңа: беренчедән, бу мәкаләне тапшырганда әле ел тәгәлләнергә тулы ике ай вакыт бар иде; икенчедән, 1990 елның баштагы ун ае һәртөрле планнарны һәм өметләрне чәлпәрәмә китергән дәвер булды. (Бу хакта «Социалистик Татарстан»да басылган интервьюда киңрәк, тәфсилләрәк сөйләнде инде).*

Шул җәһәттән Казанда яшәүче рус язучысы Лев Кожевниковның «Ищу мецената» дигән чыгышы искә төшә. «Советская Татария»дә басылган ул мәкалә нәшриятка үпкә генә түгел, дәгъва белдерүе белән дә укучыларның бер өлешен җәлеп итәргә, ышандырырга мөмкин иде. Үз вакытында аңа игътибар бирүне кирәксенмичә, без ялгышмадык микән әле?

Л. Кожевников мәкаләсенең беренче җөмләсе үк моңа кадәр мин язып килгәннәрне сызып ташлый.

СССР матбугат министры (ягъни Госкомпечать рәисе) Югары Советның әлеге дә баягы (үзен раслаган) сессиясендә шундыйрак саннар китергән иде... Безнең илдә нәшрият эшчәнлегенә бер сум акча тотсаң, ул 8-10 тәңкә табыш булып кайта; бу — гаҗәеп күрсәткеч, хәтта алтын чыга-

---

* «Сөйлә, Китап: хәлең ничек;»— «СТ.» 1990 ел, 26 октябрь саны.

рунын да файдасы 3 сум тирәсеннән узмый, имеш. Шуңа таянып, Л. Кожевников әлеге табыштан үзе мәхрүм калган кыяфәт ясый: янчыгына миллионнар тутырган «номенклатур» әдипләрне, язучыны талау юлы белән череп баючы наширләрне сүгә. Әле генә «һәр ике китапның берсе...», хәтта «ун китапның тугызы...» исрафчыл дип әйткән идек. СССРның матбугат министры берне таратып унны җыеп алу серен ачканмы әллә?

Юк шул. Пәри — башка, җен-башка, дигәндәй,— янә шул «уртача» сан күрсәтеп хәрәмләшү... Әмма Л. Кожевниковның телен кычыттырып торган сүз төптәрәк ята. Элек тә миндәй талантлы әдипләр кысыла иде, дигән фикерен дәвам итеп, ул болай ди: «произвол творится и ныне, втихую, с глазу на глаз, под трескучими перестроечными лозунгами, скажем, «издательского хозрасчета» или национального самоопределения и т. д.» (Соңгы сүзләрнең астына мин сыздым). «Астыртын башбаштаклык, золым...» — Җиңел генә кизәнеп зур гаеп ташлый бит автор. Хуҗалык исәбе белән бәйле матди хәлебез инде аңлаган кешегә аңлашылгандыр, өстәп әйтергә мөмкин булган бер генә сан: 1991 елда безнең нәшриятның китап чыгарудан 1,5 миллион сум зыян күрүе көтелә... Моның шапырынулы лозунгмы, әллә бөтенләй бүтән нәрсәме икәнен, шәт, шуннан чамалап буладыр. «Милли үзбилгеләнү дигән лозунг-шигарь астында золымлыклар эшләнүе» — хәер, бу гаепләү дә яңалык түгел инде. Шулай да, үз-үземне кабатлап булса да, тагын бер сан белән җавап бирү кирәктер: җитмеш ел эчендә Татарстан китап нәшрияты бастырган һәр 6 китапның берсе татарча булса, бишесе — рус телендә. Золым турында сөйләргә, чыннан да, нигез бирә бугай бу сан, әмма ләкин мәкалә авторы уйлаганның киресе килеп чыга түгелме соң?..

Без инде, ниһаять, һәр дүрт китапның өчесе татар телендә басыла башлавын искә алып үттек. Бер караганда, игътибарга лаек казаныш. Әмма шул хәлендә дә нәшриятыбыз милли китапка булган ихтыяҗның... яртысын канәгатьләндерә ала. Ул ихтыяҗ дигәнебез, дөрес, әле тиешенчә өйрәнелмәгән; сүз бары тик сәүдә оешмалары биргән заказ турында гына бара. Татар китабы белән СССР күләмендә сәүдә итүнең үз кыенлыклары мәгълүм, һәм ул аерым сөйләшү темасы булып кала. Җыеп кына әйткәндә, полиграфкомбинатка да татар китабын чыгару «зыян» сала, татар китабын ил буенча тарату да китап сәүдәгәрләрен бөлдерә. Һәрхәлдә, алар шундый шартларга куелган. Шуның нәтиҗәсендә, Татарстан китап нәшрияты продукциясенә 60 лап өлкәдән 5 миллион сумлык заказ килсә, хәзергә аның нибары 1 миллионын гына үтәү-җибәрү мөмкинлеге бар. 1 миллион сум — бу безнең нәшрият чыгарган басмаларның алтыдан бер өлеше дигән сүз...

Күрәсез, хикмәт кәгазь җитмәүдә генә дә түгел, һәм, шагыйрь әйтмешли, «мәсьәлә бик зур, сыйдырмый тар шигырьләр үлчәве». Әлеге «мәсьәлә»не хәл итү өчен безгә чит планеталардан да, хәтта Мәскәүнең үзеннән генә дә килмәсләре мәгълүм...

Ә шул ук вакытта, истә әле, моннан бер-ике ел элек Башкорт университеты галиме безнең матбугатта Татарстан мәгариф министрлыгын да, нәшриятны да гаепләп чыгыш ясаган иде: янәсе, ничек инде ул, Казан — бүтән республикаларда татар телен укытуны тикшерү өчен инспекторлар җибәрми, дәреслекләр белән дә тәэмин итеп җиткерә алмый?..

Мөхәммәтдин агайның хаты миңа шундый каршылыклы уйлар кузгатты. Һәм ул уйларны беренче хатта әйтеп бетерә алмаганымны аңлап, өстәвенә зарланып кына әлләни майтарып булмасын да белгәнгә, кулыма тагын каләм алдым...

## Икенче хат

*Хөрмәтле Мөхәммәтдин ага!*

*Татар китабына гадел мөнәсәбәт күрсәтүне үтенеп язган хатыгыз бик урынлы булса да, күрәсең, хәзерге көндә безгә «Үзәк»тән ярдәм көтеп тору гына хилаф бер эштер. Әлбәттә, «уртак мал»да халкыбызның мәгълүм өлеше бар, һәм ул өлешне сорап түгел, даулап алырга туры киләчәк әле.*

*Татарстан сәяси һәм икътисади-экономик мөстәкыйльлеккә чын-чынлап ирешә икән, тормышның бүтән проблемалары никадәр күп һәм никадәр катлаулы булмасын, безнең Югары Совет һәм хөкүмәт милли мәдәният, милли нәшрият мәсьәләсен озын чиратның койрыгына куя алмас. Хәзер һәр көн, һәр сәгать исәптә. Без инде җитмеш ел вакытны югалт-*

*тык. Таралган авылларыбызны җыю әнә ничек кыен! Телен югалткан миллионлаган милләттәшебезне кайтару аннан да авыррак. Милли китап учагының күз-күмерләре тәмам сүнгәнче, ашыгыч чарасын күрәсе иде.*

*Соңгы елларда әдәбиятка, журналистикага килүче агым бик саекса да, әлегә иҗади көчләр бар. Беренче чиратта нәшриятның полиграфия базасын аякка бастыру, моның өчен Татарстан хөкүмәтеннән матди ярдәм алу, кадрлар белән эшләүне үзгәртеп кору һәм, әлбәттә, басмаханәне милли китап мәнфәгатьләре белән турыдан-туры бәйләү таләп итела. Бәлки, ул моннан ике-өч ел элек барлыкка килгән идеягә таянып, «Китап» фирмасын (нәшрият-полиграфия — китап сәүдәсе берләшмәсен) төзү рәвешендә гамәлгә ашыр? Бик зур, катлаулы эш бу, әмма тиешенчә аңлау һәм яклау тапканда, андый адымга тәвәккәлләргә мөмкин, һәм ул үзен аклар иде.*

*Нәшриятта да кадрлар мәсьәләсе белән кыклап шөгыльләнәсе бар әле... Нәшрият редакторы булу — авыр иҗат һәм казна хезмәте; ул теләсә кемнең хәленнән килми. Кызганычка каршы, буыннар алышыну үзен бик сиздерә... Әмма бу да күп сәбәпләрнең берсе генә. Соңгы вакытка кадәр журналистлар арасында иң түбән хезмәт хакы китап нәшриятында булды, һәм әле дә ул чагыштырмача түбән булып кала. Нәшрият бик авырлык белән генә елына бер квартира ала; вуз бетереп бирегә эшкә килгән кеше фаразан 120 елдан соң гына баш өстендә түбә булуына исәп тотарга мөмкин.*

* * *

Хатның шул төшендә бүленеп, нәшриятка эшкә килгән көннәремне хәтергә төшердем. Нинди уйлар, хыяллар иде бу башта! Әле ике ел да узмаган, әмма кырыс чынбарлык ул планнарның бер өлешен сытып ташларга өлгерде инде.

Җөмләдән, шигырь китапларын гына алыйк. Күрәсең, алар һәрвакыт нәшриятның авырткан төшедер... Танылган тәнкыйтьче белән әңгәмә корып, берничә ел элек шул замандагы баш редактор шигырьнең кыйммәткә төшүе хакында бик уф орган иде. Шагыйрь кесәсендәге тиеннәрне санау...— шәхсән мин моны хуплый алмыйм. Әмма эт теле кебек юка-юка җыентыкларның зур газаплар белән 1-2 мең данә генә басылып та, кибет шүрлекләрендә тузан эчеп ятуы кемнең эчен пошырмый икән. Шагыйрьләрнең дә затлы тыш кигезгән, рәсем һәм кереш сүз белән бизәлгән, һәр китапханәнең күрке булырлык китап чыгарасы киләдер дип уйлыйм. Ә кем комачаулый соң шундый басмага ия булырга?! Бүген нәшрият, билгеле бер шартлар үтәлгәндә, шигырь китабын нәкъ әнә шулай — затлы итеп чыгару ягында.

Сүз уңаеннан, тормышка ашмас икенче бер хыялымны да әйтим әле.

Мәктәп балаларының букчасын күтәреп караганыгыз бардыр,— бигрәк тә башлангыч сыйныфта укучыларныкын. Ни өчен таш төягән кебек авыр соң алар? Дәресләр күп булгангамы? Әллә соң уку әсбаплары калын булган өченме? Кайбер дәреслекләр икешәр, өчәр, хәтта дүртәр класска исәпләнгән бит. Бала ничә ел буе һаман шул бер китапны күтәреп йөри-йөри туеп бетә. Миңа калса, җиденче класска кадәр һәр дәреслекне ярты еллыкка бүлеп чыгару балалар өчен бик уңайлы булыр иде. Әлеге китапларны тулы көенчә алып килү ихтыяҗы кабатлау дәресләрендә генә туачак. Әмма... Колхоз басуын әзмәвердәй тракторлар белән таптата гына белгәнебез кебек, супер-дәреслекләргә җайлашкан ич без. Әле бер уку әсбабын чыгару мең бәла булганда, аны икегә, дүрткә бүлеп аерым китаплар итү — кая ул, авызымнан җил алсын!

Әлбәттә, болары — «кычытмаганны кашу» сериясеннән... Ә бит, мәсьәләгә җитдирәк карасак, нәшриятның уңай традицияләрен саклаган һәм үстергән хәлдә, аның җитмеш ел эчендә деформацияләнеп каткан структурасы тамырдан үзгәртеп коруга мохтаҗ. Бу — редакцияләрдә, бүлекләрдә хезмәтне оештыру рәвешенә дә, тематик планның эчтәлегенә дә, күпме миләргә кереп оялаган стереотипларга да кагыла. Безнең «эчке» эшләр булып тоелса да, боларны уңышлы хәл итү нәшрият хезмәткәрләренә генә түгел, авторларыбызга, укучыларыбызга да бик бәйле.

Эчке эшләр димәктән, Мөхәммәтдин ага, әнә, кәгазь табу — нәшриятның үз кайгысы дип тормаган... Аңа һәм аның кебек, чит җирләрдә яшәп тә

халкыннан аерылмаган затларга ихтирам хисен хат аша гына җиткереп булса икән...

## Икенче хатның дәвамы

*... Сездәй милләт хадимнәре күбрәк булсын иде, Мөхәммәтдин ага. Инде бит заман шундый: милли китапны Татарстаннан гына көтеп ятыр чак узып бара. Мәктәп дәреслекләрен җибәрүне, мәсәлән, бездән хәзер үк, карлыгач балалары кебек, утыз биш өлкә көтеп тора. Уку әсбаплары-на ихтыяҗ бер ел эчендә генә дә бермә-бер диярлек артты (72 мең сум-нан 136 мең сумга җитте). Якын елларда да әле бу санның үсү тенден-циясе сакланачак. Казанны рухи мәркәзебез дисәк тә, бөтен авырлыкны ул гына күтәреп бетерә алмас бит?! Һич югы дәреслекнең өлгесе бездә әзерләнеп, бастыру эшен урыннарда, җирле типографияләрдә җайга са-лырга кирәк. Заманында Казан, үз өлешенә кертеп булса да, кардәш халык-ларга һәм дәреслеген, һәм уку әсбабын бастырып биргән ич. Әле соңгы елларда да кайсыбер Урта Азия, Алтай халыклары китапны Казанда бас-тыргалый иде. Халыклар тулай торагында хокуксыз өйдәш булып җитмеш еллап тереклек итә торгач, күрәсез, инде үзебез ярдәмгә мохтаҗ булып калдык. Һәр мәхәлләнең үз «әттәхияте»,— мәгәр, әйтик, тугандаш Баш-кортстандагы татар мәктәпләренә дәреслек бастыруны Уфа үз өстенә алса, бу хәл үзара хезмәттәшлекне, якынлыкны ныгыта гына төшәр иде.*

*Тарих хәтерли: заманында татар китабы Россиянең байтак шәһәр-ләрендә басылган. Димәк, аңа ул чакта ихтыяҗ да, мөмкинлек тә булган. Хәзер шул ихтыяҗны һәм мөмкинлекләрне яңабаштан өйрәнәсе, чарасына ныклабрак керешәсе бар.*

*Аңлашыла ки, татар китабын бастыру, тарату мәсьәләсе безне илнең (СССРның) төрле төбәкләре белән эшлекле бәйләнешләр урнаштырырга ча-кыра. Шуңа күрә ул Союз дәрәҗәсендә дә һәм аерым республикалар, шул җөмләдән Россия белән дә махсус килешүләр төзүне ашыктырачак...*

* * *

Икенче хат шулай, күпнокталар белән өзелгән килеш, язу өстәлендә калды, миңа ашыгыч эш белән Мәскәүгә китәргә туры килде. Аннан әйлә-неп кайтуга, көндәлек мәшәкатьләр үз эченә суырып алды. Хатка нокта куярга җай чыкмады да чыкмады. Аннары күңелдәге уй-фикерләрне бер Мөхәммәтдин агай белән генә түгел, татар китабы язмышына битараф булмаган бүтән милләттәшләр белән дә уртаклашасы иде, дигән теләк туды. Бәлки, без аерым-аерым шул хакта уйлап йөрибездер, фикернең уртак булганы да, бәхәскә керердәе дә бардыр. Һәрхәлдә, бу юнәлештә дә җәмә-гатьчелекнең мөнәсәбәте ачыкланырга, сүздән эшкә күчү тизләнергә тиеш бит. Нәшриятның эченнән торып әле бик аз вакыт кына шул хәлләрне күзәтү дә бер нәтиҗәгә килергә мөмкинлек бирә: без пружина кебек тыгыз-ланган көннәр кичерәбез, һәм һәр бирмеш көн йә — татар китабы файда-сына, йә аңа каршы эшли. Йә татар... файдасына, йә аңа каршы...

Кайчандыр күкрәгенә «әллә нинди кара көчләр» басып торганга гына уяна алмаган халык өстенә янә җитмеш кат вәгъдәләр юрганы ябылган. Россиядә сан ягыннан икенче булган милләт — Урал, Казагыстан, Урта Азиягә яңа дәвер мәдәниятеннән ут алып биргән милләт — чыра яктысы кебек бердәнбер нәшриятка карап калды. Дөнья базарына «кара алтын», мех чыгарган, автомобиль, химия, хәрби комплекс гигантларын иңендә кү-тәргән Татарстан җире бүген «эштән чыгарылган татар кызы» хәлендә... Гасыр башында ук: «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» дип ачынган Шагыйрь гасыр ахырында хәл-халәтебез тагы да мөшкелрәк була-сын күз алдына китерә алдымы икән? Югыйсә аның сүзләре әле дә бик ва-кытлы яңгырый: «Әгәр милләтне йоклаган дисәк, дөнья көпчәгенең бу ка-дәр дөбердәп әйләнүенә вә башка милләтләрнең әллә нинди каты вә йөрәк яргыч тавышлануларына уянырга кирәк иде». Әлегә безнең агай-эне (ни аяныч!) өч хәрефкә койрык ялгамакчы булып кеше көлдерә, «татармы без, болгармы?» дип дөнья болгата, тарихына, диненә кагылышлы китап белән спекуляция итә...

Берсе тора да кычкыра: «Ниткән эш ул кәгазь булмау? Бер «КамАЗ»га

бер вагон кәгазь бирәләр!» — ди. Икенчесе: «Нишләп әле нефть саткан акчага алмыйсыз ул кәгазьне?!» — дип четерекле мәсьәләне чишә дә бирә. Шул юл белән кәгазьле булу өчен бер генә нәрсә җитми: китап нәшриятының әлегә ни «КамАЗ» җитештерү, ни нефть чыгару мөмкинлеге юк... Инде артык та беркатлысы: «Таләп итәргә кирәк, бугаздан алып сорарга, фәлән-фәсхет!» — дип кыюлана. Әйтерсең лә... Әйтерсең лә...

Әйе, килер бер көн: матбагачылык та аерым ширкәтләр кулына калыр. Ихтимал, китап басу эшенә спекуляциянең бер рәвеше дип түгел, ә милләткә хезмәт итү мөмкинлеге дип караучы зыялы кооператорлар заманы булыр ул. Кулны һәм зиһенне богаулап торган «планлы-команда» системасы җимерелер. Ул чагында инде бер дивизия зурлыгындагы совет язучылары гаскәре, хисапсыз фән кандидатлары (аеруча миллионлаган графоманнар чирүе!) китапны партия комитетлары, яисә министрлыклар ярдәменнән башка гына чыгару мөмкинлегенә ирешерләр... Әмма вакыйгаларны никадәр ашыктырсак та, бүгенге мәсьәләләр иртәгәсе көн хисабына чишелә алмый. Һәм, сүзне түгәрәкләп әйткәндә, хәзерге шартларда Татарстан җирендәге полиграфия көчләрен, ниһаять, татар халкы мәнфәгатьләрен дә санга сугарга мәҗбүр итми, тәэминат (кәгазь) проблемасын хөкүмәт дәрәҗәсендә хәл итми торып, бер адым да алга китеш булмасы ап-ачык. Икенче адым,— әлбәттә, куәтле полиграфия базасы төзү, аннары нәшриятлар системасы өчен кадрлар әзерләү, татар китабын СССРда һәм чит илләрдә тарату юлларын табу... Санап китүе генә җиңел, боларның берсен дә көмеш табакларга салып китермәсләре шулай ук мәгълүм...

Беләм, Мөхәммәтдин агай да хәзер Мәскәүдән пилмән яумасын яхшы чамалыйдыр, Николай Ивановичтан җавап та көтмидер. Мәскәү белән Алма-Ата каршында мин генә уңайсызрак хәлдә калдым: үзем язган хатлар астына Н. И. Рыжковның имзасын салып җибәрә алмыйм ич инде. Күз алдыгызга киләме, йә:

## Өченче хат (проект)

*Хөрмәтле Мөхәммәтдин Гарифуллович!*
*Сезгә язган ике хатымны берьюлы җибәрергә булдым.*
*Озак хәбәрсез торуыма үпкәләмәгез, якташ.*

*Сәлам белән, Николай Иванович...*

Яисә менә болайрак өстәп куйсаң, күңелгә тагы да хуш килер иде:

Өченче хатның дәвамы (хыял)

*...Халкыгызның ил хәзинәсенә керткән өлешен искә алып, һәм аңа карата күп еллар буе эшләнеп килгән гаделсезлекне бетерү өчен, Татарстанны кәгазь белән тәэмин итү, Союз хисабына Казанда яңа полиграфия комплексы салып бирү мәсьәләләре хәл ителәчәк.*

*Сәлам белән...*

Юк-юк, «Мәскәүләрдән Казан күренмидер»... Якташыннан мондый җавап килүенә барыбер ышанмас агаем. Иң яхшысы — берничә сүз белән хәлне аңлатып үз исемемнән генә язып да, тапшырылмаган хатларны «Казан утлары» аша җиткерергә рөхсәт сорыйм, дип уйладым мин.

*1 ноябрь, 1990 ел*

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# ТАКТАШ ҺӘМ ТАКТАШЛЫК ТУРЫНДА

## (ШАГЫЙРЬНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН)

*Кто прячет прошлое ревниво,*
*Тот вряд ли с будущим в ладу.*

А. Твардовский.



Безнең көннәрдә Такташ исеме тирәсендә егерменче елларны хәтерләткән чыгышлар тагын ишетелгәли һәм күренгәли башлады. «Мәгариф» редакциясе журналның эшчәнлеген активлаштыру турында сөйләшү уздырган иде. Әдәбият буенча программа һәм дәреслекләрнең кимчелекләренә тукталып М. Мәһдиев Такташның «Мокамай», «Алсу»лары, («Киләчәккә хатлар»ын әйтәсе дә юк инде) һәм дәреслекләргә кертелгән башка күп кенә шигырьләре — шул чордагы хәлләрне бозып күрсәтәләр, алар яңа дәреслекләргә кертелмәскә тиеш, дигәнрәк фикер әйтте. Такташны шагыйрь дип укучыларга тәкъдим итмәкчебез икән, чын шигърият үрнәкләре итеп аның башлангыч чор шигырьләрен балалар кулына бирергә кирәк, дигән нәтиҗәгә килгән ул. «Социалистик Татарстан»ның 1990 елгы 1 апрель санында ул бу хакта өлешчә язып та чыкты.

Шәхес культын ихлас өнәмәгән язучы авызыннан культ чоры кайтавазын хәтерләткән мондый фикерләрне ишетү гаҗәбрәк, әлбәттә.

Мирас комиссиясенең чираттагы утырышында А. Әхмәдуллин дә 20-30 нчы еллар драма әсәрләренә үзгәртеп кору чоры югарылыгыннан яңача бәя бирү тиешлеге турында чыгыш ясады. Вульгар социологизм шаукымына юлыккан әсәрләргә мисал итеп ул, башлыча, Һ. Такташның «Күмелгән кораллар», «Камил» пьесаларына тукталды.

Утырышта тагын И. Нуруллин, Т. Галиуллин, Ә. Рәшитов, М. Гайнетдинов чыгышлары булды, шагыйрь иҗатына капма-каршы бәяләр куелды.

Ә безнеңчә эш болайрак тора.

Һади Такташ яңа җәмгыятьнең тирән эчке проблемаларын дөрес сиземләде, тапты һәм аларны чагылдыруда талант, иҗади тапкырлык күрсәтте. Бу казанышлар: «Әдәбият — иҗтимагый һәм рухи эшчәнлекнең мөстәкыйль бер тармагы, ул чикләнмәгән мөмкинлекләргә ия»,— дигән карашка нигезләнгән иде. Әнә шул идея Такташ иҗатының төп пафосы булып тора. «Җир уллары трагедиясе» (1923) дигән беренче җыентыгына бирелгән «Иҗадиятем турында» исемле кереш мәкаләдә Такташ — яңа заманның яңа шигърияте иске классика казанышлары дәрәҗәсендә булырга тиешлеген генә әйтми, ул классика казанышларының үстерелеше,— чорга җавап бирерлек яңа баскычка, яңа югарылыкка күтәрелү булырга тиеш, дигән таләп белән дә чыга. Шунда гына әдәбият үз алдына куелган бурычларны үтәгән булыр. Мондый карашның хыялый ашкыну, нигезсез, җирлексез дәгъва гына булмаганын Такташ үз иҗаты белән раслады да. Ул, яңа һәм үтә катлаулы шартларда, әдәбиятыбызны Тукай казанышлары белән ярышып яңәшә яши алырлык, үлемсез шигърият хәзинәләре белән яңа югарылыкларда ныгытып калдырды. Аңа киләчәккә барырлык ышанычлы «старт мәйданы» җулады.

«Җырланмаган җырлар турында» (1926) шигырендә:

*Ә җырлаучы кайда шул хисләрне? —*
*«Җырчы» урыны көтә ияен! —*

дигәнендә дә, «бөек елларның» «җыр Ленинын» тудыра алу көченә ышаныч бар. Зур эшләрдә — зур талантларга таянырга диган сүз бу.

Шул ук көннәрдә Такташта чагылган бу тенденциягә капма-каршы максатларны кыйбла иткән икенче бер юнәлеш тә мәйданга чыга. Бу юнәлешнең нигез принцибы шуңа кайтып кала: тормышны, идеологияне нигездән яңарту эше — революция, партия, Совет дәүләте тарафыннан башкарыла. Яңа әдәбият алдында да шул ук максатлар тора. Димәк, яңа пролетар әдәбияты да «яңабаштан чабата уйлап табу» белән шөгыльләнмәскә, ә бәлки партия һәм дәүләт карарларын сәнгать чаралары белән халык арасында популярлаштырырга гына тиеш! Тыштан караганда, бик тә дәлилле, чынлыкка туры килә торган караш кебек. Әмма... Бүгенге хәлләр яктылыгында һәм хәзерге ераклыктан караганда, аның хата алшартларга нигезләнгән булуы аңлашыла. Ул — ясалма һәм абстракт нигез.

Биредә Богданов ялгышулары һәм пролеткультчылык теорияләре коньюктур максатлар җирлегендә абсолютлаштырыла. Пролеткультчылык нигезендә «буржуаз»-лык тамгасын басып, культураның үткәндәге казанышларыннан баш тартырга, умыртвсыз модернизмның сәнгатьне җимерүче принципларына капкалар киң ачыла. Революция һәм максатлар уртаклыгы яңа рус әдәбияты белән татар әдәбияты арасын да күрелмәгән дәрәҗә якынайта. Шул җирлектә Богданов һәм пролеткульт принципларын татар әдәбиятына тулысынча күчерү мөмкинлеге туа. Менә шул «якынаю», «яңалык» үзенчәлекләре аны татар әдәбиятына революция китергән яңалык, яңа күренеш итеп таныту мөмкинлекләрен бирә. Тик бу «яңалык»ның кысыр яңалык булганын гына ул чакта тулы төсмерли алмаганнар!

Шуңа күрә тормышта нәкъ менә киресе килеп чыга: җанлылыкка, талантлылыкка (асылда, прогресска) каршы үлем сугышы алып барса да, бу юнәлеш җиңүдән җиңүгә, тантанадан тантанага гына атлый... Тормышта да шул тенденция тантана итүнең җимеше буларак: шәхес культы, торгынлык, безнең көннәрдәге тирән социаль-экономик һәм политик кризис мәйдан тота.

Мондый шартларда җәмгыятьтә микроб урынына үрчегән карьерист, авантюрист элементларның активлыгы күтәрелә. Сәнгатьчәлектән качу һәм «пролетарлык», үзләрен һәрнинди әхлакый чикләүләрдән азат дип санау, әдәбият-сәнгатькә һичнинди катнашы булмаган әлеге элементларның бу юнәлешкә күпләп сарышуларына китереп чыгара. «Пролетар» атамасын үзләренә калкан, түбән максатларына пәрдә итеп алып, алар үз ишләрен яклаучы төркемнәргә укмашалар. Тормышта үз «күсәкләре» хөкемен урнаштыру эшенә ташланалар.

Такташ юнәлеше хәтта әдәбият өчен чит булган менә шул әрсез элементларны да берникадәр үзенә тартты. Әдәбият мәйданында Такташ бар икән, аны күпме генә хурламасыннар, болар да аның белән «ярышырга», шул юнәлештә, ачулы-үртәнүле ниндидер эшчәнлек күрсәтергә мәҗбүр булалар. Мисал өчен, Такташ бер уңышлы шигырь яза икән, икенче көнендә үк диярлек шул мотивка «яңа әсәр» мәйданга килә. Әмма *мондый* мәҗбүри «казанышлар» күп түгел, уңышсызлык күбрәк. Ләкин үзләренең «яңа», «саф сәнгать»ләре үрнәкләрен мәйданга куя алмауларын, тискәре нәтиҗәләргә генә ирешүләрен дә алар башлыча «буржуаз» комачаулыкларның мәкерле аяк чалу нәтиҗәсе итеп аңлаталар. Кыскасы, бу юнәлешнең нигезсез дәгъвалары, һәртөрле эшлеклелек, сәләткә, талантка үчегү, шелтәгә генә әйләнә.

Бу юнәлеш безнең әдәбиятта, илдә беренчеләрдән булып, пролетарлык монополиясен үз кулына ала. Моның да, әлбәттә, тарихи сәбәпләре бар. 1921 елда Идел буе коточкыч ачлык дәһшәтен башыннан кичерә. Революция ялкыны дөрләткән иҗтимагый активлыкны ачлык нык зәгыйфьләндерә. Бу хәлләргә яңа күңелсезлекләр ялганып китә. 1923 нче елда Үзәк мөселман коллегиясе рәисе, милли-азатлык лидерларының берсе М. Солтангалиев, беренчеләрдән булып, Сталин репрессиясенә юлыга. Ә карьеристлыкны көсеп иткән намуссыз элементларга файдаланып бетерә алмаслык яңа зур мөмкинлекләр ачыла. Һәр төбәктә, һәр шәһәрдә, һәр оешмада «солтангалиевчелек»кә каршы ярсу көрәшләр оештырып җибәрелә. Менә шул коньюктурада инде безнең татар әдәбиятындагы әлеге «пролетар» юнәлеш тә үз дәгъвалары белән мәйданга ташлана. Шунысы үзенчәлекле: аның (безнең белүебезчә беренче тапкыр) «зур көрәш»кә чыгуы — теш күрсәтүе дә нәкъ менә — чын талантларга һәм Такташка каршы тупас, пычрак һөҗүмнәрдән башланып китә. «Чаян» журналында «Җылтыр күз» диган берәүнең «Шакшак шагыйрь булды ди» диган пасквилен бастырып чыгаралар (1923, № 4). Моннан башка да, бүген инде безгә билгесез ниндидер формаларда, Такташка көчле басым ясаулар булган, күрәсең. «Такташ үлде» диган шигырь белән шагыйрь үзенең шуннан элеккеге иҗатыннан, рәсми рәвештә диярлек, ваз кичәргә мәҗбүр ителә. Әмма бу да инде аны әзәр-

текләүдән коткарып кала алмый. «Татарстан» газетасының 2 нче декабрь (1923) санында Кави Нәҗминең 20—50 нче еллар политик доносларының «өлгесе» һәм беренче үрнәге булган «Такташизм» дигән язмасы басыла. «...изм»нар, «...щина»лар тамгасы белән башлар чабыла башлаган бер заманда, бу «сигнал»ның максаты — сукырга да күренерлек дәрәҗәдә ачык.

Аның нигезендә Такташның башы җилкәсеннән тәгәрәми калган икән, мәкаләдә сыланган гаепләр азлыктан түгел. Башка комачаулыклар килеп чыга. «Идел» (1989, № 6) журналында басылган «39 хаты»ннан күренгәнчә, авторитарлыкка йөз тоткан режимның үз халкы язмышы турында уйланырга батырчылык иткән татар җитәкчеләрен «Солтангалиев артыннан» озатырга җыенган көннәре була бу. Татар әдәбиятындагы инде көчкә сулу алган сәләтле, инициативалы юнәлешне аҗгырып килгән карьерист һәм авантюристлар юнәлеше болай да буып тончыктырасына, күрсәң, югарыда ышаналар. Такташ мәсьәләсен баш чабарлык дәрәҗәгә күтәрмәскә булалар. Шул ук «Татарстан»да әлеге юнәлешнең тагын бер вәкиле Г. Толымбайның «гильотинага» «отбой» уйнаган, «Такташизммы, әллә аңламаумы?..» дигән мәкаләсе урнаштырыла (1923, № 230). Әмма бу әле Такташ юнәлешенә басым ясаулар туктатылган дигән сүз түгел. Киресенчә, шагыйрь гомеренең азагына кадәр, инде ул басымнар көннән-көнгә көчәя, төрлеләнә генә бара: хурлыклы «әдәби суд»лар, әзәрлекләүче, мәсхәрәләүче мәкаләләр, пасквильлар («Кара малай», «Вак бур» имзалары белән — «Чаян», 1927, № 11 һ. б.), гаиләсен җимерү һәм эштән куулар, ачлык газаплары һәм «кулак җырчысы», «мистик», «анархист», «индивидуалист» кебек, ул чор өчен мыскыллы атамалар...

Шагыйрь «совет язучысы» дигән исемне ишетә алмый үлә, аны иң яхшы очракта, «юлаучы язучы» («попутчик») исеме белән йөртәләр. Менә шундый ачыктан-ачык тупас әзәрлекләүләр, талантлы булганы өчен генә законнан тыш хәлгә куелу шартларында да Такташ үзенең олы шагыйрьлек миссиясенә туры кала. Татар совет поэзиясенең җәүһәрләре булган, мәңге шиңмәс эстетик накаллы «Мокамай», «Алсу», «Киләчәккә хатлар» һ. б. әсәрләрен шигъриятебезнең якты йолдызлары итеп кабызып калдыра. Әгәр ниндидер детальләрдә ул, сафта калу, шигъриятебезгә тагын һәм тагын кабатланмас әсәрләр бирә алу өчен, компромисска барырга мәҗбүр булган икән, моны аның кимчелеге итеп түгел, тапкырлыгының күпкырлылыгы, оперативлыгының тагын бер дәлиле дип кенә бәяләп була. Яңа әдәбиятыбызның Тукай иҗатына тиңләшерлек бер терәк баганасы булган шигърияттен тормышта ул менә шул бәягә сатып алган.

...Такташны күмү — халыкның олы һәм с екле шагыйре белән хушлашуга әйләнә. Бу аны, шундук, «юлаучыдан» — «күренекле совет шагыйре»нә әйләндерә. Мондый данлы шәхес белән дуслыкның файдасын «тегеләр» дә шундук чамалап өлгерә. «Иң якын дус» буларак, хушлашуларның башында торалар. Тормышта булып үткән бәйләнүләр, өнәмәүләр, ызгышлар юкка чыга, китаптан китапка күчеп йөри торган «дуслык» кына кала. Һәм ул безнең көннәргә кадәр, «гади укучылар» өчен язган китапларда шулай аңлатылып килене.

Бүгенге көнгә кадәр Такташ иҗатының тәнкыйтьтә яктыртылуы, асылда, 20 нче еллар билгеләмәләреннән уза алмый. Шагыйрьне бәяләүдә бу кысалардан чыккан ике генә очрак бар: шул эш өстендә янып үлгән З. Искужның мәйданга чыга алмаган монографик хезмәте һәм М. Маминның «Һ. Такташ поэзиясе» дигән монографиясе (1941, 1952). Ә башка хезмәтләр: Х. Хәйринең «Һади Такташ» (1949), Х. Госманның «Такташ поэзиясе» (1953), «Егерменче елларда татар поэзиясе» (1964), Г. Халитнең «Герои, рожденные революцией» (1967), «Шагыйрь, чор, герой» (1971), «Поэзия дерзаний» (1980) «Такташ — мистик, анархист индивидуалист, вак буржуаз бунтар, революцияне аңлый алмаучы» кебек нигезсез сафсаталарны һичнинди үзгәртүсез, тагын да бераз үтемлерәк формага кертеп әдәбиятта саклап калырга, яшәтергә тырышудан башка нәрсә түгел. Безнең барлык «тикшерүче»ләребез менә шул кысыр хәсрәт белән мәш килгәнгә күрә, байтак китаплар язылуга да карамастан, Һ. Такташ иҗатының чын мәгънәсен чагылдыручы фәнни өйрәнелү дәрәҗәсе, нигездә 20 нче еллар чикләрендә кала килә. Хәер, 30 нчы еллар башында тагын бер тәнкыйтьчене «күсәкләп» алалар. Шагыйрьнең дусты Г. Гали Һ. Такташ үзе исән көннәрдә чыккан иң күләмле, соңгы җыентыгына (1930) сүз башында аны «советчыл позициягә карап үсүче» итеп күрсәтергә теләве шунда ук Г. Нигъмәтинең «төзәтүе»нә юлыга: юк, Такташ вак буржуаз нигилист янәсе... Г. Галинең 1936 елда шул юнәлештә тагын бер мәртәбә талпынып каравы кабат шул ук язмышка — тагын Г. Нигъмәти «төзәтүе»нә юлыга. Шуннан соң инде, күргәнебезчә, Г. Гали омтылышына охшаш «ялгышучы»лар табылмый. Киресенчә, безнең көннәргәчә, әдәбият бар игътибарын, теге — 20 нче еллар тамгаларын, бераз тәмләләндергәләп, түкми-чәчми саклап яшәтә...

Илдә XX съездны әзерләгән шартлар һәм шуннан соңгы хәлләр Такташ юнәлешенә якын торган Г. Афзал, Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәт кебек талантларны мәйданга чыгарган иде. Хәзер алар, кайсы өлкәнәеп, кайсы — тормыш басымы астында, инде шак-

тый сүлпәнәйделәр. Ә аларга алмаш булырлык яңа көчләр өстәлмәде кебек. Газ вулканнары кебек, басым артык та көчәйгән вакытта ухылдалап, күбекләнеп куюны хәтерләткән аерым фактларны бу юнәлешнең яшәве, җан әсәре күрсәтүе дип билгеләү мөмкин түгел.

Ләкин, аның каравы, әлеге «пролетар» юнәлешнең дәвамы исә, шәхес культы һәм «изге Лаврентийлары» (Берия) «өшкерүе» бәрәкәтендә, яхшы сәгать механизмы кебек төгәл «эшчәнлек»кә ирешкән. Алар арасында «кыйбласын» ялгыштырып, «хаталану»ларга юл куйган бер генә җан иясе дә юк! Һәр кайсы үз «урынын», үзе нәрсә мәтәштерергә тиешлеген абсолют белә. Моның сыналган механизмы борып, кузгатып җибәрелгән. Ә намус, оят, әхлак, идеал кебек сыйфатларга «Берия тарикатендә» инъекция ясалып, «паралич» суктырылган. Болар хәзер теләсә нинди рольгә керә белүче «артист»ка әйләнгән. Креслода утырып, әшләмичә генә учлап-учлап акча күрәү максаты аларга тартынмаслык тапкырлык бирә. Үзара яклашу, буйсыну мәҗбүри булган субординация, башка юнәлеш кешесенә юл бирмәү...— Аларның бөтен төгәллекләре менә шул примитивлаштыруга кайтып кала. Шул юл белән алар җәмгыятьнең һәр күзәнәген үрмәкүч пәрәвезе кебек каплап алуга ирешкәннәр. Шуңа күрә, кайсы күзәнәктә җанлану әсәре төсмерләнгәнен шунда ук сизәләр. Андый җанлану төсмере сиздергән «күзәнәк»не шундук чагып, җанлылыкны паралич суктыра торган, «үрмәкүч»лекне кәсеп иткән «аучы»лар да бар... «Җиңү» дигән нәрсә идиллия түгел шул! Ул сиңа, үзеннән-үзе генә килеп керми... Такташлар исә (намус, сәләт, талант ияләре) мондый, «үрмәкүчлек»кә бара алмыйлар. Алар бу дөньяга, «алырга» түгел, «бирергә» килгән затлар. Үткән заманнарда, талант, илһамлылык — ходай бүләге, илаһи билге саналган: аны кабул итә алмасалар да, аны эзәрлекләргә, юк итәргә батырчылык итмәгәннәр — аның яшәргә хокукы булган. Тарихта, прогрессны буучы, һәр нинди җанлылыкны туңдыручы буларак танылган Николай Палкин, Бенкендорфларның тулы җиңү тантанасы кичергән көннәрендә Н. В. Гоголь, В. Г. Белинский кебек титаннар калкып чыга. М. Ю. Лермонтов, Н. А. Некрасов, И. С. Тургенев кебек рус әдәбиятының горурлыгы булган дистәләгән олы талантлар мәйдан да яулый, таныла да алганнар. Булгарин, Греч һ. б. кебек «үрмәкүчләре» булса да, күрәсең, аларга талантларны параличлый торган итеп чагырга ирек бирмәгәннәр...

Ә безнең әдәбияттагы «пролетар» юнәлеш исә, күргәнебезчә, Такташ юнәлешен хәрәкәтсез калырлык итеп «чага» алган. Моның нәкъ шулай икәне Такташка хәзерге кизәнүләр белән дә дәлилләнә. Алар инде «хәрәкәтсез калган» юнәлешнең юлбашчысы Такташны — яңа әдәбиятыбызның Тукай кебек үк терәк баганасы булганын танырга теләмиләр. Ул терәкне аударгач, үзләре аның урынына «терәк багана» булып калмасмы дип өметләнәләр, күрәсең. Әмма моның киресенә аларны ышандыру инде мөмкин түгел: ничек инде, аларга шул кадәр «җиңүләр» китергән, зур хезмәтсез генә дәрәҗәле исемнәр бирә алган «престиж Кресло»сы төтен генә булсын ди?!

Егерменче елларда ук маңгайга-маңгай килеп бәрелгән каршылыкларның бүгенге торышы һәм көчләр нисбәтенең чагылышы менә шундый... Бүгенге бу ике тенденция, күргәнебезчә һәм алда билгеләгәнебезчә, бер медальнең «иләк» һәм «күн» яклары булса да, аларны бер эстетик күренешнең — бер әдәби юнәлешнең ике ягындагы йөзе чагылышы дип уйлау хата булыр иде. Такташ, югарыда әйткәнебезчә,— прогрессив яңару көрәшчесе, югары талант, намус һәм активлык гәүдәләнеше. Ә Такташны тәнкыйтьләүчеләрдә, каршы көчләрдә нинди дер активлык һәм күпмедер сәләт билгеләре гәүдәләнеш тапса да, аларның социаль-идеологик юнәлеше һәм кыйбласы Такташ юнәлешеннән төптән аерыла. Алар — капма-каршы якка омтылышлы күренешләр. Теге чактагы «такташизм» кебек чыгышлар һәм бүгенгә кадәр Такташ юнәлешенә каршы ачыктан-ачык көрәш бару — безнең бу нәтиҗәнең уйлап чыгарылган нәрсә генә түгел икәненә ышандырырлык дәлил.

Такташны аңламаучылар элек, культ һәм торгынлык чорларында Такташ иҗатының гыйсьянчылык чорын (аякларын билгә кадәр) чабып ташлаган булсалар, инде хәзер (гәүдәсен-башын чабып ташлап), гыйсьянчылыктан соңгы чор иҗатын әдәбияттан чыгарып атып, укучыга бирергә телиләр. Рәхәтләнегез! Мондый кискен «үзгәртеп кору» бары тик безнең татар башында гына туа ала торгандыр! Егерменче елларның «Кара малай»лары моны күрә алса, үзләренең ни дәрәҗәдә «җебегән» булганлыкларын күреп, чәчләренә кадәр кызарырлар иде мөгаен...

Юк, болай ярамый!

Егерменче елларда «аякларын» чабып ташлап «төзәтелгән», «яхшыртылган» Такташны, бүген «гәүдәсен» чабып ташлап, аякларын гына калдырып «яхшырту», «төзәтү» дөрес түгел! Аның талантының үзенчәлеген — конкрет социал һәм идеологик йөкләмәсен, юнәлешен, татар әдәбиятындагы урынын һәм эволюциясен ныклап ачыкларга кирәк!

Мәсгут ГАЙНЕТДИНОВ.

# ЕГЕРМЕ БЕРЕНЧЕ ЕЛ АВАЗЫ

Соңгы вакытта татар әдәбиятының хаксызга онытылган исемнәрен, әсәрләрен кабаттан киң катлау укучыга кайтару юлында җитди эшләр башкарыла. Әдәби мирасыбызда ак калган тапларны бетерү әдәбият тарихын тулырак кына түгел, ә чын, дөрес итеп күзалларга мөмкинлек бирәчәк.

Бу өлкәдә бәхәсләр башлыча татар мәдәниятының титаны Гаяз Исхакый мирасы тирәсендә барды һәм бара. Әмма тыюлардан инде күптәннән азат булган классик язучыбыз Г. Ибраһимовның да бүгенге гади укучыга мәгълүм булмаган хезмәтләре һәм әсәрләре бар бит әле. Биредә әдипнең 8 томлык әсәрләр җыентыгына керми калган «Әдәбият кануннары», «Татар мәдәнияты нинди юл белән барачак?» кебек күләмле һәм бүгенгесе көндә дә кыйммәтләрен югалтмаган китапларын атап үтү дә җитәдер. Аларның басылмавы беренче чиратта заман чире — өстән расланган күләмнең сыйдырмавы белән бәйләп аңлатылды. Хәзер инде бу алымның яңа төшенчәсе барлыкка килде — бүген ул хәл «кәгазь кытлыгына» барып терәлә.

Әмма Г. Ибраһимовның соңгы тапкыр 1931 елда дөнья күргән «Адәмнәр» повестена караш та, мөнәсәбәт тә, бәя дә башкачарак булды. Кыска гына итеп әйткәндә, бүгенге көнгә кадәр татар әдәбият белеме ул әсәрне кабул итә алмады, аннан гел читләшергә тырышты, һәм повесть егерменче елларда бирелгән бәяләмәләр белән әдәбият тарихының иң күләгәдәге урынында кала килде.

Бол…рны хәл кадәри күз алдына китерү өчен повестьның язылу тарихына килик.

«Адәмнәр» 1923 елда тәмам була һәм шул ук елны 3000 данә белән Казанның «Шәрыкъ» нәшриятында басылып та чыга.

Бу чорда инде Г. Ибраһимов зур, талантлы язучы, күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм киң кырлы эшчәнлеккә ия галим булып танылган. Аның басылуга ук татар әдәбияты тарихында лаеклы урыннарын алган «Яшь йөрәкләр», «Безнең көннәр» кебек романнары җәмәгатьчелекнең даими игътибар үзәгендә тора. Шул дәвердә кинәт язучының «Адәмнәр» повесте дөнья күрә.

Повесть «1921-22 елларда Идел-Урал буйларында булып үткән трагедияләр» турында сөйли. Г. Ибраһимовның бөтен башка әсәрләреннән аермалы буларак, «Адәмнәр» тулысынча кара, дәһшәтле картиналардан гына тора. Без, гадәттә, тарихтан укып 1921 елда Идел буенда булып узган ачлык афәте турында белә идек. Ләкин факт буларак кына тиз-тиз әйтеп үтелгән ул җөмләләр халкыбыз өстенә ябырылган (ә Идел буе ул — татарлар яши торган төп төбәк) коточкыч фаҗигане берничек тә тулысынча аңларга да, төшенергә дә мөмкинлек бирмәделәр. Әгәр дә без, Татарстанда бүген татарларның бары тик чирек генә яши дибез икән, аның сәбәпләренең берсен (барысын да түгел!) әнә шул дәһшәтле вакыйгалардан эзләргә кирәк. Әсәрнең фикер сөрешеннән мәгълүм булганча, ач үлем куркусыннан аяк өсте тора алган шәүлә-мәетләр Кавказга, Себергә, Урта Азия якларына юл алып, шунда чәчелгәннәр, сибелгәннәр, эзсез югалганнар. Без ул югалтуларның дәрәҗәсен һәм ачы нәтиҗәсен әле бүгенгә кадәр төшенеп җитә алганыбыз юк. Корт оясына таяк тыгып болгаткандай татар милләтен тәмам туздырып, бутап, таратып ташлаган әнә шул вакыйгаларны, чын талант һәм үз халкына бирелгән фидакарь буларак, Г. Ибраһимов һич ничек тә уратып уза алмады. Милләтнең, гомумән, бу төбәктә яшәгән халыкларның киләчәге өчен чиксез борчылган әдип каләменең бу очракта якты буяуларга мөрәҗәгать итә алмавы (яки теләмәве) һәм чынбарлыкны аллы-гөлле буяуларга манмый гына, бөтен кырыслыгында сурәтләргә тырышуы аклана да, аңлашыла да. «Ул коточыргыч авыр ачлык елның тирән куркыныч трагедиясен әйтеп бирергә адәм теле җитәчәк түгел!» — ди автор. Коточкыч ачыгу нәтиҗәсендә акылдан шашарлык булган, кеше ите ашауга барып җиткән адәмнәрнең кылганнары — кырыс. Хәтта, әйтергә кирәк, фактографик, натуралистик тәфсиллек белән сурәтләнгән өлешләрне уку җиңел түгел. Ул вакыйгалар күңелдә авыр, гаять авыр тәэсир калдыралар. Ләкин бу да бит — тарих, болар бит бар да үткәндә булган хәлләр. Чынбарлык никадәр ачы булса да, аны ничек бар шулай кабул итми торып, хакыйкый үткән юлны күзалларга мөмкин түгел.

Повесть беренче җөмләсе белән үк укучыны дәһшәтле вакыйгалар эченә алып кереп китә:

«Үлем үзенең кара канатларын җәйде. Җир йөзе гүя шуның астында капланып калды. Тирә-як куркыныч караңгы каберлекләр, ләхетләр белән, бер үлгәч терелеп чыккан җанлы мәетләр белән тулды».

...Авылның иң хәлле кешесе, рибачысы (ростовщигы) Намаҗан үзенең бертуганы Галим картның хәлен белергә килә. Шунда ачлыктан читән буенда егылып җан биргән картны бер ала эт талап, актарып ятканын күрә...

Сюжетта берсеннән-берсе җан өшеткечрәк картиналар кинокадр кебек алмашынып торалар. Менә Намаҗан белән урамда беренче очраган Гәрәй атлы кеше үлекне күтәреп якындагы келәткә (чөнки кабер казырлык кеше дә, көч тә юк) — башка мәетләр янына илтеп куялар. Шунда келәттәге үлекләр арасында ыңгырашкан

тавыш ишетәләр. Карасалар, ул Гәрәйнең үлгән олы кызының кияве Миңлебай булып чыга, тифтән һушсыз егылгач, үлгәнгә санап аны монда китереп ташлаганнар икән. Гәрәй шашынып аны йолкырга, елый-елый өстерәргә, тарткаларга керешә.

Шуннан соң вакыйгалар Гәрәйләр йортына күчә һәм төп фаҗига шушында башкарыла да инде. Язучы әнә шул бер гаилә мисалында авыр трагедияләрнең дәһшәтле күренешләрен укучыга бәян итә.

...Гәрәйнең хатыны Сабирә тиф хәстәсеннән каты авырып ята. Олы кызы Зәйнәп, улы Зәйни аяк өстендә йөрсәләр дә, кече кызы Нәфисә ачлыктан ятып кына тора. Шуларга авыру Миңлебай да килеп өстәлә. Ачлыктан ябыгып бит тиреләре тартылган, карт-карчыклар чырае кергән балаларының аянычлы хәленә нишләргә белмәгән Гәрәй чарасызлыктан йортта булган соңгы әйберне — казанын Намаҗан байга өч кадак алабута онына сатып кайта. Әмма Сабирә ризык кабудан узган, ул бик авыр газаплар белән җәфалану соңында вафат була.

Гаять дәрәҗәдә ачыгудан интеккән авыл кешеләре соңгы чарага керешәләр: әз-мәз онга тирә-юньнең бөтен җиһазын, мөлкәтен җыеп бетергән Намаҗанның өен басып, икмәген алырга уйлыйлар. Әмма бу эш тә көткәнне бирми: хуҗа үзе каравыл кычкырганда буып үтерелә, ә бик нык яшергән икмәген ни кадәр эзләсәләр дә таба алмыйлар.

Кыш уртасында аеруча авыр, караңгы көннәр башлана. Миңлебай әзрәк терелгәч, «үлсәк, юлда үләрбез» дип Гәрәйдән фатиха алып, үзе белән Зәйнәпне дә ияртеп бер тарафка чыгып китәләр. Ачлыкның «корыч тырнаклар белән карынны кысып актык канны суыруына чыдый алмаган» Гәрәй ахыр чиктә этен суя. Бу да озакка бармый. Ачыгу соңгы чиккә җитә. Шушында язучы ачлыкның төс-кыяфәткә генә түгел, ә иң куркынычы, кешенең психологиясенә сугуын күрсәтә. Ачлыктан шешенә башлаган ата кеше фикерендә ялгыш, буталчык төшенчәләр барлыкка килә... Ул кинәттән балаларын танымый башлый, киресенчә, туганының кызын үзенеке итеп күз алдына китерә. Ахырда үз балаларына сәерсенеп, дәһшәтле күз карашлары белән озак карап тора да, шашып, кечкенә кызының бугазына пычак сала... Бу урында Г. Гобәйдуллинның «Вестник научного общества Татароведения» журналының 1925 ел, 1-2 санында әсәргә карата әйткән фикере гыйбрәтле: «Адәмнәр»дә татар авыл тормышы фонында ачлык сәбәбеннән туган кеше ашаучылык психологиясенең эволюциясе тасвирланды. Биредә материалист автор ачлыкны сурәтләп һәм урта кул крестьянның иң нормаль психикасына коточкыч тәэсир итүен күрсәтеп, җинаять экономикага баглы булуын ачып бирде».

Канлы дәһшәт белән башланган әсәр фаҗигаләр белән төгәлләнә дә. Кылган җинаяте өчен кулга алынып, калага озатылган Гәрәй төрмә камерасында асылына. Улы Зәйни дә, шәһәр урамнарының берсендә каңгырап йөри торгач, хәлсезлектән егылып, кар астында үлә.

Шул рәвешле повестьның башыннан ахырына кадәр кан, дәһшәт, җан өшеткеч сурәтләр, коточыргыч тасвирларның ургылышы бара. Шуңа күрә «Адәмнәр»не «дәһшәт әсәр», «фаҗигаи әсәр» дип билгеләргә мөмкин булыр иде.

«Адәмнәр» басылып чыгу белән әдәби тәнкыйть аны мәгълүм бер сагаю белән каршы алды. Г. Толымбайский («Татарстан», 1924, 9 январь) әсәргә кайбер өстәмәләр һәм төзәтмәләр керткәннән соң «эшче-крестьян укучыларының күзлегеннән үткәрелергә тиешле» дигән фикер әйтә. Ш. Госманов исә, повестька кискен тәнкыйть белән чыга («Безнең юл», 1924, 3 сан). Биредә «советлар хөкүмәтенең ачлык белән көрәшү юлында иткән фидакарьлеге, ачлык фәлакәте астында калган авылга ярдәм кулы сузганлыгы» сурәтләнмәвен әйтеп, гомумән, «Адәмнәр» «пролетариат әдәбияты сафыннан чыгарылып ташланырга тиеш» дип нәтиҗә ясый. Бүгенге әдәбият белемендә исә «Адәмнәр» Г. Ибраһимовның социалистик реализм методын үзләштереп бетерә алмавыннан туган уңышсыз бер әсәр дигән фикер ныгып урнашты.

Шунысы аянычлы, бүгенге укучы әсәрне укып үз бәясен чыгару мөмкинлегеннән мәхрүм калды. Без шулкадәр күнеккәнбез, һәрбер әсәр уңай төгәлләнешкә ия булырга тиеш дип ышанып килгәнбез. Хак анысы, героик үткәннәргә бай безнең тарихыбыз. Шул ук вакытта халкыбыз узган юл гаять дәрәҗәдә фаҗигале дә.

Бу повесть ил тарихында мондый дәһшәтле фаҗига бүтән кабатланмасын өчен кешелекне кисәтү иде. Канкойгыч гражданнар сугышы, урыны-урыны белән рәхимсез талау рәвешен алган продразверстка (1918—21 елларда хәрби коммунизм чорында азык-төлек әзерләү системасы) нәтиҗәсендә күпләр, бик күпләр ач үлемгә дучар ителделәр. Ачлык гасырлар буе яшәп килгән әхлакый принципларны һәм тыюларны, мораль кагыйдәләрне җимерде. Монысы күпкә аянычлырак иде. Җәмгыятьне әчтән тарката торган куркынычлы көч иде бу. Г. Ибраһимов шул хакта чаң кагып, кешелекне уяу булырга чакырды. Повестьның 1931 елда икенче тапкыр басылып чыгуы да шул хакта сөйли.

Шушыннан соң бер генә ел узар: ачлык афәте, тагын да дәһшәтлерәк көч белән котырынып, халык өстенә ябырылыр. Ләкин 1932-33 елларда миллионлаган җаннарны алып киткән ачлык турында инде әдәбият дәшмәс. Шәхес культы корбаны булган Г. Ибраһимов та бу хакта киләчәк буынга сөйләп калырга өлгермәс. Язучының соңгы кисәтүе инде 60 елга якын укучы игътибарыннан читтә калып килә... Тарихның ирексез онытылып, мәҗбүри күмелеп калган вакыйгаларын барлау бурычы безгә — исәннәргә йөкләнә...

Инде «Адәмнәр» повестеның 1931 елгы басмасына килик.

Әсәр язучы тарафыннан тагын бер кат редакцияләнеп чыгылган. XV бүлекнең уртасына кадәр (повесть унсигез бүлектән тора) үзгәрешсез диярлек бара. Аерым җөмлә төзелешенә кайбер төзәтмәләр кертелгән һәм кайбер персонажларның исемнәре үзгәртелгән (Сабирә — Сатирә, Зәйнәп — Бәхрия). XV бүлек уртасыннан исә «Адәмнәр» бөтенләй үзгәртеп язылган. Биредә ач авылга ярдәм килү күренеше өстәлгән. Тәнкыйди фикерләрне искә алып, язучы аерым эпизодлар керткән (яки кертергә мәҗбүр булган) һәм шуның белән әсәрнең дәһшәти көчен киметкән, дип уйларга һич тә ярамый. Г. Ибраһимов үзенең талантлы каләме белән шул кисәктә дә ачлыкның тетрәндергеч картиналарын тагын да калкурак итеп сурәтли алды. Менә бер генә мисал:

...Юл буйлап шәһәрдән ярдәм олаулары килгәнен ишеткәч, ач, хәлсез, тере мәетләр соңгы тамчы көчләрен туплап шунда ташланалар. «...ач күләгәләр бер-берен таптап, алдагы чаналарда кар сырып бетергән капчыкларны берәм-берәм өстерәп тарткалап, җиргә кар өстенә тәгәрәттеләр, хәлсез куллары, зәңгеләдән йомшарган тешләре белән газапланып капчыкларны ертып-ертып җибәрделәр, чана тирәсе кар белән тулды....һәммәсе җиргә ташландылар, ертык капчыкка тыгылдылар, каушап, калтырап, карлы бәрәңгеләр белән авызларын тутырдылар, дөньяларын онытып, йотлыгып ашарга атылдылар».

Олаулар килгәч, авылга бераз өмет, җан керә, ләкин Гәрәй гаиләсенә инде ул кагылмый. Беренче басмада Гәрәй төрмә камерасында үлгән итеп күрсәтелсә, икенче вариантта ул, җинаяте өчен авыл халкы тарафыннан рәхимсез кыйнап ташланганнан соң, өстерәлеп чыгып ишек алдында асылына.

1921-22 елгы ачлык вакыйгаларына багышланган әсәр дәһшәтле сурәтләүдән башланып, фаҗигале ноктада тәмам була.

Соңгы сүз итеп әйткәндә, повестьның ике басмасын да тикшереп өйрәнгәннән соң, әдәбиятыбыз тарихының буш калган урыннарын тутыру җәһәтеннән «Адәмнәр»не киң катлау укучыга тәкъдим итәргә вакыт җиткәндер дип уйлыйм.

**Фәрит БӘШИРОВ**

*Котлыйбыз!*

## Нил Юзиевкә 60 яшь



Тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме Нил Гафур улы Юзиев 1931 елның 10 гыйнварында Башкортстанның Яңавыл районы Ямады авылында туа. 1948—53 елларда Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый.

1956—60 елларда Нил Юзиев «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакциясендә эшли. 1960 елда Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасына күчә. «Татар совет поэзиясенең поэтикасы» дигән темага докторлык диссертациясе яза һәм 1974 елда аны уңышлы яклый. 1973 елдан бирле Нил Юзиев Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият секторына (соңгы елларда кулъязмалар һәм текстология бүлегенә) җитәкчелек итә.

Нил Юзиевнең әдәбият фәне һәм агымдагы әдәби процесска багышланган беренче тәнкыйть мәкаләләре матбугатта илленче еллар башында күренә башлый. Ул бигрәк тә поэзия турында яратып яза. Муса Җәлил, Әхмәт Фәйзи, Сибгат Хәким кебек күренекле шагыйрьләрнең иҗатларын тикшерә. Аның «Муса Җәлил поэмалары» һәм «Тормыш поэзиясе» дигән китаплары шул елларда басыла. Алтмышынчы елларда «Традицияләр яңарганда», «Сәнгатьчә матурлык һәм осталык» җыентыкларын яза. Җитмешенче елларда исә аның «Шигырь гармониясе», «Хәзерге татар поэтикасы» исемле теоретик хезмәтләре дөнья күрә. Бу китаплары өчен ул 1974 елда, әдәбият галимнәреннән беренче булып, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләген ала. 1961 елда — СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

Каләмдәшебезне олы бәйрәме белән чын күңелдән котлыйбыз, аңа ныклы сәламәтлек, озын гомер һәм яңа иҗади уңышлар телибез!

**Лəбибə Ихсанова**

# АНЫҢ САБАКЛАРЫ

Илленче еллар башында əдəбиятка килгəн безнең буын өлкəн язучыларның бик күп акыллы сүзлəрен, киңəшлəрен ишетеп үсте. Ул елларда яшь язучыларның республика күлəмендə зурлап үткəрелгəн конференциялəре була иде. Жанрлар буенча үткəрелгəн семинарларны əйтəсе дə юк, хəтта бер елны өметлерəк яшь калəмнəрне өлкəн язучыларга беркетү практикасын да кулланып карадылар. Лəкин исемдə калганы (мөгаен, безнең өчен иң файдалысы да булгандыр əле) яшь язучылар секциясенең эше иде. Бу утырышларга, кагыйдə буларак, кимендə өч-дүрт танылган язучы катнаша. Аларның абруе иркебезне чиклəми, жим көтеп утырган сары томшыклы кош балалары хəлендə тоймыйбыз үзебезне, киресенчə, алар дəрəҗəсенə күтəрелгəндəй булабыз. Шул вакытта алган сабаклар утыз еллар үткəч тə онытылмый, хəзер дə үз-үзеңə контроль ясау чарасы булып тора.

Ибраһим ага Гази образлар эшлəнешенə бик талəпчəн булды. Бер вакытны яшь прозаиклар белəн сөйлəшеп утырганда:

— Сез кире образларны ярыйсы гына оештырасыз. Чөнки сез аны тормыштагыча аласыз. Ə уңай геройны идеальгыздагы кешегə охшатырга тырышып язасыз,— дип əйтте дə, кызык кына бер мəзəк сөйлəп алды.— Бер хатын кер уганда улының күлмəген, сөекле улымныкы, яраткан баламныкы дип, сыйпап-сыйпап уа, йомшак кына итеп сыга икəн. Ə иренекен, теге каһəр сукканныкы, теге явызныкы дип, бəрə, йолкый, сыкканда да борып-борып сыга, ди. Керлəрен кибəргə элгəч караса, улының күлмəгеннəн кер дə чыкмаган, ə иренеке ап-ак булган. Шуның кебек сез дə уңай геройларыгызны бик яратасыз, аңар авырлык китерергə тырышмыйсыз. Ə ул чын кешегə охшамый. Хəтерлəсəк, без аның исемен генə хəтерлəп калабыз. Күп вакыт аныңсы да онытыла.

Бу сөйлəшүгə кырык еллап вакыт үтте. Əмма Ибраһим аганың сөйлəгəн сүзлəре генə түгел, тоныграк тавышы да колакка ишетелеп торган кебек əле. Ул гынамы, Тукай клубының март кояшына күмелгəн залы, яшел сукно ябылган өстəл тирəли тезелеп утырган калəмдəшлəрем дə күз алдымда. Əле əдəбият дигəн изге мəйданга аяк басарга гына җыенган, барыбыз да бер төслерəк язып киткəн, үз юлын, үз тавышын эзли генə башлаган, дан һəм дəрəҗəлəргə бүленеп бер-беребездəн аерылмаган яшь чагыбыз ул безнең.

Өлкəн буын дигəнебез дə бит күбесе əле иллегə дə аяк басмаган ир уртасы кешелəр. Лəкин алар сугышка хəтле үк инде татар прозасының остасы булып танылырлык гүзəл əсəрлəр биреп өлгергəн, фронтлардан йөреп кайткан, җəмəгатьчелек алдында абруйлы сүзе булган язучылар. Шуңа күрəдер ахрысы, алар белəн һəр очрашу безнең өчен бер вакыйгага була торган иде.

Элекке традициялəрнең дəвамы булдымы, сугыш елларында калəмдəшлəрнең үзара очрашулары сагындыргандымы, əллə тормыш шуны талəп иттеме, əдəби проблемалар турында зурдан кубып, вакыты белəн икешəр-өчəр көнгə сузып, җыелып сөйлəшүлəр гадəте бар иде. Балалар əдəбияты турында, драматургия, тəрҗемə мəсьəлəлəренə кагылган җыелышларга Мəскəүдəн дə танылган язучыларның чакырылуы истə калган. Иҗат секциялəре дə бик җанлы үтə иде ул елларда. Танылган олы язучы булса да, бер генə китап чыгарып өлгергəн яшь кеше булса да яңа язылган əсəрен, нəшриятка тəкъдим итүдəн элек, иптəшлəре хөкеменə тапшыра торган иде. Бу утырышлардан автор мактау сүзлəре генə ишетеп, күңеле хуш булып кына китми, үпкəлəшүгə кадəр барып җиткəн вакытлар да була. Ул вакытта əле, кемнең кем булуына карамастан, туры əйтеп сөйлəшү гадəте бар иде.

Бер вакыт яшь язучының повестен тикшергəндə Ибраһим Гази аның теленең ярлылыгына игътибар итте. Шактый сөйлəгəч, ышандырырлык итеп сөйлəгəч, əдəбияттан кызыклы бер мисал китерде.

— Горький бабаңда мондый бер җөмлə бар: укатил пятак по полу звеня и подпрыгивая, дигəн. Укыган булсаң хəтерлисеңдер. Ягъни мəсəлəн, биш тиен акчаның тəгəрəп китүен генə түгел, аның идəн буйлап зыңгылдап, сикерə-сикерə баруын да күз алдына китергəн. Ə синеңчə язса, укатил пятак по полу, дип кенə əйткəн булыр иде. Аерма бармы?

Шулай күрсəтеп биргəч, аерманы күрмəсə, сукыр кеше генə күрмəс иде. Кызым сиңа əйтəм, киленем син тыңла, дигəндəй, остазыбызның сабагыннан автор гына түгел, барыбыз да гыйбрəт алып утырдык.

Ибраһим ага кырыс кешегə охшый иде. Туры əйтү гадəте дə булганга кайберəүлəр аны өнəп тə бетермəде. Шулай да, кемнəргəдер ошарга тырышып, инанган фике-

реннән чигенми иде. Аның яратып, шаяртып, Әбҗәлетдин дип дәшә торган гомерлек дусы Афзал ага Шамов булды. Тиз җәрәхәтләнүчән йомшак күңелле кеше дә иде ул үзе. Пропагандист эзләп исемлек актарып утырган бер чакны алфавит буенча төшә-төшә:

— Ибрай Гази,— дип әйтеп җибәрмәмме.

— Ибраһим дип әйт инде...

Язучылар үзара сөйләшкәндә «Совет әдәбияты» журналының җаваплы секретаре Абдулла Гомәрне — Агомәр, Ибраһим аганы Ибрай Гази дип кыскартып әйтергә өйрәнгәннәр иде. Телемнән шул ычкынуга, Ибраһим аганың йомшак шелтәсен дә ишетеп, уңайсыз булып китте.

Тора-бара мин аның бала кебек оялчан һәм бала җанлы кеше икәнен дә күрдем. Бер елны Саба районында әдәбият көннәре барган вакытта Ибраһим ага белән бер фатирга төшәргә туры килде. Килүебезне көтеп торганнар икән, ак яулыгын артка каерып бәйләгән ачык йөзле хуҗа хатын безне капка төбенә ук чыгып каршы алды. Янында биш-алты яшьлек чая гына кызы да бар иде. Нилектәндер бу кыз безне бик тиз үз итеп алды. Кая барсак та яныбыздан калмый. Юынганда сабын тотып булса да ярдәмен күрсәтергә тырышты. Хуҗа хатын өйнең алгы ягына аш әзерләгән икән. Әлеге сөйкемле кыз бездән алда өстәл артына кереп утырган иде инде. Аңар ирек бирсәң, башыңа менеп утыра ул дип, әнисе кызының ай-ваена карамыйча, кулыннан җитәкләп алып чыгып китте.

— Нигә алай итте инде ул, комачауламый иде бит, бергә утырып ашаган булыр идек,— диде Ибраһим абый, көчләп ишек алдына чыгарып җибәрелгән кызчыкның елаган тавышын тыңлап торгач.— Фатирга төшүнең кыен ягы бар шул. Кешене уңайсызлыйсың.

Башка авылларда йөргән чакта да аның хуҗалар белән читенсенеп сөйләшүен, оялып кына ашарга утыруын күреп тора идем. Ибраһим ага очрашуларга сирәгрәк чыга шул, юл хәленә шуның өчен күнегеп җитә алмыйдыр. Алай дисәң, ничә ел фронтта йөргән кеше бит, анда да шулай булдымы икән дип гаҗәпләнә идем. Уйларымны үзенә әйткәч:

— Ятимлектән калган гадәттер инде, приутта иң оялчан малай идем мин,— диде.

Ашап-эчкәч, гәрәбәдәй сары баскычка чыгып утырдым да, ишек алдына очып төшкән чыпчыклар белән талаша-талаша, табакан җим чүпләгән чуар тавыкларны күзәтергә тотындым. Кай арада килеп җиткәндер, сөйкемле кызчык та яныма ук сыланып, килеп утырды.

— Еламыйсыңмы инде? — дидем аны кочып алып. Үстерә башлап та үремгә кереп җитмәгән, күзенә төшеп интектергән аксыл, йомшак чәчләреннән сыйпап куйдым.

Ул җавап бирмәде. Йөземә үрелеп карап торды да:

— Апай, нигә синең колак алкаң юк? — дип сорады.

— Синең дә юк бит.

— Барые ла. Дәү апа алды.

— Ник алды соң?

— Бүген бичыр ла клубта,— диде ул, шуны да белмисеңмени дигән тавыш белән.— Шунда барырга алды. Бирми инде ул аны.

Ибраһим абый да чыгып ишек яңагына сөялгән икән. Сөйләшүебезне тыңлап торган.

— Кибетегездә алка бармы соң? — дип, безнең сүзгә ул да кушылды.

— Бар, ник булмасын.

— Мин сиңа алка сатып алырмын.

Кызчык сикереп торды да, сөенечле хәбәр әйтергә дип, әнисе янына йөгерде, ә без кичәгә җыена башладык.

Хуҗа апай миңа дигән урынны чоланга җәйгән икән. Урын күрсәтергә чыккач, гаепле кешедәй уңайсызланып әйтте:

— Гаеп итмә инде. Бу бала синең белән йоклыйм дип интектерде.

Кая ул гаеп иту! Юрган астында бөгәрләнеп яткан сөйкемле кызчыкны рәхәтләнеп кочагыма алдым.

Иртән торуга урынында юк иде ул. Яшь баланың изелеп йоклар чагы, югыйсә. Чәй янында да күренмәде. Кая китте дип сорауга әнисе елмаеп:

— Кибет тирәсендәдер әле. Сез торганчы ук барып кайтты инде,— диде.

Чыннан да, бик күңелсезләнеп, озаклamый кыз бала үзе дә кайтып керде.

— Апай, кибет ачылмаган бит әле,— диде ул, кулымнан тартып бер читкә алып киткәч, борчылып.

— Ачар әле, кайгырма, сеңлем.

Иптәшләребез белән колхоз идарәсе янында очрашырга булган идек. Барышлый кибет яныннан урап киттек. Кибет ишегендә бала башы хәтле йозакны күргәч, кыз елап ук җибәрде. Бөтен өмете киселгән иде.

— Җылама, җылама, матур кыз,— дип, Ибраһим абый аның кулыннан җитәкләп алды.— Начальник абыйларың янына барыйк әле, берәр нәрсә уйлап табарбыз.

Бу сүзләрне ул кызны юатудан бигрәк үзе өчен әйтә иде.

Язучыларны озатырга килгән колхоз җитәкчеләре, кибетчене чакырып, вакытыннан алда кибетне ачтырдылар. Ибраһим ага кызны җитәкләп кибеткә алып керде:

— Я әле, апасы, иң матур алкаларны күрсәт әле безгә,— диде ул.

...Казанга кайтуыбызга озак та үтмәде, «Казан утлары» журналында Ибраһим аганың «Колак алкасы» дигән кечкенә хикәясе басылып чыкты.

Китап күзәтү

# ЗӨЛФӘТНЕҢ ЯҢА КИТАБЫ

Бер танышым белән бәхәскә кереп калдым.

— Хәзер шигырь китапларын укып вакыт әрәм итәсе юк, — диде ул. — Кешеләрдә шигырьгә карата аллергия башланды инде...

— Нинди шигъриятне әйтәсездер бит?!. Мәсәлән, Зөлфәт шигърияте хакында алай дип әйтергә тел әйләнми! Рәхим итеп, яңа гына басылып чыккан «Адашкан болыт» исемле китабын укып бак. Ышанып әйтәм, Зөлфәт шигъриятенә орынсаң, «шигъри аллергия» хакындагы сүз уйнатуларыңны калдырып торырга туры киләчәк.

— Белмим, белмим... Башкалардан кай ягы белән аерыла соң ул?

Танышыма сөйләгәннәрне хәзер хәтеремдә яңартырга тырышып карыйм...

Зөлфәт шигъриятенең төп хасияте нәрсәдә соң?

Әгәр яшәешебезнең соңгы дистә елларын гигант айсберг белән чагыштырсак, без шул боз тавының судан чыгып торган өске өлешендә уйнаган кояш нурларына мөкиббән китеп, биһуш гомер кичергәндә, Зөлфәт шигырьләре игътибарыбызны айсбергның су астындагы төп өлешенә, безнең зиһеннәр тоя, күзләребез күрә алмаган империячел сәясәт фаҗигасенә дучар булган халык язмышына юнәлтергә тырыша.

Китап битләрен актарам. Рух уяна... Җаның — Ил һәм Халык язмышына кушылып тетрәнә. Әйтерсең, шагыйрь мәңгелек хакыйкать атавының иң биек ноктасына күтәрелгән дә укучы белән сөйләшә. Мине дә үз биеклегенә күтәрә... Җитмеш ел буе тырыша-тырыша Ялганга тәрелгән гамәлләребезгә бәя бирә. Аның һәр сүзе мигә бәрә.

*...Төрле тормыш корып карадык без,*
*Кеше сыман яшәмәкче булып...*
*Гөнаһ шомлыгыдай,*
*Өстебезгә*
*Килде һаман шул адашкан болыт.*

Әйе, шагыйрь без яшәгән Җирдә яши, без йөргән урамнарда йөри, без сулаган һаваны сулый... Ләкин аның кыйбласы башка! Без — читлек куяннары, идеологик кысалар эчендә тәрбияләнгән күндәм, «инсафлы» буын. Тынмас алкышлар астында үскән ләббәйкәчелек буыны... Шагыйрь үзендә шул кысаларны ватып, җимереп чыгарлык көч тапкан һәм көрәшкә ташланган. Башкаларны да азат итү өчен көрәшкә...

*...һәм шул килеш,*
*шундый хәлдә килеш*
*Азат итеп маташабыз тагын*
*Үзебезнең түгел —*
*Олы җирнең*
*Бездән ирекләрәк халыкларын!*

Яисә менә 1987 елда язылган «Кырау» исемле әсәр:

*...Куырылган җимешләр без*
*Ватанның түтәлендә —*
*Илкәй һаман*
*сезнең буын*
*Чишендергән хәлендә...*

Шагыйрь үзе генә беләдер: башкалар «тынычлык, дуслык иленең саф һавалы җылы җилләрендә кабат-кабат яшәреп», унай гына иҗат итеп ятканда, иманыңның тайпылмаган хәлдә Шигърият бакчасында үзенчәлекле гөл булып таныла алу җиңел булмагандыр. Күрәсең, монысы өчен Шагыйрь үзенең зур талантына бурычлыдыр. Талантка баш ими мөмкин түгел. Аны күрмәмешкә салышырга гына мөмкин... Бу — Шагыйрьне рухи үтерүнең берләнбер юлы. Әмма Зөлфәт үз иҗатының башлангыч чорында ук Шагыйрьне җиңел тормыш көтмәгәнлеген яхшы аңлый. Шагыйрь сүзе кара көчләргә каршы иң көчле корал.

*...Дога белән шигырь арасында*
*Зур аерма күрмим әллә ни...*

Башкалар «Бөек киләчәккә» кысыр өметләр баглап, элегияләр язып азапланганда Зөлфәт Намус, Вөҗдан өчен зур әхлакый көрәшкә чыга.

*...Мин Буран туганыдыр —*

Күкрәгемдә
Буран болытлары...

Шагыйрьнең җирдәшләргә һәм, гомумән, яшәешкә фән-техника революциясе китергән һәм әле китерәчәк коточкыч афәтләрен тасвирлаган шигырьләрен дә тыныч кына укып булмый. «Бөеклек» зәхмәте кагылган илдә барлыкка килгән буынны нинди язмыш көтә? Шагыйрьнең хөкеме кырыс:

Без — реакторлар,
Без номерлы
Җирдә,
һәммәбезнең номер —
дүртенче...

«Изгеләр чишмәсе», «Җирдән кайтышлый», «Сәрем», «Күрсәнү» шигырьләрен дә зур кисәтү итеп кабул итәм.

Зөлфәт туган як, татар халкы, тел язмышы хакында да үзенең уй-фикерләрен үзәккә үткәрерлек итеп яза. Әсәрләр әчкерсез, кылану юк. Ниятен томанлы ишарә рәвешенә төреп азапланмый. Ясалма, төче ватанпәрвәрлекнең дә эзе юк. Шул ясалмалылык, төчеләнү «китапча шигърилек»кә китерде дә бит инде! Шул нәрсә татар халкының шигырьгә булган традицион мәхәббәтен киметтә дә инде!

Туган авыл, яшьлек истәлекләренә таңгал рәвештә Зөлфәт шигъриятенә ат образы килеп керә. «Ат йокысы», «Ике ат турында баллада», «Атлар чаба», «Ат карагы», «Ул карашлар истә» кебек шигырьләрдә мең еллар буена кешенең тугрылыклы дусты булган, авыр йөген үз иңсәсендә тартып, кешелекне безнең чорга — фән һәм техника революциясе чоры дип аталган Ахырзаманга алып чыккан Ат образы төрле фикри агышларда сурәтләнә. Сагыну; ирегә чикләнгән язмыш; тамырын югалткан буын һәм табигать белән кешенең бер бөтенлеге...

Зөлфәт шигъриятендә саллы катлам — ул да булса татар халкының фаҗигале, гыйбрәтле язмышы. Мәрҗанине, Тукайны, Җәлилне тудырган халык хәзер денсез-имансыз буын үстереп ята. Кем гаепле моңа? Шагыйрь шәхси үрнәк күрсәтә — ул бармак төртеп гаепләнә күрсәтми, гаеп безнең үзебездә, һәр кайсыбызда икәнен ассызыклый:

Үзебезнең оят —
безнең сыртка!
Җир күтәрә алмас һәммәсен...

Кыйблалар югалган, гореф-гадәткә төкереп кенә карыйлар, әхлак-вөҗдан дисәң, мыскыллы көлү ишетерсең... Яшәешне көйләп торучы иң изге төшенчәләр урынына — бушлык, әмма ул тиз арада әдәпсезлек, әхлаксызлык, денсезлек, намуссызлык микроблары үрчи торган инкубаторга әйләнә.

...Имансызлар калдың, и халкым,
Ни саклар куңеленне!
Үйнаштан туган буынга
Калдыра күрмә Илне!...

Зөлфәт шигырьләрендә халкым башыннан үткән авыр язмыш төрле ассылыкларда ачыла. Халык, туган тел, яңа буын язмышына булган Салкын Битарафлык диварын шигырьләре белән әрнеп, ярсып утка тота шагыйрь.

Зөлфәтнең күп шигырьләренә болыт образы килеп керә. Болыт — Өмет. Болыт — билгесез килачәккә шөбһә. Болыт — Ышаныч. Болыт — Кәтү. Болыт — Намус...

Вето салдым барлык мескенлеккә!
Җитте Оят ап-ак болыттан!

Шагыйрь замандашлары җанына тирән үтеп керә. Безнең чор кешесенең чын йөзен ачып бирә.

Без — күкертсез шырпы,
Без — кешесез учак.
Без — яшәми торган адәм балалары,
Без — сурәтсез сурәт.
Рәссам туган!
Безнең натюрмортка
нәрсә кирәк тагын!

Безнең тәнкыйтьтә Зөлфәт иҗатына төпле анализ ясаган мәкалә укырга туры килгәне юк әле. Бер-ике автор шагыйрьнең исемен телгә алып китә китүен. Ләкин болай гына, үтеп барышлый гына...

Шулай итеп, Зөлфәтнең иҗаты әдәби тәнкыйтьтә, Мөхәммәт Мәһдиев әйтмешли, «пачти кыз» килеш яши бирә. Әнә шуңа күрә Татарстанда яшәүче кайбер милләттәшләребезнең шигъриятебез горурлыгы саналырлык шагыйрьне:

— Кем соң ул? — дип соравына гаҗәпләнми дә башладым. Бездә бит конфитчан тәнкыйть чәчәк аткан, ул бүген дә гөрләп яши бирә! Ә белгәнебезчә, конфит тешне бозучан. Димәк, тәнкыйтьнең Зөлфәт кебек фидакарь шагыйрьләребез, язучыларыбыз иҗатына теше үтмәве табигый.

...Туган телне ыштыр итүчеләр
Җир җимертеп бәйрәм иткәндә,
Газиз сузкай,
урын кала синә
Тиреннәрдә бары, үткәндә...

Хәзер инде «үзгәреш» сүзе модада. Шагыйрь тарихның бу борылышын да үзенчә кабул итә.

...Тагын
яңа болыт килде өскә.
Шифалымы —
ходай үзе белсен...
Күчкыллана, дулый, тугарыла —
Хаерлегә генә була күрсен.

Шагыйрь тынычлану хакында уйларга ир-

тә булуын кисәтә. Көрәшсез бер нәрсә дә бирелми. Озак еллар буена рухын таптаган Иблисләрнең тамыры тирәндә, аларның кулында көчле корал — Сукыр Ышаныч бар.

*...Рәнҗетелгән җаннар очып йөри —*
*Һәммәсендә яна минем тамга.*
*Фәрештәләр чакырдым мин җиргә,*
*Тик иблисләр килде,*
*Алар кала...*

Зөлфәт иҗатының тагын бер үзенчәлеге — аның Туфанилыгы. Ул — татар халкының намус сагы — Туфанның рухи туганы дисәм дә ялгышмам.

Җитмешенче елларда Туфан яшь буынга:

*— Кемнәр сез?*
*Безнең дәваммы?*
*Һәм безнең нәселме сез?*
*Тукайлар изге йоласын*
*Үтәргә әзерме сез!? —*

дип эндәшкән иде.

Зөлфәт — шушы шигъри наказны үтәргә алынган фидакарьләрнең берсе. «Чык төшкән Парнас тавына», «Күңел сагы», «...Хан да түгел, мин — бары тик Зөлфәт» кебек әсәрләрендәге сурәт-образлар, романтик фәлсәфә, шигырьләрдәге лиризм, моң Туфан чалымнарын еш искә төшерә.

Зөлфәтнең мәхәббәт лирикасы да үзенчәлекле. Аның шигырьләрендә кысыр сагыш, сөйгәне ташлап киткән Мәҗнүн йөрәкнең «аһ-ух» килеп өзгәләнүләре юк. Зөлфәт мәхәббәт лирикасында да фәлсәфи тирәнлеккә омтыла, хисләре бай, катлаулы. Тормыштагы кебек үк... «Оныт», «Икебез», «Теләк», «Берүзем», «Ул яшеннәр кайда», «Ак шомыртым» һ. б. шигырьләрдә замандашыбызның саф хисләрен ышандырырлык итеп сурәтли. Үзең дә сизмәстән шагыйрьнең сердәшенә әверелеп куясың. Кемгә килеп, кемне генә яндырмаган сөю!

*...Юатулар безгә кирәк түгел,*
*Ихлас язга кирәк юату:*
*Чын мәхәббәт —*
*җирдә юкны табу,*
*Чын мәхәббәт —*
*Барны югалту...*

Зөлфәтнең күп шигырьләрендә табигать күренешләре эчке кичерешләр аша үткәреп тасвирлана. Ләкин бу абстракциягә корылган коры фәлсәфә түгел. Яшәешнең бакыйлыгы, гомернең чикләнгән булуы һәм, иң әһәмиятлесе — шәхеснең кешелек алдында җаваплылыгы калку чагыла. «Сулыш», «Сират күпере», «Офыкларда төн канаты яна» һ. б. шигырьләр шул хакта сөйли.

Шагыйрьнең китабын укыйм... Күңелдә давыл, уйлар өермәсе... Менә тагын Тукай премиясенә тәкъдим итүләр башланыр. Табигый дип уйлыйм, бу исемлектә Зөлфәтнең «Адашкан болыт» китабы да булыр. Һәм инде премиягә тәкъдим ителгән кандидатларны караган чагында берәрсе:

— Кем соң ул Зөлфәт?! — дип «сорый» икән, андыйларга шагыйрьнең үз сүзләре белән алдан ук җавап бирәсе килә:

*...Еллар узды... Инде уйлыйм мин —*
*Чын дөресен әйтәм, алдамыйм:*
*Алла чакта — кеше түгел мин,*
*Кеше чакта — бераз алла мин.*

**Факил САФИН,**
Чаллы.



**Равил Фәйзуллин**

# АК РОЯЛЬ ХУҖАСЫ

(БЕР УЙЛАНУ)

Җиһанның Нәҗип ага Җиһансыз яшәвенә дә инде ике ел ярым вакыт узды. Исән булса, олуг шәхесләребезнең берсе буларак, аның 80 яшьлеге зуррак һәм тантаналырак рәвештә узар иде. Дөрес, бу дата җәмәгатьчелек тарафыннан болай да киң билгеләнеп үтелә. Шулай тиеш. Әле узган декабрь аенда гына Салих Сәйдәшевнең 90 еллыгы гөрләп узды. Бер кыш эчендә ике мәшһүр,— хәтта бөек дип әйтүдән дә курыкмаскадыр,— композиторыбызның юбилей даталары. Төптәнрәк уйлап карасаң, гыйбрәтле һәм сөенечле хәл бит бу! Иә, кайсы халыкның, бигрәк тә төркиләрнең, шулай янәшәләтеп дигәндәй, зурлап ядь итәрлек, бәйрәм итәрлек олуг композиторлары бар икән? Ихтимал, шул чордан болар рәтенә әзерләрнең (әзербайҗаннарның) Гөзәер Хаҗибәковны («Аршин мал алан» операсы авторы) гына куеп буладыр...

Һәрбер юбилей иясе нинди өлкәдә хезмәт итсә, беренче чиратта, табигый, аның иҗат бәйрәме шул өлкәнең, шул даирәнең бәйрәме булып уза. Әгәр хезмәте, иҗаты үзеннән соң килгән буыннарны да дулкынландыра, рухландыра икән — ул юбилей инде гомумхалык бәйрәменә әверелә. Бу очракта да шулай булды, Сәйдәшев һәм Җиһанов юбилейлары уңае белән без яңадан 50-60 елда узылган музыка дөньябызга экскурс ясадык. Байтак мәкалә-истәлекләр укыдык, көйләре, җырлары белән бергә замандашларының хатирәләрен тыңладык, яңа мәгълүматларга ия булдык. Горурландык, кайчакта офтандык та... Үткәннәрне үзебезчә анализлап, киләчәккә барыр юлларны дөресрәк билгеләргә тырыштык. Мәрхүмнәргә дан да, мал да кирәкми. (Нәҗип Җиһановның үлү хәбәрен мин 1988 елның 4 июнендә Башкортстанның Мәләвез каласында ишеттем. Безгә — әдәбият-сәнгать көннәрендә катнашучыларга бу кайгылы хәбәрне Татарстан партия өлкә комитеты секретаре Наил Кадермәтов җиткергән иде. Ул да инде (әле яшь иде) ике ел элек гүр иясе булды. Кабере — Нәҗип аганыкыннан 5-6 адым ераклыкта гына). Аларның дөньялыкта калдырган гамәлләре исәннәр хөкемендә.

Юбилейларга әзерлек чоры кампаниясендә — матбугатта, радио-телевидение тапшыруларында, аерым җыелышларда — татар музыкасы өчен горурлык уяткан тойгылар белән бергә, беркадәр ризасызлык хисләре кузгатырлык сәбәпләр дә булмады түгел. Шуларның берсе — иң рәнҗеткәне: кайберәүләрнең бу ике бөек композиторны бер-берсенә каршы куярга теләве, берсен күтәребрәк, икенчесен төшеребрәк күрсәтергә тырышуы. (Татар әдәбияты тарихында булып узды инде андый хәлләр! Тукайны Дәрдемәндкә, Ибраһимовны Исхакыйга, Такташны Кутуйга... каршы куеп сөйләшүләр. Вакытлар узгач һәммәсенең үз урыны табыла, асыл бәясе бирелә барды). Бу — акыллы караш түгел, милләт алга барсынга әшли торган юл түгел. Зирәк халык һәр зур талантның, һәр зур иҗатчының (алар сирәк туа!) уңай ягын әләм итеп күтәрә, аны көч санап, үзенең рухын көчәйтә, үзаңын арттыра. ...Әлбәттә, бер адәм дә, шул исәптән зур иҗатчы да, фәрештә була алмый. Берәү дә хатадан хали түгел. Бер шагыйрь әйтмешли:

*Беләсең:*
*Бик тигез салмадык эзне дә.*
*Без дә бит бу Җирнең баласы,*
*еллар сагынып безне дә!*

Мин шәхсән үзем Нәҗип ага белән шактыйдан ук таныш булып, соңгы 10—15 ел эчендә дустанә аралашып яшәдем дип әйтә алам. Үз вакытында аның тормышы һәм иҗаты турында бер әдәби хезмәт тә язарга исәбем бар иде. Ул үзе дә бу ниятемне белә иде. Шуңа күрә өендәме, эшендәме яки берәр бүтән җирдәме аның белән еш кына очрашырга туры килде. Ул үзе дә бу очрашып-күрешүләргә бик тә разый иде шикелле. Атна-ун көн күрешми торсак, «Нигә югалдың әле?» дип өйгә дә шылтыраткалый иде. Күрәсең, миңа ышаныч күрсәтеп, эше, иҗаты, тормыш рәвеше турында күбрәк белүемне теләгәндер мәрхүм. Шәхси архивының байтак өлешен бергәләп актарып чыгарга да вакыт тапкан идек. Ул мине иҗатын аңларга сәләтле дип уйлаганмы (ә болай музыканы аңлавым бик чамалы), фикердәше дип таныганмы, тәгаен белмим, әмма аталарча якын итүен үзем сизә идем. Күңел булсын диптер инде, шигырьләремне дә мактап куйгалый иде. Ихлас әйтүе дә бар: бу хакта шулай сөйләгәннәрен кешеләр аша да ишеткәләдем. Шулай «ахири» булсак та, без уртак бер генә көй дә, бер генә җыр да язмадык. Мин тәкъдим итмәдем, ул сорамады...


Нык ихтыярлы максатчан шәхес. Күңелеңдә нинди зат булып калды дисәләр, тагын шул ук сүзләрне кабатлар идем: нык ихтыярлы максатчан шәхес. Әгәр шул сыйфатлары булмаса, ул тау кадәр хезмәт калдыра да алмас иде. Андыйлар турында кала интеллигенты «титан!», ә авыл агае — «эш аты!» дип әйтер иде. Хезмәт җитештерүчәнлеге дигән производство терминын кулларсак, бу яктан татар музыкасында бүтән андый кеше юк (әдәбиятта — Н. Исәнбәт, рәссамнар дөньясында — Б. Урманче белән тиңләп булса гына). Хезмәтләренең тау сырты кебек күренеп торганнарын гына санап узыйк: сигез опера, унҗиде симфония, өч балет (һәрберсенең партитураларын гына язып чыгар өчен айлар, еллар кирәк!), берничә симфоник поэма һәм кантата, дистәләгән вокаль-инструменталь әсәрләр, җырлар... Эстетик байлык күләм белән бәяләнмәсә дә, чагыштыру өчен әйтеп узыйк: мәшһүр Д. Шостаковичның опера һәм симфонияләр саны күпкә кимрәк.

Дөресен әйтим, кайчак язгы ташулар аккан кояшлы көннәрдә яки ямьле җәй сәгатьләрендә аны һаман саен ак рояле артында утыруын күреп, кызганып, җәлләп тә куя идем. Бу кадәр эшләп бер дә дөнья рәхәтен күрми ахры бу абзый! Бәлки ялгышамдыр. Ул, әлбәттә, эшеннән, нәтиҗәсеннән, җиңүеннән, данынннан һәм хезмәте китергән тагын әллә нәрсәләрдән тәм һәм ләззәт алгандыр. Ә шулай да...

Шундый бер тәгъбир бар: җирдә теге яки бу миссияне башкару өчен ходай миңтамга салган кешеләр була, имеш. Нәҗип агага күктән, белмим, ниләр иңдерелгән булгандыр, әмма татар музыкасының соңгы ярты гасырлык язмышында аның миссиясе гаять зур. Музыка дөньябызда этап булырлык төп тарихи вакыйгалар аның исеме, аның иҗаты белән берегеп калган. 1939 елда, яңа оештырылган опера һәм балет театры Н. Җиһановның «Качкын» операсы белән ачыла, соңрак — Татарстан дәүләт филармониясе үзенең беренче эшен Җиһанов әсәре белән башлап җибәрә. 40 нчы елларда Татарстан Композиторлар берлеге (союзы) оештыруда ул башлап йөрүче була, Берлек барлыкка килгәч, 30 елга якын аны җитәкли. Казанда консерватория ачылу көненнән башлап гомеренең соңына кадәр ул аның редакторы иде... Ялгышмасам, татар композиторлары даирәсеннән профессор исемен йөрткән беренче кеше дә Җиһанов булды шикелле. СССР халык артисты. Өч тапкыр СССР Дәүләт премиясе лауреаты. Татарстанның Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Татар әдәбияты һәм сәнгате дөньясында Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелгән беренче карлыгач... Беренче, башлап йөрүче, тәүге... Гел иң беренче... «Ах, беренче зөфаф кичәсе!» дигәндәй, һаман-һаман беренче булу, мөгаен, күңелне гел котырта, нәфселәндерә, ярсытадыр... Хәер, иҗат бәйгесендә кемнең койрыкта сөйрәләсе килсен икән. Әмма беренчелек ул — горизонталь яссылыктан бигрәк вертикаль биеклек төшенчәсен дә үз эченә ала. Болытларга тиеп торган биек тауларның очына якынайган саен җилләр көчлерәк һәм суыграк. Югары дәрәҗәгә ирешкән саен җаваплылык хисе арифметик кына түгел, геометрик прогрессиядә арта гына. Андый кешенең ялгышы да, кояшлы көндә тау өстендәге кешенең күләгәсе ерак-еракларга төшкән шикелле, күпләргә кагылып үтә...

Әйе, Нәҗип Җиһанов — кабатланмас зур шәхес. Иш ише белән дигәндәй, Бакый ага Урманче да аны якын итеп, «безнең Нәҗип! безнең Җиһан!» дип әйтергә ярата иде (сүз уңаеннан әйтеп узыйм: миңа калса аның иң уңышлы портретын да Бакый ага иҗат итте). Йолдыз белән йолдыз, таулар белән таулар сөйләшә, диләр. Тауларның калкулыклар, түмгәкләр белән үз мөнәсәбәте булуы табигый. Һәр биеклекнең үз хакыйкате. Мондый табигый хәлне табигый рәвештә, шулай булырга тиеш дип кабул итәргә кирәктер.

Нәҗип аганы да музыка дөньясына әзме-күпме катнашы булган һәр кеше олуг,



Сулдан уңга: *шагыйрь Равил Фәйзуллин, композитор Нәҗип Җиһанов, режиссер Ширияздан Сарымсаков. 1980 ел, май.*

бөек дип кабул иттеме соң? Һич юк! Яшәве дәверендә аны яратмаган, аңа каршы кешеләр дә байтак булды һәм алар хәзер дә җитәрлек. Аларның да үз дөреслекләрен расларлык үз дәлилләре бар. Чыбык озын булган саен очы нечкәрәк була. Зур шәхес өчен кичерерлек объектив каршылыклар белән бергә, ихтимал аның традицион канунанарга (ташламаларга) сыеп бетмәгән үзенең «авторски» хаталары да булгандыр. Шәхси һәм иҗтимагый тормышында аның да байтак драматик тетрәнүләре булган һәм булды. Җәмәгатьчелеккә билгеле булган ул фактлар үз эзен калдырган, әлбәттә. Миңа калса, Нәҗип ага үзенең иҗатында үзе тудырган киң масса «кара халык»ның ихтыяҗларына һәм зәвыкларына тиешле игътибар итеп җиткермичә, аларның реаль көчен тулы ук бәһали алмады бугай. Үзәк — Мәскәүнең югары музыкаль даирәләре белән бер дәрәҗәдә торып, җирле хакимият вәкилләре белән артык конфронтациягә кермичә фанатикларча эшләү — аның төп кредосы иде шикелле. Бар каршылыклары белән ул үз заманын, үз чорын чагылдырган бер зур көзге, бер зур шәхес.

Нәҗип Җиһановны өнәп бетермәүчеләрнең аргументлары тагын мондыйрак. Ул, янәсе, Салих Сәйдәшевне көндәш итеп, аны күләгәдә калдырган, яңа талантларны үстерүдә җитәрлек тырышмаган... Мөгаен, бу гаепләүнең икенчесендә өлешчә хаклык та бардыр. Татар республикасы үзәгендәге Консерваториядә моңа кадәр татар музыкасы кафедрасы да булмау (андый кафедра үткән ел ачылды) үзе үк күп нәрсә турында сөйли. Консерваториянең педагоглар составында да татар халкы вәкилләренең аз булуын да аклап булмый. Күрәсең, беренчедән, укыту программалары РСФСРдан моңарчы автономия булып килгән Татарстанга рус өлкә шәһәрләрендәге консерваторияләрендәгечә, диктат рәвешендә өстән тагылган, икенчедән, ректорның да милли музыканы үстерү проблемаларына игътибары җитәрлек булмаган. Ә менә Салих Сәйдәшевне кыерсыту мәсьәләсе, минемчә, уйдырма. Сәйдәш иҗаты белән таныш кешеләр белә булыр: Салих аганың иҗади пигы 30 елларда була. Шәхес культының канлы куллары К. Тинчурин кебек иҗатташларын, фикердәшләрен буып юк иткәч, Сәйдәш иҗаты да сүрелүгә таба бара. Үзеннән 10 яшькә кече Җиһанов бит әле ул чакта аренада юк иде... Татар музыкасы тарихындагы бөтен негатив якларны бер Җиһановка гына аудару дөрес булмас. Кемнең хыялына ирешүдә ихтыяр көче җитеп бетмәгән, кемнең гаиләсендә фаҗига булган, кемнең бүтән бер кайгысы... Дөнья бу! Базар гайбәтен иҗтимагый фикер мөнбәренә күтәрмик!.. «Сәйдәш» поэмасын язганда мин күп мәртәбә Нәҗип агага мөрәҗәгать иттем, киңәшләр сорадым. Ул һәрвакыт Сәйдәш турында ихтирамлы сүзләр әйтеп килде. Аның юбилей мәҗлес-

ләрендә олы сүзләр сөйләде. Хәтердә, шагыйрьләр секциясенең «Сәйдәш» поэмасын укып-тикшерү җыелышына да килеп утырган иде. Архив документларында Нәҗип аганың Салих Сәйдәшевне кыерсытканын дәлилләгән документлар таба алмассыз. Кыскасы, чәкештермәскә кирәк иде ике бөек затны! Бу бит суверенитет алган халык файдасына түгел.

Нәҗип ага ак рояль артына утырып иҗат итә иде. Менә инде ул рояльнең хуҗасы юкка өченче ел китте. Кемнәрдер уйлаганча, «Татар музыкасын басып торган «Җиһангир — Җиһан» юк инде. Тынычланыйк. Иә, музыкаль тормыш җанланыбрак киттеме? Татар музыкасы дөнья аренасына киңрәк чыгамы? Яшь композиторлар гөрләп үсә башладымы? Хәер, әле мондый сораулар куярга иртәрәктер, үзгәрешләр, әлбәттә, булыр. Ә хәзергә үзгәрешләр шул: элек опера һәм балет театры үз сезонын традиция буенча татар композиторы Н. Җиһанов операсы яки балеты белән башлап җибәрә иде, ә бу сезонны «Иоланта» белән. Симфоник оркестр да дистә еллар буена сезон ачылу концертында Н. Җиһановның яңа симфониясен яңгырата иде, бу юлы — яңа милли симфония әзерләнмәгәч, бүтән — интернациональ программа...

Тукай шагыйрь булып җитешкән Җаекта (Уральск) туып, ятимнәр йортында үсеп, таланты һәм тырышлыгы белән Казан, Мәскәү калаларын таң калдырып, татар музыкасы вәкиле буларак, үз иҗатын Европага, Азия киңлекләренә яңгырата алган Нәҗип Гаяз улы Җиһанов ак рояльдә уйнап иҗат итә иде. Дөньяда ак рояльләр күптер ул. Әмма аларда бөтен дөнья тыңларлык әсәрләр иҗат итүчеләр генә сирәк.

Соңгы сүз итеп, бөек затка багышланган шигырем:

## Ак җилкән

Биләүләрнең аклыгына кунгач,
ятимлекнең кара канаты —
саклап калды мине Әниемнең
күңеленнән иңгән нур-якты.

Чаган өсләреннән ак томанны
ак болытлар төшеп алырмы?
Кай як офыклары тартыр икән
ак хыяллы сабый җанымны?

Ап-ак күлмәгемнең изүендә
күз яшьләрем түгел, сәдәп лә...
Күпме булды ул чак өметемнең
ак канатын кисәр сәбәпләр!

Бу дөньяның ак көйләрен җыеп,
тибрәттем күңелем кылында.
Тыелгысыз дәрт-көч алып чыкты
ак чәчкәле илһам юлына!

Хак эш өчен җан аямас ирнең
шәүләсе дә, имеш, ак кына!
Тормышымда көйне корал иттем
җирдә аклык, сафлык хакына.

Сынмады Рух — Замананың төрле
җил-давылы сынаган чакта.
Мин каплаган Җиргә — хезмәт иттем
һәм җиһанны күрдем ак атта!

Ак тауларга мендем, биек җилләр
иркәләрме, егып китәрме?
Ак дулкынга кереп, каршы бардым,
сулышларым озакка җитәрме?

Һәм ышандым: иманың нык булса,
түз калырга дәрман җитә ул!
Ил йөзендә ак эшемне күргәч,
халкым мине үзе күтәрде.

...Гомер күкләрендә ак яшендәй
үтә еллар, үтә яшьнәр чак...
Күпме генә җанга кер кунса да,
бу дөнья, барыбер ап-ак ак!

Ак чәчләрем җилдә җилфердиләр.
Ак җилкәндә инде хәзер мин.
Киләчәкнең ап-ак Хәтеренә
күчәр өчен җаным әзерлим.

# ГОРЬКИЙ ӨЛКӘСЕ ҖЫРЛАРЫ

Мин аларны кече яшьтән үк тоеп, ишетеп үстем. Әнием мине йоклатканда, мәсәлән: «Кем бишекне тирбәтә дә, кем сиңа җырлар көйли? Ай, былбыл, яшь бала, әниең шатлана»,— дип, йомшак җылы куллары белән аркамнан сыйпый-сыйпый, күңелгә көй сеңдерә иде. Мин сабый өчен бу моң, күрәсең, иң яхшы йоклаткыч булгандыр. Чөнки йокы аралаш: «Әкият сөйлә, әнием»,— дисәм дә, ул миңа янә дә: «Кем сине җандай сөя, баштан сыйпый? Ул — әнкәң...»,— дип, шул ук көйне көйли торган иде. Һәм мин шуннан, аның шомырт кара (хәзер генә алар ап-ак инде) толымнарын тотып, үзем дә пиләрдер мырлый-мырлый, күзләремне йомып куяр идем...

Былтыр минем әнкәмә җитмеш тулды. Үземә дә илле тирәсе. Уйлап-уйлап куям да шаккатам: гомеремнең бары унсигез елы үткән икән әнкәм янында! Күптән инде, күптән без аерым-аерым икән... Мин Казан-калада гомер итәм. Ә ул Кольчугино дигән шәһәрдә яши.

Сагына, күрәсең, бердәнберен. Күңеле туладыр кайчакта. Җырлыйдыр да шулчак, елыйдыр да... Хат язарга тотынадыр җыр белән: «Кем синең өчен кайгырып яшьләр койган? Ул — әнкәң...».

Әбием дә җырлап яшәде. Канлы сугыш еллары беткәндә:

*Очар булсаң, кара карга,*
*Язар идем канатыңа;*
*Язарга канатың кара,*
*Ерак булды ике ара...* —

дип сузар иде дә, яудан кайтмаган улын көтә-көтә, тәрәзәгә сарылыр иде...

Инде шушы юллар авторы үзе дә бер заман, армиягә малаен озатканда, түземде, мишәрләрчә җырлап җибәрде:

*Төшләремдә генә күрдем:*
*Кара су, кара урман,*
*Шул кара су, кара урман*
*Без аерылышырга булган...*

Әле генә китерелгән мисаллар — Горький ягы татарлары җыр мирасының нәни бер кисәге, өлеге генә.

...Берчак шулай кулыма «Казан утлары» журналы (1985 ел, 2 сан) эләкте. Шунда Мидхәт Фәйзуллинның үз туганы Җәүдәт Фәйзигә караган истәлекләренә тап булдым. Укыдым да, исем китеп куйды: композиторыбыз Җәүдәт ага егерменче еллар азагында Иш авылы дигән җирлектә (элек Сергач, хәзер Спасск районы) укытучы да булган икән. Әйдәгез шуннан бер өзекне укып китик:

«...Әйтүе сәер: бу авылда татар көйләрен бөтенләй диярлек җырлый белмиләр. Берничә рус җырын татар сүзләре белән җырлаган булалар да, шуның белән эш бетә». Килешеп була моның белән. Әмма заманасы нинди булган бит! «Бөтен авылына берничә генә кеше дөньяда электр, телефон, телеграф барын белә. Газета-журнал дигәннәрне авыл Советы яздыра да, укытучы алдыра...» — дип дәвам итә Мидхәт ага шунда ук. Үзебездән өстик: ул чакта бит әле радиоалгычлар да булмаган. Артистлар да, хәзерге кебек Казаннан килеп, концертлар биреп йөрмәгәннәр. Шулай булгач, яшьләр нәрсә ишетсен дә, нәрсә белсен, нинди көйләргә җырласын ди? Тагы бер өзек китерәм: «Без бит кирәгенчә җырлый белмибез»,— диештеләр. «Белгәнегезне җырлагыз, ялгышсагыз, мин төзәтермен, тик ачуланыштан булмасын». Шуннан скрипкачы (Җ. Фәйзи үзе — Х. Г.) бу авылда бик таралган «Балахна» көен уйнап җибәрә, егетләр дәррәү җыр башлый:

*Егет егетлеген итә,*
*Ат эчерә бүрәнда;*
*Йөрәгенә чыдый алмый,*
*Чыгып китә урамга...*

Менә диган фольклор үрнәге ич бу!

Күренекле музыка белгече Мәхмүт Нигъмәтҗанов безгә «Татар халык җырлары» китаплары белән таныш. Татарстан һәм Мәскәү нәшриятларында 1970, 1976, 1984 елларда басылган бу җыентыкларда татарларның төрле этник группалары яшәгән өлкә-республикалардан язылган җыр-музыка үрнәкләренең җиде йөздән артык төре бар. Шуларның 60 ы Горький өлкәсеннән алынган. Әле алары да утыз татар авылының бары уникесеннән генә язылган.

...Безнең якләрдагы туй-мәҗлесләрдә өлкәннәрдән, гадәт буларак, бәет җырлауларын

сорыйлар. Ә сорагач, телисеңме-теләмисеңме, син җырларга тиеш. Һичшиксез, җырларга! Тавышын, моңын, дәртең бармы — анысын сорап тормыйлар. Хуҗа кеше: «... Кычкырып җырлап җибәрсәң, минем дә күңел булады!..» — дип канатландырып тора. Кунакларның хәйләкәрләре (миңа гына тимәсеннәр, янәсе!) хуҗаны яклап, утка ялкын өстәп: «Әйдә, давай, җырла, агай! Ялындырма... Әйт берәрне! Җырлый белмәсәң, сөйләп бир... Әллә ашарга дип кенә килдеңме?..» — кебек өндәүкыстау сүзләре белән тәмам интектерәләр тегене.

Кунак нишләсен соң, җырлый, билгеле. Камка авылында «Әхсән бәете»н, Кочко-Пожаркида «Сабир»ны, Актүк җирлегендә «Тали бәете»н, ә Андреевкада — «Ташкай»ны...

Инде исемнәреннән күренгәнчә, бу бәетләрнең барысы да, татар фольклорына хас буларак, аерым шәхесләргә багышланган.

Югарыдагыларның беренчесендә «Әхсән голованы югалтучы Усман азанчының олы улы» каттый гаепләнә, икенчесендә ни өчендер җәза алган Сабир язмышы тасвирлана: «Елашмагыз, туганнарым, изгеләр дә җәфа чиккән...», — диелә анда.

«Бәетләр» дигән җыентыкта Хәмит Ярми: «... безнең заманнарга якынрак килә барган саен, бәетләрдә социаль мотив көчәйгәннән көчәя бара», — ди дә, мисалга «Тали бәете»н китерә. Шулаен шулайдыр да, мөгаен, әмма ләкин «Тали бәете» дә, алда күрсәтелгән «Ташкай»да, безнең заманнардан шактый ерак чорда чыгарылганнар һәм без аларда «...элеккеге дастаннардагы кебек, эпик герой образны сурәтләүне һәм төп вакыйганы шул образ тирәсенә туплауны күрәбез. Бу бәетләрдәге эпик геройлар патша түрәләре һәм байларга каршы күкрәк киереп көрәшүче батырлар итеп сурәтләнәләр» (Ярми Х. Бәетләр. Татарстан китап нәшрияты. Казан, 1960, 31 бит).

Талины (аның чын исеме Фәйзулла Сәйфетдинов) Актүк авылы бае Мизан мулла үзе урынына солдатка җибәрмәкче. Ләкин эше барып чыкмый. Тали буйсынмый, 25 ел буе качкын булып яшәргә мәҗбүр. Текстта алар бар да чагылыш тапкан.

Горький өлкәсендә, әйткәнемчә, иң таралган, иң популяр икенче бер бәет — «Ташкай»га аерым тукталыйк. Чөнки бу бәетне белмәгән-җырламаган бер генә татар авылы да, бер генә авыл карты да юктыр. Аны хәтта урта яшьтәгеләр дә, хәзерге буыннар да белә. Якташларым аны Мәскәүдә дә, Горький белән Казан каласында да, илебезнең башка шәһәрләрендә дә, кирәк икән, шундук җырлап бирәләр.

СССР Фәннәр Академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәрләре 1958 елда булган экспедиция вакытында шул бәетнең 11 строфасын Татар Маклаука авылында яшәгән 53 яшьлек Билал Бәдретдиновтан язып алганнар. Шул ук елны шул ук коллектив, Андреевкага да тукталып, авыл карты Мөхәммәди Бугровтан (1886 елгы) тагын 12 строфа өстәгән. Хәмит Ярми үз чиратында, Камка авылы кешеләре Хәмзә Мәҗетдинов һәм Хәбирә Исмаевaларны да тыңлап, бәет күләмен тагын да үстергән: бу юлы 18 строфага. Горькийлылар Гөмәр Минһаҗетдинов, Котдус һәм Рәшидә Абдюхановлар да, галимнәр үтенгәч, ялындырмый-нитми «Ташкай»ны җырлап күрсәткәннәр.

Бәетнең язылу чоры әлегә билгесез. Хәмит Ярми халыктан бу турыда: «XIX йөз урталарында булган хәлгә карата чыгарылган», — дигән сүзләрне кайчандыр ишеткән. Әмма мондый мәгълүматларны «фәнни яктан ачыкланган, дәлилләнгән фикерләр, дип кабул итү хата булыр», ди Мәхмүт Нигъмәтҗанов (Татар халык көйләре. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1976, 4 бит). Зиннәт Фәтхуллин, мәсәлән, «Ташкай»ны Пугачев хәрәкәтенә бәйләгән (Исхак Зәбиров. Җәлил һәм җәлилчеләр. Рус телендә. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1983, 40 бит). Кем белә бит, бәлки шулайдыр да, ә бәлки ул аннан да алдарак — Степан Разин чыгышына бәйледер? Һәрхәлдә, сораулар, әлегә җавапсыз сораулар...

Ташкайның туган ягы — Андреевка авылы. Элегрәк аны Метер авылы дип йөрткәннәр. Әнә бәеттә дә:

*Метер авылымны чыккан чакта*
*Кычкырсам чыкмыйдыр өн*
*генәм...,—*

дип әрни Ташкай туган җиреннән куылганда.

Бәет җырлаучыларны тыңлаганда Ташкайның качкын икәнлеген дә сизәсең:

*Кара урманнарда качып йөрим,*
*Йокламыйча татлы йокымны...*

Ни өчен ул шундый юлга баскан соң? Җавап эзләп баш ватасы юк. Патша законнарына, Бикчәнтәй кебек морзаларга, муллаларга каршы кыю чыкканы өчен. Шуңа да аны беричә тапкыр тоталар. Тотылгач, билгеле, Себергә куалар. Әмма Ташкай аннан да кача:

*Ун мең чакрымнан качып килдәм.*
*Казык йолдыз минем*
*юлдашым...*

Инде менә ул туган илендә, үзенең туган авылында:

*Караңгы төннәрдә айлар калка*
*Кайгылы кешегә йөрергә.*
*Миңа да бер ходай язган икән*
*Кайтып туган илне күрергә...*

Байлар, руханилар аны кабат эзәрлеклиләр, кабат кулга алырга тырышалар. Ташкай тагы качу ягын карый. Ул башта Анды авылы аша бармакчы. Әмма анда Али мулла — киртә:

*Тотсам, терелтә тунар идем*
*Анды иленең Али мулласын!*

— ди Ташкай, ачуына түзә алмагач. «Инде

нишләргә соң?» — дип тормый, ул икенче якка юл ала. Бу юлы Парша. Иш авыл, Бозлаулар аркылы өяз үзәге Васильга кузгала. Барасы юл шактый озын — илле чакрымнан да артык. Еракмыни бу ара аңарга — Себерләрдән качкан Ташкайга?! Ә шулай да борчыла баһадир:

*Парша белән Бозлау арасын*
*Ничек караңгыда барасың?*

— ди.

Ләкин караңгылык дошман түгел аңа, киресенчә — юлдаш, ярдәмче. Әмма дошманнары алда икән:

*Парша белән Бозлау арасында*
*Көлтә кебек солдат тезелгән.*
*Сугышыр да идем солдат белән,*
*Баксам кистән бавым өзелгән.*

*Кучка (куак) да төбендә яткан чакта*
*Яфрак явадыр ла йөземә.*
*Бирешмәс тә идем Бикчәнтәйгә*
*Унау бәйләнделәр үземә...*

Шуннан Ташкай кулга алына, җәзага тартыла.

*Кар тавыннан ары озаталар.*
*Туган илдә бетте көн генәм,*

дип хушлаша ул якташлары-авылдашлары белән соңыннан.

Ничәмә еллар үткән бит ул чактан! Шулай булса да онытмый халкым Ташкаен. Юк-юк та, халык җыелган җирдә әле дә ишетелә ерак еллар авазы:

*Ташкай кебек батыр юк иде,*
*Җәяләрдән чыккан ук иде...*

...Җыеннарда озын лирик көйләр дә еш яңгырый. Мәхмүт Нигъмәтҗанов бу турыда болай яза: «... Халыкның гасырлар буе камилләшкән көй сәләте, кичерешләре, тарихы, иң изге һәм тирән хисләре, хыяллары — болар барысы да озын көйләрдә. Алар тыңлаучының иң нечкә күңел хисләрен уяталар, тирән тойгылар, кичерешләр дөньясына алып китәләр».

Моның шулай икәнлеген төрле җырлардан, елаулардан һәм хәтта туй җырларыннан алынган менә бу юллардан күрәсең: «...Әй, дусларым, сезләргә ниләр булган, ике күзеңә канлы яшьләр тулган...» («Әй, дусларым»), «Адәм башларына хәсрәт төшсә, йөрисе юлларыннан да адаша...» («Азизә кыз»), «Бер карында яткан туган сеңелем, мусигынама атланып елыйдыр...» («Буран да гынай, буран»), «Сәфәргә йөреп тә малсыз кайтсаң, үз туганнарың, ай, ят була...») («Тәфтиләү»). Дәвам итүнең кирәге бармы икән?

*Әткәем, ызбаң саламдыр,*
*Салам гына түгел, сарайдыр.*
*Каеным ызбисы кабыктыр,*
*Кабык кына түгел, тәмуктыр...*

(«Болдырлары биек»).

«Заманалар авыр, михнәтләр күп», — дип юкка гына җырламаган бабаларыбыз. Ә шулай да алар бирешмәгән, сынмаган-бөгелмәгән. Шаянлык-наянлык, җор телләре белән шундый кыенлыкларны да җиңгәннәр. Андреевка авылы өлкәннәреннән, «Зимагорлар» җырын ишеткән бар:

*Мужик абый, кайт илеңә,*
*Иген чәчеп китәрсең.*
*Трубкаңны сука ясап,*
*Чабатаңны җигәрсең.*

Моңдыйларны белгечләр, дөрес, такмак дип атап үтәләр. Шулай икән — шулай булсын. Тик аларны бездә «Такмаклар» дип беркайда да, бер җирдә дә әйтмиләр: «Картош көе», «Челбәй», йә «кыска көй (кыска күй)» диләр дә, җырлыйлар да җырлыйлар:

*Без үзебез Казанныкы,*
*Казанда тумасак та.*
*Алдыйсың? Валлаһи!*
*Казанда тумасак та.*
*Сөярбез матур ярларны,*
*Матурлар булмасак та.*

...Халык җәүһәрләре... Шулай дип язып куйдым да, нәкъ шул исемдәге телевизион тапшыру үзеннән-үзе искә төште. Әле күптән түгел генә бит ул бар иде. Аны алып баручы И. Кадыйров ничек тырышлык күрсәтте ул чакта: үзе сөйләп, үзе баянда уйнап, үзе үк берәрсен җырлатып... Йә булмаса магнитофоны аркылы әллә кай җирләрдән һәм әллә кемнәрдән язып алынган, әлегә безнең колак ишетмәгән борынгы җырларны, бәет-көйләрне тыңлатыр иде.

Ә Мәскәүдән килгән «Хыял» ансамбленең «Нижгар такмаклары»н хәтерлисезме? Нинди алкышларга күмелде ул! Шуннан язып алган тасмамны куям да, йөрәк әллә нишли. «Бу бит безнең яктагыча, нәкъ Мишәрстанча!» — дип куанам шуны тыңлый-тыңлый.

Профессиональ җырчылар башкаруында «Олы юлның тузаны» җырын да без бик яратып тыңларга күнеккән. Баксаң, аның туган ягы Сергач ягы, Горький өлкәсе.

Өлкәнрәк тыңлаучылар Р. Ваһапов башкаруында «Урман»ны да яхшы хәтерлиләр. Моның белән әйтергә теләгән шул: якташ җырчыбыз Х. Бегичев ни өчен берәр «Нижгар» көен үз программасына кыстырмый икән? Баянчы Р. Курамшин да бит «безнеке»: ул — Кочко Пожарки авылыннан.

Татарстан җыр һәм бию ансамбле дә үз репертуарына төрле төбәк фольклор элементларыннан торган аерым номерлар әзерли ала.

«Минем фикеремчә, Казанда фольклор театры оештыру турында да уйларга вакыт җитте», — дип әйтеп үткән иде профессор Ш. Сарымсаков бу мәсьәләгә карата яшьләр газетасында оештырылган түгәрәк өстәл янында. Моның белән килешми мөмкин түгел.

Хәмзә ГАБДЕЛКАЮМОВ.

*Татар халкы:*
*төрле төбәкләрдә, төрле илләрдә*

# ШВЕЦИЯ ТАТАРЛАРЫ

Икенче бөтендөнья сугышы вакытыннан башлап, Швециядә татар колониясе яшәп килә. Колониядәге халыкның күбесе Түбән Новгород татар-мишәрләре. Борынгырак заманнарда бу иммигрантлар, качаклар рәвешендә, башлыча көнчыгыштан күченгәннәр. Кайберләре эшче күчләрнең Финляндиядән күчүе нәтиҗәсендә урнашып калган.

Кемнәр соң алар — татарлар?

II гасырда төрки халыкларның күчену дулкыны бүгенге Монголия һәм Алтай якларыннан көньяк-көнбатышка таба тартыла. Бер үк вакытта ул көньяк-көнбатыш юнәлештә дә бара. Безгә II гасыр башында Идел буена кыпчак кабиләләренең күченүе билгеле. Әмма болгарлар бу тирәгә алардан күпкә алдан күчеп киләләр. Кайбер галимнәрнең исәпләвенчә, алар Идел буена гуннарның һөҗүме нәтиҗәсендә «этеп чыгарыла». Болгарлар VII гасырда Иделнең өске ягында — Кама белән кушылган урында утрак тормыш корып, үз дәүләтләрен төзиләр. Яңа төрки кабиләләр бу дәүләткә XIII гасырда, монгол басып кергәннән соң кушылалар.

Төрле этник группалар: мөселман Идел болгарлары, кайбер фин-угыр кабиләләре, төрки күчмә халык (аларны инде ул вакытта ук татарлар дип йөртәләр), бергә кушылып, татар исемен йөртүче яңа этник төркем оештыралар. Шуны истә тотарга кирәк, беренче вакытларда татар дип чыгышы белән монгол булган кешеләргә әйткәннәр.

Алтын Урда дәүләтенең соңгы елларында аның халкы чиста монгол гына булмый. Бату ханның гаскәре 1237 елда ук инде башлыча төрки кабилә кешеләреннән тора. Тарихчыларның берсе бу хакта болай дип яза: «Бу ханлыкта төрки сугышчылар монголлардан күпкә артык иде». Төрки кабиләләрнең Идел тирәләренә күчүе XIV гасыр ахырында тәгамамланган, дип фараз кылу бар.

Бату хан идарә иткән вакытта Алтын Урдага Казан һәм Әстерхан шәһәрләре керә. Киев, Мәскәү, Новгород кебек вассал шәһәрләр дә Урданың өлешләре булып санала. Әмма Мәскәү Русенең үз эчендәге каршылыклары һәм экспансиясе (яулап алу) аркасында, Алтын Урда 1502 елда тарала. Нәтиҗәдә берничә яңа — Казан, Әстерхан, Кырым, Себер, Нугай һәм Касыйм ханлыклары барлыкка килә.

Татарлар Идел буенда таралып урнашкан. Түбән Новгород, Пенза, Ульяновск (элеккеге Сембер) шәһәрләрендә һәм аларга якын урыннарда алар бүгенгәчә гомер кичерәләр. Аларның күбесе Касыйм шәһәре һәм Ока буеннан чыккан мишәрләр.

Финляндия һәм Швециягә татарлар ничек килеп эләгә соң? Түбән Новгородтан көньяк-көнчыгышка таба 100 километр ераклыкта урнашкан Сергач каласы бар. Ул XIX гасыр ахырында тимер юлның иң соңгы станциясе дип саналган. Сергачтан көньяктарак исә, элеккеге патша Россиясенең Түбән Новгород губернасындагы 35 татар-мишәр авылыннан барлык Эстония, Швеция һәм Финляндия татарлары чыккан.

Күчүнең икенче стадиясе, мөгаен, Россия империясе эчендә эшче күчләрнең Финляндия тарафына алышуы нәтиҗәсендә башлангандыр. Ачтан үлмәс өчен, Сергач татарлары яңа җирләр эзләгәннәр. Узган гасыр урталарында мишәрләрдән вак сәүдәгәрләр, чикне узып, Эстония һәм Финляндиягә барып чыгалар. Соңрак алар шушы илләрдә урнашып та калалар, үзләре янына хатыннарын һәм балаларын алдыралар.

Икенче бер зур халык арасына килеп кушылсалар да, алар анда таркалып югалмыйлар. Диннәрен, телләрен, гадәт-йолаларын саклый алалар. Бу — фин татарларының көчле этник инфраструктурасы аркасында гына мөмкин була. Билгеле, милли үзенчәлекне саклап калырга ярдәм иткән

башка сәбәпләр дә бар, болар — балаларга кече яшьтән татар телен өйрәтү, катнаш никахлардан баш тарту. Фин татарларының хәтта алтынчы буыны да ассимиляциягә бирешми.

Икенче бөтендөнья сугышы һәм эшче кулларның миграциясе татарларны көнчыгыштан Балтыйк диңгезен кичеп, Швециягә җитәргә мәҗбүр итә. Бу — алар күчешендә өченче стадия.

Швеция татарлары 1949 елда Стокгольмда «Швециядә дин һәм мәдәният эшләре буенча төрек-ислам ассоциациясен» төзүгә ирешәләр. Беренче вакыт оешмада (соңыннан ул «Швециянең ислам җәмгыяте» дип үзгәртелә), күпчелекне тәшкил иткән татарлар, төрле илләрдән мөселманнарның иммиграциясе арткач, аның өстеннән контрольлекне югалталар. Тиздән башка мөселманнар аларны сан ягыннан күпкә узып китә.

Швеция татарлары үзләрендә, Эстония һәм Финляндиядәге ватандаш милләтләре кебек үк, ныклы инфраструктура төзи алмыйлар. Шулай ук, колониядә татар этник ассоциациясен үзгәртеп оештыру да барып чыкмый. Беренче-икенче буыннар этник группаны тәшкил итә, ягъни татарлардан тора иде, ә аннан соңгылар ассимиляция проблемасы белән бәрелешә. Бу фактлар швед татарлары өчен фаҗигале тәмамланырга, ягъни алар милләт буларак, югалырга мөмкин. Группаның аз булуы — 80 ләп кеше — аркасында катнаш никахлар арта. Социаль-этник оешма һәм үз милли укыту системасы булмау яшь буынны телне, гореф-гадәтләрне онытуга китерә. Швециядә бу группаның этник бердәм булып, дүртенче буын азагына кадәр яшәве дә инде бик икеле.

**Тюркар СУЫККАН,**
юридик фәннәр кандидаты.

*(Швециядә яшәүче төрки халыклар турында Истанбулда чыккан мәкаләләр җыентыгыннан).*

---

## *Котлыйбыз!*

# Адлер Тимергалинга 60 яшь



Адлер Камил улы Тимергалин 1931 елның 1 гыйнварендә Татарстанның Сарман районы Иске Минзәләбаш авылында укытучы гаиләсендә туа. Урта мәктәптән соң Казан дәүләт университетының астрономия бүлегендә белем ала. 1952 елда Ташкентка китеп, укытучылар институтына укырга керә. Аны тәмамлагач, 1955 елның кышына кадәр туган авылында укыта. 1956 елда Казанга килә, 1957 — 1969 елларда Татарстан китап нәшриятында эшли. 1970 елдан соң ул бары тик әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә. Ә 1979 елдан бүгенге көнгәчә китап нәшриятында өлкән редактор булып эшли.

Адлер Тимергалин — татар әдәбиятында фәнни фантастика жанрын үстерүгә күп көчен салган язучы. Аның «Роберт, уян сөеклем!» исемле беренче фантастик хикәясе 1959 елда «Идел» альманахында басылып чыга, ә инде бер елдан аның «Пәһлеван кабере» дигән тәүге китабы да дөнья күрә. Шуннан соңгы елларда язучы «Ике хикәя, бер хыял», «Ерак планетада», «Мәңгелек хатирәләр», «Космостан кунаклар», «Адашкан йолдыз», «Таш алиһә», «Кайтыр юллар» һ. б. китаплар иҗат итте.

Ул — 1975 елдан СССР Язучылар берлеге агъзасы.

Каләмдәшебезне олы бәйрәме белән чын күңелдән котлыйбыз, аңа ныклы сәламәтлек, озын гомер һәм яңа иҗади уңышлар телибез!

## В. В. Бартольд

# КЫСКАЧА ИСЛАМ МӘДӘНИЯТЕ ТАРИХЫ

ӨЗЕК

...Мөселманнарның мәдәнияттә алдалыклары, кирәк сугышларны алып баруда вә кирәк солых вакытында булсын, дәүләт хәятендә дә күренә иде. 9 нчы гасырның башында Бизантиядә (Византиядә) гарәп инструкторы булганлык зикер ителәдер: ул румлардан вәгъдә ителгән мөкяфәтне ала алмагач, ул вакытта әле мәҗүси булган болгарларга китте вә аларның беренче мәртәбә юнаннарны җиңүенә сәбәб булды. (851) дә шул ук 9 нчы гасырда гарби Яурупадан барган христиан хаҗилары үзләренең хәят вә милекләре ислам йортында үз ватаннарындагыга караганда әминрәк булганлыкны игътираф итәләр. Шулай була торып гыйлем вә аңның күтәрелүе табигатьнең йомшаруына, иҗтимагый әхвәлнең һәм дәүләт идарәсенең үзгәрүенә аз тәэсир итте. Философлар Әфләтун һәм Аристуның сәяси нәзарияләре белән таныш иделәр: аларның бәгъзеләре, шул җөмләдән Фараби сәясәткә даир әсәрләр дә яздылар. Ләкин бу әсәрләр идеалдагы «Төзек шәһәрне» тасвирдан гыйбарәт булып, хакыйкый тормыштан ерак тора иде. Фарабиның хөкүмәт идарәсе хакында шул фикерен күрсәтү җитәдер ки, ул әгәр хаким өчен кирәкле сыйфатлар бер кешедә табылса, хакимият шуңа тапшырылырга тиеш, әмма әгәр мондый бер кеше табылмаса, бернichә кешелек бер комиссия ясарга кирәк ки, кирәкле сыйфатлар берәм берәмендә табылмаса, барысын бергә җыйгач табылыр, дигән бер фикерне алга сөрәдер.

Бартольд В. В. Кыскача ислам мәдәнияте тарихы. — Казан, 1922, 37 б.

---

**Искәрмәләр:** В. В. Бартольд (1869—1930) — академик, Шәрыкне өйрәнүче күренекле тарихчы һәм тюрколог.
Зикер — искә алу, телгә алу; мөкяфәт — бүләк; юнаннар — грециялеләр; гарби — көнбатыш; Әфләтун — Платон, безнең эрага кадәр V—IV гасырларда яшәгән борынгы грек философы; Аристу — Аристотель, безнең эрага кадәр IV гасырда яшәгән борынгы грек философы; Фараби (870—950) — философ, энциклопедист-галим; игътираф — үзенең гаебен тану, әйтү; сәяси нәзария — сәяси (политик) карашлар; бәгъзе — кайбер; даир — бәйләнешле, караган.

ۋ. ۋ. بارتۇلد. قسقاچا ئیسلام مەدەنیەتێ تاریحێ.
(ئۈزێنك)

مۆسلمانلارنڭ مەدەنیەتدە آلدالقلارێ کیرەك سوعشلارنێ آلب بارودا وە کیرەك سۇلح واقتندا بولسن، دەولەت حەیاتندا دا کورێنە ئیدێ. ۹ نچێ عەسرنڭ باشندا بیزانتیەدە عەرەب ئینستروکترێ بولعانلق زیکر ئیتێلەدر: ئول روملاردان وەعدە ئیتلگەن مۆکافەتنێ آلا آلماعاچ، ئول واقتدا ئەلێ مەجوس بولعان بۇلعارلارعا کیتدێ وە آلارنڭ برنچێ مەرتەبە یونانلارنێ جیڭووێنە سەبەب بولدێ. (۸۵۱) دە شول ئوق ۹ نچێ عەسردا عەرەبی یاورو- پادان بارعان حریستییان حاجیلارێ ئۈزلەرێنڭ حەیات وە میلکلرێ ئیسلام یۇرتندا ئۈز واتانلارنداعێعا قا- راعاندا ئەمینرەك بولعانلقنێ ئیعتیراف ئیتەلەر. شولای بولا تۇرب علم وە آڭنڭ کوتەرلووێ تابیعەتنڭ یو- مشاروونا، ئیجتیماعی ئەحوالنڭ هەم دەولەت ئیدارە- سێنڭ ئۈزگەروونە آز تەئسیر ئیتدێ. فیلاسوفلار ئەفلا- تون هەم آریستونڭ سەیاسی نەزەریەلەرێ بلەن تانش ئیدێلەر: آلارنڭ بەعزێلەرێ، شول جوملەدەن فارابی سەیاسەتکە دائیر ئەسەرلەر دە یازدێلار. لاکین بو ئەسەرلەر ئیدیالداعێ «تۇزك شەهەرنێ» تەسویردان عیبارەت بولب، حەقیقی تورمشدان یراق تۇرا ئیدێ. فارابینڭ حوکومەت ئیدارەسێ حاقندا شول فیکرن کورسەتو جیتەدرکی، ئول ئەگەر حاکیم ئۈچن کیرەکلی سیفاتلار بر کشێدە تابلسا، حاکیمیەت شوڭا تاپشرلرعا تیێش، ئەمما ئەگەر مۇندی بر کشێ تابلماسا، برنیچە کشێنڭ بر کامیسیە یاسارعا کیرەك کی، کیرەکلی سیفاتلار برەم برەمندە تابلماسا، بارسن برگە جیعاچ تابیلر، دیگەن بر فیکرنێ آلعا سۇرەدر.

*Текстны журнал өчен Җәүдәт Миңнуллин һәм Раиф Мәрданов әзерләде.*

## ТАТАРСТАН КУНАКЛАРЫ

29 декабрьдән 31 декабрьгә кадәр Татарстан республикасында ИҮБның (Ислам Үсеш Банкы) һәм «Эль-Игаса» Комитеты (Согуд Гарәбстаны һәм Төркия) берләштерелгән миссиясенең делегациясе — СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнары диния нәзарәте мөфтие Тәлгать Таҗетдин кунаклары булдылар.

ИҮБның Төркиядәге советы әгъзасы, Төркия республикасы Президенты И. Озалның абыйсы, доктор, профессор Коркут Озал җитәкчелегендәге бу делегация республикабыз башкаласы һәм Зеленодольск шәһәре мәчетләрендә булды, «Мәрҗани» мәчетендә намаз укуда катнашты, Кремльне, Сөембикә манарасын карады, Казанның бүтән истәлекле урыннарында булды.

30 декабрьдә Согуд Гарәбстаны, Иордания, Төркиядән килгән эшлеклеләр һәм дин әһелләре делегациясен Татарстан ССР Министрлар Советы Рәисе М. Г. Сабиров кабул итте. Җылы шартларда үткән әңгәмә вакытында ул Татарстанның суверенлыгы турындагы Декларация кабул ителгәннән соң республиканың экономик һәм социаль тормышында башланган үзгәрешләр хакында, Татарстан җирендә дини хәрәкәтнең активлашуы, республикадагы башкаручы власть органнары тарафыннан бу хәрәкәткә күрсәтелә торган булышлык турында сөйләде. М. Г. Сабиров Татарстанның мөселман илләре белән багланышларының җанлана башлавы белән хөкүмәтнең һәм халыкның канәгать булуын әйтте. Күптән түгел генә, диде ул, Татарстан Төркия белән һәр ике як өчен файдалы багланышларга керде. Һәм республика, аның халкы Согуд Гарәбстаны белән дә шундый ук мөнәсәбәтләргә керергә әзер.

Мондый фикер делегация әгъзаларында яклау тапты. Ислам Үсеш Банкы, диделәр алар, хәзерге вакытта 45 мөселман иленә хезмәт күрсәтә.

М. Г. Сабиров делегация әгъзаларының күп санлы сорауларына җавап бирде.

### Австралиядә яшәүче милләттәшләребезнең Татарстан җөмһүрияте югары мәҗлесенә мөрәҗәгате

Сөекле милләттәшләребез, бөтен Татарстан җөмһүриятендә яшәүче ватандашларыбыз!

Сезләрне Австралиядә яшәүче милләттәшләрегез булган бәндәләр барчабызга да уртак шатлык булган Татарстан җөмһүриятенең мөстәкыйльлек алуы белән чын йөрәктән тәбрик итәбез.

Шулай ук үзебезнең дә никадәр шатланганлыгыбызны белдерергә телибез. 1990 ел 30 августта Татарстан җөмһүрияте мөстәкыйльлек алганлыгы турында гаять зур шатлыклы хәбәрләр ишеттек. Безләр аны ишетеп шатлыгымыз эчемезгә сыймый калды. Сезгә шөкерлекләр булсын, мондый яхшы хәбәрне дә ишеттек! Иншалла, инде безнең ватаныбызның, милләтебезнең киләчәге өчен бик файдалы бер вәзгыятьләр булыр дип өмет итәбез.

Татар милләтебез — бөек бер милләт. Мәдәният, әхлак һәм дә гыйлем, фәннең нигезе булган, зур тарихка ия бер милләт. Ни-ни зур галимнәр, шагыйрьләр, белемле рәһбәрләрне җитештергән мәгарифкә ия ул. Дөньяның күп җирләренә гыйлем-фәнне тараткан, матбугатка ия булган милләтебезнең киләчәктә тагын да зур уңышларга ирешүе шиксез.

Безләр язмышның җилләре очырып чит илләрдә яшәсәк тә, Татарстан — безнең ватаныбыз, һәрвакыт күңелебез сезләр белән гел бергә!

Сезләргә зур уңышлар вә барча яхшылыкларны теләп: **Фатыйма Вәлиева**, **Мөшәрәф Вәлиева**, **Нәҗәт Вәлиев**, **Садыйк Вәлиев** гаиләсе, **Әхмәт Вәлиев** гаиләсе, **Риза Вәлиев** гаиләсе, **Сөенгел Чанышева**, **Азат Чанышев**, **Кафия Чанышева**, **Әхмәт Игәмбирде**, **Зәкия Игәмбирде** гаиләсе, **Энәс Юлдабаев**, **Суфия Юлдабаева** гаиләсе, **Зыя Маски**, **Гайшә Маски** гаиләсе, **Рамил Садри**, **Фирдәвес Садри** гаиләсе.

Аделаиде шәһәре,
Австралия.

## 7 ГЫНВАРЬ — ЭШ КӨНЕ САНАЛДЫ

РСФСР Югары Советы 1990 ел, 27 декабрь карарында 7 гыйнвар көнен (Христос туган көн) ял көне дип игълан иткән иде. Әлбәттә, христиан халкы өчен бу — зур вакыйга. Ләкин төп халкын мөселманнар тәшкил иткән Татарстанның үзенчә яшәргә хакы бар һәм бу җәһәттән ТССР Югары Советы бик тә урынлы карар чыгарды. Татарстан ССР дәүләт суверенитеты турындагы Декларация нигезендә һәм Татарстан ССРда бәйрәм көннәре турында закон кабул иткәнчегә кадәр 7 гыйнвар эш көне дип саналды.

## ПАРТИЯ ҖИТӘКЧЕСЕ — ЯЗУЧЫЛАР ЯНЫНДА

21 ноябрьдә ТССР Язучылар берлегенең Г. Тукай исемендәге клубында КПСС рескомы беренче секретаре Р. Р. Идиатуллин белән очрашу үткәрелде. Ул, язучылар алдында чыгыш ясап, Коммунистлар партиясенең бүгенге хәле, аның томышта тоткан роле,

илебездә оеша башлаган башка партияләргә мөнәсәбәте, республикабызның мөстәкыйльлеге өчен барган көрәштәге каршылыклар, алардан чыгу юллары һәм башка мәсьәләләргә тукталды.

Эшлекле, җитди сөйләшү барышында Р. Р. Идиатуллин язучыларның күп кенә сорауларына җаваплар бирде.

## ҮЗГӘРЕШЛӘР СОРЫЙ ЗАМАНА

Татар иҗтимагый үзәгенең чираттагы пленумында хәрәкәтнең яңа платформага күчүе игълан ителде. Платформа тезисларында иҗтимагый үзәкнең Казан педагогия институты базасында татар университеты, мәдәният институты һәм Казанның башка мәдәният-сәнгать уку йортлары берләшкәннән Татарстан Сәнгать академиясе, авыл хуҗалыгы уку йортлары нигезендә авыл хуҗалыгы академиясе булдыру өчен көрәшәчәге, колхоз һәм совхозларны кечерәйтү процессын хуплаячагы, татар бизнесын яклаячагы, дини уку йортлары булдыру кирәклеген алга сөрәчәге бәян ителде.

Пленумда Татарстан егетләренең хәрби хезмәтне Татарстанда үтәргә тиешлеге, Татарстан төбәген Көнчыгышның бер өлеше дип карап, киләчәктә гомумтөрки телгә бурылыш ясау кирәклеге кебек әлегә бәхәсле булган мәсьәләләр дә кузгатылды.

Пленумда Татар иҗтимагый үзәгенең уставына да кайбер үзгәрешләр кертелде.

## ТЕЛӘКТӘШЛЕК

10 декабрьдә цирк бинасы тамашачы белән шыгрым тулы иде. Концерт-ял кичәсе аларның өметен аклады: тамашачылар алдында шагыйрьләр Әхмәт Рәшитов, Рәшит Әхмәтҗанов, артистлардан Айрат Арсланов, Вафирә Гыйззәтуллина, Равил Шәрәфиев, Римма Ибраһимова, Руслан Дәминов, Венера Ганиева һәм башка күренекле сәнгать осталарыбыз, Татарстанның җыр һәм бию ансамбле чыгыш ясады.

Татар иҗтимагый үзәге лидерлары М. Мөлеков, Г. Фәйзрахманов, Р. Газизовның бүгенге сәяси хәлебез, башкарылган эшләр турында сөйләве дә халыкта зур теләктәшлек тапты.

Концерт-очрашудан кергән акча Татар иҗтимагый үзәге файдасына күчерелде.

## ӘЛМӘТТӘ — «МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕК» КЛУБЫ

Әлмәттә «Мөстәкыйльлек» клубы оешты. Аның төп максаты — халык арасында аңлату эше алып барудан тыш, республика Югары Советы сессиясе игълан иткән мөстәкыйльлек Декларациясе идеяләрен тормышка ашыруда җөмһүриятебезгә ярдәм итү.

Татарстанның мөстәкыйльлегенә каршы төрле яктан, аерата Үзәктән көчле һөҗүм барган бер заманда, бу клубның оешуы бик вакытлы һәм урынлы. Аны оештыручылар — КПССның Әлмәт шәһәр комитеты идеология комиссиясе һәм Татар иҗтимагый үзәгенең Әлмәт бүлеге.

## ТАТАР СТУДЕНТЛАРЫНА — ГАЗЕТА

Быел республикабызда татар телендә яңа газета нәшер ителәчәк. Ул — Татарстан Республикасы студентлары газетасы.

Аны оештыручылар арасында ВЛКСМның Татарстан республика комитеты һәм Татар яшьләре берлеге, Казан дәүләт университеты, консерватория, Чаллы педагогия институты, Казанның медицина, педагогия, ветеринария, төзүче-инженерлар, мәдәният, финанс-экономика һәм авыл хуҗалыгы институтлары бар.

## МУЗЕЙЛАР САТЫЛМЫЙ

Татарстан ССР Мәдәният министрлыгы системасында мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең арендага бирелгән биналары, музей әсбаплары, рәсем сәнгате әсәрләре, китапханә фондлары, тарих, мәдәният һәм архитектура һәйкәлләре сатылмый. Татарстан Министрлар Советы 1990 елның 29 декабрендә әнә шундый карар кабул итте.

## ХӘСӘН ТУФАН ЮБИЛЕЕ

17 декабрьдә К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында классик шагыйребез Хәсән Туфанның тууына 90 ел тулуга багышланган кичә булды.

Аны кереш сүз белән Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев ачты. Әдипнең иҗат гомере турында шагыйрь Роберт Миңнуллин сөйләде. Аннары Хәсән Туфан турында истәлекләр яңгыратылды. Чыгыш ясаучылар арасында Башкортстаннан килгән кунак — РСФСР Дәүләт премиясе лауреаты шагыйрь Наҗар Нәҗми дә бар иде.

Кичәнең икенче өлешендә әдәби-музыкаль тамаша булды.

* * *

Хәсән Туфанның туган авылы Иске Кармәттә аның музее ачылды. Хәзергә ул кысанрак кына бүлмәдә урнашкан, якын киләчәктә исә яңа музей-йорт сафка басарга тиеш.

## ГАЛИМНЕ ОЛЫЛАУ

Узган ел ахырында Төркиянең өч университетында татар галиме — телче, тарихчы Зәки Вәлидинең тууына 100 ел тулуга багышланган конференцияләр булып узды. Аларны бөтен дөньяга билгеле галимнәр — З. Вәлидинең шәкертләре уздырды.

Зәки Вәлидигә багышлап Голландиядә үткәрелгән конференциядә Татарстан халык депутаты язучы Фәүзия Бәйрәмова да катнашты.

# ТАТАР ТӘҢКӘЛӘРЕ

Безнең бабаларыбыз Көнчыгыш Европага югары культура элементлары алып килүчеләр буларак тарихта билгеле: алар беренче феодаль дәүләт төзүчеләр (Хазар дәүләте), беренче булып төзелештә һәм архитектурада кирпеч (кәрпәч) кулланганнар (хазарлар, болгарлар) һәм бигрәк тә җәмгыять үсешенең югары бер баскычы булган процесс — акча йөреше кертқәннәр. Иң беренче тәңкәләр Идел буенда урнашкан Хазар башкаласы Итил шәһәрендә 737 елда рәсми рәвештә ислам дине кабул ителгәннән соң сугыла башлаган. Киев Русе урыс, белорус һәм украиннар өчен уртак тарихи җирлек булган кебек, Хазар дәүләте дә Идел-Урал, Кавказ, Кырым төркиләре өчен уртак тарихи бишек булган. Өч гасыр дәвамында барлыкка килгән уртак культура, уртак дәүләт телен мирас итеп алган болгар шәһәрләре Болгар һәм Суарда да тәңкәләр сугыла.

Идел буе шәһәрләрендә сугылган тәңкәләр шулай ук бу шәһәрләрдә йөрештә булган гарәп дирһәмнәре белән аралашып борынгы урыс шәһәрләренә үткәннәр һәм анда бердәнбер акча берәмлеге булып хезмәт иткәннәр. Тәңкә сүзе үзе дә урыс теленә «деньга» булып кергән (борынгы формасы дәник, дәнкә — авырлык берәмлеге).

Журнал тышлыгында сез күргән тәңкәләр алтын-көмеш түгел (хәер, андыйлары да күпләп сугылган). Болар бары тик Идел буе шәһәрләрендә XIV—XV йөзләрдә әйләнештә йөргән бакыр пуллар. Кайбер болгар пулларында «Уналты пулы — дәник» яки «Котлы булсын яңа пул!» дигән язулар бар. Бу түкми-чәчми күчереп алынган язулардан сез XIII—XIV йөзләргә караган болгар теле, шул хисаптан, Идел буе шәһәрләре теле турында фикер йөртә аласыз. Пул сүзенең килеп чыгышы кызыклы: борынгы Римда бакыр акчалар очсызлангач, аларны капчык белән йөрткәннәр («фоллис» — капчык). Болгар теленә ул пул булып кергән.

Ислам дине рәсем ясауны тыйган икән дигән сүз дөреслеккә туры килеп бетми. Коръәндә андый тыю юк. Меңләгән бакыр акчаларда (бер дәниккә — 16 пул, бер көмешкә — 32 пул, ә бер алтынга 96 пул килгән!) нинди генә орнамент булмаган да, нинди генә рәсемнәр төшерелмәгән! Ул сандугач сурәте дисеңме, горур басып торган бөркет, я булмаса күтәрелеп килүче кояш нурларында мәһабәт атлаган барс, яки канатларын җәйгән ике башлы каракош дисеңме — бар да бар.

Сарайларда акча суккан бабаларыбыз көчле экономистлар да булганнар. Акча системасы шактый катлаулы, нык уйланып эшләнгән. Кечкенә аңлатмада барсын да сөйләп бетерү мөмкин түгел, тик шунсын әйтеп үтим, төрле язуларның, рәсемнәрнең тирән мәгънәсе бар! Аларны халык яратып, теләп алсын өчен шулай эшләгәннәр. Матур итеп, яхшы теләкләр белән сугылган пуллар сандыклардан көмеш тәңкәләрне чыгарырга ярдәм итәргә тиеш булган, чөнки акчаларның сандыкта саклануы хөкүмәт өчен бервакытта да уңай күренеш түгел. Шуңа күрә пулларга төрки календарьдагы ел сынамышларында яхшыга юралган кош яки җанвар сурәтләре сугылган да. Мондый юрамалар халык арасында хәзергә кадәр сакланган: барс елы — байлык, тычкан елы — баллык, сыер елы — туклык, куй елы — кытлык, куян елы — йотлык һ. б.

Пулларда рәсем һәм бизәкләрдән тыш тамгалар да бар. Акчадагы бишпочмаклы «йолдыз» эчендә сез урда ханнары тамгасын күрерсез. Тәңкәләрнең берсендә тартылган җәяне хәтерләтүче тамга — Казан тамгасы. Казанның меңләгән акчалардагы рәсми исеме «Болгар», чөнки Казан — борынгы Болгарның дәвамчысы. Беренче мәртәбә мондый тамга Казан патшалыгының мөстәкыйль хакиме Гиазетдин (1422—1445) акчаларында сугыла башлый.

Әзһәр **МӨХӘММӘДИЕВ.**


Юрий **ФИЛИМОНОВ** фотосы.

Борынгы тәңкәләр белән кызыксынган укучылар игътибарына. 1991 елның башында Татарстан китап нәшриятында авторның рус телендә «Древние монеты Поволжья» дигән китабы чыга.

**Тышлыкның дүртенче битендә.** Татарстанның халык язучысы, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Гомәр Баширов.

Рәссам **Әхмәт Кытаев** рәсеменнән **А. ФИРСОВ** репродукциясе.

Бәясе 1 сум 50 тиен. Индекс 73210




КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРСТАНА
(на татарском языке)